**Зиннур Хөснияр**

# ЭТТӘН ТУГАН

Роман-дилогия
Повесть
Хикәяләр

*Казан*
*Татарстан китап нәшрияты*
*2005*

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)–44
Х 97

**Хөснияр Зиннур**

Эттән туган: Роман-дилогия, повесть, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 383 б.
Бу китап болгавыр заманыбызның мең дә бер төрле халәте турында. Җитәкчеләрнең башбаштаклыгы, әхлаксызлыгы да, бүгенге көннең фәлсәфи нигезе дә сурәтләнә һәм, әлбәттә, саф мәхәббәткә дә күп урын бирелә.

ISBN 5–298–04126–4
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Зиннур Хөснияр

## БЕРЕНЧЕ КИТАП

## ТЕРСӘК СУГЫШЫ

### Мөхәммәт — пәйгамбәр түгел

Ике нәни кошчык юл буендагы әрем арасыннан пырхылдап килеп чыктылар да, — алар тургай балаларына да охшамаган, сыерчык балалары да түгел, кыскасы, таныш булмаган ниндидер кош малайлары, — әүвәл, бер-берсен куыша-куыша, күз күреме биеклегендә әйләнделәр-тулгандылар да, шул рәвешле канатларын бераз чарлаганнан соң, кинәт югарыга, аккош каурые сыман ак болытларга таба күтәрелә башладылар. Күренеп тора: алар иксез-чиксез зәңгәр күк белән хозурланып туя алмыйлар иде.

Каяндыр икенче бер зур кош пәйда булды. Ул, чыннан да, иләмсез зур һәм гайрәтле бөркеткә дә, тилгәнгә дә охшамаган кыяфәтсез дәү кош; аның аяклары да самолетның җирдән күтәрелеп киткән вакытында җыеп өлгерелмәгән тәгәрмәчләре кебек канат асларына яшерелмәгән, шөкәтсез булып тырпаешып, асылынып торалар.

Ике нәни кошчык һаман биеккә, һаман болытларга таба күтәрелделәр, ә теге кош, җилкән кебек канатларын иренеп кенә җилпи-җилпи, нәкъ алар турысында әйләнгәләп йөрүендә булды. Һәм кинәт ул котсыз гәүдәсен күккә чөеп җибәрде, күз ачып йомган арада югары күтәрелде, очкан уңайдан нәни кошчыкның берсен авызына капты, икенчесен тырнакларына эләктерде дә, кыя башыннан егылып төшкән таш кебек, җиргә якынлашты. Төшеп җитәм дигәндә генә кош балаларын, мәхбүслектән ычкындырып, иреккә җибәрде; тегеләре, чырык-чырык елашып, болын өстеннән әйләнделәр дә, янә тузанлы әрем арасына кереп югалдылар.

Иләмсез канатлы һәм кыяфәтсез дәү кош алтын кояш нурлары белән чигелгән зәп-зәңгәр күктә үзе генә калды. Бу —аның патшалыгы иде.

Юлчы егет әлеге галәмәтне күзәтеп бара иде. Ләкин бу хакта исе китеп, шаккатып, уй-фикер йөртә-йөртә нәтиҗәләр ясарга аның исәбе күренми. Күрәсең, йә кулындагы сумкасы бик авыр, яисә үз уйлары көчлерәк иде.

Кешеләр, бу Җирнең бай бәндәләре, хәерче адәмнәре, аларның да йорт-җирсезләре, мулла-мунтагайлары, рухани-изгеләре, наданнары вә гыйлемлеләре, шыр тилеләре һәм түгәрәк башлары, сыерлары, сарыклары һәм дуңгызлары, шуннан килеп, очар вә сайрар кошлары, туфракта сөйрәлүчеләре, тагын... чебен-черкиләре, барча бөҗәкләре, үсемлекләреннән — кычытканнары, имән, каен агачлары, кыскасы, барлык җансыз һәм җанлы нәрсәләренең аңлый алганнары һаман аңларга, белергә, танырга теләмәүчеләре, дөньяны тою әгъзалары белән тоярга сәләтлеләре бер хакыйкатьне һич кенә дә кабул итә алмыйлар: Хак Тәгалә китабында язылганча гына түгел, чынбарлык тормышның үзенә дә ахырзаман күптән, әллә кайчан килеп җиткән һәм барчасы да шунда кадалышып, чукынышып, сөешеп-суешып, сатып-сатылып, адашып-саташып, тагын әллә ниләр кыланган булып, яшәгән кыяфәт ясап шуышалар гына, бәргәләнеп кенә яталар лабаса!

Кемдер фани дөнья тәмугында яна. Кайсылары шул ук җиһанның оҗмахына эләккән. Ләкин һәммәсе дә бер йорт эчендә. Ул йортны күптән социализм дип тә, капитализм дип тә атамыйлар инде. Ул — ахырзаман җәмгыяте. Бер төшеннән ямап кына куялар, икенче җирдән бүселеп тә чыга. Ары ни булыр, алдагысы, чираттагысы?.. Ахырзаманның да ахыры булырмы?

...Кәстүмен уң җилкәсенә салып, ашыкмый-кабаланмый гына Ташсу елгасы яры буйлап сузылган сукмактан туган авылына таба атлаган Мөхәммәт атлы егерме сигез яшьләр тирәсендәге гәүдәгә нык, таза ир-егетне әлеге дөньяви уйларыннан су буендагы комлыкка туплауга җыелган сарык-кәҗә көтүенең ара-тирә кычкырган тавышлары арындырдымы, ул болай да күңел-уйларын еш кына Җир һәм Күк арасында чөеп уйнатырга яраткан, төгәлрәге, ярым хыялый, ярым реаль кеше, капылт туктап, көтүне күзәтергә кереште.

Иртәгә аларга да көтү чираты. Мөхәммәт инде шәһәр кешесе, ул күптән, мәктәп тәмамлап чыгып киткәннән бирле, калада яши. Авылдагы әти-әнисенең ике баш сарыгы, сыңар кәҗәләре бар. Әнә шуларны көтәргә чират килеп җиткән икән.

Иртәгә аның туган авылы Байтимердә сабан туе. Ә ул үз теләге белән урман буена сарык көтүен алып чыгачак. Сабантуйга барырга күңеле тартмый.

Мөхәммәт ахырзаман җәмгыяте хакындагы уйларын үзе туктатты. Кыскасы, шартлатып бикләп, бер шагыйрь дустым авызыннан ишеткән сүзләр белән мөһерләп тә куйды.

Йә, җитәр. Үчләнмим.
Калганы хакында авыртсын ар башы.

Ар авылы ерак түгел, күршедә генә, ике чакрымлап булыр. Янәшәсендә урыс авылы да бар. Аннан чак кына арырак мари авылы. Кыскасы, бик тә интернациональ төбәк булып чыга икән әле бу!

Аны баягы уйларыннан... фәлсәфәсеннән, дөресрәге, комлы-тузанлы Байтимер юлыннан шактый авыр сумкасын күтәреп, тәпиләп кайтып барганда, арттан куып җиткән җиңел машина бүлдерде. Олы юлдан читкә тайпылып, Ташсу буендагы сукмакка шуннан соң гына кереп китте ул. Артыннан машиналы тагын берәр авылдашы куып җитмәсен дип... тагын узып китмәсен дип.

Тегесе алай выжылдап ук узып китмәде китүен, туктады. Классташы Сәмигулла икән. Өр-яңа «Нива»га менеп кунаклаган. Ул шып итеп туктады да көпчәк тузаны басылганчы әүвәл ишеген ачмый торды, аннары, сикереп төшеп, очына-очына, узгынчы машинага утырам дип өметләнгән Мөхәммәт янына килде.

—А-а! Яшьти! Кайтып килешме? Менә мин дә яңа машина куып кайтам әле. Казанның үзеннән үк! «Нива» алдым инде, яшьти, «Нива». Авыл җирендә шәп машина! Түлке мин, яшьти, ачуланма инде, утырта алмыйм. Өр яңа әле ул! Нумеры да алынмаган. Беренче итеп хатынны — Рәзифәне утыртырмын дигән ием. Шулай тиеш икән ул. Маһирә әби шулай диде. Малай да бар минем, яшьти. Ачуланма инде син берүк. Иртәгә сабантуйда күрешербез. Әле нумеры да алынмаган, яшьти!

Һәм яңа машина да, сабакташы да, Мөхәммәтне соры тузан болыты эчендә калдырып, Байтимергә таба чапты.

Сәмигулла авылда үзенең такта яру җайланмасын ачып җибәргән. Мәктәптә укыганда, бик тә надан һәм җылак малай иде. Өйгә биргән эшләрне күчертергә сорап тәмам җелегенә төшүе әле дә истә Мөхәммәтнең. Үзе гел «бишле» билгеләренә генә укыды ул. Кызык бу дөнья дигәнең: Сәмигулла машинада чаба, Мөхәммәт, әти-әнисенә, күрше-күләмгә дип җыйган күчтәнәчле сумкасын өстерәп, комлы Байтимер юлыннан җәяү тәпили. Югыйсә бер җылак малай иде. Рәзифә артыннан да җылый-җылый йөрде. Ә Рәзифә... Әйе, рәнжетте бугай аны Мөхәммәт. Шуңа күрә бүген ул хакта искә дә төшерәсе килми иде аның. Хәер, күңелсез хатирәләрне кемнең кабат яңартып торасы килсен инде!..

Юк, гарьләнмәде Мөхәммәт. Вак-төяккә генә һич тә исе китә торган кеше түгел иде ул. Менә иртәгә сабан туе, ә көн нинди шыксыз, салкын, әйтерсең җәй башы түгел, чиратсыз яңадан көз җиткән диярсең. Мөхәммәтнең әнә шуңа гына эче пошарга мөмкин. Хәер, кемгә нәрсә, кәҗәгә — кәбестә дигәндәй, кемгә — сабан туе, кемгә — сарык көтүе.

Мөхәммәтнең тагын нәрсәгә эче пошарга, йөрәген ни таларга мөмкин соң әле? Әнә, әле өченче көн генә, Зур залда рәссамнарның күргәзмәсе булды. Мөхәммәтнең эшләре исемлеккә кермәсә дә, залның директор урынбасары, үтә чая, кыскасы, бик булган, үткен ханым,— ул әле дәрәҗәле һәм атаклы сәнгать белгече дә,— аны эзләп тапты һәм эшләрен алып килергә кушты. Почмакта буш урын бар икән, аның хезмәтләрен шунда урнаштырасы иттеләр. Мөхәммәт, шатлана-шатлана, рәсемнәрен алып килеп тапшырды. Күргәзмә ачылгач, ни күрсен — зур гына бер эше юкка чыккан!

— Эзләмәгән җир калмады. Урлап китүләре точно! — диде директор урынбасары Сиринә Самуиловна. Әнисе татар, әтисе яһүд аның.

Әнә шул чакта да исе-акылы киткән иде Мөхәммәтнең! Ничек? Кем? Нигә кирәге булган!

Сиринә Самуиловна,— Мөхәммәтнең иҗатына үлеп гашыйк булган сәнгать белгече,— әлеге хәбәрне әйтте дә, моңа бары тик үзен генә гаепле санап:

— Мөхәммәт Уразмәтович! Мин гаепле! Кичерегез дип әйтмим. Тик минем тарафтан махсус эшләнгән дип уйламагыз, зинһар! — дип, елап ук җибәрә язды.

Сиринә Самуиловнаның гаепле түгел икәнлеге болай да көн кебек ачык. Нинди гаепләү ди аны! Әгәр шушы мөлаем ханым булмаса, аны... анымы?.. Әйе шул, Мөхәммәт Уразмәтовичның һәрбер эшенә шундук бәя биреп, иң әһәмиятлесе — аны, җае туры килгән саен, һәртөрле күргәзмәләр исемлегенә кертеп, һәрдаим ярдәм кылып торучы шул ханым бит инде! Әгәр ул булмаса, Мөхәммәтнең әсәрләре Италия, Франция күргәзмәләрендә урын алыр идеме соң?! Әле күптән түгел генә Мәскәүдәге зур күргәзмәгә Сиринә ханым тырышлыгы белән биш әсәре китте!

— Сиринә Самуиловна, юк өчен борчылмагыз! Сезнең гаеп юк икәнлеген беләм бит мин.

Сиринә Самуиловнаның,— Мөхәммәт аны күңеленнән «Гүзәл ханым» дип атап йөртә,— матур йөз-кыяфәтендә гел балкып торган кояшны бүген күләгә каплаган, зур һәм чем-кара күзләрендә моңсулык сизелә. Күренеп тора: әлеге хәл, Мөхәммәтнең үзеннән бигрәк, бу матур ханымны хафага салган иде.

— Сволочи! Найду, убью! — дип җикеренде ул.

«Кара, Сиринә Самуиловна да сүгенә белә икән?!» — дип уйлап куйды Мөхәммәт. Һәм шулчак ханымны иңнәреннән кочып тынычландырасы, юатасы килде.

Ул үзе дә аны бер туган апасы кебек якын итә, аңа бу ханым янында рәхәт тә, бик тыныч та. Инде утызны түгәрәкләү алдында торган ир заты булуга карамастан, авыл туфрагында шытып, гап-гади татар гаиләсендә канына сеңгән мокытлык һәрдаим егеткә тышау булды... берничә катлы тышау. Шуның иң юаны, ат арбасына төялгән саламның бастырыгын кыса торган аркан кебек юаны, әлбәттә, кыюсызлык иде. Ул һәрдаим үз-үзенә ышанмау дигән хәерсез хис-гамәл белән аралашып тора, егетнең Ходай тарафыннан иңдерелгән сәләтенә тулысынча ачылып китәргә ирек бирми, кыршаулап куйган кебек иде. Мөхәммәт акылы белән моны тоемласа да, шуны җимереп, ватып сындырырлык көч табудан гаҗиз. Әлеге гаҗизлектән туган бушлыкны Сиринә Самуиловна гына тутырып тора, өстәвенә хатын егетне магниттай үзенә тарта иде.

— Кай җиренә кызыктылар икән соң ул картинаның? —дип аптырады Мөхәммәт.

Әле генә еларга җитешкән ханым кинәт кабынып, терелеп китте.

— Политический иде ул синең! Җәмгыятьнең асылын сәнгать аша күрсәтү, ул — политика, Мөхәммәт Уразмәтович!

Сиринә Самуиловна, бер карасаң, үзен нәкъ мәктәп укытучысы кебек хис итә бугай. Ул — укытучы, Уразов Мөхәммәт — укучы. Иң алдынгы, тәртипле укучысы әле! Мөхәммәт шуны уйлап, елмаеп куйды. Сиринә Самуиловна, имән бармагын — ханымның һәрвакыт буялган озын тырнаклы нәфис бармаклары бүген лакланмаган иде — чак кына өскә күтәрде.

— Кем эше икәнлеген чамалыйм мин. Ну тотсам!.. Беләсең килсә, иң яхшы унбиш эш Мәскәүдә узачак күргәзмәгә сайланып алырга тиеш иде. Теге «ата таракан» моны сер итеп мең кат йозак астында сакласа да, шулай булачагын белдем мин! Ул анда швабра белән рәсем ясаучы киявенең эшләрен төртмәкче!

Мөхәммәт «ата таракан»ның кем икәнлеген чамалый иде. Шул җитәкчене таракан итеп күз алдына китергәч, аның кычкырып көлеп җибәрәсе килде. Тыелып калды. Көлемсерәп кенә куйды.

Юкка чыккан рәсемдә гап-гади табигать күренеше, урман алды, су буе күренеп тора, болын сымак җире дә бар, болында өч кара сыер утлап йөри, дүртенчесе,— анысы кызыл сыер,— читтәрәк, шул сыерларны биш көтүче көтә.

Мөхәммәт барган җиреннән шып туктап калды. Карале, нәкъ менә шушы урыннар табигате иде ич рәсемдә! Ташсу елгасы яры буенда аякларын салындырып утырып, бер атна тирәсе язган иде ул картинаны Мөхәммәт.

Искиткеч гүзәл табигать күренеше. Юан, сап-сары кәүсәле нарат агачлары әйтерсең Ташсу елгасына су эчәргә төшеп килә. Урман алдындагы ачыклыкка бура бурап куйганнар. Юк, юк, наратларның су эчәргә төшүләре түгел бу. Әнә теге өч нарат,— алары алгарак чыгып үскән,— урманнарыннан аерылып, үзләренең балаларын эзли киткәннәр. Кайларга китеп югалган соң аларның газиз балалары? Әле генә, яңа гына янәшәләрендә шаулап утыралар иде. Бураның агачлары бик нечкә күренә. Әллә... шуларны кисеп, каезлап-тунап?..

Ә сыер көтүе нишләп йөри монда? Хәер, көтү түгел лә! Дүрт сыер нинди көтү булсын инде! Ә нишләп дүрт сыерга биш көтүче?

Зур урманнан бары өч-дүрт кенә төп нарат агачы аерылып чыккан. Көтүе дә көтүгә охшамаган. Тәңгәллек бозылган бит монда. «Табигатьтә тәңгәллек бозылган. Кешеләр тормышында да бозылган ул! Юкса өч сыерны дүртәүләп көтмәсләр иде! Табигатьтәге тәңгәллек бозылу кешеләр тормышына да йогынты ясаган. Бәлкем, киресенчәдер әле ул! Это точно!» — дип, әллә шаяртып, әллә чын-чынлап шәрехләгән иде картинаны Сиринә Самуиловна. «Бозылган инде, бозылган шул,— дип, үзалдына уйланды Мөхәммәт.— Бозылмаган булса, сабакташым һәм җан дустым, үзе әйтмешли, колхоз персие Барый Әкбәров авыл кадәр авылны тау башына күчерәм дип җенләнеп йөрмәс иде!»

* * *

Мөхәммәт, авылның сарык көтүен җыеп, иртән иртүк Сай суга таба куып алып киткәндә, сабантуйга барырга тиешле халыкның күпчелеге йокысыннан да уянып җитмәгән иде әле.

Нәкъ шулчакта Байтимер авылының икенче башыннан райүзәккә таба ак «Волга» чыгып чапты.

Көтү чираттан булса да, сабантуй көнне аны көтү мәҗбүри түгел, бер көнгә абзарларында да түзә алырлар иде, әлбәттә. Ләкин шунысы бар: сабантуй көнне көтү көтү ике чиратка санала, ягъни икенче юлы син көтмисең дигән сүз. «Гөлчәчәк тә булмагач, нишләп йөрим!» — дип уйлаган иде Мөхәммәт.

Ул сарыкларын су буена чаклы җыеп алып төште дә аннары колхоз печәнлеге белән янәшә чирәмлеккә таратып җибәрде. Үзе, кулындагы таягына таянып, елганың аръягындагы урманга таба карап тора башлады. Көтүнең артыннан тагылып йөрисе юк иде: болын киң, иркен, сарык хайваны өчен генә монда үлән җитәрлек; хайван булгач, тамаклары туеп та, нәфесләре, күзләре туймый икән инде, әнә колхозныкына керсеннәр; Әкбәровтан куркып торган юк. Барый аннан үзе курыксын, ни дисәң дә куркырлыгы бар бит!

Көтү, чынлап та, чыклы яшел үләнне кетердәтә-кетердәтә, колхоз печәнлегенә таралды. Колхозныкы тагын да тәмлерәк иде, күрәсең.

Мөхәммәт, Ташсу буендагы болында япа-ялгызы калгач, малай чагына «кайтып китте». Елга ярына аякларын салындырып утырды да күңел көймәсен су өстенә «төшереп куйды»; балачак көймәсе, кара сыртлы дулкыннар өстендә җай гына тирбәлә-чайкала, мари урманнары буйлап акты да акты. Көймәдә Мөхәммәт Уразов атлы танылып килә торган рәссам түгел, дулкыннар өстендә Байтимернең Мөхәммәт исемле малае, элеккеге балта остасы, колхозның алтын куллы тимерчесе, туган авылында хәзер карчыгы белән пенсия акчасына көн күреп ятучы, көтү чираты җитсә, әнә шулай дүрт күз белән каладагы малаен көтеп алучы Уразмәт аганың бердәнбер улы иде. Исеме Мөхәммәт булса да, ул пәйгамбәр түгел, ул — егерменче гасыр ахыры һәм яңа гасыр башында иҗат итүче бер рәссам иде. Һәм гаять талантлы егет, әгәр «терсәк сугышында» харап булмаса, киләчәге бик зур иде егетнең.

## Мин

Ашыга бу дип гаепли күрмәгез, серне алдан ук чишеп куярга булдым: мин, Мөхәммәт, урманчы кызы Гөлчәчәкне, урманыннан аерып, шәһәргә алып китү турында хыялланам. Аларның өйләре әнә генә, урман буенда гына.

Безнең балачак та, яшүсмер вакытлар да Ташсу буенда, шул елгада көннәр буе бака малайлары белән бергә коенып, ярындагы гәрәбәдәй сары комында тәннәр төтенли торган мичтә утыручы кара чуен кебек каралышып, данлыклы мари урманнарында аю-бүреләрдән курка-курка булса да, вакыты җиткәч, әүвәл җиләген, аннары гөмбәләрен җыеп узды. Әнә Кызылъяр өстендәге наратлар да картайган, безнең балачак та Ташсу елгасы буйлап еракларга агып киткән; елганың үзе кебек үк әүвәл Илләткә*, аннан килеп, Иделнең үзенә барып кушылган. Ә Идел исә Каспий диңгезенә чаклы барып җитә. Әгәр безнең гомерне шул елга-диңгезләр белән чагыштырырга мөмкин булса, мин малай чакны Ташсу, яшүсмер вакытларны Иллəт елгалары белән чагыштырыр идем. Мин, хәзер утызга җитеп килә торган рәссам, яшем буенча Иделгә кушылган чагымдыр. Тора-бара Каспий диңгезенә дә «кушыласы» бар бит әле дигән уйлар мине бер караганда шомландыра, күп вакыт әлеге хис, киресенчә, ымсындыра, ашкындыра гына кебек.

Байтимер халкы сарык көтүен, гадәттә, Наратлы болынында көтә. Мин, әни әйтмешли, Алланың бер кире һәм карышкан бәндәсе буларак, көтүне Сай суга алып төшеп киттем әле. Авыл үзе тау башында, елга үзәненнән биектәрәк булганга күрә, без Ташсуга барабыз, дип түгел, төшәбез, дип сөйләшәбез. Ташсуның да Сай су дип аталган бер тугайлыгында мин хәзер сарыклар артына тагылып йөрим.

Сай су — Ташсуның иң тирән урыннары. Малай чакта без бөтенләй икенче төштә, су өстендә йөзеп йөргән гөнаһсыз сыер тизәкләре белән бергәләшеп, җәйләү дип йөртелгән урында коена идек. Җәйләү турысыннан узганда, Ташсу текә ярга ышыкланып акмый, тигез яр буенда сап-сары һәм кайнар комы да булганлыктан, бала-чага өчен су коенырга иң шәп җирләр иде ул. Хәзер ярлары җимерелеп, ул төшләр күңелсезләнеп калган.

Ташсу да үзгәргән, мин дә картайганмын бугай. Хәер, егерме сигез яшьлек ир-егетнең гаиләсе, ким дигәндә бер-ике баласы булырга тиеш иде бит инде югыйсә. Әле һаман өйләнә алмыйча йөрим. Гомумән, үземне таркау кеше дип исәплим. Үземә бүген, иртәгә нәрсә

кирәклеген беләм, әмма бер атнадан соң ни кылачагымны һич төшенеп бетерә алмыйм. Аның каравы тагын берәр елдан ни булырга тиешлеген күз алдына ачык китерәм. Таркау адәм булсам да, максатым бар. Алдан ук әйткән идем инде, урман каравылчысы кызы Гөлчәчәкне Казанга алып китәчәкмен!.. Әгәр шулай булмый икән... йә эчүгә сабышачакмын, дөньяның кызыгын йә наркотиктан табармын кебек. Бер дә булмаса, мәгънәсез тормыш алып барып, анда-санда рәсем-картиналар ясаштыргалап, шулардан килгән акчага ирекле, бәйсез, гомумән, дилбегәсез тормыш кичерәчәкмен. Кыскасы, башкага өйләнмәячәкмен!..

Хәер, каты һәм кискенрәк әйтелде бугай, нәзерем булмасын тагын!..

Алла сакласын!..

Гөлчәчәк турында да ашыгыбрак әйтеп ташладым, ахрысы, син дә укучым, ашыктыра күрмә, чөнки ул максатыма гомерем буе,— ундүрт яшьтән алып исәпләсәң, хәзер егерме сигез, нәкъ ундүрт ел килеп чыга икән,— барам бугай инде. Әлбәттә, кыен чаклар да күп булды, аптыраганнан чукынасы килгән вакытлар да булмады түгел... Ләкин алай гына җиңеллек килсә иде ул! Чукынсаң, урыс буласың да куясың инде. Шул гына... Йөрерсең аннан соң муеныңа салкын тәре асып...

Ундүрт яшемдә мин шофер булырга хыяллана идем.

Әти белән әни төне буе йокы күрмиләр, бер төнне билдән кар ерып колхоз басуына саламга барсалар, икенчесендә ферма янындагы сенаж чокырына китәләр. Маллар күп: сыер, тана, унҗиде баш сарык, өстәвенә сыерыбыз ел саен бозаулап та тора. Ашатырга, һәммәсенә җиткерергә кирәк, тамаклары ачыкса, ярты авылны күтәреп кычкыра, акыра-бакыра башлыйлар. Ә курмы машина белән кайтмый. Колхоз мин белгәннән бирле үләксә хәлендә. Басудагы салам-печәнен, фермасына ташырга да хәленнән килмичә, җир өстендә черетсә черетә, ләкин колхозчысына бирми. Әни җәй буе колхоз эшендә сәнәк-көрәк күтәреп йөрсә дә, әти данлыклы балта остасы һәм тимерче булса да... Ә мин әле бәләкәй. Дөрес, әти-әнигә ияреп, салам урларга йөрергә ярый башладым инде. Тик күтәреп кенә күпме генә алып кайтасың! Мәсәлән, сыек җилкәм өстендә кайткан сенажны безнең үзе комсыз, үзе чырсыз тана бер кабуда юк итә дә куя. Аннары, ашарга сорап, тагын паровоз кебек үкерә башлый.

Тимер юл станциясе янында яшәмәсәк тә, аталары машина-тракторда эшләмәгән минем кебек малайларның лапаслары паровоз депосы кебек: кемнең кыш чыккан үгезе үкерә, кемнең сыер-танасы акыра. Авызларына, паровоз миченә тыккан шикелле, утын-фәлән салып булмый шул инде. Печән сорыйлар, башак кирәк ул җүнсезләргә!

Нәкъ шул туймас тамаклар аркасында шофер булырга хыялланып йөри башладым да инде. Саламын, печәнен дә машинасы белән генә алып кайтып тондырыр идем дә ашасыннар, тыгынсыннар иде шунда! Юк ла, тыгылмасыннар тагын! Тыгына-тыгына ашасалар йә тыгылып куярлар. Миннән башка дүрт апам бар бит әле. Шулар кияүгә чыга-китә калса дип асрыйбыз без ул хәтле малны. Ичмасам, кыз бала булып тумаганмын шунда, дүрт кыз янына сыяр идем әле, болай иттереп колхоз саламын урлап йөрмәс идем, йоклар идем бер рәхәтләнеп. Алай дисәң... әти белән әни жәлке инде. Икесе генә азапланачаклар бит! Мин алып кайткан өлеш әллә ни күп булмаса да, барыбер иш янына куш булып тора әле ул. Әни шулай дип башымнан сыйпый. Әллә үсендерүе, әллә чынлап та шулай уйлый.

Ыштан туздырып мәктәпкә йөрүем, бигрәк тә анда алган билгеләрем дә шоферлык кына иде. Шофер була алсаң, шул да бик җитеп тора инде. Әти әйтмешли, барыбер үз борыныңнан да югарырак сикерә алмассың. Кушаматыбыз «болан» булса да, сикерергә яратмыйм мин. Сикерергә яратмаган кебек, математика дәресләрен дә җенем сөйми менә. Ярый әле математиканы Зөләйха апа укыта. Тәрбия эшләре буенча завуч ул безнең. Чиреккә «икеле» чыгармагыз, дип, аның артыннан ялынып йөрисе урынга, классларны бизик яки стена газетасы чыгарыгыз, дип, үзе арттан йөри. Ә рәсемгә кул ята минем. Шулай дип кешеләр әйтә. Әйтмиләр икән,— фикерләре үзләренә булсын,— оста икәнлегемне үзем дә бик яхшы белеп торам. Рәсем укытучысы,— сабакташым Барыйның бертуган абыйсы Һадиулла,— мине бик якын итә. Миннән рәссам ясамакчы була ул. Әллә нинди акыллы китаплардан укыган акыллы сүзләрне тукый-тукый башымны катырып бетерә. Имеш, «искусство начинается там, где начинается чуть-чуть». Янәмәсе, миңа табигать тарафыннан хәтта «чуть-чуть» кына бирелмәгән, күбрәк тамызылган икән. Ялкауланмаска гына кирәк. Чуртыма хаҗәте бар иде рәссамлыгыңның, дип уйлыйм эчемнән генә. Ак кәгазьгә төшергән трактор яки машина белән безнең паровоз депосы чаклы лапаска бер йөк печән түгел, шырпы салып та алып кайтып булмый. Һәм моның шулай икәнлеген Һади абыйга ничек аңлатасың! Маңгаеңны парта кырыена бәрә-бәрә аңлатсаң да аңламаячак ул аны! Чөнки аның әтисе колхоз рәисе. Салам урларга йөрми алар. Урламый гына

алып кайта. Көпә-көндез. Ә йөге белән көндез урлаган кеше каракка исәпләнми дә, бездә шулай: култык астына кыстырасың икән, ул вакытта син чып-чын карак, угры, бур, тагын әллә кемнәр әле. Кыскасы, эләгәсең икән, урының өтермәндә. Ә өтермәндә, күрше Самат абый әйтмешли, гел макарон гына да ашатып тормыйлар. Ул белсә белә инде, чөнки, хатынына кырын караган саен, гел унбиш тәүлектә бушка ашап кайта ул.

Рәсемне болай гына ясыйм мин. Мәктәп директоры Фәрит абый тәрәзә ваткан саен мунча кертмәсен дип тә ясыйм. Андый чакта завуч Зөләйха апа яклый үземне, Һади абыйның яклавы бигрәк тә тәэсирле була. Ә Һади абыйның сүзен директор булсаң да тыңламый хәлең юк, әтисе — персидәтел!

Үзеңнән нинди сүз көткәннәрен белмәсәң, чын дөресен әйтүе кыен, диләр. Ә мин сөйлим дә сөйлим, егерме сигез ел эчендә үзем белән ни булганын түкми-чәчми, курыкмыйча һәм дөресен сөйлим. Чөнки болар чит кеше турында гайбәт түгел, үзем турында сөйлим бит.

Һади абый, беркөнне рәсем дәресендә эленке-салынкы гына утырганымны күргәч, соңыннан үземне генә алып калып, калын китап белән салам чүбеге тулган маңгайга кундырып алды да: «Син, малай актыгы, туган ягыңны яратасыңмы?» — диде. Таптың сорар нәрсә, үзенең туган ягын кем яратмасын инде! Яратмасам, монда туып та тормаган булыр идем әле. «Безнең якларның табигате искиткеч гүзәл шул ул! Без шуны,— бу очракта өмет синдә,— бар дөньяга күрсәтергә тиешбез, белдеңме? — дип дәвам итә бу.— Күрсеннәр, шаккатсыннар һәм безнең якка ял итәргә дип, бар халык агылсын! Үзебезнең Ташсу буйларыннан, урманнан заповедник ясыйбыз. Ял итәргә теләүчеләр күп булгач, доходы була дигән сүз! Шуннан соң безнең яклар баеп китәчәк!»

«Монысы да нәкъ персидәтел булып эшләүче атасы кебек хыялый икән,— дип уйлыйм мин.— Заманында бабаң тау башында утырган авылны үзәнгә күчереп утырткан бит инде. Зират хәтле зиратны каберлекләре белән бергә күчерттергән! Хәзер бәрәңге бакчаларын су басып интектерә!»

Бу сүзләрне телем белән әйтмим.

Һади абый минем башка кундырган теге калын китапны ачты да, үзенә кирәкле битен эзләп тапкач, борыныма төртте. Мә, укы, янәмәсе. Борын белән укый алмыйм ич инде дигәндәй карышып, башымны күтәрәм, акыллы фикерләрне Һади абзый үзе укып бирә: «Лондонские туманы не существовали пока их не открыло искусство,— дигән Оскар Уайльд абыең.— Без дә үзебезнең якның матурлыгын сәнгать ярдәмендә ачып биреп, дөньяны шаккатырырга тиеш! Аңладыңмы, малай актыгы! Әфлисун гына ашап яшәргә тиеш бу як халкы. Ә хәзер бәрәңгегә дә туймый, бакчалары суда утыра»,— ди ул, якын итеп иңемнән кочаклап. Аңладым, билгеле, борын белән төртә-төртә аңлаткач инде... Тагын бер нәрсәне аңладым әле: безнең Ташсу буенда курорт ачып, шунда ял итәргә киләчәк берәр интеллигент кыз-хатынга өйләнергә телисеңдер әле. Авыл кызлары ярамый бит сиңа. Ярасалар, ялгыз ата каз кебек утыз яшеңә чаклы йөрмәс идең болай!

Баш гел кире якка эшли, карышкан тек карышкан, үҗәт һәм кире беткән малай инде. Югыйсә Һади абый турында шулай начар уйлыйлармы соң? Әйбәт кеше бит ул, чөнки мине үз итә!..

Сабакташ булса да әйтим әле, Барыйлары гына үҗәт аларның. Алай ук җүнсез түгел ул түгелен, тар маңгаендагы уйлары гына җүнсез кайчакта.

Һади абыйсының мине җибәргәнен мәктәп капкасы янында көтеп торган икән; дус бит, мәктәптән бергә кайтабыз. Кызыксынуы да көчле инде, әлбәттә. Дус булса да, көнче ул.

— Абый сине нигә алып калды?

Барыйның беренче соравы шул булды. Кәефкә болай да кырау төшкәнрәк вакыт иде, үртәргә керештем:

— Синең турыда борчыла ул, беләсең килсә! Гел «бишле»гә генә укып, безнең Барыйның башына кан саумаса ярый инде, ди. Син дусты бит, әйт әле шуңа, артык көчәнмәсен, яраткан энекәшемнән колак кагасым килми, ди.

Барый, әлеге сүзләремә ачуы килеп, кулындагы ялтыравык күнле портфеле белән берне ямамакчы иде, минем үзеннән көчлерәк икәнлеге исенә төште булса кирәк, ул, кырыйга борылып, черт иттереп төкерде дә, үчен сүз белән алырга уйлап:

— Бу затлы портфелемә синең кебек «ике»ле салып йөри алмыйм бит инде мин! — дип телләште. Кайсы яктан суктырырга кирәклеген белә персидәтел малае! Аның кулында өр-яңа портфель, миндә исә әтинең элек өтергеләр салып йөри-йөри тузып, кыршылып беткән арзан күнле букча.

Аның сүзләреннән соң эчем кендек турысыннан авырттырып борып куйса да, бирешергә һич исәбем юк.

— Мактанмасана! Беләсең килсә, эти хәзерге вакытта өйдә бака тиресеннән портфель тегеп утыра! Суда да батмый ул, беләсең килсә! Бу синең суда бата бит! — Үз ялганым үземә дә ошап, мин кызып ук киттем: — Әйдәле, әйдә, синең бу әтәч тиресеннән эшләнгән портфелеңне суга салып карыйк әле! Ике күзем чәчрәп чыксын, таш кебек төпкә китәчәк ул! Менә күреп торырсың!

— Баткан ди сиңа, бар!

— Әтәч йөзә белми ич ул! Шулай булгач, портфелең бата да бата инде синең!

Без өч чакрым араны шулай үртәшеп, телләшеп кайтабыз да, авыл башындагы күпергә килеп җиткәндә, яңадан дуслашып беткән булабыз. Бүген дә Барый миңа иң якын дуска гына әйтелә торган бер сер әйтте. Дөресрәге, әйтеп бетермәде, күңелне генә ымсындырып куйды.

— Бу шимбә урманга барабыз, бер кызык күрсәтәм мин сиңа!

— Нинди кызык? — дип, күпме генә телен чишәргә азапланып карасам да әйтми, Һади абыйсының мине нигә алып калганлыгын әйтмәгәнгә үч ала, сары баш!

Барыйның чәче урысныкы кебек сары, йөзе кызгылт иде. Ачуым килгән чакларда: «Мунчала баш! Мунчала!» — дип үртим. Ул миңа: «Болан!» — дигән кушаматымны исемә төшерә. Ә аларның кушаматлары юк. Авылда һәммә кешенең дә кушаматлары бар, ә Барыйларныкы юк. Күрәсең, персидәтел кешенең кушаматы булмый торгандыр инде. Кушаматсыз берьялгызы ятим булып, каңгырып йөрмәсен әле дип, «мунчала»ны Барыйга үзем тактым. Барыйның үзенә генә ошап бетми, сабакташларга бик ошый ул ошавын.

Күршеләр булгангамы икән, Барый нәкъ минем кебек үк кире һәм үҗәт иде. Нинди кызык икәнлеген әйтми бит тәки. Әйтер, әйтер, хәзер әйттерәбез аны дип уйлап бетердем дә, уйлаганны эшләргә дә кирәк бит инде: Барыйның муеныннан каптырып алып, башын җиргә таба бөктем.

— Әйтмәсәң, күпердән очырам бит хәзер!

Тел чиштерү әмәле шәп минем, Барый шундук бирелде. Прәннек ашап кына көч җыеп булмый ул, кара ипи ашарга да кирәк бераз.

— Бу шимбәдә урманга барабыз. Гөлчәчәк белән Гөлйөзем янына кунакка!

Муенны тагын да катырак кыса төштем:

— Нинди кунак ул? Йомшак җиреңә Ярулла абзыйдан тоз белән аттырасың киләмени!

— Без качып кына, шыпырт кына. Хәзер сорама, калганын шунда баргач үзең күрерсең.

Ул кызларның исемен ишетү тынычландырып җибәргән иде, мин, келәччәмне ычкындырып, Барыйның муенын «иреккә җибәрдем».

— Әйдә, Барый, теге колонкага хәтле минем җилкәгә атланып кайтасың киләме?

Барый буйга шактый калыш булганлыктан, минем өчен аның бернинди дә авырлыгы юк, дустымның күңелен күрәсе килгәндә бик еш шул тәкъдимне ясый идем. Барый тешләк, буе Наполеон кебек кәтүк кенә булса да, телгә бетәшкән адәм иде. Бик каты ачуы килгәндә, аның озын теле аеруча зәһәр һәм кычытканлы була. Ә бүген аның ачуы килү өстенә, үтереп муены да авырта булса кирәк, сүзләре белән минем маңгайга алла шәп чәпәде ул! Күпер астына мәтәлә яздым, билләһи. «Әйдә, җилкәгә утырасыңмы?» — диюгә, Барый, авырткан муенын ышкый-ышкый, бары бер генә сүз әйтте:

— Ишәккә атланып йөрмим мин!

Шул мизгелдә без, Барый белән кочаклашып,— мин сугып җибәрәм дигәндә, ул бер кулы белән букча каешыннан эләктереп өлгергән икән,— икебез дә күпер астына очтык.

Шимбә көн җиткәндә, без ике күрше, Барый белән Мөхәммәт, аерылгысыз дуслар идек инде. Бүген кич урман каравылчысы Ярулла абыйлар катына барырга тиешбез. Үзе чакырмаса да, Ярулла абзыйның игезәк кызлары без койрыксыз әтәчләрне магниттай тартып тора.

Ул кызлар дип хәтта кабырга сындырган малай мин!..

Барыйның әтисенең энесе Сибгат абый ел да урман каравылчысының аланлыктагы печәнен чабарга булыша һәм шуннан үзенә дә шактый өлеш чыга иде. Узган ел печән аеруча котырып уңды. Ярулла абый Сибгат белән бергә әтине дә дәште. Елга буйларыннан кыркынып йөргәнче, кыш ашатырлык печәнең булыр дигәч, чабылган печәнне киптереп, чүмәләгә салырга дип, эти үзе белән мине дә алды. Сибгат абый энесе Барыйны ияртте.

Урман урман инде, шундый рәхәт анда. Кигәвеннәре, усал чебеннәре дә булмаса менә.

Өлкәннәр печән чапкан арада, Барый белән рәхәтләнеп җиләк ашадык.

Әбәт тирәләрендә урманчының ике кызы төшке аш алып килде. Болар,— безнең тирәме, әллә яшьрәкләр, берсеннән-берсе матур җиләк кебек ике игезәк кыз,— тынычлыгыбызны алдылар. Алар килгәнче, этиләр чапкан печәнне тиз-тиз генә таратып ташлап, агач башында тукран куркытып, маймыл шикелле ботактан ботакка сикерә-сикерә тиен куып йөргән малайларың кинәт җитдиләнеп калды. Югыйсә әле борын астына сыңар бөртек төк тә чыгып өлгермәгән, ә үзебез кисәк кенә үзгәрдек тә куйдык. Минем эти әйтмешли, менә сиңа табигать балалары!..

Кызлар үлән яфрагындагы чык тамчылары сыман охшашкан да, бер тамырда үсеп икесе ике төрле каен җиләгедәй бер-берсенә охшамаган да. Хәтта игезәк булсалар да.

Мин учымдагы җиләкләрне Гөлйөзем атлысына сузганымны сизми дә калдым. Югыйсә икесенә дә тигезләп бүлеп бирәсе иде дә! Тик нишлим, җиләкле кулымны Гөлчәчәккә таба сузарга батырчылыгым җитмәслеген ниндидер эчке тойгы аша чамалап өлгергән идем, кулларым калтырар, ә үзем уч төбемдәге җиләкләр кебек кызарырмын төсле иде.

Гөлчәчәкнең каен җиләгедәй алсу иреннәре җиңелчә генә дерелдәп куйды, ул зуп-зур, кап-кара күзләрен тагын да зуррак ачып, нишләп миңа җиләк юк дигәндәй, аптырап карады да, аннары әле тагын бер мәртәбә күз сирпеп алды. Гәүдәм буенча кырмыска көтүе чабышып узды дип торам, өстәвенә шуның артыннан ук бөтен җанымны авыр халәт биләде, авызым кибеп, телем аңкауга ябышып калды. Мин, ялгышканымны аңлап, җәһәт кенә хатамны төзәтмәкче булам, аяк астына күз ташладым: җиләк күп, ләкин алары пешмәгән әле.

Бәлки, минем үземә генә шулай тоелгандыр, чөнки Гөлчәчәк тамчы да үпкәләмәгән икән: ул учындагы кура җиләкләрен, төгәл ике өлешкә бүлеп, әүвәл миңа,— мин Барыйга караганда шактый читтәрәк торсам да,— аннан соң Барыйга сузды.

Кара күзле, ак йөзле бу кызлар үзләре дә пешәр-пешмәс җиләк кебек иделәр. Икесе дә пардан киенгән, ак ситсыга төшкән кара чәчәкле күлмәкләре янәшәдәге пар каенга охшап тора. Борыннары уймак сыман гына, әйтерсең бу матур йөзләрдә борын да булырга тиеш бит инде дигәндәй генә утыртылып куелган. Гөлйөземнең иреннәре юкарак, Гөлчәчәкнеке калынрак та, алсурак та. Кызларның буйлары безнекеннән чак кына кайтышрак. Төгәлрәк әйтсәк, минем колга буй белән Барыйның кәтүк буе үлчәме арасында. Гөлчәчәкнең ирен өстендә, сул яктарак, канәфер төсендә матур, кечкенә миңе бар. Шундый ук миң Гөлйөземнең нәкъ уң бит алмасына кунган.

Безнең авылда мондый ук шомырт кара күзле кызлар юк, барысы да йә минеке кебек яшькелт яисә канәфер төсендәге күзлеләр.

Дөресен генә әйткәндә, мин урман аланында кызларның йөз-кыяфәтләренә җентекләп игътибар итеп, аларны энә күзе аша үткәреп тора алмадым инде. Аерылышкач кына, тере һәм җанлы булып, аермачык күз алдыма килде аларның йөз-сыннары.

Гафу ителмәслек хәл: мин, бүтән чакта телемә шайтан төкергән күп сүзле малай, телсез-өнсез калган идем. Урман аланында моңарчы кызлар белән күрешкән булмагангамы шунда...

Гөлйөзем игезәк туганына караганда кыюрак, чаярак күренә. Шуңа күрә Барый да күбрәк аның белән сөйләшергә тырыша:

— Аю-бүреләрдән курыкмыйсызмы соң сез?

Гөлйөзем ялт кына гөлҗимеш куагы төбенә чүгәләде һәм аннан ике көпшәле мылтык тартып чыгарды.

— Менә.

Без аһ иттек. Икебезнең дә моңарчы мылтык күргәнебез юк иде. Чын мылтык, зур, авыр мылтык, түтәсенә зәңгәр тасма уралган, күрәсең, шул төшеннән ярылып киткән булгандыр.

Гөлчәчәк, мылтыкны нигә күрсәттең дигәндәй, туганына шелтәле караш ташлады да аннан соң, эш узгач соң инде дигән кыяфәт белән, янәшәдәге каен агачына сөялде.

Мылтык күргәч, мин әсәренеп киттем, аны тотып та карыйсым килгән иде — горурлыгым комачаулады, кызлар каршында уенчыкка кызыккан бала-чага хәлендә каласым килмәде, телем дә һаман аңкауга ябышкан килеш иде әле. Җәһәт кенә алан читендә үсеп утырган озын нарат агачына таба киттем, игътибарны башка нәрсәгә юнәлтәсем килде. Агачның очында ук тиен сикергәли иде. Шул тиенне тотып Гөлйөземгә бүләк итәсем килеп китте.

Агач башында шәп йөрим, нәкъ маймыл кебек. Барый, кул-аяклары кыска булгач, минем сымак ук булдыра алмый, калышмаска тырыша үзе. Тиен, әлбәттә, агач кәүсәсенә орынуга, җәһәт кенә янәшәсендәгесенә сикереп, күздән югалды. Барыбер менәм. Өстәвенә күптән түгел Тарзан турындагы кино да караган идек.

Нарат хәйран биек. Иң очтагы бер ботакка менеп атландым. Алан тагын да бәләкәйләнеп калды. Кызлар да, Барый да кеп-кечкенә булып күренәләр. Аларның күзәтеп торганлыкларын күрәм бит, шуңа күрә шаккатырасым килде: озак уйлап тормыйча, янәшәдәге наратка сикердем. Куллар, йөзләр тырналып бетеп, бер очлы ботак чак кына күзне төртеп тишмәде, барыбер агачка эләгеп кала алдым. Астагылар шаккатып карап торалар бугай. Хәтта сокланыптыр да. Бигрәктә Гөлйөземнең исе киткәндер! Бу тойгылар миңа рәхәтлек бирә, яңадан-яңа батырлыкларга ымсындыра. Агачтан бер күркә өзеп алдым да, Гөлйөземнең кай төштәрәк басып торганлыгын чамалаганнан соң, аны аска таба аттым.

Нарат күркәсен Гөлчәчәк тотып алганлыгын күрми калдым.

Тагын агачтан агачка сикерәсем килде. Теләгән нәрсәне эшлим инде мин анысы: сикердем дә... һәм бу юлы эләгеп кала алмыйча, җиргә мәтәлдем.

Ярулла абзый өендә аңыма килгәндә, ничә кабыргамның сынганлыгын белерлек хәлдә түгел идем әле...

...Бүген шимбә без Барый белән урман каравылчысы өенә кызык карарга барабыз. Барый кызыкның нидән гыйбарәт икәнлеген әйтмәсә дә, урманчы кызларын күптән (аз дигәндә ел ярымлап булыр) күрәсем килеп йөри иде. Әүвәл, әлбәттә, кабырга сындырган «батыр» малай буларак күзләренә күренергә оялып йөрдем: алар миннән көләрләр кебек иде. Көлгән чагында, Гөлйөземнең матур кара күзләре чак кына кысыла төшеп, шул серле күзләрдә мыскыллы караш та чагылса, беттем, үләм, бүтән яшәмәячәкмен! Гөлчәчәк, бәлкем, көлмәс тә. Хәер, шайтан белсен, кызлар көләргә ярата инде алар...

Мәхәббәт — бала-чаганың иң соңгы һәм бик тә көчле авыруы, дигән кемдер Ул акыллы башның әлеге сүзләрен ул чакта белми идем, ишетмәгән идем әле.

Мөгаен, балачак белән саубуллашу вакыты булгандыр ул. Үзебезнең авылдагы кызларга, хәтта көн саен аралашып яшәгән кызларга карата минем йөрәктә беркайчан да андый сәер, ят хиснең кабынганы булмады ич... Билләһи менә!.. Күрше кызы Алмазиянең,— без бер сыйныфта укыйбыз,— сәгать ничәдә йокларга ятканын да, иртә белән нәрсә ашаганын да, сөтле аш яратмаганын да, зәңгәр чәчәк төшкән күлмәк өчен апасы белән сатулашып, төн буе мендәр чылатып чыкканлыгын да, аның гөлләр үстерергә яратканлыгын, өендәге роза гөле сулгач, тамактан калганын да белә идем. Алай гынамы соң, шулай бервакыт аларга печән өешергә кергәч, алмагач бакчасындагы кер бавында, әлбәттә, кеше-кара күзеннән яшерен җирдә, җәйге җилгә кибәргә элгән эчке киемнәренә чаклы күргәнем бар; хәтта печән өеп бетергәч,— аларның чәй суына дигән коелары алма бакчасында,— салкын су эчәргә кергән җиремнән җил белән җиргә төшкән бәләкәй лифчигын (әнисе төптән юан хатын, өлкән кызы да үзеннән калышмаган, димәк, аларныкы түгел) кулыма алып, җәһәт кенә кер бавына кире элеп тә куйдым.

Күп нәрсәне безгә Алмазиянең әнисе кереп сөйли, ялгыш кына шуннан ишетәм. Һәм, күрше буларак аралашып яшәгәч, үземнең күзләр дә ботак тишеге түгел ләбаса инде. Әмма Алмазия бары күрше кызы гына.

Озын толымлы Рәзифә дә сыйныфташ кына, бер парта артында утырсак та. Бик теләп математикадан контроль эшләрне күчертсә дә.

Мәхәббәт дигән олуг хиснең килүен мин еракган көтә идем. Бер дә булмаса, хет күктән ишелеп төшсә төшсен, тик безнең авылныкы гына булмасын. Безнең авыл кызлары, алар — безнең авыл кызлары. Алар да «болан» кушаматлы Уразмәт малае икәнлегемне белә, апаларымның төпчек энекәше дип кенә карыйлар, тик алар күңелемдә ниләр кайнаганын мәңге белә алмаячаклар инде!..

Чын мәхәббәт өрәк кебек була микән әллә ул? Һәммә кеше дә аның турында сөйли, әмма берәүнең дә күргәне яки орынып караганы юк!..

Мин — Байтимер Тарзаны, әни әйтмешли, җунгли маймылы,— ул моны яратып, исән-сау калганыма сөенеп әйтә, әлбәттә,— аңыма килгәндә, Ярулла абзыйлар өендә йомшак урын-җирле тимер караватта чалкан ята идем. Яныма кешеләр җыелган: әти, Сибгат абый, хатыны белән Ярулла абзый үзе, бераз читтәрәк, миңа зур батырлыклар кылырга сәбәпче булган шомырт кара күзле ике кыз. Мин күзләремне ачкач, барысы да җиңел сулап куйдылар.

Барый, машина алып килергә дип, авылга чапкан икән. Ул килгәнче, берәр сәгать чамасы Ярулла абзыйның сагызлы түшәменә карап тик яттым: кузгалмаска, торып йөрмәскә кушылган иде. Имеш, башта «землетрясение» булырга мөмкин. Күңелең болганмыймы, дип сорый-сорый, тәмам җелегемә төштеләр.

Өлкәннәр таралгач, янымда калган ике кызга «землетрясение» турында әйткән идем, алар, шуны ишетүгә, тәгәрәделәр генә; «землетрясение» түгел, «мозготрясение» яки «сотрясение мозга» була икән ул. Димәк, минем баш тулысынча эшләп бетерми икән әле. Көлеп арыгач, Гөлйөзем беравык миңа төбәлеп карап торды-торды да, аннан соң почык борынын җыерып:

— Малай-шалай... агач башында йөрмәсәң. Буе үскән, акылы үсмәгән,— дип куйды. Аның бу сүзе миңа бер дә ошамады, әлбәттә. Гөлчәчәккә дә ошамаган икән: ул, туганының беләгеннән тотып, ишеккә таба борды.

— Эч пошырып торма әле монда!

Аның бу сүзләреннән бик тә күңелем булып, елыйсыларым килеп китте, тик яшь күрсәтү түгел, суламаска да тырышып, эчкә һава җыям диеп киерелгән идем, авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып җибәрдем. Кабыргамны нидер чәнчеп алды. Гөлчәчәк яныма ук килде.

— Кай җирең авырта?

Кыз кечкенә йомшак кулын маңгаема куйды. Мин югалып калдым. Шул мизгелдән Гөлчәчәк аеруча якын булып китте.

Ә Гөлйөзем? Һай, җавап көтмәгез: бу сорауга батырып кына җавап та бирә алмыйм икән бит! Күңел һаман иләс-миләс. Чынлап та, кайсысына күбрәк тартылам соң әле? Шушы иләс-миләслегем киләчәктә үз башыма гына булмаса ярый инде...

Җәйге көн минем буй кебек озын булса, төне Барыйныкы сыман кыска. Көтүләр кайтып, сыерлар савылып, күрше кызлары кичке уенга чыгарга дип, нәкъ көзге янында бөтерелгән вакытта, без, ике дус, кәҗә бәтиләре кебек черт-черт теркелди-теркелди, урман буена, каравылчы өенә таба юл тоттык.

Барый, Мунчала тәре, Ташсуны кичкәндә минем җилкәгә атлангач кына (ыштанын салса, кичке елга суы салкын, чалбарын салмаса, балагы суга тия) серенең бер читен ача төште: бүген Ярулла абзый хатыны мунча яга икән, үзләре кереп чыкканнан соң мунчаларында төн буе урман кызлары юына икән. Нәкъ Такташ шигырендәге урман кызлары инде. Үзе, кәтүк тәре, җилкәмдә утырган килеш, хисләнеп китеп, аяк үкчәләре белән күкрәккә төя-төя, кычкырып шигырь укырга тотынды.

Шул урманда
Үскән фәрештәдәй кыз бала,
Җирдә түгел, күктә, гарештә дә
Булмаган бер генә тиң аңа.

Урман биргән аңа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр.
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр.

Әгәр шигыре ошамаса, мин аны су уртасында ук җилкәдән чөеп төшерә идем, билләһи! Шигыре әйбәт. Аны Барый язмаган, аны Такташ язган.

Шигырь сөйләп йөрү кызлар эше дип уйларга гадәтләнгәнгә күрә, шигърияткә төкереп тә бирми идем. Соңгы араларда, урманчы кызлары белән танышкач, минем ул фикерләрем җилләбрәк тора әле: исәп тамырдан үзгәрергә. Әдәбият дәресләрен моңарчы бигүк өнәмәсәм дә, укытучы Мәдинәападан китаплар сорап торып, мин дә шигырьләр ятлый башлыйм әле. Аннан соң... Ярулла абзыйның йорты каршысындагы иң озын нарат башына менеп утырам да сөйли башлыйм:

Таң җилләре аның, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган,
Төне, ае, төннәрдә йокламыйча,
Ана булып күктән караган!

Таң җилләре кайсысының чәчкәйләрен тараган соң әле: Гөлчәчәкнекенме, Гөлйөземнекенме? Шайтан белсен!..

Урман каравылчысының мунчасы шактый читтә. Каралты-кура өчен урын иркен булгач, хуҗа җирне кызганмаган, бары ат абзары гына өй янәшәсендә үк салынган. Атларга угрылар кызыкмасын, диптер инде.

Без мунча тәрәзәсе каршындагы юан каен кәүсәсенә сыендык. Мунча эчендә ут юк, дөм караңгы. Мин, беркавым күз бәбәкләрем авырткачы көчәнеп, караңгы мунча эчендә берни шәйли алмаганыма гаҗиз булып, терсәгем белән Барыйга төртеп алдым. Без һәрвакыт шулай аңлашабыз: буем озын булгач, терсәк очы Барыйның нәкъ колак төбенә туры килә, Барыйның

терсәге минем бөерләр турысында, ул шунда төртә. Кул күтәреп сукмагач, айканмагач, берәү дә безне күрми, нигә сугышасыз дип әрли дә алмыйлар. Барый бөеремә җиңелчә генә төртеп: «Ашыкма, хәзер, хәзер»,— дип, мине тынычландыра.

Алдамаган икән: беравыктан мунча эчендә гөлт итеп ут кабынды. Аулак булгач, тәрәзә пәрдәсен дә тартып тормадылар, ап-ак итеп акшарланган мунча миче дә, ләүкәдәге ләгәндә яткан себерке сабы да аермачык күренеп тора. Ярулла абзый мунча тәрәзәсен артык биек иткән, мунча эчен тагын да яхшырак күрим дисәң, агач башына ук менәргә туры киләчәк. Менә берзаман эчтә бер шәүлә чалынып алды. Ике шәүлә! Шәүлә генә түгел, ап-ак иңбашлы ике кыз! Шәрә урман кызлары! Минем кинәт авызым кипте: телемне әйләндерә алмас булдым. Күрдеңме инде, күрәсеңме дигәндәй, терсәк очы белән янәшәмдә мыш-мыш сулап торган Барыйның колагына төртеп алдым. Кисәк кенә бөерем авыртып киткәннән Барыйның: «Күрдем, мин сукыр түгел лә!» — дигән ымын аңладым.

Без ул чакта тормыштагы шактый кызык хәлләрнең кендектән астарак булганын да чамалый идек инде: агач башына үрмәләдек. Мунча эче нәкъ кинодагы кебек күренә. Икебезнең дә авыз куышлыгында сулар күптән кибеп бетеп, тирләп-пешеп чыктык, гәүдәләребез үзебез менеп кунаклаган каен агачының яфраклары сыман дер-дер килә: яфраклар безнең еш-еш сулаудан гына шыбырдаша бугай.

Тәрәзә янында урман кызларының берсе, гәүдәгә чак кына калкурагы күбрәк кайнаша, аны танып, чак кына: «Гөлйөзем бит бу!» — дип кычкырып җибәрмәдем. Шөкер, тыелып кала алганмын, кычкырсам, кызны һәм аның шәрә матурлыгын куркытачак идем.

Барый, хисләнеп китеп, саксызрак кыймылдап куйдымы, әллә каенның очына ук үрмәләмәкче булды инде, кыскасы, ул утырган ботак шартлап сынып, тын урман эчендә мылтык аткандай яман каты тавыш чыкты. Барый бер кулы белән янәшәдәге ботакка ябышып өлгергән иде, әмма озак асылынып тора алмады, шапылдап, агач төбенә барып төште. Мунча эчендә ут сүнде.

Бер-бер артлы мылтык гөрселдәгән тавышка Ярулла абзыйның артыбыздан ни дип кычкырып калганын һич тә ишетерлек түгел. Күрмәгәннең күрәсе, күргәннең качасы килә, дигән әйтем бу очракта безгә тач туры килеп тора иде...

Җирдән аерылып киткәндә, космик ракета да, билләһи дип әйтәм, шундый зур тизлек җыеп өлгерә алмый торгандыр! Йомшак җирләребезнең авыртуына түзә алмыйча уктай атылып, Ташсуга таба томырылдык. Чапкан уңайдан бер куян баласын узып китеп, өстеннән сикереп чыкканым гына аз-маз исемдә калган, бүтәнен хәтерләмим: тозын җәлләмәгән иде Ярулла абзый: монысын без, ай-һай, шәп татыдык соң!..

Өйдәгеләрне, урманда ялгыш бүре җиләге ашадык, эчебез авырта, дип хәйләләргә туры килде. Караватка чалкан ятып булмый да булмый инде, авыртуга түзәр әмәл юк, төнне керфек какмыйча, корсакта килеш уздырырга туры килде.

Әлбәттә, авырту нинди генә каты булмасын, ул барыбер урманда күргәннәрне оныттыра алмады. Күргәнең сигез, күрмәгәнең тугыз дигәндәй, мунча тәрәзәсе гел күз алдыннан китмәде. Барыйның урман кызлары, урман ияләре дип, мине алдаганын яхшы белсәм дә, бу юлы, нигәдер, аны ачуланмадым. Әмма бар курыкканым урман каравылчысының безне танып калуы иде. Шөкер, икенче көнне дә, өченче, дүртенчесендә дә өйгә килмәде Ярулла абзый. Тора-бара мин дә, Барый да тынычландык.

Күзең кайда булса, күңелең шунда дигәндәй, күңел күзенең карашында һаман урман кызларының фәрештәдәй гүзәл шәрә сыннары тора. Мин аны яшертен генә ак кәгазь битенә төшердем һәм астына: «Урман кызы Гөлйөзем»,— дип язып куюдан чак кына тыелып калдым. Әмма барыбер Барыйга күрсәтмичә түзә алмадым. Ул бик озаклап карап торды торды да: «Аллай!» — дип, соклануын яшерә алмады. Тик шунысын гына аңлап җиткермәдем, минем осталыкка шаккаттымы Барый, әллә сурәтнең үзе әсәрләндердеме? Мин рәсемне китап эченә яшердем.

Шунысы яхшы истә калган: әлеге хәлдән соң без Барый белән шактый вакыт мәктәптән бергә кайтмадык. Бер-беребезгә күтәрелеп карарга да ничектер уңайсыз сыман иде.

Оятсыз оялса, каты оялыр ди бит...

Әмма шуннан соң,— бер кавым вакыт узгач,— аралар тагын да якынайды гына сыман. Үзебез дә әллә ничек җитдиләнеп киткәндәй булдык...

* * *

Ел кебек озын җәйге көндә таңнан алып кичкә кадәр көнозын көтүдә йөргәннән соң, капканы сыңар мөгезе белән генә төртеп ачып, әлсерәп, ишегалдына кайтып кергән сыер хайванын күргәнегез бардыр инде. Сусаган була ул. Ашыга-кабалана су эзләп, ишегалдындагы бар савыт-сабаны, чиләк ише нәрсәләрне тикшереп, аударып чыга, максатына ирешеп су тапса, дөньясын оныта.

Үзебезнең капка төбенә җитәрәк, озак торып каладан кайтып кергән саен, минем белән дә гел шулай була: ашыгам-кабаланам, еш-еш сулый башлыйм. Күкрәк читлегендәге кош баласы уянып китә. Мин капкага килеп төртелгәндә, аның келәсе төшкән булса, келәсе-ние белән очыртырга теләгәндәй, капканың калын тактасына тез башым белән төртеп алам; тимерчелектә эти үзе эшләгән нык келә кымшанырга да уйламый, аңа уч төбем белән генә сугам да нәкъ сыер кебек капкага бәреләм, ул ачылып китә.

Мин тәгәрәп үскән ишегалды. Лапас янында нидер эшләгән булыпмы, өйлә җитеп килсә дә, минем һаман кайтып җитмәүгә эче пошыпмы, юкны-бушка аударып, эти йөри. Әти, мине күргәч, үзе дә сизмәстән көлеп җибәрә: кайтты! Аның бияләй чаклы авызы (әни шулай дип әйтә) колакларына җитә. Малай кайтты! Әти дәү авызын һаман җыеп бетерә алмый әле. Аның нәкъ менә чын ирләрнеке кебек зур авызлы булуы миңа бик ошый. Ир-ат уймак авызлы булырга тиеш түгел кебек, минемчә.

Әти көтүгә дигән озын каеш чыбыркысын күптән әзерләп куйган, ул рәшәткә башында эленеп тора. Һәм беренче эш итеп миңа шуны күрсәтте. Менә әзер, янәмәсе.

Әтинең йөзендәге беренче шатлыклы тойгыны икенче төрле хис алыштыруын бары мин генә чамалый һәм сизә алам: авылга минем җәяү кайтуга бик тә эче поша инде аның. Рәссам дигән зур исемең бар, дәрәҗәң бар, үзең тузан таптап җәяү йөрисең! Әнә фәләннең малае! Әнә тегенең малае! Кыскасы, әтинең әйтергә теләве шул: кеше малайлары машинаны күлмәк урынына алыштыра. Ә син?..

Әти миңа ни уйлаганын турыдан-туры әйтми. Үзем дә беләм. Аның малае бит мин...

«Төкерсәнә, эти, машинасына, җәяү йөрү файдалырак ул!» — дип, аны бик тә юатасы килә килүен. Ләкин ул фикерен кычкырып әйтмәгәч, ничек итеп авыз ачасың инде.

Чукынып китсен машиналары, эти, борчылма! Синең малаеңныкы да булыр һәм кешенеке төсле генә булмас! Һай, белсә иде эти мин эшләгән берничә картинаның күпме торганын! Егылып китәр иде, билләһи! Алайса ник машина алмыйсың соң, малай актыгы, диячәк шул ул.

Сиринә Самуиловна берьюлы ике машинасын миңа бирергә әзер тора, дисәң дә аңламаячак ул. Аннары сорау арты сорау китәчәк: кем ул Сиринә дигәнең, нигә ул сиңа машинасын бушка бирсен? Әллә башына тай типкән бер тилемсә хатынмы?

Без әти белән бик җылы күрештек.

Ишегалдында әйтмәгән сүзен әти чәй янында барыбер әйтеп куйды; эчендәгесе тышында инде үзенең.

— Барый тагын яңа машина апкайтты. «Волга». Ап-ак төстә.

— Чукындың инде шул машина белән! Алса алсын шунда. Хет унны. Барый колхоз малын кимереп ята ул!

Монысы әнинең сүзләре. Әйе, анысын да яхшы беләм: әнигә минем исән-имин күзгә күренүем машинага караганда мең өлеш кадерлерәк. Машинага утырып кайтасыңмы син, әллә атка атланыпмы? Кайт кына, исән-сау гына йөре.

Әлбәттә, әнинең дә эчен тырнап торган бер борчуы бар: ул — минем өйләнмичә йөрүем. Әнигә килен кирәк. Үз янында бергә тормаса да, килен кисәге кирәк әнигә.

Әти машина, ди, әни килен, ди. Мин боларның барысын да яхшы беләм, аңлыйм, хәтта миндә шул нәрсәләрнең, ичмаса, берсе генә булмавына борчылам да кебек үзем. Әмма бәрелеп сугылмыйм. Чөнки беләм, бары үзем генә беләм: эти белән әни хыялланган ике теләкнең берсен генә булса да иртәгә үк тормышка ашыра алам лабаса!..

Алайса нигә шулай итмим соң? Ә менә анысы бөтенләй икенче мәсьәлә инде...

«Машина белән килен» темасын онытгырырга, бастырыклап куярга теләп, мин чәй янында ук эти ягына карап:

— Көтүне кайсы болынга алып чыгасы булыр инде? —дигән булам. Бик тә әһәмиятле сорау, янәмәсе. Әһәмиятле түгел, әлбәттә. Теләсәң, Наратлыга алып бар, телисең икән, сарык-кәҗәләреңне Сай суга куасың, әмма минем картлар өчен бу дөньяда әһәмиятсез бер генә нәрсә дә юк: чыннан да, ул чират көтүен кайсы болынга алып бару мәслихәтрәк булыр икән соң? Әти белән әни шул хакта баш ватарга керешә. Ахырдан Сай су дигән катгый карарга киләбез дә аш-

су өчен рәхмәтемне әйтеп, ишегалдына чыгам. Әти бу юлы чыбыркының шәбен әзерләп куйган. Зәһәрен дип әйтсәң дә була. Үзе озын, үзенең каешы да, кылы да шәп күренә.

Рәшәткә башындагы чыбыркыны алдым да бер-ике мәртәбә, кул язу өчен генә айканып алганнан соң, аннары чынлап торып, шәп итеп урман ягына таба каратып шартлатып җибәрдем.

Чыбыркы тавышы урманга кадәр үк барып җиттеме икән, юкмы икән? Җитсә, беренче булып кайсысы ишетте икән: Гөлчәчәкме, Гөлйөземме? Кайсысы? Шунсын беләсе иде, ә?.. Кайсы ишетте икән?..

## Мин һәм Гөлчәчәк

Теге чакта Барыйга ияреп йөреп, адәм мәсхәрәсе булганнан соң, урман кызлары белән тиз генә күрешү насыйп булмады. Күрәсе килә иде үзләрен. Мунчаның парлы тәрәзәсе аша шәрә шәүләләрен күргәннән соң, бу күрешү бөтенләй башкача һәм бүтән төрле булырга тиеш кебек иде. Кызганыч, кызлар безнең мәктәптә укымыйлар. Ярулла абзый аларны урман артындагы Бурян мәктәбенә йөртә. Бурян урыс авылы һәм, әлбәттә, мәктәбендә дә урысча укыталар. Ул чакта баланы урыс мәктәбендә укыту, бердән, зур дәрәҗә саналса, аның икенче әһәмиятле ягы да бар: мәктәп тәмамлаганнан соң, теләгең булу өстенә башың да түгәрәк икән, үзең теләгән - югары уку йортына имтиханнар тоту бермә-бер җиңелрәк иде.

Кызларны мин сабан туенда очраттым. Очраттым да телсез үк калдым бугай: барлы-юклы бер ел эчендә алар тәмам үзгәргәннәр. Әлбәттә, бар үзгәреш аларның үсүләрендә, балалыкның күкәй кабыгын ватып чыгып, җиткән кызлар булып өлгерүләрендә иде. Ул вакыт эчендә үзем дә үскәнмендер инде, көн саен көзгедән күреп торганга гына сизми калганмындыр... Көн дә күрешеп торгач, Барыйда да әллә ни үзгәреш күренми. Ул да бер урында гына тормагандыр, мөгаен.

Сабантуй сабантуй булмады минем өчен ул көнне. Карак-угры кебек Гөлчәчәк белән Гөлйөземне күзләп йөрдем. Үзем дә сизмәстән, алар халык арасында күздән югалугa, кызларны эзлим, әмма яннарына барып сүз катарга йөрәк җитми, тик барыбер күз уңаеннан да югалтасы килми үзләрен. Күзең кайда булса, күңелең шунда, ди бит. Дөресрәге, күп вакыт кызлар артыннан күңел үзе ияреп йөрде бугай. Сабан туе таралгач та кызларга ияреп китте ул. Һәм шуннан соң бүтән үземә кире әйләнеп кайтмады, урманчы кызлары яныннан күкрәк читлегендә тыпырчынган бәләкәй кошчыкка берөзлексез җим биреп тора кебек иде.

Сабан туеннан соң да нәкъ бер атна тирәсе аңкы-миңке йөрдем әле. Кызларны сабан туенда Барый да күргән булырга тиеш. Ләкин аның белән теге вакыттан соң урманчы кызлары турында сөйләшәсем килми, ничектер тел әйләнмиме, күңел тартмыймы...

Бер дә уйламаган җирдән, миңа әти ярдәмгә килде! Ул тимерчедә эшли иде бит. Беркөнне, эштән кайткач, ат арбасыннан ниндидер тимер-томырлар алып, аларны баз өстендәге келәткә җыеп куярга кушты да:

— Иртәгә боларны Ярулла абзаңа илтеп бирерсең,— диде. Нәрсә икәнен әйтмәсә дә, үзем шундук чамаладым: җәнлек тозаклары иде ул.

Нәрсә булса да булсын — йөгерә-йөгерә илтермен, әти бәгърем! Рәхмәтләр яусын сиңа! Анда кадәр баргач баргач, урманчының кызларын да күрәм дигән сүз бит инде! Тик мунча вакыйгасы гына бераз күңелне тырнап тора торуын. Гөлйөземне күргәч, колакларыма ут кабып, эшне сиздермәсәм генә ярый инде. Колаклар бигрәк сатлык- җаннар шул минем! Берәр төрле шуклык кылу гына түгел, хәтта аны эшләү турында уйлап куйсам да хәзер кызарырга гына торалар. Барыйга рәхәт, аның әрекмән колаклары кызаруның ни икәнен дә белми!

Башка вакыт булса, җәнлек тозакларын илтергә Барыйны да иярткән булыр идем, әлбәттә. Ләкин «мунча тәрәзәсе» һаман тынгылык бирми. Шуның өчен әле һаман Барыйны сүгәм, хәер, сүгүен сүгәм дә... икенче яктан, ул кичне күргәннәр һаман күз алдыннан китми... Күңелне рәхәт кытыклап тора. Әллә бу күңелнең ояты юк инде... Тфү! Үзем дә буталып беттем. Дөресен әйтим, ул турыда тамчы да уйлыйсы килми... ә үзе уйлаттыра һәм еш уйлаттыра.

Авылны чыгып китеп, Ташсу елгасына җитәрәк, колаклар гына түгел, әллә нинди сәер хис тәэсирендә бөтен гәүдә-тәнем үк кызыша башлады. Бәлкем, кызу-кызу, ашыга-ашыга баргангадыр? Байтак вакыт елгада суынып яттым һәм шул ярдәм итте: гәүдәм генә түгел, хисләр дә суына, тотрыклана төштеләр бугай.

Мин барып җиткәндә, Ярулла абзый мотоциклы янында кайнаша иде. Урман хуҗалыгыннан яңа мотоцикл биргәннәр. Моңарчы гел ат җигеп йөри иде.

Матае, күрәсең, ватылып киткән, Ярулла абзыйның беләкләренә кадәр майга манчылган.

Ул тозакларны кабул итеп алды да тикшереп караганнан соң: «Шәп булган бу! Рәхмәт!» — диде.

Аннары сорашмасам да, әлеге тозакларның нигә кирәклеге турында аңлатырга кереште:

— Төлкегә бу тозаклар. Лапаска килеп ничәмә ничә тавыкны буып китте инде. Кыш көне, Алла боерса, алма бакчасына килгән кылый күзләргә дә куярбыз.

«Бик әйбәт, Ярулла абзый, куярсың, куярсың. Мине алар кызыксындырмый. Мине...» Шулчак ишегалды бакчасына сузылган баудагы керләрдән тып-тып су тамганына игътибар итеп өлгердем. Күңелгә җылы кереп китте: кызлар кер уа, димәк, тагын ишегалдына чыгачаклар әле. Шуңа күрә монда, Ярулла абзый янында, ничек тә булса озаграк тоткарланырга кирәк. Ә матай моның өчен менә дигән сәбәп иде. Барыйның «Минск» матаен атнага җиде тапкыр сүтеп җыябыз без. Шуңа күрә бу техниканы ярыйсы ук чамалыйм мин.

— Ярулла абый, нәрсә, матаең ватылганмы әллә?

— Кабынмый шул, кәҗәләнә,— диде ул.

— Үзем актарып карыйммы соң?

— Әйдә, булдырасыңмы? Конторга барасы бар иде. Ашыгам.

Ике кулымны сызганып эшкә керештем һәм, бу очракта кызганычка каршы, дияргә кирәктер инде, аның эшләмәвенең сәбәбен дә бик тиз таптым. Башым эшләп өлгерде: серне Ярулла абзыйга шундук ярып салмадым.

— Ярулла абый, лесхозыңа бара тор. Син кайтканда матаең сәгать кебек эшләячәк!

Мин, таз башның, әнә шулай дип әйтергә кыюлыгы җитте! Үземнең тапкырлыкка үзем шаккаттым.

Ярулла абзый, берсүзсез ризалашып, атын җигәргә кереште. Юкка гына мотоциклы белән маташмаган икән, биясе абзардан алып чыгуга чыгымлый башлады. Ярулла абзыйга аны арбага җигешергә булыштым. Бияне җиккәндә, урманчы бер-ике сүз белән генә бер атна элек биянең таена бүре һөҗүм итүе һәм шуннан соң таен югалткач, акыллы биянең кинәт холкы үзгәрүе хакында сөйләп алды.

Безнең урманда бүреләр бар шул. Бигрәк тә узган кыш котырды алар. Күрше авылдан мәктәптән кайтышлый унике яшьлек мари малаен да ботарлап ыргытканнар иде. Малайны, укуын юньләп белмәгәне өчен, укытучы дәрестән соң алып калган була. Биш чакрымдагы авылына караңгы төшәр алдыннан гына кайтырга чыга малай. Басу юлында бүреләр очрый. Малайның бары китаплар салынган букчасы белән киез итекләре генә торып калган дип сөйләделәр. Бу хәбәрдән соң бар тирә-як шаулап алган иде. Район үзәгеннән махсус кешеләр килеп, кыш буе бүре аулап та йөреп карадылар. Сөйләүләренә караганда, алар соңгы елларда безнең якның мари урманнарында үрчеп һәм котырып киткән шактый гына бүреләрне киметкәннәр. Ләкин аларны бөтенләй кырып бетерергә дә ярамый бит әле. Һәм шул кыштан соң исән-сау калган бүреләрнең кешеләргә бик ачуы килеп, хәтта җаен дә гел зыян салып торырга карар кылганнар, имеш. Халык шулай сөйли. Ярулла абзыйның тае шул бүреләр корбаны булган.

Ярулла абзыйны капкадан хатыны Гөлчирә апа озатып калды. Хуҗаның кушуы буенча, әгәр дә мәгәр мотоцикл рәтләгәндә миңа кирәк-ярак булса, шул Гөлчирәападан сорарга тиеш идем. Гөлчирә апа белән дә күптән таныш без. Ярулла абзыйга утырып, бик еш авыл кибетенә килгәли ул.

Әйткәнемчә, матайның очына тиз чыктым: гаеп карбюраторында гына иде. Аннары тиз генә кабызып карарга исәпләдем һәм тагын шундук уемнан тукталып калдым: кайдандыр өй артыннан, кулына керләр өелгән бәләкәй таз күтәреп, Гөлйөзем килеп чыкты. Минем тамакка туралмаган бербөтен бәрәңге килеп тыгылды, колакларыма гөлт итеп ут кабуын тойдым, борыныма су җыелып, мышык-мышык суларга керештем. Бу халәтемнән мине матай коткарды. Басып җибәрүем булды, аның, кабынып китеп, чатыр-пытыр эшли башлавы булды. Сүндерергә вакыт булса да, алай эшләмим, матайны һаман акыртам да акыртам. Ишегалды зәп-зәңгәр төтен белән тулды.

Гөлйөзем, керләрен янбакчадагы бауга элеп бетереп, ишегалдына чыккан һәм миңа нидер ымлый-әйтә бугай, аны ишетмим, матайны һаман акырта бирәм. Төтенгә үзем дә тончыгып беттем, кызның да күзләре яшьләнде, куллары белән нидер аңлатмакчы була, иреннәре дә хәрәкәтләнә. Йә нәрсә димәкче буласың, чибәр кыз!

Мин матайны сүндерәм.

— Мөхәммәт, керләрне төтенгә батырып бетерәсең бит инде! Ишегалдында эшләтмәле бүтән! — ди Гөлйөзем.

— Ярулла абый бензинга майны күп кушкан,— дим мин аңа каршы.— Шуңа төтенли ул.

Минем бу сүзләр мәгънәсезлекнең арт ягында икәнлеген үзем дә беләм. Бүтән чарам юк. Колаклардагы утны ничек тә булса сүндерергә кирәк бит. Рәхмәт төшкере, матай сүнүгә, колакларым да салкыная башлады бугай.

Зәңгәр төтен, җил белән капка астыннан урамга суырылып чыгып бетте. Әмма барыбер Гөлйөземгә нинди дә булса сүз кушарга кирәк ич, каен бүкәнедәй бу рәвешле күпме басып торып була инде!

— Әйдә, Гөлйөзем, бер әйләндереп киләм,— дидем мин, телемә шундый сүз килүенә үзем дә сөенеп.

— Аңа утырып йөрергә куркам мин. Әнә Гөлчәчәккә әйт. Ул өйдә елап ята. Яраткан таен бүре суккан.

Рәхмәт төшкере, сүзләр генә түгел, эшләр дә җайга салынырга тора бит болай булгач. Сөенүемне яшерә алмыйча (әйтерсең тайны бүре алып киткәнлегенә куанам):

— Кайда соң ул? Бар, әйт,— дидем аңа каршы.

Гөлйөзем җәһәт кенә өйгә кереп китте һәм күп тә үтмәде, алар, Гөлчәчәк белән икәүләшеп, килеп чыктылар. Чыннан да, Гөлчәчәкнең йөзләре сулыгып та, чак кына агарып та киткән сыман. Кыз туп-туры минем янга атлады.

— Мөхәммәт, әйдә, Аккашкага бүре ташланган урынга алып барып кайт әле,— диде кыз.

«Бик хуп, әйдә киттек!» — дип, шатланып-сөенеп, шундук матайны кабызасы урынга мин югалып калдым, аңа каршы ни дияргә дә белмәдем. Мин җавапсыз калып торгач:

— Матай эшли торгандыр бит? Мин әнидән рөхсәт сорадым,— диде кыз.

Бу хәлгә Гөлчәчәкне утыртып (егылып төшмәс өчен миңа тотыначак та бит әле ул!) урманга чыгу җае туры килүенә һич кенә ышанып җитәсе килми бит! Бүкән сыман һаман сүзсез басып торам!

— Беләм, вакытың юктыр инде?

Мин кисәк аңыма килдем.

— Капканы ач әле!

Матайны капкадан этеп алып чыктым, Гөлйөземнең ап-ак керләре чынлап та жәл иде.

Тайга бүре һөҗүм иткән урын Бурян ягында икән. Анда Бүре чокыры дигән урын барын да беләм әле мин. Без ел саен әти белән Бүре чокырында мунча миллеге җыябыз, яшь каеннар күп анда.

Ярулла абзыйның матае зәһәр икән, газын боруга йолкып алып та китте. Аннары Гөлчәчәк янында гомер буе матай өстендә чапкан ярышчы кебек кыланам. Ярулла абзыйның кызы чытырдатып миңаябышты. Һай, күктән кинәт ишелеп төшкән бәхет! Өнемме соң, төш кенә түгелме икән бу! Күңелем чиләк булган: унбиш яшьлек яшүсмернең, шулчак әллә нинди батырлыклар, әллә ниткән җүләрлекләр кыласы килә башлады бугай. Мин, тиле һәм мәгънәсез яшүсмер, берара хәтта: «Рәхмәт сиңа, соры бүре!» — дип тә кычкырып җибәрә яздым бугай.

Гөлчәчәк урманда үскән кыз, мондагы һәр сукмак, һәр агач төбе аңа яхшы таныш: ул юлын күрсәтеп баргач, Бүре чокырына турыдан гына бик тиз килеп җиттек.

Гөлчәчәк белән икәүдән-икәү генә калып күзгә-күз беренче сөйләшүем Бүре чокырында булды. Дөресен генә әйткәндә, урманда минем Гөлйөзем белән ялгыз каласым килгән иде. Чөнки мунча тәрәзәсеннән аны күрдем бит! Күрдем дә гашыйк булдым. Мизгел эчендә минем иләс-миләс күңелдән кырыкмаса-кырык төрле уй-фикер үтте. Әйе, Гөлйөземне ялангач килеш күрдем дә, ди. Шуннан аңа гашыйк булдым да, ди. Ә менә аның урынына күрше кызы Алмазияне күргән булсам? Аңа гашыйк булган булыр идем микән?..

Гыйшык-мыйшык турындагы уйларым бер-берсенә шул рәвешчә гел каршы килә дә тора. Бернинди мантыйк юк.

Бүген шуларны кабат искә төшереп уйлыйм да хәзерге яшьләрне кызганып куям. Бер-берсе белән кочаклашып йоклаганнан соң, шуны мәхәббәт белән бутап, тормыш корып җибәрүче яки «я без него (неё) не могу!» дип адашкан-саташкан яшьләрне кызганам! Шул рәвешле алар чын мәхәббәтнең ни икәнлеген белми, татымый да кала! Моның нәтиҗәсе буларак, алдавыч хисләр дулкынында корылган гаиләләр үзләре дә чәлпәрәмә килә. Әйе, чынлап та шулай бу. Чөнки бүген, моннан унбиш-егерме ел элек вакыт белән чагыштырганда, яшь кыз белән яшь егетнең җенси якынлык кылуы чаттагы әбидән сатып алган бер стакан көнбагыш вату кебек кенә. Һәммәсе өчен булмаса да, һәрхәлдә, күпчелек өчен шулай. Беләм бит, чөнки мин үзем дә бу тормышта яшим, һәм нәкъ шушы казанда кайныйм лабаса!

Үзем теге вакытта Гөлчәчәк белән Бүре чокырында ялгыз калгач, аның кулын тоту түгел, хәтта күзләренә күтәрелеп карарга да курыктым. Ул очрашу бүген дә хәтернең һәр күзәнәгендә диярлек саклана.

Гөлчәчәк Аккашка кушаматлы тайны үзе тәрбияләп үстергән булган. Гомумән, ул атларны бик ярата икән! Әлеге хәбәргә ышанасы да килмәгән. Хәзер менә, Бүре чокырына үзе килгәч, күңеле чынлап торып ышанды. Кыз шунда үскән бер яшь каен янына килде дә аны учлары белән сыйпап:

— Һай, каенкаем, ул хәлне син күреп торгансыңдыр бит инде? Ник ул явыз бүрегә Аккашканы харап итәргә ирек бирдең соң син, ә? — дип куйды.

Мин, матайга сөялгән килеш, кулымдагы абага белән кигәвен куып тора идем, кызның әлеге сүзләреннән соң эсселе-суыклы булып киттем. Әүвәл кычкырып җылап җибәрәсем килде, аннары, тиз генә акылыма килеп, Гөлчәчәкне юатмакчы булдым:

— Гөлчәчәк, теләсәң, ул бүрене үтереп, колагын сиңа кисеп китерәм! Үзем дә сиздем: булмаслык хәл турында сөйләнсәм дә, сүзләрем эчкерсез һәм ихлас иде.

— Кирәкми, Мөхәммәт,— диде Гөлчәчәк, миңа таба борылып.— Син ул бүрене үтерсәң, аны да җәлләячәкмен бит мин!..

Гөлчәчәк минем янга килде. Матайны кабыздым. Ярулла абзыйның матае, урман эчендә булгач, нәкъ танк чыгарган тавышлар белән эшли башлады.

Юлга чыкканчы, урман чәчәкләрен таптый-таптый, тар сукмактан гына элдерттем. Кыз:

— Әти миңа ак ат алып бирәм дип вәгъдә итте! — дип кычкырды..

## Берәү сата, берәү ала

Миндәге үзгәрешне беренче булып Һади абый күреп алды: рәсем соңгы көннәрдә минем өчен мавыгу гына түгел, яшәеш рәвешенә әверелеп, ак кәгазьгә төшәчәк төсләр бар тормышымны тутырды.

Мин тиле кебек урман ясыйм да урман ясыйм, йә урман аланын сурәтләргә маташам да шунда чәчәк җыйган бер кыз бала төшереп куям. Тора-бара, күп кәгазьләр бозып, үзем үк ертып ата торгач (өйдә әнигә мич тергезеп җибәрү өчен файдалы булса, мәктәптәгеләре чүпкә әйләнеп, җыештыручы апаларның нервасына гына тия иде), урманыма чак кына урман рәвеше керде. Әмма чәчәк җыйган кызым күбәләккә яисә су анасына охшый иде.

«Барыбер Казанга алып китәм әле мин сине, урман! Гөлчәчәгең белән бергә!..» Бу минем йөрәкнең ярсулы тибү тавышы, бу уналты яшьлек үсмер егетнең үз башыннан узачак язмышына, фани дөньяда күрәчәк кырыкмаса кырык төрле тормыш сынауларына кизәнүе, алай гына да түгел, киләчәгенә: «Сиңа бик көчле, каны кайнап торган бер егет килә, тормыш! Аяк чалырга уйлап та карама! Ул барыбер җиңүче булачак!» — дип, алдан ук аваз салуы һәм әледән үк йодрык төйнәп куюы иде.

Җикеренмә, малай! Үз башыңа булмасын! Тормышның күсәге бик саллы аның!..

Ярый, хуш. Укуым да үзгәрде минем: ничә еллар буе аяктан артка сөйрәп килгән «өч»ләләр язгы сулар белән бергә Иделгә таба агып киттеләр, өстәвенә рәсем җене миңа чын-чынлап кагылды. Моңа иң куанган кеше Һади абый булды. Тырыша-тырыша өйрәтә. Ул мине генә түгел, энесе Барыйның да кабыргаларына төрткәләп тора. Әлегесен Барыйның нәрсәгә талантлы икәнлеге ачыкланып бетмәгән, ләкин малайның колаклары зур булу өстенә баш та шактый түгәрәк. Бу кечкенә буйлы энекәш киләчәктә Наполеон булып куярга да мөмкин әле. Шуңа күрә Һади абыйсы аңа да кул селтәми, ышаныч һәм өмет белән карый иде. Тик Барыйның дөньяны болгатырга яратуы гына аның күңелен бераз тырнап тора.

Ышанасызмы, юкмы: уналты яшьтә Барый белән икебез Ницше фәлсәфәсен өйрәнә башлаган идек инде без. Әлбәттә, Һади абый ярдәме белән. Гитлер әлеге философ тәгълиматын ни рәвешле үз максатларында файдаланса, Һади абый да аны безгә кирәгенчә һәм бары тик безнең файдага гына эшкә җигә: Мөхәммәт атлы күрше малае зур рәссам булырга, Барый энекәш җитәкче-сәясәтче булып үсәргә тиеш!..

Ул китаплардагы акыллы сүзләр әле дә булса колагымда яңгырый. Чөнки без аларны дәфтәргә күчереп алып ятлый да идек.

«Матурлыкның иң күркәм йөзе дә үзенә шундук тарта алмый, ул көчле исертүгә дә ия түгел (андый матурлык бик җиңел генә нәфрәт уятырга да мөмкин); ул сиздермичә генә күңелеңә сеңә; син аны әле кабат очратасың, йөрәкләрдә бик озак тыныч кына посып ятканнан соң гына, ул кабат безне тулысынча биләп ала, күз һәм йөрәгебезне яшьле сагыш белән тутыра.

Матурлык иҗат иткәндә, без нәрсәгә омтылабыз соң? Әлбәттә, гүзәллеккә! Бәхет тә нәкъ шуның белән килә бит инде. Ләкин бу ялгышу!»

«Рәссамнар балкыш-нурлануның кинәт киләсенә кешеләр ышанырга тиеш дип уйлый. Икенче төрле ул илһам килү дип атала. Сәнгать һәм шигъри әсәрләрнең идеясе, төп фәлсәфи фикерләр яктылык сыман күктән иңгән кебек. Чынлыкта яхшы рәссамның яки фикер иясенең фантазиясе һәрвакыт йә яхшы, йә уртача, йә начар әсәр тудыра: ләкин аның үткән һәм тәҗрибәле фикерләве кире кага, үлчи-исәпли; күптөрле караламаларыннан һәрдаим гүзәл көйләр сайлап ала торган Бетховен көндәлекләреннән дә күренә бу.

...Барлык даһилар да фидакарь эшчеләр булганнар; алар арып-талып иҗат кына итеп калмыйча, шулай ук тырыша-тырмаша кире дә какканнар, кабат тикшергәннәр, тәртипкә салганнар».

«Сокландыргыч әсәр! Ләкин шунысы түзеп торгысыз: иҗатчы һәрвакыт бу әсәрнең үзенеке икәнлеген искәртеп тора».

«Кеше үзенең фикерен анык әйтә алырга өйрәнгәннән соң аңа ышанмый башлыйлар. Тотлыгып торучыларга күбрәк ышаналар».

Барыйга исә немец фәлсәфәчесенең фикерләре үз каланчасы биеклегендә аңлашыла иде. Гомумән, Барый һәрвакыт үзенең шул каланчасыннан да өскәрәк менә алмастыр. Хәйләкәр ул. Һәм үзенең хәйләсен берәү дә сизми дип уйлый. Унынчы класста укыганда, мин аның шарж-рәсемен ясап үзенә күрсәттем. Кыска буйлы, базык бәдәнле, башы да түгәрәк кенә, ягъни нәкъ үзенеке сыман килеп чыкты. Ә колаклары... колакларын мин аларны юри, куян колакларына охшатып, озын итеп ясадым: ул колаклар Барыйның үзен дә узып китте. Бу, минемчә, Барый башындагы хәйләнең шулай зур булып калкып торуына бик шәп ишарә иде. Колак-хәйлә Барыйның үзен дә узып киткән. Барый үз колакларын үзе күрми, ә кешеләр күрә.

Теге чакта, күпердән төртеп төшергәндә дә, ул бу чаклы ук үпкәләмәгән иде. Бу юлы Барый бөтенләй телсез-авызсыз калды, сөйләшмәс булды. Миңа зыянлы ягы тагын шул булды: без мәктәпкә өч чакрым ераклыктагы Байтирәккә йөреп укыйбыз бит, барганда да, кайтканда да мәктәпкә Барыйның матаена атланып йөри идек, колак-хәйлә рәсеменнән соң тагын җәяүгә калдым. Әмма сизеп торам: Барыйның үч алуы моның белән генә тәгәлләнмәячәк иде әле. Классташ дустым миңа каршы тагын нинди этлек уйлар?..

Байтимер юлында Барый дустым мине бер көн тузанга коендырып китте, икенче көнне дә янымнан пырылдап узды. Тик гарьләнмим: үземнең кем малае икәнлегемне беләм бит, шуңа ияләнгәнмен, күнеккән инде. Бер түгел, ун матай алып бирәм дисәләр дә барыбер Хаҗи малае булмас идем мин. Минем үз әтием алтын! Куллары гына түгел, чынлап та, үзе дә алтын кеше ул! Җитмәсә, быел көзгә әти миңа да матай алып бирергә уйлый бугай. Бу серне шыпырт кына әни чиште.

Аннан соң мәктәптән кайтканда, мин, адым саен каерылып, урман ягына карыйм, Гөлчәчәкне күз алдыма китерәм, күңелдән аның белән сөйләшә-сөйләшә атлыйм. Һәм шул рәвешле өч чакрым араны ничек кайтып җиткәнемне сизми дә калам. Өйгә кайтып җитүгә көндәлек эшләрне тәмам кылгач, дөньямны онытып рәсем төшерергә тотынам. Юлда кайтканда, мин бүген урманны тагын бүтән сурәттә күрдем. Карашым ул күренешне, капылт кына югала күрмәсен дигәндәй, үзенә җыеп алып, күңел сандыгыма салып куйды яисә хәтер күзәнәкләремә сеңдерде дип әйтсәң дә була.

Минем исәп буенча, рәсем-картинада тере урман аланлыгында бер кыз чәчәк җыярга тиеш иде. Аланлык әллә ни зур да түгел. Як-ягын төрле яшьтәге һәм төрле-төрле агачлар: каеннар, усаклар, наратлар уратып алган. Бер карт усак башында, чәчәктән чәчәккә кунып йөргән кызны күзләп, дәү козгын утыра, икенче якта, яшь наратның очына ук лачынмы, бөркетме кунган. Ул кызның тынычлыгын саклый. Әйбәт килеп чыкканлыгын үзем дә беләм. Һади абыйга әйтсәм, ул да шулай диячәк, әлбәттә. Ләкин бу минем серем, аны хәтта Һади абыйга да чишә алмыйм. Урман кызы Гөлчәчәккә булган хисләрем бары тик минеке, үземнеке генә!..

Өченче көн дигәндә, Барыем түзмәде, узып киткән җиреннән кире борылып килеп яныма туктады да матаена утырырга чакырды; күптән беләм: Барый дустым купыгырак булса да, күңеле яхшы аның. Бердәнбер якын дустым лабаса ул минем! Әүвәл утырмаска маташып карышасым килгән иде, Барый, гаепле тавышы белән:

— Киреләнмә инде, Мөхәммәт. Син дә, мин дә бүтән алай эшләмибез түлке, яме,— дип, чын күңеленнән әйткәч, нишлисең, тәпи-тәпи кайту ләззәтеннән баш тартырга туры килде инде.

Анысы да монысы: Ярулла абзыйның матаен ремонтларга да без Барый белән икәүләшеп йөри башладык. Бу минем тарафтан оештырылган кечкенә, ләкин бик изге хәйлә иде:

Гөлйөземгә дә пар кирәк бит инде. Бәлкем, Барый белән борчаклары пешәр дип уйладым мин һәм ялгышмадым бугай: алар хәтта холыклары белән дә бер-берсенә туры килеп торалар; Барый да, Гөлйөзем дә безнең белән чагыштырганда кыю һәм чаярак, алар нинди булса гамәлне кылганчы түгел, соңыннан гына уйлыйлар иде. Эшнең нәтиҗәсе турында аны кылганчы түгел, соңыннан, эш беткәч кенә уйлыйлар иде.

*** * ***

Сәгать уннарга кадәр сарык-кәҗәләр капланып ашаячак әле, унбер тулганда мин аларны Ташсуның комлы ярына туплауга алып килергә тиеш. Тамаклары туйган булса, өйлә вакыты авышканчы комлыкта тынсыз ятачаклар. Мин бу чаклысын гына беләм, чөнки яшьтән үк чират көтүе көтеп үскән малай. Шулай да арада алдындагы үләнгә генә риза булмаган туймас тамаклы һәм чырсыз маллар да бар. Бигрәк тә кәҗәләр холыксыз була. Җитмәсә, үз артларыннан сарыкларны ияртәләр!

Шуңа күрә яр буенда аякларны озак салындырып утыра алмадым, торып, көтүнең әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан әйләндем. Башка чак булса, көтү көтешергә үзем белән берәр күрше малаен да ияркән булыр идем. Тик бүген малайлар буш түгел, бүген — сабан туе.

Кичә Казаннан соң кайтылды, Гөлйөземне дә күрергә өлгермәдем. Сабантуй мәйданы урман каравылчысының өеннән ерак түгел. Гөлйөзем, бәлкем, җыенга чыккандыр.

Ә Гөлчәчәк хәзер ерак районнарның берсендә эшли. Мәктәптә укыта. Читкә китеп яшәвенең сәбәбе бар: әнисенең бертуган апасы, моннан ел ярым элек параличланып, урын өстенә яткан иде. Ул апа ялгыз башы гына. Минем Гөлчәчәгем, университетның биология факультетын тәмамлап, кире үз урманына кайтып киткән иде. Әйтергә онытып торам: Гөлйөзем кыз башы белән урман техникумында укыды һәм ул да әти-әнисе янына кайтты. Урман кызларын шәһәр үзендә алып кала алмады. Гөлчәчәк бәхетенә, урман буенда иң яхшы юртаклардан гына торган ат заводы да ачылган иде. Ул шунда эшкә керде. Яшьтән үк ат җене кагылган иде шул кызга. Мин үзем дә атларны бик яратам. Ләкин мин яратам гына. Ат өстендә үсмәгәч, аларның холыкларын белмим, яшүсмер чакта, ат өстеннән мәтәлеп төшеп, аягымны имгәткәннән соң, аларның янына килергә дә куркам.

Вәгъдә иткәнчә, Аккашка тайны бүре суккач, Ярулла абзый ак ат алып кайткан иде. Урманчы өчен бик уңай транспорт та бит: телисең икән, арбага җик, теләсәң, атланып чыгып кит.

Әнә ул ак ат моннан, мин көтү көткән урыннан да күренеп тора. Ярулла абзый атны арканга чыгарган. Гөлчәчәк булмагач, күрәсең, атның күп гомере арканда уза. Гөлчәчәк ничек яраткандыр, чорсыз-холыксыз ат ул. Гөлчәчәк уйлап тапкан Лачын дигән кушаматы да бар әле аның. Тайдан яңа гына ат булып килгән Лачынны алып кайткан көнне без Барый белән Ярулла абзыйның утынын кисә идек. Мотопычкы белән чытыр-пытыр кисәбез, кисәбез дә аннары ярып ук куябыз. Кызлар ярылган каен утыннарын әрдәнәгә өеп тора. Күңелле, рәхәт. Ярулла абзый өйдә юк, күрше колхозга ат сайларга китеп барган. Гөлчирә апа безгә, утын кисүче яшь «кияүләр»гә, өйдә өчпочмак пешерә.

Соңгы утын пүләнен әрдәнәгә куйганда, Ярулла абзый да кайтып керде. Арба артына каеш белән шул Лачынны бәйләгән.

Лачын бик матур иде. Ул әле яшь тә икән. Үзе әкияттәге ак байтал кебек ап-ак, алгы аякларына кара итекләр киерткәндәй: тояктан өстәрәк кап-кара. Кыскасы, кара аяклы ак ат иде Лачын. Моңарчы аның тәртәгә дә кергәне булмаган, ләкин атланып йөрергә өйрәткәннәр инде.

Гөлчәчәкнең сөенүләрен күрсәгез иде шул чакта! Әгәр дә ат куян баласы булса, билләһи, кочагына алып шундук иркәли башлаган булыр иде.

— Җигәргә өйрәтмәбез инде моны. Атланып йөрергә булса шунда,— диде Ярулла абзый.

Атны арбадан ычкындыруга, Барый, егетлек күрсәтергә теләп, сыртына сикереп тә менде. Менүе булды, Лачын артын чөеп тә җибәрде, Барыебыз очып та төште. Әмма Барый ат янында (әтисе Хаҗи абый да атка атланып йөри иде) кайнашып үскән малай, аны алай гына сер бирер димә. Ул җәһәт кенә сикереп торды да тагын атланмакчы булган иде, Гөлчәчәк туктатты.

— Борчыма әле атны, Барый. Юлдан соң бераз ял итсен, хәл алсын. Аңа ияләшергә дә кирәк бит әле,— диде кыз, бер кулы белән атның йөгәненнән тотып, икенчесе белән муеныннан сыйпый-сыйпый.

— Лачын, Лачын, дип исем кушам мин аңа, әти, яме!

Лачын хәл алгач, Гөлчәчәк келәттән ияр алып чыкты.

— Малайларны яратмый ул. Менә хәзер карап тор, Барый, яме.

Ярулла абзый иярне үзе киертте һәм каршы сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп:

— Әүвәл үзем атланып карыйм! — диде дә җиңел генә ат өстенә сикереп менде. Болай гына атландырмый ул. Башта ук ияр салырга кирәк булган. Шулай дип әйттеләр.

Хурлыгыннан җиргә сеңеп беткән Барыйга әлеге сүзләрдән соң янә җан керде. Ишеттегезме дигәндәй, ул әле миңа, әле кызлар ягына карап куйды: «Иярсез атланганым өчен егып төшерде ул мине!» — ди кебек иде аның яктыра башлаган карашы.

Дөрес хәлгә ни әйтерсең, чынлап та шулай икән шул: Ярулла абзыйны тыныч кына әйләндереп килде Лачын. Аннан соң ияргә Гөлчәчәк менеп кунаклады. Атның шул чактагы кыяфәт-кыланышын күрсәгез икән сез! Гомере буе сыртына Гөлчәчәк атланганын гына көткән диярсең, әүвәл ул бер урында тыпырдап, хәтта биеп дип әйтсәң дә була, торды, торды да, аннары Ташсу буеннан искән җил белән куышкан кебек юыртып, юк алай түгел, кияү егетләре кебек кәс-кәс басып атлап китте һәм бармый да, атламый да, ә йөзә кебек. Аның борын тишекләре киңәйде, зур коңгырт күзләрендә кояш нурлары чагылып-чыгылып алды. Ат Гөлчәчәкнеке иде, гомере буе яратачак иде ул аны...

Гөлчәчәк әйләнеп килгәч, аңа ияр дән төшәргә булышкан арада, йөгәнне Барый эләктереп алган иде. Лачын аны да хәтәр-хәвефсез генә әйләндереп килде. Чират миңа җитәчәген сизгән идем. Ләкин үз гомеремдә бер мәртәбә дә атка атланып караганым юк. Мәтәлеп төшәчәгем көн кебек ачык иде. Каян башыма килгәндер: мин чарасызлыктан, пычкы янына килеп:

— Ярулла абый, бу агачларны да кисәседер бит! — дип кычкырдым.

Ярулла абзый тыныч кына:

— Утынга түгел алары,— диде.

Мин аны ишетмәгәнгә салыштым һәм пычкыны да кабызган идем инде. Аның чытыр-пытыр эшләгән тавышы ак атның котын алды, ул Барый кулыннан ычкынып, лапаска таба шылды. Лапасның кайда икәнлеген ничек чамалады диген, бу йортка беренче аяк басуы бит әле!

— Урманчыда агач бетмәгәндер әле, монысы да утынга булыр,— дип, мин, атка атланырга чакыруларыннан котым ботыма төшеп, пычкыны каезланган агачка батырган идем. Ярулла абзый кулымнан килеп тотты да пычкыны сүндерергә кушты. Нишлисең, кушкач, сүндерәсең инде. Әмма кушсалар да атка атлана алмаячагымны яхшы белә идем. Рәхмәт инде Гөлчирә апага, өчпочмаклары пешеп чыккан икән. Ул, тәрәзәне ачып:

— Кулларыгызны юыгыз. Өчпочмакларым суына! — дип кычкырды.

— Дөрес әйтәсең, Гөлчирә апа, дөрес. Өчпочмакны кайнар килеш ашарга кирәк,— дип сөйләнә-сөйләнә, мин беренче булып юынгычка таба атладым.

Бүген котылдым атка атланудан. Ләкин бит әле иртәгә бар, берсекөнгә... Бу нисбәттән нәрсә булса да уйларга, ни булса да кылырга кирәк иде. Шуннан соң мин, инде буй җиткән егет, атта йөрергә өйрәнергә ныклы карар кылдым. Күрше Хәмит абый бер карт алаша җигә. Әүвәл шуңа атланып өйрәнәчәкмен!

Хәмит абый эштән кайткач, алашасын ишегалдында туара да, кәнүшнигә илтә. Мин аның нәкъ шул чагын сагалап тордым һәм беркөнне:

— Хәмит абый, кая үзем илтәм,— дип, аңа каршы сүз әйтергә ирек бирмичә, йөгәненә килеп тотындым.

Ике арада шундыйрак сөйләшү булып алды.

— Оясын беләсеңме соң?

— Табармын, борчылма. Күнних шунда бит! Атландырамы соң ул?

— Атланып караган җук шул. Хәер, нишләп атландырмасын. Юаш хайван ул. Карт бит инде, минем кебек.

Безнең мунча янында узган-барган машина-трактор бәреп китмәсенгә зур таш куелган. Алашаны шул таш янына алып килдем дә атланып карарга исәпләдем. Алаша карт булса да, шактый биек һәм гәүдәгә зур. Корсагы да мичкә кебек бүселгән. Сыртына ике кулым белән ничектер җайсыз гына ябышып, сикереп атланмакчы булган идем, күрәсең, артыграк тырышып ташлаганмын, сикергән уңайга атның икенче ягына — юлдагы пычракка барып төштем. Шөкер, бу хурлыклы хәлемне алашадан бүтән җан иясе күрмәде. Җәһәт кенә сикереп торып, пычракка буялган киемнәргә дә исем китеп тормастан, янә таш өстенә мендем. Бу юлы каударланмадым, каты көчәнмәдем — ат өстенә менеп утырдым. Бер кулым йөгәндә, икенчесе белән атның ялын урап тоттым. Киттек бит, әй! Як-якка чалшаям, ияр булмагач шуа да, әле ярый, корсагы зур мескен алашаның, аның «мичкәсен» бар көчемә аякларым белән кысам. Барабыз шулай. Чак кына ара узуга иялəшә да башладым. Кызык икән ат өстендә, рәхәт.

Кәнүшнигә барып җитәрәк бәләкәй генә тау менәсе әле. Бар курыкканым — алаша атландырган килеш таудан менә алырмы, юкмы? Ирексездән, атның колагына үрелгәнемне сизми дә калдым. Имеш, таудан хут белән менсен өчен, матайның «газын» —ат колагын борырга кирәк. Алашам ачу белән башын чайкап алгач кына исемә килеп, матайда бармаганлыгымны аңладым. Бу гамәлем үземә дә көлке булып тоелды.

Алаша таудан бик җиңел менде. Кызык икән бу, чынлап та. Кызыгын кызык та, тик мәтәлмәсәм генә ярый инде.

Бу юлы мәтәлмәдем тагын.

Минем өйрәнү шул рәвешле көн саен дәвам итте. Хәзер ат өстендә бик ышанычлы йөрим. Хәтта чаптыртып та карыйсым килә. Тик алашам ялкау, күпме генә тарткаласам, чөңгерсәм дә чабарга уйлап та карамый: бер көйгә атлый да атлый. Ә минем юырттырып карыйсым килә. Чөнки Лачын мондый көйгә йөрми бит, баскан урынында да биеп кенә тора.

Атта тәмам өйрәнеп җиткәнче аяк басмадым урманга. Хәмит абыйга да, аның алашасына да бик зур рәхмәт: хәзер мин чын кавалерист кебек. Кулда кылыч, аркада мылтык кына юк.

Гөлчәчәк белән алай еш күрешеп торырга да җай гел чыгып тормый. Ә күрәсе килә, көн саен очрашып сөйләшәсе килә. Узган баруымда (бу юлы Барыйны ияртмәдем, аның белән аралар бозылышкан чак иде) Гөлчәчәкнең кулларын тоту бәхетенә ирештем. Шундый кечкенә, үзләре йомшак һәм кайнар иде ул куллар. Хәтта уч төбем пешкән кебек булды. Кулын гына да тотмадым әле...

Ул көнне без аның белән Кызылъярга чишмә суына бардык. Икәү генә, җәяү генә. Кулларыбызга кечкенә бидоннар тоттык.

Гөлчәчәк сөйләшә дә сөйләшә. Әүвәл нигә бу кыз шулчаклы күп сөйләшә әле, дип аптырап та куйган идем. Икебез генә калудан курыккан булган икән ул! Урман кырыеннан барган юлыбыз, кинәт каерылып, агачлар ышыгына кереп китте. Урманның тәмле исе борыннарны яра. Сулыш алуы ук җиңел, рәхәт. Урман эченнән сузылган олы юл комлы, өстәвенә ул машина-трактор тәгәрмәчләре белән казылып та беткән иде. Кызылъяр чишмәсенә куян сукмагыннан да барып була. Без сукмакка чыктык. Сукмакта тагын да аулаграк. Гөлчәчәк тагын да күбрәк сөйләргә кереште. Мин аның нәрсә турында сөйләгәнен тыңламыйм да бугай. Башымда үз уйларым кайный. Кинәт Гөлчәчәкнең алдына чыгып туктадым да:

— Гөлчәчәк, әйт әле, менә бер шагыйрь усак егете каен кызын үпмәкче була, дип яза. Ничек уйлыйсың, чынлап та гашыйкмы ул аңа? — дидем.

Гөлчәчәк бермәл, йөзенә җитдилек чыгарып, аптырап торды, аннары кинәт көлеп җибәрде.

Чү! Тукта! Ул көлдеме соң? Әллә, әллә инде әнә теге чәчәкләр, янәшәдәге аланда шаулап үскән берсеннән-берсе матур, аллы-гөлле чәчәкләр шулай тирбәнеп, чыңлап куйдымы?!

— Әйе, әйе,— ди Гөлчәчәк көлү аралаш,— усак егете каен кызына үлепләр дә гашыйк ул! Сөя усак егете каен кызын! Шулчаклы көчле итеп сөя ки, синең белән мин аны хәтта күз алдына да китереп карый алмыйбыз, Мөхәммәт!..— ди Гөлчәчәк, кыланчык кызлар тавышы белән.

— Ә мин...— дидем кызның көлүен бүлдереп,— мин моны күз алдына китерәм, Гөлчәчәк!

Әлеге сүзләремнән соң урман кызы көлүеннән дә, кыланчыклануыннан да туктап калды.

— Ничек! Каян?

— Мин... ә мин үзем усак егете!

Кызым бермәл тын гына, шомырт-кара күзләрен зур итеп ачып, бик игътибар белән миңа текәлеп карап торды-торды да кинәт аның иңбашы сикереп куйды, ул янә матур тавышы белән урманны чыңлатып көләргә кереште!

— Мөхәммәт! Син... син бит агач түгел! Усак утын агачына гына ярый бит ул!

Кызның бу сүзләренә бик тә ачуым килде. Көл, көл, әйдә. Утын агачын күрерсең менә хәзер. Кулымдагы бидонны сукмак кырыендагы абагалар арасына ташладым да Гөлчәчәкнең кулларыннан тотып, үземә тартып китердем. Һәм... һәм, кызны кочып алып, аның миңле битеннән үптем!..

Ирennәремнең бик кайнар икәнлеген үзем дә сизгән идем, әллә кызның битен пешердем инде, ул «Ай!» — дип кычкырды да артка чигенде. Кызның йөзе ап-ак булды, болай да зур чем-кара күзләре тагын да зуррак булып ачылдылар, иреннәре, ирен читендәге кара миңе — барысы да дер-дер килә. Мин курка калдым. Һушын җуя язган кыз баланы ничек тә аңына китерергә кирәк иде.

— Гөлчәчәк, Гөлчәчәк, дим! Мин чынлап та усак егете кебек. Ә синең каен кызы буласың киләме, Гөлчәчәк?

Кызның йөзенә алсулык йөгерде, әмма күзләреннән сирпелгән карашы җитди, хәтта куркулы да иде.

Ул минем сорауга җавап бирмәде. Без бер авыз сүз сөйләшмичә генә чишмәгә барып җиттек, аннан су алдык һәм ике телсез кебек ләм-мим аларның өйләренә кире кайттык. Минем күңелгә шөпшә кереп ояларга өлгергән иде инде. Үземне сүгәм: «Усак егете, имеш. Бернинди усак егете дә түгел син, белдеңме. Мокыт! Утын агачы син!»

Капка келәсенә кулы тиюгә, Гөлчәчәгем кинәт ачылып китте (аңламассың бу кызлар холкын!), кояштай балкыган матур күзләрен тутырып бер карады да:

— Әйдә, Мөхәммәт, Лачында йөрибез! — диде.

Утын агачы, ягъни усак булсам да, шундук сиздем: кыз миннән чишмә сукмагындагы наянлыгым өчен үч алмакчы, көлмәкче була! Атта йөри белмәгәнемне теге көнне чамалап алган иде булса кирәк. Мин, батыраеп:

— Әйдә! — дидем һәм күңелемнән Хәмит абыйның карт алашасына тагын бер тапкыр рәхмәт укыдым.

Ишегалдында кеше-кара күренми. Ярулла абзый урманга чыгып киткәндер, Гөлчирә апа авыл кибетенә барам дип калган иде, Гөлйөземнең өйдә икәнлеген беләм, ул чыкмый. Ник чыкмаганлыгын да яхшы беләм: кыз миңа үпкәләгән. Барыйны ияртеп килмәгәнем өчен. Нигә гел-гел мин аны үзем белән ияртеп йөрергә тиеш ди әле. Ияртмәдем шул. Сөйсә, үзе килсен. Мин менә килдем бит әле, юк-бар сәбәп эзләп таптым да йөгереп килеп җиттем. Имеш, Ярулла абзыйга куян тозаклары тагын кирәк түгелме икән? Әти сорарга кушты, имеш. Кушкан ди сиңа әти! Әгәр минем шулай дип хәйләләгәнне ишетсә, колакны борачак әле ул. Һич югында бармак яначак!

Барыйны ияртмәвем бик яхшы булды әле, алайса, чишмә суына без дүртәүләшеп барырга тиеш була идек.

Гөлчәчәк, йөгән киертеп, Лачынны ишегалдына алып чыкты, мин аңа ияр салдым. Белеп торам, урманга чыгуга, Гөлчәчәк: «Атлан!» — диячәк. Ләкин аның кушуын көтеп торырга уйлап та карамадым, ишегалдында ук җиңел генә ат өстенә сикереп мендем. Гөлчәчәк капканы ачты. Күрәм: кыз бик игътибар белән күзәтә, мәтәлеп төшүемне, көлкегә калуымны көтә бугай. Ачуым бер чыкса, мин бик усал малай. Әмма эчемдәгесен кызга сиздермим, аңа күз кысып алам да җай гына тезгенне тартам.

Йа! Чынлап та, Лачын лачын икән шул инде! Бу сиңа лырык-лырык килеп атлаган карт алаша түгел, әнә ничек биеп бара ул. Капкадан чыккач та без шактый юл киттек, тагын Гөлчәчәк янына кире әйләнеп килдек. Рәхәт! Һәм бу рәхәтлектән тиз генә аерылырга исәбем дә юк. Гөлчәчәк, миннән көләргә җыенганына үкенә дә башлагандыр инде. Көл, көл әйдә, көләреңә сәбәп булса инде әгәр... Кеше белән атны чыбыркы берләштерә дигән берәү. Лачын акрын бара. Карт алашага өйрәнгән гадәт буенча, егетләнеп китеп, тезгенне тарткаларга, аякларым белән атның корсагын төяргә керештем. Шулай итүем булды, Лачыным, алгы аякларын югары күтәреп, ачу белән бер кешнәп җибәрде дә томырылып чабып китте. Их! Мин, тиле! Истән чыгарып җибәргәнмен бит! Бу карт алаша түгел, бу — Лачын лабаса!

Лачын ничек тә булса мине сыртыннан сыпырып төшерү максатын куйды булса кирәк, ә мин, чытырдатып, тезген тоткан кулларым белән аның җилдә җилфердәгән ялына да ябыштым.

Хәзер әлеге хәлләр турында сөйләргә түгел, хәтта искә төшерергә дә яратмыйм. Ничек исән-сау калганымны бер үзем генә беләм.

Битемә җылы, юеш нәрсә тигәнгә күзләремне ачып җибәрдем һәм, котым алынып, тиз генә йомдым: бүреме, этме колакларымны, йөзләремне ялый. Ул үзе бертуктаусыз еламсырап шыңшый, борыны белән гәүдәмә төрткәли һәм шул арада җиңнәремнән дә тарта иде. Куркуны җиңеп, күзләрне тагын чак кына ача төшәм. Нинди эт булсын бу! Бүре бит! Дәү башлы, соры күзле чып-чын бүре ләбаса! Бер караганда, Барыйларның урманда адашып калган Пиратларына да охшаган төсле үзе!

Мин тагын аңымны җуйганмын.

Кабат хушыма килгәндә, янымда чырсыз ат (ул агачка бәйләнгән иде) һәм Гөлчәчәк басып торалар иде. Комлы юлда чалкан ятам. Үтереп сул аягым авырта. Тубык турысыннан шартлап сынганмы, әллә тайган-чатнаганмы, шайтан белсен! Әмма авырту бик көчле. Әгәр янымда Гөлчәчәк булмаса, елап җибәрергә дә күп сорап тормас хәлдә идем.

Гөлчәчәк, күземне ачуга шатланып, яныма тезләнде, йомшак, нәни куллары белән битемнән сыпыра, кайнар бармак очлары иреннәремә кагылып-кагылып ала. Авырту басыла төшкәндәй булды. Гөлчәчәккә елмаясым килә. Тик чыраем утын агачы кебек авырту-сызланудан катып

калган. Гөлчәчәк, иелеп, тиз генә минем битемнән үбеп алды. «Бүре ялады бит аны!» — дип, чак кына кычкырып җибәрми калдым. Авырту бетеп китте шикелле. Исән кулым белән Гөлчәчәкне үземә таба тартам. Ул карышмый, ул буйсына. Иреннәр иренгә тиде. Ләкин бу бәхетле рәхәт мизгелләр мизгел генә булды, кинәт ат кешнәп җибәрде. Гөлчәчәк җәһәт кенә аякларына торып басты:

— Кайдадыр бүре йөриме?

Кызның тавышы куркулы. Мин аны юатмыйм. Мин комлы урман юлында чалкан ятам. Урман шаулый, исемнәре дә билгесез әллә нинди кошлар сайрый, чикерткәләр сикерешә, тәмле чәчәк исләре килә. Матур! Һай, матур бит бу дөнья! Әйе, бик матур икән шул!..

Көтүем елга буйларына таралып, болынны тутырган. Сарыклар «пейзаж»ны кетердәтә.

Вакыт тизрәк узсын өчен, көтүдә ничәләп сарык булыр икән дип, тәртипсез таралган малларны санарга азапланам.

Көтүдә сарык башы санап утыру миңа рәхәтлек бирә, шул рәвешле кичәдән бирле кымырҗап торган җаныма тынычлык иңәрдер төсле. Ә кичә нәрсә булды соң ул? Кичәме? Кичә кич урманга киттем. Мәктәптә укыганда, әти алып биргән кызыл матай йөрерлек иде әле. Шуңа атландым да, руленә кучтәнәч салынган сумка асып, туп-туры Ярулла абзыйлар катына элдерттем. Байтактан күрешкән юк. Аннары, авылга кайтыр алдыннан гына, телефоннан Гөлчәчәк белән сөйләшкән идем.

Урманчы йортына үзем белгән кәҗә сукмагыннан гына бармакчы булдым. Матайның шул ягы шәп: сукмактан да яхшы чаба. Таныш урманыма килеп кереп, беркавым баргач, авып китә яздым: әйтерсең моннан зур сугыш узган! Галәмәт зур түгәрәк аланлыкта бер-бер артлы төзеп куелган төрлесе төрле зурлыктагы буралар — өй буралары, мунча буралары. Кем бураткан, нишләп шулчаклы күп? Анысы, анысы, урманны, балачак урманымны тетеп бетергәннәр: аяк атларлык урын юк, аркылы-торкылы усак, каен агачлары, төп башлары аунап ята! Йа Хода! Сугыш кына узмагандыр моннан! Бомба төшкәндер. Урман өстеннән очып узган берәр хәрби самолеттан берәр бомба егылып төшкәндер монда! Кая карама — төп башлары, киселгән нарат агачлары, трактор сытып-изеп узган усак, каеннар! Артларыннан ботаклары да җыештырылмаган. Нәрсә, әллә Ярулла абзый үлгәнме соң? Әти дә, Гөлчәчәк тә ул турыда аны-моны әйтмәделәр бит! Югыйсә ишетелгән булыр иде! Һай Аллакайгынам: элек мичкә ягу өчен коры утынга килә торган идек! Ярулла абзый артыбыздан ук килеп тикшерә иде, янәсе, арттан ботак-чатак калмаганмы, үсеп утырган агачны екмаганбызмы! Кайда икән соң бу Ярулла абзый?!

Минем таныш сукмагым өстендә аркылы-торкылы юан агач ботаклары, киселгән нарат-каен башлары аунап ята. Әле һаман ис-һушымны җыя алмыйча, кире борылдым, урман буйлап сузылган комлы юлга чыктым.

Бу юлның да юл диярлеге калмаган! Танклар узган кебек. Казылып, чокырланып беткән. Әле кайчан гына без — мәктәп балалары — 19 май көнне шушы юлдан Әмир чишмәсендәге аланлыкка пионер туган көнен бәйрәм итәргә бара идек. Кулдагы киндер капчыкта ике-өч телем ипи, утыз өч тиенлек кильки консервасы, әни пешереп салган берничә күкәй. Без бәхетле! Без бәхетле кешеләр. Өстәвенә без бүген консерва ашаячакбыз! Бүген безнең бәйрәм! Барый белән минем арттан ике эт теркелди. Минем этем кечкенә, әмма бик чәңгелдек, усал, Сигнал кушаматлы булыр. Барыйныкы — бүре! Әйе, әйе, әтисе Хаҗи абый күрше мари авылыннан алып кайткан иде. Имеш, Барый сөйләвенчә инде бу, марилар аны бала вакытында урманнан табып алып кайтканнар, шуңа күрә бүрегә охшаган ул, зур башлы. Бәлки, уйласаң, чынлап та, бүре баласы булгандыр әле. Күзләре, борыны, гәүдәсе генә түгел, соры йоннарына хәтле нәкъ чын бүренеке инде менә. Акыллы эт ул. Акыллы икәнлеген күзләре үк әйтеп тора. Барый артыннан ияргән ул үзе, ләкин алар Барый белән дус түгел. Минем Сигнал холкы белән җилбәзәк. Әмма тыңлаучан, өстәвенә цирк эте кебек һөнәрле дә. Аны күрше Заһидулла абый Казан юлында очратып, машинасына салып алып кайткан. Миңа бүләк итте. Чынлап менә, бик һөнәрле эт Сигнал. Әти әйтә, бу эт баласы, циркран качып, Казан юлында адашып йөргәндә очрагандыр әле Заһидулла абыеңа, ди. Сигнал ыргыткан таякны җәһәт кенә кире алып килеп бирә, кыршау аша сикерә, хәтта кулны чәбәкләп торсаң, арт аякларына басып, биегәндәй дә итә. Аның бу һөнәрләреннән Барый көнләшеп үлә иде инде. Чөнки аның Пират кушаматлы бүрегә охшаган эте һөнәр белми. Бик салмак, акрын ул. Тик күзләре акыллы инде менә, адәм күзләре диярсең!

Бу урманның шултиклем таланганын Гөлчәчәк миңа ник сөйләмәде икән соң? Без хәзер, Петербургтан кайтканнан бирле, гел күрешеп торабыз бит.

Мәктәп тәмамлагач, мин Казан сәнгать мәктәбенә барып кердем. Аягым гарип булганга,— теге чакта ат өстеннән егылып төшеп имгәнгән аяк,— хәрби хезмәткә яраксыз диделәр; сизелерлек аксамасам да, тубыктан бөгелеп бетми. Казанда укыганда ук миңа «ак билет» тоттырдылар. Сәнгать мәктәбеннән соң мин, үҗәт һәм үзсүзле малай, Ленинградтагы сәнгать академиясенә — Репин исемендәге югары уку йортына барып керә алдым.

Барый Пиратны кыйный, кулына ни туры килсә, шуның белән бәрә, Сигнал кебек һөнәрләргә өйрәтмәкче була. Ник каһәрлисең аны, дип, гел каршы төшәм. Барый, телгә беткән малай, бер сүз белән генә минем авызны каплый да куя: этнең койрыгын кем күбрәк кисә, ул шуңа тугрылыклырак була, янәмәсе! Була сиңа, бар! Гел алай яманлык белән генә булмый ул! Булмый икән шул! Пират кыенга түзә алмады: бер дә бер көнне, Барыйга ияреп урманга барган җиреннән, кире әйләнеп кайтмады. Тагын кыйнаган булгандыр инде!

Читкәрәк киттем бугай. Нишләтәсең, бүгенгедәй истә бит.

Матай казылган юлдан бара алмагач, кырыйга каердым.

...Сарыкларым, көтүченең үзләренә игътибар итмәвен сизеп, төрлесе-төрле якка чәчелә башлаган. Мин аларны җыярга керештем. Урман ягына борылып карыйсым килми.

Тора-бара Петербургтан кайтулар сирәгәйде. Гөлчәчәк белән йә телефоннан сөйләшәбез, яисә сагыну хатлары язышa идек. Гөлчәчәгемне берәүгә дә алыштырмадым. Группа кызлары: «Однолюб!» — дип кушамат тактылыр.

Академиядә укыган чагында, мин рәсем сәнгатенең серләренә тагын да тирәнрәк төшендем. Шуның өстәвенә тәмәке тартырга өйрәндем, сакал үстереп җибәрдем.

Кичә кич, бөек рәссам кыяфәтендә кызыл матайга атланып булачак кияү-балакай, ягъни мин барганда, Ярулла абый өйдә туры килмәде. Гөлйөзем үзенең ат заводында иде, мин аны эзләп йөрмәдем. Барые килеп эзләсен, дидем. Хәер, кайгысын уртаклашсам буласы икән дә. Мин шул көнне урманнан әйләнеп кайткач, әни яңа хәбәр җиткерде: күптән түгел Гөлйөземнең ике яшьлек малае суга төшкәндәй юкка чыккан. Өй янында ялгыз башы уйнап йөргән җиреннән югалган бала. Эзли-эзли бөтен урманны аркылы-торкылы карап чыкканнар — бала табылмаган. Мин, нигә аны кайтуга әйтмәдең син дә дигәндәй, әнигә үпкәле караш ташладым да, беркавым ишегалдында таптанып йөргәннән соң, Барыйларга сугыласы иттем. Әнисе Хәдичә апа: «Барый районда»,— диде.

Югалган бала Гөлйөземнеке генә түгел, ул Барый малае да ич! Моның шулай икәнлеген бар авыл белә, алар аны үзләре дә яшермиләр. Һәм берни булмагандай бер-берсенә килеп-китеп кунакка да йөрешәләр.

Бергә яшәмәсәләр дә... Хәер, ни генә булмасын, мөнәсәбәтләре барыбер сәер иде. Авыл халкы баштарак чәйнәде, чәйнәде дә, хәзер ияләнде, ризалашты бугай — исләре китми, аерым торалармы, бергәме — авылның анда эше юк. Дөрес булса, Барыйның авыл саен никахсыз хатыннары һәм законсыз балалары бар, ди. Булдыра икән яшь хуҗа!..

Мин түзмәдем, өйгә кире кайтып, кызыл матайны кабыздым да урманга чыгып киттем. Ташсу елгасына таба сузылган комлы юлдан (безнең якта туфрак комлы, көне-төне чиләкләп яңгыр яуганнан соң да, кояшы карап торса, җир өйлә вакытына кибеп бетеп, юлда тузан оча башлый) урманга таба юнәлдем. Көн кичкә авышкан булса да, җәйге көннең кызуы әле сүрелеп өлгермәгән, җылы җил, күлмәк изүе аша җиң очларыннан үтеп кереп, тәнне рәхәт кытыклый. Матай гына булса да, артта машина узган кебек тузан болыты. Каршыма урман ягыннан ак машина килеп чыкты. Дәүләт номерлары урынына алгы тәрәзәсенә транзит кәгазе ябыштырылган. Мин акрынайдым. Тузан туздырып килүче машина да акрынаер, тузанга батырмас дип уйлап, әллә ни читкә дә чыкмадым. Ләкин шаккаттым: ак машина, минем яннан узганда, тагын да кызулады, аптыравымнан авызымны ачып калдым дисәм дөрес булмас, чөнки авызга бер пот тузан кереп тулачак иде. Сәмигулла иде бу! Ул, мокыт, баштанаяк тузанга коендырып китте! Юри эшләде ул моны, мине һәм матайны шул рәвешле мыскыл итәсе, көләсе килде бугай! Мин шып туктадым, чөнки сулап булырлык түгел, авыз-борыным ком белән тулды, чәч-башлар, киемнәр тузанга батты. «Мокыт!» — дип кычкырып калдым аның артыннан, судан чыккан ата каз кебек кагына-кагына. Куып җитеп, машинасыннан сөйрәп төшерәсем һәм тукмап атасым да килгән иде. Тик бу уемнан шундук кире кайттым. Мәктәптә укыганда, ул җылак Сәмигне күп тукмадым инде мин. Әләкче иде ул.

Тузаннан арынгач, мескен матаемны кабыздым, аның утыргычларында да катлам-катлам тузан иде.

Гөлйөзем өйдә иде. Матаемны капка төбендә калдырдым да, шакымый-нитми генә, үз кеше кебек, урман каравылчысының имән ишеген тарттым. Гөлйөзем өйгә кеше керүен сизми калды, ул киемнәрен алыштыра иде. Чалбарын салып урындык артына элгән, ярым шәрә килеш идән уртасында басып тора, кулында халаты, тырыша-тырыша ул аның уң ягын әйләндереп маташа. Мин кире чигендем, тышкы ишек катына ук барып, тамак кырдым. Киен, тизрәк, кеше бар, янәсе. Гөлйөзем «абау!» дип кычкырып, зал ишеген ябып куйды да беркавымнан халатын төймәли-төймәли атылып чыкты.

— Уф Аллам! Кеше куркытып йөрмәсәң!

— Исәнме, Гөлйөзем!

— Исәнме, Мөхәммәт, исәнме. Уз, әйдә.

Үзем дә сизмәстән, чекерәеп, хатынның йөзенә текәлдем: ябыккан, суырылган Гөлйөзем. Бала кайгысы, күрәсең, аны шулай бетәштергән, тагын ни булсын! Әмма Гөлйөзем Гөлйөзем булып калган. Бәхеткә каршы, аның гел янып, яктырып, балкып торган шомырт күзләре сүрелмәгән. Малае хакында сүз кушкач, ул ике сүз белән генә:

— Бүре алып китте Әнвәремне! — дип офтанды да башка бу хакта сөйләшәсе килмәде. Авыр иде аңа, әйтеп-аңлатып бетереп булмастай авыр иде!..

Һай, Гөлйөзем! Тормыш шулай шул ул: тиктомалдан гына гел көтелмәгән яктан күсәк белән китерә дә суга. Сизми дә каласың. Бик бирешмә инде син! Кайгы кешеләрне берләштерә бит ул. Барыең да, никах укытып, сине алып кайтып китәр. Начар малай түгел бит ул, күңеле яхшы аның! Менә күрерсең.

Гөлйөземдә Гөлчәчәк чалымнары бар дисәм, хата сүз булыр: чалымнар гына түгел, игезәкләр бер-берсенә коеп куйгандай охшаган, икесе ике чык тамчысы кебек иде. Элек мин аларны битләрендәге миңнәреннән генә аера идем. Аны күргәч, Гөлчәчәкне сагына башлавымны тойдым. Күптәнге танышының килеп керүе Гөлйөземне дә сөендергән күрәсең. Ул йөгереп барып чәй куйды, өстәл хәстәрли башлады.

— Юк, юк, Гөлйөзем, мәшәкатьләнмә. Мин чәйләр эчеп тормыйм. Синең хәлеңне белешергә генә килгән идем,— дип, ишеккә таба атладым.

— Хәл дип... нәрсәсен белешәсең инде аның. Бер ай була инде.

— Барый килеп керсә дә яхшы булмас.

Гөлйөзем, Барый дигән исемне ишеткәч, кинәт агарып китте, йөзендәге хәсрәт томанын җил куып тараттымыни, хәтта ул көлемсерәп тә куйды һәм:

— Барый кичкырын урманга килергә курка ул! — диде. Хатынның йөзе ачулы.

— Нишләп курыксын! Мылтыгы бар ич аның. Минем кебек матайга атланып та йөрми. Машинасы бар,— дидем Гөлйөземгә каршы.

Әлбәттә, Барыйны яклап әйтүем түгел, сүз булсын дип кенә инде. Кем белә, Барыйны яклап маташуым Гөлйөземгә ошармы, юкмы? Гөлйөзем бу юлы кычкырып ук көлеп җибәрде.

— Мылтык дисең син, Мөхәммәт! Кая мылтык кына! Машинада хәтта граната да йөртә әле ул. Чын менә! Шуның өстенә газовый пистолет! Газовый балончик! Тот та хет бүген ук Чечняга җибәр! Вооруженный да зубов! Чөнки аны инде менә елдан артык күрше мари авылы егетләре сагалап йөри. Анда да бер мари кызына бала ясап киткән бит ул, ата мәче!

Бу хәбәрне инде ишеткән булсам да, Гөлйөземгә кушылып көлмичә түзә алмадым.

— Ну, Барый! Өлгер егет икән!

Без Гөлйөзем белән утырып чәй эчтек. Урман буйларына эңгер-меңгер төшә башлады. Мин кайтырга кузгалдым. Ишекне ачам дип, ишеккә үреләм дигәндә генә,— сизми дә калдым,— Гөлйөзем кинәт муеныма асылынды.

— Кунып кит, Мөхәммәт!

Аның кайнар сулышы битләремне, муенымны пешерде. Мин коелып төштем. Дөресрәге, баскан җиремдә бер каен бүкәненә әйләндем дә калдым, ни кылырга белмәдем.

— Үч аласым килә минем ул Барыйдан. Әүвәл үч алам, аннан соң законный кияүгә чыгам мин аңа!

Ниһаять, миңа да тел керде бугай.

— Гөлйөзем,— дидем пышылдап.— Әйдә, тынычлан әле син!

— Минем Гөлчәчәктән дә үч аласым килә, аңлыйсыңмы, Мөхәммәт!

Монысы һич аңлашылмый иде инде. Барыйдан үч алуын аңлыйм. Чөнки Барыйны үзе ата мәче диде. Ә Гөлчәчәкнең, Гөлчәчәкнең нинди гаебе бар? Игезәк сыңарының?..

— Башта Барый минем арттан йөри башлагач, аның янына чыкмый идем. Гөлчәчәк, этә-төртә, мине Барый янына чыгарга кыстый. Аптырагач, беркөнне үзе чыгып китте. Караңгы

төшкән иде шул. Барый Гөлчәчәкне танымаган. Мин дип уйлаган. Мине көнләштерү өчен икенче көнне дә чыгып китте Гөлчәчәгем. Өченче көнне дә чыгам дигән иде. Чыгармадым, үзем киендем. Хәзер шуңа үкенәм инде. Гөлчәчәк булмаса, Барый белән йөреп китәсе түгел идем. Син, Мөхәммәт, Гөлчәчәк турында начар уйлый күрмә тагы. Ул сине ярата, ул синең белән бәхетле булачагын белә. Барый янына шаяртып кына, көнләштерер өчен генә чыкты ул. Чөнки аны жәлли иде. Аның җавапсыз мәхәббәтен кызгана иде ул. Ә теге вакытта ике чыгуында да мин булып сөйләшеп кергән. Үбәргә үрелгән иде, яңагына чылтыраттым, диде.

Мин телсез калдым. Әлбәттә, бу халәтемне Гөлйөзем яхшы аңлады, ул, минем кулымны тотып, түргә әйдәде. Мин карышмадым. Һаман үз аңымда түгел идем әле. Хәер, Гөлйөземнең соңгы сүзләре томан пәрдәсен бераз ача төшкән, күкрәгемдә гөлт итеп кабынган көнчелек уты, шактый сүрелеп, төтенли генә башлаган иде. «Барый янына шаяртып кына... Мине көнләштерер өчен генә чыкты ул. Капканың эчке ягында нәрсә сөйләшкәннәрен шыпырт кына тыңлап тордым. Барый Гөлчәчәккә: «Гөлйөзем, мин сине үлеп яратам бит!» — дигәнен ишеткәч, түзә алмадым, өченче көнне үзем йөгереп чыгып киттем. Күңелем белән Барыйны кабул итеп бетерә алмасам да. Һай, Гөлчәчәк кенә гаепле! Шул рәвешле кыланмаган булса, ул ата мәчегә борылып та карамаган булыр идем! Минем хәтта Гөлчәчәк кебек аның яңагына да чылтырата алганым юк әле!

Әйе, бу сүзләр мине айнытты, тора-тора көнчелек уты хәтта төтенләми дә башлады, бөтенләй сүнде.

Гөлйөзем мине шаша-шаша үбәргә кереште, күлмәгемне аерып төшерде. Авызымны ачып һәм нишләргә белмичә катып торган арада, өстендәге халатын салып атты. Каршымда бая ялгыш кына күргән яшь шәрә хатын басып тора иде. Аның кайнар куллары, мине, күзле букәнне, караватка төртеп екты. Абайламыйча карават өстендә йоклап яткан кара мәче өстенә барып төшкәнмен икән. Ул, мыраулап кычкырып, идәнгә атылды. Гөлйөзем һаман шашып, кайнарланып үбә, бу вакытта үземнең тәндәге күзәнәкләр дә уянып, хатынны кочакларга батырчылык иткән идем инде. Ничек кенә тырышсам да, хисләр каршында акылымның бәләкәйләнеп, көчсезләнеп калганын тойдым. Үз-үземә ачуым килде. Шул рәвешле үз-үземне әрли-сүгә, орыша-тирги һаман хатынның шәрә тәне буенча кармаландым.

— Гөлчәчәк! Гөлчәчәгем минем!

Авызымнан ялгыш шул исем чыгу булды, Гөлйөземне алыштырып куйдылармыни: ул ялт итеп сикереп торды да, җәһәт кенә өстенә халатын элеп, әмма тыныч, йомшак тавыш белән:

— Гафу ит инде син мине, Мөхәммәт. «Бар, бар кайтып кит!» — диде, идәндә аунап яткан һәм төймәләре кырылган кыска җиңле күлмәгемне өстемә ташлады.

«Ә» димәдем, «җә» димәдем, яңа гына кышкы йокысыннан уянган аю кебек, алпан-тилпән килеп, идән сайгакларын шыгырдата-шыгырдата, ишеккә таба атладым. Кулым тотканы эзләп тапкач, артыма борылып карадым. Гөлйөзем мендәргә капланган да үксеп-үксеп елый иде. Аның иңбашлары калтырый. «Ела, ела! Сиңа елау бик файдалы ул, Гөлйөзем,— дип пышылдадым мин.— Елау җиңеләйтеп җибәрә ул...»

Елга ярына ак «Волга» килеп туктады. Әле яңа, буяулары да йолык-йолык килеп тора. Машинадан Барый килеп чыкты. Авызын ерган. Сагынгандыр, яшьлек дустым бит: Казанда чакта үзем дә юксынам аны. Барый артыннан ук машинадан ике малай да төште, үзебезнең авыл малайлары, бәйрәмчә итеп киенгәннәр, күрәсең, Барый аларны сабантуй мәйданыннан ук утырткандыр.

— Менә сиңа көтүчеләр алып килдем! — ди Барый, ике кулын сузып, миңа таба күрешергә килә-килә.— Даһи башың белән көтү көтеп йөрмәссең бит инде! Ха! Бигрәк кызык килеп чыга икән: бөек художник һәм көтүче! Шул рәвешле тарихка кереп каласың килә, ахры, синең! Ярамый, брат, ярамый, ярамый!

— Нишләп ярамасын,— дим, Барыйның кулларын учларымда кысып.— Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек дигәнме әле!

— Чепуха! Син күптән күтәрелдең инде!

Барый бервакытта да тиктомалдан гына мактый белми иде. Мин аңа сынаулы карашымны ташладым. Барый дустымның «мунчала»сына беркадәр коңгырт төс керә башлаган димме? «Зәңгәр күзләре дә, әрекмән колагы да шул ук, үзгәрмәгәннәр. Хәер, күрешмәгәнебезгә ярты еллап кына бит әле. Узган кайтканында үзен күрмәдем, шоферы районга чаклы илтеп куйган иде куюын.

— Машинаны күлмәк алыштырган кебек алыштырасың син малай, ә! — дим, ак «Волга»га ымлап. Яшьтәшем һәрвакыттагыча тапкыр, җавапсыз кала торганнардан түгел.

— Машина — не роскошь! А средство передвижения!

— Барый, малайларны сабан туеннан аермаска иде бит, ә?

Барый сүз уңаеннан малайларның да күңелен күреп алды:

— Нинди малайлар булсын алар! Быел икесенә бер комбайн бирәм мин аларның! Күрмисеңмени, полный җегетләр бит инде!

Барый түш кесәсеннән шытырдап торган ике йөзәрлек чыгарып малайларга бирде.

— Көтүне шәпләп көтегез, яме! Колхоз печәнлеген таптату обязательно түгел, аңладыгызмы!

Малайларның берсе минем чыбыркыны алды.

— Их, урман буенда рәхәтләнеп йөрергә исәп иде! Ирек бирмәдең бит, брат, ә! — дип, мин дустымның иңбашын шапылдатып алдым.

— Нием калган синң урман буенда! Гөлчәчәгең барыбер кайта алмаган. Апасы авыр хәлдә, ди. Гөлйөземне күрдем.

— Гөлйөзем монда булгач, сиңа рәхәт! — дидем шаяртып.

Кинәт Барыйның йөзе сытылып китте, әмма ул минем моңа игътибар иткәнне сизеп булса кирәк, үзен бик тиз кулга алды, хәтта көчәнеп елмайды да әле.

— Гөлйөзем кая китсен ди ул! Урман буендагы ат заводының башлыгы ул хәзер. Юртаклар үрчетәбез бит туган, юртаклар. Икесе хәтта Франциядән кайтарылган!..

— Аһа, зур эшләр майтарып йөрисең икән әле син.

— Беләсең, ат белән хатын-кызга үлеп гашыйк бит мин!

Барый шаркылдап көлеп җибәрде. Һаман кеше төсле көлә белми икән әле бу, дип уйлап куйдым.

— Ат заводы ерунда ул, брат! Аннан да зуррак эшләр тора әле монда! Алла боерса, тиздән революция ясыйбыз!

— Беләм, беләм, ишеттем инде. Авылны күчерергә йөрисез икән. Халык зар елый. Берәүнең дә күченәсе килми.

Барый җитдиләнеп китте, беркавым дәшми торганнан соң (без машинага кереп утырган идек инде):

— Күчәрләр, брат. Йөгерә-йөгерә күчәрләр! Их, рөхсәт алсаммы!

— Аңламыйм мин, Барый! Авылны тау башына күчереп утырту нигә кирәк соң сиңа, ә?

— Нигә кирәк дисезме? Һи, кирәк, брат, кирәк. Бик кирәк.

— Алайса аңлатып карале?

— Минем бабам егерме бишенче елда тау башындагы авылны үзәнгә күчереп утыртканмы — утырткан. Шул күченү мәшәкате белән халык революцияне генә түгел, хәтта ата-анасын да оныткан.

— Йә, шуннан.

— Шуннанмы? Шуннан, брат, хәзер үзәндәге авылны мин тау башына кире күчерәм инде! Аңладыңмы?

— Бернәрсә дә аңламадым, брат.

Барый иңбашларын сикертеп, миңа таба борылып карады. Ул машинаны кабызган иде, кире сүндерде. Һәм, шуны да аңламыйсыңмы инде дигәндәй, әүвәл беркавым сәерсенеп карап торды.

— Бабай тау башыннан үзәнгә күчергән. Мин кире менгезәм. Минем малай яки онык аны, кирәк тапса, тау башыннан яңадан үзәнгә күчерәчәк!..

Әллә Барый фикерен әйтеп бетерми, әллә үзем аңлап җиткермим инде, карашым һаман сораулы иде әле. Барый, сиңа аңлатканчы дигәндәй, җәһәт кенә машинасын кабызды. Кузгалып киттек. Авыл белән елга арасында комлык бар. Комы бик әйбәт, балчык изгәндә төпкә дә утырмый, мич чыгарырга яраклы, диләр. Комлык турысына җиткәч, Барый дустым машинасын шып туктатты да, тәрәзәдән карап:

— Күрәсеңме, җил елга ягыннан исә. Комны да шул якка, үзе искән тарафка күчерә. Авыл ягыннан искәндә, киресенчә, ул комны шул якка — елгага таба себерә. Мәңге шулай: әле авыл ягына, әле елгага таба. Кыскасы, әле болай, әле тегеләй. Гел хәрәкәттә, гел тудый-судый. Син, тау башына күченүнең халыкка ни файдасы бар, дип сорыйсың. Файдасы турында кем уйлап торган инде аның, брат. Самый главный хәрәкәт булсын! Селкенергә кирәк халыкка, хәрәкәт кирәк. Тормыш гел хәрәкәттән торырга тиеш, брат. Хәтерлисеңме, Һади абый безнең чүбек башларга тырыша-тырыша дөнья философиясен тутырган иде. Ул һаман истә әле минем. Син

хәтерлисеңме Ницшены: «Кем муеннан эшкә чумган, аның нәрсә эшләгәнен уйлап торырга вакыты юк» — дигәнме?

Барый миңа карады. Хәзер аңладыңмы инде, ди кебек иде аның бу карашы. Ә мин барыбер берни аңламадым. Әллә кайчангы һәм әллә кайдагы немец ни әйтмәс!

Түзмәдем, көлеп җибәрдем. Һәм дустымның җилкәсенә кулымны куеп, аны үземә таба тарттым:

— Ну, Барый, әйттең син, малай!

— Мин әйткән сүзләр түгел... «что ценить каждого исключительно как средство для своей собственной цели и не признаешь в других отношениях». Монысы — синең «кешеләр» дигән сүзләреңә җавап, брат!

— Гитлер да Ницше тәгълиматын өйрәнгән һәм аның белән эш иткән булган. Ярый ла, синең бабаң колхоз председателе, брат, бронь эләктереп калган. Минем ике бабам да сугышта үлеп калганнар!!!

Барыйга һәм аның Ницшесына ачуым килә башлаган иде. Бу халәтем сүзләремә дә, йөземә дә чыкты бугай, чөнки ул моны шундук сизеп алды. Дәшмәде, җавап кайтармады, үрелеп, арткы утыргычтан кәгазь тартма алды да аны, ике арага урнаштырып, ачып җибәрде. Мин сул күземнең кырые белән генә тартма эченә карадым: ул аракы, сыра һәм кабымлыклар белән дыңгычлап тулган иде.

— Сабан туе бит бүген, брат! Бәйрәм бүген! Әйдә, берәрне кәгеп алыйк әле шул хөрмәткә!

Минем моннан ярты еллап элек эшләрем бүләккә тәкъдим ителеп тә, бер талантсыз ялагай адәм җиңеп чыкканнан соң, ачудан дөньясына төкерә-төкерә эчеп-буталып алганнан бирле аракы ише нәрсәне авызыма да алганым юк иде. Ул чакта мине Сиринә Самуиловна айныткан иде. Ике эшемне Англиягә күргәзмәгә җибәртергә сөйләшкән булган һәм ун-унбиш көн эчендә без үзебез дә аның белән чит илгә чыгарга тиеш идек. Минем «творческий запой» тәмамланган гына вакыт, үзем салкын көнне дә шабыр тиргә батам, өстәвенә кан басымы уйный, күзләрем куян күзе кебек кызыл. Шул хәлдә мин чит ил паспорты һәм виза артыннан чаптым. Тиз айнытты мине Сиринә Самуиловна! «Рәссамнар һәрвакыт чак кына салмыш һәм сакаллы булырга тиеш» дигән принципларны читкә куеп торырга туры килде. Хәер, салгалап йөрүемә Гөлчәчәк тә каршы иде, ул шул хакта ым кагуга, мин аны тиз хәл иттем. Бүген сабан туе, бүген бәйрәм. Бүген мин туган авылымда, янымда яшьлек дустым һәм фәлсәфәче дустым Барый.

Чак кына кәефләнеп алдык.

— Синең сабан туеңны кем алып бара соң? — дип сорыйм Барыйдан.

— Силсәвит! — ди ул, колбасасын чәйни-чәйни.— Син көтү көтеп ятканда, мин бәйрәм итеп йөрмәм бит инде,— дип тә өсти.

Барый күңелне күрә белә. Хәер, шулай булмаса, җитәкче булып та эшли алмас иде ул.

— Слушай, брат,— диде Барый, рюмкаларга аракы койганнан соң. Миндә синең өчен бик шатлыклы хәбәр бар бит! Бүген таң тишегеннән районга чакырттылар әле. Синең авылда, отпускада икәнлегеңне белгәннәр, дөнья бетереп, Казан эзли сине анда!

Мин, аптырап, Барыйга карадым: «Нигә?».

— «Урман кызы» дигән картинаңа Мәскәү кунагының күзе төшкән. Дөресрәге, бер зур түрә хатынының.

— Кит! Булмаганны! — дип кычкырып җибәрүемне үзем дә сизми калдым, кулымдагы аракы чайкалып, тез башларына түгелде.— Ул картина остаханәдә саклана бит! Аннан соң мин аны берәүгә дә күрсәтергә уйлаганым да, күрсәткәнем дә юк! Сатыла да, бүләк ителә дә торган картина түгел ул!

— Анысы миңа караңгы, брат. Әйдә, конторга киттек. Сиңа Казанга шалтыратырга куштылар. Сезнең ниндидер начальникның замы, Сиринә Самуиловна диме шунда?

Йа! Сиринә Самуиловна мине моннан да эзләп тапкан! Ул чая хатынның миңа мәңге тынгылык бирәсе юк! Димәк, мәскәүлеләрне остаханәмә дә ул алып кергән! Ичмасам, андагы шешәләрне алгалап куйдымы икән соң!

— Бүләк ителә торган картина түгел ул! — дидем мин, Барыйга ачулы караш ташлап. Әйтерсең монда Барый гаепле иде. Югыйсә аның ул картинаны күргәне дә юк бит. Ул минем ничәмә-ничә еллар буена, кырыкмаса-кырык кат сыза-боза, төннәр буе иҗат иткән картинам! Ул Гөлчәчәк өчен!

Әгәр дә минем урманымны шәһәргә алып китә алсаң, сиңа ияреп китәм дип, әллә шаяртып, әллә чын-чынлап әйткән иде бит Гөлчәчәк... Ниһаять, аның урманын рам арасына сыйдыра алдым бугай. Үзенә дә күрсәтергә өлгермәдем. Ашыкмый да идем әле. Чөнки ул көн минем

тормышымда гаять зур вакыйга булачак, ул көнне дистә еллар буе зарыгып көттем, ул мизгелләр ничәмә-ничә еллар җиде төн уртасында төшләремә кереп сөендерә, сөелергә, сөяргә ашкынып торган йөрәгемне өмет утында яшәтә, кыскасы, әгәр шул картинаны иҗат итүне моннан ун ел элек үземә максат итеп куймасам, бәлки, рәссам булып та китмәс идем. Архитектор булган булыр идем, төзүче...

Барыйга боларны сөйләп тә, аңлатып та торасым килми. Хәер, «Урман кызы» дигәч, сизенә торгандыр инде. Аның үзенең дә урман кызы бар бит!

Шулай да конторага барудан баш тартмадым, Сиринә Самуиловнага шалтыратып, эшнең нәрсәдә икәнлеген үземнең ачыклыйсым килә, берочтан минем эшләргә рөхсәтсез кысылып, тыгылып йөргәне өчен үпкәмне дә белдерермен, дип уйладым.

Хәер, рөхсәтсез дип инде... Остаханә ачкычымны аңа үзем биргән идем бит. Кысылып, тыгылып диюем дә урынсызрак бугай. Әгәр Сиринә Самуиловна булмаса, Казандагы якын һәм бик көнче дусларым ук мине, бер тәрәксез авыл малаен, күптән төкереп чүплеккә аткан булырлар иде. Әйе, әйе, үзең дә сизми калачаксың. Терсәк сугышы заманы бу! Кул күтәреп, йодрык йомарлап, моңа сугам әле дип, зурдан кубып сукмыйлар хәзер, терсәк белән генә төртеп алалар. Кем төрткәнен һәм нигә төрткәнен сизми дә каласың. Безнең татарда бу бигрәк тә шулай. Яһүд булса, бер-берсен ничек тә булса йолка, тарта, күтәрә әле. Безнең туганның исә очлы терсәге һәрвакыт һөҗүмгә әзер. Ерак бабайлардан килгән кан безнең тамырларда да ага. Юкса заманасында, тәхет өчен сугыша-сугыша хәлләре бетеп, мескенлеккә төшеп, үзләрен урыслардан тукматырга ирек куярлар идеме соң?.. Шул рәвешле мәңгелек коллыкка төшәргә риза булырлар идеме. Дүрт гасыр буе марҗа итәге астында бит инде бу халык! Яман холкы, терсәк сугышы, бер-берсен сату, сыту, изү һәм көнләшү һаман бетә алмый! Үз бәхетен тәхеттә генә дип уйлаган халык мәңге яктылыкка чыга алмаячак!..

Мин милләтче түгел. Бары тик татарның тарихын яхшы беләм, чын тарихын. Үзем аралашып йөргән язучы дусларым белән без бик еш шул темаларга гәп куертабыз. Язучылар арасында да каткан милләтчеләр юк. Татарның бу хәленә аларның йөрәкләре авырта. Минеке дә авырта, сызлый.

Һай, терсәк сугышы дигән спортның яңа төрен уйлап табып, шуның дөнья чемпионатында катнаштырасы иде безнең татарны! Алтын медаль белән күкрәкләре тулыр иде, билләһи!..

Барый дустымның машинасында барганда, әнә шуларны уйладым мин. Барый да күңелемдәге тойгыларның каршылыклы һәм төссез икәнлеген чамалый бугай. Үзенчә юатмакчы була:

— Балтаң суга төшкән кебек утырма әле, брат, ә! Гөлчәчәгеңне бүләк итәргә кушмыйлар бит. Картинаны син тагын ясыйсың бит аны! Между прочим, бик талантлы художник, диләр сине. Беркөнне телевизорда кич буе мактадылар.

Мин дәшмим. Үземнең талантлы икәнлегемне беләм, шуңа күрә дә дәшмим.

Шалтыраттым. Сиринә Самуиловна өендә дә, эштә дә юк иде. Шуннан соң Барый Казанны үзе җыярга кереште. Аның кешесе урынында иде. Барыйның сөйләшүенә, бигрәк тә мизгел эчендә ялагайлы елмаю катыш курку, каушау чыккан кыяфәтенә караганда, телефонның теге очындагы кеше түрә һәм шактый зур түрә булырга тиеш.

— Хәниф Хатыпыч! Мин идем әле бу, Барый. Байтимердән. Председатель. Колхоздан. Хәниф Хатыпыч! Сабан туена көткән идек Сезне. Кайта алмадыгыз, ахрысы? (Ул берара тын торды. Күрәсең, Казан кешесе нидер әйтә бугай.) Хәниф Хатыпыч! Уразов белән сөйләштем мин. Ул риза, Хәниф Хатыпыч! Яхшы, Хәниф Хатыпыч! Рәхмәт, Хәниф Хатыпыч! Сез әйткәч, тырыштык инде, Хәниф Хатыпыч! Сау булып торыгыз, Хәниф Хатыпыч!

Мин өнсез калдым. Барый телефонын шапылдатып аппаратына куйгач кына аңыма килдем һәм аның изүеннән каптырып алдым:

— Нәрсә дидең син?! Нәрсәгә риза дидең мине! Пред дип тормыйм, тәрәзәңнән очрам бит хәзер үзеңне! — дип, аны җилтерәтергә керешкәнемне сизми дә калдым. Ләкин Барый тыныч иде. Аның баягы ялагайлы елмаюы хәзер чын, дусларча елмаю белән алышынды.

— Туктале, брат. Тынычлан әле. Беләсеңме кем белән сөйләштем мин?

— Беләсем дә килми! Син мине нәрсәгә риза дидең? Картинаны бүләк итәргәме? Менә сезгә картина, менә кукиш, яме!

— Тынычлан әле, дим бит, Мөхәммәт, дустым, брат! Причем монда бүләк итү! Сиринә Самуиловнаң синең керебеткән, үҗәт икәнлегеңне, сине ризалатуның кыен булачагын әйткән булган икән инде Хәниф Хатыпычка. Сатып алабыз, ди. Долларга, брат, долларга! Моңарчы синең төшеңә дә кереп карамаган суммага!

— Кукиш! — дип кабатладым, Барыйның изүләрен ычкындырып.

Барый, минем тарафка кулын селтәп, урыныннан торды да суыткычын ачып өстәл өстенә шешә һәм кабымлык чыгарып утыртты.

— Кызма әле син, брат! Һәм юкка нервыланма да!

— Как-так нервыланмыйм ди мин! Минем картинада синең ни эшең бар!!!

— Мөхәммәт, дим, дустым, аңла инде. Байтимерне тау башына күчерү мәсьәләсен бары тик Хәниф Хатыпыч кына хәл итәчәк! Ул миннән синең белән сөйләшергә попросил. Ышанмасаң, Сиринә Самуиловнадан шалтыратып сора.

Һаман юньләп берни аңлап җиткермәгән идем әле. Кабат Казанны җыярга керештем һәм бу юлы Сиринә Самуиловнаны өендә туры китердем. Мәсьәлә аңлашыла төште. Сиринә Самуиловна Мәскәү кунагы хатынына «Урман кызы»н күрсәткән. Ул аңа бик охшаган, шуның өстәвенә миңа бер бүлмәле фатирымда урнашкан кысан остаханәм урынына икенчесен, үзәктә зур фатир бирергә тиешләр икән. Әгәр «Урман кызы»н бүләк иткән очракта инде...

Мин лып итеп артыма утырдым, Сиринә Самуиловнага Барыйга кычкырган кебек җикеренә алмый идем, әлбәттә. Ак, димәдем, кара, димәдем, телефонны ташладым да Барый өстәлендәге рюмканы кулыма алдым.

— Әйдә, Барый дустым, сабан туе хөрмәтенә берәрне тотып куйыйк әле! Ә картина, кабатлап әйтәм, кукиш аларга! Син дөрес әйтәсең, нигә юкка нервыланам соң әле? Бирмим дигәч, бирмим инде, әйе бит, дустым? Остаханәләре үзләренә булсын!

— Киреләнмә, Мөхәммәт, остаханә дип, күптән хыялланасың бит инде син!

— Элек хыяллансам, менә хәзер бүтән хыялланмыйм инде. Кадалып китсеннәр шунда! Әйдә, эчеп җибәрик әле!

Барый минем белән чәкештерергә үрелде. Ул бераз тынычланып калган һәм мине ризалатачагына да һичшиксез ышана бугай, «мунчала баш»!

— «Написать картину может последний дурак, а вот продавать ее только умный сумеет». Кем әйткән моны, беләсеңме?

— Белмим. Һәм беләсем дә килми!

— Мин дә белмим. Анысы не важно. Но әйткәннәр бит! Һәм дөрес әйткәннәр, брат! Синең турыда әйткәннәр моны, понимаешь!

Мәсьәлә тәмам ачыкланды. Мәскәү түрәсенең хатыны белән тагын ике атнадан Казан сабан туена килергә тиеш икән. Минем «Урман кызы»м шул вакытка бүләк ителергә әзер булырга тиеш ди...

* * *

Бер атналык ялым өзелде. Мин тагын шәһәрдә, Казанда. Таш кала, баш кала. Элек минем бабаларымныкы гына булган шәһәр. Казан... Син хәзер хәтта губерна башы да түгел инде! Синең белән һәрвакыттагыча Мәскәүдән торып, синең белән хәзер Түбән Новгородта — губерна тәхете хәзер шунда — утырып идарә итәрләр. Район үзәге, гап-гади бер райүзәк син хәзер, Казаным!..

Гасыр ахырында чак кына кымшанып куйган идең син, селкенеп алган идең, өстеңдәге тузаннарны кагынгандай иттең дә янә тынып калдың. Йөгән, дөресрәге, тагын авызлык киертелде сиңа, Казан... Ахырзаман җитүе шулмы икән әллә, Казан? Милләт ахырзаманы...

Ачуланма миңа, Казан! Кәеф юк минем бүген. Картинам Мәскәү кунагына кирәк дигәч кенә киреләнеп, ачудан сүгенү бу! Шуңа күрә башыма чүбек кебек кирәксез һәм күңелсез уйлар туган. Тизрәк шагыйрь дусларымны күрергә, чак кына булса да алар белән аралашырга кирәктер. Алар оптимистлар. Алар сиңа борын салындырып утырырга ирек бирми инде...

«Менә безнең Ватан.
Соңгы көне булып сүреләм дә,
өр-яңадан таңы булып атам».

Бу юлларның авторы чыкылдаган мишәр егете. Дустым... мишәрләр белән яһүдләр, өсләренә яңгыр урынына таш яуса да, төшенкелеккә бирелмәсләр. Алардан үрнәк алырга кирәк. Минем тамырларда да ерак бабалардан килгән кыпчак-мишәр каны ага. Өстәвенә нугай бабалар каны. Кыяфәттә нугайлык чалымнары — кысык күзләр, табак бит — канда мишәрлек тантана итә бугай.

Язучылар союзына кагылдым. Анда дусларны туры китерә алмагач, туп-туры Сиринә Самуиловна фатирына юл тоттым.

— Картина язу — һөнәр, ә аларны сату исә зур сәнгать ул, туганым!

Сиринә Самуиловна — минем туган апам кебек иялэнгән кешем — ишектән әнә шундый сүзләр белән каршы алды. Ул өч бүлмәле фатирында үзе генә. Аның өендә еш булам. Зәвыклы хатынның өе дә зәвык белән киендерелгән. Затлылык, зиннәтлек монда. Килгән саен кәефем күтәрелә, күңелнең йомыкый чагы булса, хәзер үк уяна.

Бу ханымга өендә авыз тутырып «Сиринә Самуиловна» дип әйтәсем дә килми, ничектер тел авыр әйләнә. Ләкин «Сиринә» дип кенә дә эндәшеп булмый инде. Ул хөрмәтле, абруйлы, дәрәҗәле сәнгать белгече. Ул миннән ун яшькә өлкәнрәк. Сиринә Самуиловнага кырык тула дип һич кенә дә әйтеп булмый, әлбәттә. Хәтта буй-сынына хәтле кызларныкы кебек. Холкы да җиңел, кыз-кыркынныкыдай чуар-чобар, килделе-киттеле. Аларны еш кына Гөлчәчәк белән янәшә куеп, тикшереп, чагыштырып карыйм: Гөлчәчәк, әлбәттә, яшьрәк. Ул ничектер ачылып җитмәгән чәчкә сыман. Әйтерсең аңа, урман күләгәсендә үсеп утырган бик матур чәчәккә, озак вакыт кояш нурлары төшми торган. Әйтерсең бер генә тамчы, бер генә сыңар якты нур кирәк аңа — ачылып китәчәк тә бар җиһанны гүзәллеккә күмәчәк!..

Ул гүзәллек үзенә җәлеп итеп, мине тилертәчәк, шаштырачак, соклануымнан башымны югалтачакмын! Тик аның бар җиһанны яктыртуын теләмим. Ул минеке, тик минеке генә!..

Усак агачы кебек каткан адәм булмасам да, көнләшәм. Яратып көнләшәм. Көнләшә-көнләшә яратаммы, анысын бер Алла белә!

Әйткәнемчә, мәктәп тәмамлагач, Петербургтагы Репин исемендәге сәнгать академиясенә киттем. Гөлчәчәк,— ул миннән өч яшькә кечерәк,— Казан университетының биология факультетына кереп укыды. Без сирәк очраштык. Ләкин һәр очрашу миңа Петербургтан исән-сау кире әйләнеп кайтырга җитә; оят булса да әйтим: мин Татарстанга әти-әниемне түгел, күбрәк Гөлчәчәкне сагынып кайта идем...

«Урман кызы»н тәмам кылмыйча, Гөлчәчәккә өйләнү хакында авыз ачарга базмадым: яшүсмер чакта куйган максатым, күрәсең, андый-мондый гына түгел, бик җитди, үтә җитди иде. Без сирәк булса да күрешеп торабыз. Гөлчәчәк хат яза, мин күбрәк телефоннан шалтыратам. Соңгы араларда вакыт ягым чамалырак, әлбәттә. Аннан соң егерме сигез яшь хәйран гомер икән шул инде ул. Беркадәр сабырлана да төштем бугай. Кайчак: «Әллә Гөлчәчәкне яратмыйммы икән?» — дип тә уйлап куям. Әйе, әйе, әнә шундый фикер килә башка. Яратсам, Петербургтан кайтуга, өйләнешик дияр идем Гөлчәчәккә. Алай дип әйтмәдем бит! Хәер, Гөлчәчәк бу тәкъдимне әле үзе дә көтми, ул да минем: «Урманыңны шәһәргә алып китәм» — дип, күкрәк кагуымны чынга алган, шуны көтеп яши булса кирәк. Мин дә көтәм. Без икебез дә көтәбез. Инде ул эшем тәмамлану алдында.

Берничә ел элек,— әле очларга ерак иде,— мин «Урман кызы»н Сиринә Самуиловнага күрсәткән идем. Ул аңа бик озак, хәтта чамадан тыш артык озак, әле янына ук килеп, әле артка чигенә-чигенә карап торды. Мин мактау сүзе көткән идем, ә ул дәшмәде, сүз әйтмәде. Киресенчә, йөзе караңгылангандай булды, кара күзләре дымланды, кулыннан яраткан курчагын тартып алган кыз бала кебек йөз-кыяфәтенә үпкәләү галәмәтләре чыкты, турсайды. Әмма, хисләрен йөгәнләргә өлгергән тәҗрибәле ханым, күңелендәгесен тышка чыгармады. Аның бу кыланышына бик тә сәерсенсәм дә, мин сүз катарга, сорау биреп аптыратырга җөрьәт итмәдем, дөресрәге, үзем дә тел белән генә аңлатып бирә алмаслык сәер хәлдә калган идем.

Кыскасы, «Урман кызы» ошамады бугай Сиринә Самуиловнага. Ә хәзер ул бүген шуны зур кунакка бүләк итәргә, хәтта сатарга йөри! Аңлашылмый иде бу!

Сиринә Самуиловна мине кочаклап каршы алды. Ике як битемнән үбеп алып, кулымнан тоткан килеш, залга алып керде. Без икебез йомшак диванның ике читенә чумдык. Сиринә Самуиловна зәңгәрсу юка һәм кыска халат кигән. Диванга утыргач, болай да кыска итәге тагын да өскәрәк күтәрелде. Үзем оялам, уңайсызланам, ул якка карамаска тырышам. Ул шуны сизгән кебек итәкләрен аска тарта, рәтләгәндәй итә. Хәер, бер караганда матур аякларын халат астына яшерәсе дә килми бугай, шулай булмаса, озын халат кигән булыр иде...

Бу хакта мизгел эчендә генә уйлап алам. Кыяфәтем җитди. Мин ачулы, хәтта үпкәле дә.

— Мин ул картинаны сатарга да, бүләк итәргә дә җыенмыйм бит, Сиринә Самуиловна! Әнә бүтәннәрен, пожалуйста!

Сиринә Самуиловнаның матур калын иреннәре дерелдәп куйды. Ләкин ул бик тыныч иде.

— Мәскәү кунагы, дөресрәге, аның хатыны синең нәкъ менә «Урман кызы»ңа кызыкты бит, Мөхәммәт. Башкасы кирәкми аңа. Аңла! Син андый гына картинаны унны, тагын йөзне язырсың әле. Якты, зур остаханәдә!

— Чит кешегә бирә алмыйм мин аны, Сиринә Самуиловна!

— Һе... ә син беләсеңме, кунакның нәкъ шул картинага күзе төшкәч, теге тараканнар нишләделәр?

— Нишләделәр соң?

— Берни эшли алмадылар. Каттылар да калдылар. Көнләшүләреннән хәтта акырып елыйсылары килде!

— Мине тагын күралмаячаклар икән инде.

— Юк. Киресенчә, синең янда алар калтырап торачаклар моннан соң!..

— Юк, Сиринә Самуиловна, хет нәрсә әйтегез, ул картинаны бүген үк күздән югалтам мин! Кешегә бирә алмыйм мин аны...

— Үҗәтләнмә, Мөхәммәт. Дөрес, бик талантлы эшең ул синең. Урман кызыңны да нәкъ җанлы, тере итеп иҗат иткәнсең. Нәрсә, ул кыз рәссамның фантазиясе генә түгелмени. Реаль кызмы әллә ул?

— Беләсез бит инде, Сиринә Самуиловна. Гөлчәчәкне күргәнегез бар.

Сиринә Самуиловна утырган урынында сикереп куйды, шул уңайдан халат итәге өскә менеп китте, матур аяклары, нигә безне моңарчы иреккә чыгармый утырасың дигәндәй, минем карашны үзләренә таба магниттай тарта, суыра, кызыктыра иде. Ләкин бу минутта миндә аяк кайгысы түгел. Минем бар дөньясына, хәтта Сиринә Самуиловнага да ачуым килгән чак. Ишеген шапылдатып ябып чыгып китәргә дә уйлаган идем бер. Ләкин акылым шундук хисләремне суытып өлгерде. Бу ханым, мине, мокыт авыл малаен, колакларымнан тарта-тарта якты дөньяга алып чыккан кешеләр арасына алып кереп, исememне таныттырган изге җанлы кешем! Бу терсәк сугышы заманасында ул көтелмәгән һөҗүмнәрдән касыгымны, бөерләрне, кабыргаларны саклап калган кеше. Шуңа күрә кызуым соңгы дәрәҗәгә җитсә дә, шөкер, үземне тыеп кала алдым. Хәерлегә булсын... Тик... тик хәерлегә булырмы икән соң?.. Күңелемнең бер почмагына авыр тойгы кереп урнашты. Мин ул тойгыдан үземнең тиз генә арына алмаячагымны сиздем.

Сиринә Самуиловна, кинәт нидер исенә төшкәндәй, урыныннан сикереп торды да, кыска халат итәген тезенә таба тарта-йолка, кухнясына чыгып китте. Аннан мин аның газ плитәсенә чәйнек утыртканын һәм савыт-саба шалтыраганын ишеттем, гәүдә-сыным кыйналган эт кебек, уй-хисләрем болганчык, авыр иде. «Кем соң мин? — дип уйладым мин.— Әйе, талантым бар, әйе, кулымнан килә. Нинди илдә яшим мин? Бу сәләтле егет-кызларның кадерен белә торган илме? Һич юк. Киресенчә, соры адәмнәр тантана иткән Рәсәй бит бу! Бу илдә мин кем соң? Әйе, яшь булсам да, дәрәҗәм бар, исемем бар. Талантым булганга шулаймы соң ул? Һич юк. Күкрәк киереп йөргән чамалы һәм талантсызлар буа буарлык бит. Әллә аларның исем-фамилия-псевдонимнары шулай везучий инде?..

Талантымны калкан итеп, ялгыз башым гына максатыма таба олы юлга чыксам әгәр? Барып җитә алырмынмы? Үземә ышанам: барып җитәчәкмен! Тик соңга калып, ун-егерме ел соңга калачакмын мин! Юлымдагы ясалма проблемалар, каршымда махсус төзелгән баррикадалар вакытымны алачак, энергиямне суырачак! Моннан биш ел элек кенә дә мин берни аңламый торган самими яшь рәссам идем. Хәзер тормышның чуар икәнлеген яхшы беләм. «Урман кызы»н тәмам кылгач, шул Дөньяны рәсемгә төшерергә хыяллана идем. Аны ничек башкарачагымны анык кына күзалламасам да, бу теләгем бик көчле иде.

Сиринә Самуиловна мине кухняга чакырды. Ул тиз арада бай гына табын әзерләгән. Йөзе якты, бая җитди карашлары белән миемне бораулаган шомырт күзләре көлә.

— Әйдә, Мөхәммәт, бәйрәм итәбез.

— Нинди бәйрәм? — дим аптырап.— Туган көнегез дә түгел инде?

— Туган көн түгел. Бәлки, туган көндер дә, әйдә, Мөхәммәт, син миңа башка «Сез» дип дәшмә әле. Без дуслар бит. Отчествомны әйтмә. Сиринә диген, бары Сиринә генә!..

Сәерсенеп калдым: ничек «син» инде ул, ничек «Сиринә генә»? Алай әйтергә минем телем әйләнерме? Иялнмәгән, күнекмәгән килеш?

Сиринә Самуиловна, ягъни Сиринә өстәл өстенә коньяк чыгарып утыртты.

— Син авылдан көтү көтеп килгән хөрмәткә бу! Пикассо и пастух! Ха! Кызык бит! Ерак китәчәксең син, Мөхәммәт!

Сиринә Самуиловнага кушылып, көләсе дә иттем. Авыз каткан, ихтыярыма буйсынмый, көлүем ыржаю булып килеп чыкты бугай. Теләгем булмаса да (коньяк кан басымын күтәреп, башны томалаячак иде), тизрәк канны уйнатып җибәреп, Сиринә Самуиловна белән бер дулкынга күчеп сөйләшә алыр өчен, рюмканы кулыма алдым.

— Сезнең... синең исәнлеккә Сиринә... Самуиловна!

Сиринә Самуиловна яңгыравыклы көмеш тавышы белән янә көлә башлады. Минем югалып калуым аңа ошый иде, күрәсең. Аның кинәт көлеп җибәргән тавышына, газ плитәсе янындагы артсыз урындыкта йокымсырап яткан йонлач песие дә башын күтәреп карады. Ни булды, янәсе, нигә шулай көләсез? Минем белән дә уртаклашмыйсыз! Хуҗабикәнең бу песиендә,— кушаматы Фәрештә,— адәм акыллары бар, сөйләшә белмәсә дә соры күзләренә туры карап аңлашып буладыр кебек иде. Сиринә Самуиловнаның «йонлачы» мине үз итә, килеп керүгә, сырпаланырга, аякка чорналырга керешә торган иде. Бу юлы да мине күргәч, ялт итеп урындыгыннан сикереп төште дә алдыма менеп утырды. Аның башыннан сыйпап куйдым.

— Минем Фәрештәм үлеп гашыйк инде сиңа, Мөхәммәт.

Телем чишелә башлап, кәеф тә башка дулкынга күчкән иде, тапкыр сүз әйтәсем килеп китте:

— Мине песиләр генә ярата бугай.

Сиринә Самуиловна иренена тидергән рюмкасын читкә этәрде, күз карашы янә бораулый башлады.

— Ә урман кызы?

— Урман кызымы?.. Әгәр дә мәгәр картинамнан колак каксам, ул миңа сәлам дә бирмәячәк!

Җавабым Сиринә Самуиловнаны шулчаклы өтәр дип һич тә уйламаган идем, ул хәтта утырган урындыгыннан сикереп торды.

— Чынлап та шулай дип уйлыйсыңмы?

— Уйлыйм. Нигә?

— Алайса, ул синең бик җиңел акыллы нәмәрсә икән! Җиңел акыллы хатын-кыз ирләрне бәхетсез итә!

Сиринә Самуиловна бу сүзләрне сөенә-сөенә әйтте. Әйтерсең Гөлчәчәк, чынлап та, җиңел акыллы кыз, гүя мин бәхетсез булачакмын һәм остазым шуңа куана иде.

— Җиңел акыллы булса, егерме бишкә чаклы мине көтеп утырмас иде! — дидем, тавышыма кырыслык, кыяфәтемә төксе сурәт чыгарырга тырышып.

— Ярый. Кеше тикшереп утырмыйк! Синең өчен күтәрик әле, Мөхәммәт! Синең зур киләчәгең өчен!

— Сез булмасагыз, минем киләчәк зур булмаячак! — дип җавап бирдем кыланыбрак. Чөнки Сиринә Самуиловнаны картина турында сөйләшүдән, Гөлчәчәк хакындагы сүзләрдән читкә алып китәсем килә иде.

— Чынлап та шулай уйлыйсыңмы?

— Уйлыйм, Сиринә Самуиловна, уйлыйм.

Хатын, кара күзләрен тутырып, беравык миңа карап торды да рюмкасын янә иреннәренә китерде.

— Рәхмәт, Мөхәммәт! Тик үзең дә талантлы егет. Үҗәтлегеңне, кирелегеңне генә җиңсәк менә,— дип көлде ул һәм бу юлы рюмкасын кире куймады.

Иртәгесен кара махмырдан уянып китеп, байтак вакыт үземнең кайдалыгымны аңышмыйча яттым. Тубал булган башны чак кына күтәрә төшеп, каршы стена буендагы кәнәфи-караватта тынсыз йоклап яткан Сиринә Самуиловнаны күргәч кенә хәтер күзәнәкләре хәрәкәткә килеп уяна башлады шикелле. Димәк, монда кунып калганмын. Сиринә Самуиловна (аның өстенә япкан юрган идәнгә төшкән, ул эчке күлмәктән бөгәрләнеп ята иде). Май урларга җыенган карак песи кебек, башны чак кына күтәрдем дә, сулыш алырга да куркып, Сиринә Самуиловнаның ярым ялангач гәүдәсенә карап өнсез калдым. Күңел ничектер кытыкланып, кымырҗап куйды.

Йонлач песи, уянганымны сизеп булса кирәк, әллә кайдан гына килеп чыкты да, яныма менеп, күкрәгемә сыенды. Аның мыр-мыр иткән тавышы ачуымны китерде, песине идәнгә төртеп төшердем; бу хәлгә аптыраган песием, идән уртасына утырды да елаган тавыш белән «мияу» дип куйды. Үпкәләгән иде ул... аннары, сыртларын дугаландырып, бер киерелде дә ярым шәрә хуҗабикәсе янына менеп ятты.

Беркавым аларга карап яттым, яттым да песи кебек сак кына юыну бүлмәсенә атладым. «Моннан соң чынлап та «Сиринә» дип кенә йөрермен мин сине, мөгаен»,— дип тә уйлап куйдым әле...

## Мөхәммәтнең беренче мәхәббәте

Мөхәммәт үзенең Мөштәри урамындагы бер бүлмәле фатир-остаханәсенә кайтып кергәндә, төш вакыты җитеп килә иде. Бүген балалар киләчәк. Ул үз остаханәсендә «Балалар сәнгать студиясе» ачып, рәсем дәресләре бирә, укучылар киләсе көнне-сәгатьне һәрвакыт түземсезләнеп көтә. Әлеге эше буйдак егеткә зур шөгыль булып, шулар белән уздырган минутларын иң бәхетле мизгелләр дип исәпли. Балалар килергә иртәрәк әле. Ишегенә язу кыстырып киткәннәр. Мөхәммәт буш путевка бланкасы артына язылган кылдый-былдый язуны күрүгә, көлемсерәп куйды: Барый килгән. Аның язуын йөз кешенеке арасыннан да танып алыр иде Мөхәммәт. Болай ямьсез итеп бары тик Барый гына яза ала. Шул язуы өчен мәктәптә укыганда да гел әрләнә, сүгелә торган иде ул. Барлык фәннәрне дә су урынына эчә, әйбәт укый, алдынгылардан санала, әмма язуы юк инде, дәфтәр битләре өстеннән бер көтү таракан йөгерешеп узган кебек. Язуының ниндилеге кешенең холкын билгели, диләр. Имеш, язуына карап, адәм баласының холкын әйтеп биреп була. Дөрестер бу, чөнки Барыйның холкы, чыннан да, кылдый-былдый, аның бүген кичтән нәрсә уйлап, иртәгесен ни кылачагын берәү дә алдан белә алмый. Шуңа күрә аның колхоздагы нарядны да кичтән биргәне юк, җәйме ул, кышмы — барыбер: Барый нарядка кешеләрне һәрвакыт иртән, таң тишегеннән җыя.

«Тагын картина турында авыз суы чайкарга килгәндер инде»,— дип уйлады Мөхәммәт һәм шулчак аның иртәдән бирле көзге томан сарып алгандай тоныкланып торган башы кисәк ачылып киткәндәй булды, ул кызу-кызу ванна бүлмәсенә керде, әүвәл җылы, аннары салкын су астында, пырхылдый-пырхылдый, бик озак басып торды.

Барый кичкырын сугылырмын, дигән. Кибеткә чыгып керергә кирәк.

Аның өендә ашарга пешереп ашаганы да юк. Күп вакыт янәшә-тирәдәге ашханәләргә йөри, өендә исә такы-токы белән чәй генә эчкәли.

Авылдашы сүзендә торды: кичке якта ишек кыңгыравына бастылар. Мөхәммәт, ишек артындагы кешенең Барый булуына тәмам ышанган хәлдә, «Кем бар?» дип тә сорамады, күз-тишектән дә карамады, шундук ишеген ачты. Һәм ачты да артына авып китә язды: бусагада Барый да түгел, башка дусты да түгел... авылдашы, элеккеге сыйныфташ кызы, күптән түгел генә яңа машина алган Сәмигулланың хатыны Рәзифә басып тора! Авыл хатынына иннек-кершән дә артык мул килешми, ә бу артыгын тырышып ташлап бизәнгән, үзе елмайгандай итә, үзе, күренеп тора, бик каушаган да. Мөхәммәт «Рәзифә!» диде дә авызын ачып катып калды. Аның аптырау-каушавы, киресенчә, хатынга кыюлык өстәп җибәрде булса кирәк, баягы оялчан күзләре янып, ялкынланып алдылар. «Таныдың инде, рәхмәт! Мин инде танымассың да дип уйлаган идем»,— диде хатын. Тел-тегерманенең хәрәкәткә килүе янә кыюлык өстәде бугай хатынга, ул, бер адым арткарак чигеп, ике адым алга атлады, Мөхәммәтнең алдына ук килеп басты. «Кертәсеңдер бит инде!». Мөхәммәт, ялт кына кырыйга тайпылып, хатынга юл бирде, хатынның җилкәсе аша тагын кемнедер эзләп баскычка күз ташлады. Үзенең авызы һаман ачык иде әле.

«Йә, кайда узыйм соң? Әллә кертәсең дә килми инде авылдашыңны... Класстташыңны һәм...»

«Һәм! Нәрсә «һәм»?..» — дигән уй мизгел эчендә Мөхәммәтнең инде кыймылдый-хәрәкәтләнә башлаган акыл шәрифләрен чеметеп узды, ул, тиз арада ис-һушын җыеп өлгереп, хатынны түргә узарга кушты, аның артыннан ишекне ябып, бермәл бикләргәме, юкмы дигәндәй, тоткадан кулын алмый торды һәм аннары уйламастан шартлатып йозакны борды.

Чыннан да, алар Рәзифә белән классташлар, алай гына да түгел, ун ел буе бер парта артында утырдылар. Рәзифә аңа математикадан бирелгән өй эшләрен күчертә — Мөхәммәтнең хәтере яңарды: математиканы су урынына эчкән кыз моның өчен мәктәпкә махсус гел алдан килә, кыңгырауга чаклы аның дәфтәрендәге катлаулы мәсьәләләрнең чишелеше Мөхәммәтнең дәфтәрендә урын алганын түземлек белән көтә. Малай исә, үз чиратында, партадаш кызына әүвәл рәсем ясарга булыша, аннары үсә төшкәч, аның шигырь белән тулган калын дәфтәрен бизәкли-чуклый иде.

Рәзифә кыска итәкле, ачык изүле (авыл хатынына мондый фасонлы кием ятышлы түгел, дибез, гадәттә) юка күлмәк киеп, чәчен ясаттырган һәм өстәвенә тәмле хушбуй сөртенгән. Моны һич кенә дә авылда такта ручы Сәмигулла хатыны димәссең! Хәер, ул авылда яшәсә дә, таң белән торып, фермага сыер саварга йөрмәгәнен белә иде аның Мөхәммәт: Рәзифә колхоз кәнсәләрендә бухгалтериядә эшли. Барыйның уң кулларыннан санала. Өстәвенә алар чыбык очы туганнар да бугай әле.

Рәзифәнең чәче каре фасонында киселгән һәм бу егерме сигез яшьлек хатынның берничә елын артка чигергән. Кыз чактагы сипкелләре һаман сакланган икән әле. Хәер, аны сипкелле дип тә әйтеп булмый: канәфер төсендәге ул мөлаем төрткеләр бик текәлеп карамасаң, күзгә дә чалыныырлык түгел, ләкин аны сипкелсез дип тә әйтеп булмый иде. Коңгырт зур күзләрен ул әле зур итеп ача, әле күрә карачы кешедәй, тәмам кысып бетерә.

Рәзифәнең кыяфәте килешле, бар җире дә килгән иде. Инде бер бала табуга карамастан, әллә шушы рәвешле бизәнү-ясанулары һәм яшьләрчә киенүе хатыннан егерме яшьлек кыз-хатын әвәләгән дә куйган.

Рәзифә залдагы диванга кереп урнашты, бер аягын икенчесенә атландырды. Ир-ат дурак түгел бит: хатын матур аяклары белән Мөхәммәтне ымсындырырга тели иде булса кирәк. Бәлки аңа шулай утыруы җайлырактыр? Үзенең ашыгыч нәтиҗә чыгаруын тойган Мөхәммәтнең колак очларына ут капты.

Хуҗа кешенең әле һаман аптырабрак утыруын күреп, хатын беренче сүзне үзе башлады:

— Сиңа йомышларым бар иде, Мөхәммәт. Шуңа дип килдем. Мин Казанда, бухгалтерлык курсларында бер атна булам әле. Иртәгә, дүшәмбедән башлана,— дип, мәсьәләнең пәрдәсен чак кына ача төште.

Рәзифә үзе белән төрле күчтәнәч-җимешләр күтәреп алып килгән иде, Мөхәммәт, җәһәт кенә кухняга чыгып, чәй куярга уйлады. Бәхеткә күрә, суыткычында шампан шәрабы да бар. Нинди генә йомыш белән килсә дә, ул, үз дәрәҗәсен саклап, авылдашы, классташын сыйлап җибәрә алачак. Кухняга чыккач, беренче уйлаган нәрсәсе шул булды буйдак егетнең.

Кайнап чыгуын борынын сызгыртып хәбәр итә торган чәйнегенә краннан су агызды, газга ут элдерергә дип, тәрәзә төбендә яткан шырпыны табып алды. Аның кабы юешләнгән, эчендәге шырпылары дымлы иде. Өендәге бердәнбер шырпысы бу аның. Шуңа күрә буйдак егетнең әлеге хәлгә кәефе китеп, беркавым аптырап торды да, аннары, бәлкем, кабынырсың әле дигәндәй, шырпыны сызып җибәрде. Ни гаҗәп: юеш капка ышкылган дымлы күкерт гөлт итеп янып китте, газга ут элдергәнче сүнмәде.

Ул зал якка чыкканда, Рәзифә, тез өстенә калын дәфтәр салып, бармак очларын иреннәренә тидереп юешли-юешли, шуны актарып утыра, Мөхәммәтне күргәч, дәфтәрен кулына тоткан килеш, урыныннан торып басты, икенче буш кулы белән кыска итәкләрен тарткалап-рәтләп:

— Синең вакытыңны аламдыр инде мин, Мөхәммәт? — дип куйды.

— Юк, нишләп? Утыр әле, Рәзифә!

Мөхәммәт үзе дә диванның икенче очына килеп урнашты.

— Утыр инде, утыр, тартынма!

Хатын янә диван кырыена чүмәште, бу юлы аякларын бер-берсенә атландырмады, әмма утыргач, бик тырышып, күлмәк итәген ачык тез башларына тартты. Мөхәммәт шунда гына игътибар итте: хатын бу күлмәген авылдан ук киеп килмәгән, шәһәрдә генә алган һәм кибеттә үк киеп, туп-туры аның янына килгән; күлмәкнең кибет тамгасы да өзелмәгән, ул артта, муен турысында асылынып тора иде. Шуны күргәч, Мөхәммәтнең көләсе килеп китте, әүвәл, үрелеп, ул тамганы үзе тартып алмакчы иде, әллә уңайсызланды, әллә хатынны оялтырмын дип курыкты — дәшмәде.

— Мөхәммәт, мин синең вакытыңны озак алмам. Ачуланма. Менә сиңа шушы дәфтәрне генә тапшырмакчы идем. Редакциягә иде ул.

— Нинди ачулану ди ул, Рәзифә. Ташла әле шундый сүзләреңне, зинһар!

— Йә, нинди дәфтәр ул? — дип, Мөхәммәт аңа таба кулын сузды. Ләкин Рәзифә дәфтәрен аңа бирергә ашыкмады.

— Шигырьләр монда. Үзем язган. Телисеңме, берәрсен укып китәм? Вакытым бар, дисең ич?

— Бик рәхәтләнеп тыңлыйм, Рәзифә. Хәзер чәй дә кайнап чыга. Классташны кунак итмичә җибәреп булмас,— дип, Мөхәммәт диванга тагын да җайлабрак урнашты.

Рәзифәнең шигырьләр белән шыплап тулган калын дәфтәрләрен төрлечә бизәкләгәне исенә төште аның. Әле дә истә калган, бәлкем, шул вакытта ул ныклап игътибар ителмәгәндер: ул шигырьләрне кемнән булса да күчереп язган дип уйлый иде Мөхәммәт. Баксаң, янәшәсендәге математик кыз шигырьләрне үзе иҗат иткән икән! Югыйсә үз-үзен тотышы яки холкы белән дипме, Рәзифә бер дә шигырь яза торган кыз балага охшамаган: ул йә елак, йә бар дөньяга ачуы килгәндәй үпкәле, төксе кыяфәтле иде. Баксаң, кыз баланың күңелендә ниләр генә кайнамаган икән!

Әнә ул бик бирелеп, дөньясын онытып, аңа үзе язган шигырьләрен укырга җыена. Сәер дә, кызык та.

Син шаян күрше малай,
Мин елак бер кыз идем.
Бер партада без утырдык.
Чәчләремнән тарттың, шаярттың.
Ә мин,

Ә мин елаган булдым.
Син рәсемче малай идең,
Бик зур иде хыялың.
Тик мине сурәтләргә
Җитмәде шул буявың.

Син хәзер ерак киттең,
Мин дә елак кыз түгел.
Янәшәңдә булмасам да,
Гел синең янда күңел.

Пумалаңны чылат әле,
Минем күз яшьләремә.
Рәсем генә түгел, үзем итеп
Төшер әле күңел дәфтәреңә!..

Шигырьнең шактый кытыршы икәнлеген шундук тойды Мөхәммәт. Юк, башка кеше укыса, шулай кытыршы-мытыршы тоелган булыр иде әлеге такмак-шигырь. Шигырьдән дә бигрәк, Рәзифәнең укуы, һәр юлын йөрәге, күңеле аша уздыруы таң калдырды Мөхәммәтне!

Син шаян күрше малай,
Мин елак бер кыз идем...

Әлеге гап-гади генә сүзләр тезмәсен ул шундый итеп әйтте ки: Мөхәммәт эсселе-суыклы булып китте. Әйтерсең аны мизгел эчендә мәктәп елларына кире алып кайтып утырттылар! Гап-гади сүзләр югыйсә. Тик... ләкин аларны Рәзифә әйтә бит! Аның классташ кызы Рәзифә! Һәм ул сүзләрне Мөхәммәткә укый! Әллә нәкъ менә шуның өчен, шулай булганы өчен генә тәэсирлеме соң ул сүзләр?!

Йа Хода! Бу дөньяда балачакка кайтып килүдән дә ләззәтлерәк нәрсә юктыр! Утызга якынлашып килүче ир-атның, буйдак егетнең, тагын бер кат яшүсмер чагында «яшәп» алуы дисәк тә була бу халәтне. Әлбәттә, әлеге аралар берничә дистә еллар белән исәпләнми исәпләнүен. Нибарысы түп-түгәрәк ун еллап булыр. Шулай да һәр үткән көн, яшәгән гомер, вакыт үлчәменә дә карамастан, барыбер хатирә инде ул. Әгәр дә ул матур булса, бигрәк тә истә кала, аны искә төшерү бик тә ләззәтле.

Урманнарга кереп адаштың да
Кире чыгар юлың тапмадың.
Мин дә сине йола алмадым,
Алдандың син, егет, алдандың!..

Нинди алдану соң ул? Кем турында, нинди егет хакында яза Рәзифә?

Бу сорауны Рәзифәнең үзенә бирергә уңайсыз иде. Әле алай гына да түгел, наданлык, шыр наданлык билгесе булачак иде мондый сорау белән аптырау. Чөнки ул үзе дә иҗат кешесе бит: әдәбият-сәнгать әсәрләрендәге геройларның прототиплары булса да, аларда барыбер нindiдер кеше төгәл рәвештә үк сурәтләнә алмый, җыелма образ, бу очракта исә аның «егете» шигъри образ буларак аңлашылырга тиештер...

Мөхәммәт шулай дип уйлап бетермәде, Рәзифә үзе, капылт кына зур күзләрен тутырып, аңа күтәрелеп карады да:

— Сүзнең кем хакында барганлыгын беләсең киләме? —дип куйды.

Мөхәммәт көлемсерәде, шулай да әгәр Рәзифә атарга әзер икән, ул әлеге образның кем икәнлеге турында беләсе килгәнлеген аңлатып, баш какты.

— Синең турында...

Мөхәммәт утырган урынында кыймылдап куйды.

— Ничек? Минем урманда адашканым юк бит?

— Адашкансың шул. Һәм менә син аны туры мәгънәсендә аңлыйсың. Адашу бу очракта күчерелмә мәгънә. Урманы исә төгәл, дөрес.

— Мин барыбер аңлап җиткермәдем, Рәзифә?

Кинәт хатын, кытыгы килгән кешедәй, көләргә кереште. Мөхәммәт күрә, сизә: бу хатын-кызның бармак күрсәткәннән генә көлүенә һич тә охшамаган. Бу көлү ничектер сәер көлү, ачынган, бәргәләнгән җанның көлүе иде. Һәм бу көлүне тиздән хатын-кызның тагын бер гамәле: чәчләрне йолка-йолка елау галәмәте алыштырырга да бик мөмкин икәнлеген тойды егет. Дөрестән дә, беркавымнан шулай булды: хатын, такмаклый-такмаклый, еларга кереште:

— Син гомер буе аңламадың инде. Аңламаганга салыштың! Без синең белән ун ел буе бер партада утырдык. Күпме генә теләсәм дә, син мине күрмәдең, белмәдең! Шул кыргый урман кызың янына чыгып чаптың! Хәзер дә шуның үзеңә кияүгә чыкканын көтеп, өйләнмичә йөрисең! Сукыр син! Кеше белән кешене аера белмисең!

Әнә шундыйрак сүзләр сипте Рәзифә күз яшьләре аша.

Мөхәммәт катып калган иде. Әйе, әйе, ул ни әйтергә, нәрсә дип дә юатырга белмәде ир хатынын! Рәзифә алдында аның гаебе юк бит! Ярый, булсын да ди, тугызынчыдамы икән, унынчы класста укыгандамы — ул аны бер-ике мәртәбә озата барды. Очраклы рәвештә клубтан икесе бергә чыкканнар иде. Рәзифә үзем генә кайтырга куркам дигәч, капка төпләренә кадәр бардылар. Икенче көнне: «Мөхәммәт Рәзифә белән йөри икән»,— дигән сүз чыкты. Икенче көнне мәктәпкә килгәч, аның парта утыргычына кадак какканнар иде. Өченче көнне парта өстенә язу карасы түгеп киттеләр. Шул көнне мәктәптән кайтышлый, юлда ул классташы Сәмигулла белән канга-кан сугышты. Инде хәтерләми дә, тегесе, мыскыл итеп, ниндидер сүз әйтте бугай. Юл тузанында ауный-ауный чәкәләшкән ике этәчне классташлары Барый килеп аралады. Истә калганнар әнә шулар гына.

Әлбәттә, әүвәл Мөхәммәт Рәзифәгә гашыйк та булган шикелле иде. Әмма Гөлчәчәк белән чираттагы бер очрашу-күрешү үк әлеге хисне шундук кысрыклап чыгарды.

Мөхәммәт бу хакта оныткан да иде инде. Рәзифә исә җитди кабул иткән булган икән ләбаса!

Ул, үзен аның алдында гаепле итеп сизгәндәй булды һәм сулкылдый-сулкылдый чын күз яшьләре белән елаган хатын чынлап торып кызганыч иде. Мөхәммәт Рәзифә янына күчеп утырды, кулын иңенә салып юатырга теләде. Хатын кискән агачтай аның алдына авып төште һәм аннары, җәһәт кенә күтәрелеп, муеныннан кочты.

— Мөхәммәт, мин аңлыйм, барсы да узды, артта калды инде. Тик минем синнән бер бала табасым килә. Минем малаем бар инде. Җиде яшьтә. Икенчесенең синнән булуын телим! Миңа боларны әйтүе бер дә җиңел түгел. Тик нишлим?.. Беләм, аңлыйм. Минем поезд күптән узып китте инде. Зинһар, каршы килмә. Ичмасам, гомерем буе синең балаң дип, шуның белән үземне юатып, шушы язмышым белән килешеп яшәрмен. Каршы килмә, Мөхәммәт!

Буйдак егет хатынның кулларыннан араланырга тырыша-тырыша, аны акылына китермәкче булды.

— Ни сөйлисең син, Рәзифә! Сәмигуллаң бар бит синең! Әле генә яңа машина алып кайтты. Сине ярата. Тормышың начар түгел бит синең, Рәзифә!

Хатын елавыннан шып туктады, әмма кулларын ычкындырмады.

— Тормышым авыр түгел. Ирем акча таба. Алма кебек малай үстерәбез. Иртәнге дүрттән торып фермага сыер саварга да йөрмим. Эшем чиста. Үзем сайлаган һөнәрем бар, Мөхәммәт. Син дөрес әйтәсең! Ләкин! Ләкин җанымдагы бушлыкны ни белән тутырыйм соң мин, Мөхәммәт! Яратып чыкмадым бит мин кияүгә. Аптыраганнан, карт кыз булып утырып калудан куркып кына чыктым. Сине кыргый Гөлчәчәгеңнән аерып, аралап алмаслыгымны белгәч кенә. Кирәкми миңа Сәмигулланың шкаф тулы затлы күлмәкләре, кыйммәтле туннары! Кадалып китсен шул чүпрәкләре белән! Мәхәббәткә сусадым мин, бик сусадым, Мөхәммәт!

— Тынычлан әле, Рәзифә. Тормышның бөтенлеге хатын-кыз өчен зур бәхет бит инде ул: һәрхәлдә, мин шулай дип уйлыйм!

— Һай, Мөхәммәт, барын да аңламыйсың икән әле син! Шуның гырылдавына хәтле сөймим бит мин, беләсең килсә!

Хатын янә еларга кереште.

— Бәхетсез хатын мин, Мөхәммәт. Кыйммәтле туннарга, затлы күлмәкләргә төренгән бәхетсез, җансыз курчак кебек итеп хис итәм мин үземне! Ичмасам, синнән бала табып, гомерем буе шуның белән юанып яшәрмен дип хыялланган идем!..

Хатын капылт кына кулларын ычкындырып, диваннан торып басты да, чәч-башын төзәткәли-төзәткәли, ишеге ачык торган ванна бүлмәсенә кереп бикләнде, аннан шыпырдап су аккан тавыш ишетелде.

Мөхәммәт әле һаман ис-һушын җыеп өлгермәгән, әле һаман диван почмагында өнсез утыра иде. Су тавышы аны кинәт айнытып җибәргәндәй булды. Ул урыныннан торырга теләп талпынды. Ләкин диван магнитлы кебек, җибәрми, хәер, дөресрәге, күңелендәге авыр таш шулай басып тора сыман иде аны.

Рәзифә юыну бүлмәсеннән бөтенләй икенче кеше булып чыкты. Тынычланган, үз-үзен кулга алган хатын. Әйтерсең аны алмаштырып куйганнар, хәтта сүзләренә кадәр суык йөгергән:

— Мин сиңа бая укыган шигырьләр унынчы класста укыганда язылган иде инде. Пешеп җитмәгән алар, чиле-пешле дип әйтсәң дә була. Ә менә болары... болары яңалары,— дип, ул сумкасыннан баягысы кебек үк калын яшел тышлы дәфтәр чыгарды.— Редакциягә тапшыра алмассыңмы? Синең танышларың күптер? Мин беркемне белмим.

Мөхәммәт яшел тышлы дәфтәрне алып көзге янәшәсендәге тумбочка өстенә куйды.

— Тапшырам, әлбәттә. Вәгъдә бирәм.

— Ярый, Мөхәммәт, мин китим инде. Вакытыңны алдым, ачуланма!

Мөхәммәтнең хатынны нинди дә булса җылы сүзләр эзләп табып юатасы, хәтта гафу да үтенәсе килеп китте. Бу теләге мизгел эчендә шулчаклы зурайды, көчәйде ки, ул үзе дә сизмәстән, урыныннан ук сикереп торды, ләкин кирәкле сүзләр барыбер тиз генә теленә килмәде: Рәзифә каршысына басып, аптырап сүзсез-авызсыз калды. Хатын, аның бу теләген аңлагандай, әлеге хәлдән чыгарга үзе булышты:

— Кирәкми, юатма мине, Мөхәммәт! Хәзер тынычландым инде. Хатын-кыз бит инде мин: ничек тиз кабынсам, шулай тиз суына да алам. Кирәкми, юатма...

— Рәзифә...

Хатын кулы белән аның авызын каплый.

— Юк, Мөхәммәт, син миңа бер сүз дә әйтә күрмә, яме. Тик син, Мөхәммәт, артык наивный да булма. Алдап йөриләр бит сине! Мин сиңа моны әйтмичә булдыра алмыйм. Шуны бел: Гөлчәчәгең чәчәк түгел инде синең. Синнән көлеп йөри ул. Имеш, аңа багышланган картинаңның тәмамланганын көтә! Җирбит ул! Чәчәген күптән койганнар инде аның! Ә син һаман бала-чага кебек.

Хатын әлеге сүзләрне кызу-кызу сипте, сипте дә, җәһәт кенә сумкасын эләктереп, йөгереп диярлек ишеккә китте, әйтерсең Мөхәммәтнең башына күсәк белән сукканнар иде — ул идән уртасында өнсез басып торып калды. Буйдак егетне ишек йозагының ачылган тавышы сискәндереп җибәрдеме, әллә Рәзифәнең сүзләре яңа гына аңына барып ирештеме — ул ишекне яртылаш ачкан хатын артыннан атлады һәм аның беләгеннән эләктереп алды.

— Дөресме бу! Кайдан беләсең?!

— Әй, Мөхәммәт, хатын-кызның белмәгәне юк аның. Берсе, Гөлйөземе, уйнаштан бала тапты бит инде! Игезәк сыңары да ерак киткәндер дип уйлыйсыңмы әллә?

Мөхәммәт ишекне шапылдытып кире япты, бер кулы һаман Рәзифәнең беләген кысып тоткан килеш иде әле.

— Чынлапмы? Гайбәт бит бу!

— Һа! Гайбәт! — Хатын ямьсез итеп көлеп куйды.— Синең өчен, бәлки, гайбәттер!

Ачуыннан бүртенеп, шартлар дәрәҗәгә җиткән буйдак егет хатынны залга кире тартып кертте.

— Ант ит!

— Ник мин шул себерке өчен ант итеп торыйм суң әле!

Мөхәммәтнең бөтен гәүдәсе дерелдәди, тәне уттай кызыша башлады.

Ул хатынны, җилтерәтеп, диван янына алып килде дә дорфа гына аны төртеп аударды. Тегесе, карышмакчы булып, сикереп тормакчы иде, тик егет аңа ирек бирмәде, шулай ук тупас кыланып, хатынның киемнәрен йолкып атты.

Кухнядагы чәйнек яман итеп сызгырырга кереште һәм әле ул шул рәвешле суы кайнап беткәнче сызгырачак иде...

Кичкырын, чыгып киткәндә, Рәзифә, Мөхәммәткә таба борылып:

— Миңа Барый сөйләде. Миңа үпкәләмә. Бигайбә, Мөхәммәт җаным! — диде. Гап-гади сүзләр. Акланумы бу, әллә тынычландырырга теләүме? Алла белсен...

Сәнгать студиясенә йөрүче балалар килергә сәгатькә якын вакыт бар иде әле.

Барый һаман күренмәде. Хәер, Барыйның Казанда икәнлеген белсә дә, аның үзе янына керергә уйлап та карамыйча, Рәзифәне махсус котыртып җибәргәнен чамаламый иде Мөхәммәт. Барый, колхоз рәисе буларак кына түгел, интригалар, кешегә төрле тозаклар кору буенча да шактый шомарган һәм түгәрәк башлы адәм иде. Гөлчәчәкнең «чәчәге» хакындагы экият-гайбәтне дә ул юри уйлап чыгармады микән әле? Барый Әкбәровның башында нинди уйлар кайнаганын этем белсен диме! Дистә еллар буе тау итәгендә яшәгән Байтимер чаклы Байтимерне тау башына күчерергә йөргәнне инде! Бу кешегә хәйлә-тозаклар күп, бик күп кирәк булачак, югыйсә ул әлеге максатына шуларсыз үлсә дә ирешә алмаячак!

Мөхәммәт исә боларны чамалау гына түгел, бу хәлләр аның ике ятып бер мәртәбә төшенә дә кереп карамый, ул иҗат кешесе, хак Тәгалә аңа кызганмыйча талант биргән, ул әнә шул талант исереклеге белән саташып яши; калганында аның эше юк, андый кеше печән урынына салам бирсәләр дә куанып кабул итәр һәм әле шуңа сөенеп тә йөрер иде.

## Иртәгә көн болытлы булачак

«Урман» картинасы иҗат ителеп тәмам кылынган иде инде. Аның исеме әүвәл «Урман кызы» иде. Хәлләр бу рәвешле куера башлагач, ягъни аңа тирә-юньдәгеләрнең күзе төшеп, ул игътибар үзәгенә әйләнгәч, Мөхәммәт әлеге исемнең койрыгын кисте: «Урман» булып кына калды.

Хәзер, тиз генә тотып, «Урман»ны Гөлчәчәккә күрсәтәсе, бүләк итәсе, күрәсеңме, мин вәгъдәмдә тордым бит, урманың таланып беткән инде, ләкин мин сиңа син үскәндәге, моннан ун ел элек булган урманыңны саклап калдым, Гөлчәчәк, диясе килде егетнең. Тик ничек итеп ул кыз янына бармак кирәк?! Рәзифә сөйләп киткән коточкыч хәбәрләрдән соң? Ә бәлки, чыннан да, ул гайбәт кенә булса? Мәкер һәм хәйлә белән тулган бу соры җиһанда нинди генә ялган булмас!

Ул әүвәл Барый белән күрешеп сөйләшергә уйлады һәм шул максат белән авылга җыенды. Ләкин Барыйны авылда күрергә язмаган икән, алар шәһәрдә күрештеләр; Барыйны ярты үлек хәлендә Казанга — хастаханәгә алып килеп салганнар икән.

Әлеге хәбәрне ишетеп, Мөхәммәт хастаханәгә барганда, дусты реанимациядә ята, янына кертмиләр иде. Ул ишек төбендә беркавым таптанып торды да, хәлен генә белим ичмаса дип, бүлек мөдирен эзләп тапты. Реанимация бүлеге мөдире кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге баһадир гәүдәле, маңгай чәче пеләшләнә башлаган ир-ат (ишегендәге язудан ул аның Ибраһимов Виктор Саматович икәнлеген укып белде) Барыйның хәле турында анык кына җавап бирә алмады:

— Әлегә берни әйтә алмыйбыз. Он пока в коме,— диде ул, ярым татарча, ярым урысча һәм, әлеге сүзләрен мөһерләгәндәй, иңбашларын сикертеп куйды.

— Монда больницага кем алып килде соң аны, Виктор Саматович?

Мөхәммәтнең берни белмичә кайтып китәсе килми, шуңа күрә төпченә иде.

— Мин абыйсы белән сөйләштем. Абыйсы монда иде. Кстати, он сказал, что в час подойдет.

Җавапның монысы Мөхәммәтне канәгатьләндерде. Димәк, Һади абый кайдадыр монда гына. Ул бүлек мөдиренә рәхмәт әйтеп, коридорга чыкты. Тагын ишек янында таптанырга кереште. Бер өлкән яшьтәге шәфкать туташы (шәфкать әбие дисәң, дөресрәк булыр, чөнки пенсия яшендәге авыр гәүдәле әби коридордан барганда да ике як стенага бәрелә-сугыла, алпан-тилпән, кыскасы, бик авыр атлый. Әллә ул хастаханә ыгы-зыгысыннан шулай талчыкканмы, бәлкем, төнен кизү торып арыган, алҗыгандыр) аның янына килеп, ике мәртәбә куып чыгарырга тырышкан иде, гөрнәдирдәй гәүдәсе һәм һәйбәт киеме, җитмәсә, чем-кара түгәрәк сакаллы кыяфәте әбигә артык батыраеп китәргә ирек бирмиме? Өстәвенә Мөхәммәт «Я только Виктор Саматовича дождусь! дип, тавышын калынайтып әйткәч, «шәфкать әбие» тынычланды, бүтән бәйләнмәде.

Табиблардан һәм укытучылардан һәрвакыт могҗиза көтәләр, ә ул тормышка ашкач, бу хәлгә берәү дә гаҗәпләнми, дигән кемдер. Мөхәммәтнең: «Больницага китереп җиткерүләре әйбәт булган әле»,— дип уйлап бетерүе булды, ишектә иңенә ак халат салган Һади абый күренде. Алар Һади абый белән бик җылы күрешсәләр дә, сүзләре әүвәл ялганып китә алмады, күренеп тора, ул энесе өчен бик борчыла, аның күңел халәте йөзенә үк чыккан.

— Барыйга ни булган соң, Һади абый?

— Ни булганын кем белсен! Урманнан табып алып кайттылар. Машинасыннан 40—50 метрлар чамасы читтә, кырмыска оясы өстендә капланып яткан, ди. Тәнендә яра-фәлән дә, бәрелгән-сугылган җирләре дә юк. Үзе сөйләр иде дә, аңына килә алмый бит!

Сәер. Нәрсә булырга мөмкин Барыйга? Әле генә җир җимертеп йөри иде ич!

— Урманга нәрсәгә барганы аңлашыла инде. Марилардан колхозга делянка сатып алган иде. Нишләп аңын югалтып егылган, монысы һич тә башка сыймый.

Төш вакыты җитәрәк, шәфкать туташы (карбыз йоткан марҗа әбине мөлаем гына яшь кыз алыштырган иде), алар янына чыгып, авыруның күзен ачуы һәм сөйләшә башлавы хакында хәбәр итте. Кыз әйтүенчә, күзен ачуга, Барый сау-сәламәт кешегә әйләнгән дә куйган. Ләкин барыбер янына керергә рөхсәт юк әле. Кәефе шулай әйбәт торса, кичкә гади палатага күчерәбез, дип вәгъдә иттеләр һәм күрешү дә шул вакытта гына рөхсәт ителәчәк иде.

Мөхәммәт Һади абыйсын өенә чакырды, кичкә чаклы ял итәрсең, аннан соң, бергәләшеп, тагын килербез, дигәч, тегесе карышмады, чөнки шәһәрдә укучысы Мөхәммәттән дә якынрак башка барыр кешесе болай да юк иде. Мөхәммәт,— рәсем төшергәндә бите, борыннарына чаклы буяуга манчылып бетә торган малай,— җитди кешегә әверелгән, үз-үзен тотышы гына түгел, холык-фикеренең дә нык үзгәргәнлеген чамалады Һади.

Петербургларда укып йөрү, күрәсең, эзсез калмаган. Гап-гади татар авылы малае дип һич кенә дә әйтә алмыйсың!

Мөхәммәт хастаханә каршына чыгуга, Һади абыйсы хөрмәтенә машина туктатты. Танкадром, Вишневский урамнары аша кайттылар. «Барыйның кәефе яхшырса, килгән юлы берәр мәчеткә кереп чыгарга кирәк әле...»,— дигән теләге барлыгын әйтте Һади абый.

Мөхәммәт укытучысының мәчет сүзен телгә алуына гаҗәпләнмәде, чөнки белә: соңгы елларда Һади абый шамаилләр язу белән мавыгып киткән иде. Ул моннан җиде-сигез еллап элек Казан кызына өйләнгән һәм алар Байтимердә бер малай үстерәләр. Югары белемле табибә хатын авыл медпунктында гади фельдшер булып эшли.

Мөхәммәт яшәгән биш катлы «хрущевка» йортның ишегалды бизәкләп эшләнгән тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган. Аның ике капкасы бар, берсе җәяүлеләр өчен, зурысыннан җиңел машиналар кереп-чыгып йөри.

Хуҗа кеше әүвәл, өйгә керер алдыннан, янәшәдәге маркет-кибеткә сугылмакчы иде, аннары кунагы белән алай йөрүне килештермәде, соңыннан үзем генә чыгып керермен дигән уй белән, Һади абыйны туп-туры өенә таба алып китте.

Баскычтан бишенче каттагы фатирга күтәрелү беркайчан да матур хисләр уятмый, иртәләрен бигрәк тә шулай. Беренчедән, подъезд яннарындагы үлән өстендә файдаланылган шприцлар аунап ятса, баскычта һәрвакыт сырадан бушаган шешә ватыклары аяк баскан саен чытыр-чытыр килә. Югыйсә бу күптән салынган «хрущевка»ның күпчелек фатирларында ялгыз әбиләр, гомумән, карт-коры гына яши. Надан булмаган кеше яхшы белә: ул шприцлар әби-бабайлар чакырткан «скорый»дан төшеп калмаган, кич җитүгә, ишегалдына, подъезд төпләренә яшь кызлар, яшь малайлар җыела. Наркомания Казанга яшен тизлеге белән үтеп кереп, яшь буынны яртылаш гарипләндерергә өлгерде инде!..

«Кәефеңне күтәрү өчен түгел, кәефең начарланмасын өчен энә кадау моменты бик тиз килеп җитә икән ул»,— дип ачынып әйткән атаклы француз җырчысы Эдит Пиаф. Заманында ул да әлеге чирдән дәваланып йөргән.

Пычрак сәясәт белән мавыгып китеп, дөньясын оныткан сәясәтчеләр, дәүләт-хөкүмәт бәндәләре үз гаиләләрен, кызларын-малайларын наркомания дигән афәттән ничекләр итеп саклап калмакчы булалар икән?

Ниндидер бер бәйрәм табыны артында кызып киткән бер хөкүмәт чиновнигы, күкрәген кагып мактана-мактана: «Минем байлык оныкларымның оныкларына җитәрлек! Халык турында уйлый-уйлый чәчләрем агарып бетте инде болай да!» — дип ычкындырды. Шулчак Мөхәммәт янәшәсендә тәмәке пыскытып торган таныш язучы: «Малаең яки кызың энәгә утырса, байлыгың оныкларыңа калу түгел, ничек итеп соңгы ыштаныңны салганыңны үзең дә сизми калырсың әле, туган!» — дип, тегенең авызын каплаган иде. Чынлап та, наркомания һава буенча таралган яман вирус кебек бит ул!.. Аннан балаларыңны яки оныкларыңны зиннәтле коттеджыңа бикләп куеп кына качып котыла алмассың, кем әйтмешли, тынчу көннәрдә барыбер тәрәзәңне ачасы булыр! Шуңа күрә, син, агай, кулыңда власть бар чакта, ул афәткә каршы аяусыз көрәш инде, яме. Әгәр дә халык турында уйлый-уйлый, аның мәнфәгатьләрен кайгырта-кайгырта каешланып бетеп, бик шомаргансың икән, йөрәгең маемлаган икән, һичьюгы, үз балаларымны һәм оныкларымны кайгыртам дип тырыш, ичмаса, чиновник агай!

Мөхәммәт яши-яши белде: бер нәрсә дә юктан бар булмый. Үзгәртеп корам дип, Горбачев Ил капкасын төбенә чаклы каерып ачып куюга, Рәсәйгә күп афәтләр иңде. Ә боларның тамыры ерактан, бик ерактан килә икән ләбаса!

Ул яшүсмер вакытта Һади абыйсы Мөхәммәткә Шопенгауэрлар, Ницшелар тәгълиматының кайбер җөмләләрен тукый иде, ә бүген, баскычтан күтәрелгән арада, наркомания хакында авыл укытучысына үзе тулы бер лекция сөйләп ташлаганын сизми дә калды.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Америка Кушма Штатлары Советлар иленә каршы салкын сугыш ача. Аларның максаты СССРны таркатып, халкын кол итү була. Михаил Горбачев ярдәмендә алар тыныч юл белән, нәкъ яһүдләргә хас булганча, салкын акыл белән максатларына ирештеләр. 1945 елда Америка стратегы Даллесның нәрсә дип хыялланганы һәркемгә мәгълүм хәзер.

«Сугыш бетәр, барысы да тегеләйме-болаймы тиешле эзенә төшәр, көйләнер,— ди ул.— Һәм без бөтен көчне, булган бар нәрсәбезне... барлык алтыныбыз, матди куәтебезне совет халыкларының башын әйләндерүгә, аларны җүләргә сабыштыруга ташлаячакбыз.

Кешенең баш мие, акылы үзгәрүчән бит. Анда буталчыклар тудырып, без чын кыйммәтләрне ялган кыйммәтләргә алыштырачакбыз һәм гавамны шул ялган кыйммәтләргә ышанырга мәҗбүр итәчәкбез. Ничек итепме? Фикердәш, аркадаш һәм ярдәмчеләрне Рәсәйнең үзеннән үк табачакбыз.

Дөнья сәхнәсендә, Җир йөзендәге иң башимәс халыкның һәлакәте, аның акылының тәмам, инде кабат уянмаслык булып сүнүе хакында биниһая фаҗигага уйналачак. Әдәбияттән һәм сәнгатьтән без әкренләп социаль мәгънә дигән нәрсәне юып алачакбыз, сәнгатькярләрнең гавам эчендә барган процессларны тасвирлауга диикме, өйрәнүгә диикме, булган теләкләрен юк итәчәкбез. Әдәбият, театрлар, кино — һәммәсе кешенең иң түбән хисләрен сурәтләячәк һәм данлаячак. Кеше аңына секс, көчләү, садизм, хыянәт — бер сүз белән әйткәндә, һәртөрле әхлаксызлык тутыру һәм төйгечләү белән шөгыльләнүче ул «сәнгатькярләр»не без һәрдаим яклаячакбыз һәм күтәрәчәкбез. Дәүләт белән идарә итүдә без буталчыклык һәм башбаштаклык тудырачакбыз...

Без сиздермичә генә, әмма бик актив һәм даими рәвештә чиновникларның, ришвәтчеләрнең башбаштаклыгын, аумакайлыкны алга сөрүгә булышачакбыз. Намуслылык һәм гаделлектән көләчәкләр, алар бөтенләй кирәге бетеп, искелек калдыгына әвереләчәк.

...Ерткычлык һәм оятсызлык, алдашу һәм ялган, эчкечелек һәм наркомания, бер-береңнән хайваннарча курку, читенсенә белмәү, хыянәт, милли өстенлек, халыклар арасында дошманлык — боларның һәммәсе гөрләп чәчәк атачак һәм, бары тик азчылык, бик кечкенә азчылык кына илдә нәрсә барганын төшенер һәм аңлар... Әмма андыйларны без мескен хәлгә куячакбыз, тәмам көлкегә калдырачакбыз, алар турында ялган фикер тудыру һәм аларны җәмгыять төпкелендә дип игълан итү юлларын табачакбыз. Большевизмның рухи тамырларын йолкып ыргытачакбыз, әхлакый нигезләрен пычратачакбыз һәм юк итәчәкбез. Без шулай итеп буын арты буыннарны какшатачакбыз. Ленинча фанатлыкны җилгә очырачакбыз. Без кешеләрне балачактан, үсмер чактан тотынып эшкәртәчәкбез, төп игътибарны һәрвакыт яшьләргә бирәчәкбез, аларны рухи таркатачакбыз, бозачакбыз, аздырачакбыз. Без алардан шпионнар, космополитлар ясаячакбыз. Без моны нәкъ менә шулай эшләячәкбез».

Мөхәммәт, үз янәшәсендә ватык сыра шешәләренә басмыйм-басмыйм дип, сак кына атлаган Һади абыйсына кыскача шуларны сөйләп ташлады. Һади абзый бу мәсьәләләрдә үзе дә төшеп калганнардан түгел икән:

— Гасырлар буе урыс хакимлек иткән бу илне, ниһаять, кызык иттеләр! — диде ул уфтанып.

Сөйләшә торган сүзләре күңелсез темага булгач, бишенче катка менеп җитү бик авыр, газаплы гомер узуга тиң иде кебек.

— Гитлер кадәр Гитлер дүрт ел буе сугышып та басып ала алмаган иде. «Горбач җилләре» исә башлагач, ниһаять, безне чит илләр сугышсыз-нисез генә яулап алдылар!

— Әйе шул, әйе,— дип куәтләде аның сүзләрен остазы.— Дошман тугыз, без сигез генә икән ләбаса!

Алар икесе дә, яхшы аңлап, бүгенге җәмгыятьнең сәяси һәм икътисади хәленә шактый ныклы анализ бирә алырлык кешеләр иде.

Гомумән, нәрсә соң ул бер илнең икенче илне тыныч юл белән басып алуы? Гади генә аңлашканда, басып алучы басып алынган илнең икътисадын кысрыклап, үзенекен кертә. Аның

халкы үзе берни җитештерә алмый, тегесенең үтмәс тауарын гына үзләштереп ята. Кыскасы, дошманының байлыгын арттыра!

Икенче ягы да бар. Анысы тагын да куркыныч һәм ул кабахәтләрчә эшләнә. Монысы мәдәниятне, рухи мирасны үтерү. Ягъни басып алучы ил үз мәдәниятенең төссез, ямьсез тауарын басып алынган илгә кертеп тутыра һәм шуның белән «кол» халыкның миен агулый, күңелен тупасландыра, пычрата.

Карагыз, көнбатыштан һәм океан аша кергән ул «хлам»ны! Ниләр генә юк! Секс, үтереш, шакшылык, пычраклык һәм дә иң әшәкесе — наркомания!

Остаз белән шәкерт икенче кат белән өченче кат баскычлары арасындагы мәйданчыкта тукталып калдылар. Бүген якшәмбе көн булгач, баскыч мәйданчыклары җыештырылмаган, төнге хәлләр аермачык булып күз алдында тора. Чүп савытлары сыра шешәләре һәм шприцлар белән тулган...

Боларны күрү бик авыр да һәм шул ук вакытта әлеге аңсыз яшьләр кызганыч та иде. Һади, тәрәзә янагына сөялеп, урамга карап тора башлады. Тәрәзә каршындагы ялгыз каен агачы,— күрәсең, күптән утыртылган булгандыр,— бишенче катка чаклы матур булып үскән, ямь-яшел яфраклар ярган.

Каен гына аны баягы күңелсез сөйләшүдән һәм авыр уйлардан арындыра алмады. Ул үзе кебек үк тәрәзә янагына сөялеп урамга карап торган Мөхәммәткә таба борылды.

— Телевидение көне-төне наркофильмнар, боевиклар әйләндерә. Минем кечкенә малаем телевизордан пычрак секс карап утырырга тиеш! Нишли алам соң? Шарт иттереп телевизорны сүндереп куйдым ди. Бу мәсьәләне хәл итү түгел. Баланың күңеле ымсынып калачак, чөнки аның кызыксыну хисен берничек тә сүндереп булмый, ул телевизор гына түгел. Шулай итеп, бары бер юл — фильмдагы хәлләргә аңлатма биреп утырырга гына кала. Ләкин ул «безобразие»гә беркем дә, берниндн дә аңлатма бирә алмаячак!

Әгәр дөньялар киләчәктә дә болай бара калса, иманым камил, тагын ун-унбиш елдан тулысынча бозык буын барлыкка киләчәк. Күреп торасың, әледән үк тараканнар кебек үрчи инде алар. Тиздән яшьләр җенси мәнфәгатьләрен нәкъ этләр кебек урамнарда, чүплек артларында канәгатьләндерә башлаячак!

Мөхәммәт үзе дә сизмәстән сүгенеп җибәрде. Әлбәттә, хәзер сүгенеп кенә берни кылып булмаячагын да яхшы аңлый, бары чак кына күңелең тынычланырга мөмкин. Подъезддагы тәртипсезлеккә ул, әллә ияләнгән булганга инде, иртән әллә ни игътибар да итмәгән иде, шешәләрне дә таптап-сытып кына узды. Ә Һади абыйсы алдында, укытучы һәм авылдан килгән кеше каршында уңайсыз, бик уңайсыз иде. Әйтерсең тәртипсезлекләрне ул үзе эшләгән, баягы сүзен дә аклану өчен генә башлап җибәргән иде, Һади абыйга шул җитә калды, ул боларны күңеленә бик якын алып кызып китте. Хәзер Барый да беркавым онытылып торды.

— Көнбатыш һәм океан арты культурасының язгы ташу кебек килеп керүе бигрәк тә безнең татар милләте өчен куркыныч! Без, урыс итәге астында болай да «үләм-бетәм» дип яшәгән милләт, үзебезнең борын-борыннан килгән милли гореф-гадәтләребезне ничек саклап калырбыз, газиз балакайларыбызны ничекләр итеп, кемнәр итеп үстерербез икән!

Мөхәммәт, аның сүзләрен куәтләгәндәй:

— Урыс итеге һәм марҗа итәге астында яшәгән милләт без,— дип кенә куйды да башка сүз әйтмәде.

— Кая, синең «Урман» картинаң нинди хәлдә? Ул урман үзе таланып бетеп бара бит инде. Ичмаса, синең картинаңда булса да, саклап каласы иде аны.

Әлеге сүзләрне Һади абыйсы ачынып, йөрәге җылап әйтсә дә, Мөхәммәтнең ул хакта сүзне артык куертасы килмәде.

— Һаман шул картина! — дип көрсенде дә,— тәмам инде ул,— диде. Бу вакытта алар ул яшәгән фатир ишегенә килеп җиткәннәр иде инде. Өендәге радиосы бар көченә кычкырып эшләп утыра, алар ишектән кергән шәпкә дикторның иртәгә булачак һава торышы хакында әйткән җөмләсен ишетеп калды. «Иртәгә көн кояшлы...»

«Кояшлы, пычагым! Көн иртәгә дә болытлы булачак! Нәкъ бүгенге кебек. Синоптиклардан алган хәбәрне укыганчы, ичмасам, тәрәзәдән урамга күз ташлар идең. Дөньяны болыт каплаган бит!» — дип көрсенде Мөхәммәт, диктор белән күңеленнән бәхәскә кереп.

**Эттән туган...**

Энесе аңына килеп, кәефләре яхшыргач, Һади абый Байтимергә кайтып китте. Мин иртәнге якта көн саен Барыйның хәлен белергә бардым. «Бәлки, невроз булгандыр, ял итсен, каннарын чистартабыз»,— дип, табиблар Барыйны тагын бер атнасыз чыгармаячакларын әйттеләр. Урындагы кеше урындагы кеше инде, Хәниф Хатыйпович, шалтыратып, Барыйны тыныч, уңай палатага күчерттерде. Шуңа күрә мин аның янына баргач, иркенләп сөйләшеп утырырга да мөмкинлек зур, комачаулаучы кеше юк. Ә палатадашы исә — үзе дә сөйләшергә сусаган пенсия яшендәге абзый кеше — менә дигән әңгәмәдәш. Ул гомере буе университетта фәнни коммунизм һәм атеизм укыткан. Хәзер дә хезмәттә әле: хөкүмәттә дин эшләре буенча консультант, Татарстанда мәчетләр төзү буенча Үзәк киңәшмә әгъзасы. Ул һәрвакыт диярлек гәүдәсе каеш белән тартылган сурәттә караватында чалкан түшәмгә карап ята. Остеохондрозмы, умырткасының нервылары кысылып шулай булганмы: биле катып, гәүдәсе алга таба бөгелгән килеш калгач, хастаханәгә керергә мәҗбүр булган. Үзе әйтмешли, гәүдәсе фәнни коммунизм фәне кебек берзаманны тиктомалдан каткан да калган. Юморга бай, күңелен төшенкелеккә бирми торган җор телле кеше Сабит Садыйкович.

Хәл сорашудан башка, иркенләп Барый белән сөйләшеп утыра алганым юк. Килеп керүгә, Сабит Садыйкович сүзгә кушыла һәм аның ару белмәс, тиктормас теле гел тегермән тартуда. Үзе сөйләвенчә, ул карчыгы белән ике малай тәрбияләп үстергән. Карчыгының аяклары авыртса да, ул аның хәлен белергә атнага бер булса да килеп китә, ә малайларның эзе дә юк һәм алар турында сөйләргә Сабит Садыйкович үзе дә бик атлыгып тормый. Шул хакта сүз чыкканда да, әңгәмәне бик җайлап кына икенчегә борып җибәрә иде.

Мин килеп кергәндә, Барый баш өстендәге радиосын тыңлап ята, Сабит Садыйкович гәзит укый һәм ат кебек ара-тирә пошкырып көлеп җибәрә. Аның янәшә койкасындагы керәшен Василий түшәмгә карап тавышсыз-тынсыз гына нидер уйланып ята. Күренеп тора: аңа Сабит Садыйковичның ат кебек пошкыруы бер дә ошамый, әлеге авазлар кинәт, көтелмәгән булгач, ул сискәнеп-сискәнеп китә, әмма күршесенә шелтә белдерергә һич тә җөрьәт итә алмый: Сабит Садыйкович килештереп, кызык итеп сөйли, аны тыңлап ятуы үзе бер рәхәт! Нәкъ менә шул сәбәпле түзәргә дә туры килә инде. Ни хәл итәрсең!..

Ул Сабит Садыйкович авызыннан үз гомерендә беренче мәртәбә «масон» дигән ят сүз ишетте. Әүвәл ул аны «масло» дип аңлаган иде. Кешеләрнең иң каймакларын гына ул оешмага кертәләр, ди бит! Каймак белән май бертуганнар бит инде, әллә ни аерма юк! «Масон»ны «масло» дип аңласа да гаеп түгел.

— Егетләр, тыңлагыз әле менә! — диде Сабит Садыйкович. Һәм рөхсәт тә сорап тормыйча укырга керешә.— Умнеющей и хитреющей нации ты принадлежишь, Хакимов, то есть татарской, ди Виктор Астафьевның бер герое татар кешесе турында. Икенче урында башка герой нәкъ шул ук сүзләрне еврейлар хакында әйтә. Күрәсезме, яратмый атаклы урыс язучысы татарны. Еврейларны да яратмый, әмма курка. «Умнеющая и хитреющая нация»,— дип атый, еврейлар белән бер калыпка сала. Һе, кызык бу кызыгын. Дөреслек тә бар монда. Чынлап та, умнеющая нация без, еврейлар кебек. Бәлки, алардан да умныерактыр әле. Кыскасы, чуаш әйтмешли, польно умныйлар. Туган Ватан кабалада булса да, Татарстан дигән җиребез бар. Мәдәниятебез, телебез, динебез. Еврейның болар юк бит! Урыс булып йөриләр. Ул милләтне кимсетеп әйтмим мин. Затлы халык алар. Әнә безнең врачны, профессор Берманны гына алыйк. Андый шәп врач бөтен Татарстанга берәү! Бертуган абыйсы күрше кафедрада, философиядә эшләде. Беләсезме, шуның, Михаил Израиловичның, лекциясен тыңларга бар институт җыела, утырырга урыннар булмый торган иде.

Сабит Садыйковичның сүзе бүленде, палатага, гомере озын булыр, профессор Александр Израилович Берман үзе килеп керде.

Александр Израилович уртача буйлы, аның бер генә бөртек кара чәче дә юк, ап-ак һәм коелмаган, бик куе. Шул ак ефәк чәче бөдрәләнеп тә тора. Күзләре коңгырт, иреннәре калын, борыны карчыга борыны сыман: алай ук очлы булмаса да, дуга кебегрәк. Профессорның кыяфәте читтән караганда, җитди кебек тоелса да, авыру янында ул гел көләч йөзле. Шунысы кызык: авыру янәшәсендә берничә минут хәлен сораштырып һәм киңәшләр биреп утырганнан соң, тегесе дарусыз да терелеп киткәндәй була, профессорның йә күзләреннән, йә кулларыннанмы, зур дәвалау көченә ия булган уңай энергия агыладыр шикелле. Бу юлы да ул, һәркем белән итагатьле генә исәнләшкәннән соң, әүвәл Барый янына килде (бу палата махсус һәм түләүле палата булып, авыруларны атнага ике мәртәбә профессор үзе кереп карый). Мин гафу үтенеп, коридорга чыгып торырга уйлаган идем, профессор кузгалмаска кушты. Ул койкасы янәшәсендәге артсыз урындыкка утырды.

— Син борчылма, егет! Тиздән өеңә кайтып китәрсең. Җаның өшәнгән булган. Арыган, талчыккан булган рухың, егет. Чөнки син соңгы арада аны үстерү, баету өстендә эшләмәгәнсең. Җан — үлемсез. Аңа һәрвакыт энергия өстәп тору мәҗбүри. Шулай итмәсәң, ул сине ташлап китәчәк. Синең бар бәхетең, үзеңә салынган индивидның нинди булуы синең тормышыңа турыдан-туры йогынты ясый, Гётены укыганың бармы синең? Ул менә нәрсә ди:

Кол, халык һәм җиңүче
Күптән инде танылган.
Һәм җирдәге зур бәхет
Шәхескә бит салынган.

Сәламәт хәерче, авыру патшага караганда, күпкә бәхетлерәк.

Рухы бай кеше адым саен кызык эзләп йөрми. Аңа болай да тормыш күңелле. Сократ нәрсә дигән, беләсеңме? Ул әйткән: «Уйласаң, тормышта миңа бөтенләй кирәге булмаган бик күп нәрсәләр бар икән!»

Йә, ярый, күп сөйләп ташладым. Син акыллы егет, үзең дә аңларсың. Җан тынычлыгы кирәк сиңа, җан тынычлыгы. Якын иткән кешең булса, өйләнеп җибәрерсең тагын!

Аның бу сүзләреннән мин үзем дә сизмичә көлеп җибәрдем һәм Барыйның да ирен читләре белән елмаеп куйганын күрдем. Барый җавапсыз калмады:

— Рәхмәт, профессор! Минем туйда түр башында булырсыз!

Профессор саф татар акценты белән:

— Алла боерса! — диде. Аның күзләренә чаклы елмая иде.

Профессор чыгып китүгә, Сабит Садыйковичның тел тегермәне янә хәрәкәткә килде. Аның гәүдәсе каеш белән тартылган иде, ул, башын чак кына күтәрә төшеп:

— Акыллы адәм дә инде бу профессор! — диде ул.— Тик беләсезме: еврейлар бер-берсе өчен тырыша, яклый, диләр. Безнең татар да шулай. Казанда димим, диаспорада шулай. Читтә татарлар бер-берсе өчен үлеп торалар! Киресенчә, без еврейларның бер-берсен ничек кырулары турындагы фактларны күбрәк беләбез. Троцкийларны искә төшерегез. Бер-берсен ничек бугазлыйлар! Ә шулай да еврей барыбер татарга караганда өстенрәк бит! Ни өчен шулаймы? Аңлатам: диаспорада татарлар бер-берсен яклый, күтәрә, дидем бит әле. Ә еврей өчен бу Җир шарының һәр кыйтгасы да үз туган иле, төбәге булмагач, нәкъ диаспора инде. Еврейның туган иле —диаспора! Юк, юк, бу гына түгел әле! Ул халыкның иң светлый умнары масон ложасында тора! Менә көч кайдан килә аларга! Заманында безнең татар да әлеге ложаларга кергән булсамы!!! Их, юк шул!.. Беләсезме?!

Сабит Садыйкович сүзен тәмамларга өлгерә алмады, шәфкать туташы, кереп, тарттырылган каешларны чиште һәм аны икенче процедурага алып чыгып китте!

Мин, аның масон ложалары хакында әйткән сүзләре белән килешмичә:

— Петербургта укыганда күрдем мин, Сабит Садыйкович! Җир йөзендәге барлык бәла, афәт шул масоннар аркасында! — дип калдым. Миңа каршы җавап бирергә вакыты юк иде.

— Шат күңелле карт,— дип куйды Барый аның артыннан.— Бүген малайлары турында сөйләп алды әле. Моңарчы ул турыда авыз ачкан юк иде. Начар төш күргән, борчыла. «Үзем гомерем буе фәнни коммунизм укыттым. Ә үз гаиләмдә дә тәртип ясый алмаганмын. Балалар ач-ялангач йөрмәсен, кеше булсыннар дия-дия, көн-төн эшләдем. Нәрсә килеп чыкты диген? Зур түрәнең игезәк кызларына өйләнделәр. Ул иркә кызлар икесе дә наркоманка булып киттеләр. Үз артларыннан малайларны да иярттеләр! — дип сөйләп торды.

Мин сүз катмадым, авыр итеп көрсенеп кенә куйдым.

— Бүген көн тагын болытлы, ахрысы? — дип сорады Барый, тәрәзәгә карап.— Әйбәт йокладым бүген. Бер төш тә күрмәдем,— диде ул, шуның артыннан ук һәм янә миңа таба борылды: — Профессор хәйләкәр карт. Кичә миннән сорый: аракыны күп итеп эчәсеңме, ди. Мин әйтәм, туры килгәндә берәр шешә инде, дим, ә ләкин ул гына күзгә дә чыкмый, дим. Еш туры киләме соң, ди. Дөресен әйтмәдем: айга бер-ике мәртәбә генә, дидем. Үзенчә, белая горячка булмаганмы икән, дип кызыксынуыдыр инде. Бар ди сиңа, белая горячка! Начар аракы эчәбез, мин әйтәм. Шуны эчкәч, күзгә әллә нәрсәләр күренә башлый, мин әйтәм. Алар үзләре чиста спирт кына эчеп яткач та!..

Василий тәмәке тартырга чыгып китте. Икебез генә калгач, Барый белән күзгә-күз карашып сөйләшеп булачак иде. Ул, минем төпченә башлавымны көтмичә, үзе:

— Беләсеңме, малай, мин урманда ул көнне кызык хәлгә тап булдым бит,— дип сүз башлады.

— Кеше башлы бүре күрдем мин!

— Кит! Ул көнне үзең әйтмешли, начар аракы эчкән идең мәллә?

— Юк, ул көнне грамм да тотмаган идем. Аның алдагысында да.

— Алайса, нәрсә булды икән соң?

— Син, зинһар, бу хакта бер кешегә ләм-мим, яме. Хәтта Һади абыйга да әйтмәдем мин моны.

Күренеп тора: Барый уйнап та, шаярып та сөйләшми, сүзләре чынга охшаган. Тик ул таланып беткән шәрә урманда кеше башлы нинди бүре булсын?! Бүре башлы чын ерткычлар да качып киткәннәрдер инде!

Барый беркавым тәрәзәгә таба карап хәрәкәтсез утырды да, аннары кинәт утырган урынында кымшанып куйды һәм, кипкән иреннәрен ялаштыра-ялаштыра, миңа төбәлде.

— Беләсеңме, Мөхәммәт, Пиратны күрдем бугай мин. Хәтерлисеңме син безнең Пират исемле этне? Әле соңгы юлы түгел, аңа кадәр инде. Бүрегә әйләнгән ул. Бәлки, Пиратның баласы булгандыр. Мин аны күптән юкка чыккандыр, дип уйлаган идем. Урманнан кире кайтмады бит теге вакытта. Кыйнаган идем, миңа үпкәләде. Ул үзе дә бүрегә охшаган иде бит. Хәтерлисеңме син?

— Хәтерлим,— дидем мин, моннан байтак еллар элек булган вакыйгаларны, дөресрәге, үземнең Сигнал кушаматлы нечкә билле маэмаемны һәм Барыйларның бүре белән эт кушылмасы булган Пиратларын искә төшереп.

— Пират иде ул. Йә баласы! Янымда мылтыгым юк иде. Шуны сизеп, урман авызына чаклы артымнан озата барды. Ярый, машина сүнеп калмады әле.

— Ярый,— дидем мин, Барыйның сүзләре белән килешкәнлегемне белдереп.— Пират та булсын ди. Этнең бүре белән кушылып гибрит барлыкка килүе дә яңалык түгел, бәлки, Пиратның баласы булгандыр. Ә теге кеше башлы бүрең?

— Белмим,— дип, җилкәсен сикертеп алды Барый һәм аптырап, гаҗәпләнеп, миңа карады. Син ничек дип аңлатасың, янәмәсе? Аннан соң өстәп куйды:

— Бүре гәүдәсендә... беләсеңме, олы кеше башы түгел иде ул. Бала... бала башы иде, Мөхәммәт.

— Әкият! — дидем мин һәм, капылт кына урынымнан торып, тәрәзә янына килдем.

Болытлар таралып, күк йөзе ачыла башлаган кебек тоелды.

— Әкият! — дип кабатладым мин, караватта тынсыз утырган Барыйга таба борылып:

— Син, брат, мөгаен, урманда югалган малаеңны сагынып саташасыңдыр. Шуңа күрә сиңа шулай булып тоелган да ул! — дип, аның сүзләрен кире кагарга тырыштым.— Профессор дөрес әйтә, җаның талчыккан синең...

— Бернинди дә әкият түгел, дустым. Саташмадым да, төш тә күрмәдем мин.

— Син ул көнне тәгаен исерек түгел идеңме?

— Юк, юк, шыр аек идем. Шуның алдыннан гына, килгән юлы дип, Гөлйөзем янына да кереп чыктым әле...

— Син, бәлки, кара махмырдан булгансыңдыр. Махмырдан да күзгә әллә нинди шайтаннар күренә бит ул. Мәсәлән, минем шулай булганы бар. Кичтән бик көчле йокы даруы да эчеп яткан идем. Төнлә саташып уяндым. Имеш, безнең урман дөрләп яна икән. Гөлчәчәк белән икебез ут-ялкын эчендә калганбыз. Әллә төш күрәм микән соң дип, тәнне чеметеп карыйм, авырта, нормально, төшләнмәгәнмен дә. Менә шулай да була ул, брат.

— Юк, юк! — диде Барый, аның сүзләренә каршы.— Әлбәттә, мин ул көннәрдә арыган, талчыккан идем, ике-өч көн рәттән йоклый алмадым. Шуннан Һади абый хатынына, җиңгәйгә зарландым. Кичен ул миңа ниндидер укол салды салуын. Барыбер йоклый алмадым. Аунап яттым, яттым да нарядка чаклы урманга чыгып киттем. Өйләре янында Гөлйөземне очраттым. Ул атлары яныннан кайтып килә икән. Минем машинаны таныгач, капка янында көтеп торган.

— Җиңгәң йоклата торган укол салып, минем кебек син дә саташкан булсаң? — дидем мин, аның белән килешергә теләмәгәнемне белдереп.

— Белмим,— диде Барый, янә җилкәләрен сикертеп.— Ну, аңа чаклы, бүрене дә, бүрегә әверелгән Пиратны күрдем бит мин. Димәк, ул мине сагалый! Корытам мин ул урманны, Мөхәммәт! Авылны тау башына күчергәндә, яңа йортлар салу өчен агач та күп кирәк булачак. Үзәнгә, иске Байтимер урынына, яңа урман утыртачакмын!

— Ничек бетермәкче буласың син ул урманны, Барый туган, тайгага чаклы дәвам итә бит ул! — Илләтнең теге ягы мариныкы бит әле аның.

— Мари белән дә уртак тел табарбыз. Кирәк булса.

Безнең әңгәмәне, тәмәкесен пыскытып бетереп, палатага кергән Василий бүлде. Ул нигәдер ялт-йолт минем якка карап куйды да урынына барып ятты. Аннары үзалдында сөйләнгәндәй:

— Без берни белмичә яшибез икән, ә, малай! — дип мыгырданды.

Мин дә, Барый да аның сүзләрен игътибарга алмадык, үзебезнеке куәтлерәк иде. Ләкин чит кеше янында сөйләшеп тә булмый иде инде. Сүзләренең җавапсыз калуын Василий өнәп бетермәде бугай, ул, башын күтәрә төшеп, миңа эндәште:

— Син... Сез художник бит, иеме?

— Әйе,— дидем мин, салкын гына. Дөресен генә әйткәндә, бу вакытта аның белән ачылып сөйләшеп тә торасым килми иде. Шуңа күрәме кыяфәтем дә, сүзләрем дә төксе иде.

Әлбәттә, ул кешегә салкынрак мөгалләмәдә булуыма бернинди сәбәп юк. Аз-маз,— якынча гына инде,— авыру тарихын да беләм: нервылары какшаган Василийның. Ул студентлар тулай торагында комендант булып тора икән. Апрель аенда ике студент белән тулай торак түбәсеннән кар төшергәннәр. Егетләрнең берсе түбәдән егылып төшеп һәлак булган. Аның наркоман икәнлеген Василий белмәгән, кесәсенә шприцын тыгып менгән булган икән.

— Әгәр наркоман икәнлеге ачыкланмаса, минем урыным больницада түгел, төрмәдә булыр иде инде хәзер! — дип кабатларга ярата керәшен абые.

— Безнең общежитиенең бер залын бизисе бар ие. Шуңа художник таба алмыйбыз.

Бу кешенең миңа ни өчен сүз катарга тырышуы аңлашылды: тулай торак бизәргә үзенчә рәссам эзләве икән. Ләкин мин аңа тагын җавап кайтармадым. Кабат сүз кушарга ул үзе дә уңайсызланды булса кирәк, караватын шыгырдата-шыгырдата, тәрәзәгә таба борылып ятты.

Мин, Барый белән саубуллашып, палатадан чыгып киттем һәм коридорда баягы профессор белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздык. Ул мине туктатты да:

— Сез Петербург академиясен тәмамладыгызмы? — дип сорап, мине гаҗәпкә калдырды.

— Әйе,— дидем мин, аның бу соравына бик тә аптырап.

— Сезне Берман укытмадымы?

— Берман? Христофор Иосифович!

Профессорның йөзе яктырып китте.

— Әйе, әйе. Минем бертуган абый ул!

— Укытты. Сәнгать теориясеннән. Һәм бик зур художник та бит ул!

— Әйе, әйе,— дип җөпләде профессор, үзенең көйле тавышы белән.— Йә, ярый, гафу итегез. Мин шул хакта гына сорамакчы идем. Ләкин Сез, яшь егет, төрле оешмалар хакында... атап сөйләшмик, үзегез дә аңлыйсыз, шактый ялгыш фикердә икәнсез! Ул Сезнең үзегезнең фикерегез генә булып калсын. Сөйләп йөрмәгез. Сезгә файдага эшләмәячәк дип уйлыйм мин ул ялгыш фикерләрең. Йә ярый, гафу итегез. Мин болай гына. Онытыгыз минем сүзләремне, аларны башкалар белән анализлау мәҗбүри түгел. Аңламаган кешеләр бар. Мәсәлән, ул гап-гади комендантка шул кирәкме соң инде! Минем янга кергән дә башымны катыра. Ә Сез... Сез башка! Сез үсәсе кеше әле! «Война и мир»ны укып чыгыгыз әле тагын бер кат! Хәер, Казанда Сезнең күргәзмәләр бармы?

Мин аңа җавап йөзеннән санап чыктым. Бу минутта бик каушаганымны сиздем мин. Моны, әлбәттә, профессор да тойды булса кирәк, ул кулын дусларча иңбашыма куйды да:

— Уңышлар Сезгә! Вакытыгызны алдым! Мине гафу итегез! — дип, тиз генә коридорның аргы башына таба китеп барды.

Минем бөтен тәнем манма су иде...

«Вак балык йокыга талмасын өчен елгада чуртан да кирәк!» Кем әйтте бу сүзне? Профессор Берманмы?

Әллә... Әллә аны егеткә ниндидер яшерен, серле тавыш китереп ирештердеме? Санкт-Петербургта укыганда ишеткән идеме әле? Таныш бит, бик таныш сүзләр?!.

...Петербургта без тулай торакның бер бүлмәсендә өчәү: Мәскәү астындагы бер авылда туып үскән чандыр озын гәүдәле сары егет Василий Иванов һәм Кырымнан бөдрә чәчле, киң маңгайлы, уртача буйлы Абрам Соловьев белән бергә тордык.

Василий бәйрәм-сәйрәмдә авылына кайтып йөри һәм һәрвакыт, үзе әйтмешли, чык тамчысы кебек саф көмешкә кыстырып килә дә аннан шул кичне үк, өчебез утырып, авыз итә идек. Көмешкә каннарга йөгерә башлагач, Иванов белән Соловьев һәрвакыт милли темаларга кереп китеп, соңыннан бу аңлашуның ахыргы нәтиҗәсе тәпәләнүгә чаклы да барып җитәргә мөмкин иде.

Гадәттә, бәхәсне һәрвакыт Иванов башлый, мин, араларына кереп, нокта куярга ярдәм итә торган идем.

— Масоннар һәм еврейлар, якты идеягә хезмәт итәбез дигән булып, халыкның башын катырып яталар!

— Ә нигә? Халыклар арасында аерма булырга тиеш түгел! Милләт дисең! Причем монда милләт! Милли төшенчәне без онытырга тиеш!

Мин аларның бу бәхәсләренә кысылмаска тырышам. Бүлешсеннәр, талашсыннар шунда икесе генә, дип уйлыйм.

— Абрам, беләбез бит инде! Алар милләтләрне бер тагаракка салып бутап, көчсезләндерү максатын куялар. Нигәме? Чөнки милләт аерым, үзенчә булганда куәтле, көчле була. Аңа бу көчне милли идея бирә! Бер тагаракта буталгач, милли идея бетеп, ул үләчәк, еврейның итек астында калачак! Масон итәге астында...

— Масоннарга тел тидермә син! Белмәгән башың белән! Барлык дәүләтләрдә дә көчле йогынтылы, дәрәҗәле кешеләр һәм идарәчеләр масоннар булган. Алар Европаны урта гасыр баткагыннан алып чыкканнар!

Алар бар халыкларның да туганлыгы идеясен таратучылар!..

— Икътисад, финанс, капитал масоннар һәм еврейлар кулында. Урта гасырда масоннар «ирекле ташчылар», ягъни төзүчеләр булганнар һәм төп эшләре храмнар төзү булган. Ә хәзер, төзү эшләрен онытып, алтын чүпләү белән мәшгульләр.

— Барлык гыйлем-белем дә, таралу дәрәҗәсенә карап, тора-бара беренчел максатын югалта һәм һаман саен үзгәртелә. Ә үзгәртү нәрсә ул? Үзгәртү — бозу ул, кадерлем! Такова человеческая природа!..

— Дема-а-го-гия бу, Соловьев! Масон син!

— Масон оешмаларының бер характерлы ягы бар: алар беркайчан да ачыктан-ачык чыгыш ясамыйлар, кире какмыйлар һәм мактауга да, тәнкыйтькә дә җавап бирмиләр. Ә мин синең фикерләрне кире кагып утырам. Димәк, мин масон түгел! Югыйсә минем бу гамәлем масон этикасын бозу булыр иде. Мин бары хакыйкатьне яклыйм!

— Җир йөзендәге бар зур үзгәрешләр, революцияләр, канлы сугышлар, дәүләтләрнең юкка чыгуы, һәммәсе дә — интернациональ еврей һәм масоннар эше! Алар бүтән халыклардан өстен булырга, бүтәннәрнең муеннарына менеп атланып, рәхәтлектән аякларын селтәп утырырга телиләр!

— Син алайса җавап бир: нинди партия яки оешма, йә булмаса кайсы халык өстенлеккә, башкалар өстеннән идарә итәргә омтылмый соң? Бармы андый халык?

— Мин сиңа талантлы язучыбыз Валентин Распутин сүзләре белән җавап бирәм: без, урыслар, байлыкка омтылмыйбыз. Байлык кешеләрне боза ул!

— Распутинны хөрмәт итәм мин. Ләкин икегез дә мине гафу итегез: байлыкка, яхшы тормышка омтылмаган халыкның мондый психологиясе аңлашылмый! Гел гөмбә җыеп, тозлаган кәбестә чәкәне суырып утырып кына да яшәп булмый ич инде!

— Башка халык өстеннән идарә итәргә омтылу — кешелек алдында коточкыч җинаять! Наполеон, Гитлер язмышлары ничек тәмамланды? Шул ук Гитлер һәм Сталин еврейларга коточкыч ачулы иделәр. Икенче бөтендөнья сугышына кадәр һәм шуннан соң синең күпме туганың кырылды! Сез үз халкыгызга каршы җинаятьне үзегез эшлисез. Березовскийларың эшли! Бар капиталның бер учта булуы бүтәннәрнең ачуын чыгара.

— Үз халкыма каршы андый җинаять эшләгәнче, иң яхшысы тозлаган кәбестәгә канәгать булып утырам мин. Уразов, ник дәшмисең, шулай бит?

Мин болардан ансат кына котылып булмаслыгын яхшы беләм, шуңа күрә берәр сүз кыстырып куям:

— Үз урынында тозлаган кәбестәсе дә, капиталы да кирәктер инде аның!

Иванов мең тапкыр кабатлаган сүзләрен тагын әйтә:

— Ну хәйләкәр татар син, Уразов!

Мин, бертуктаусыз бимазалап теңкәмә тиеп беткән тизәк чебенен кугандай, аның ягына таба кулымны айкыйм. Янәсе: «Чукынышып китегез шунда! Тик мине кыстырмагыз гына!»

Әңгәмәнең читкә борылуына Соловьевның эче поша, ул кызу-кызу:

— Ну, ярый, синеңчә булсын ди. Берәр халык икенчесе өстеннән идарә итәргә омтылсын ди. Ләкин монда бөтен кешелек өчен дә бернинди куркыныч янамый лабаса! Эволюция ич бу, тормышның алга бару законы! Каршылыксыз үсеп булмый бит! Бу, беләсең килсә, файдалы да әле! «Вак балык йокыга китеп харап булмасын өчен елгада чуртан да кирәк диме әле? Юкса йокыга талган вак балыкны агым үзе белән иялтеп китәчәк һәм көчле дулкыннар аларны яр өстенә ыргытачак! Менә һәлакәт кайда ул туган!

Иванов, көмешкә шешәсен әңгәмәдәшенә табарак этеп:

— Әйдә, эчеп куйыйк әле. Сал әле чак кына! Демагог кешенең сүзләре кебек кулы да җиңел була ди.

— Бернинди демагог түгел мин! Демагог булсам, синең тавык тизәгеннән ясалган көмешкәңне эчеп утырыр идем мәллә?

Соловьев үпкәләде, ахрысы. Әмма аның үпкәләве әңгәмәдәше каршында, бирелән дип, ике кулын күтәрүе түгел иде әле, ул һаман телләшә:

— Вак балык турындагы сүзләремне дәвам итәм, Василий Петрович! Менә шул: мәгәр вак балыклар чуртанга каршы көрәшә-көрәшә ныгырлар, көч җыярлар һәм дә беркөнне чуртаннан курыкмый да башларлар. Мин монда, беләсең килсә, синең файдага сөйләп утырам әле!

— Син нәрсә, безне вак балык дип атамакчы буласыңмы әллә?

— Мин чагыштыру гына китерәм.

Көмешкә Ивановның кәлләсенә барып җитеп, егетнең холкы кайнарлана башлаган иде бугай, мин, бу ике этәч арасында сугыш-фәлән чыгып куймасын дигәндәй сагаеп, караватымнан башымны күтәрәм. Юк икән, әлегесен икесе дә тыныч. Шулай да Ивановның бала башы чаклы йодрыгы өстәл өстендә ята иде инде. Соловьев хәйләкәр һәм өстәвенә сак та, ул, Ивановның йодрыгына ымлап:

— Йодрык белән сугышып, үзеңнең хаклыгыңны исбатлый торган заман узды, дустым. Терсәгеңнең очлы булуы кирәк хәзер. Төртеп кенә аласың — кем төрткәнен чуртым да белми, шулай бит, Мөхәммәт?

Боларның миңа еш мөрәҗәгать итә башлаулары бәхәскә нокта куярга кирәклеген аңлата иде. Мин аларның икесеннән дә куәтлерәк. Ачуым чыкса, икесен берьюлы тотып, түшәмгә эләм дә куям. Алар моны яхшы белә. Ләкин, Иванов бер кызып китсә, тиз генә туктатырмын димә, бүлмәдә барыбер нәрсә булса да ватылачак һәм тавышның коридорга чыгуы да бар. Шуңа күрә мин, әңгәмә темасын икенчегә борырга тырышып, бәхәсне тыныч юл белән төгәлләргә исәплим.

— Сез нәрсә, егетләр, юк белән башны катырасыз! Сез рәссамнар бит! Сәнгать турында бәхәсләшегез, файдасы күбрәк булыр.

Алар минем әлеге хәйләмне икесе дә бик яхшы сизә, әмма минем белән һәрвакыт килешәләр тагын үзләре.

— Дөньяга татар тугач, еврей кычкырып елаган ди.

Бу Ивановның яратып кына миңа төрттерүе.

Соловьев та җавапсыз калмый:

— Шатлыгыннан елаган ул: ичмасам, җиргә тагын бер җүнле халык туды дип!

Без өчебез дә дәррәү көлешәбез.

— Татармы? Татар — җүнле шул!

— Заманында юкка гына масон ложасына кермәгәннәр. Әрәм булып йөриләр.

Монысы Соловьевның Ивановның касыгына янә бер мәртәбә терсәк белән орынып алуы иде. «Тагын башлана бит!» — дип уйладым мин һәм өстәлгә Пикассо әсәрен китереп салдым.

— Әйдәгез, кем нинди мәгънә чыгара.

Бу Пабло Пикассоның «Герника» картинасы иде. Пикассо аны Басклар илендәге Герниканы җимергәч, шул уңайдан яза. 1937 елның 26 апрелендә көпә-көндез фашистлар авиациясе саклаучысыз шәһәр өстенә ябырыла. Җиде мең кешедән бер мең алты йөз илле дүрт кеше һәлак була, сигез йөз сиксән тугызы каты яралана. Картинада әнә шул дәһшәтле мизгелләр сурәтләнә.

Миндә үзебез яшәгән бу болгавыр дөньяны, кызыклы-кызыксыз җәмгыятьне, аның барлык матур якларын һәм бөтен фаҗигасен картинада сурәтләргә хыялланам! Беренче хыялым «Урман кызы»н язып, аны Гөлчәчәккә бүләк итү булса, икенче һәм зур максатым әнә шул!.. Ходай мидәт бирсен! Өметсез шайтан гына була ди...

— Үгез, үгез нәрсәне аңлата картинада? — дим мин, егетләргә карап. Иванов иренеп кенә:

— Нинди катлаулылыгы бар инде аның? Үгез образы аяусызлыкны, мәрхәмәтсезлекне гәүдәләндерә.

Соловьев, аңа янә каршы төшә:

— Үгезнең кыяфәте усал, рәхимсез түгел бит! Пикассо аның сугышка ташланырга әзерләнгән мизгелен сурәтләгән!

— Ана белән бала образлары хакында ни диярсең?

— Пикассо кубизм алымы белән иҗат итә бит. Бер рәсемдә үзе сурәтләгән предметның барысын да символлар белән күрсәтергә омтыла. Парижда яшәгән испан егетенең француз

көймәсенә утыруы дигән сүз инде бу. Әнә ананың ачыргалануы хәнҗәрне хәтерләткән үткен тел ярдәмендә тасвирлана.

— Ат образы, Пикассо үзе раславынча, халыкны аңлата! — дим мин, егетләрнең салынкы утыруларына эчем пошып. Югыйсә моңарчы телләре телгә йокмый иде!.. Хәер, алдагы көнне алар икесе дә лекциядә булмадылар. Югыйсә Берман ничек шәп сөйләгән иде Пикасо турында!..

Әйе, шул рәвешлерәк Пикассоны «сүтеп» чыктык та тынычландык без. Тик минем күңелне генә Иванов белән Соловьевның бәхәс-чәкәләшләре вакыт-вакыт тырнап тора һәм мин, кайсысы ягына чыгып уйласам да, бер уртак фикергә килә алмыйм, үз акыл-көчем белән дөрес җавапны табарга азаплана идем.

Ул җаваплар тормышның үзендә икән... Аны аңлау өчен вакыт һәм тәҗрибә кирәк һәм, әлбәттә, бик еш кына тирә-юнеңә дә күз салу мәҗбүр икән... Хакыйкать лапас артындагы тиреслектә генә аунап ятмый икән ләбаса!..

Барыйның тирә-юньдәге төрле милләт халыкларыннан торган берничә авылны берләштереп, укмаштырып, тау башына менгезеп утырту хыялы ни белән тәмамланыр соң? Төрле-төрле милләт халкы бергә-бергә,— дөресрәге, укмашкан хәлдә,— ничек яшәп китәрләр?

Әлбәттә, бу хактагы уйлар Барыйның башына да кереп карамаганлыгын мин яхшы чамалыйм. Идеологик максаты юк аның. Аңа хәрәкәт кирәк, аңа үзгәреш, яңалык кирәк...

Минем аңымдагы әлеге уйлар,— Барый хакындагылары да, Петербургтагы бәхәсләр дә,— буталып бетте. Әмма мин күңелем белән тоям һәм сизәм: алар арасында ниндидер эчке бәйләнеш бар, әлбәттә, бу очракта ул аңсыз бәйләнеш түгел иде.

Әмма ни дисәң дә СССР чаклы держава капылт кына таркалды да бетте бит?! Тиктомалдан гынамы? Гомере беткән идеме? Горбачев белән Ельцин таркаттылармы? Әллә аларның куллары белән генә эшләндеме?

Горбачев Кремльне «яшәртте», әлбәттә. Триумфы да бик әйбәт башланып китте. Сөйкемле һәм телгә оста бу кеше әдәбият-сәнгать әһелләре һәм дөнья сәясәтчеләре белән бик җиңел аралашып китте, аны яраттылар. Шул рәвешле президентның даны бермә-бер артты. Горбачевны чит ил сәясәте йолдызлары Рейган, Тэтчер һәм башкаларның якын итүе һәм аның СССР җитәкчеләреннән беренче булып, дөнья элитасының формаль булмаган клубына керүе дәрәҗәсен тагын да үстерде. Һәм, үз чиратларында, чит илләр Горбачевның карьерасына кабер дә казып куйганнар иде. Чөнки аны чит илдә никадәр ныграк яратсалар, үз халкы шул дәрәҗәдә үк күралмаска әйләнде.

Герцен декабристларны уяткан кебек, Горбачев Ельцинны «уятты». Холкы белән аның киресе булса да, Горбачев башлаган җимерү эшен бик төгәл үтәде ул. Менә тәхеткә яңа президент килде. Бик күпләр Ельцинны сагынып күз яшьләрен түкмәгәйләре әле!..

...Хәтерем нәкъ кинофильм тасмасы кебек. Кадрлар берсе артыннан берсе чиратлашып, алышына тора.

Соловьев:

— Дөнья белән масоннар да, яһүдләр дә түгел, өлкән ир туганнардан торган күзгә күренмәс Хөкүмәт идарә итә. Ул масоннардан да, яһүдләрдән дә һәм кешелектән дә өстенрәк. Кешелекнең бөтен бәхетсезлеге әнә шуны аңларга теләмәүдә. Ахыр чиктә аны белергә кирәк. Һәм үзеңнең чын Хөкүмәтеңә ышаныч белән карау зарур. Ул безгә нәрсә кирәген үзебездән дә яхшырак белә.

Иванов:

— Мин сиңа, Соловей, бер генә сүз белән җавап бирәм: дема-го-гия!..

Соловьев:

— Яңа Бөек Ачышлар шуны күрсәтә: киләчәк якты чор —рух чоры. Анда узып баручы изге расаның алтын Үгезбозавы бар мәгънәсен югалта. «Җирнең алтынын Яңа металл белән коям. Алтын калкан нык түгел»,— ди Ходай. Яңа чорга алтын калкан түгел, рухи капитал зарур. Киресенчә уйлаучылар бик каты ялгышачаклар. Дөрес, әлегесен алтын Үгезбозау тулы һәлакәткә дучар булмады. Шулай булгач, эволюция вакытында ул да кирәксез түгелдер.

Иванов:

— Масоннар халыкның инде бәгырьләренә кереп сеңгән изге диннәргә каршы киләләр. Диннән тыш мораль тудыралар. Имеш, ул бар халыклар өчен дә уртак булырга тиеш. Масоннарның байраклары шайтан-иблис кулында. Алар шуның ярдәмендә безнең диннәргә каршы көрәшәләр.

Бар кешелекне, барча халыкларны, милләт, раса, кабилә һәм дин-мәдәниятләренә дә карамастан, бергә берләштерергә азаплаunion. Утопистлар!..

Хәтерем тасмасы әлеге урынга җиткәч, мин сискәнеп киттем һәм Барыйның «бөек күчеш»ен күз алдына китерергә күпме генә тырышсам да, барып чыкмады, мин буталып кына беттем бугай. Ләкин кызык нәрсә: башта кырыкмаса кырык төрле уй-фикер яки фаразлар диикме, йә аны нинди дә булса хәлгә, күренешкә бәяләмә дип атыйбызмы,— барысы да үз вакыты җиткәч, барыбер мәгънәви калыпка салына икән. Син йә тагын бер мәртәбә арба тәгәрмәче «уйлап табасың», яисә ул синең үзеңнең бәләкәйме, зурмы ачышың була. Үз ачышың!..

Бүгенге җәмгыятьнең үсешенә, андагы төрле-төрле һәм эреле-ваклы үзгәрешләргә табигать кануннарыннан тыш, тагын башка көчләр дә тәэсир итә, зур йогынты ясый түгелме соң?..

Әйтик, коммунизмның максаты да, милләтләрне уртак тагаракта болгатып, совет кешесе дигән соры масса «тудыру» иде бит!

«Туганнар! Тигезлек! Ирек!» лозунгысы да нәкъ шул максатка чакыра түгелме соң? Хәтта диннәрне дә юк итәргә өнди! Шуңа каршы явыз иблисне өстерә...

Гасыр капкасы ябылыр алдыннан, безнең татар милләтен салып бәйләгән «капчык»ның авызын ачып алдылар. Бераз һава керде. Иркен сулыш алып җибәрдек. Тик янә ныклап, каты итеп бәйләп куелды. Сулап калган һавабыз тагын күпмегә җитәр!

Ул «капчык» Рәсәй корсагы кебек тишек тә түгел, ичмаса. Һаваны шуннан булса да сулап торыр иде бу милләт!..

Хәер, кем әйтмешли, бу тормыш пессимист өчен трагедия, оптимист кешегә комедиядер инде...

...Барыбер мин, бер татар баласы, шуннан соң массоннар хакында тагын да ныграк кызыксына башладым. Әлбәттә, беләм: табигать кануннарына каршы баруның нәтиҗәсе соң чиктә һәлакәт белән бетәчәк! Ә шулай да масоннар феодализм чорыннан бирле яшәп килә бит әле?.. Исән-саулар, чәчәк аталар!..

Хәер, тагын шуны аңладым бугай (әлбәттә, үзем өчен): боларның серенә төшенми торып, алдынгы сыер савучыларның портретларын яки натюрмортлар ясаудан ары китә алмаячакмын!.. Мин... мин... мин моңа гына риза, канәгать түгелмен!

Бәлкем, татар масоны оештырыргадыр? Безнең халык та бөтен Җир шары буйлап сибелгән ләбаса!.. Һәм максат изге, гүзәл, якты, матур булырга тиеш!..

Һай! Янәшә үскән ике агачның да көчлерәге, көчсез күршесен узарга тырышып, тизрәк кояшка омтылырга тырыша шул!..

Әгәр уйлый китсәңме? Бер уйлый башласаң, әлләниләргә барып чыгасың! Әнә бит, теге чакта, Ивановны яклаганым өчен Соловьев миңа: «Шаһгалиле халык бит сез!» — дип үчен алды.

Йә, әйтеп кара син миңа Соловей туган: кайсы милләттә булмаган һәм хәзер дә юк соң ул шаһгалиләр?..

Кайсысында чын каһарманнары юк?! Йә, әйтеп кара!..

...Барый, авылларын тау башына күчергәнче, әүвәл андагы калкулыкка мәчет, чиркәү һәм синагога салдырам дигәч, аңа бу әңгәмә-чәкелешләр турында сөйләгән идем. Ул, кызыксынып китеп, масоннар хакында язылган китаплар да укып чыкты. Болай гына, үзем өчен генә дигән иде. Ай-һай, Барый дустым кызык өчен генә вакыт әрәм итеп, китап укып ятар микән, дип тә уйлап куйган идем. Хәер, белмәссең Барыйны!..

Тик әлегә Әкбәровта дөнья кайгысы түгел иде.

*** * ***

Барый саташмаган иде, Барый Әкбәров үз акылында һәм ул чынлап та кеше башлы, дөресрәге, бала башлы бүре күргән иде, аңын югалтып кырмыска оясы өстенә егылганда...

Бүре генә дә түгел әле... Бүре белән эт кушылмасы булган Пиратны һәм... һәм үзенең малае Әнвәрне...

Пират, чынлап та, бүре нәселеннән иде. Аның әнкәсе кайчандыр кыргый эт, әткәсе чын бүре иде. Пиратта кечкенәдән ике җан яшәде: аның берсе — урман-кырларын сагынып өзгәләнүче бүре җаны булса, икенчесе кешеләрне тансыклаган эт-җан иде. Эттән туган бүре баласы иде Пират...

Эт әнкәсе аны юеш карлы апрель аенда урманда дөньяга китерде. Энеләре-сеңелләре белән дүртәү иде алар. Ни сәбәпледер туганнарының икесе, җиде көн дигәндә, үлеп беттеләр. Алар бер кыз туганы белән генә калды. Дөньяга килгәннәренә егерме көн булды дигәндә,— май башлары иде ул,— өлкәннәр, аларны ояларында ялгыз калдырып, азык эзләп чыгып киттеләр. Ояны аучылар килеп тапты. Урманда бүреләр ишәйгән чак, хәтта кешеләргә дә һөҗүм итә башлаганнар иде. Аларны мылтыклы кешеләр, эт балалары дип алдап, икенче кешеләргә саттылар. Кыз туганы белән икесе бер хуҗада яши башладылар. Ләкин кыз туганы, сагынуга түзә алмады булса кирәк, бер атна эчендә дөньялыктан китеп барды. Ул ялгызы калды, әти-әнисез һәм туганнарсыз. Тууына егерме көннән артты дигәндә, хуҗа аны бер танышына зур акчага сатып җибәрде. Ул Барыйларга килеп эләкте.

Кешеләр арасында, эт тәрбиясендә яши башлагач, аның тамырларында атасы каны суына төшеп, әнкәсеннән килгән эт каны хакимлек итәргә кереште. Әмма барыбер холкы атасыныкы, ул башка этләр кебек һич кенә дә, кирәксә-кирәкмәсә дә, койрыгын болгап, кеше кубызына биергә теләмәде. Хәтта койрыгын да эт кебек өскә күтәреп йөрми, куе йонлы койрык күп вакыт асылынып тора.

Яңа хуҗасы Барыйга тиз ияләште Пират. Аны үз итте, яратты. Әмма чак кына үсә төшкәч, аларның аралары суынды. Хуҗа малай аннан цирк эте ясамакчы була, үзенчә әллә нинди һөнәрләргә өйрәтергә тели. Аны күршеләренең Сигнал кушаматлы чәңгелдек этеннән үрнәк алырга өнди. Имеш, ул хуҗа ташлаган таякны алып килеп бирергә, бөҗра аша сикереп чыгарга тиеш. Әлбәттә, ул бу эшләрнең барысын да күз ачып йомган арада башкара ала, тик бүре үҗәтлеге аңа буйсынырга ирек бирми, дөньяга килүенә өч ай тулды дигәндә, ул инде җитди эт — бүрегә әйләнгән, бала-чага уены аны һич кенә дә мавыктырмый иде.

Барый белән аралары бозылды. Сүзен тыңламагач, хуҗа малай аңа типкәли, таяк белән тондыра башлады. Түзде Пират, чөнки тамырында эт каны да ага һәм нәкъ менә шул нәрсә язмышына нәкъ эт кебек түземле булырга көч бирә иде бугай. Һәр түземлекнең ахыры була. Көннәрдән бер көнне, урманга баргач, Пиратта йокымсырап яшәгән бүре җаны уянып, ул үзен яңадан тугандай хис итте. Ул хәзер монда, үзенең туган урманында, гел таяк белән кизәнеп торган усал хуҗага буйсынмаячак, ул урманнан яклау таба алачагына өметләнә, бүре җаны аңа кыюлык бирә иде. Барыйдан чираттагы каеш эләккәч, Пират аны-моны уйлап тормады, арырак чыбып китеп, урман куелыгына кереп югалды.

Урман буйлап ике-өч көн ачтан тилмереп йөрде ул. Кешеләр янында яшәгәнлектән, анда эт геннары да өстенлек итә, ул урманда тереклек итәргә әзер түгел; зур куе урман, андагы агач ботакларының җил искән саен шартлап сынуы, төнге көннәрнең ямьсез тавышлары аны куркыта; эт булып бәйдә яши башлагач, койрыгы чак кына өскә күтәрелә башлаган иде, хәзер, кыска гына вакыт арасында, куркыныч урманда койрык нәкъ атасыныкына охшый башлады — салынып төште; әллә куркудан йонлач койрыгын үзе шулай бот арасына кыстырырга гадәтләнеп китте инде...

Бүре туганнары белән очрашып, аралашып китү дә җиңел генә булмады. Әмма ул очрашу котылгысыз иде. Ләкин ничек кабул итәрләр бит һәм кабул итәрләрме әле?

Пират, өченче көн дигәндә, борынына җил белән килеп бәрелгән ят ис тоеп, сагаеп калды, алай гына да түгел, җаны тәмам шиңеп-шәлперәеп, ул өнсез булды һәм куркудан дерелдәгән гәүдәсен куаклар арасына яшерергә ашыкты, җиргә сеңеп бетте, кызганыч тавыш белән еламсырап та карады, әмма курку аны ташлап китәргә ашыкмый, ул һаман дер-дер килде, күзләре яшьләнеп, авызыннан бер өзлексез селәгәе акты. Борыны янәшәдә генә бүре исен сизгән иде.

Бичара Пиратның болай да мескен башына ишелеп төшкән кайгысы, эт җанындагы коточкыч курку хисе аны өченче көн изеп, сытып тора иде инде. Янәшәдә бүре барлыгын сизү әлеге куркуны бермә-бер көчәйтеп, аны тәмам эштән чыгарды, ул, соңгы көчен җыеп, гәүдәсендәге эт җанын саклап калырга тырышты. Ләкин эт җаны мондый курку халәтен күтәрә алмады: Пиратның гәүдәсеннән суырылып чыкты да, куе нарат ботаклары арасыннан үзенә юл табып, күккә ашты. Һәм шул мизгелдә үк Пират үз гәүдәсендә икенче бер төрле җанның — бүре җанының уянуын тойды: аңа рәхәт булып китте, гәүдәсе калтыраудан туктады, аякланып, куак арасыннан аланга чыкты һәм, нәкъ чын бүре кебек, куе ябалдашлы чыршы агачы очына карап, улап җибәрде.

Дүрт-биш айлык бүре баласы белән алар нәкъ шул аланда күзгә-күз очраштылар. Гәүдәсенә яңа гына иңгән бүре җаны куркусыз булса да, мондый шартларга ияләнмәгәч, кыюсызрак иде әле. Шулай да яшь бүрене горур кыяфәт белән каршы алды. Алар беркавым алан уртасында

бер-берсенә сынап карап тынсыз тордылар. Пиратның койрыгы ялгыш бер мизгелгә генә өскә күтәрелеп алды. Яшь бүрегә шул җитә калды, ул, аны эт дип кабул итеп, бүре-этнең өстенә ташланды. Пират яртылаш кына бүре кавеменнән булса да, эт акыллары булу аңа әлеге сугышта зур өстенлек бирде, ул яшь бүрене аландагы чәчәкләр өстендә ауната-ауната кыйнады, аннан соң, истәлек өчен дигәндәй, кырт итеп сул колак очын тешләп үлән арасына төкерде.

Аларны, канга баткан ике сугыш чукмарын, ана бүре килеп аралады. Бу бүре үзе дә бүре генә булмыйча, яртылаш кыргый эт кавеменнән һәм ул Пиратны дөньяга тудырган Ана да иде.

Танышу һәм бүре өеренә кушылып китү әнә шулай тәмамланды.

Ул вакытта урман кешеләр тарафыннан таланмаган һәм зур куе урманда азык табу да кыен эш түгел, шуңа күрә бүреләр интегеп яшәмәделәр һәм (мәсәлән, аерым очракларны искә алмаганда — көтүдән аерылган сарыкларга һөҗүм итү) янәшәдәге авылларга да зур бәла-казалар китермәделәр.

Пиратның эт-җаны күккә ашып өлгермәгән, мөгаен, ул озын агач ботагына гына эленеп калган булгандыр, чөнки беркавымнан әлеге җан, аның үзенә кире әйләнеп кайтып, бүре җаны белән янәшә оялады.

Шуңа күрә Пират вакыт-вакыт моңсулана һәм кешеләрне дә сагынгалап куя. Беркөнне, әнкәсеннән аерылып калган колынны күргәч, ул нишләргә белмәде, шул чакта ничек сөенүләрен күрсәгез иде икән аның! Ул колын белән уйнап чак кына булса да сагыну-сагышларын басарга теләде бугай, тай янына якынрак килде, аякларын кытыкларга теләде. Әлбәттә, колын моны уен гына дип кабул итә алмады, куркуыннан ачыргаланып кешнәде дә арт аяклары турысында кайнашкан бүрегә инстинкт буенча тибеп җибәрде; аны-моны абайламаган һәм мондый һөҗүмне көтмәгән эттән туган бүре чалкан әйләнеп төште. Алар ауга китек колак белән икесе чыкканнар иде. Агачлар артында яшеренеп, сыйланырга уйлап торган китек колак, әлеге хәлне күреп, колынның бугазына барып ябышты. Аларның кешеләргә беренче мәртәбә зыян салуы иде бу.

Еллар үтә торды, Пират тәмам чын бүрегә әйләнеп калса да, җанындагы этлек һаман аны ташлап китмәгән һәм ул ара-тирә барыбер кешеләрне юксына, ләкин хәзер алардан курка, бигрәк тә тәгәрмәчле һәм яман тавыш белән бар урманның котын алып тырылдаучы үзйөрешле тимер өйләреннән коты алына. Өстәвенә торган саен урмандагы агачлар да сирәгәя һәм шул сәбәпле элеккеге куе урман эченә кояш иялəшә башлады.

Көннәрдән бер көнне ул шул рәвешле кешеләрдән бераз шүрләп тә, аларны чак кына сагынып та урман буенча киләп сарып йөргәндә, урман каравылчысы йортына барып чыкты һәм... өйдән шактый читтә уйнап йөргән нәни кешегә юлыкты. Куанычыннан Пират эт булып өреп куйды һәм курка-курка әлеге бала янына якынлашты. Нәни кеше аннан курыкмады, киресенчә, кечкенә кулларын сузды, үз янына уйнарга чакырды, кесәсеннән баллы прәннек алып алдына ташлады.

Алар беркавым дөньяларын онытып уйнадылар. Тик берзаман кыр ягыннан чатыр-потыр килгән яман тавыш ишетелә башлады. Бу кешеләрнең урманны кыра торган үзйөрешле өйләре иде. Пират, аны күргәч, гел тизрәк качу ягын карый иде. Әлеге афәттән кеше баласын да йолып калырга уйлап, аны киеменнән өләктерде дә урман ешлыгына кереп югалды.

Тешләре белән нәни кешенең күлмәген өләктереп, шактый ара узды Пират. Бу рәвешле бару үзенә дә уңайсыз булганга күрә, тиз талчыкты. Нәни кешегә дә рәхәт түгеллеген сизә иде эт-җан. Бер аланлыкка җиткәч, иплəп кенә куе үлән өстенә салды. Борыны белән төрткәләп-төрткәләп аягына бастырды. Шулчак алар туктаган җиләкле аланның икенче ягында зур кеше пәйда булды. Үлән арасында басып торган малайның башы, олпат бүренең гәүдә өлеше кешегә аермачак булып күренде.

Пират, нәни кешесен җәһәт кенә өләктерде дә, бәладән башаяк дигәндәй, агачлар арасына кереп югалды.

## Барый Әкбәров кара мәчедән курка

Колхозны үземнең этидән алып калдым: өлкән Әкбәров пенсиягә китте, мине, аның малае Барыйны, авыл хуҗалыгы институтының соңгы курсын тәмамлап, кулга диплом алуга үзебезнең Байтимердә «Ленин юлы» колхозының рәисе итеп сайладылар... Куйдылар, билгеләделәр дисәк тагын да дөресрәк булыр.

Мин, яшь рәис Барый Әкбәров, эшне колхозның исемен үзгәртүдән башладым, чөнки хәзер берәү дә «Ленин бабай юлыннан» бармый, ул сакау яһүднең сызган юлыннан без күптән тайпылышып беттек.

Эш анда гына да түгел. Инде канга «перестройка» аңы сеңеп, ул шунда эрегән, үзгәртеп коруның үзе кебек, кан белән буталып бетеп, бер булган һәм үземне замана җитәкчесе итеп хис итәргә гадәтләнгән идем инде. Колхозга «Кукуруз» дигән исем кушып, аның хуҗалык итү формасын да үзгәрттем: җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять булды ул. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Республика буенча бердәнбер экспериментль хуҗалык! Үзебезчә, ягъни урысча итеп әйткәндә, ООО була (общество ограниченной ответственности) инде бу...

Әлбәттә, эти һәм аның зур урындагы танышлары булмаса, теләсә нәрсә кыланырга миңа берәү дә рөхсәт бирмәс иде. Әтинең якын дусты Хәниф Хатыйпович, колхозга «Кукуруз» дип исем кушам дигәч, имтихан алган кебек маңгай астыннан миңа сөзеп карап:

— Нәрсә ул кукуруза? Хәзер үк шуңа аңлатма бирә алсаң, молодец буласың! — диде.

Сизеп, тоеп торам: нәкъ шушы минутларда минем колхозның исеме хәл ителәчәк. Хәниф Хатыйпович эти белән бераз кызып алырга да өлгергәннәр иде инде.

Безнең Байтимер Казан артында гына бит, турыдан машина белән утыз биш минутлык юл. Урман эчендәге Умырзая күле буенда этинең,— төгәлрәге, колхозның инде,— умарта бакчасы һәм ике төрле мунчасы бар: берсе ак мунча, икенчесе юкә бурасыннан махсус эшләнгән кара мунча. Эшеннән туеп, Казаннан бик арыган чакларында Хәниф Хатыйпович безгә ял итәргә килә иде. Хәтерлим, мин яшүсмер чакта ул еш кына хатынын — исеме дә тел очымда гына тора инде... Әйе шул, Сиринә атлы каратутлы ханым иде. Ияртеп килә иде. Соңгы елларда шоферы белән икесе генә йөриләр. Кайчакта дусларын да иярттә. Ялгыз башы килгән чакта, этинең удмурт авылындагы бригадиры Николай Михайлыч мунчаны һәрвакыт зәңгәр күзле, чибәр ар кызы Наташага яктыра иде.

Хәниф Хатыйпович бу юлы да үзе генә килгән. Наташа кара мунчага су ташый. Хәниф Хатыйпович белән эти күләгә астындагы беседкада корт балыннан коелган салкын эчемлектән авыз итеп утыралар.

— Кукурузмы? — дидем, сорауны кабатлап.— Бер өйләләр семьялыгыннан, орлыклары чәкән формасында булган юан, озын сабаклы, кыяк яфраклы берьеллык үлән үсемлек! — дип чатылдатып җавап та бирдем. Хатыйпычның күзләре маңгаена менеп, кулындагы чәркәсенә чаклы чайпалып куйды һәм сары сыеклык, аның ак, төссез йонлы ботына түгелеп, озын балаклы трусигы эченә агып кереп китте. Әллә шул галәмәттән, әллә инде кыю һәм төгәл җавапка шаккатып, ул эскәмиядән үк сикереп торды:

— Ну, молодец, ну, майттвай! Акберыч! Күрдеңме, яшьләр нинди грамотный хәзер, ә! Да, болар кулына колхозны гына түгел, районны да ышанып тапшырырга була! Районны гына түгел, хәтта, хәтта... Хәниф Хатыйпович Республика дип тә өстәмәкче иде, ләкин вакытында тукталып кала белеп, «кһым» дип тамагын гына кырып куйды.

Әйе, республика аларның үзләренә кирәк иде шул әлегесен...

Ләкин ни әйтсәң дә, умарталыкта колхозның исеме хәл ителде, «Ленин юлы»ннан ул «Кукуруз» булып үзгәртелде. «Кукуруз» якын арада бу төбәктә булачак зур үзгәрешләргә ишарә, хәтта шуның символы да кебек иде. Тарих кабатлана бит ул...

Капылт кына исем үзгәртергә рөхсәт биргәч, колхозның һәм аңа кергән биш авылның астын өскә китерәм дисәм дә, түрәләрнең ризалыгын аласына ышандым хәзер. Һәм бу ышанычым һәр гамәлемдә көч биреп, рухландырып торырга тиеш иде. Шулай булмаса, бу заманда башыңны ташка орсаң орырсың, әмма җүнле эш кырырмын димә. Авыл хуҗалыгы турында атлаган саен чыгып торган мәгънәсез законнар, күрсәтмәләр, эт эчәгесе кебек, аякка уралудан бүтән бер нәрсәгә ярамыйлар. Шундый замана килде ки, әгәр баш шөрепләреңне кыймылдатырга иренмәсәң, теләгән һәрнәрсәгә дә ирешергә мөмкин.

Кайчан тәртип булыр икән соң бездә?! Һәм аннары нәрсә соң әле ул «тәртип»? Ул ничек була икән соң?..

Бөтен максатым хуҗалыкны компьютерлаштыру. Һәр сыерның уң арт аягына датчик куячакмын. Савым сыерын компьютер ныклы күзәтү астында тотачак. Әгәр ул ун тоннадан да кимрәк сөт бирә икән, аны колбасага җибәрүең файдалырак булачак. Колхоз тракторлары соляркага коргаксып яткан заманда компьютер дип авыз ачу сәеррәк яңгырый инде, әлбәттә. Яңгырасын. Акча табарга кырыкмаса кырык төрле җаем бар. Мин бу рәвешле бернинди җинаять тә кылмыйм. Бары урыннан кузгалып китәргә этәргеч өчен генә ул. Аннан соң минем «Кукуруз» аны уны белән кайтарачак бит.

Мин тик тора торган кеше түгел. Әүвәл гектарыннан шуның чаклы уңыш алдым, һәр сыердан шулчаклы сөт дип лаф органчы, хуҗалыкны төптән ныгытырга уйладым. Бу ныгыту эше, әлбәттә, үзгәртеп корулардан башланырга тиеш иде. Әти карт үпкәләмәс, чөнки ни булса да майтарган саен: «Әти, синең киңәшсез булмый. Шулай итсәм, ничек уйлыйсың?» — дигән булып, аның салпы ягына гел салам кыстырып торам. Беренчедән, әтине әти буларак үпкәләтергә ярамаса, тагын икенче ягы да бар әле аның: Казандагы түрәләр әтинең җан дуслары. Түрә дигәч тә, аларның да кара мунчада яки ак мунчада чабынасылары килмимени! Анысыннан да бигрәк, урман эчендә бит, галәмәт аулак җирдә. Ә корт балыннан койган медовуханы исә мари карты умартачы Бачли (чын исеме — Василий бугай) хан заманындагы рецепт белән әзерли. Аннан соң мунча ягучы зәп-зәңгәр күзле ар һәм чирмеш кызларын кар өстеннән төртеп чыккан гүзәл умырзаялардан аера алмассың!

Хәер, Казан түрәләре һәрвакыт «умырзая җыярга» гына килә дисәм, сүзләрем хата булыр. Минем сымак малайларын ияртеп, ауга да еш йөри алар безнең якларга. Аннан соң әти Тәбәнәк тау дип аталган уйсулыкта,— ул галәмәт зур урман аланлыгында, анда мүк арасыннан бихисап чишмәләр тибеп ята,— балык күле ясатып, карплар да җибәрттерде. Димәк, кунаклар балыкка дип тә киләләр булып чыга. Әнә шуларның үзем кебек шыртлака малайлары белән куян, төлке артыннан куып арыган чакларда, дөньябызны онытып, балык та тотабыз. Кыскасы, Казан кунаклары килгән көннәр минем өчен зур бәйрәм була иде. Әти — акыллы кеше — алдан күрә белгән икән: ул малайлар белән аралашу киләчәктә минем өчен зур мөмкинлекләр ачачак, һәм урыннарында аталарын алыштырган балачак дусларымның ике кат ишекле кабинетларына шакымыйча да керә алачак идем. Вакыт аяусыз: күз ачып йомган арада буыннарны алыштыра да куя. Кичә — атасы, бүген — баласы.

Әти «Ленин юлы» хуҗалыгының урмандагы «фазенда»сына гел мине ияртеп бара иде. Һади абый яшькә зуррак, акыллырак булса да, ул аны андый бәйрәмнәргә катнаштырмады. Хәер, баштарак абыйны да ияртеп иярткән иде. Әле мин бөтенләй бәләкәй чакта ук. Һәм ул бар эшне дә бозып ташлаган бугай. Сөйләүләренә караганда, бер яшьрәк түрә атна саен килә башлаган. Һәр килүендә үзе белән яңа кыз-хатын ияртә икән. Һади абый, — бигрәк беркатлы инде ул безнең,— әлеге түрәнең чираттагы килүендә сорап куймасынмы: «Абый, син мулла булып эшлисеңме әллә! Әллә бүген өченче хатының белән киләсең инде?» Санап барган икән, бахыр... Шуннан соң ни булганын күз алдына китерәсезме инде?

Андый чакларда Мөхәммәт дустымны да ияртми идем. Әти кушмый.

Читкәрәк киттем бугай, хәерлегә булсын. Сүзем ничек итеп әтидән колхоз дилбегәсен алып калу турында иде бит әле. Әйе, мин эшне колхозның исемен үзгәртүдән һәм... хосусыйлаштырудан башлап җибәрдем. Бу адымга үзенең «приватизация» сәясәте белән Мәскәү түрәләренә дә этәргеч бирде. Өстәгеләр ни эшли — астагылар шулай кылана. Хәтта берничә мәртәбә арттырып ук җибәрә. Әти әйтмешли, тегеләр таякны бөгеп кенә күрсәтә, болары, ягъни «безнең белән бер чыбыкка кунып сайрый торган» җитәкчеләр, ул таякны шартлатып сындырып та куя...

Әлбәттә, урман эчендәге күлдә бергәләшеп балык тоткан малайлар булмаса,— алар хәзер зур җитәкчеләр,— колхоз чаклы колхоздан шәхси милек ясап булмый иде. Без бергәләшеп авыл хуҗалыгына яңалык кертергә уйладык. Сабакташым Мөхәммәт бер акыллы башның сүзләрен кабатларга ярата: «Рәсәйдә йә революция, йә ачлык!..» Без дә эш күрсәтергә, ягъни «революция» ясарга ният кордык. Шулай итеп, миңа әтидән калган колхоз «Кукуруза» исемендәге җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы булачак! Әлегесен моны халыкка әйтмим. Белеп торам: күпчелек аяк терәп каршы киләчәк. Халык бездә үзенчәлекле һәм кире. Байтимердә гел татарлар гына яши. Чудрасала авылында — марилар, Нырыяда — удмуртлар, Грибники исә — урыс авылы. Дөрес, урыс авылының авыл диярлеге калмаган инде. Алтмыш алты хуҗалыкның яртысыннан күбрәгенең капкасына йозак эленгән. Алар, җиңел тормыш эзләп, Казанга китеп беттеләр. Ташсу буенда ук тагын бер авыл бар, кыш көне анда каравылчы белән эте генә яши. Җәй җитүгә, Казаннан унбиш яһүд гаиләсе кайтып тора. Үзләренең әйтүләренә караганда, алар бу җирләрдә моннан ике мең ел элек яши башлаганнар, имеш. Мин үзем тарихчы булмасам да, беләм: Казан артындагы бу авыллар (татар авыллары — нугай белән кыпчак кушылмасы. Нугайлык төс-кыяфәтләрендә сакланса, кыпчак-мишәрлек сөйләмнәрендә ярылып ята. «Ч»ны «ц» хәрефенә охшатып һәм, гомумән, болай каты итеп безнең якта гына әйтәләр... һәм тагын мишәрләр инде) уналтынчы гасырда гына барлыкка килгән. Иван Грозный татарларны Казаннан 40 — 50 чакрым еракка сөргән. Ә яһүдләр монда ике мең ел элек нигез

салган, имеш. Дарвин, кеше маймылдан килеп чыккан дип, бик нык хаталанган булгандыр, бахыр. Без барыбыз да яһүдләрдән килеп чыкканбыз, ахрысы, маймыллардан түгел...

Шулай җиңел кулдан гына башланып китәр төсле иде бу эшләр. Ләкин көн саен яңа мәшәкать, вак-төяк ыгы-зыгысы туа да тора. Гаҗәеп үзенчәлекле, сәер халык яши бу якта дидем бит инде: татарлары ат урынына эшли һәм эт кебек урлаша, удмуртлар көмешкә мичкәсендә коена, урыслары шәһәргә шылды, монда калганы эшкә яраксыз исерек мари халкы урманда гөмбә җыюдан һәм балыктан кайтып керми, яһүдләре исә «курортка» гына килә. Менә шулар белән алып барып кара син колхозны! Әтинең башында кырык биш яшендә ни сәбәпле бер тотам кара чәче дә калмаганлыгын аңлыйм мин хәзер. Ләкин мин эшне башкачарак оештырып җибәрдем. Удмурт кызлары егет-җилән күрмичә зар елый, кияүгә чыга алмыйча интегәләр, һәм һәркайсы да бары тик шул сәбәпле генә шәһәр ягына каермакчы була. Чөнки үз авылы егетләре көн-төн көмешкә чөмерә. Уйладым, уйладым да Байтимер белән Нырыя арасына зур итеп клуб салдырып куйдым. Авыл аралары нибары бер чакрым гына. Хәзер ул уртак клубта татар егетләре гармун тарта, ар кызлары типтереп бииләр. Берәүгә дә күңелсез түгел. Кызлар шуннан гына туп-туры иртәнге савымга, егетләр басуга китә. Өстәвенә удмурт авылына бригадир итеп татар кешесен куйдым. Өйләнмәгән яшь егет иде. Фердинат атлы малаем шундук Пирдинат Пәритовичка әйләнде дә куйды. Җитмәсә, матур гына бер ар кызына өйләнеп тә җибәрде.

Байтимердә бригадир итеп урыс кешесе Иван Михайловичны билгеләдем. Элеккеге трактористны, моңарчы мунчага кергәндә дә күн итеген салырга иренгән Михалычны күрсәгез сез хәзер! Министрмыни! Сөйләшүе генә түгел, нечкә тавышына хәтле калынайды. Нәчәлник булу килешә икән үзенә! Мариларда бригадир булып ар хатыны эшли. Моңарчы унбер бала табып, кояш йөзен дә күрмичә, өендә чаршау артында гына яткан кырык яшьлек Настя яше буенча егермегә төште дә китте. Ире өендә балалар карап утыра.

Бу «кадровой перестройка»ларның уңай нәтиҗәсе дә күп, тискәре яклары да булгалый. Ни чыкса һаман да шул татарлардан чыга инде. Узган атнада гына удмурт авылы бригадиры Фердинатны чак кына рәшәткә артына утырудан йолып калдым. Егетнең кылган эшләре үзе бер вакыйга. Удмуртлар арасында матур гына эшләп киткән иде егетем. Ар кызына өйләнеп җибәргәч, аны тагын да үз иттеләр. Тик егетнең бер «кимчелекле» ягы бар: аракы эчми. Әлбәттә, егетнең бу «һөнәр»не белмәве халыкка ошап бетми инде. Үзләре кебек булмагач, берзаманны аны өнәми дә, сүзен дә тыңламый башлыйлар. Нишлисең инде, йә дөньяны үзгәртәсең, йә булмаса, үзең үзгәрәсең. Өченче юлы юк. Егетебез үзе үзгәрергә була һәм капкалый башлый. Эшләр дә көйләнә төшә кебек, авторитет та үсә. Ләкин егет каршында көтелмәгән тагын бер каршылык калкып чыга: киявенең эчүенә каенанасы каршы. Ник дисәң, кияү балакай бүтәннәр кебек көмешкә эчми, кибет аракысын гына эчә икән. Ә бу нәрсә күп чыгымнар белән бәйләнгән, чөнки көн саен бит ул. Берәр шешәдән исәпләп карасаң да...

— Аптарititы булмаса булмас, Пирдинатны эчүдән биздерик, кызым,— ди каенана беркөнне кызына.

— Ничек итеп?

— Аракчинода бер карчык бар. Шул бер зәһмәт сыеклык әзерли икән. Бу сыеклыкны эчә торган аракыга җиде тамчы итеп тамызсаң, кеше бөтенләй бизә,— ди.

Әлеге сөйләшүне кияүнең бабасы да ишетеп торган һәм серне нәчәлник кияүгә чишкән. Менә беркөнне Нина түтәй Аракчинога дип чыгып китә. Кич кияү эштән кайтуга мул итеп табын әзерлиләр, өстәл өстенә кибет аракысы утырталар. Нина түтәй кияүне ишектән тәмле телләре белән үзе каршы ала. «Әйдә, кияү, кулларыңны ю да өстәл янына рәхим ит. Эшеңнән бик арып кайткансыңдыр»,— дип, бертуктаусыз сөйләнә үзе. Кияү балакай да Шомбай кебек хәйләкәр: ыштан бавына бер урыс малаен кыстырып кайткан була һәм, тегеләр күрмәгәндә генә, өстәл өстендәгесе белән алыштыра да куя. Менә хатыны белән әбисе кияүне кыстарга керешәләр. Эһ тә итмичә бер стаканны каплап куя кияү балакай, икенчесен... һәм берзаманны тиктомалдан, каенанасына карап, эт булып өрә башлый! Нина түтәйнең коты алына, зәхмәт салынган аракы кияүне кешелегеннән яздырды, кеше хәтле кешедән эт ясады, дип, коты ботына төшә карчыкның. Кияү, һау-һаулап өрә-өрә, каенанасына ташлана. Тегесе аннан кача, тоттырмаска тырыша. Аптыраган карчык куркуыннан карават астына качып котылмакчы була. Кызып киткән кияү-эт тә шунда томырыла һәм, карават астына башын тыгып, әбинең йомшак җиреннән тешләп тә ала. Әби-карчык, коты алынудан шундук җан тәслим кыла, куркуыннан йөрәге ярылган була бичараның...

Шулар белән эшләп кара син менә. Үз башың Себер китәр...

Ләкин вакыт узган саен, мин каешлана барам. Иртән-иртүк ферма мөдире исерек булса, аны тагаракка салып, кабыргалары сынганчы тукмыйм, басуда угры-бур тотсам, алып кайтып барган салам-печәненә тәмәке төпчеге ыргытам — ул шундук көлгә әйләнә. Урманда гөмбә җыйган мари, ар кызларын күрсәм, ул көнне, һичшиксез, берәр кырмыска оясы тузгый инде.

Халык мине ярата. Колхоз паркын яңа техника белән тутырдым. Ай саен хезмәт хакын түлим. Икмәген, салам-печәнен, хәтта корылык елны да җитәрлек итеп бирдем. Бригадалар арасында асфальт юллар салдырдым, җимерек күперләрне яңарттым. Яңа клубны әйттем бугай инде.

Әллә халык курка гына микән?.. Хәер, анысы да юк түгелдер. Рәсәй халкы белән җитәкчелек итү рәхәт ул. Безнең халык сарык көтүе кебек, әүвәл, чыбыркы шартлатып, аның котын аласың, аннары, башыннан сыйпап, ипи каптырасың. Кызганам мин бу халыкны. Шул исәптән үземне дә... Һай, канын чистартасы иде безнең милләтнең! Элек шәп, затлы кан булган бит ул! Хәзер бозылган, сыеклана башлаган...

Ә мин үзем бары тик кара мәчедән генә куркам. Ике мәртәбә урман юлында кара мәче юлымны кисте. Беренчесендә малаемның югалганын белдем. Икенче юлы кеше башлы бүре очраттым... Язмышмы бу? Ул язмыш дигәннәренең борынымнан сөйрәп үз артыннан йөртүеме, әллә үзем гел аның артына тибеп тораммы соң?

Хәер, киләчәк күрсәтер... Кем әйтмешли, рожденные ползать летать не умеют. Әнигә рәхмәт: ул мине, нәкъ шундый малайны тапкан. Әтигә рәхмәт: миңа түш белән шуышырга туры килмәде. Әлегесен... Хәер, бар нәрсә дә үземнән тора. Мин әнә шул хакыйкатьне аңлап, аны үземнең акылыма сеңдерә алдым. Кара мәчедән куркуым исә ул без яшәгән җәмгыятьнең тотрыксыз булуыннан гына килә. Иртәгә нәрсә буласын бу илдә беркем дә белми. Иртәгесе өчен ишәк кайгырсын, диләр диюен дә... Ләкин минем ишәк буласым килми!..

## Язмыш яры текә була

Гөлчәчәк хакында Барыйдан бик сорыйсы килсә дә, Мөхәммәтнең теле әйләнмәде. Хәер, бу турыда авыз ачарга башка вакытта да җөрьәт итә алмас иде. Иң яхшысы: Гөлчәчәкнең үзе белән сөйләшү.

Мөхәммәт Гөлчәчәк янына кайтырга җыенды.

Ләкин планнар бу юлы да җимерелеп төште. Күрәсең, Гөлчәчәк белән күрешү тиз арада гына насыйп булмагандыр инде. Ул, Барыйны озатып, хастаханәдән кайтып кергәндә, ишегенә язу кыстырылган иде. «Кайтуга, миңа килеп җит! Сиринә»,— диелгән. Мөхәммәт Мөштәри урамында узгынчы машинаны туктатты да Сиринә Самуиловна өенә юнәлде.

Ул килеп керүгә, Сиринә Самуиловна егеткә, кыланып, кул биреп күрештe дә, яшь кызлар кебек җиңеләеп, битеннән үбеп алды һәм, кулын һаман әле җибәрмичә, залга әйдәде. Диванда йокымсырап яткан песи, тавышка уянып, иренеп кенә күзләрен ачты да, каршында Мөхәммәт икәнлеген белгәч, үпкәләгән кыяфәт чыгарып, кухня ягына кереп китте. «Харап икән! Песи дә үпкәли белә!» — дип уйлый-уйлый, Мөхәммәт диванга песи урынына килеп утырды.

Сиринә Самуиловнага ни булган соң, нигә кош тоткандай йөри әле ул? Мөхәммәт, җавап эзләп, аның йөзенә текәлде: «Йә, сөйлә инде!» — ди иде аның сораулы карашы.

Сиринә Самуиловна бүген, чыннан да, яшь кызлар кыяфәтенә кергән: өстендә итәге тездән югары юка халат, чәч-башы да яшьләрчә фасон белән лакка катырылган, бүген битендәге иннек-кершән дә аеруча мул, күзгә бәрелеп тора, болай да озын кара керфекләре буяудан тагын да каралып киткән кебек. Чибәр, тагын да матур иде бүген Сиринә Самуиловна.

— Италиягә җыен. Синең загранпаспортыңның срогы чыкмаган бит әле?

— Чыкмаган,— диде Мөхәммәт, хатынның әлеге хәбәренә аптырап.

— Чыкмаса, әйбәт. Анда международный выставка була. Татарстаннан син генә. Россиядән барысы ике кеше. Икенчесе Мәскәү художнигы. Хәтерлисеңме узган ел Петербургта танышкан идек. Эрнст Козловский. Пейзажист.

— Хәтерлим,— диде һаман ис-һушын җыеп өлгермәгән Мөхәммәт.

— О-о-о-о! Син күрсәң иде ул! Теге ата кара таракан үз малаен исемлеккә кертү өчен ничек чабулады! Мәскәүләргә хәтле барып җиткән! Хәниф Хатыйповичка шалтыратып әйткән идем, шул сәгатьтә үк үзенә чакыртып эт иткән. Ярый, бог с ним! Искусствовед буларак, списокта мин дә бар, беләсең килсә!

Сиринә Самуиловна куанычыннан Мөхәммәтне муеннан ук кочаклап алды. Хатыннан гаҗәп тәмле хушбуй исе килә. Бите егетнең битенә орынып китте: кайнар, пешерә. Утын агачы кебек

утыру уңайсыз, җавап йөзеннән Сиринә Самуиловнаның иңбашына кул салу исә тагын да уңайсызрак. Утын агачы булмый хәлең дә юк, нишләрсең!.. Өстенлек Сиринә Самуиловна ягында иде. Ул чарасыз утырган егетнең салкын маңгайлы башын күкрәгенә кысты, ни арада халат төймәләре ычкындырылып өлгергән: Мөхәммәт борыны белән кайнар имиләр арасына төртелгәнен сизми дә калды; салкын маңгае кызыша башлады, моңарчы үз җаена, салмак кына типкән йөрәге урыннан кузгалды диярсең — бөтен күкрәк читлеген селкетә, чыгар урыны булса, кош булып ачык форточкадан атылыр иде дә һәм... һәм, әнә, теге каенга, тәрәзә каршындагы яшь каен ботагына кунып, өздереп-өздереп сайрап җибәрер иде...

Үпкәсе басылган ата мәче, ахрысы, ялгызлыктан туеп, зал якка кире кереп килә иде, диванның буш түгел икәнлеген күреп, башын боргалый-боргалый, беркавым диван өстенә элengән картинага карап торды да, әллә аның песи акылы берәр төрле этлек кылырга уйлады: ул хуҗасының идәндә яткан халатын тарткалады, йолыккалады да, моның бернинди дә кызык гамәл түгеллегенә инангач, тәрәзә төбенә сикереп менде һәм, күзләрен ялт-йолт уйнатып, ишегалдын күзәтергә кереште. Урамда үз ишләре күренми. Шуннан соң ул, нидер сизенеп, башын күтәрде һәм каршыдагы күп катлы йорт тарафына төбәлде. Бер тәрәзә төбендә аның күптәнге дусты, мияубикәсе, битен юып утыра, күрәсең, урамга чыгарга әзерләнә иде булса кирәк...

* * *

Яшьләре утызга чаклы булган рәссамнарның чит илдә узарга тиешле күргәзмәсе Мөхәммәт Уразовның тормышында бик зур борылыш ясарга тиеш, моны һәммә кеше дә аңлый һәм юкка гына: «Нигә Уразов? Нигә мин түгел?!» — дигән кара тавыш юкка гына чыкмаган иде. Шуңа күрә иртәгә китәсе дигән көнне дә әллә нинди көтелмәгән үзгәрешләр булырга мөмкинлеген Мөхәммәт үзе дә, Сиринә Самуиловна да чамалый, һәм икесе дә ул көннең тизрәк килеп җитүен түземсезлек белән көтәләр иде.

Китәсе көн тәгаен генә билгеле булмаса да, әлеге күргәзмәдә катнашуның гонорары долларда исәпләнгәнен белмәгән кеше юк иде. Калҗа бик майлы һәм дәрәҗәсе дә бик зур. Шуңа күрә күпләрнең йокысы качты. Берничә рәссам һәм сәнгать белгечләре, үз араларыннан делегация төзеп, Мәскәүгә чыгып чаптылар, чөнки Казанда Хәниф Хатыйповичны узып берни кылып булмый, аның сүзе исә катгый, ул үз фикерен әйткән иде инде.

Үзешчән делегация Мәскәүдә әллә ни эш кыра алмаса да, барыбер «сиңа да, миңа да булмасын» дигән максатларына ирештеләр: Татарстан исеменнән Италиягә барырга тиешле яшь рәссамны Мәскәүнең үзеннән табып кайттылар; Мөхәммәтнең яшьтәше, атасы ягыннан чыгышы буенча Бөгелмә егете Яков Крысин атлы егет алар тарафыннан Республика һәм Рәсәй данын якларга лаеклы дип табылды. Атасы тумышы белән Бөгелмәдән булгач, ул Татарстан исеменнән барырга тиеш иде. Халыкара күргәзмәдә катнашу өчен Мөхәммәт Уразовны артык провинциаль һәм әлегә чак кына җитлегеп бетмәгән, диделәр. Ни хәл итәрсең, демократик җәмгыять төзеп маташабыз, чиновник сүзенә карап, аңа ләббәйкә дип утыра торган заманалар күптән узды. Шуңа күрә рәссамнарны әйдәп баручы рухи лидер агай, минем малай катнашмагач, Уразовка да тәтемәсен дигән катгый һәм ныклы, алай гына да түгел, үз фикеренчә, гадел принциптан чыгып эш итәргә карар кылды. Демократия булгач, демократия булсын, әлеге мәсьәләне иҗат көчләренең гомуми җыелышы хәл кылырга тиеш һәм бары тик яшерен тавыш белән генә.

Иртәгә җыелыш буласы көнне рухи лидерны Хәниф Хатыйпович үзенә чакыртып алды, һәм кабинетта сүз кыска, әмма җитди булды:

— Синең малай Госсоветка кайсы районнан кандидат әле? — дип сорады Хәниф Хатыйпович. Тегесе район исемен атады.

— Ул районга тагын ике кандидат билгеләргә булдык әле.

Һәм Хәниф Хатыйпович әлеге кандидатларның исемнәрен атады, аларның берсе бик атаклы язучы, икенчесе бай эшмәкәр, зур заводның директоры иде.

— Ничек?! Алар белән көрәшеп булырлык түгел бит! Сез моны юри оештыргансыз!

— Ә иртәгә булачак җыелышны сез юри оештырмадыгызмы?

— Аңламадым, Хәниф Хатыйпович!

— Бик яхшы аңладың. Отмени җыелышыңны!

— Ничек? Белдерү элengән, халык белә бит инде.

— Көн тәртибен үзгәрт! Сезнең оешмага санаторийга бушлай ике путевка бар, җыелышта шуларны кемнәргә бирәсен хәл итегез. Аңлашылгандыр бит?

— Аңлашылды, Хәниф Хатыйпович, аңлашылды.

Шифаханәгә барырга тиешле кешеләрне икенче көнне иҗат көчләренең гомуми җыелышы көне буе хәл итте, чөнки лаеклы һәм сырхау кешеләр байтак, һәммәсенең барасы килә иде. Халык тәмам алҗып, инде «путевка» сүзен ишетәсе килми башлагач кына, соңгы чиктә җиңел юлы табылды: жирәбә салдылар. Һәм шуннан соң тавыш та тынды. Баштан ук шулай эшлиселәре калган икән!

Җыелыштан халык төркеме белән чыгып барганда, кемдер Мөхәммәтнең касыгына төртте. Кеше күп һәм барысы да янәшә булганлыктан, ул төртүченең кем икәнлеген абайламый калды. Шунысы хак: ул иптәшнең терсәге хәйран очлы булып чыкты — авырту озакка сузылды.

Астан һәм астыртын гына зурдан кубып пычагым да кыра алмагач, «терсәк төртү белән генә канәгатьләнәләр икән — бик хуш, күңелләре булып, тынычланып кына кала күрсеннәр!» — дип уйлады Мөхәммәт. Ләкин астыртын сугыш — терсәк сугышы моның белән генә тәмамланмаган, алда аның дәвамы булачак иде әле...

* * *

Чит илгә кайчан китәсе һаман ачыкланып бетмәде, дөресрәге, хәбәрләре һаман килеп җитми иде әле. Мөхәммәт Сиринә Самуиловнага авылга кайтып киләм, телефон аша хәбәрдә торырмын, диде дә үзе Ютазыга юл тотты.

Рәзифә авызыннан коелып калган гайбәт күңелен бертуктаусыз тырнап тора. Мөхәммәт шуннан бирле сәер халәттә яши, уйлый-уйлый да, берара һәммәсенә кулын селтәгәндәй: «Гөлчәчәк үз иркендә бит! Ничек тели, шулай яшәсен сәнә!» — ди. Ләкин ярата ич ул аны? Ярата-а-а! Кызык кына инде! Әгәр яратса, «Урман»ны сатарга риза булыр идеме соң? Чыннан да, бу сату гына да түгел, хәтта бу — сатылу! Хәлдән котылу юлын тапкан иде бит инде: тиз генә тотып, шул бәхетсез картинаң күчерелмәсен ясарга кирәк!.. Үз кулы белән язгач, хәтта күчермә генә дә булмый ич әле ул! Авторы үзе үк ләбаса!

Ләкин Рәзифә җиткергән хәбәр?.. Бәлки, ялгандыр ул? Берәр хәйлә, тозак кынадыр? Чөнки «Урман»ны алу өчен нинди көрәш бара: өстән дә, астан да (Барый, Сиринә Самуиловна) тынгылык бирмиләр. Имеш, ахыр чиктә ул картина аркасында Мәскәү түрәсенең хатынын, сәнгать белгечен үпкәләтү бер дә җүнлегә китермәячәк, дигән булалар... Ул имеш-мимешләрдән кырыкмаса кырык төрле фараз-маразлардан Мөхәммәт тәмам гарык инде.

Сиринә Самуиловна: «Миндә генә яшәп тор, үз фатирың остаханә булып калсын»,— ди. Сиринә Самуиловна, Сиринә апасы тугыз яшькә өлкәнрәк. Ләкин яшь аермасын белмәгән кеше әллә ни чамалап та бетермәс кебек. Сиринә, Америкада җиткән кызы булуга карамастан, үзе дә кызлар кебек. Каратутлы хатыннар тиз картаймый, диләр.

Ә яшь аермасы нәрсәгә соң сиңа! Ул акчаларга син бар тормышыңны көйләп җибәрә аласың: коттедж, машина, диңгез буендагы иҗат йортлары; авылда әти-әнинең өйләре җиргә чүгә башлаган, аннан соң әтисе, кайткан саен, Сибгат абыйның тракторы хакында авыз суларын корытып сөйли, үзенә дә шундый тәгәрмәч булдыру хакында хыяллана; бер апасы кияүдән аерылып кайтты, Казанда тулай торакта яшәп ята...

Гөлчәчәк!.. Гөлчәчәкнең гаебе үзендә бит! Мөхәммәт ничә еллар буе урман кызын шәһәргә алып китәм, рәсемдә генә булса да урман ясыйм дип хыялланып йөргәндә... Хыялланып кынамы?! Ул хыялы тормышка ашты: картина язылып бетте ич! Остаханә-фатирда гына булса да, тормышны башлап җибәрергә мөмкин бит инде канә!

Язмыш яры текә, аннан чамаламыйча гына сикерсәң, муеныңның шартлап сынуын көт тә тор.

Мөхәммәт көне-төне «Урман»ның күчермәсен язды. Көн саен Сиринә Самуиловна фатирында кунып йөрмәскә дә яхшы сәбәп иде бу. Мөхәммәт аңа: «Яңа картина язам. Төгәлләмичә күрсәтмим!» — диде.

Ләкин Сиринә төн уртасында булса да шалтыратып, таңга чаклы гына булса да килим инде, дип җелегенә тия. Хәер, җанына тияме икән соң? Ул аны Гөлчәчәктән аерырга уйламый ич! Ирсез хатынның төннәрен ничек уздырырга теләве — аның үз иркендә, яманлап та, кыек сүз әйтеп тә булмый. Хатын-кыз, нинди генә зур әхлаклы, саф-намуслы булса да, табигатькә каршы бара алмый, сау-сәламәт тәнендә-тамырларында уйнаган кайнар канны салкын су сибеп кенә суытып булмый!..

Хәер, хатын-кызның һәммәсенә дә мондый бәя бирергә аның ни хакы бар, башы яшь, үзе дә яшел бит әле...

Ә Гөлчәчәк!..

Ә Гөлчәчәк, гадәттәгечә, көннәрдән бер көнне килеп чыгар дип, Башкортстан чигендә аны көтеп яши иде. Ул теге вакытта, урманда, егетнең вәгъдәсен җитди рәвештә һич кенә дә кабул итмәгән иде. Ләкин егетнең бик үҗәтләнеп үз дигәнен итәргә,— әйтүенчә, картинасын язып тәмам кылу алдында,— йөрүе аның мәхәббәт учагына ялкын гына өсти һәм егерме биш яшькә җитеп килүе дә һич куркытмый иде. Мәхәббәт көтә белгәндә генә кадерле һәм газиз була икән ул лабаса! Әлбәттә, хәзер ул Мөхәммәткә: «Урманымны ташлап китмим!» — дигән шарт та куя алмаячак: урман таланып, мәсхәрәләнеп бетте. Урман каравылчысы булып торган Ярулла абзыйның бар эше, кешедән калган ботак-сатакларны җыеп, яндырып йөрү. Әнә Мөхәммәт, аның Мөхәммәте: «Синең урманыңны картинада булса гына да саклап калдым, Гөлчәчәк!» — ди. Рәхмәт сиңа, Мөхәммәт! Мин яратам сине, Мөхәммәт! Бик яратам!

Гөлчәчәкнең күңелендә,— быел җәй ахырларында булырмы, кыскасы, август ае җитеп, җиләк-җимешнең мул чагында,— өйләнешербез дигән өмет тә шытып килә иде.

Мөхәммәт Гөлчәчәк белән күрешүне бу рәвешле күз алдына һич тә китермәгән иде. Ютазыга кайтам дип ым кагуга, аның дус-таныш председателе «Волга»сын җибәргән иде, районның иң алдынгы хуҗалыгы җитәкчесенең зур портретын ясап бүләк иткән иде, икенче юлы Хәким Фаруковичның мөлаем хатыны Рәвия ханымны рәсемгә төшерергә вәгъдә итте.

Хәким Фарукович таң белән Казанга чыгып киткән машинасының кайчан кире әйләнеп кайтачагын чамалый иде, күрәсең: «Волга» Гөлчәчәк яшәгән йортның капка төбенә килеп җиткәндә, өйлә вакыты якынлашып килгән чак, үзе дә шунда Мөхәммәт кайтканын көтә иде.

Беренче мәртәбә генә түгел, Мөхәммәт белеп тора: Хәким Фарукович, яше белән алтмышка якынлашып килгән карт җитәкче, кунак Казанга кайтып киткәнче, аны күз уңыннан җибәрмәячәк, көн саен мунча яктырып, шашлык, шашлама һәм башка төрле ризыклар белән сыйлый-сыйлый, яратып кына әйтсәк, «теңкәсенә» тиячәк. Үзе шундый сәнгать җанлы кеше инде ул Хәким Фарукович. Әнә эш вакыты дип тормаган, хәер, аның колхоздагы эше майлаган кебек көйләнгән, үз җаена салынган, үзе әйтмешли, акыллы җитәкченең эше үзе булмаганда көйлерәк барырга тиеш, машинасын да Казанга чаклы куган, каршыларга да килеп җиткән.

Гөлчәчәк бу юлы, кеше бар дип тә тормады, мәктәптән кайтып килеше икән, Мөхәммәтнең муенына килеп асылынды. Башка чакта болай итми, кеше булмаса да, сагынуын йөзендә балкыган кояш нурларыннан гына аңлап була иде. Мөхәммәт аны үзе дә кочаклап алды. Хәким Фарукович көлә.

— Мәктәптә укулар да бетте. Үзеңнән калдырма инде син аны. Казанга алып кит. Апасын карарга кеше табарбыз,— диде ул, гадәттәгечә, аталарча кайгыртып. Мөхәммәткә дә берәр сүз кушарга кирәк инде кирәген югыйсә. Ләкин ул каушап калган, бик тырышса да, теленә кирәкле сүзләр килми, аптыраганнан, сүз булсын өчен генә: — Ютазы һавасы килешә икән сиңа! — дип, кызга комплимент әйтә.

Хәким Фарукович ниндидер сәбәп тапкан булып чыгып китте, ләкин тиздән әйләнеп киләчәген һәм алма бакчасында шашлык әзерләнүен әйтте.

— Бу юлы балык шашлыгы! — дип тә өстәп куйды. Мөхәммәтнең балык ратканын белә Хәким Фарукович, шуңа басым ясап әйтүе хәйләкәр картның.

Колхоз рәисе китеп бармаган булса, яхшырак булыр иде, бәлкем: Гөлчәчәк белән икесе генә калгач (әнисенең авыру апасы аерым бүлмәдә кузгала алмыйча ята, бусагадан атлауга, аның белән күрешеп чыккан иде инде), берара сәер тынлык урнашты. Мөхәммәт моны үзеннән күрде: Рәзифә җиткергән хәбәр һаман күңелен тырный, Гөлчәчәкнең үзе белән күрешкәч, әлеге җәрәхәт тагын ачылып киткәндәй булды, көнчелеге җанын суытып, сөйләшә алмас хәлгә китергән дип уйлады. Күңелендә кайнаган хисләрне вакытыннан алда Гөлчәчәккә сиздерәсе килмәде. Ләкин кызның күзләре дә үткен, күңеле дә сизгер, егеттәге үзгәрешне, үз-үзен тотышындагы сәерлекне тояр дип курыкты. Ләкин Гөлчәчәк аны-моны әйтмәде, чөнки күптән түгел генә аның үз җанына да тоз салганнар һәм шактый ук күңелсез хәбәр ишеткән дә, шул хакмы, юкмы дигән уй аны да берөзлексез борчый һәм ул аны яшерергә, белгертмәскә тырыша иде. Беркөнне, аны сорап, мәктәпкә шалтыраттылар. Казаннан. Ят ир-ат тавышы. «Мөхәммәт Уразов «Урман» картинасын сөяркәсенә бүләк иткән. Ул сине алдап кына йөри, имеш...» Гөлчәчәк бу хәбәргә ышанмады, дөресрәге, ышанмаска тырышты һәм әле дә тырыша, кыскасы, күңеле икеле-микеле, ул ныгытып кына ни дип уйларга да белми, бу хакта чынын үзеннән

ишетермен дип, Мөхәммәтнең кайтуын зарыгып көтте. Менә ул көн килеп тә җитте. Әмма тиктомалдан гына бу хакта сүз башлап та булмый. Мөхәммәтнең үпкәләп куюы бар.

Моңарчы сүзгә, сөйләшергә туймаган Гөлчәчәкне, икәү генә калгач, алыштырып куйдыларммыни! Мөхәммәтнең шөбһәсе көчәйде. Кыз нәрсәдер әйтмәкче дә була кебек, ләкин теле чишелеп китә алмый, күңел түрендәге нindiдер яшерен сер тирәли тик әйләнеп йөри, аны тышка чыгармый. Мөхәммәтнең Казаннан ук төяп кайткан шик-шөбһәләрен кызның әлеге халәте тагын да арттыра, аны талый иде.

Моңарчы, икәү генә калгач, Мөхәммәт кызга Казан хәлләрен, үзенең эше хакында, «Урман»ның ничек язылуы турында бертуктамый сөйли ала иде. Бу юлы егет үз эченә йомылган, күз карашына чаклы, моңарчы Гөлчәчәкне сөеп туймаган коңгырт күзләренә чаклы сынагандай бораулап карыйлар, әлеге гадәти булмаган карашны кыз бик авыр күтәрә һәм елап җибәрмичә чак кына тыелып тора иде.

Мөхәммәт үзе дә шундыйрак хәлдә. Әмма Рәзифәдән ишеткәнне,— гайбәтме ул, хак сүзме — анысы караңгы,— ничекләр итеп Гөлчәчәккә әйтмәк кирәк!

Мәхәббәт... Ярату, гашыйк булу адәм баласының йөрәген яшүсмер чакта гына җилкетеп, еллар өстенә еллар өстәлүдән хасил булган Вакыт, торган саен, читлектәге кош баласыдай бәргәләнгән, тасырдык йөрәкне тынычландырып, урынына утыртып куяр төсле иде ләбаса!.. Юк икән. Алай гына түгел икән!..

Ерактан торып сагыну үзенә бертөрле рәхәт: газаплы көткәнең тормышка ашып, ниһаять, күрешү минутлары килеп җитү тагын үзенчә татлы һәм... (юк, алай газаплы булырга тиеш түгел) була бит инде!..

Янып торган оятсыз күзле кара мәченең коерыгында бастырык буе гайбәт сөйрәлә... Акыллы кешеләр яхшы белә: ишеткәннәренең яртысына гына ышанырга кирәк. Ләкин бик акыллы кешеләр генә шуның кайсы яртысы хак икәнен аера алалар. Бер хатын-кыз әйткән бу сүзләрне. Мөхәммәт исә әлеге ярты өлешнең кайсысына ышанырга белмичә интегеп утыра. Шунысы хак: йөрәге, инде яшүсмерлек чоры күптән узып, һәрнәрсәне акыл иләге аша уздыру яшендә булуга карамастан, бар гайбәтләрдән дә өстен икәнлеген белгертеп тасырдый, ашкына Гөлчәчәккә тартыла...

Бу газаплардан аларны Хәким Фаруковичның шоферы килеп аралады: тиздән алма бакчасында шашлык әзер буласы һәм капка төбендә аларны машина көтә икән.

Вакытында хәл кыла алмыйча изаланган тормыш мәсьәләләрен киләчәккә калдырырга Мөхәммәт күнегеп беткән иде. Һәм бу дөрестән дә бик һәйбәт ысул, шулай итеп, моңарчы хаталанганы юк бугай әле. Бу юлы да алар арасында хасил булган соры томан пәрдәсен, бәлкем, Вакыт җилләре куып таратыр — аңлашуы җиңелрәк булыр, бәлки, ярдәмгә кояш нурлары килер, томанны аралар һәм бар нәрсә дә ачыкланыр, җайланыр...

«Матур хатын-кызлар беркайчан да үзләре генә булмыйлар, ләкин алар һәрвакыт ялгыз». «Әгәр дә ялгызлыктан куркасыз икән, өйләнмәгез». Беренче гыйбарәне кем әйткәндер — билгесез, дөресрәге, Мөхәммәт хәтерләми, ә соңгысы —Чехов сүзләре.

Ялгызмы соң ул, юкмы? Ул әле өйләнмәгән бит. Димәк... Ә Гөлчәчәк, матур, гүзәл зат, ялгызмы?

Чынлап та хыянәт иттеме икән Гөлчәчәк?!

Ә үзе?.. Рәзифә... Сиринә Самуиловна? Болары нәрсә? Хыянәтме, хыянәт түгелме? Хыянәт түгелдер, мөгаен, ул үзе... үз теләге белән түгел ләбаса! Язмышның текә ярында аякларын асылындырып утырган бер мәлдә, ул баскыч-баскыч уелган ярдан ялгыш нәкъ бер басмага түбән төште түгелме соң инде? Ир-ат белән хатын-кыз якынлыгы табигатьнең иң зур могҗизасы, җанвар-хайваннарда ул инстинкт дәрәҗәсендә генә диярлек, табигатьнең гаҗәеп зур сере түгелме соң? Шулай булса, ул, өйләнмәгән егет, әлеге сернең капкасын бернинди әзерлексез җиңел ачты һәм шул рәвешчә аның кадере кимеде, алай гына да түгел, өстәвенә күзгә күренеп торган бик нечкә кыллардан торган күңел дөньясы, әлеге хис-кыллары каешланырга, тупасланырга өлгерде ләбаса!

Шулай булдымыни: ул хәтта картинасын да сатып җибәрергә әзер бит! Әйе, әйе, берәү дә шыр надан түгел: Италиягә аны күзләре матур булган өчен генә җибәрмиләр, гәрчә монда Сиринә Самуиловнаның, хәзер инде Сиринә генә, тырышлыгы гаять зур булуга да карамастан... Ләкин бу бәладән котылып була сыман иде әле: күчермәнең эшен тизрәк тәмамларга кирәк. Мәскәү кунагы — сәнгать белгече, ул аңлар бәлкем.

...Казанга кайткач, төнге бердә телефон шалтырады. Сиринә Самуиловна икән, хәзер сиңа килеп җитәм, ди. Бу юлы Мөхәммәт канәгатьсезләнеп каш-күзен җимермәде, киресенчә, бу

минутларда Сиринә Самуиловна аңа бик кирәк. Ул сәнгать белгечен урамга чыгып каршы алды. Янәшәдәге төнге кафеда музыка дөберди. Йолдызлы күк сискәнеп-сискәнеп китә.

Сиринә Самуиловнаның сүзе катгый булды:

— Мәскәүләргә — оригинал! — диде матур хатын.— Синең кыргый урман кызың барыбер берни аңламаячак!

Сиринә Самуиловна ул кызны көндәш дип исәплиме, юкмы — белгән юк. Әмма ул үзенең көченә һәм һәр алышта да җиңеп чыгачагына нык ышана торган хатын.

Заманында бик үзсүзле һәм каткан коммунист җитәкче Хәниф Хатыйповичны да үз алдында тез чүктергән иде ул! Бу җиңүнең гомере кыска булды: алар икесе ике якка киттеләр. Уртак җимешләре — кызлары — Америкада укый. Бүген исә Хәниф белән дустанә мөнәсәбәттә яшиләр.

Ниндидер кыргый урман кызы аның өчен дулкын өстендәге йомычка гына!..

## Гөлчәчәк

Урманда үссәм дә, кыргый кыз түгел мин. Беренче сыйныфтан ук бүтәннәр белән бергә без дә мәктәптә укыдык ич, аралашып яшәдек, яраткан укытучыларыбыз, дус кызларыбыз да бар.

Урманда туып үссәк тә, Гөлйөзем белән икебез дә дөньяви кешеләр без. Нәкъ авыл кызлары кебек Кызылъяр чишмәсенә суга йөрдек, әти-әни, ни теләсәк, шуны алып кайтты: авыл кызлары кигән киемнәрне кидек, мәктәптә аларга куйган «ике»ләрне безгә дә куйдылар, «биш»ләрне без дә ала торган идек. Дөрес, гомеребезнең күп өлеше урманда үтте. Шуңа күрә Бурянның марҗа кызлары — сыйныфташларыбыз — безгә чак кына башкачарак карыйлар, әмма яраталар, һәркайсы безнең белән дуслашырга тели, безне үз итәләр; укытучыларыбыз исә, башкалардан аерып, безне бер башка өстен куялар, гомумән, гап-гади сыйныфташ кызларыбыз кебек үк булсак та, безгә карата бераз аерым караш булуын сизә идек. Ни дисәң дә, урманда үскән кызлар бит: усал аю-бүреләр һәм хәйләкәр төлкеләр патшалыгында.

Тик аерма шунда гына: берчак, буй үстергәч, Бурян кызлары да, Байтимернекеләр дә кичке уеннарга чыгалар, ә без өйдә утырабыз, китап укыйбыз һәм сандугач оялаган күңелләребезне килгән-киткән туган-тумачаның, кунак-фәләннең кичке әкият-хикәятләрен тыңлап баса идек. Хәер, берзаман без дә Байтимер малайлары белән дуслашып киттек, алар бик еш безгә,— әти янына килеп йөриләр, ара-тирә кыю гына аралаша да башладык, соңрак, «күңел оясындагы бала сандугач канат чыгарып, сайрарга өйрәнгәч», безнең әлеге аралашулар, мавыгуга тора-бара гыйшык-мыйшыкка ук әверелеп китте!.. «Гыйшык-мыйшык» дип, китап сүзләре белән генә әйтүем. Без һәрвакыт дус, таныш малай-кызлар гына идек. Әмма шунысы хак: толымнар билгә җитеп килгән чакта, әлеге малайлар белән — Мөхәммәт белән Барый исемле алар — булган мөнәсәбәтләребез сәерләнде, тагын да дөресрәге, Гөлйөзем дә, мин дә бер дә бер көнне әллә ничек үзгәрдек тә куйдык менә.

Мөхәммәт, агач башыннан егылып төшеп, кабыргаларын сындырганнан соң, минем ничек кайгырганнарымны, ничекләр итеп борчылуымны белсәгез иде сез! Үлә яздым! Кызгандым, жәлләдемме? Әллә?.. Нәрсә, «әллә?» Бернинди дә «әллә-мәллә» түгел. Сызлануын күреп жәлләдем! Бары шул гына! Аннан соң үләр дип уйладым, курыктым, бик-бик курыктым. Гөлйөзем генә пошмас җанлы безнең. «Маймыл кебек агач башында сикереп йөрмәсен, шул кирәк!» — диде. Имеш, ул инде дәү кыз! Имеш, мин әле бәләкәй, шуңа күрә сытык та. Һай, харап икән, дәү кыз! Апа, имеш. Үзе миннән нибары унбиш минутка алданрак туган ул. Әни әйтте. Ул белә бит инде. Хәер, нишлисең, унбиш минут тек унбиш минут инде, ул мизгелләрне беркая да куеп булмый, шулай булгач, ул миннән олырак, димәк, «апа» тиеш. Юк ла, нинди «апа» ди, ул миңа игезәк сыңары гына ла...

Мөхәммәт агач башыннан мәтәлгәч, күңелемдә ул малайга карата ниндидер хис тә яши башлады. Әүвәл кызгану хисе генә булды микән соң ул?.. Тора-бара әлеге хис мәхәббәткә үк әйләнеп китте ич. Хәзер уйлыйм: Мәхәббәт дигән олы хис әллә һәр кешедә дә миндәге кебек кызгану, жәлләүдән башлана микән?.. Алай булса, кызык... сәер. Бәлки, ул малай агач башыннан егылып төшкәнче үк, аны күргән мизгелләрдә үк, күңелдәге бер кылым сиздерми генә чыңлап, тибеп куйгандыр?.. Алла белсен... Мин биолог кеше, моны үзем дә чамаларга, аңлата белергә тиеш идем югыйсә!.. Тик андый теләгем юк. Бәлки әле, бу кешенең,— биологик бербөтен организмның,— саклану галәмәтедер! Әйе, әйе. Мәхәббәтнең ни икәнлеген аңлатырга, әлеге олуг хиснең кем әйтмешли кисәген кисәккә аерырга маташкан акыллы башның күңелендә, максатына инде килеп җиттем, зур ачыш ясыйм дигәндә генә,— Илаһи көч

әлеге Теләкне юк итә дә куя! Табигать могҗизасы! Мәхәббәт дигән хисме ул, халәтме,— кем ничек тели шулай атасын,— үзе үк Илаһи могҗиза булмаса, гасырлар буе табынырлар идеме соң аңа! Мисалларны тезеп китсәңме, бу хакта бер сөйли башласаңмы!.. Минем дә бер кичә генә дә җитмәс, билләһи...

Мөхәммәт тырыша-тырыша «Урман»ны яза, минем портретны. Аның рәсемнәрне матур ясавын беләм. Тик «Урман»ы минем күңелгә ошармы икән соң? Әгәр дә мәгәр портретым үземә ошамаса? Дөресрәге, үзем дә сизмичә, әлеге портретны күрүгә, ихтыярсыздан йөземә-сүземә канәгатьсезлек төсмере чыгарып куйсам! Ике төрле була алмыйм бит: эчтән бертөсле, тыштан икенче... Һәм шуның белән Мөхәммәтнең күңелен кайтарсам?.. Һай, әлеге мизгелләрне бик көтәм көтүен, тик куркам да. Ярабби бер Аллам, дим, Мөхәммәтнең «Урман»ы минем иләс-миләс, әле утырып җитмәгән күңелемә хуш кына килә күрсен иде!.. Ходайдан мин шулай дип сорыйм. Аннары, исемә килеп, үземне сүгәргә, әрләргә тотынам! Каян килгән хан кызы! Күңелемә хуш килмәсә, имеш!.. Мөхәммәтнең әлеге гамәле (үзеңне дә, урманыңны да шәһәргә алып китәм дип талпынып йөрүе) үзе генә дә ни тора лабаса! Без кыз-кыркын масаеп куябыз инде кайчакта! Әллә кем булабыз!..

Шөкер, үземне шул рәвешле тәнкыйтьли беләм икән әле! Дөресен әйткәндә, хәзер үз һөнәрем турында түгел, Мөхәммәтнең эшләре хакында ешрак уйлыйм, аңа булышасым, ярдәм итәсем килә. Мин аңа әйбәт хатын булырмын. Туп кебек малайлар, күбәләктәй кызчыклар алып кайтып бирермен, Алла боерса! Без барыбыз да аның илһамчысы булырбыз!.. Ә ул иҗат итәр. Кыскасы, без бик бәхетле булырбыз кебек.

Мин Гөлчәчәк, элекке урман кызы, урманчы кызы бүген әнә шундый хыял белән яшим. Мин бәхетле! Бүген үк бәхетле инде! Һай, Аллаһы Тәгаләм, бездән күпсенә генә күрмәсеннәр иде инде берүк. Арага керә күрмәсеннәр...

Күңелемдә гомер буе балачакта ишеткән бер хикәят яши. Аны безгә бер кунакка килгән чагында әнинең апасы,— хәзер ул урын өстендә, мин аны тәрбиялим,— сөйләгән иде. Алар шулай берзаман карты белән икесе генә кич чәй янында юк-барны сөйләшеп, балачакларын исләренә төшереп утыралар икән, ди. Бабай Идел буендагы «Кызыл байрак» пионерлар лагеренда булган вакытларын искә ала. Болай гына, балачагын исенә төшереп, хисләнеп китеп кенә. «Пионер лагерьда ошатып йөргән бер кызым бар иде. Беркөнне су буеннан тузбаш еланы тоттым да теге кызның мендәре астына салып куйдым бит! Әй чырылдады инде теге кыз, әй чырылдады».

Аның сүзен әби ялгап китә: «Карале,— ди ул.— Нәкъ шундый ук хәл минем белән дә булды ич! Пионерлагерьда бер малай мендәрем астына елан салган иде... Туктале, тукта! Ул лагерьның да исеме «Кызыл байрак» иде бит! Идел буенда! Класстан иң яхшы укучы биш кызны, Казандагы пионерлагерьга путевка белән бүләкләгәннәр иде. Бишенче классны бетергәч!..»

Моны ишеткәч, бабайның кулындагы шакмаклы шикәре өстәл астына тәгәри. «Ничек алай?!! Мин дә бишенче класстан соң бит! Путевканы этигә профсоюз биргән иде!.. Алайса, ул кыз син булгансың бит инде!!! Алайса... унбиш елдан соң яңадан Казанда күрешкәч, ник мине танымадың суң? Мин сине ник танымаганмын?!!»

Менә бит! Алар икесе ике районнан.

Зур үскәч, Казанда яңадан күрешкәннәр!

Әбинең шаккатып сөйләгәне елан гына түгел. Кызлар яшәгән бина бик биек койма белән уратылып алынган була. Ул малай шул койма аша ничек менә алды икән дип, аның кыюлыгына шаккаткан кыз ул чакта!.. Батырлыгына сокланган булган!

Илаһи могҗиза — Мәхәббәт — үзенең эшен эшләгән: күп еллардан соң, очраклы рәвештә генә Казанда күрешкәч, алар тагын бер-берсен ошатып, кавышып та куйганнар... Апа белән җизни бер-берсен сөешеп, бик матур гомер кичерделәр. Монысы безнең күз алдында иде инде.

Мәхәббәткә ышанмый кара син шуннан соң менә!..

* * *

Италиягә китү Казан сабан туена туры килде. «Урман» картинасын иртән-иртүк күргәзмәгә илтеп тапшырдылар да (Мәскәү кунагына ул шунда бүләк ителергә тиеш иде), сәнгать белгече һәм рәссам егетне «джип» машинасы аэропортка илтә китте.

Туган ягында үзенә киләчәк дәрәҗәне һәм капылт кына ишелеп төшәчәк бәхетне Мөхәммәт Уразов чит илдән табып алып кайтачагына чын күңелдән ышана һәм ул бүген дә үзен бәхетле, ай тулган төннән соң кичергән бәхет кебек үк бәхетле хис итә иде.

Гөлчәчәк Мөхәммәтнең чит илгә җыенганын белсә дә, китәсе көн тәгаен билгеле түгел, дигәч, Казанга килер алдыннан барыбер телеграмма сукты: «Сабан туена киләм. Каршы ал»,— дип хәбәр ителгән иде анда.

Телеграмманы Мөхәммәт ишектән чыгып барганда гына кулына тоттырдылар. Аны укып, берара аптырап торды да, аннан соң йомарлап, кесәсенә тыкты.

Гөлчәчәк исә, үзен каршы алучы булмагач, аптырап тормады, үзәккә кадәр баручы ярым буш троллейбуска кереп утырды һәм аннан, Толстой тукталышында төшеп, туп-туры Мөхәммәтнең фатирына китте. Егет аңа фатир ачкычын калдырып киткән иде.

Тимер челтәрле койма белән әйләндергән ишегалдында Гөлчәчәк Гөлйөзем белән Барыйны күреп алды. Алар машинага утырырга җыеналар иде. Гөлчәчәкне беренче булып кыз туганы күреп алды. Һәм, машинаның алдагы ишеген ачып:

— Карале, кем килә! — дип кычкырды, аннары җәһәт кенә арткы ишекне ачты һәм, кулыннан тотып, бер баланы төшерде.

Гөлчәчәк, җиңсез матур күлмәк, шорты һәм аякларына әллә кайдан кычкырып торган кроссовка кигән малайны танып, югалып киткәндәй булды.

— Әнвәр ич бу? Кайдан? Ничек?

Энәдән-җептән генә чыккан өр-яңа киемнәр кидерелгән бала, чыннан да, Гөлйөземнең малае Әнвәр — Гөлчәчәкнең урманда югалган энесе иде!

Әнисе аны кулыннан бер дә ычкындырмый, малай да үзен әллә ничек сәеррәк тота, әнисеннән ычкынып китмәкче булып, әледән әле тартылып куя, бу теләге барып чыкмагач, бер урында сикерә, чәбәләнергә керешә. Гөлчәчәк аңа күз ташлауга күрде: элек туп шикелле тәгәрәп йөргән бала суырылган, ябыккан, шыр сөяккә калган дип әйтергә дә мөмкин. Йөзләре, муеннары тырналып беткән, ике беләгендә дә, аякларында да тырналмаган, кутырламаган бер генә сау җире дә юк. Гөлйөзем аңа нигә кыска җиңле күлмәк һәм шорты киерткәндер? Малайның ике тез башы да каралып тора.

Гөлчәчәк энесен бик ярата, ул аны бишектән үк үзе карап үстерде диярлек, чөнки үз әнисе бик еш хастаханәләргә кереп, айлар буе дәваланып ята иде. Корсаклы чагында, кешегә сиздермим дип, билен буып йөрүе эзсез калмады, күрәсең.

Гөлчәчәк Әнвәрне кочагына алды һәм күкрәгенә кысты.

— Кайларда булган бу бала?

Гөлйөземнең йөзе шат, кәефе күтәренке иде.

— Белмибез,— диде ул, туганының соравына каршы.— Әни әйтә, капка астыннан шуышып керде дә мунча буендагы ком өемендә калган машинасы белән уйный башлады, ди.

— Адашкан булгандыр инде.

Сүзгә Барый кушылды:

— Адашмаган ул. Адашса, тапкан булыр идек. Бөтен урманны тарап чыктык бит! — диде ул. Малайның, үз баласының табылуына ул да чиксез куанган, җитди председательнең йөзендә кояш балкый.

— Үзе бернәрсә сөйләмиме?

— Юк, сөйләми шул. Күрәсең, ни булганын үзе дә аңлашып җитмәгәндер.

— Урманда адашкан ул, адашкан. Берәр чокырда йә куак арасында яткандыр, шуңа күрә табылмагандыр,— дип, Гөлчәчәк энесен күкрәгенә кысты.— Тик нәрсә ашаган ул анда?

Бу юлы аның сүзенә каршы да килмәделәр, җөпләмәделәр дә һәм капка төбендәге комда ярылып яткан бүре эзләре хакында да әйтмәделәр. Бүренең эттән туган бүре Пират икәнлеген беләләр һәм Барый аны табып юк итәргә тели иде.

Гөлйөзем сүзне икенчегә борып җибәрде:

— Мөхәммәт өйдә юк икән. Без аны Казан сабан туена алып чыкмакчы идек,— диде ул һәм, тагын югалмасын дигәндәй, малаен үз янына тартты.

— Шушы көннәрдә Италиягә китәргә тиеш иде ул. Бәлкем, китеп баргандыр. Без күптән түгел күрештек.

Гөлчәчәкнең бу сүзләре Барыйга ток суккандай тәэсир итте:

— Ничек?! Бүген Казан сабан туе көнне Казанда аның күргәзмәсе бит! Мәскәү кунаклары киләчәкләр!

Гөлчәчәк Барый белән сүз көрәштереп тормады, белгәнемне әйттем мин дигәндәй, иңбашларын сикертеп куйды да:

— Минем күргәзмәгә барып карыйсым килә. Әйдәгез, бармыйсызмы? — дип, әңгәмәдәшләренә мөрәҗәгать итте.

Күргәзмә бүген төштән соң гына ачылырга тиеш икән. Залда каравылчыдан башка кеше-кара юк. Каравылчы, зур гәүдәле урыс хатыны тупас кына:

— Күргәзмә төштән соң ачыла! — диде.

Барый, алгарак чыгып, марҗа апайны итагатьле генә читкәрәк дәште һәм кесәсеннән акча чыгарды:

— Без ай момент! Сдача да кирәкми, билет та кирәкми!

Каравылчы йомшарды.

— Тик тиз булыгыз! Начальство сабан туена китеп барды югыйсә...

Мәскәү делегациясе төштән соң гына киләчәк. «Урман»ның да күргәзмәгә куелачагын Мөхәммәт үзе үк әйтте. Һәм шуннан соң туйда мин аны сиңа бүләк итәрмен, дигән иде.

Гөлчәчәкнең күзенә ак-кара күренмәде: ул «Урман» эзләп китте. Теле белән әйтмәсә дә, Барыйны да нәкъ шул картина кызыксындыра. Әгәр Мөхәммәт Италиягә китәргә ризалык биргән икән, димәк...

Әйе, Хәниф Хатыйпович тәки үзенекен иткән. Һәм аның, Барыйның да тырышлыгы бушка китмәгән, күрәсең...

«Урман»ны иң беренче булып Гөлчәчәк эзләп тапты һәм күрүгә залны яңгыратып кычкырып җибәрде: «Әнекәем! Мин бит бу!»

Урман. Кызылъяр өсте. Яшь наратлар үсеп утыра. Кырыйдагы сирәк агачлар арасыннан чәчәкле алан күренеп тора. Алан өстендә мәһабәт бөркет әйләнә. Анда бер кыз такыя үрә. Ул кыз — Гөлчәчәк! Бу кадәр охшаса да охшар икән! Кара, чынлап та, үзе бит! Коеп куйган!..

Чып-чын урман бит бу! Җанлы, тере урман. Кызылъяр өсте. Әнә тегендә, чак кына сулда һәм астарак, чишмә тибеп ята!

Урман кызларына мондагы һәр агач, һәр түмгәк, аланлыктагы һәр чәчәк таныш лабаса! Күз тимәсен, фотоаппарат белән дә бу хәтле төгәл һәм чын итеп чагылдырып булмастыр урманны!..

Хәзер урман киселеп беткән диярлек. Ләкин кызлар икесе дә, Гөлчәчәк тә, Гөлйөзем дә, яхшы хәтерлиләр: моннан берничә ел элек нәкъ Кызылъяр өсте урманы картинада сурәтләнгәнчә иде...

Кызларның күзләре яшьләнде. Бигрәк тә Гөлчәчәк... ул тын гына елый иде. Кыз тел-авызсыз калды. Якынрак та килеп карады, арткарак та китеп.

Рәсем-картинада гына булса да, урман исән-сау бит!

Барый дәшми, ул да сүзсез калган. Аның, бердәнбер кешенең, бу картина яныннан тизрәк китәсе, моннан качасы килде.

«Мәскәүләр тиле түгел икән шул! Һе... күпмегә сатып була икән соң бу картинаны? Италиягә китү шуның хакыдыр инде?» — дип уйлап куйды ул һәм әлеге хакта берни белмәгән Гөлчәчәккә күз ташлады, кыз аңа кызганыч булып китте.

Хәтта... хәтта... әлеге картина һәм бер егет белән бер кыз турында халыкта матур риваять тә йөри.

Риваять-легендалар тарихта гына түгел, бүген дә бар. Имештер, яшәгән, ди, булган, ди, бер бик гүзәл кыз бала. Ул урманчы кызы, урман кызы икән, ди. Бу кыз баланың күзләре урман кебек серле, тавышы урман чишмәседәй саф, күңеле шул кара урман кебек ихлас икән, ди.

Урмандагы бар җәнлекләр: куяннар, керпеләр, тиеннәр, хәтта аю-бүреләре дә кызны бик яраталар, якын итәләр икән, ди. Башка иптәшләре булмагач, кыз шул җәнлекләр белән күңел ачкан: уйнаганнар, биегәннәр, җырлаганнар. Һәм җәнлекләргә бәла-каза янаса, кыз аларны яклап чыккан, тегеләре, үз чиратларында, аның күңелен ача торган булганнар. Менә шулай күңелле һәм бик тату, дус яшәгәннәр алар.

Кыз бала зур кыз булып үсеп җиткән. Бик матур кыз булган ул! Аның гүзәллегенә бар тирә-юнь шаккаткан! Урманга килгән аучылар, кызны күргәч, аның матурлыгына таң калып, кулларындагы мылтыкларын ташлаганнар да чәчәк җыярга керешкәннәр. Шулай итеп, һәр аучы да кызга үзенең мәхәббәтен аңлатырга, аны үзенә каратырга тели икән. Көннәрдән бер көнне гүзәл урман кызы турындагы хәбәр ерак тайгада яшәүче Диюгә дә барып ирешкән. Дию, бу хәбәрне ишетүгә, агач башларына баса-сикерә бик тиз генә мари урманнарына килеп җиткән. Иллэт елгасы ярындагы куаклыкта, кызны күзләп, өч көн, өч төн кунган ул һәм, дүртенче көн дигәндә, ап-ак атка атланган гүзәл урман кызын күреп алган! Ул Дию егете бик

хисле һәм кайнар йөрәкле булган: кызны күргән дә телдән язган, йөрәге котырып тибәргә керешкән. Тасырдаган йөрәге, күкрәк читлеген ватып, чыгып китәм дигәндә генә, Дию егете салкын Иллэт суына чумган. Өч көн, өч төн судан чыга алмыйча йөрәген суытып яткан ул. Инде тынычланып, яр буена чыкса, урман кызы җырлый-җырлый такыя үреп йөри икән. Диюнең каны тагын кызган, йөрәге янә тасырдарга керешкән; хисле егетнең йөрәген мәхәббәт ялкыны урап алган һәм ул дөрләп яна башлаган. Ялкын, ут, агачтан агачка күчә-күчә, бар урманны чолгап алган һәм зур янгын чыккан.

Дию дә, урмандагы агачлар да өч көн, өч төн янганнар, урман кара күмергә әйләнгән!..

Гүзәл урман кызы исә кара кайгыга баткан, ашаудан калган, телдән язган. Шуннан соң Аю табиб аучыларга мондый хәбәр салган: кем дә кем урман кызын савыктыра, кыз шуңа кияүгә чыгачак! Бу хәбәрне ишетеп, тирә-яктан бар аучы халкы җыелган. Уйлашканнар, киңәш-табыш иткәннәр, ләкин уртак фикергә килә алмаганнар. Араларыннан бер яшь аучы егет, табиб Аюны дәшеп әйткән: «Иртәгә кызны шундый-шундый урынга алып килегез!»

Билгеләнгән урынга кызны күтәреп алып килгәннәр. Егет аның күзләрен бәйләргә һәм шуннан соң тау мәгарәсенә керергә кушкан. Мәгарә эче бик якты, бик зур, ди! Һәм аның стенасында кыз туып үскән урман рәсеме, ди! Чып-чын урман! Агач башында тукылдап утыручы тукранына хәтле бар, ди! Аучы егет бик оста рәссам икән, ди. Кызның күзен ачып җибәргәннәр: ул, рәсем-урманны күреп, сөенеченнән көлеп җибәргән, күзләренә нур иңгән, сөйләшә башлаган.

Шуннан соң инде, Аюның вәгъдәсе буенча, рәссам егет белән урман кызы бик зурлап туй ясаганнар. Аларның бик күп балалары булган. Ул балалар, үсеп җитеп, янган урман урынына бик күп агачлар утыртканнар.

Менә сиңа әкият, легенда... һәм менә сиңа чын тормыш!..

Гөлчәчәк картинага бармак башы белән орынып алганын үзе дә сизми калды. Каравылчы хатын, аның беләгеннән тотып, читкә этте.

— Мин тагын сезне җәлләп керткән булам! Барыгыз, бар! Хәзер үк чыгып китегез! Милиция чакыртам! Бүләккә дигән картина бит ул. Бүген аны Мәскәүгә алып китәләр!

Аларны эткәләп-төрткәләп диярлек чыгарып җибәрделәр.

— Барый, син берәр нәрсә беләсеңме? Ни сөйли ул теге хатын?

Барый тамагын кырып куйды, беркавым җавапсыз торды, аннары, кызны юатырга теләгәндәй:

— Күрмисеңмени аның кем икәнлеген! Кайдан белсен ди ул? Надан бит ул, надан хатын! — дип куйды да аннан соң шуның артыннан ук: — Әйдә, лучше сабан туена киттек.

— Мин бармыйм!..

Бу минутта канаты сынган кош сыман иде кыз...

Күргәзмәдән соң Барый белән Гөлйөзем Каенлыкка сабан туе карарга китеп бардылар. Гөлчәчәк Казансу яры буенда тезелеп киткән эскәмияләрнең берсендә утырып калды. «Урман»ның тәэсире әле һаман көчле иде...

Ишек ачык, янәшә тирәдә кеше-кара күренми. Кыз песи адымнары белән икенче катка күтәрелде, аннан соң, сак кына атлап, «Урман» янына узды. «Мөхәммәт! Мин сине яратам! Рәхмәт сиңа, Мөхәммәт!»

Ул, өнсез калып, картина каршысында байтак басып торды; калын, алсу иреннәре дерелди, нидер әйтмәкчеме, әллә сурәттәге урман кызы белән сөйләшәсе, гәпләшәсе килә һәм аңа: «Урман кызы! Син — мин ул! Исәнме! Саумы, минем яшүсмер кыз чагым! Казанга ук килеп җитә алдыңмы? Ә мин һаман читтә әле... Мөхәммәт сәфәрдән исән-сау әйләнеп кайтсын инде, яме. Көтик. Ул безнең икебезне дә ярата. Тик белеп тор: мин синнән тамчы да көнләшмим. Син — мин. Мин — син...» — дигән сүзләр тәкрарлый, нәкъ тере зат кебек эндәшә.

«Чү!.. Сине алып китәләр, диме?.. Хуҗаң да бар инде, диме? Юк, юк, борчылма! Мин дә, Мөхәммәт тә сине берәүгә дә бирмәбез, яме...»

Гөлчәчәк тагын да якынлашып картинаның рам кысасына гына булса да (ул бик затлы, әллә алтын белән йөгертелгән инде) бармак очын тигезеп карыйсы килде.

— Не трогать! Милиция!!! Охрана! Ничек кердең син монда?! Милиция! Милиция! Хәзер үк чыгып кит! Милиция!

Кыз коелып төште, югалып калды.

Күз ачып йомган арада аның ике ягыннан ике егет култыклап алдылар да:

— Пройдемте! — дип, ишеккә таба әйдәделәр.

Милиция бүлегендә күпме утыргандыр, анысын тәгаен генә әйтүе кыен, әмма аны урамга чыгарып җибәргәндә, көндезге эссе һава суынган, димәк, көн дә кичкә авышып бара иде.

Ул тирә-ягына каранып беркавым басып торды-торды да, кинәт катгый карарга килгәндәй, янә күргәзмәгә таба атлады. Урамнар көндезге кебек буш түгел, сабан туенда кәефләнгән халык шәһәргә кайта башлаган. Ул йөгерергә үк кереште. Бу күңел дигәнеңнең сизгерлеге! Күргәзмә куелган бина янында, чыннан да, җиңел машиналар, караңгы пыялалы затлы чит ил машиналары, автобуслар тезелешеп тора. Бина каршындагы тар урамда эт көтүе кебек халык, төрлесе-төрле киемнән һәм төрле кыяфәттә. Кара урманда күзләрен бәйләп йөри ала торган кызыбыз бер мәлгә каушап, югалып калды. Ләкин бу халәте шул бермәл эчендә генә булды да; ул халык диңгезен терсәкләре белән ишә-ера ишеккә таба китте.

Һаман шул ук кешеләр арасыннан кысыла төртелә икенче катка күргәзмә залына күтәрелде. Ләкин ни файда, картиналар янына үтәрлек түгел. Халык төркемен ул терсәкләре белән булса да этә-төртә, түргә уза алыр иде. Ләкин мондагы халык сабан туеннан кайтып килүче гади халык кына түгел, ахрысы. Кыймылдарга, хәтта суларга да ирек бирмиләр. Әллә нинди сәерләр, бер шырпы кабындагы игезәкләр кебек, кайсы уңга караган, кайсысы сул тарафка, кайберләре исә картиналарга артлары белән үк борылганнар да күзләрен ялт-йолт йөртеп уклау йоткан сыман катып тик басып торалар. Кыскасы, сәер халык һәм күргәзмә карарга килмәгән болар. Ә алдагы төркем,— ул төркем каршылыксыз үтү өчен буш коридор калдырылган, кыскасы, ул төркем янында һәрвакыт шактый зур бушлык бар. Төркем кузгалса, «бушлык» та аның артыннан «калышмый». Гөлчәчәкнең әнә шул бушлыкка эләгәсе килгән иде. Тик кая ул, «бушлык» картиналар эленгән стена буенча шуыша да шуыша.

«Бушлык» «Урман» янында туктап калды.

— Бу картинаны Сезгә дип әзерләдек!!!

— ...

— Узган юлы, хәтерлисезме, ул Сезнең күңелегезгә бик хуш килгән иде. Хәтерлисезме?

— Я не имею такого желания. Спасибо.

— Ул Сезгә бик ошаган иде бит!

— Я картин не коллекционирую. От них слишком много пыли.— У Фаины Максимовны от пыли аллергия!

«Бушлык» ары китте. Әлеге төркем залның икенче почмагына күчүгә, кемдер килеп, «Урман»ны салдырып алды да тиз арада каядыр юкка чыгарды.

Беравыктан «Урман» эленеп торган урында бушлык күргәч, безнең Гөлчәчәгебез чак кына һушыннан язмады. Картина урынында буш стена гына!..

Беркавымнан зал үзе дә бушап калды.

Буш... бушлык... Нишләптер, мәгънәсез бушлык, диләр... Бушлыкның үз мәгънәсе бар аның...

Бушлыктан, бернәрсәсез юклыктан, барысын да табарга була, анда бетмәс-төкәнмәс көч яшерелгән. Бу — алҗыган гакылның алдавыч халәттән арынып, бушанып, үзенең чын табигатенә кайтуының бердәнбер юлы...

*Беренче китап тәмам*

# ИКЕНЧЕ КИТАП

## ЭТТӘН ТУГАН

### Карга көтүе

Очты-очты... каргалар очты, авыллар очты, шәһәрләр очты... алар артыннан кешеләр очты. Кыскасы, авыллап-давыллап очты болар... Кошлардан кала барысы да берзаман арып туктадылар. Кара каргалар, ала каргалар, сыерчыклар, чыпчыклар, саесканнар, чәүкәләр исә һаман очтылар да очтылар.

...Кара каргалар, бала чыгаруга ук, үзләре арасында сәер хәлләр башлануын сизеп алдылар. Башлары белән бик озак уйландылар, үзләренчә фикер дә йөрткән булдылар, аптыраштылар, шаккатып та карадылар, әмма бырыбер уртак бер акыллы нәтиҗәгә килә алмады, бахырлар. Эш шунда иде ки: күкәйдән яңа борын төртеп чыккан бер кара карга баласы үзен гаҗәп сәер тота,

ул бер дә башка кара карга балаларына охшамаган. Бу кара карга баласының анасы — зур кара карга да аптыраган булды, әмма ничек кенә аптыраган булып кыланмасын — ул һич кенә дә эчкерсез түгел кебек, барыбер сере булгандыр аның, төп гаеп ана каргада шикелле иде...

Гаеп шул: менә дигән сөлектәй кара карга егетләре була торып, нигә, нигә әле ул, — җир бит! — башка кош егетләре белән әвәрә килгән! Әнә хәзер оясындагы бер җан иясенә карасын: ни кара карга түгел, ни чын чәүкәгә дә, козгынга да, кыскасы, шайтаныма да охшамаган!.. Холкы нинди булыр әле тагын! Анысы бераз үсә төшкәч күренер... Әйе, бер караганда, әгәр дә ул адәм затыннан булса, ана карганы шул рәвешле гаепләп тә булыр иде кебек. Ләкин ул бары тик карга гына лабаса! Оясына берәрсе үз күкәен салып киткәндер дә... Бәндәләр карыннарында йөрткән газизләрен чүплеккә яки балалар йортына ыргыткан шикелле...

Ә хәзергә очты-очты... каргалар очты... Авыллар очты, шәһәрләр очты, кешеләр...

* * *

...Әкбәровның көне иртәдән җан кыю белән башланды... Алай булырга тиеш түгел иде югыйсә. Бу эш уйламаган-көтмәгәндә килеп чыкты. Киресенчә, нәкъ менә бүген буйдак егетнең тормышында зур үзгәреш, борылыш булырга тиеш иде ләбаса! Монда җан ияләре канының ни катнашы бар соң, Ходаем!

Киче дә бик матур башланган иде бит канә! Эңгер-меңгер белән үк, май урларга барган ата мәче сыман кача-поса, тол хатын янына килде. Көндез үк сөйләшеп куйдылар. Бүләккә дип бер кочак чүпрәк-чапрак та сатып алды. Бүтән вакыт «уҗымга» кереп чykканнан соң һәркайсының өстәлендә акча гына калдырып киткәләде. Кичә, гомердә булмаганча, махсус ниятләп, чүпрәк җыйды. Башка чакта култык астына коньяк ише эчемлек кыстыра яки затлы коры шәраб ала иде.

Соңгы араларда сөйгәне Гөлйөземгә карата суынибрак йөри Барый. Гаепнең кемдә икәнлеген белми, әмма җанын битарафлык пәрәвезләре чорнап алуы хак. Бу халәте егетне куркыта, юлын аркылы кисеп чыккан кара мәчедән дә артыграк шүрләтә һәм ул алай булуын үзе дә теләми, ары бәрелә, бире сугыла, күңел күзенә төшә башлаган эңгер-меңгерне якты өмет нурлары белән тутырып, мең-миллион төрле шик-шөбһәләреннән котылырга, арынырга тели, тагын да дөресрәге, тыпырчына, бәргәләнә.

Ул үзенең җир өстендә бик нык басып торганлыгын белә, алдына куйган максатларына ирешәчәген аңлый. Ләкин шул ук вакытта байлык-муллыкның, кесә тулы акчаның һәм хәтта дан-шөһрәтнең генә барыбер күңел тынычлыгы алып килмәячәген чамалый.

Адәм баласы үз гомерендә бер генә тапкыр булса да, коштай талпынып алырга тиеш, аның яраткан кешесе булырга тиеш. Бәхетле адәм баласының...

Барый Әкбәров акылсыз малай түгел. Байлык һәм дан-шөһрәт тавының иң очына менеп утырып та, әгәр Табигать-Алланың иң бөек хисеннән — мәхәббәт тойгысыннан мәхрүм буласың икән, әлеге алтын тау башында сиңа, һичшиксез, шыксыз булачак! Әнә шул шыксызлык өркетә дә инде аны. Ә кемне булса да яратамы соң ул? Бәлкем, Табигать-энкә аны бу хистән мәхрүм иткәндер? Аның тынгысыз ярсу җанына андый нечкә хис орлыкларын салып вакланып тормагандыр!

Чү! Тукта! Мәхәббәт мәсьәләсен нигә акыл бизмәненә салып үлчи соң әле ул?

Любовь, любовь, когда ты овладеваешь нами,
Можно сказать, прости, благоразумие.

Жан де Лафонтен атлы адәм әйткән бу сүзләрне. Колхоз рәисе өчен ул Жанның кем булуы ул чаклы әһәмиятле булмаса да...

Әлеге сүзләрнең Барый җанына тиюе хак, билләһи менә!.. Димәк, ярата белми ул. Акыл белән генә эш итә. Алайса Гөлйөземгә карата булган хисләре? Яратадыр шикелле иде бит...

Барый кулы белән тотып карамыйча ышанмый. Һәм үз-үзен инандыру өчен төрле ысулларны файдалана. Хәер, төрле дип... Бу очракта аның ысулы бер генә бугай инде: Гөлйөземне башка кыз-хатыннар белән чагыштырып карау. Һәм ул карый да: өйрәнә, җентекләп чагыштыра...

Барый Әкбәров үзенең кача-поса марҗалар белән «маташуын» әнә шундый фәлсәфә нигезендә аңлатырга тырыша. Үз-үзенә инде, билгеле. Һәм, шулай иткәч, кылган гөнаһлары да акланадыр сыман иде.

Без үзебез сокланган кешеләрне түгел, ә безгә хушлары киткән кешеләрне яратабыз, дигән бер акыллы баш. Наташа атлы бу яшь тол хатын, кыз-кыркынны авылда калдыру өчен һәм хатын-кызга эш булсын дип, махсус оештырган колхоз йортындагы тегүчеләр остаханәсенә хәл-

ләрен белергә Барый абыйсы килеп керсә, каушавыннан ике бармагын бер итеп тегеп куя торган иде. Кулына кайчы тоткан чагы булса, бармакларын турардай булып онытыла, бинадагы электр уты кинәт кенә сүнеп, яктылык һәм нур бары тик аның зур зәңгәр күзләрендә генә янып кала иде. Моны иптәшләре дә белә, моны колхоз рәисе үзе дә сизә.

Ел ярым тирәсе элек Наташаның Степаны, үз каберен Чечня җирләрендә табып, шунда ук ятып калды. Җаны сагыш белән тулган яшь бикәчнең шул рәвешле ирен юксынуымы бу, әллә инде уенчак күңеленең азынасы килү галәмәтеме? Ул хәтлесен иптәш кызлары да белми, җитәкче абыйлары да тәгаен генә әйтә алмас. Әлбәттә, Наташа үзе дә чамалап бетерми. Шулай да?..

Кем үз гомерендә мәхәббәт татымаган, шул яшәмәгән, диләр. Мәет кенә булган, тере мәет. Әлеге гыйбарә-теорияне Әкбәров яхшы белә, мәгънәсенә дә төшенә. Дөнья белән Мәхәббәт һәм Ачлык идарә итә дигәнне дә ишеткәне бар аның. Әйе, ач эт күзеңә карап тора, ачлы-туклы халык сарык көтүе хәлендә. Монысы аңлашыла. Ә мәхәббәт? Гөлйөзем?.. Барыйның әлеге гыйбарәнең соңгы шөребенә чаклы сүтеп бетереп, тикшереп карыйсы килә. Нигилист булмаса да, дөньяның күп кенә могҗизалары аның өчен балачакта әбисеннән ишеткән матур әкият кенә кебек. Башкортларның арба тәгәрмәче уйлап табуларына ышанмаган шикелле, һәрнәрсәгә дә аһваһ итми, бик шаккатып тормый. Аның өчен бу дөнья сораулардан бигрәк гел җаваплардан гына торадыр сыман иде бит?!

Ә мәхәббәт?..

Гөлйөзем?..

Аның моңа һаман тәгаен генә җавап бирә алганы юк. Һәм шуңа эче поша да инде. Нәкъ менә шул сәбәпле кичә кич яшь хатын катына килде буйдак исемен йөртүче Барый абзагыз Әкбәров. Әйе, шуңа күрә чуала ул һәм үзенең «уҗымга йөрүләрен» әнә шундый зур фәлсәфи фикернәтиҗәләр ярдәмендә нугытып та куя.

Ләкин барыбер... Барыбер кемнедер яратасы килә егетнең. Шулай диюгә, күз алдына капылт кына Гөлйөзем килә дә баса. Ә Барый аннан курка. Үзеннән түгел, ияләнеп, күнегеп китүеннән курка. Бик гади генә ияләшеп, Мәхәббәтне татымый калырмын дип курка.

Наташа кич буе Барый бүләк иткән күлмәкләрнең әле берсен, әле икенчесен киеп карады. Адәм күрке — чүпрәк, ди. Төскә-биткә һәм гәүдәгә болай да сөбханалла гына булган яшь хатын да курчак, курчак та курчак иде. Күз карашларының янып-янып алулары, яңа кием кигәч, өй буенча очынып-очынып йөрүләре Барыйның күңеленә хуш килде. Юк, дөрес аңлагыз, үзен әллә кемгә куеп, үзе алган чүпрәк-чапракка сокланып, аларның нәкъ менә аның бүләге булуына хушланмады Әкбәров. Ул кич буе бары тик матурлык кына карап утырды. Яшь хатынга сокланды, җаны эреп, шулчаклы рәхәт, ләззәтле булып китте аңа кайбер мизгелләрдә... Әллә Мәхәббәт дигәннәре?!

...Тулып җитешкән түгәрәк ай төн уртасында, тәрәзәдән кереп (пәрдәсен дә тартып куймаган мәхәббәткә сусаган хатын), буяулы идәнгә тәгәрәде. Өй эче гөлт итеп яктырды. Шул яктылык Барыйны да уятты. Ул, борыны белән хатынның ике күкрәк арасына төртелеп, йоклап киткән иде. Уянгач та кинәт кенә һушына килеп җитә алмады, беркавым хәрәкәтсез ятты. Иреннәре хатынның тыгыз күкрәкләренә тиеп алды. Наташаның тәме бүтән, башка төрле иде. Тел белән тоеп булса да, әмма шул ук тел белән әйтеп, аңлатып биреп булмаслык чит, ят тәм иде бу. Ул, шундук кискен генә борылып, сары йонлы мари мәчесе кебек тынсыз гына йоклаган кызга аркасын куеп ятты.

Мари авылында песиләр һәммәсе дә бертөрле сары була. Татарларда мәчеләр аклы-каралы. Әллә ягы белән генә шулай микән? Ә урыс авылы Бурянда песиләр нинди төстә соң әле? Барый беркавым шуны исенә төшерергә тырышып ятты да үзалдына көлемсерәп куйды: алар кечкенә юлбарыс балаларына охшаган — комсызлар, караклар. Бурян урыслары, җиңел тормыш эзләп, шәһәргә күченеп китә, мәчеләрен үзләре белән алып тормыйлар, тегеләре кыргыйлаша. Әллә ул җан ияләре, киләчәк язмышларын алдан ук сизенеп, урман-кырларда япа-ялгыз каласыларын белеп, юлбарыска охшап туалар микән?

Тәмсез тоелган истән соң Наташаны тагын кочарга теләге сүрелгән иде. Шуңа күрә песиләр дөньясына кереп китте ул, яңа шөгыль тапты. Аннары беркавымнан үзалдына: «Мәхәббәткә бар да мишәйт итә икән», — дип сукрана-сукрана, торып китәргә уйлады. Шул мизгелдә мари кызы, муенына йокы аралаш кайнар беләген салып, аны бастырыклап куйды. Кайнар беләк пешерсә дә, җылына алмады Барый, кызның кулын дорфа гына читкә этәреп, идәнгә сикереп төште. Урамда каргалар тавышы, авыл әле уянмаган. Каргалар каркылдавы күңелгә тия. Бигрәк тә бүген. Барыйның кәефе шәп — мәхәбәттә ачыш ясаган көне. Ул, үзе белән алып килгән мылты-

гын кора-кора, урамга чыкты һәм, ишегалдына аяк басуга, багана башларында тезелешеп утырган карга көтүенә төбәп атып та җибәрде. Иртәнге тәмле йокысыннан уянасы килмичә тыныч кына изрәп яткан авыл сискәнеп китте, өй түбәләре, урыннарыннан кубып, күккә күтәрелгәндәй, тәрәзә пыялалары чатнагандай булды, мари урманы артыннан сыртын күрсәтергә әзерләнгән кояш куркуыннан беркавым токтарланып торасы итте.

Комбайнчы Валерийның — халык телендәге исеме Бәлүк — хатыны Нәчтә җиде айлык корсаклы булып, таң белән җиңелчә генә кысталып, лапас ишеге артына чүгәләгән иде; ату тавышыннан коты ботына таба тәгәрәп, лап итеп үзе юешләгән җиргә утырды, капылт кына эче борырга керешә һәм ул, әле беренче бәбиен генә алып кайтырга йөргән Бәлүк хатыны, әллә куркуыннан, әллә каты авыртудан чырылдап кычкыра башлады.

Этләр өрмәде, аларның койрыклары бот арасында иде.

Бәлүк үзе дә йокламыйча ята, аңа торып, комбайнын кабызырга да вакыт җиткән иде. Кичтән Бачылый белән шәп кенә кәгелгән, башын сүтеп алып, аның урынына тегермән ташы кигертеп куйган кебек: мендәрдән күтәреп алып булмый. Аты-юлы белән Бачылыйны сүкте: бу хәлгә ул гаепле иде. Эш болай булды: алар кулга-кул сугышып бәхәсләштеләр, имеш, Бәлүкнең малае ничек, ни рәвешле туачак? Дөресрәге, Нәчтәгә хастаханәдән: «Үзең таба алмасаң, кесерово ясарбыз», — дигәннәр. Бәлүкнең мондый ят сүзне моңарчы ишеткәне юк иде, сәер булса да, бик кызык тоелган иде: кесерово! Әллә нинди чит сүз шунда! Малай, дөньяга аваз салуга, бүтән телдә сөйләшеп китмәсә ярый инде, дип уйлады ул. Бу шик-шөбһәләрен Бачылыйга да чиште. Ул гыйлемлерәк икән, Бәлүк шулай диюгә:

— Беләсең килсә, кесерово корсакны яру дигән сүз була ул! — дип шәрехләп тә бирде. Нәкъ менә шул нәрсә араларында бәхәс кузгатты да инде: хатынның корсагын аркылыга ярачаклармы, буйгамы? Бачылый үзенекен әйтә: буйга, ди, Бәлүк үз ягына каера, аныңча, корсак аркылыга ярылырга тиеш. Мин әйткәнчә булырга тиеш бит инде канә, чөнки малай минеке бит, дип уйлый ул. Алар барыбер уртак бер фикергә килеп бетә алмыйча, кул сугышырга булдылар. Кем отыла — шунан бер читүк көмешкә! Бәхәсне исә бер чирек белән ныгытып, пичәтләп тә куйдылар. Әмма берсе дә соңыннан Нәчтәнең Бачылыйга корсагын ачып күрсәтерме, юкмы икәнлеге хакында уйлап карамады.

Ә иртәгесен!.. Иртәгесен бары тик Бачылыйны сүгеп кенә җиңеләеп булыр төсле иде. Тик ишегалдында хатынының кычкырган тавышы аны шундук айнытып җибәрде — ул караватыннан идәнгә мәтәлде һәм тышка атылды.

Нәчтәне вакытыннан алда тулгак тота башлаган иде. Мондый вакытта нәрсә эшләргә кирәклеген белмәгән яшь ир урамга чапты, бәхетенә күрә, алар урамында аты-юлы белән сүгенә-сүгенә «уазигы» тирәли әйләнеп йөргән Әкбәровка тап булды. Тәгәрмәчләрнең дүртесен дә кайсыдыр явызы тишеп киткән. Бәлүк, атылып, аның янына килде һәм, сулышы кабудан ашыга-ашыга, мәсьәләне аңлатырга керешә. Әкбәров тагын бер тапкыр ачу белән тәгәрмәченә тибеп куйды да:

— Комбайның кайда соң?! — дип кычкырды. Комбайн авыл башында гына булып чыкты. Ул кызу-кызу шунда таба атлады.

Барый комбайн кабызып маташкан арада, Бәлүкнең хатынын, кул арбасына утыртып, алып килеп тә җиткерделәр. Куларба тәртәсенә Бәлүкнең этисе Сәнүк карт үзе кергән. Бәлүк арттан этә, әнисе Соня апай, авып китмәсен дигәндәй, килененең иңбашыннан тоткан. Сәнүк карт — кечкенә генә буйлы, какча чырайлы, ләкин бик елгыр, тере бабай — атлаган саен башын артка таба кыегайтып, ялварулы тавыш белән килененә эндәшә:

— Нәчтүк, киленкәем! Малай апкайт инде син, яме.

Арттан эткән Бәлүкнең моңа эче поша, күрәсең, ул аңа:

— Җитте инде сиңа! Малай кайгысымы соң әле монда! Үзең исән-сау котыл, килен, диген! — дип шелтә белдерә.

Ләкин картның һаман үз сүзе:

— Әгәр малай булса... Мин аны председатель итеп куйдыртам, Әкбәровны Казанга зур эшкә алгач!..

Аның шулай дип әйтүе юкка гына түгел, чөнки мари авылында колхоз рәисен аеруча яраталар, олысы-кечесе хөрмәт итә. Сүз саен: «Барый Хазиевич безгә авыз тутырып ипи ашата!» — дип мактап кына торалар. Тик... тәгәрмәчләрне кем тишкән менә?..

Участок хастаханәсенә ике төрле юл алып бара: берсе — туры юл, ләкин ул таштан түшәлсә дә, бик сикәлтәле, икенчесе — әйләнечтәнрәк салынган асфальт юл. Әнә шул асфальт юлга кадәр ярты чакрымлап басу аша ат юлыннан чыгасы бар. Барый комбайнны басуга таба каерды.

Басуда котырып арпа үскән. Колхоз җирләре түгел бу, фермер Сибгатуллинныкы. Барый эшкә килгәнче үк, Барыйның әтисе өстеннән югары оешмаларга йөри-йөри, талаша-сугыша торгач, Сибгатуллин үзенең фермер хуҗалыгы өчен җир алуга ирешкән иде. Шул җирендә менә ничә ел рәттән әйбәт арпа үстерә. Үстерү генә түгел бит әле, аны җыеп алып урнаштырасы да бар. Сибгатуллин моның да җаен тапкан: уңышны Казанның сыра заводына тапшыра, чөнки арпасы аларның таләпләренә туры килә иде. Әнә өр-яңа «КамАЗ» алып кайтып куйган. Тик нишләп машинасын басуда калдырган ул? Эшкә чыкканнар дисәң — иртә әле. Төнлә кайтмаганнар дисәң — басу юеш.

«Ниемә дип баш катырам соң әле, миңа димәгәе, ник чукынып китми шунда Сибгатуллиннары. Барыбер сытып ташлыйм әле мин аны!» — дип, ачу белән сүгенеп куйганнан соң, Әкбәровка җиңелрәк булып китте. Тик күңелгә этлек дигән нәрсә бер кереп урнашсамы? Ул этлек барыбер үзенекен эшләргә тиеш. Югыйсә Барый булмый бит ул...

Зур тизлек белән басу юлыннан чапкан комбайнның бер канаты яр буендагы машинаның әрҗәсе кырыена эләгеп китте. Дыңк иткән каты тавыш чыкты, нәрсәдер шатыр-потыр килде, яңа машина, урыныннан кузгалып, тирән елгага таба тәгәрәде. Бу вакытта комбайн асфальт түшәлгән юлга күтәрелеп маташа иде инде.

Хуш, асфальтка чыкты инде болар, хастаханәгә дә ерак калмады, барып җитәрләр әле, шәт. Ә менә өр-яңа «КамАЗ» әлегесе минутларда маңгае белән сусыз елгага төшеп кадалган иде. Руль артында йокымсырап утырган Сәмигулла уяу кеше булып чыкты: машина яр буена җитәргә дүрт-биш адым кала, арткы тизлеккә салып, муфтадан аягын алды. Машинаның баруы кимеде кимүен, тик ул барыбер ярдан аска мәтәләсе иде инде.

Сәмигулла үзенең исән калуын балалары хакына дип уйлады, алгы тәрәзәгә маңгае белән төртелеп алган Гөлйөзем дә бердәнбере — Әнвәре бәхетенә дип юрады.

Машинага шактый зыян килгән. «Өр-яңа «Нива» белән түлисе булыр инде моны Сибгатуллинга!» — дип офтанды Сәмигулла. Ә Гөлйөзем куркуыннан чытырдап ябышкан, бер кулы белән маңгаен тоткан, икенчесе Сәмигулла муенын кыскан. Муен сөякләре чатыр-чотыр килсә дә, Сәмигулла араланырга ашыкмады, бу вакытта икесе дә исән калганлыкларына тәмам ышанып беткәннәр, әмма бик каты каушаганлыктан, әле дә булса зур аптырауда иделәр. Иң беренче булып Сәмигулла аңына килде, ул борыны белән хатынның ике күкрәк арасына төртелгән хәлдә иде. Йөзенә яшь хатынның ачык изүеннән кайнар дулкын бәреләә. Бу дулкын әле яңа гына исхуш җыйган Сәмигулланың янә аңын алды: ул, әсәрләнеп, хатынның изүен аерып төшерде, халат төймәләре борчаклар кебек машина тәрәзәсенә сибелделәр. Теге дулкын тагын да кайнарланды, Сәмигулла, үз-үзен белештермичә, юеш борыны белән ике күкрәк арасына кадалды. Әле генә теге дөньяның капка төбенә килеп җитә язган хатын, кытыклануга түзә алмыйча, чырык-чырык көлә башлады.

Җил исеп куйды. Яр буенда укмашып үскән тал агачлары салмак кына, бер җайга гына тирбәлергә кереште.

Бу мизгелләрдә өр-яңа машинаның ватылу кайгысы да онытылып торды. Ә югыйсә... югыйсә бар да юктан гына башланган кебек иде, шайтан алгыры!..

Сибгатуллинга яңа машина алырга Сәмигулла үзе ярдәм итте. «Сөйләшеп куйган машинам бар, хатын, җиңел машина, дип, авыз суын корыткач, «КамАЗ»га барган җиремнән, «Нива»га атланып кайттым, «КамАЗ»ны син ал», — диде. Фермерга йөк машинасы кирәклеген ишеткән иде ул. Икәүләшеп барып машинаны алып кайттылар. Кайтуга, Сибгатуллинга кереп, яңа машинаның юл тузаннарын «юдылар», аннан соң, шул ук машинага утырып, Сәмигулла үз авылларына кайтырга чыкты. Бу вакытта төн уртасы җитеп килә иде инде. Мари авылы аша узганда, Сәмигулла бер капка төбендә Әкбәров машинасын күреп алды һәм Барыйга булган үче исенә төште. Ул, «КамАЗ»ын авыл башына чаклы чыгарып куеп, кире килде дә үткен без белән тәгәрмәчләренә төртеп чыкты, аннан соң, ачуы моның белән генә басылмагач, башында яңа план туды. Яшьтәшләр булып ун ел бер парта артында ыштан төбе туздырсалар да, Барый белән дус түгел алар, хәтта бер-берсен сөймиләр, күралмыйлар. Ләкин моны берәүгә дә сиздергәннәре юк, икесе дә эчтән генә көяләр.

Сәмигулла туп-туры урманга таба чапты. Капкасын дөбердәтеп, Гөлйөземне уятып чыгарды. Ике-өч көн элек кенә Барый килеп, сине генә сөям, дип антлар эчеп, тиздән өйләнешәчәкбез, дигән хәбәр дә калдырган иде, шуңа күрә ул әүвәл исерек Сәмигулланың яңагына чылтыратырга уйлады, тик ниндидер эчке хис аны туктатып калды һәм шул мизгелдә үк күңеленә хәерсез шик кереп оялады. Кызыксынуы бик көчле иде, бәлкем, көнчелегедер... Әмма икеләнүе дә

юк түгел. Шулай да ул беркавым аптырап торды-торды да, вакыт таңга таба авыша башлаган бер мәлдә, халат өстенә юка куртка гына элеп, «КамАЗ» кабинасына үрмәләде.

Алар дамбадан Сибгатуллинның арпа басуына борылуга, сизгер хатын Чудрасала ягында — тау башыннан төшеп килгән комбайнны күреп алды. Комбайн таң белән кырга кузгалган, димәк, наряд бирелгән дигән сүз. Мари кызының җылы кочагыннан нишләп болай иртә торып китәсе итте икән соң бу Әкбәров?

**Гөлйөзем**

Мин үземне үз хисләремнең колы дип уйлый башлаган идем инде.

...Үч минем тарафтан бу юлы алынмый калды. Тагын Барый!

Рәхмәт төшкере — коткарды бугай ул мине... Үч алу гөнаһыннан... Ә үзе гөнаһлы булып калды, бахыр...

Сәмигулла хатыны Рәзифәне Мөхәммәт катына җибәргән! Мин үзем дә Сәмигулладагы үчемне аның хатыны аша алырга уйлап тора идем. Рәзифәнең иләс-миләс икәнлеген сизә идем бит. Ләкин исәбем монда һич кенә дә Мөхәммәтне катнаштыру түгел иде!

Чү, туктале, тукта, Гөлйөземкәем!.. Тагын алдашасың бит! Җае туры килсә, син дә рәхәтләнеп Мөхәммәтне файдаланган булыр идең ләбаса! Һәм ничек кенә әле!

Һай Аллакаем, үзең саклый күр бу бәндәләреңне җир йөзендәге гөнаһлардан!.. Юкса алар муеннарына чаклы батып бетәчәкләр ләбаса!

Хәерле булсын, тагын аклану булды бугай инде бу... Адәм баласы үз-үзен аклау өченниләр генә кыланмый...

Ә Барый?.. Ни генә әйтсәң дә, аның шулай эшләве мине чиксез куандырды: без икебез дә бер үк төрле уйлый башлаганбыз икән.

Хәерлегә булсын, Ярабби!..

Барый белән икебез дә бертөрлерәк фикер йөртәбез икән... Бу юкка гына түгелдер...

Яше авыша башлаган кыз-хатын мәхәббәт, ярату хакында акыл белән уйлый башлый икән инде ул. Бәлкем, җүләр чакта гашыйк булып, шул вакытта сөйгәненә кушылырга кирәктер кыз балага?.. Тагын сорау инде... Сорау артыннан сорау...

**Җилләр исә, комнар күчә**

Яшьрәк чакта, уку йортын тәмамлагач, авылга кайтырмын да, шулай итәрмен, болай итәрмен, дип корган планнарны тормыш һәр җәһәттән үзгәртеп тора. Чөнки үзе дә үзгәрүчән ул. Шул исәптән кешеләр дә. Кешеләрне тормыш үзгәртәме яисә киресенчә: кешеләр тормышнымы? Гади генә фәлсәфә кебек югыйсә.

Кайчандыр Ил дигән Ил бар иде. Аннары аны Республика дип атадылар. Хәзер — филиал. Урысчасы: «Үзәкнең Казан геополитик филиалы...» Кемнәрдер Идел-Кама филиалы дип тә атый. Кыскасы, кем ничек дип әйтергә иренми инде.

Филиал... Бу яңа сүзне халык бигүк аңлап бетермәсә дә әйтелешенең татарча булмавы күпләрнең күңеленә хуш килде. Өстәвенә бер академик-галим, аз-маз тарихта чокынгалаганнан соң, «филиал» дигән сүзнең чын төрки-татар сүзе булуын исбатлаган иде. Исбатлау бик гади, нәкъ халыкча: «фили» дигән сүздән кыскартылып, чак кына үзгәртелеп ясалган ул. Урыс-француз сугышыннан хәбәрдар булган кеше өчен бигрәк тә гади инде: Фили авылында Кутузов, хәл җыеп, французлардан качып яткан. Тарихи хәлиткеч киңәшмә дә Фили авылында узган. Ә Кутузов — татар малае — андый зур киңәшмәне бары тик татар авылында — Филида гына үткәрә ала! Бу аксиома инде! Каршы да килеп маташмагыз! Иң әһәмиятлесе: ул бик гади, аңлаешлы. Шул сәбәпле «филиал» сүзен Казан халкы үлеп ярата. Казанда урнашкан зур идарәне Дәү филиал дип, аннан да бәләкәйрәкләрен кече филиал яки «фили» дип кенә җиффәрәләр иде. Фили башлыкларын исә «филләр» дип әйтү гадәткә кереп киткән һәм шул гадәт кайбер тишек күзәнәкләр аша канга ук үтеп керергә өлгерде.

Филләр булгач, нигә Һиндстан түгел дигән фикерләр дә йөрде. Чөнки сирәк-мирәк «Татарстан» диючеләр дә очраштыргалый иде әле. Бу фикерне, ягъни Һиндстанны, аеруча бер җирән башлы депутат куәтләде. Аның уенча, бу нисбәттән ныклы дәлиле дә булып, ул шуннан гыйбарәт иде: «Һиндстанда кызлар бик матур була, кинолардан күрсәтәләр бит. Җырлары да ярыйсы гына. Без һинд кинолары карап үстек. Безне яшьлегебездән аерырга берәүнең дә хакы юк!»

...Кәефе әллә ни шәптән түгел. Берәр куян ише нәрсә атып алса, бәлкем, күңеле күтәрелер. Барыйны таң белән фили башлыгы чакыртып алды. Хәзер аның шуннан кайтып килеше. Урман аша узганда туктап алырга да исәпләде, башлык әйткән яңа фикер-идеяләрне дә акылы кабул итә алырлык хәлгә килер кебек.

Фили башлыгы Барый Әкбәровның туган тиешлесе. Чакырта дигәч тә, мунча кертергә түгел икәнлеген белеп барды ул. Зәет Вәлиевич өстәвенә өлкән Әкбәров сөйрәп чыгарган кадр да иде әле. Читләргә ышана торган замана түгел. Бар ышанычлы терәк — туганнарда, малайларда, кыз-кияүләрдә.

— Ике колхозыңны тиз генә тотып берләштерергә кирәк! — диде Зәет Вәлиевич. — Заманның нинди икәнлеген сиңа аңлатып торасы юк.

— Нишлим ди мин ул чаклы авыллар белән?

— Тире җыеп, күн эшләрсең!

— Юк, чынлап та?

— Күрмисеңмени?! Ишетмисеңмени бер дә?! Дөнья кая таба бара! Колхозлар юкка чыгачак, җирләр сатылып бетәчәк!

— Ну...

— Күтеңне у, энекәш! Файдаланып калырга кирәк! Акча күктән яумый ул! Бетә дигәч тә, ике-өч елга сузылыр әле. Акылы булган кешегә шул вакыт бик җиткән инде, зур имчәкнең сөте дә күп була аның.

— Син нәрсә, мине монда тагын өч ел черетергә җыенасыңмыни әле! Казанга китәргә йөргәнемне беләсең бит!

— Китмисең син беркая да, энекәш! Син монда кирәк. Озакламый Франциядән яңа чабышкылар партиясе кайтачак. Кабул итеп алырга җыен.

— Миңа булганнары да җитеп ашкан!

— Ә Мәскәү! Мәскәүне нишләтмәкче буласың! Сөйләштек бит: атлар белән Мәскәүне алырга барачакбыз!

— Син дә Һади абый кебек бер хыялый инде, Зәет Вәлиевич! Мәскәү, имеш! Мәскәү күз яшьләренә ышанмый ул, беләсең килсә! Исләре китәр бик!

— Как так син, энекәш! Күршеләрне оныттыңмыни?!

— Син дә Мәскәүне атлар белән яуларга уйлыйсың инде алайса, кызык... Тик хәзер, Зәет Вәлиевич, самолет ярышлары модада бит инде.

— Мәскәү өчен ат һаман да важно әле. Ат ярышларын уздырып, алар үзләренең элек ничек итеп Казанны басып алганнарын искә төшерергә яраталар. Атлар Казаннан булса, бигрәк тә хушлары китә инде аларның!

— Син нәрсә, Зәет Вәлиевич!

— Ат модасы бетсә, тарих модасы бетмәде.

Әгәр татар атлары Россиядә беренче урынны алса?

— Алай булмаячак. Беркайчан да...

— Нигә алай дисең әле?

— Дим шул... Син иң яхшы атларыңны барыбер общий казанга салырга тиеш буласың. Икенче төрле әйтсәң, сборный командага. Атларның милләтләре юк аларның. Кая ул атларның гына!.. Адәм балаларының милләте дә көчләп юк ителеп яткан замандамы?

— Бу сорауны миңа бирәсеңме, Зәет Вәлиевич?

— Юк, сиңа түгел. Беркемгә дә түгел. Бу сорау җавап таләп итми, энекәш...

Зәет Вәлиевичның урындыгы шыгырдап куйды. Ул шактый гына авыр гәүдәле кеше: чак кына кыймылдауга, урындыгы һәм өстәле берьюлы селкенгәндәй була да читтән карап торган кешегә хәзер үк урыныннан кузгалып китәр төсле тоела. Аның бу гадәтен белмәгәннәр, хуҗаның сүзе беткәнгә исәпләп, үзе дә кузгалып китәргә әзер торыр, тик әйтеп каласы сүзе бетмәгән очракта кызу-кызу сөйли башлар шикелле иде. Барыйга Зәет Вәлиевичның һәр хәрәкәте таныш булганлыктан, ул урыныннан кымшанмады.

— Теге авылларны да миңа кушып, бака боткасы ясамакчы буласыңмыни! Беләсең бит, болай да эшем муеннан ашкан минем: тау башына күченәсебез бар.

— Нием калган сиңа ул тау башында?!

— Уйланган бит инде ул. Халыкны да күпме ризалатып йөрдем, беләсең бит.

— Беләм, энекәш, беләм, яхшы беләм. Тик шуны аңламыйм: нигә кирәк ул сиңа!

— Миңа гына түгел, сиңа да кирәк ул, Зәет Вәлиевич. Халык хәзер элеккеге түгел, грамоталыланды, күп белә, күп күрә башлады. Күтенә утырсын өчен, бер бутап алу кирәк аны. Шуннан

соң тынычлана ул. Аннары инде синең Казансу буендагы чиркәү чаклы коттеджларыңны да, бүтән гаепләреңне дә күрми башлый. Тикшереп йөрергә просто вакыты калмаячак аның.

— Беләм, беләм, Барый туган, максатың ул гына түгел синең! Шыттырма!..

Барый ирен читләре белән елмаеп куйды. «Кемне-кемне, сине хәйләләп булмаганын беләм бит инде мин, Зәет абзый», — дип уйлап куйды ул үзалдына. Әмма һаман бирешәсе килмиме, йә башлаган сүз-фикерен аста калдырасы килмәүдәнме — үзенекен тукыды:

— Точно әйтәм мин сиңа! Әнә кара. Колхозның унтугыз исереген үзем лично автубоска төяп барып айнытып кайттым чуаш карчыгына. Хәзер айнылылар, әнә күпне күрә башладылар. Акыл сатарга остарып киттеләр. Элек мин шуларга, бер ярты куеп, тау-таш җимерттерә идем. Хәзер аркылыны буйга алып салсалар да, акча сорыйлар! Менә бит ул!..

Зәет Вәлиевич көлемсерәп куйды. Барый энесенең сүзләре хак булса да, ниятенең бүтәндә икәнлеген чамалый иде ул.

— Анысы шулай да, тик алай гына да түгел икәнлеген белми дип уйлыйсың инде син. Авылны тау башына күчереп, тарих ясыйсың килә инде синең. Бабаң кебек.

Барый аңа каршы берни дә җавап бирмәде. Үзен аңламаганга Зәет абзыйсына ачуы да килми аның. Аның бу симез гәүдәле элеккеге спортсмен абзыйсы еракка китәчәк, үсәчәк әле. Һәм үз артыннан энесен дә ияртәчәк. Чөнки Барыйның әтисе алдында аның гомерлек бурычы бар, Хаҗи ага туганнан туган энесен сәнәктән көрәк ясаган кеше бит. Теге чакта ук.

Барыйның артык сүз куертып торасы килмәдеме:

— Ярый, синеңчә булсын, — дип ризалыгын белдерде.

Бу сүзләрдән соң элеккеге көрәшче утырган урынында янә кузгалып куйды, аңа ияреп йомшак күн урындык һәм өстәл дә кымшангандай булды.

Фили башлыгы үзенең җиңгәнлегенә, дөресрәге, хаклы икәнлегенә ишарәли-ишарәли дә, шуңа басым ясап та кызу-кызу сөйләргә кереште. Барый чамалады: Зәет абзыйсы үз сөйләгәненә үзе дә ышанып җитми, бәлкем, шул рәвешле Барыйдан һәр җөмләсенә хуплау да көтә торгандыр, андый чакта кызу сөйли ул — стенага борчак белән аткан шикелле:

— Соң, менә үзең уйлап кара: дөньяларның кая таба барганын хәзер сиңа берәү дә әйтеп бирә алмый. Бүген болай, иртәгә тегеләй. Киләчәк турында кайгыртып калырга кирәк. Тора-бара ул синең зурайтылган хуҗалыгыңның җирләрен уңга-сулга ата, өләшә башлаячаклар. Ә җир ул — дөньяда иң зур капитал! Җирсез пычагым да кырып булмый! Вакыты җиткәч, без аны үзебезнеке итәчәкбез. Эшләр шуңа таба бара бит, энекәш. Ашарына сорамаячак бит ул! Акыллы кешеләр шулай итә. Ә хәрәкәт булсын өчен безгә авылларны күчереп йөртү генә җитми әле! Шул чабышкыларың белән шаулап барып, даулап җиңеп кайтсаң, ә! Әкбәров тик ятмый, Әкбәров эшли, молодец, диячәкләр! Ә авыл күчерү дигәннән... Эшлә син аны, хәрәкәт файдалы нәрсә ул. Нәрсә, халык бик риза түгелме?

— Хәзер сорап та торган юк инде. Тау башыннан бер ун иң шәп участокны сайлап, бүлеп куям да күченү башланганлыгын игълан итәм. Тизрәк әйбәтрәк җирне эләктереп калу өчен талаша-талаша күченәчәкләр. Хәер, кайберәүләр белән аерым сөйләшеп чыгасы булыр әле.

Икесе дә бер-берсенә карап елмаешып куйдылар.

— Колхозны алып бару барыбер җиңел түгел хәзер. Койрыкны сыртка саласы булыр.

— Әле хуҗалык рәисен... и тагын берничә кешене генә туйдырырлыгы бардыр ич?

— Сукыр күздән дә яшь чыгар, ди. Әгәр чынлап торып... Беләсең, мин елап йөрергә яратмыйм.

— Белеп тор, энекәш, сине зур тәхеткә бары тик атларың гына илтәчәк!

— Атка атланып, дисең инде алайса?

— Атка атланып... Ниме... Израэль ничек анда?

— Асфальт салынгач, кышын да шунда гына яшәп ятарга уйлыйлар бугай, — диде Барый Зәет Вәлиевичның соравына каршы. Өстәп тагын нидер әйтергә уйлаган иде, тик тыелып калды: фикере очланып җитмәгән идеме яисә үзенең бу хакта артык сүз куертып торасы килмәде инде. Зәет Вәлиевич әңгәмәдәшенең колагы селкенгәннән дә ни хакында уйлаганын чамалый торган сәләтле кеше, ул да беркавым тынып торды. Икесенең дә бу темага сүз куертасылары килә, хәтта бик килә, тик җепнең очын ничек сузарга гына белмиләр. Израэль Исаевич күрше яһүдләр бистәсендә җаен яшәп китә торган шәһәр кешесе. Шәһәрдә фәнни институтта галим булып эшли. Күптән түгел генә Барый аның белән умарталыкта корт балы чөмереп утырды. Халык санын алу вакыты иде бу. Шуңа күрәдер дә сүз гел сәясәт хакында барды бугай.

— Әгәр юл салсагыз, кышын монда яшәргә әзер без, — дип куйган иде шул чакта Израэль Исаевич. — Кстати, перепись вакытында мин татар булып язылырга уйлыйм әле. Әнә керәшен татарларыгыз урыс булып йөрсеннәр!

— Әгәр сезнең бистәгә чаклы асфальт юл салсаммы? — дип сораган иде Барый.

Израэль Исаевич әлеге җавапка күптән әзер иде, күрәсең, уйланып, икеләнеп тормады:

— Әгәр юл салсагыз гына да түгел, үзебез теләп татар булып язылырга әзер без.

— Аннан соң гомерегез буе татар булып йөрер идегезме?

— Без урыс булып та, мари булып, чуаш... тагын әллә кемнәр булып әле... хәтта негр булып та языла алабыз. Тик без барыбер еврей булып калачакбыз!!! Ә сез татарлар алай түгел. Әгәр татар кызы урыска кияүгә чыга икән, аның баласы да, үзе дә шундук марҗага әйләнәчәк. Татар егете марҗага өйләнсә дә, нәкъ шундый ук хәл булачак!

— Ничек?

— Тора-бара чукыначак ул барыбер!

Әкбәров, шул сөйләшүне исенә төшереп, көлемсерәп куйды.

Фәлсәфә фәннәре докторы профессор Израэль Исаевич Вороновның яратып әйтә торган бер сүзе бар: «Җилләр исә. Комнар күчә...»

...Хак булып чыкты: соры карга баласы, чак кына тернәкләнүгә, үзенең ямьсез холкын күрсәтә башлады. Башка балаларга караганда ул иң күп ашаучан булып чыкты, анасы алып кайткан җимне иң беренче булып каптырып алырга гына тора, җим иң әүвәл үзенә эләкмәсә, дөнья бетереп каркылдый, — ул нәкъ бүтән карга балалары кебек кычкыра иде, талаша, башкалар авызыннан тартып алмыйча, һич кенә дә тынычланмый.

Каргалар ел саен оя кора торган агачлыкта тынычлык бетте. Кара булмаган кара карга баласы, тамагы ачуга, башкалар кебек сабыр гына әнкәләре кайтканны көтеп ятмый — дөнья бетереп кычкырырга керешә. Балаларына җим эзләргә дип киткән каргалар, бәла килгәндер дип белеп, тизрәк агачлыкка ашыга, кайтып керсәләр, бернинди куркыныч юк, кара булмаган кара карга баласының бары тамагы гына ачкан, шуңа күрә дөнья куптарган!

Башка кара каргаларның тәмам үзәгенә үтте инде ул...

...Районнан — кече Филидан кайтышлый Байтимер юлы урман аша уза. Урманга керүгә, Барыйның күңеле кытыклана башлый: кеше башлы теге бүре белән тагын очрашасы һәм, бу юлы аны атып үтереп, җанына кереп оялаган хәерсез хистән котыласы килә.

Ләкин бүген никтер аның ялгыз башы гына урманга керәсе килмәде. Капылт борылып, яһүдләр яшәгән авыл ягына каерды. Израэль Исаевич кичә кич Казаннан кайткан булырга тиеш, вакыты булса, ул, Әкбәровка утырып, басу-кырларны әйләнеп йөрергә ярата, соңыннан алар һәрвакыт, умарталыкка туктап, корт балыннан авыз итәләр, вакытлары иркенрәк чакта, мунча яктырып, дөбер-шатыр чабынырга яраталар.

Зәет Вәлиевич, бая Израэль хакында сүз чыккач, көрсенеп: «Сиңа ФСБдан килгәннәре юкмы?» — дип сорап куйган иде. Көтелмәгән әлеге сәер сорау Әкбәровны аяктан ега язды: «Нишләп миңа ФСБдан килергә тиешләр соң әле? Аларга эшем төшкәне юк минем!» — дип, гаҗәпләнүен белдерүгә, Зәет Вәлиевич, бик тырышып, сүзне икенчегә борып җибәрде. Хәзер Барый шул хакта аптырап уйланып бара һәм бу турыда Фили башлыгыннан төпченмәвенә үкенә. Инде ул урман юлына кермичә Израэль Исаевичка борылуына үкенә үк башлады. Әле соң түгел иде, машина капма-каршы якка борылды.

Казанга якын булгач, яһүдләр авылда яшәп яталар. Дөресрәге, аларның барысының да эш урыннары шәһәр җирендә, яшәүләре халык теленә «Тол-Әби» («Тель-Авив») дип кереп калган шушы авылда. Күрше авылларда гына татарлар җир сөреп гомер итә, марилары да шушында. Яһүд белән урыс шәһәрдә. Тик аерма шунда гына, урыс шәһәргә бөтенләй качты, нигезен төбетамыры белән йолкып алып китте, яһүднең исә эше генә шәһәр җирендә. Һич аңлап була торган халык түгел үзләре. Шулчак Мөхәммәтнең дус шагыйре сөйләргә яраткан берничә юллык шигырь исенә төште.

Иван — Абрам Тәхет бүлә,<br>
Кан чыгарып талаша.<br>
Гали дәшми, әле һаман<br>
Ул аларга булыша<br>
...Һәм ярарга тырыша.

Иван — Абрам Бәхет бүлә,<br>
Тир чыгарып көрәшә.

Гали дәшми, ул юаш шул.
Куркып тора янәшә,
Үксеп тора янәшә.
Иван — Абрам Ил бүлешә,
Кисәкләп алып тора.
Ә Гали калып тора,
Ул янә калып тора,
Ул һаман калып тора...

«Яһүдтән дә акыллырак халык юк дөньяда», — дип сүз кушканы бар Барыйның Израэль Исаевичка кайчандыр, умарталыкта хәл җыеп ятканда булды бугай мондый сөйләшү. Аның бу сүзләреннән карт яһүд рәхәтләнеп көлде, аннары, күз яшьләрен сөртә-сөртә: «Бар дөньяны кайнатып яталар, дисеңме?» — дип гөрелдәде.

— Кайнатса да... акыл белән.

— Палестинада яшәүче мөселман булсаң, алай димәс идең син, әлбәттә.

— Анысы сәясәт. Пычрак сәясәт.

— Мировая гегемония, — дип өстәп куйды Израэль Исаевич һәм беркавым зур зәңгәр күзләре белән аяк астындагы үләнгә төбәп карап торды, аннары борынын тартып куйды. Нинди дә булса җитди нәрсә хакында уйлаганда, аның борыны гел юешләнә иде. Шуннан соң көтелмәгән берәр фикер әйтеп куячагын көт тә тор инде син аның...

— Еврейларның һәммәсенә дә бер үк төсле карарга ярамый. Еврей күп вакыт үз башын үзе ашый. Троцкий, Зиновьев, Каменевлар...

— Әйе, аларның үзләрен дә юк иттеләр.

— Хәзер дә шулай әле ул. Киләчәктә еврей халкын олигархлар харап итәчәк! Урыс илендә еврей революция дә ясарга тиеш түгел, олигарх булырга да хакы юк. Рәсәй еврей өчен куркыныч ил. Урмандагы кыргый аюның холкын аңлап булмаган кебек, аның да холкын аңлап бетереп булмый. Еврей үзе уйлап чыгарган яңа тәгәрмәч тора-бара аның үзен дә сытып китәргә бик мөмкин. Олигархлар шуны аңламыйлар. Яңа Сталин килеп чыкмас дип, кем гарантия бирә ала бу илдә!

Умарталык тау битенә урнашып, аннан Байтимернең бәрәңге җирләре дә аермачык булып күренеп тора. Әңгәмәдәшләр икесе дә сүзсез калдылар һәм карашлары таудан түбән тәгәрәп төшеп китте. Байтимер халкы бәрәңге алып мәш килә. Күбесенең бакчасы лапас артында гына, бәрәңге җирләре тау битендә. Әнә берәү «уфалла» арбасына ике капчык бәрәңге салган да аны тауга каршы өстери. «Сираҗи карт, — дип уйлап куйды Барый эченнән. — Нигә азаплана инде бу Алла бәндәсе! Иртәгә, шимбә көнне үк, шәһәрдәге биш баласы кайтып, бәрәңгесен күз ачып йомганчы алып бирәчәкләр бит инде югыйсә! Юк, ул үзе азаплана, балалар кайтканчы бераз булса да киметим, ди торгандыр. Тау астындагы капчыкларына караганда бераз гына казылмаган инде. Таң белән кузгалгандыр».

Урман буендагы кардыга чабышкы атларны алып кайтып тутыргач, иң куанган кеше Сираҗи карт булган иде. Ул үзе яшь чакта колхоз атларын караган. Хәзер колхозның сыңар аты да калмады. Халык сугыш вакытындагы кебек яңадан уфаллага күчте. Җәй көне бәрәңге араларын да кул белән китмәнли, икенче катын сукага үзе җигелеп, тартып сыза.

— Рәхмәт, улым! — дип сөенде Сираҗи карт, чабышкы атларны кайтарткач. — Авыл атсыз була алмый ул! Дөрес эшләдең, маладис! — дип, чын күңеленнән сөенгән иде. Иртән идарәгә, бәрәңге ташырга, ат сорап та килгән иде картлач. Халык аннан егылып көлде. Аннары: «Чабышкы атлар бит алар! Берсе-берсе миллион сум тора!» — дип, картны өенә кайтарып җибәрделәр. И моңсуланды шул чакта Сираҗи карт. Әйтәсе сүзен дә әйтеп китте: «Ат булып та, аны җигәргә ярамагач инде... Ничек була инде ул? Хуҗа Насретдин ишәге кебек килеп чыга бит инде бу! Үзең ишәккә атлан, үзең капчыгыңны аркаңа ас... Ат була торып та аны җигәргә ярамагач инде... Ничек була инде бу?»

Израэль Исаевич та шул хакта уйлап тора торгандыр кебек тоелды Барыйга. Иптәшенең уе башкада икән:

— Синең теге чиркәвең... тау башына салыначак мәчетең ни хәлдә соң әле? — дип сорады ул.

— Чиркәү дә түгел ул, мәчет тә. Бар диннәрне... дөресрәге, төп өч динне берләштерәчәк храм.

— Хаталанасың син, Барый Хаҗиевич.

— Бар диннәр дә үзара тату яшәсәләр, начар булырмы?

— Начар булмаячак булуын. Тик аңла: хәзер Рәсәйдә идеология калмады. Элек коммунизм бар иде. Ул идеология иде әле. Шул идеология белән балалар тәрбияләдек. Идеология булмауның иң коточкыч ягы шунда: тәрбия мәсьәләсенә зыян киләчәк! Ә буыннарны юньләп тәрбия кыла алмасак, һәммәбезгә грош цена! Цивилизациянең төп эше үзенә лаеклы алмаш тәрбияләү. Татарларга тәрбия эшендә нигә ислам динен файдаланмаска! Үз динен христиан да эшкә җиксен, башкалары да!

— Вахабизм, дини секталар үрчесен дипме?

— Рәсәй кампанияләр иле. Чиктән чиккә ташланырга яратабыз. Ә нигә уртадан гына бармаска? Тәрбия эшендә ислам диненең энҗеләрен генә булса да файдаланып була лабаса! Урысны урыс итеп, татарны татарча, еврейны еврей итеп тәрбияләргә кирәк. Бу, туган, аксиома! Һәр халык үз динен эшкә җигәргә тиеш...

Бу сөйләшү аның күңеленә шом салды. Аннан соң карт яһүднең әлеге фикерендә ныклы мантыйк та бар. Гомумән, аңа каршы бәхәсләшү һәрвакыт файдасыз була.

* * *

Урман авызына килеп җитәрәк, Барый, машинасын туктатып, биштән корыла торган мылтыгын күн капчыгыннан салдырып алды һәм әзерләп утыргычка куйды. Ялгыз башы гына урманга мылтыксыз кергәне юк инде аның: һәрвакыт бала башлы бүре белән очрашуны көтә, дөресрәге, ул аны үзе күптәннән, бик күптәннән эзли, әгәр очратып, шул хәерсез җанны атып ала алса, бу — Барый өчен гаҗәп зур җиңү булачак, аның шомлы җанына мәңгелек тынычлык иңдерер әле, бәлкем...

Мылтыкны алдан әзерләп кую күңелен тынычландырды. Япон «джибы» сикәлтәле урман юлында бала бишеге кебек йомшак кына тирбәлеп бара, Барый үз уйларында. Ә уйлар исә бүген, Зәет Вәлиевич белән сөйләшүне исәпкә алмаганда, бик тәмле, татлы иде, чукынчык!.. Гөлйөземгә өйләнәм дигән катгый карарга килгән мизгелләр бит. Өйләнәсе килгән егет кәҗә сатып өйләнә дигәндәй, Барый ничә еллар инде үз күңелендә бәйдә торган үзсүзле, киребеткән һәм карышкан кәҗә бәтиен башы-аягы белән сатып җибәрде — ныклы фикергә килде: ул өйләнәчәк һәм бары тик Гөлйөземгә! «Малаемның әнисенә өйләнәм!» — дип, үзалдына шаяртып көлемсерәп тә алды. Бу өйләнү түгел, сөйләнү генә булып калмасын өчен, Барый әлеге эшне озакка сузарга ярамаганын да чамалый һәм урманны чыгуга кесә телефоныннан Мөхәммәткә шылтыратырга, яңалыгы белән уртаклашырга, берочтан Гөлчәчәк хакында аның да фикерләрен тартып карарга ниятләде. Италиядән кайтканнан бирле, Мөхәммәт белән күрешкәннәре юк әле. Сәфәрдән кайтуга мин дә өйләнәм, дигән шикеллерәк фикер әйткән иде бит дусты. Барый шулай дип уйлауга, күз алдына капылт кына Сиринә Самуиловна килеп басты. «Неужели, шул баба-ягаһың кармагыннан ычкына алырсың?» — дип, дусты хакында борчылып куйды. Өстәвенә узган күрешүләрендә Хәниф Хатыйпович та Мөхәммәт белән ул хатын арасындагы мөнәсәбәтләр хакында бик җентекләп сораштырып торды. Серле дә, шикле дә иде бу кызыксынулар. Хәниф Хатыйпович филнең сыртында ук утырмаса да, аның койрыгына тотынган кеше һәм бик каты ябышкан, филнең нечкә койрыгы шартлап өзелмәсә, үз теләге белән генә гомер ычкындырачак түгел ул аны... мәңге ычкындырачак түгел...

...Байтак вакыт узуга карамастан, урман Пиратның эт канын кысрыклап чыгара алмады. Чөнки урман хәзер кыргый түгел, ул кешеләр кесәсендәге шырпы кабы кебек таушалган: таланган, тапталган, аударылган, киселгән. Пират кешеләрне сагынып яшәде. Төннәрен авылга да еш килгәләде, абзар-кура тирәләрендә дә йөрде, берзаман хәтта төнлә лапас артларында куна торган булып китте, таң беленә башлауга, урманына кире чаба иде. Моның шулай икәнлеген авылда бер генә кеше сизенде, Пират аны белмәде, авылга килүен дәвам иттерде. Ә теге кеше аны авыл этләре янына йөри дип уйлады һәм авылдагы бәйсез этләрне атуны үзенә максат итеп куйды. Авылда ул кешегә каршы авыз күтәреп беркем бернинди сүз әйтә алмый.

Үз аркасында эт туганнарына нинди зыян килүен аңлый алса, әлбәттә, ул авылга аягын да басмас иде. Хуҗаларын тыңламыйча, бәйдән ычкынып, бер рәхәтләнеп уйнарга атлыгып торган эт-җаннар кырыла торды. Этсез яшәүгә өйрәнмәгән Байтимер халкы атылган этләре урынына яңаларын (шәһәрдән зур бәяләргә усал овчаркалар, тагын әллә нинди токымлы кыяфәтсез, әмма бик явыз этләр алып кайтып бәйләделәр. Зур акчаларга алынган булгач, бу этләрнең бәйләре бик нык, ансат кына ычкынырлык түгел иде инде) булдырдылар. Акчага алынган этләр чыннан да бик зәһәр, куркыныч һәм дәһшәтле иделәр. Әгәр дә мәгәр аларның һәммәсе ычкынып берьюлы урамга чыксамы?..

Бер дә бер көнне муенчагын салуга ирешкән Актырнак кушаматлы бер чибәр авыл эте Пиратка «кияүгә» чыгып алды. Гадәттә, берьюлы бишәр-алтышар бала китерә торган Актырнак бу юлы бер малай гына алып кайтты. Ул малай бик шук булып үсте, күзе ачылып, аяклары йөгерекләнүгә, капка астыннан урамга чаба һәм шул гадәте бәйдәге әнкәсен еш кына хафага сала иде. Шулай бер чыгып китүендә көчек кире әйләнеп кайтмады. Бик зарыгып, борчылып көтте аның кире кайтуын Актырнак. Вәсвәсәләнгән әнкә соң чиктә түзә алмады, ничек итсә итте, бәйдән ычкынды да, лапас астыннан гына шуып чыгып, баласын эзли китте. Авыл буйлап озак эзләде ул аны, җимерек бәрәңге лабазларына керде, ферма буйларын айкады — көчек табылмады. Бәлки, өйгә кайткандыр дигән нindидер эчке сиземләү белән авылга таба чапты. Шулчак аяз көнне яшен яшьнәгәндәй булды, нәрсәдер шарт итте, Актырнак, чак кына ял итеп алырга уйлагандай, комлы юлга сузылып ятты. Юл буйлап озын кызыл тасма сузылды...

Малай бу вакытта авыл янәшәсендәге мари урманында куян боты кимерә иде. Куянны үзе тотмады ул тотуын, аны бер зур эт-бүре сыйлады. Алай мәрхәмәтле булгач, ул аның артыннан ук тагылып йөри башлады. Абый-эт сүз әйтмәде, каршы килмәде, киресенчә, ул моңа үзе дә бик шат бугай.

Малайларны уеннан, шуклыктан тыеп буламыни соң инде?! Көчек урманда да үзен бик чос тотты, вакыт-вакыт абыйсыннан аерылып та калгалады. Шундый чакларның берсендә, көчек кешеләргә тап булды, дөресрәге, кешеләр аңа тап булдылар. Урман аланында ялтыравыклы матур машина тора. Ишекләре ачык. Яшь бер кыз үлән арасыннан җиләк эзли. Менә ул машинага сөялеп торган егеткә таба борылды да:

— Син быел мине джунглига алып барам дип обещать иттең! — диде чытлыкланып.

— Безнең свадебное путешествие Кипрда узачак!

— Юк, юк! Мин джунглига барырга телим! Анда барып Мауглины күрәсем килә!

— Мауглины? Әгәр дә ул чынлап та шунда икән, мин сиңа Кипрдан соң ул Мауглины тотып алып кайтып бирәм! Читлеккә ябып асрарсың!

— Ха! Сиңа тагын Мауглины тотарга!

— Мин үзем тотмасам, башкалар тотып бирер! Акча күрсәтсәң, Мауглины гына түгел, фил көтүен дә самолетка төяп җибәрерләр!

— Мактанчык син! — дип куйды кыз һәм урман аланын яңгыратып көләргә кереште. Аның бу көлү тавышы һәрвакыт егетнең кендегенә генә килеп кадала, аңа рәхәт булып китә, каны кызыша башлый. Ул кызны эләктереп алды, җай гына, саклык белән генә йомшак үлән өстенә салды һәм шашып-шашып үбәргә кереште. Кызны әллә аландагы үлән кытыклады, әллә егетнең яңа чыгып килгән сакалы — аңа рәхәт иде, ул чырык-чырык көлде, иркәләнде, иркәләде.

— Мин үзем Маугли сиңа, мин — кыргый! — дип сөйләнә-сөйләнә, егет кызның киемнәрен аерып төшерде. Мондый кыргыйлык кызга да рәхәтлек бирә иде, күрәсең, ул чырык-чырык көлүен дәвам итте. Алан кырыенда утырган карт нарат, нәрсәдәндер оялгандай, чал башын түбән иде. Аның иң югары ботагына кара карга баласы килеп кунды. Кара булмаган кара карга баласы текәлеп-төбәлеп аланга, алан уртасындагы үләндә аунаган ике адәмгә карап торды торды да каркылдап кычкырып җибәрде. Урман әүвәл карга баласының тавышын үзенә йотты, аннары беркавымнан аны кайтаваз рәвешендә, Гомәр Хәйям робагые итеп, алан өстенә сипте:

Чынлап та шундый түбәнлекме?  
Каны кайнаган тәнеңнең колы бул әле!  
Бу дөньяда берәүнең дә хәтта  
Теләгенең сусавын басалганы юк әле!

Кызның кинәт ачыргаланып кычкырган тавышына карт нарат, куркынып, чал башын югары күтәрде, аның шәрә ботагына кунган кара карга баласы чак кына егылып төшмәде. Алан кырыенда ялтыравыклы машина күреп туктап калган көчек исә куркуыннан чинап җибәрде. Югыйсә мәсьәлә бик гади, куркырлык, коточарлык берни дә юк иде: кызның йомшак җиреннән бер өер кырмыска көтүе генә йөгерешеп узды. Киресенчә, карга баласыннан, карт нараттан һәм көчектән дә бигрәк, кыз үзе курыкты, чөнки аяусыз кырмыска көтүе тешләпме-тешли, өстәвенә кызыкай үзенә нинди дошман һөҗүм иткәнен аңлап та җиткерми — иң куркынычы әнә шул булгандыр да әле.

Пират якын-тирәдә генә йөри иде, көчекнең ачыргаланып чинаган, елаган тавышына ул уктай атылып аланга килеп җитте, килеп тә җитте, аны-моны абайлап өлгермәгән егеткә ташланды да. Тегесе куллары белән этнең һөҗүмен кире кага-кага ничек итсә итте, тиз генә машинасына кереп утыра алды һәм ишекләрен шартлатып ябып куйды. Ә эт усал иде, бу мизгелдә

аның тамырларын тутырып бүре каны ага башлаган иде, ул машина тәрәзәсенә сикерде. Бу егетнең тагын да котын алды, ул җәһәт кенә машинаны кабызды да, кызны да онытып, урман юлыннан ачыклыкка томырылды. Эт-бүредән, бәлки, ул чаклы ук курыкмаган да булыр иде егет кисәге, ләкин аның да җан җирен нәрсәдер бик каты тешли, үзәкләрен өзепме-өзә инде, нәкъ менә шуннан өректе ул. Һе, кырмыска, иң усал, зәһәр ана кырмыска икәнлеген белсә, сыпырып кына төшергән булыр иде дә бит! Әнә шул белмәве, билгесезлек котын алды шәһәр малаеның!

Пират, көчеген ияртеп, урман ешлыгына кереп югалды.

Ә кыз тәнен кырмыска һөҗүменнән коткару белән мәшгуль иде.

Бу вакытта Барый да аланлыкка җитеп килә, каршысына томырылып чабып килгән «джип»ка чак кына юл биреп өлгерде. Юл бирер өчен читкә каерды, машина буявында агач сыдырган урыннар калды. Ачудан, кире борылып, үз биләмәсендә чатыр чабып йөргән чит машина хуҗасының арт сабагын да укытырга уйлады, ләкин аланлыкта эт өргән тавыш аны бая ук сискәндереп куйган һәм ул, бар ачуларын онытып, шунда ашыкты. Мылтыгы әзер иде инде.

Аланлыкта җүләр кеше кебек сикергәләп йөргән ярым шәрә кызны күреп, Әкбәровыбыз өнсез калды. Теге чакта, нәкъ шушы тирәләрдә бала башлы бүре күргәч, һушыннан язган иде. Бүген дә аптырау-гаҗәпләнүләренең чиге-чамасы булмады, әмма бу юлы, кыюланып, машинасыннан төште дә кыз янына килде. Тегесе чит кеше барлыгын абайлагач кына үзенең ярым ялангач икәнлеген күреп, карт нарат күәсәсе артына посты. Кырмыскалары коелып беткән иде, күрәсең. Барый, кыз янына килеп, аның өстенә үзенең пинжәген япты. Ни булды, дип сорап тормады, каршысына очраган машинаның нилектән томырылып чапканын чамалаган иде инде. Ул кызны машинасына утыртты һәм:

— Теге бандитны куып тотыйкмы соң? — дип сорады.

— Бандит түгел бит ул! — диде кыз. Аңа янә җан кергән, бәлки, кырмыскалардан котылу сөенеченнәндер, ул чытлыкланып көлә үк башлады: — Булачак киявем ул минем! Атаклы Шаһмәлиев малае! Кабахәт җан! Эттән куркып чыгып качты, артына да борылып карамады! Менә сиңа кияү! Әти иманын укытачак әле аның! Укытмаса, аңа үзе кияүгә чыгар!

Кыз бик чибәр, курчак кебек матур. Йөз-кыяфәтенә карап чамалап була: яше егермедән узган, кыланышлары бала-чаганыкы төслерәк булса да, сазаганга охшаган иде.

— Йә, нишләтим мин сине? — дип аптырап сорады Барый. — Кайсы авылдан соң син, булачак кәләш?

— Казан кызы мин! Казанга илт! — диде кыз, бер дә тартынып, уңайсызланып тормыйча гына. Аннары: — Әти яхшылыгыңны онытмас! — дип тә өстәп куйды.

Барый чарасызлыктан иңбашларын сикертеп алды да машинасын кабызды.

— «Джип» ничего икән синең! — диде кыз, егетне үчекләгәндәй.

— Ничего гына түгел ул, ничегоның да ничегосы!

— Анысы ничек була?

— Ничек буламы? — Бу кыз Барыйның эчен пошыра башлады, шуңа күрә ул, аны үртәгәндәй: — Җирдә дә йөри, суда да йөзә ала! — дип куйды.

Кызыкай беркавым тын гына барды, аннары барыбер түзә алмады, урман авызына килеп җитәрәк янә ачылып китте. Үз хәлен үзе белеп, авызын йомып кына барса да була иде кана!

— Джентельменнар калмады бездә! Ир-ат хатын-кызга караганда да ваграк һәм куркаграк! Их, кайда ул рыцарьлар!

Шушы кыз аркасында тиктомалдан Казан юлын таптарга туры килүенә Барыйның болай да эче пошып бара иде, аның өч тиенлек фәлсәфә сатарга керешүе ачуын гына китерде!

— Ир-атны дуңгыз иткән дә, кондыз иткән дә хатын-кыз! Киресенчә, хатын-кыз калмады бездә! Чүпрәккә әйләнеп беттеләр! — дип куйды ул дорфа гына.

Аның бу сүзләреннән кыз җүләр нәрсә кебек чырык-чырык көләргә кереште. Аннары яшь аралаш:

— Дуңгыз диденме? — дип кайтарып сорады һәм урман шүрәлесе кытыклагандай янә чыңларга кереште.

«Көлүе матур икән», — дип уйлап куйды Барый үзалдына. Тиктомалдан гына аның үзенә дә ничектер кызык булып китте, ләкин барыбер ачылып китәсе килмәде, ирен читләре белән елмайгандай итте.

Кызның көлүе генә түгел, үзе дә гаҗәп чибәр икәнлегенә егетебез бая ук игътибар иткән иде. Ул ара-тирә аерылган изүен каплап куюлары! Үзенең оят җирен болай сәнгатьле иттереп, рәвешен китереп яшерә алу сәләтенә бар хатын-кыз да сәләтле түгелдер!

Тора-бара Барыйның йомык күңеле ачыла башлады.

— Исемең ничек соң синең?

— Аля! — дип җавап бирде тегесе шундук, әйтерсең әлеге сорауны баядан бирле түземсезлек белән көтеп утыра иде.

— Аля гына түгелдер инде?

— Әлфия!

— Исемең матур икән. Мин Барый булам.

— Боря, да?

— Нинди Боря! Барый дидем бит!

— Бааари-и-иии! Звучит! Ә Боря дисәң ярыймы?

— Бөтенләй әйтмәсәң, тагын да яхшырак!

Бу кыз үпкәли белә торган нәрсә түгел иде, ахрысы. Барыйның дорфалыгына да, кирле-мырлы җавабына да әллә ни исе китмәде. Урман буенда сыер көтүе утлап йөри иде, шуларны күреп, кычкырып җибәрде:

— Кара, кара! Сыерлар! Коровы!

— Ну и что. Үгез дә бар анда!

— Ә үгезләр ничәү? Быков сколько?

— Ничә булсын, икәү генә.

— Два быка! Ике үгез! Шулар бар сыерларны да саклый аламы! Урманда бүреләр бар бит!

— Нишләп сакламасын, саклый.

— Ох! Какой джентельменнар! Настоящий рыцарьлар!

Барый аның әлеге сүзләреннән пырхылдап көлеп җибәрмичә түзә алмады. Тора-бара бу кыз чынлап та аның күңеленә хуш килә башлады. Ләкин Казан читенә килеп җиткәннәр иде инде.

Әлфия шәһәргә керүгә төшеп калды.

* * *

Барый туп-туры «ат заводы»на таба юл алды. Үзе оештырып куйган бу утарны «ат заводы» дип ул гына атый. Ат заводы булырга шактый ерак әле. Менә тора-бара кымыз да эшкәртә башласалар, тагын берничә пар гарәп, инглиз-гарәп атлары сатып ала алсалар, авыз тутырып «ат заводы» дияргә булыр иде аннан соң.

Атларга Гөлйөзем хуҗа. Малае Әнвәр белән көнозын ул атлар янында, урманчылык һөнәрен ташлады.

Урманда үскән кызга, бер караганда, урман чытырманлыгы, андагы җанварлары: бүре-төлкеләре һәм дә керпеләре якынрак булырга тиеш иде югыйсә. Юк, Гөлйөземне күбрәк атлар тарта, шулар янында әвәрә килергә ярата, тынгысыз җанына шул рәвешле урын таба шикелле ул. Дөрес, барысын да ташлап, өйдә генә утырасы килгән чаклары да күп була, инде ис-хуш җыя башлаган малаена багышлыйсы килә көннәрен. Әмма бу тулысынча гаилә казанына чуму дигән сүз. Ә алай итәр өчен ул гаиләдә терәк кирәк, дәү мәшәкать — ир заты кирәк. Дөрес, Гөлйөзем башка ир-ат эзләп йөрмәде. Ул барыбер кайчан да булса иләс-миләс Барыеның үз катына киләчәген, китмәскә дип аяк басачагын хатын-кыз сиземләве белән сизенә, күңеле белән шул хәлнең булуын түземсезләнеп көтә иде.

Атлар, атлар... Чиста канлы гарәп атлары үзләренә бер- төрле, каннары кушылган инглиз-гарәп чабышкылары алардан аерылып тора. Америка аты... «Американский сэддлбред» дип йөртәләр аларны. Төсе дә үзенчәлекле: туры, ягъни ялы, койрыгы кара, үзе кызыл. Күрән һәм чемкаралары да бар. Бу хайванның холкы бик акыллы, атланып йөрү өчен дә уңай, алар атлаган кебек тә түгел, әйтерсең биеп кенә баралар. Гөлйөземгә бигрәк тә матур итеп бөгелгән муеннары ошый иде. Холкын аңлап бетереп булмый торган француз юртагы белән чагыштырып булмый инде аны. Ләкин алар бик чыдам. Муеннары да аккош муены кебек озын. Тәртә кебек озын аяклары исә гаять көчле «француз»ларның.

Әнә гарәп атлары. Болар гаҗәп акыллы атлар, өстәвенә бик чыдамнар да әле! Маңгайлары киң, зур булмаган, тар йөзле. Колаклары кечкенә. Сыгылып торган матур муен белән киң күкрәкләр дә әлеге токымның затлы икәнлеген күрсәтеп тора. Әлбәттә, шуңа да карамастан «гарәп»ләрнең аяклары искитәрлек көчле түгел.

Әлеге токым атлары койрыкларын югары, дуга сыман итеп тоталар.

«Инглиз» белән «гарәп»ләрнең каннары кушылгач, инглиз-гарәп токымнары килеп чыккан. Гаҗәп: болары бөтенләй үзгә атлар! Гадәттә алар туры яки карасу-җирән төстә булалар. Аеруча

көчле, бик кыю, тик тора белмәс. Ләкин ышанычлы хайваннар! «Инглиз-гарәп»ләрнең башлары бик матур, гәүдәләре зур, күкрәкләре киң, чыдам, аяклары озын, нечкә. Гөлйөзем бу атларның күзләрен ярата: матур, мәгънәле, акыллы күзләр.

Каннар кушылу нисбәтеннән Мөхәммәтнең үз фәлсәфәсе бар. Италиядә йөреп кайтканнан соң, ул һәр нәрсәне чагыштырып карарга өйрәнеп китте әле. Гөлчәчәген дә берәр маржа белән чагыштырып карамаса ярый инде дип борчыла Гөлйөзем. Ышан син ул байтимерләргә! Барый дустына да охшап куйса тагын...

Гөлйөзем шулай уйлый да тирән көрсенеп куя. Кичә килде бит әнә Барые. Үзе еш-еш сулый, үзе әллә нинди. «Гөлйөзем, без кайчан өйләнешәбез инде?» — ди. Аны бу халәттә күргәч, Гөлйөземнең көләсе килеп китте. Горур Барый исә аның бу көлүен мәсхәрәләү дип кабул итте бугай. Серкәсе су күтәрмәс бәндә! Гөлйөзем аңа бер дә үпкәләми әле, берәү булса, сөйләшеп тә тормаган булыр иде! «Әллә минем хатын-кыз горурлыгым калмады инде?» — дип тә уйлап куйгалый хатын. Әгәр чын ярату үзе булып чыкса?! Бу хакта уйлау күпкә яхшырак, күңеллерәк, рәхәтрәк. Ә уйламыйча гына атларың янында, аларның ялларын тарап, муеннарыннан сыйпап, тыныч кына йөрсәң... Тагын да шәбрәге: алдыңа карап, атыңны куаласаң гына!.. Тик нигәдер, гадәттә, атлар янында озаграк кайнашканнан соң, Гөлйөзем һәрвакыт, нилектән икәнлеген үзе дә төшенмичә, Барыен юксына башлый.

Атлар тынычландыру сәләтенә ия, җәя бавы кебек киерелгән нерв җепләре алар янында йомшарып киткәндәй була. Мөхәммәтнең каннар кушылу фәлсәфәсе дигәндәй... Ат белгечләре моны ничек кенә хупласалар да, барыбер Хак Тәгалә, Табигать-әнкә кануннарына каршы килү ул. Һәр организмга яралганда ук табигый, ыру, кавем дисәк тә була торгандыр, — әнә шундый геннар салынган була, ягъни туганда ук организм туксан процент генофонд — байлык белән туа. Ике кавем кушылу аркасында исә әнә шул генофондка зыян килә, алар буталышып бетәләр, ыгы-зыгы һәм чуалыш башлана.

Барыйдан җигәр өчен гарәп аты сорап йөргән, гомере буе атлар янында кайнашкан Сираҗи карт та, ат белгечләре дә белми иде бу кадәрлесен! Мондый атларны җигеп булмый, хәтта тимер арбаларга да. Колхоз кырында бәрәңге чүпләргә сәләтсез булган Казан кызлары кебек алар, — дискотекада кәҗә кебек сикерергә, таңга чаклы армый-талмый селкенергә мөмкиннәр, — бәрәңге чүпләүгә килгәндә — нуль! Арка-җилкәләре уклау кебек катачак!

Каннар кушылу бигрәк тә адәм баласының генофондына нык тәэсир ясый: геннар буталышып бетәләр, имгәнешәләр, гарипләнәләр, нәкъ менә шуның аркасында аларның балалары гомер буе рухи яктан да, физик яктан да зыян күреп яши. Алай гынамы соң әле: элек акыллы бабаларыбыз, ул өйләндергәндә, кыз биргәндә, милләткә генә түгел, хәтта нәсел-ыруга да бик каты игътибар иткәннәр. Узган гасыр башында һәм аннан да алданрак затлы шәхесләр, генийлар әнә шул татар гаиләләрендә туган. Урыс инкыйлабы һәм төрле репрессияләр аларның башын кисеп бетергән. Шуңа күрә хәзер халык соры массаларга әверелеп бетте!..

Бер караганда, гади генә нәрсә кебек, ләкин алай гади дә түгел икән ләбаса! Халык сарык булдымы, аның җилкәсенә менеп кунаклаган җитәкчеләре дә шулкадәр оятсыз һәм намуссыз була. Ә җитәкче сүзе нәкъ менә шул җилкә дигән сүздән алынган да инде! Аксиома...

...Чит ил тормышын күреп кайту үзгәрттеме Мөхәммәтне, әллә Сиринә Самуиловнаның йогынтысы тәэсир итәме шулай, ни генә әйтсәң дә, ул элеккеге кебек, Гөлчәчәкнең гүзәл образын тудырам да, сөйгәнем белән кушылып, бәхет диңгезенә чумам дип, беркатлы, ләкин саф һәм ихлас уй-максатлар белән яна торган егет түгел инде хәзер. Һай, әйтүче, киңәш бирүче, һич булмаса, колагын борып: «Нишлисең син, егет кисәге! Араңны өз карт хатын белән, яшьлек мәхәббәтең зарыгып көтә ләбаса үзеңне!» — дип кисәтүче юк бит канә! Синең талантыңның нигезендә Гөлчәчәгеңә булган эчкерсез мәхәббәтең ята лабаса!..

Юк шул, тана сөте белән генә керми шул инде ул!..

### «Син — Барый Әкбәров»

Сираҗи карт бәрәңге бакчасында җан тәслим кылды... «Уфалла»сында өчәр кәрҗин бәрәңге салынган ике капчык булган. Кул арбасының тәртә арасында килеш егылып үлгән карт. Йортында гомер буе «уфалла» тотмаган иде (ат җикте бит, кул арбасының кирәге булмагандыр инде) Сираҗи карт. Атын колхозга тапшыргач, каралты-курада арбаише нәрсәнең юклыгы бик тиз үзен сиздерде, кулы балта эшенә дә ябыша иде, арбаны үзе әмәлләде.

Шул көнне ул иртән, ат сорап, колхоз идарәсенә килгән булган. «Буталып йөрмә әле аяк астында! Ат юк сиңа!» — дип, аны бригадир кире борып җибәргән. Авыл телендә сүз иясе белән йөрми, Сираҗи карт бәрәңге бакчасында кул арбасы тәртәсе астында егылып үлгәч, әлеге, бер караганда бик мөһим дә булмаган вакыйганы, — бригадир сүзен, — бар кеше дә белә һәм һәммәсе дә нигәдер картка ат бирмәгән юньсез бригадирны түгел, ул чакта комбайн белән бала табу йортында йөргән Әкбәровны гаеплиләр иде: «Өчәр миллионлык чабышкы атлар — әрәмтамаклар асрап яткан «перси» авыл кешесенә бәрәңге ташу өчен кәҗә бәтие чаклы гына бер чирле атын да бирә алмаган! Оят кирәк! Сираҗи карт рәнҗеп киткәндер әле үзенә!»

Сираҗи карт унике яшеннән колхозда кунних булып эшләмәгән булса, бер хәер иде әле! Оят кирәк! Җаны юктыр аның!

Барыйның җаны да, күңеле дә бар! Әмма халык кайгысын урта буын җитәкчеләр генә түгел, хәтта зуррак түрәләр дә кендектән өскә таба җибәрмиләр иде шул инде... Кендек турысына җиткәч, шып тукталып кала ул, кендек чокыры аларның гадәттә бик тирән була! Ай-һай тирән, баш бармак кереп чумарлык!

Барый моның шулай икәнлеген үзе дә яхшы белә, кемдер әйткән яңа ачыш түгел ул. Тик кайдан белә — анысын тәгаен генә хәтерләми, күпме мәртәбәләр исенә төшерергә тырышып караганы бар инде, һич башына килми. Әллә авыл өстеннән очкан теге кара булмаган кара карга баласы каркылдап-кычкырып узды инде... «Син — Барый Әкбәров. Кеше кайгысын, аларның бетмәс-төкәнмәс моң-зарын кендегеңнән өскә таба җибәреп, йөрәгең белән кабул итмә! Син — Барый Әкбәров бит!»

Барыйның бу хакта уйланганы юк түгел: кендектән өскә китмәгәч, ул йөрәккә генә түгел, акылга да барып җитми ләбаса?!

Димәк, шулай кирәктер инде... Өстәвенә теге кара булмаган кара карга баласы да каркылдагач... Тик ул ямьсез тавышлы карга баласын Әкбәров барыбер атып үтерәчәк әле...

Аристотель адәм балаларының рәхәтен өч төргә бүлгән: рухи, тышкы һәм тән рәхәте. Өстәвенә һәр кеше дә дөньяга үз күзлегеннән карый. Мәсәлән, елгада тавык батып үлгән ди. Меланхолик өчен бу зур фаҗига, сангвиникка бу хәл кызык кына, флегматикның исә аңа исе дә китмәстер, мөгаен. Һәр кеше дә үзенең табигый казанында кайный, тышкы тәэсирләр генә аны ул казаннан тартып ала алмый. Күңел киңлегенең катгый чикләре бар. Хәтта бик тырышып җыйган белем дә әлеге чикләрне артык киңәйтә алмастыр. Иң зур рәхәтлек булган рухи рәхәтлек тә һәр кешенең рух көченә бәйләнгән. Бу рух көченең үлчәме гомер буе бер тамга югарылыгында торачак, өстәвенә томана гомере буе— томана, акыллы үлгәнче акыллы булып калачак!.. Кешенең бәхете дә нәкъ менә шуның белән билгеләнә, кыскасы, бәхет кешенең эчке дөньясына үзе туганда ук салынып куелган була.

Сәламәт хәерче авыру байдан күпкә бәхетлерәк...

Безнең Барый әлегә сәламәт бай иде.

Борынгы фәлсәфәчеләр фикеренчә, талантлы хәерче талантлы байга караганда хезмәт баскычларыннан күпкә югарырак күтәрелергә мөмкин. Чөнки ул ялагайланудан, тәлинкә тотудан һәм җитәкчелеккә ярарга тырышудан тарсынмый. Ул аңа өйрәнгән инде. Ә талантлы бай исә боларның барысын түбәнлеккә санаячак, корсагы кебек бүлтәеп торган горурлыгы аңа, иелеп, башка берәүнең ботинка бавын бәйләргә мөмкинлек бирмәячәк!.. Һәм нәкъ менә шуның аркасында ул арбадан төшеп тә калырга мөмкин...

Безнең Барый яшьтән үк хәерче дә түгел, әллә ни череп тә баемаган, әмма түгәрәк башлы, ягъни талантлы кеше иде. Борынгы заман фәлсәфәчеләре нишләптер мондый категория кешеләрнең киләчәк язмышлары хакында берни язып калдырмаганнар. Алдагысын күзаллау безнең Барыйга бераз кыенрак булыр инде. Берәр очраклык, язмыш очраклыгы ярдәм итеп куймаса. Белмәссең тагын...

Барыйның дөньяга үз карашы. Мәсәлән, аның уенча, горурлыкның иң арзанлы төре — милли горурлык. Шәхес булган кеше кайсы милләттән булуы белән горурланып, барабан кагып йөрми, чөнки милләттәшләр миллионнарча бит! Шәхес булган зат үз милләтенең җитешмәгән һәм көчле якларын күрергә тырыша ул. Ә адәм актыклары, шәхси индивидлары зәгыйфь булу сәбәпле, тизрәк милләт саламына ябышып, быргы кычкыртырга керешәләр, дөбер-шатыр барабан сугып, шуның белән үзләренең табигый көчсезлекләрен һәм дә бушлыкларын тутырмакчы булалар. Мәсәлән, «Кукуруз» күмәк хуҗалыгына кергән мари авылында ничек «чуаш юкәләре» үсә алсын инде! Ә шулай дип җырлар җырлыйлар бит әле! Менә шул була инде ул иң арзанлы милли горурлык!..

Дөрес, мари халкы юкә үстерергә ярата. Кирәк ул аларга — мунчала ясап саталар, чыпта үрәләр, себерке ясыйлар.

Барыйның үзендә исә табигатьтән салынган горурлык бар иде. Гәрчә аның бу горурлыгын колхоз рәисе Хаҗи Әкбәров малае булу белән генә аңлатырга тырышсалар да. Хәер, Барыйның моңа исе китми. Горур дияләр икән яки түгел дип әйтәләрме, барыбер ләбаса! Гарәпләр, коллардан көлеп: «Кол белән шаяртып сөйләшсәң, арты белән борылыр», — диләр. Шаяртканны кабул итә алмый кол әфәнде, чөнки горур, имеш.

Ул намуслымы соң? Гомумән, нәрсә соң ул намус? Бу хакта моннан меңнәрчә еллар элек тә уйланганнар. Һади абыйлары Барый белән Мөхәммәткә юкка гына Ницше һәм Шопенгауэр тәгълиматларын тукымагандыр... Ул фәлсәфәчеләр дә моннан гасыр ярым элек баш катырганнар намус хакында, аның нәрсә икәнлеген аңларга һәм аңлатып бирергә тырышканнар. Тышкы яктан караганда намус ул башкаларның синең хакында ничек һәм ни дәрәҗәдә уйлавы, күңел байлыгыңа, мөмкинлекләреңә мөнәсәбәте. Субъектив намус исә кешенең нәкъ менә шул мөнәсәбәтнең ничек булуыннан куркуыдыр.

Бу тормышта кайнар өчен Барый Әкбәровка әнә шуларны белү дә бик җитеп ашкан. Тагын күз күрер әле...

Хәер, Барыйның авылны тау башына күчерергә йөрүе дә үзе хакында фикер тудырырга теләү түгел микән әле?.. Һәм бу фикер аңа болай капылт кына кайдан килеп кунды соң? Бу фикерне аңа кемдер «төртте» бит?!

### «Абзый» чакырта

Кара булмаган кара карга баласы, бераз тернәкләнә башлау белән, үзен күрсәтергә кереште. Сәер һәм бик әшәке холыклы иде ул. Ояда чакта бүтән балаларны кыерсытып тәмам үзәкләренә үтә. Үсә төшкәч, болай да ташка үлчим холкы тагын да бозылды: явыз, усал иде, берәр нәрсә ошамаса, гел чукырга торды, бүтәннәрнең азыгын тартып алды, әллә нинди ямьсез тавышлар белән кычкыра да, җитмәсә! Әле монысы баласы гына булган икән. Менә берзаман бала каргалар да әткәләре-әнкәләре белән бергә, җим эзләп, басу-кырларга оча башладылар. Юллары авыл өстеннән уза. Карга халкының бер ишесе ияләнгән гадәт буенча юл уңаеннан гына кешеләрнең ишегалларына да төшкәли һәм, хуҗа-фәлән күреп өлгергәнче, тавыкларга куелган җимнәрдән дә авыз иткәли иде. Менә шундый чакта теге карга баласы иң беренче булып берәр кырый йортның ишегалдына чума һәм, тиз генә томшыгына азык эләктереп, аны кабып йотканнан соң, дөнья беткәндәй каркылдарга керешә. Әлбәттә, бу тавышка өйдән хуҗалар йөгерешеп чыга, башка каргалар тавык азыкларыннан сыйланмыйча кала.

Бу хәлгә кәефләре киткән карга көтүе аптыраганнан басуга юл тота. Ә теге мәхлук җан шат, канәгать, көтү алдыннан ул да басуга таба оча.

...Яхшы түгел дип, Барый Сираҗи картны күмәргә үзе дә барырга булды. Әүвәл бармам дип уйлаган иде, шундый чакта кеше күзенә күренеп (Сираҗи картның үлемендә авылдашлары картлыкны түгел, үзен гаепләүләрен сизенә ул), халыкның ачуын кабартып йөрисе килмәгән иде. Әмма күмәр алдыннан, җаен табып, мәрхүмнең карчыгы Галимә әбинең хәлен белеп, күмү мәшәкатьләре өчен шактый акча калдырып чыкты. Моңа, — акчасыннан бигрәк, авыл хуҗасының аерым игътибарына, — карчык кешенең бик күңеле булды. Төн саклаучы карчыклар арасыннан берсе Барыйга: «Бер атыңны җәллләгәнсең шул бичарага!» — дип төрттереп алгач, Галимә әби ахирәтенә ачулы карап, рәисне читкәрәк алып китте дә: «Үләр алдыннан синең теге... бик каты чаба торган атларың янына барып кайтты. Гөлйөземнән сорыйм әле, берәр атын атланып карарга биреп тормас микән, ди. Барды, мәрхүм. Кайтканда бик күңелсез иде. Карчык, малай чактан ат астында үстем. Аннары гомерем буе шулар янында чуалдым, минем күз карашымнан ни теләгәнемне аңлый торган иде ул хайваннар. Ә болар әллә нинди, ди. Нинди була соң ул әллә нинди, дип сорыйм. Менә әллә нинди инде, ди. Күз карашлары да безнең авыл атларыныкы шикелле түгел, ди. Бик күңелсезләнеп кайтты, мәрхүмкәем. Шуннан, җанына урын таба алмыйча, бәрәңге казырга чыгып китте. Югыйсә каладагы балалар: «Кәрәк тә тотасы булмагыз!» — дип кисәтеп киттеләр. Гөлйөзем атлары яныннан кәефе төшеп кайткач, мин дә каршы килеп тормадым инде, берәр көрәк казыр да үзе туеп ташлар әле дип уйладым. Кая инде ул сиксәнне куып барганда бәрәңге казулар! Чыгып китте бу гайрәтләнеп. Берзаман керми дә керми. Аптырап бакчага чыксам, җан биреп ята иде инде. Теле бар иде әле: «Андагы бер атның күзе зәп-зәңгәр иде бит, Галимә...» — дип пышылдады да күзләрен йомды. Халык, Барый улым, сине гаепләп сөйли, борчылма, синең тырнак очы кадәр дә гаебең юк. Зәңгәр күзле ат күреп сәер-

ләнеп йөрде ул соңгы көннәрдә. Әҗәле килеп җиткән булгандыр инде. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмкәемнең...»

Галимә карчык белән сөйләшкәннән соң, Барый җиңел сулап куйды, күмәргә баруы да шуннан иде. Тик күңел дигәнеңне алай гына тынычландырып, ул рәвешле генә алдап буламы соң: авылдашлары ни уйлый икән соң бу хакта? Алар Галимә карчыкның сүзләрен ишеттеләрме икән, юкмы, баксаң, белми дә торганнардыр әле... Барый, Барый... Әллә нишләдең әле син! Элек халык фикерен санга суга торган кеше идеңме соң син! Ник болай үзгәрдең!.. Дөнья үзгәрттемени?! Әйе, шулайдыр шул, үзгәрткәндер... Әнә бит: көн саен диярлек ауга чыккан буласың, бер аксак куян да атып алганың юк. Ә авылга бүреләр ияләшкән, ди. Бүреләре дә әллә нинди аның хәзер, замана бүреләре... Элеккеге бүреләр, авылга килгәч, кәҗә-сарык очрата алмасалар, бәйдәге этләрне булса да буып ыргытып, күңелләрен басып китәләр иде. Ә болары этләр белән дуслашкан дип сөйлиләр! Шаклар катып үләрсең: бүре белән эт дуслашкан! Замана бүреләре, замана этләре шулай буламы икәнни әллә, дип аптырап сөйләшә халык. Кеше кешегә бүре булган бу чуар, болгавыр заманда диген әле син аны!

Барый әлеге «замана бүреләре»нең башында бала башлы теге бүре торганлыгын сизенә иде. Күңеленә шом инде Әкбәровның... Хәерсез, начар шом...

Мөхәммәтнең этисе Уразмәт агай элек әллә нинди хәйләкәр капкыннар эшли иде, хәзер ул күптән пенсиядә инде. Аның урынына калган телсез Габдерәхим дә яхшы капкыннар ясый белә белүен. Тик ул киребеткән, үҗәт адәм сүзне тыңлармы икән соң?.. «Кукуруз»да хуҗалык рәисенең сүзләренә төкереп тә бирми торган бердәнбер кеше ул. Урынына тимерче тапса, Барый аны күптән чыгарып аткан булыр иде, тик хәзер яшьләрнең тимерче булып керәселәре килми, күрек янына кемне бастырасың ди! Әнә ул бер читтә тракторчы Галләм абзыйга кызып-кызып куллары белән нәрсәдер аңлата. Тегесе әллә аңлап, әллә аңламыйча гына, «әйе» дигән кыяфәт чыгарып, башын селкеп тора. Капкыннар турында телсезгә Галләм аша әйттереп карасынмы соң? Барыйны әлеге уйларыннан колхоз идарәсеннән килгән кизү кыз бүлдерде:

— Барый абый, телефонограмма бар! — диде ул һәм учына кәгазь тоттырды. Ул язуны, укып та тормыйча, кесәсенә тыкты да күрше өйнең капка төбендә торган машинасына таба атлады. Быел мәктәпне тәмамлап колхозда эшкә калган кыз, — тракторчы Галләмнең кече кызы Зәринә, — аның артыннан теркелдәде һәм Барыйдан алданрак машинага кереп утырды. Барый, моны күреп, әүвәл, машинага утырып та тормыйча, идарәгә җәяү генә китеп бармакчы иде (бу сәер кыз, — үзе балкашыгына салып йотарлык чибәр, матур кыз бала, — инде берничә айлап булыр, кирәксә-кирәкмәсә дә рәис абыйсы тирәсендә чуалырга ярата, халык телендә теләсә нинди чыш-пышлар китереп чыгарырга менә дигән сәбәп инде! Җитмәсә, арттан атасы да карап калды!..), аннан соң әллә яхшысынмады, әллә капка төбендә өелешеп торган халыкның, каракның бүреге яна, ләкин сиздермәскә тырыша, дип тел чарлавыннан курыкты — машинаның ишеген ачты һәм, дорфа булырга тырышып:

— Мин идарәгә бармыйм бит! — диде.

Алгы утыргычка кереп кунаклаган кыз әүвәл шундый матур, самими итеп елмайды, аннары, каушаган кыяфәт чыгарып:

— Абау, Барый абый, шулаймыни! Мин белмәдем бит, — дигән булды да шуның артыннан ук кура җиләге кебек кызарып пешкән калын иреннәрен бүлтәйтте: — Ничек бармыйсыз? Сезгә тиз арада идарәгә килеп җитәргә кушылган бит анда. — Кызның телефонограммага ишарә итүе иде, күрәсең. Хуҗа кеше кесәсеннән кәгазь кисәген тартып чыгарды. Аңа бер сәгать эчендә Казанга килеп җитәргә кушылган, кул куючысы Мөхәммәт постскриптум белән: «Синең язмышың хәл ителәчәк!» — дип тә өстәгән. Барый аптырап тамагын кырып куйды да машинасын кабызды. Янәшәсендә бәхетле елмаеп утырган кыз янә телгә килде:

— Сиражи бабайның үлемендә сине гаеплиләр, Барый абый.

— Мин причем? — дип куйды Барый аңа каршы, ул әле һаман, бик тырышып, Мөхәммәттән алынган ашыгыч хәбәр хакында уйлана иде. Ләкин кызның әлеге сүзләре аны мизгел эчендә айнытып җибәрде: — Ничек мине? Мин нишләгән аңа!

— Мин үзем дә шулай уйлыйм, авыл халкы әшәке телле безнең! Ә мин үзем менә син... Сез гаепледер дип уйламыйм! Ипидер менә!

Барыйның әлеге сүзләрдән көләсе килеп китте, кыз үзе дә, фикер йөртүе дә артык самими тоелды аңа. Иң кызыгы шул: бу кыз бала ни өчендер Барый абыйсына ярарга тырыша бугай.

Монда нindидер сер дә булырга охшап торган кебек.

— Ә син нәрсә дип уйлыйсың соң... — Барый беркавым аның исемен хәтеренә төшерергә тырышып торды. Кыз моны сизеп ярдәмгә үзе килде:

— Зәринә мин.
— Әйе, Зәринә?
— Мин нәрсә дип уйлыймны? Ә мин уйлап та тормыйм, чөнки беләм бит.
— Нәрсә беләсең соң син, Зәринә!
— Төссез күзле ат күргән ул, шуннан курыккан. Аннары шул турыда уйлап йөргән-йөргән дә куркуыннан йөрәге ярылып үлеп тә киткән бабаең... Менә шул гына...
— Төссез күзле түгел, Галимә апа әйтә, зәңгәр күзле, ди... Бәлкем, тозсыз күзледер...
Кыз, аның үзен ирештерүен аңламаганга салышып:
— Ул атларның күзләрендә нур юк иде, дигән Сиражи карт, — дип, сүзен дәвам итте.
Барый үзенең нигә сүз кыстыруына үкенеп куйды, тизрәк әлеге әңгәмәгә нокта куясы килептер, тамагын кырды, бүтән җавап биреп тормады. Бу кызчык аның эчен пошыра башлады. Шөкер, идарә каршысына килеп җиттеләр. Хәйран кызу барган машина кисәк кенә туктауга, кыз бала, алга таба тартылып, маңгае белән тәрәзәгә төртелеп алды. Чык иткән тавыштан Барый курылып килде, аның үзенә дә бик уңайсыз булып китте. Ул хатасын төзәтергә уйлады бугай, уң кулын Зәринәнең җилкәсенә салып, үзенә табарак тартты, сул кулы белән маңгаена орынды.
— Бик каты авырттымы?
— Сезнең кул тигәч, авыртуы бетте, — диде кыз, күзенә атылып чыккан яшьләрен сөртәсөртә. Әлеге сүзләрдән соң Барый дорфа гына кулын тартып алды да машинадан төшеп китте. Ачуы килүен килсә дә, нигәдер күңеле булып, егетнең ирен читләренә елмаю кунып маташа иде. Ул шуны Зәринәгә күрсәтмәс өчен, абына-сөртенә, идарә ишегенә таба атлады.

## Мөхәммәт

Италиядә йөреп кайтканнан соң, Уразмәт абый малаен алыштырып куйдылармыни! Элеккеге Мөхәммәт түгел инде ул, Байтимер малаеннан кабыгы гына калгандыр кебек. Элек сүзгә шактый саран булган егетебезгә тел керде: хәзер ул кирәксә-кирәкмәсә дә тик тора алмый, сөйләвен белә, ләкин шунысы шаккатмалы, сабыр холыклы, җитди Мөхәммәт хәзер бар нәрсә хакында да иркенләп сөйләшергә, вак-төяккә дә игътибар итеп, шул турыда бертуктамый сәгатьләр буе сөйләп торырыга мөмкин. Егетнең Гөлчәчәк белән мөнәсәбәте элеккечә калды. Хәер, элеккечә дип... Әйе, алар нәкъ элеккечә сирәк күрешәләр, шул гына.
Әллә сөюләре платоник мәхәббәткә әйләнеп бара инде? Мөхәммәтнең үз фикере буенча, иҗат кешесенә тегесе дә кирәк, монысы да мөһим дигәндәй. «Тегесе» аңлашыла, ә «монысы» ни була соң аның?.. Сиринә Самуиловнадыр инде?.. Кызык бу хисләр дигәнең... «Тегесен» сагыну, юксыну бар, «монысына» исә ияләнеп, күнегеп килә түгелме?.. Бу куркыныч бит, бу коточкыч хис ләбаса! Җәтмәгә эләккән чуртан кебек чәбәләнәсе, бәргәләнәсе генә калган түгелме соң инде?..
Ләкин тормыш болай дәвам итә алмый бит! Нәрсә булса да хәл итәргә кирәк. Башыңны дуракка салып йөрсәң, Гөлчәчәгең дә чыгымлый башлар әле. Хәер, чыгымласа соң... Чебен дулап тәрәзә вата алмастыр. Ул иҗат кешесе бит, аңа үсәргә кирәк, тагын да зуррак дәрәҗәләргә ирешергә кирәк. Ул боларның барысын да киләчәк хакына, Гөлчәчәк хакына эшли ләбаса!
Соңгы очрашуларында ул Гөлчәчәккә шундый фәлсәфәсен «төртте». Ләкин кыз да аптырап калмады: «Синең иҗатыңа комачаулармын дисеңмени?» — дип сорады аның бу нигезсез дәлилләренә каршы. «Әлегә миңа кайнарга, бөтерелергә кирәк, как белка в колесе! Сиңа игътибарым җитмәячәк. Син үзең үк үпкәләячәксең бит аннан соң».
Мәхәббәт әллә чынлап та сукыр була инде, кыз Мөхәммәтнең бу сүзләренә ышанды һәм хәтта аның белән ризалашуын да белдерде бугай әле.
Тик нәрсә белән ризалашуын үзе дә аңлап бетермәде. Мөхәммәт өчен дә сер бу. Ләкин рәссам егет үз гомерендә беренче тапкыр «серне» аңларга тырышып азапланмады. Шул килеш кенә узды да китте. Чөнки бу аның файдасына иде бит.
Ни әйтсәң дә, Сиринә Самуиловна яшәгән дөнья аңа күбрәк ошый. Иҗаты бара, дәрәҗәсе үсә. Тора-бара әлеге мөнәсәбәтләр, дөресрәге, рәссам егетнең мондый яшәү рәвеше шундыйга әйләнеп китте ки, күңеле, йөрәге Гөлчәчәк белән рухланып, яңадан-яңа яхшы, уңышлы картиналар яза, ә ул картиналар исә нәкъ менә Сиринә ханым аркасында уңышка ирешә, дөньяга чыгып зур бәяләр ала торалар. Тормышта мондый конструкция-төзелешне бик теләсәң дә махсус уйлап чыгарып булмый торгандыр. Ә бу нәрсә исә үзеннән-үзе шулай килеп чыкты һәм Мөхәммәткә бик ошаса да, барыбер аны күпмедер дәрәҗәдә куркыта, өркетә. Кыскасы, ике «илһамчысының» бирсен югалту уе белән куркып яши башлады егетебез... Тик кайсысын алданрак югал-

тыр, әллә икесен дә берьюлымы?.. Бу сорауга хәзер генә берничек тә җавап биреп булмый һәм хәзергесе вакытта сорау җавап көтми дә кебек. Мондый очракта адәм баласы башын дуракка салса яхшырак... Мөхәммәт Уразов шулай итте. Теге сорау җавап белән ашыктырмаса да яшәешнең үз кануннары бар: рәхәтлек бушка килми, соң чиктә барыбер аның өчен җавап бирергә туры киләчәк. Мөхәммәт тә икегә бүленеп, ике тормыш белән яши башлады. Ә мондый халәт бирәү өчен дә рәхәт нәрсә түгел һәм алай була да алмый. Егет күңеленең ике катлануын ахыр чиктә үзенең һөнәре белән бәйләп аңлатырга азапланды: ул иҗат кешесе, иҗат кешесенә бар да килешә... Һәм, бер караганда, ул хаклы да кебек иде шикелле...

Хәер, бер караганда гына микән... Иҗат кешесе өчен беренче нәүбәттә аның иҗаты тора. Мөхәммәт яшәгән кабахәт җәмгыятьтә исә тормышның язылмаган кануннары аеруча кырыс. Йә иҗат, йә гаилә баткаклыгы... Чын талант өчен бигрәк тә шулай бу. Уртакуллар өчен исә чыгарылмалар шактый. Алар трактор кебек бара, шуңа күрә артларыннан да, гадәттә, чокыр-чакыр гына кала. Алар шул чокырларны, күл урыннары дип уйлап, гомерләре буе шунда су тутырып интегәләр, үзләренчә төнбоеклы, астында салкын, саф чишмәләр тибеп ятучы күл ясыйлар, имеш, күл тирәли гәҗәп матур камышлар утыртып чыгалар, имеш... Күл әйләнәсендәге шыксыз куаклыклар аларга нәфис тал агачлары булып күренә. Аннан соң шул талларда тырыша-тырыша сандугач сайратырга керешәләр. Андыйларның колаклары бака тавышы белән сандугач тавышын аермый. Һәм аларны тыңлаучылар да бака сайравын сандугач җыры итеп кабул итәргә мәҗбүр ителәләр. Бу шундый ил ки, кемнеңдер әмере, ихтыяры белән бака тавышы сандугачныкына, сандугач сайравы бака тавышы кебек яңгырарга гына түгел, нәкъ менә шулай итеп кабул ителергә мөмкин. Үзең җайлашмасаң, бу ил синең көеңә мәңге җайлашачак түгел!..

Әлбәттә, бу фикерләр, мондый уй-муйлар Мөхәммәт Уразовның тормыш фәлсәфәсе түгел, егет әлеге теория белән яшәми. Тик нәкъ менә шул фәлсәфә кысаларына башын тыгып барганлыгын аңлап та, төшенеп тә җиткерми әле ул. Сиринә Самуиловна ярдәмендә аның иҗаты шактый шома юлдан тәгәри әлегә.

Бүген ул шактый зур түрә абзыйның шәһәр читендәге коттеджында кунакта. Садыйк Сираевич өч катлы йортының икенче катына Мөхәммәт язган картиналарны гына эләргә карар иткән. Рәссам егет бүген чираттагы эшен алып килде. Хезмәтенә долларлар белән түләнә. Тормышта монысы да әһәмиятсез түгел. Үзең язган шәп картинадагы урман һавасы белән тамак туйдырып булмый. Ул болай чын урманга охшап торса да, андагы гөмбә, җиләкләрне авызга кабып булмый.

Садыйк Сираевич менә-менә үзе дә кайтып җитәргә тиеш. Хатыны аны өйдәге ике пешекче һәм хезмәтче ир белән калдырып, үзе тиз генә массажга барып киләм дип китте. Мөхәммәт, хуҗалар юклыктан файдаланып, мәдәният йортын хәтерләткән ихатаны карап йөрде. Ачуым килмәгәе, мондагы бәдрәф тә аның бер бүлмәле фатиры чаклы гына бар. Кыскасы, шаккатмалы иде бу йорт, ханнар сарае кебек иде. Тик шунысы гаҗәп, өй эчендәге байлыкка сокланып йөрсә дә, Мөхәммәт бу хәлне артык исе китеп йә булмаса кара көнчелек белән көнләшеп кабул итмәде, чөнки егетнең күңелендә үзе сәер, үзе шактый кыю булган әллә нинди генә бер тойгы кереп урнашкан: әйтерсең ул нәкъ шундый ук коттеджыннан чыгып китеп, күршесенә хәл белергә генә керде. Каян килде күңеленә шундый мәгънәсез, аңлашылмаслык тойгы — бер Алла белә! Хәер, үзе чамалый шикелле: Италиядә бик уңышлы күргәзмә уздырып кайтты бит.

Сиринә Самуиловнага мең рәхмәт: әлеге сәяхәттән соң Уразов ике башка үсеп китте. Шуның артыннан ук аңа, күргәзмә оештыруын яки катнашуын үтенеп, төрле төбәкләрдән кызыклы тәкъдимнәр ява башлады, иң кызыклылары, әлбәттә, Мәскәү, Петербургтан һәм Идел-Кама филиалыннан иде.

Егеткә моңарчы булмаган, бу көнгә чаклы татып карамаган ышаныч иңгән кебек булды! Ләкин бу ышаныч үзе генә яши алмый, ул Сиринә Самуиловна белән янәшә. Кәкре каенга терәткән терәү кебек бу хатын аны җил-давылдан саклап тора. Йа Ходa, мондый хисне нигә син адәм балаларыңа тәпи йөреп китүгә үк салып куймыйсың соң! Искиткеч зур хис икән бит ул үз-үзеңә, иртәгесе көнеңә ышаныч булу, алай гына да түгел: үз сәләтеңә ышаныч булу хисе. Бу җәмгыять, беренче нәүбәттә, бәндәләрендә әнә шул хисне үтерә, сытып изә, таптый бит! Кабыкка әйләндерә адәм балаларын ул хиснең зәгыйфь булуы. Хәер, Сиринә Самуиловна булмаса...

Мөхәммәт, яңа алып килгән картинасын эләргә дип, уңайлы урын эзләп маташа иде. Ишек ачылып китеп, зал аша икенче бүлмәгә бер күләгә шуышып узган кебек булды. Беркавымнан әлеге «күләгә» юыну бүлмәсендә бик озак су агызды, аннары гына әлеге күләгәнең иясе үзе пәйда булды: ул хуҗа кызы студент Әлфия иде. Таш курчак кебек матур бу кыз белән Мөхәм-

мәт күптән таныш. Әлфия-Аля да рәссам булырга әзерләнә. Шуңа күрәме икән алар Мөхәммәт белән аеруча дуслар.

— О, как красиво! Нинди матур! — дип телне шартлатты кыз, Мөхәммәтнең яңа картинасын күргәч.

— Менә куярга урын эзлим.

— Ты меня обижаешь, сэр. Бу эштә минем специалист икәнлегемне оныттыңмыни! Хәзер, хәзер. Ике тәрәзә арасында буш урын барын бар да. Тик анда ярамый, эти, ул як — кыйбла ягы, ди, картиналар эләргә кушмый. Слушай, карале, монда урын да калмаган икән бит!

Мөхәммәт иңбашларын сикертеп алды да, сүз булсын дигәндәй генә:

— Икенче катта урын юк микән? — дип куйды. Никтер ул бу кыз янында каушый, малайлар кебек кызарырга гына тора. Беренчедән, егетне кызның чибәрлеге каушатса, икенчедән, кыюлыгы, холкының алдан аңлап булмаслык кискенлеге, көтелмәгән капризлар чыгарырга яратуы шүрләтә. Әүвәл, танышкан шәпкә, мине шәрә килеш сурәткә төшер, дип, Мөхәммәтнең теңкәсенә тиде. Моны ишетүгә, Мөхәммәтнең күз алдына шундук Садыйк Сираевич килеп басты. Ул аның хәтта күз карашына чаклы тойды. Әлеге бакыр төсендәге караш борын тишекләреннән кереп китеп, ашказаннарын әйләндереп чыгарырдай усал, авыр иде. Мөхәммәт, яныннан бәйләнчек черкине куганлай, үзе дә сизмәстән кулларын селти-селти, аның тәкъдимен кире какты. Бәхеткә күрә, алай ук бәйләнчек түгел икән.

— А зачем нам второй этаж? Икенче этажның нигә кирәге бар? — дип, кыз стенага сөялеп торган картина янына атлады. — Минем бүлмәгә куябыз аны. Гаҗәеп урман сурәте бит! Мин урманны яратам! Тик нишләп синең урманнарың һәрвакыт карурман кебек? Бер киселгән агач юк анда, урманга кереп китүче сукмак-юллар да булмый. Шүрәлеләр генә яши торган серле урман шикелле?

— Әтиеңнең заказы шундый.

— А, понимаю тогда... Аңладым, аңладым... — Аля-Әлфия ике телне дә яхшы белә, тик еш кына аларны чиратлаштыра яки шуның артыннан ук икенче телнең тәрҗемәсен дә кабатлый иде. — Соңгы вакытта кешеләрдән качасы килә башлады бугай аның. Карурманга кереп булса да. Андый урманнар юк хәзер. Мин бүген урманга бардым. Фу! Мусор оясы! Ну только бүре күрдек! О, нинди усал иде ул! Так страшно было!

— Бүре? Ничек сиңа ташланмады соң ул?

— А меня спасли! Один рыцарь! О, шәп егет!

Әлфия кесәсеннән фоторәсем алып, Мөхәммәткә сузды. Барыйның Гөлйөзем белән парлашып төшкән фотосурәтен бая машина эченнән эләктергән иде бу ут кыз. Мөхәммәт, фоторәсемдәге таныш йөзләрне күргәч, чак артына утырмады, аңа таба бәхетле елмаеп сыйныфташы Барый белән сөйгәненең сыңары Гөлйөзем карап тора. Егеттәге үзгәрешне үткен кыз шундук сизде һәм, серне чишүен үтенеп, Мөхәммәткә чат ябышты: әйтсәң дә әйтәсең, әйтмәсәң дә әйтәсең!..

— Бу егетне беләм бугай мин, — диде Мөхәммәт, бераз ялындырыбрак. Әлфиягә шуның кадәресе дә бик җиткән иде: тәгаен белә һәм әйтәчәк!

— Үземә әйтәсеңме, әллә әтигәме? — дип, кыз шундук һөҗүмгә күчте. Бу егеткә рәхмәтле генә түгел, бу егет аның күңеленә үк кереп калган, күрәсең. Мөхәммәт, кызның ут кебек ялкынланып яна башлаган күзләренә игътибар итеп, шүрли үк башлады. «Ни булган болар арасында?» — дип куркынып уйлап куйды ул. Әлфия дә аның эчке уйларын сизми калмады, ахрысы, шундук мәсьәләгә ачыклык кертергә ашыкты. «Я должна его отблагодарить! Мине бүредән коткарып калды бит ул!»

Мөхәммәт бераз йомшара төшеп, киеренкелек сүрелә башлады.

— Однокашник бит ул минем. Барый Әкбәров. Син булган якларның хуҗасы.

Егет сизми дә калды, кыз ни арада йөгереп тә килде, ни ара Мөхәммәтнең муеныннан кочаклап, битеннән үбеп тә алды. Егетнең шул як бите ут кебек нindидер тәмле, татлы рәхәтлек биреп янарга кереште. Күргән шәпкә үк ул кызда нindидер үзгәреш барлыгын сизгән шикелле дә иде, артык игътибар гына итмәгән булган, күрәсең. Бу үзгәрешкә Әкбәров сәбәпче икән бит ләбаса! Кайдан күрешкәннәр дә ничек табышканнар диген! Берсе авылда, икенчесе Казан кызы, җитмәсә, кемнең кызы әле! Әгәр Садыйк Сираевич боларның кырын эшләрен сизсәме?! Бетте Әкбәровның! Ул аны терелә җир астына күмдерәчәк! Чөнки бердәнбер сөекле кызының әтисе «партиясенә» туры килгән шәп егет белән танышкан көннәре генә бит!

Тәртә арасыннан чыгып киткән кызының муенына камыт киертергә исәпли бугай!.. Нәкъ шул чакта арага Барый килеп кысылсамы? Һе, тегермән ташы арасындагы кибәккә әйләндерә-

чәкләр Барыйны. Әлеге уйлардан соң Мөхәммәт үзенә урын таба алмый башлады, җиңелчә генә башы әйләнергә кереште. Тагын кыз үзе ярдәмгә килде, ул яңа картинаны алды да икенче кулы белән егетнең җиңеннән эләктереп, югары катка таба әйдәде:

— Әти кайтканчы урнаштырыйк әле моны. Сюрприз сделаем ему.

— Ә син Барый белән ничек таныштың соң?

— Алайса, мин сезнең як урманына барып чыккан булам инде? Надо же!.. Танышуын танышмадым әле мин аның белән. Якыннанрак син таныштырсаң гына инде?

Мөхәммәт җиңел сулап куйды: өлгермәгәннәр әле, димәк...

— Не могу жить ни с тобой, ни без тебя, дисең инде, алайса?

Бу мизгелләрдә Мөхәммәтнең сүзне шаяртуга борасы килүе аңлашыла иде. Әлфия аңа каршы бары:

— Великая вещь — любовь! — дип кенә куйды.

— Егетең бар бит синең? Шаһмәлиев малаен кайда куясың!

— Шаһмәлиев — чмо!

— Әтиең сизсә?

— Любовь и кашель не скроешь инде.

Словно солнце горит, не сгорая, любовь.
Словно птица небесного рая — любовь.
Но еще не любовь — соловьиные стоны.
Не стонать, от любви умирая, — любовь!

Әлфия дә Хәйямне яттан белә икән, ул, елмаеп, Мөхәммәткә таба күтәрелеп карады да көр тавыш белән шигырь укырга кереште:

В этом мире любовь — украшенье людей,
Быть лишенным любви — это быть без друзей.
Тот, чье сердце к напитку любви не прильнуло,
Тот — осел, хоть не носит ослиных ушей!

— Каты әйттең син, — диде Мөхәммәт. Садыйк Сираевичның кызы ташкурчак кебек булса да, ул элек уйлаганча буш кыз түгел. Мондый әңгәмә рәссам егеткә ошый иде, ул кабат хәтер чарлагында эзләнергә кереште һәм аннан, Тукайны «табып алып», янә кызны шаккаттырмакчы булды:

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь,
әйтегез, рухланмаган?
Байронның, Лермонтовныңмы,
Пушкиныңмы — кайсысы?
Файдасыз бер ит кисәгеннән
гыйбарәттер йөрәк—
парә-парә кисмәсә
гыйшык-мәхәббәт кайчысы!..

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,
ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта!.. —

дип куйды кыз.

Гаҗәпләнүдән Мөхәммәтнең күзләре маңгаена менеп кунаклады.

— Ну ты даешь! — дип, соклануын белдермичә булдыра алмады ул.

— Нәрсә, мине Садыйк Сираевичның юлдан яза башлаган бер иркә кызы дип кенә уйлаган идеңме әллә!

Кыз шулай диде дә сабыйларча ихласлык белән рәхәтләнеп көлә башлады, самими, эчкерсез көлү иде бу. Һәрхәлдә, Мөхәммәткә шулай тоелды. Хәерлегә булсын. Тик хәерле дигәнең нәрсә була торгандыр инде тагын...

## Козгыннар йолдыз чүпли...

Садыйк Сираевич Мөхәммәтнең килүен күреп бер шатланган иде, картина исә аны икенче кат сөендерде. Картинада зур зәвык белән, югары сәнгать дәрәҗәсендә язылган кара урман. Кара урман Садыйк Сираевичның күңеленә иң хуш килгән сурәтләрнең берседер, мөгаен. Ул моның нигә шулай икәнлеген күңеле белән тоемлый, әмма ниндидер мантыйклы калыпка салып,

шуннан чыккан мәгънәне әлегә аңлап бетерми. Әлегә дидек, чөнки ул аны кайчан булса да үз аңында калыплаячак һәм гап-гади, әмма үз ачышы итеп ачачак; ул шуңа, бер яктан, балаларча сөенсә, икенчедән, бу фикернең шулай соңлап килүе аның бераз гына кәефен дә җибәрәчәк әле. Чынлап та, кара урман сурәте әллә нинди уй-хисләр тудыра...

Мин үзем, автор буларак, Садыйк Сираевичны бик яхшы беләм, аның һәр кылган гамәлен генә түгел, хәтта күңел күзәнәкләренең ни рәвешле сулаганнарын да тоям инде дип, зур канәгатьләнү белән йөри идем. Ник, шулай булмыйни! Алайса, аның хакында, бу кешенең Әлфия атлы йөгәнсезрәк кызы хакында язып, укучының башын да катырып торасым юк! Мин... мин бит аларны — мичкә керсәләр, аяк тәпиләреннән таныйм бит инде дигәндәй.

Әлфияне «йөгәнсезрәк» дип сүз уңаеннан гына әйттем. Кияүгә чыкканчы, кыз баланың кайсысы «йөгәнле» була инде! Аның белән аралашкан кайбер кызлар фикеренчә, бәхетле йолдыз астында туган кыз бала ул. Бу очракта бәхет дигәнең исә чагыштырмача мәгънәгә ия. Шундый дәрәҗәле, калын кесәле әтиең булып, өстеңдәге күлмәгеңне алыштырырга аптырап йөрмәсәң, акча дигән нәрсәнең нинди «басуда» үскәнен белергә дә теләмичә, аны уңга-сулга күзеңне дә йоммыйча туздыра алсаң, бәлкем, шундый бала бәхетле була торгандыр. Бәхет дигән нәрсә гаҗәеп кызык төшенчә! Бер генә галим яки акыл иясе дә, кыскасы, беркемнең дә бәхетнең ни икәнлеген аңлата алганы юк әле. Язучы буларак мин дә ул эшкә алынырга җыенмыйм, дөресен әйтәм: үз фикерләремдә буталып бетәсем килми...

Элегрәк басуларда каланчалар була торган иде, аны халык каравылчы каланчасы дип тә, пожар каланчасы дип тә атап йөртте. Басу никадәр зуррак булса, аның каланчасы да озынрак итеп ясала. Ә кечкенә басуга бәләкәйрәк каланча да бик ярап тора иде. Бу очракта бәхетне дә менә шул каланча белән чагыштырып карарга мөмкиндер, мөгаен. Басуың нинди — каланчаң шундый. Димәк, һәр адәм баласы өчен дә уртак булган бәхет тә юктыр ул. Һәр кеше үзенчә бәхетле. Әмма үз фикерләремә үзем үк каршы төшеп: юк, җәмәгать, ашыгыч нәтиҗәләр чыгармый торыйк әле, уртак бәхет бар ич ләбаса адәм заты өчен! Ул — акча!!! дип тә әйтә алам. Ләкин бу очракта, башымны ташка бәреп исбатлый алам, мин хаклы да, хаксыз да! Бик әллә ни еракларга китмичә ике генә мисал китерәм. Минем бер акчалы дустым бар, ул үзен бәхетсез дип саный, чөнки яшь чакта кайнарланып китеп өйләнеп ташлаган да, шул хатыны аңа рәттән ике бала алып кайтып биргән дә. Кыскасы, хатынын яратып яшәми ул. Аерылып та китә алмый һәм үзен иң бәхетсез кешегә исәпли. Икенче бай, ягъни акчалы дустым саулыкка туймый. Себер якларында дистә еллар буе үзенең сәламәтлеге бәрабәренә алтын приискаларында сукыр тычкан кебек җир казып кайтты да монда коттедж салып җибәрде, балаларын зур уку йортларына урнаштырды һәм шуннан соң урын өстенә ятты. Затлы чит ил машинасында студент кызы артыннан селәгәен агызып йөргән бер малай җилдертә, хатыны иртәдән кичкә чаклы билэмдә, чөнки авыл тулы (коттеджны хатынының туган авылында салган иде) туганнары!.. Менә сиңа акча алып килгән бәхет шулай да була ул тагын!

Әлбәттә, акчадан баш тарту дигән сүз түгел бу, бәлки шул рәвешле бәхет дигән төшенчә хакында уйлану гына.

Ә Садыйк Сираевич уйлы кеше. Уйлы булмаса, ул бүгенгесе көндә шушындый дәрәҗәгә ирешмәгән дә булыр иде. Ләкин дөнья дигәнең һәрвакытта да син дигәнчә генә бармый. Һай, бармый икән шул!.. Ике бала үстерде алар — малае моннан ике ел элек самолет ярышында һәлакәткә очрады. Спортчылар очкычларга утырдылар. Фили белән филилар арасында ярышлар башланды. Аның Шамиле дә, атна-ай саен яңа очкыч алыштыра-алыштыра, ике ел дигәндә, беренчеләр рәтенә менде, гел җиңүче булып килде. Менә шундый ярышларның берсендә Шамил, самолеты-ние белән җиргә кадалып, башын имгәтте. Хәзер әнә егерме җиде яшьлек егет чиркәү кебек пулатның беренче катында, идән уртасында, селәгәен агыза-агыза, уенчык самолет белән уйнап утыра. Югыйсә улы аның эшен дәвам иттерергә тиешле бердәнбер ир-ат варис иде. Атасы урынына түрә булып утырмаса да, аның эшмәкәрлек эшен Шамил дәвам итәргә, «Гыйфрит» фирмасының башында ул торып калырга тиеш тә бит!..

Дәү филиалда, «Гыйфрит» кебек көн күреп, зур табыш алучы фирмалар бихисап. Әлегә аларның һәммәсенең башында пенсия яшеннән авышкан зур түрәләр утыра, гаиләнең шәхси оешмалары булганлыктан, аларның җитәкчеләре дә һәрвакыт шул нәселдән булырга тиеш иделәр.

Әлеге фирманың исеме Галәветдин лампасындагы бар нәрсәне эшләргә сәләтле Гыйфриттән алынган. Бары тик шушы әкият герое гына барны юк итәргә сәләтле бердәнбер көч бит. Ә әкиятләрдәге геройларның кайдан алынганын беләбез: алар да болытлар артында түгел, алар безнең янәшәдә җиргә басып йөриләр, алар теләге һәм ихтыяры белән усак яфраклары яшел кә-

газь-долларларга әверелә, Идел суы кымыз булып кайнарга керешә, каргалар бөркет булып күккә күтәрелә, тизәк чебеннәре умарта балы ташый... Менә шундый заманда яшәгәч, — нәкъ әкияти заманда! — нигә фирмаларның исемнәрен дә «Гыйфрит» яки «Мифрит» дип кушмаска?! Усак яфракларыннан нигә яшел акчалар ясамаска? Усак күп үсә бит ул, исәпсез-чутсыз үсә, гәрчә ул да гәүдәсен төз тотып кояшка таба үрелү өчен тамырлары аша шыпырт кына, тыйнак кына җир маен суырып утырса да...

Әнә шул рәвешле Садыйк Сираевичка бүген варис, дөресрәге, шуларның барысын да ышанып тапшыра алырлык үз кешесе кирәк. Кызы Әлфияне Шаһмәлиев малае белән кавыштырып, «укмаштырып» шундый таяныч, дәвамчы булдырырыга иде исәбе. Тик Шаһмәлиев, коймакны ак ипи белән бергә ашый торган сыек буынлы студент малай, Әлфиянең иң сөймәгән, хәтта күралмаган кешесенә әйләнде. Ә болай начар парлар түгел иде шикелле бит үзләре. Җитмәсә, алар Шаһмәлиев белән гомер буе эшләрен бергә алып бардылар, атасына ышанып булгач, малае да төшеп калганнардан түгелдер дип фикер йөрткән иде Садыйк абзагыз. Кыскасы, кызына килешле генә пар булырга тиеш иде кебек Шаһмәлиев малае. Язмагандыр, күрәсең...

## Тагын автор әле бу...

«...Садыйк Сираевичны ярыйсы ук яхшы беләм, дигән идем мин. Аның җанына ук кереп, каләм тыгарга, каләмемнең карасын аның болай да каршылыклы күңел дөньясында кайнаган хисмисләренә манып: менә кем бу адәм, дип, һич кенә дә чаң сугасым, йә булмаса, берьяклы нәтиҗә-фикерләр чыгарып, берәүне дә шаккаттырасым килми. Зинһар, мине дөрес аңласыннар, бер караганда, бу каһарманымны бик яратам, икенче мәлдә исә, кызгана ук башлыйм (чынлыкта, аның кулында Иблиснең тәмуг кисәве...) һәм әлеге мескен хис нәфрәткә дә әйләнеп куя. Үзем хисләнеп киткән чакларда шулай була бу, гадәттә. Ләкин бик яхшы беләм — бу очракта миңа һич кенә дә хисләремә ирек бирергә ярамый, югыйсә геройларым белән бергә үзем дә буталып, юкка чыгып бетәрмен кебек тоела...»

*** * ***

...Сиксәненче еллар уртасында инде медицина фәннәре кандидаты булып алган Садыйк Сираевич шәһәрдәге бер психбольницаның баш табиб ярдәмчесе булып тыныч кына эшләп ята иде. Хатыны Тәслимә, элеккеге татар теле укытучысы, шәһәргә күчеп килгәч, урта мәктәптә урыс теле укыта башлады, чөнки ул чакта туган тел дәресләре модага яңа гына кереп барганлыктан, мәктәпләрдә дәрес сәгатьләре җитешмәде. Алар түп-түгәрәк малай белән сөйкемле сөякле кызчык үстереп, үз көннәрен үзләре күреп, матур гына яшәп яталар иде. Хатыны татар теле укытучысы булу да тәэсир иткәндер инде — Садыйк Сираевич шактый милли җанлы һәм интернационалист кеше дә. Туксанынчы елларда, гасырлар буе милли һәм рухи яктан изелгән Татарстанның төп халкы, милләт дип авыз ачарга батырчылык итеп, үзәк дилбегәсе чак кына бушый төшкәч, бүтән дәү корсаклы түрәләр кебек ул аларны милләтчелектә гаепләргә ашыкмады, киресенчә, чын күңеленнән, сәламәт рухлы татар малае буларак, күпчелек кебек азатлык дип төшләнә һәм, халкының матур киләчәген күз алдына китерергә тырышып, чын күңеленнән сөенә иде, өметләнә иде.

Әйе, киләчәгенә зур өметләр баглап яши торган кеше иде Садыйк Сираевич. Тик балалары ирәя төшкәч, еш кына төшенкелеккә бирелә башлады бугай. Тиктомалдан гына кәефе китә, тиктомалдан гына күңелен авыр уйлар каплап ала да кулыннан бар эше киткәндәй була. Күп акча, байлык кына да адәм баласының кәефен һәрвакыт күтәреп, күңелен канатландырып тора алмый икән шул! Кайсыдыр акыллы баш әйткән бит: байлыкның күләме керемнең зурлыгы белән түгел, кешенең яшәеш рәвеше һәм гадәтләре белән билгеләнә дигән. Белеп әйткән бу акыллы баш. Аннан соң, «урла, йолкы, тупла, ия бул — кайчан булса да барыбер һәммәсен калдырырга туры киләчәк» дигән әйтемне дә яхшы белә Садыйк Сираевич. Тик кемгә калдырырга? Әлеге сорауның бик тә четерекле, катлаулы, авыр сорау икәнлеген адәм баласы әүвәл башына да китереп карамый икән шул. Килеп терәлгәч кенә... Шекспир язганча: «В них оправданье старости моей», — дип, җиңел генә әйтә алса иде ул балалары хакында!.. Киресенчә, күп вакыт Грибоедовны исенә ешрак төшерә бугай шул ул: «Что за комиссия, создатель, быть взрослой дочери отцом!» Әйе, Әлфия җиткән кыз инде, иртәгә язмышы хакында Садыйк Сираевич үзе уйларга тиеш һәм хәл иткән сүз дә аныкы булачак. Әлфиясе нindидер Барый атлы кеше хакында кайтып сөйләгәч, аның күңелен бер корт кимерә башлады. Ул корт хәерле «корт» булырга охшап

тора бит әле менә! Ни әйтсәң дә, Әлфиясенә төпле егет кирәк, ахыр чиктә, ул егет кияү балакайга әйләнеп куеп, Садыйк Сираевичның эшмәкәрлеген дәвам иттерерлек таяныч — терәк булыр иде. Әлфиясе Мөхәммәтнең Барыйны белүен әтисенә әйтергә дип авыз ачканчы ук, Садыйк Сираевич бу хакта кызыксынып өлгерде. Дөньясы шундый: бер генә мизгелгә дә сизгерлекне югалтырга ярамый. Хәниф Хатыйповичтан әлеге егет хакында үзенә кирәкле шактый ук мәгълүмат тупларга да җитешкән иде инде карт төлке.

Төлке булырга тормыш үзе өйрәтте. Югыйсә, югыйсә... Медицина буенча докторлыгын яклап, тыныч кына, берәүгә дә тимичә, комачауламыйча гына табиб булып яшәп ятарга иде исәбе. Ләкин бу тормышның язылмаган, дөресрәге, күз белән күреп, колак белән ишетеп һәм хәтта борын белән исен дә тоеп булмаган үзенең кануннары бар икән шул. Шактый кырыс, күп очракта мәрхәмәтсез кануннар...

Туксанынчы еллар башында татарлар, ниһаять, бер кузгалып алдылар бит әле. Бүгенгесе көндә Мәскәүнең туя белмәгән түрәләре, ул чакларны исләренә төшереп: «хәерчегә якты чырай күрсәтсәң...» — дип уйлый торганнардыр, мөгаен. Сабантуй мәйданында чүлмәк ваткан чагында якты чырай күрсәткән иде шул берсе. Соңыннан ямаулык та өләшеп йөрде әле, бахыр. Хәзер аның варислары шул «ямаулык»ның җөйләренә чаклы сүтеп яталар. Күргәннәре, күрмәгәннәре шул булсын иде. Бу халык үзенә ямаулык кына түгел, ниһаять, өстенә төлке тун ябынырга да вакыт җиткәнен һәм үзенең шуңа бик лаек икәнлеген тагын бер заман аңлар әле, Алла боерса... Әлбәттә, безнең Садыйк Сираевич бүген болай дип уйламый. Аның хәзер мондый бимаза уйлар белән матавыкланырга һич кенә дә вакыты да, теләге дә юк. Ә теге чакта вакыты да булды. Җүләрләр йортында баш табиб ярдәмчесе булып эшләгән чагында... Ләкин аның үзенә уйларга ирек бирмәделәр шул, синең өчен уйланган инде, туган, кушканны эшлә, дип, кырт кистеләр...

Суверенитет, мөстәкыйльлек... Ирек мәйданы шау итә. Элек фәлән илдә төгән кеше ачлык игълан итте дигәнне телевизордан гына күреп белә иде, бахырлар. Хәзер әнә Казанның Ирек мәйданында татар зыялылары, урыстан азатлык даулап, ачлык игълан иткәннәр!.. Көне-төне мәйдан тулы халык. Транспарантлар, плакатлар, байраклар. Кемнәр генә юк алар арасында: зур язучылар, атаклы рәссамнар, күренекле галимнәр, танылган артистлар, исемнәре ил теленә кергән башка интеллигенция вәкилләре!.. Мәскәүнең, коты ботына төшеп, Казан артына, мари урманнарына, танклар китереп туплавы турында куркыныч хәбәрләр дә йөри.

Нәкъ шул заманда күк йөзендә моңарчы астроном галимнәр белмәгән, күрмәгән бер Йолдыз кабынды! Яңа Йолдыз!.. Исеме дә юк иде аның хәтта! Менә шул Йолдыз күктән тыныч кына Казанның Ирек мәйданын күзәтеп тора башлады, шунысы кызык, хәтта көндез дә сүнеп тормый иде ул Йолдыз. Кызганыч, ул Йолдызны кешеләр күреп өлгермәделәр. Тик шулай да аны күргән бер җан иясе бар иде — ул җан иясе дигәнебез Казан арты урманнарында көн күреп ятучы ике гаярь бөркет иде. Әткә бөркет тә, әнкә бөркет тә үзләренең очлы күзләре белән ул Йолдызны шундук күреп алдылар һәм, күккә күтәрелгәндә, алар һәрвакыт, куана-куана, шул Йолдызга таба омтылалар иде. Аннан соң, хәлләре бетеп, кире төшәләр, оядагы балаларын җим белән сыйлаганнан соң, янә шул Йолдызга таба уктай атылалар...

Ә бу вакытларда татар милләтенең каймагы Ирек мәйданыннан кайтып кермәде, шаулады, даулады.

Нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә Садыйк Сираевич янына психбольницага (баш табиб җәйге ялда иде) күн курткалы бер адәм килде, вәкарь белән генә кенәгәсен күрсәтте һәм алар икесе баш табибның кабинетына кереп бикләнделәр.

— Ирек мәйданында булганыгыз бармы! — дип сорады күн куртка, кабинетка кереп урнашкач ук.

— Ник булмасын, татарның бар җүнле кешесе шунда бит, — дип җавап бирде аңа Садыйк Сираевич, алдын-артын уйлап тормыйча.

Әлеге бәндә, күрәсең, мондый ук туры җавапны көтмәгән булгандыр, чөнки Садыйк Сираевичка кенәгәсен күрсәтеп, үзенең кайдан килгәнлеген искәрткән иде бит. Шулай да ул, үзенең канәгатьсезлеген эченә йотып, янә сүз кушты:

— Нишләп йөриләр дип уйлыйсың син ул халыкны анда?

— Суверенитет даулап, ирек, бәйсезлек...

Күн куртка беркавым кашын җыерып торды да:

— Ирек дисең инде, алайса?.. — дип куйды һәм, бу юлы Садыйк Сираевичка сүз кушарга да ирек бирмичә, сүзне үзе ялгап китте: — Ә менә синең пациентларың ирек даулыймы соң? Алар бит әле бигрәк тә тимер бик астында! Карап торышка сау-сәламәт кешеләр кебек үзләре!

Садыйк Сираевич елмаясы итте, ләкин бу кешенең һич тә шаяртырга җыенмаганын күргәч, иреннәре шундук җыелып, ул җитди кыяфәт алды, авыр сулаган булды:

— Минем пациентлар җүләрләр бит алар. Акыллары җитешми. — Ул, соңгы җөмләсен әйткәндә, урта бармагын чигәсенә куеп, боргычларга уйлаган иде, теге кеше әллә ни уйлар дип шикләнеп, тыелып калды һәм бары: — Минекеләргә ирек бирсәң, бүген үк стеналарны җимереп чыгып китәрләр иде урамга, — дип кенә куйды.

— Димәк, аларга да ирек кирәк?

Садыйк Сираевич әлеге сорауны аңласа-аңламаса да җавап бирергә ашыкмады, ул акрынлап акылына килә башлап, эшнең бик үк хәерле булмаячагын сизенә башлады. Нишләп теленә салынып, теләсә нәрсә сөйләшеп утыра соң әле ул?! Атасының язмышын онытканмыни!.. Шушы оешма кешеләре, аны һәм өч апасын шыр ятим калдырып, сугыш башланыр алдыннан гына, әтиләрен алып чыгып киттеләр бит! Ул «халык дошманы» малае булып үсте ләбаса! Әлеге оешмадан курку аның канында бит инде югыйсә! Күрәсең, соңгы еллардагы вакыйгалар аның уяулыгын, сизгерлеген киметеп җибәргән...

Садыйк Сираевичның иреннәре чатнап кипте.

— Сезнең әтиегез Сирай Габитовны ничәнче елларны акладылар әле?

Бу сорау түгел иде, шуңа күрә Садыйк Сираевич аңа, туры җавап бирмичә:

— Әтинең бернинди гаебе булмаган, — дип кенә куйды. Иреннәрен бер-берсеннән ничекләр итеп аера алгандыр, үзе дә аптырады соңыннан.

— Гаепсез булмаганлыгын беләм мин, — дип сүзен дәвам итте теге адәм: — Мин сезнең янга әтиегез хакында сөйләшергә дип килмәдем, хәзер башка заман. Тик менә мин шуны аңламыйм: сез ничек итеп, нинди күңелегез, ни йөрәгегез белән ул пациентларыгызны дүрт стена артында бикләп тота аласыз?! Урамда көн нинди матур!

— Сез миңа нишләргә кушасыз?

Садыйк Сираевич бик аптырашта иде. Аның мондый кыяфәтен күреп торган теге адәм үзе ярдәмгә килде:

— Һава сулап керсеннәр!

— Ничек?! — Садыйк Сираевичның күзләре маңгаена менә язды: — Ничек?! — дип кабатлап сорады ул тагын бер кат.

Күн курткалы тәрәзәгә таба ымлады һәм үзенең эч пошыргыч тыныч, ләкин боерулы тавышы белән:

— Анда автобуслар көтеп тора! — диде. — Ирек мәйданын карап килсеннәр, бераз аякларын, тамакларын язсыннар.

Ләкин Садыйк Сираевичка һаман барып җитмәгән иде әле. Ул үзе дә җүләр кеше сымак теге кешегә тик аптырап карап утыруын бирде.

Күн куртка кесәсеннән кәгазь чыгарып, баш табиб ярдәмчесенә сузды.

— Менә...

...Шул көннән башлап Ирек мәйданына милләтпәрвәрләр белән бер рәткә Садыйк Сираевичның пациентлары да басты.

Күктәге теге исемсез, яңа Йолдыз кинәт сүрелә башлады. Әүвәл ул бик көчле яктылык биреп шактый вакыт җемелдәп торды торды да аннан соң бөтенләй сүнеп күздән юкка да чыкты... Бу хәлгә, Йолдыз югалуга, иң көенгән җан иясе әнкә бөркет булды. Ул бөтенләй кәефсезләнеп, хәтта ашаудан да калды. Моны күреп торган әткә бөркет сөеклесенең күңелен күтәрү өчен нишләр генә кыланып карамады, әмма файдасы булмады. Ахырда ул, болытлар арасыннан теге югалган Йолдызны табып алып төшәм, дип, мең кат вәгъдәләр биреп, бар гаярьлеген, бар булган көчен туплап, югарыга атылды. Бу вакытта мари урманнарында Самарадан куып китерелгән танк полкы солдатлары, эшсезлектән ни кыларга белмичә, гөмбә җыеп йөри иде. Араларыннан берсе, зәңгәр күктә йөзгән бөркетне күреп алып, автоматын салды һәм аңа төбәп атып та җибәрде... Бар урман шау итеп куйды, бөркет таш кебек Илләт елгасына егылып төште. Ату тавышын кара урман үзенә йотты...

Бөркет гаиләсе ятим калды, яклаучысыз калды. Чал наратлар, яшь каен кызлары, купшы чыршылар, ятим гаиләне кызганып, сыктап-сызланып бик озак елаштылар...

## Бабай буласы кеше кармак сала

Барый Казан читендәге коттеджга барса да барды, бармаса да барды. Бу чакыру бик зур табышмак иде аңа. Садыйк Габитовның Дәү филиалда нинди урын тотканын һәм, гомумән, нинди кеше икәнлеген белмәгән кеше бар микән?

Аның күңелендә мең төрле шик-шөбһә кайнады: Барыйны кайдан белә ул, тиктомалдан гына нәрсәгә дип чакырткан? Һәм ни өчен эш урынына түгел, нәкъ менә өенә дәштерә, өстәвенә кичке якта, эш сәгате тәмамланган вакытта?! Соңгы очрашуда Зәет Вәлиевич ФСБ хакында авызын ачкан иде, тик аңлатып кына бетермәде. Барый үзе дә җентекләп тормады, ичмаса. Ник җүнләп сорашмады икән шул хакта? Югыйсә игътибарга алмаслык, колак читеннән генә уздырып җибәрерлек оешма да түгел ләбаса инде?

Ул юлга чыгар алдыннан телефон аша Зәет Вәлиевичны эзләде, тик төштән соң филиал башлыгының койрыгын тотулары ай-һай иде, кесә телефоны да сүндереп куелган. Барый идарәдә аптырап утырды утырды да гаражга барып, «уазик» машинасын кара төстәге «БМВ»сына алыштырды, арткы утыргычка ау мылтыгын салды, пистолет кобурасын киеп куйды. Бала башлы бүрене ауларга барганда гына шулай коралланa торган иде ул. Хәер, бу юлы гранаталарын алмады, ни әйтсәң дә, ул «уенчык»лары законсыз бит — курыкты егет. Әүвәл ул туп-туры урманга таба юл тотты, Гөлйөземне, малаен күрәсе килде. Ни булмас аның белән? Кияүгә чыгу хакында тәкъдим ясарга күптән йөри бит инде, хәзер менә шул турыда тагын бер кат әйтеп китсен әле.

Бүген аны урман бик тыныч каршы алды. Барый уенча, әллә нинди серле, хәтта шомлы тынлык иде бу. Әллә курыкканга куш күренә дигәндәй генәме соң? Урман авызына кереп, бераз баруга, туктап, машинадан төште һәм, мылтык көпшәсен югарыга күтәреп, төзәми-нитми генә атып та җибәрде, үзенчә бу хәерсез тынлыкны бозасы килде. Ату кайтавазы кире әйләнеп кайтырга өлгермәде, агач башыннан Барыйның аяк астына, шапылдап, канга баткан нәни тиен баласы килеп төште. Бу хәлне күреп, ул авызын ачып катып калды, аптырап яралы тиенгә карап тора башлады. Тиен баласы әле җан биреп өлгермәгән иде, гәрчә бүре ядрәләре аны чәрдәкләп ташлаган, иләк ясаган булса да. «Җүнле фал түгел бу...» — дип уйлады Әкбәров. Чыннан да, бер килмәсә килми бит ул. Габитов та аны юкка гына чакырмагандыр, хәерлегә түгелдер бу эшгамәл? Әллә барып тормаска инде?! Һе, Габитов чаклы Габитов чакыргачмы?.. Аның бит тән сакчылары да Дәү филиал башлыгыныкыннан күбрәк дип сөйлиләр. Белеп әйтәләрме, белмичә такылдыйлармы — анысы әлегә Барый өчен караңгы. Әллә Мөхәммәткә шылтыратып карарга инде?.. Хәер, ул ни белсен ди... Чү, туктале, ә Хәниф Хатыйпович!!! Бу фикеренә Барый үзе дә сөенеп куйды. Ничек бая ук башына килмәгәндер! Малай-шалай кебек коралланган булып чыгып китәргә әзерләнде бит! Әлеге уйлары Әкбәровны үсендереп җибәрде. Ул машина алдында яткан тиен үләксәсен аяк башы белән генә читкәрәк этеп җибәрде дә руль артына сикереп менде. Әүвәл Гөлйөземне күрергә!..

Гөлйөзем өйдә ялгыз башы гына иде, Әнвәрне әбисе туганнарына кунакка алып киткән булып чыкты. Малайның башыннан сыйпыйсы килгән булса да, Гөлйземнең үзе генә булуына ул хәтта сөенеп тә куйды әле.

Гөлйөземнәрнең капка төбенә килеп җитүгә, Барый ничектер тынычланып калды, Габитов та офык артынарак күмелгән кебек булды, тиен үләксәсе дә онытылды.

Һай, җан тынычлыгы дигән нәрсә! Сине бернинди акчаларга да, тау-тау алтыннарга да сатып алып булмый икән ләбаса! Нишләп адәм баласы шуны баштук аңламый икән? Югыйсә гел шуңа гына омтылып яшәгән булыр иде канә!.. Һай, адәм баласы...

Гомердә булмаганча, Гөлйөземне күрүгә исә югалып калды Әкбәров: баягы җан тынычлыгы да, өстәвенә моңарчы булган кыюлыгы, бәйсезлеге, ертлачлыгы, гомумән, «барыйлыгы» бер йомгакка җыелды да табан астына тәгәрәде инде менә! «Йа! Мин дә ояла белермен икән!» — дип, үз-үзенә шаккатып басып торды ул беркавым. Тик кайдан белсен: «КамАЗ» кабинасындагы хәерсез хәлләрдән соң яшь хатын да үзе түгел иде бүген. Аның хатын-кыз җанын курку хисе биләп алып, шуның өстенә миен бертуктаусыз юньсез бер хис кимерә: «Барый белә торгандыр, белә торгандыр, Сәмигулла дуңгыз — Барыйга үчле адәм — мыскыл итеп, мактанып сөйләнеп йөргәндер дә барып ишетелгәндер».

Югыйсә әнә бит: элеккеге Барыйны бүген әллә ничек кенә үзгәртеп куйганнар кебек, сәер ул, икенче ул бүген, үзенә охшамаган да төсле. Ярабби бер Аллам, әгәр чыннан да ишеткән булса, белә торган булса... Ул аны... Ул аны урманга алып чыгып!..

Гөлйөземе каршында уклау кебек катып сүзсез басып тору уңайсыз. Күрәләтә үз-үзеңне саткан кебек... Сүз булсын өчен генә ул авызын ачты һәм тел тегермәне аннан сүзләр дә әйләндереп чыгарды:

— Бер урманнарны әйләнеп керикме соң?

Бу сүзләр хатынны пычаксыз суйган кебек булды, ул куырылып килде, тәне аша бер көтү кырмыска чабышып узды, иреннәре дерелдәргә кереште. Ләкин хатын-кыз үзенең хатын-кыз икәнлеген инстинкт белән теләсә нинди кыен вакытларда да исенә төшереп, һәртөрле авыр мизгелдә шуны калкан итеп файдалана, организмы җитәрлек микъдарда тиз генә моңарчы табигатьтә билгесез һәм гаҗәеп саклану көченә ия булган сок бүлеп чыгарып, шул аны бар бәлаләрдән саклап кала иде. Гөлйөзем белән дә шулай булды: «Хәзер Барыйның чәченә ябышам? Мари хатыны янына барып йөргәнен исенә төшерәм дә...»

Хатынның иреннәре дерелдәвен буйдак ир үзенчә юрады: «Ярата, сагынган!.. Ә мин, юньсез, мари хатыннары янына йөрим! Шундый Гөлйөземем була торып!..» Ул хатынны сак кына үзенә таба тартып китерде дә дерелдәгән иреннәренә битен тигезеп алды. Каен җиләге, урман курасы гына үбеп үскән затлы иреннәр!.. Һай, нигә берәр галим, Барый туганчы ук, мәхәббәт, ярату дигән хисләргә аңлатма биреп, адәм баласының йөрәгендәге хисләр микъдарын тәгаен үлчи ала торган җайланма уйлап тапмаган икән соң?!

Мәсәлән, температураны үлчи торган градусник кебек. Йөрәк турысында беркавым тоттың — вәссәлам: шул хатын-кызга карата синең мәхәббәтең нуль яки йөзенче сызыкка килеп җитә язган. Аннан соң бернинди шикләнү-икеләнүләр дә калмас, гаиләләр дә бәхетлерәк булыр, яшьләр дә тотрыкланыр, чәчәктән чәчәккә кунган күбәләктәй саташып йөрмәсләр!..

Барый шундый юк-бар хыяллары белән ишеккә таба атлады, Гөлйөзем аның артыннан иярсә дә иярде, иярмәсә дә иярде инде.

Бу мизгелләрдә икесен дә бер уй газаплады: күңел түрендәниләр кайнаганын бер-беренә ничек тә сиздермәскә иде. Ләкин алар бәяләп җиткермәделәр — адәм баласының күңеле нәкъ көзге кебек ул — эчтәге хисләр икесенең дә гамәл-кыланышларыннан ук чагылып тора, моны алар бары тик икесе дә бер үк халәттә булганга күрә генә сизеп, төшенеп җиткерә алмыйлар, хәзергесе мизгелләрдә икесенә дә уртак булган бер шөгыль табудан да мәслихәтрәк гамәл юклыгын исә җаннары белән тоемлыйлар, тик ул уртак шөгыльнең тәгаен генә ни икәнлеген белмәгәнлектән, аптырап, чал нарат башларына, рәт-рәт булып утырган каен ябалдашларына карыйлар. Әмма ул уртак шөгыль агач башларында асылынып тормый иде. Алар урман эченә табарак уздылар. «Карале, кара! — диде Гөлйөзем шулчак сөенечле тавыш белән, бәләкәй генә аланлыкта үскән ике нарат агачына таба ымлап: — Ничек үскәннәр бит!»

Сыенышып үскән ике нарат агачының берсе ничектер янәшәдәгесенә башын салган кебек. Югыйсә үз йортларыннан әллә ни ерак булмаган бу агачларны ул гомере буе күреп үсте, әмма игътибар итмәгән булган икән моңарчы. Менә бүген күрә, беренче мәртәбә күрә!.. Гаҗәп бит инде бер уйлаганда! Агачларның мондый кыяфәтен күрә торып, янәшәңдә генә басып торган хатын-кызны кочагыңа алмыйча һич мөмкин түгел бит...

Урман аларның икесен дә кыен хәлдән коткарды, рәхмәт төшкере. Хәер, урманның үз кызына беренче мәртәбә генә ярдәм кулы сузуы түгел инде бу...

...Барый килеп җиткәндә, Садыйк Сираевич өйдә юк иде әле. Ул хуҗаның кайтканын урамда, машинасында утырып көтәргә уйлады.

Өйрәнгән гадәте буенча радионы кабызмакчы булды, ләкин кул хәрәкәтенә кадәр үк радиомагнитоланың юк икәнлеге исенә төште: узган атнада гына «джип»ның ишеген каерып ачып, аны урлап киттеләр, авылда бит әле, үзенең туган авылында ук!.. Бу хәл исенә төшкәч, Барый күңелсезләнеп китте. Соңгы елларда шәһәрләрдәге тәртипсезлек, — кая ул тәртипсезлек кенә булсын ди, — чын мәгънәсендә бандитлык, хулиганлык, ахыр чиктә аны авыз тутырып «бандитлык һәм оешкан җинаятьчелек» дип атап булыр иде, — авыл җиренә дә килеп керде, торабара авыллар шәһәрне дә арттырып җибәрделәр! Баксаң, нинди авыл иде ул! Кемнең казы ничә бәбкә чыгарганны да, кемнең тавыгы тәүлеккә ничә йомырка салганны да бар халык сәгате-минуты белән белеп тора торган эчкерсез авыл иде. Югыйсә моннан бер дистә ел элек кенә бит әле!.. Бу үзгәртеп кору дигәннәре тыныч кына үз көенә яшәп ята торган кырмыска ояларын бутады да атты: ата улны, ана кызны танымаслык хәлгә китерелде мескен халык. Әлбәттә, Барый замананың үзгәрергә тиешлеген үзе дә яхшы белә һәм ул хәлләргә каршы да түгел. Ләкин болай ук булыр дип берәү дә күз алдына китермәгән иде.

Совет дәүләтен яһүдләр җимерде, чөнки аларга «капканы» төбенә чаклы ачып куеп, «урыс еврейларын» СССР төрмәсеннән коткарырга кирәк булды. Яһүдләр Израильгә агылды, калганы монда калды һәм элеккеге куәтле дәүләтне эчке яктан таркатырга кереште. Әлбәттә, җимереклекләр Израильнең үзенә дә бәхет китермәде: каннары, җаннары гасырлар буе урыс холкы бе-

лән сугарылган тугандашлары аларга бары тик кайгы-мәшәкатьләр генә алып килде. Палестина белән сугыштан һаман башлары чыга алмый бахырларның...

Әлбәттә, Барый үзе болай ук, бу рәвешле үк фикер йөртми, әлеге «сәясәт» Мөхәммәт аша колагына кергән сүзләр һәм нәтиҗәләр иде. Ул шулай дип уйлап та бетермәде, аның машинасы артына чит ил машинасы килеп туктады һәм аннан Мөхәммәт үзе сикереп төште. Барый Мөхәммәтне күргәч, әллә нишләп китте! Ләкин бу хәлне ни дип юрарга да өлгермәде, тегесе, йөгереп килеп, машина ишеген ачты һәм аптыравыннан катып калган дустын кочаклап машинадан тартып төшерде.

— Нишләп йомырка баскан каз кебек утырасың монда, төш! — диде ул, гөрелдәп көлә-көлә.

— Ә сиңа монда ни калган?

— Менә син киләсе дип ишеттем дә. Ярты сәгать элек кенә Садыйк Сираевич үзе шылтыратты.

«Садыйк Сираевичны Мөхәммәт кайдан белә?» дигән уй-сорау миен борауларга керешсә дә, үзе сөйләп бирер әле дигән өмет белән әлегә сүз катмый торырга булды.

— Соңгы арада авылга да кайтканың юк, оныттың, — дип кенә куйды ул.

— Авыл халкының синнән зарланганын тыңларга дип кайтыйммыни анда! — дип төрттереп алды Мөхәммәт.

Дустының бу сүзләреннән соң шартлатып җавап бирергә бик теле кычытса да, Барый бу юлы дәшмәде, аны хәзер авыл түгел, үз язмышы күбрәк борчый.

— Мине монда ник чакырттылар икән, белмисеңме?

Тегесе көлеп җибәрде, кыяфәтенә караганда белә һәм бик яхшы белә иде. Бу исә Барыйга җиңеллек китерде, дусты дорфарак сөйләшсә дә, үпкәләргә ашыкмады, аны игътибар белән тыңлаячагын белдереп, күзләренә карады.

— Сюрприз, хәзер үзең күрерсең, тик борчылма, бу очрашу синең файдага булачак.

Ул шулай дип әйтеп бетереп авызын ябарга да өлгермәде, дустының кесәсеннән әтәч кычкырган тавыш ишетелде һәм шуның артыннан ук музыка уйнарга кереште. Мөхәммәт ашыкмыйча гына куен кесәсенә тыгылды һәм аннан кесә телефонын алып колагына куйды:

— Да, мин тыңлыйм.

Барый аның кем белән сөйләшкәнен белмәсә дә, дустының дулкынлануына караганда эфир дулкыннары юк кына кеше тавышын алып килмәгән иде. «Мин аңладым, борчылмагыз. Сез дигәнчә булыр!» дип, борчу катыш шатлыклы тавыш белән җавап бирүләре Мөхәммәтнең бик җитди кеше белән сөйләшүен аңлата, тик ул әлеге иптәшнең «Садыйк Сираевич, Садыйк Сираевич!» дия-дия исемен кабатлап, Барыйга күз кыскалап куйса да, тегесе аның кем белән гәпләшкәнен һич төшенеп бетерә алмады.

— Садыйк Сираевич үзе шылтырата, бүген күрешеп булмый, ди. Киләсе атнага инде. Үзем хәбәр итәрмен, диде. Ә мин сиңа...

— Нинди Садыйк Сираевич? Габитов үзе шылтыратмагандыр ич?!

— Үзе шул...

Барый янә беренче мәртәбә сабакташына күтәрелеп карап куйды... Ышанмыйча аптырапмы, көнләшү хисләре белән ме — монысын бу мизгелләрдә икесе дә анык кына төшенеп бетерә алмадылар. «Алай, үзгәргән бу малай!» — дип уйлап куйды Барый. «Менә мин кемнәр белән эш итәм! Хәзер син лидер түгел, мин, председатель малае!» — ди иде шикелле аның карашы. Тик ике дус, ике сабакташ арасындагы бу дөньяви, дөресрәге, мин-минлеккә вә исәп-хисапка корылган, әмма бик тә мантыйклы халәт озакка сузыла алмады. Һәрхәлдә, авылда яшәп ятучы Барый Әкбәров шулай дип уйлады. Әмма дөньяның Садыйк Сираевичлары белән кесә телефоны аша гына сәламләшә торган шәһәр кешесе алай вакланып, уй-күңелендә чокынып тормады, ярды да салды:

— Син исеменнән үк котың алынып торган Садыйк Сираевич белән без күптәнге дуслар! Аны монда сине ни өчен чакыртканлыгын да мин бик яхшы беләм. Әмма мин сине дә яхшы беләм. Шуңа күрә сине махсус үзем чакырттым, әүвәл Садыйк Сираевич белән аерым сөйләшерсез дигән идем. Булмады бит менә. Очрашу — киләсе атнада. Кыскасы, шул: абзый сине бик ошаткан!

— Кит әле моннан! Мине кайдан белсен ди ул?! Күргәне дә юк ич?

— Беләләр, туган, беләләр... алар барысын да белеп тора.

— ФСБ ашамы? — дип, беркатлы сорау бирде Әкбәров, чөнки әлеге оешманың үзе белән кызыксынганын филиал башлыгыннан бер ишеткән иде инде.

Мөхәммәт ирен читләре белән генә серле итеп елмаеп куйды да, нигәдер авыр сулап:

— ФСБдан да хуже, — дип куйды. Өстәп тагын нидер әйтмәкче иде, тик тукталып калды, аннары, Садыйк Сираевичның коттеджы капкасы ягына таба ымлап: — Әйдә керәбез, үзең күрерсең, — диде.

— Да ты што! Хуҗа үзе югындамы?!

— Хуҗа булмаса, хатыны, кызы, малае өйдә.

«Шулчаклы тыныч, гади итеп кенә сөйләшә бу Мөхәммәт, әллә Садыйк Сираевичның кияве булырга йөри инде?» — дип тә уйлап бетермәде, тегесе, аның фикерләрен укыгандай:

— Бик шәп кызы бар аның, таныштырам! — дигән булды. Мондый табышмак сөйләшү Барыйның кәефен үк җибәрә башлаган иде, ул дорфа гына:

— Үзең таныш! — диде.

— Мин бик танышкан булыр идем дә...

— Гөлчәчәк дисеңме?

— Причем монда Гөлчәчәк!

— Ничек причем?!

— Шулай причем... Ул кыз менә синең белән танышырга тели, ди икән шул.

Барый дустына ачулы итеп карап алды: «Шаяртма!» янәсе.

— Чынлап, дустым, чынлап. Син монда мине гаепләп утырган булма, үзең сөйлә! Ничек итеп син Садыйк Сираевичның кызы белән таныша алдың?! Урманда ятып, авылда торып! Менә бу табышмак! Мин түгел, син үзең тел яшереп маташасың, дускай!

Мөхәммәтнең тавышында чак кына дустына үпкә дә сизелә, имеш, мин сиңа барысын да сөйләп, җиткереп торам, эч серләремне синнән яшергәнем юк, ә син... ә син! Кыскасы, син шактый хәйләкәр дус булып чыктың әле, диясе килә шикелле иде.

Дөньяда аңлашуның төрле чаралары бар: телләр белән, язмача, куллар, ымлыклар, күз карашлары ярдәмендә. Шуларга күңелләр аша аралашуны да өстәргә мөмкин, ягъни биотоклар ярдәмендә. Аңлашуның мондый төре үзара шактый якын кешеләр арасында гына була торгандыр. Мәсәлән, ыштансыз чактан ук бергә әүмәкләшеп, әвәрә килеп үскән авылдаш-яшьтәшләр арасында.

Барый да Мөхәммәтнең ни әйтергә теләгәнен шундук төшенеп алды һәм, үзен гаепле сизгәндәй:

— Үзебез турында без идеаллар аша, калган кешеләр хакында аларның гамәлләре буенча хөкем йөртәбез, — дип куйды. — Әлбәттә, сөйлим, дустым, синнән яшерен сер юк. Тик мин әлегә нәрсә сөйләргә икәнлеген генә аңлап бетермим. Билләһи!

— Садыйк Сираевичның кызы Әлфияне белмисеңмени?

— Әлфия?!

— Әйе, әйе, анда синең Гөлчәчәк белән төшкән фотокарточкаң да бар.

Барыйның аптыравы йөзенә үк чыгып, ул иңбашларын сикертте.

— Алайса киттек, таныштырам, — дип, Мөхәммәт Барыйны тимер капкага таба этте. Аннары ул никтер кире уйлап, инде үзенә буйсынып, капкага кузгалган Барыйның җиңеннән тартты һәм бик җитди кыяфәт белән: — Узган атнада урманда бер кыз белән танышып, аны Казанга кадәр илтеп куйдыңмы?

Барый, аптырап, тирә-ягына карады, тагын бер мәртәбә үзләре басып торган урыннарны күзләп чыкты һәм шулчак аның кыяфәтендәге гаҗәпләнү, аптырау ниндидер кызыксыну белән алышынды кебек.

— Так, так, Әлфия! Исемә төште, Неужели ул, ул кыз... Садыйк Сираевичның кызы булган икән?!

— Булган гына да түгел, Садыйк Сираевичның бердәнбер сөекле кызы!

Мөхәммәт кинәт тагын да җитдиләнеп китте, күренеп тора: дусты үзе дә аптырауда, ләкин аның аптырау галәмәте Барыйныкы шикелле яңалык ишеткәннән түгел, ә бәлки чарасызлыктан иде. Шулай да ул үзен тиз кулга алды һәм, кискен карарга килеп:

— Киттек моннан! — дип, Барыйның җиңеннән тотты. — Кирәк булса, үзләре эзләп табарлар әле, син кияү егете түгел. Просмотрга килергә монда!

Барый карышмыйча аның артыннан иярде, һәркайсы үз машинасына утырып кузгалып киттеләр. Казанга борылган юл чатында туктарга килештеләр.

Әлбәттә, мондый карарга килер алдыннан Мөхәммәтнең башыннан меӊ төрле уй-фикер узды, егет бигрәк тә соңгы вакытларда һәр адымын ныклап уйларга өйрәнде: тормыш үзе өйрәтте. Авызын пешерә-пешерә өйрәтә бу тормыш!.. Чынлап та, адәм баласы үз хаталарында күбрәк өйрәнә. Бу ясалма теория, юкка акыл сату гына түгел, ул — Табигать кануннары. Табигать ка-

нуннарына каршы килеп, кешелек дөньясы күпме хата-ялгышлар кылды инде, нәтиҗәсе һаман бер үк: миллионнарча корбаннар, ачлык һәм хәерчелек булды. «Миллионнар үлеме — статистика, бер кешенең һәлакәте — фаҗига», — дип әйтеп калдырган Черчилль мең мәртәбә хаклы бу очракта. Барый дустының язмышыннан фаҗига ясыйсы килми иде Мөхәммәтнең. Үзенең шушы җәтмә корбаны булуы җитмәгәнмени! Хәер, корбан дип инде. Ләкин шулай да...

Әгәр Садыйк Сираевич Барыйны кызы Әлфия белән бәйләп куярга уйласа, Гөлйөзем ни хәлләр кичерер? Аларның балалары бар бит. Һәм нигә ике тинтәк авылдаш малайлар аркасында ул җиләк кенә үбеп үскән урман кызлары бәхетсез булырга тиеш ди?! Ул үзе Гөлчәчәкне күзенә карап алдап йөри бит!.. Хәер, алдап дип инде... Һәрхәлдә, бүгенге көнгә чаклы егетнең әлеге йомгакның очына чыга алганы юк. Адәм баласы һәрвакыт күпмедер микъдарда эгоист. Үзен аклап, соңгы чиктә ул барыбер саламга булса тотынырга талпыначак...

Фу... Бетмәс-төкәнмәс уйлар ташкыны аның башындагы уйлар кебек язгы ташуларда Ташсу елгасы да бу чаклы болганмый торгандыр, билләһи!

Ни әйтсәң дә, кыюсыз, боламык егет түгел Мөхәммәт. Ширинә Самуиловнаның да күзенә карап әйтте ул беркөнне. Афәрин, әйтте егет әйтәсен. Әмма икенче көнне үк тормыш күсәге аның башына китереп тондырды, ул миңгерәүләнеп калды.

Шулай чираттагы бер шимбәдә Мөхәммәт Бөгелмәгә кайтырга җыенды. Самолетка билетын да алдан ук алып куйды. Бер-берсе белән еш аралашканнан һәм еш кына Ширинә Самуиловнада куна да калганлыктан, алар арасында сер юк кебек иде. Ләкин Гөлчәчәк янына кайтырга җыенуын ул Ширинә Самуиловнага сиздермәде, яшерен сер итеп саклады. Хатын-кыз сизми димени соң! Тегесе моны белеп алып, ул көнне сәнгатькәрләр идарәсендә мөһим җыелыш билгеләттерде. Сүз филиал рәссамнарының Мәскәүдә узачак шәхси күргәзмә планын раслау хакында барырга тиеш. Мөхәммәтнең күргәзмәдә катнашырга теләве хакындагы гариза идарәдә күптәннән ята, өстәвенә әлеге мәсьәлә моңарчы ук та хәл ителгән иде инде, чөнки ул бәйгедә беренче урынны яулап алган рәссам. Бәйге шартлары буенча исә, беренче — өченче урыннар «автомат» рәвештә узарга тиеш, диделәр. Әнә шуларны уйлап, Уразов билетын кире тапшырмады, аннан соң алдан хәбәр ителгән, Гөлчәчәк тә көтеп тора бит. Бу хакта каяндыр белеп алган Ширинә: «Мәсьәлә бик җитди бит, бәлки, катнашырсың», — диде.

Бу сөйләшү җомга көн кичтән булды, эштән соң Ширинә Самуиловна аны ашыгыч рәвештә үз фатирына чакыртып алды. Чакыртуының сәбәбе, чынлап та, җитди икән: Ширинә Самуиловнаның Чиләбедән дус кызы килгән, ул да сәнгать белгече. Изольда Сафаровна Ширинәгә караганда шактый яшьрәк булса да, үз-үзен тотышы белән бер генә дә дустыннан калышмый, хатын-кыз таланты (хатын-кызлык сәләте Адәмнән аермалы буларак Хава ханымга өстәп иңдерелгән өстәмә талант) янына тормыштан килгән ясалма кыланыш-гамәлләрен дә кушып куйсаң, әле шактый яшь булуына карамастан, үз дигәненә ирешә ала торган ханымга охшаган. Шуның өстенә гаҗәп чибәр дә, каһәрең!.. Ни әйтсәң дә, матурлыгы ясалма матурлык түгел, зәвыклы хатын табигать биргән байлыгына бер генә артык буяу да өстәмәгән. Ширинә Самуиловна иртән торгач, Мөхәммәткә «чын йөзен» күрсәтмәс өчен тизрәк ванна бүлмәсенә бикләнеп, ясанырга, буянырга керешә, аннан бары йөз-кыяфәтен «сылагач» кына чыга. Әлбәттә, Ширинә Самуиловна Мөхәммәтне үзенә әлеге чибәр дустын күрсәтергә чакыртмагандыр. Ләкин егет тә сукыр түгел бит инде, кычкырып торган матурлыкка күзен йомып, үзен бүкән сымак тота алмый, килеп керешкә үк, ул Изольданың чибәрлегенә сокlануын яшерә алмады, сүз белән әйтмәсә дә, бу фикере аның кыяфәтенә үк бәреп чыккан иде. Гөлчәчәк исемен ишетүгә, болай да каратутлы йөзе тагын да караңгылана торган Ширинә Самуиловна Мөхәммәтнең кунак ханымга сокланып каравына игътибар итмәгәнгә салышты, киресенчә, Изольданың егетнең күңел шәрәфләренә хуш килүенә сөенде генә кебек. Хатын-кыз — мәңгелек табышмак. Яһүд белән татар катыш Ширинә Самуиловна исә табышмакларның да табышмагы. Шуңа өстәп: «Ширинә Самуиловна елый белми торган хатын-кыз ул!» — дисәк, әлбәттә, моңа берәү дә ышанмаячак, чөнки һәркемгә мәгълүм аксиома — елый белмәгән хатын-кыз булмый ул дөньяда, диярләр. Ләкин ни хәл итәсең, Ширинә ханым чынлап та елый белми һәм елый да алмый иде шул... Битендәге иннек-кершәненең күз яшьләренә чылануыннан куркып түгел, билгеле. Холкы белән, табигате белән шундый хатын ул. Хәер, бер мәртәбә ул да елаган икән. Һәм ул беренче мәртәбә Мөхәммәтне очраткан көн... Дөресрәге, егетнең үзен күргәч, йөрәгенең кайсыдыр чите кысылып куйды куюын, тик менә рәссам егетнең «Урман кызы» әсәре белән танышып, аның кемгә багышланганын белгәч, кычкырып-кычкырып елады ул. Тик кайгы-борчудан түгел, шатлыктан елады хатын-кыз ул чакта. Шундый кешене очрату шатлыгыннан... Егетнең үз йөрәгендәге мәхәббәтен сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрә алуы сокландырды, һуштан яздырды кыз-хатын өммәтен! Гомере буе ке-

шеләргә сәнгать әсәрләренең серен, мәгънәсен аңлатып һәм шуны үзенең һөнәре итеп сайлаган ханым-солтаным, үзе дә бер мәлгә югалып калып, табигатьнең шул гүзәл гармониясенә җанытәне белән гашыйк булды, йөрәгендәге көнчелек уты (бу шашкын ут ярты дөньяны мизгел эчендә көйдереп, ялмап алырлык куәттә иде), аның инде сүрелә барган күңел учагына ялкын элеп, һәр күзәнәгенә үтеп керде. Бу хәлләрнең сәбәпчесе, әлбәттә, Мөхәммәт Уразов иде... Хәниф Хатыйповичка ул яшьлеге, җүләрлеге белән кияүгә чыгып, тиз генә араларын өзгәннәр иде. Гаилә тормышы ызгыш-талашка барып җиткәнчегә кадәр үк. Ләкин бу кушылу да эзсез генә калмады, икесе дә үлеп сөйгән кызлары инде үсеп буйга җиткән...

Сиринә ханым, яши торгач, бар нәрсәне дә хәл итә алырлык кодрәтле ханымга әверелде. Ул үзен бик көчле дип уйлый. Ләкин Мөхәммәт белән очрашкач, беренче мәртәбә үзенең мескенлеген, көчсезлеген тойды һәм шуңа гарьләнеп үлә язды. Гөлчәчәк атлы ниндидер бер авыл, кыргый урман кызы каршында да көчсез бит ул!.. Шул хис аны үтереп ташлады, барлыгын юкка чыгарып, салып таптый һәм бүгенге көнгәчә изеп-сытып тора. Әнә бит... Мөхәммәт иртәгә тагын шуның янына җыена. Хәленнән килсә, Сиринә ханым аның фатирына бер олау фахишә кызлар кертеп тутырыр, ләкин Бөгелмәгә җибәрмәс иде...

Алар кич буе рәсем сәнгате хакында сөйләштеләр, төрле рәссамнарның альбомнарын актарып утырдылар. Кичке сәгать унберләр тирәсендә Сиринә ханымның фатирында телефон шылтырады. Телефонның теге очында Хәниф Хатыйповичның яшь хатыны Сиринә Самуиловнага кызып-кызып нидер аңлатты, сөйләде. Ул хатын Хәниф Хатыйповичка Сиринәдән соң кияүгә чыккан яшь хатын иде. Хуҗага янә депрессия булган, хатыны ярдәмгә көндәшен — Сиринә ханымны чакырып ята. Ул, тиз генә киенеп, кунакларыннан гафу үтенде дә чыгып китте — аны подъезд төбендә Хәниф Хатыйповичның алты йөзле «мерседес»ы көтеп тора иде инде.

Кунаклар икесе генә калды, хуҗа хатынның өйгә таң белән генә әйләнеп кайтасын белеп калдылар ул бахырлар. Мөхәммәтнең сарык белән кәҗә көтүен көткәне бар, малай чакта колхозның яшелчә бакчасына әниләре белән бергәләшеп кәбестә җыйганы да бар. Малай чактан ук кәҗәнең кәбестәгә булган мөнәсәбәтен дә күреп үсте. Бүген исә үзенең хәлләре дә шул чамадарак. Ләкин ул тук кәҗә булып кыланды, әгәр дә «кәбестә», үзеннән-үзе чәкәнен өзеп, «кәҗә» янына тәгәрәп килсә генә. Әлбәттә, бу «кәбестә»нең «чәкәне» күптән өзелгәндер инде. Бүген, ай тулган көндә, элекке иренең депрессиясе булуын алдан ук белеп торган Сиринә Самуиловна дус хатынын махсус чакыртты, Мөхәммәтне Бөгелмәгә җибәрмәс өчен ул әллә ниләр кылырга әзер, дус хатыннарының «бакчасына» керүенә дә сүз әйтерлек хәлдә түгел иде, бичара...

Чөнки ул белеп тора: иртәгә егет тагын аныкы гына булачак. Изольда ерак Чиләбесенә китеп барачак, алар иртәгә дә, берсекөнгә дә күрешә алмаячаклар. Ә менә Гөлчәчәге янына очса, аннан егетнең кире кайтасына, дөресрәге, өйләнеп, башлы-күзле булып кайтмасына аның тамчы да ышанычы юк шул. Гыйшкы әнә шул рәвешле аңын-акылын томалады хатынның...

Югыйсә мондый хәлләрне элегрәк берәр авыл кешесе ишетсә, сүзсез-авызсыз калып, «тфү!» дип төкерер генә иде. Хәер, бу замандамы!.. Табигать балалары Табигать- энкәнең үзенә каршы килеп яткан бер болгавыр замандамы?.. Табигать тудырган балалар, Табигать-энкәбез ялгышкан икән бит, аның хатасын төзәтик дип, елгалар агышын кирегә үзгәртергә азапландылар, бу — һәлакәткә алып килде. Тора-бара ул балалар җаннарына Табигать-әнкәләре иңдергән самими, табигый хисләрне «кирегә борырга» җөрьәт иттеләр — кешелекнең рухи һәлакәт башы шуннан башланды. Аклану өчен мең-миллион төрле сәбәп-теорияләр табылды: ирекле мәхәббәт, ирекле секс һәм башкалар, һәм башкалар... Кешелек рухи яктан чери башлады, аннан сасы ис килә башлады. Дөньяны болгатучы таякларның юан башлары, Казандагы сабын заводыннан килгән сасы искә борын җыерган булып, шәһәр тирәсендәге урман-кырларга таеп беттеләр, әмма алар моның белән генә рухи череклектән урман арасына, Идел буйларына качып китеп кенә котыла алачак түгел иделәр инде. Җәмгыятьнең каны бозылды һәм арт санына зур чуан чыкты…

...Ул төнне яһүдә ханымның фатирында «кәҗә» белән «кәбестә» төн кундылар...

...Ләкин аларның берсе таң белән тәки ике аяклана алды һәм, күзләрен ертып ачып, аэропортка томырылды.

...Мөхәммәт әнә шул вакыйганы исенә төшереп барды. Хәер, ул гынамы соң! «Ул урман кызы сиңа нәрсә бирә ала, егеткәем?» — дип, туп-туры күзләренә карап әйтте Сиринә ханым, егет Бөгелмәдән әйләнеп кайткач. — Син — талант, сиңа үсәргә кирәк! Мин беренче чиратта синең әнә шул талантыңа гашыйк! Шуңа күрә сине зур дөньяга чыгарасым килә! Ә син гаилә баткаклыгына кереп чумарга, камыт кияргә атлыгып торасың!..» Мөхәммәт өчен болар яңалык түгел

иде. «Әгәр Гөлчәчәк булмаса, мин рәссам булмый идем! Мин шуның аркасында гына кулыма пумала алдым. Әйе, яшь чакта да рәсемнәр ясаштыргалый идем ясавын. Ләкин болай гына, уйнап кына... Мин ундүрт яшемдә чагында ук Гөлчәчәккә аның, урман кызының портретын ясарга вәгъдә бирдем. Шуннан соң минем тормышым бөтенләй үзгәреп китте, мин үзем дә үзгәрдем. Максатыма ирешәчәкмен дип, антлар эчтем. Менә килеп чыкты, мин аның портретын яза алдым! Шуннан соң минем күңелем үсеп китеп, рәссам булырга, зур рәссам булырга хыяллана башладым». Сиринә ханым аны тыныч кына тыңлады да гади генә итеп әйтеп куйды: «Бу илдә зур рәссам булу өчен талант кына җитми шул әле, егетем». «Мин көне-төне эшләячәкмен дә!!!» «Көне-төне эшләү түгел... пумаланңы хет шунда алтын буяуга манып язмыйсың!» Мөхәммәт, аның бу сүзләренә ачуы килеп, ишекне тибеп диярлек ачып чыгып китте Сиринә Самуиловна фатирыннан.

Мәскәүдә узачак күргәзмәдә Мөхәммәт Уразовның өч яңа картинасы да куелмаячак иде. Анкета һәм башка шуның ише кирәкле кәгазьләре янында торак-коммуналь хуҗалыгыннан гаилә хәле хакындагы белешмә кәгазе җитешми икән. Мөхәммәт бу турыда ишеткәч, әүвәл Сиринә ханымга шылтыратмакчы булган иде, ләкин Бөгелмәдән кайткач та ачуланышуларын исенә төшереп, тыелып калды һәм, хатасын төзәтергә дип, торак хуҗалыгына чапты. Дүшәмбе әлеге контора, үлеп ятсаң да, беркемгә дә бернинди белешмә бирми. Егет сишәмбе җиткәнен көтәргә булды. Ләкин иртәгесен дә юлы уңмады. Өстәл артында борынын казып утыручы яшь марҗа кызы чәрелдәвек нечкә тавышы белән:

— Фатирыгызга түләнгәнлек турында белешмә кәгазе кирәк! — диде.

Әлбәттә, Мөхәммәт фатирына ай саен җиренә җиткереп түләп бара, ул яктан аның тәртип, шуңа күрә батыраеп, үзе дә дорфа гына:

— Ник түләнмәсен! Компьютерыңнан тикшереп кара! — дип җавап бирде.

— Бухгалтериядән белешмә алып килегез!

Ни хәл итәсең, ул сораганны эшләмичә булмый, егет бухгалтерия ишеген эзләп китте. Ишек төбендә су буе чират. Тагын да гаҗәбе шул ук бер бухгалтерга ике төрле чират: берәүләр белешмә алырга тора, икенчеләренең кулларында белешмәләре дә бар, икенче кулларына тартмалы конфетлар һәм матур кәгазьле төргәкләр кыстырганнар. Чираттагылар надан егеткә бик тиз аңлатып бирделәр: паспортиска кыздан бухгалтер белешмәсе белән кирәкле белешмә алганнан соң, шул кәгазьгә бухгалтердан кул да куйдырасы бар икән. Күчтәнәчле чират кул куйдырырга торучылар чираты булып чыкты. Мондый хәл бары тик Рәсәй дигән кабахәт җәмгыятьтә генә була ала иде. Мөхәммәт, тешен кысып, кирәкле чиратка басты. Ярты көн узды дигәндә, ул күчтәнәчле чиратның башына килеп җитә алды. Күчтәнәчен дә бирде, ләкин аңа кирәкле белешмә бирмәделәр.

— Сезнең квартплата нигәдер ун сумга артык түләнгән бит, егеткәем! — диде кибән гәүдәле Наташа.

— Соң... артык булса, бик әйбәт! Миңа белешмә генә бирегез, зинһар!

— Бирә алмыйбыз!

— Ничек бирә алмыйсыз?! Минем түләнгән бит!

— Артык түләнгән. Ун тәңкә!

— Соң... хөкүмәткә файда булыр, мин ул сумны сорарга дип килмәдем бит?

Бухгалтер ханым утырган урыныннан селкенеп куйды һәм, каш астыннан гына Мөхәммәткә карап:

— Син нәрсә, егет, әллә монда ришвәтчеләр утыра дип беләсеңме?!

— Сезгә димим бит, хөкүмәт файдасына калсын, дим!

Юан гәүдәдән тавыш бу юлы тагын да нечкәрәк, әмма зәһәррәк булып чыкты:

— Әле син хөкүмәтне ришвәтчелектә гаепләмәкче буласыңмы?!

— Сез... Сез нәрсә сөйлисез? Мин аны үлеп яратам бит!

— Яратсаң, аның законнарын да хөрмәт итәргә кирәк, егеткәем. Кызларын кочасыз, каенаналарыгызны күрә алмыйсыз! Алай булмый ул!

— Каенананы да кочарга что ли!

— Следующий! — дип чәрелдәде нечкә зәңгәр тавыш.

Егет аптырап урамга чыкты. Беркавымнан, күргәзмәне оештыручы түрәгә шылтыратырга уйлап, аның номерын җыйды. Тик аннан да уңай җавап ишетә алмады, кирәкле кәгазьсез күргәзмәдә катнашу хакында уйларга да мөмкин түгел, Сиринә Самуиловна бу юлы таләпне бик каты куйды. Әгәр ул, күргәзмәгә җаваплы адәм, әгәр аны бозса, иртәгә үк урынымнан очачакмын, диде.

Бәхетенә күрә, күп тә узмады, аңа Сиринә Самуиловна үзе шылтыратты. Мөхәммәт аның Америкага кызы янына киткәнлеген ишеткән иде, шуңа күрә исәнләшергә дә онытып, гаҗәпләнеп сорап куйды:

— Сез кайдан шылтыратасыз, Сиринә Самуиловна!

— Нью-Йорктан! — диде дулкынның теге очындагы таныш тавыш. Бу тавыш әлеге минутта Мөхәммәт Уразовка гаҗәп кадерле, якын һәм сөйкемле булып ишетелде. — Нинди проблема?

— Проблема юк, — дигән булды егет, тавышындагы битарафлыкны сакларга тырышып.

— Алдашма! Беләм мин! Чынлап та ЖКО кәгазе кирәк! Мин ул тәртипне боза алмыйм. Хәтта синең өчен булса да. — Хатын сөйләшә белә, ничек кенә баш күтәреп, мөстәкыйль булырга тырышып караса да, ул аны, итәк астына җыеп тыгып, чарасыз бер бала хәлендә калдыра ала һәм аннары, шул балага ана кеше сыйфатында ярдәм кулы сузган булып, ике күкрәк арасына борыны белән төртеп куя ала иде. Талантлы хатын Сиринә Самуиловна!.. — Мин төзелеш министрына шылтыраттым, ЖКОга барып белешмә кәгазеңне ал!

Телефон өзелде, Мөхәммәт, ачудан төкеренә-төкеренә, кире борылды. Бу юлы теге нечкә зәңгәр тавышлы марҗа ханым аңа: «Ник аны баштук шулай димәдең?! Ну, бу яшьләр тел яшерергә ятаталар да соң инде», — дип сөйләнә-сөйләнә, белешмә кәгазе янына кирәк булмаса да аның күчермәсен дә ясап бирде. Бая калдырган бер тартма конфетын да кире төртте: «Зурлап килүегез өчен рәхмәт, әлбәттә. Ләкин мин бүләкләр кабул итеп утыра алмыйм. Мин хезмәттә!» — дип сөйләнде ул. Мөхәммәт дәшмәде, ачудан иреннәре кысылды, ул тартмасын чиратның ахырында ук басып торучы әбигә төртте дә, ишекне бәреп ябып, чыгып югалды.

Ике дус, Казанга борылып китә торган юл чатына җиткәч, машиналарын читкәрәк куеп, туктадылар. Мөхәммәт Барый дустына күңелен ачып салып, барысын да сөйләп бирергә уйлаган иде. Ләкин аның бая Садыйк Сираевич капка төбендә утырган чактагы бәхетле кыяфәтен исенә төшереп, тыелып калды. Бәхетле иде шул кыяфәте, чөнки аны атаклы Садыйк Сираевич үзе чакырткан бит! Үзе!..

Сиринә Самуиловна белән аралары суынгач, Мөхәммәтнең алдында бер-бер артлы киртәләр пәйда була башлады. Юк, юк, гөнаһасына керә алмый: Сиринә Самуиловна аяк чалмады аңа... тик... ярдәм кулы да сузмады. Бу кабахәт илдә зур кеше булу өчен талант кына җитмәгәнлеген шуннан соң гына аңлый башлады егет. Руль артында көр тавышлы, талантсыз-сәләтсез өч тиенлек буш бугазлар утыра. Аларга синең сәнгатең кирәкме соң!!! Әгәр дә Садыйк Сираевич белән танышып китмәгән булса?! Хәер, аның белән дә Мөхәммәтне Сиринә Самуиловна таныштырды бит!.. Теләсә, күз ачып йомганчы араларын да өзә ала... Әллә шуларның барысын да Барыйга сөйләп бирергәме: дустым, сиңа Садыйк Сираевич кызының күзе төшкән, Садыйк Сираевич исә синең бабаң булырга да каршы түгел, дип шәрехләп аңлатырга, ташла ул Гөлйөземеңне, Әлфия сиңа тиңрәк, син бары ул кыз белән генә кеше була алачаксың, дияргәме?!

Соң... соң... Бүтән юл юкмы икәнни соң?! Бу умырткасыз җәмгыятьтә кеше булам дигән кешегә шуннан башка бүтән төрле юл юкмы икәнни чынлап та?!

Аерылганда авылдашлар җыен юк-бар хакында гына сөйләшкән булдылар да, икесе ике якка — Мөхәммәт Уразов Казан ягына, Барый Әкбәров Байтимергә таба юл алдылар. Ләкин егетләрнең йөргән юллары аерым булса да, язмыш сукмаклары бер төрлерәк булырга охшап тора иде шул...

## Этләрнең башына сугып торасы юк...

Кара каргаларның холкы тәмам чуалып бетте. Моңарчы авыл халкының кара каргалардан зыян күреп, бу чаклы зар елаганнары юк иде. Хәзер исә авыл өстендә карга көтүе күренүгә, шарт-шорт мылтык аткан тавышлар гына яңгырап тора. Моның сәбәпчесе булып теге кара булмаган карга баласы иде. Чөнки аның җитәкчелегендә ишегалларындагы тавык җимнәренә генә түгел, бәбкә-чебиләргә дә һөҗүмнәр бик еш булып тора, хәтта алар яшелчә бакчаларына төшеп казынырга да күп сорап тормыйлар, орлыкларны актарып чыгарып, үсемлекләргә шактый зыян салалар.

Җәй башында Байтимердә бот чабып шаккатырлык сәер хәлләр башланды. Галләм абзыйның карчыгы Җәмилә апа быел редиска чәчмәде. Югыйсә һәр елны кар ачылуга, иртә язда витамин булыр дип, янбакчасына шуны төртә иде. Редиска узган ел Галләмнең ашказанына килешмәде, кеше ашаганда кызыгып кабуга эчен тырнарга кереште, тора-бара ул сару кайнауга чаклы китереп җиткерде. Шуңа күрә чәчеп тормаска булды редисканы Җәмилә апа. Аның каравы шундый нәрсәләрне, моннан берничә ел элек Җәмиләдән күреп, ян күршеләре Сәлимә түти

утырта башлаган иде. Аныңише азыкны гомерен мари ягында балта остасы булып уздырган Салих абый үлеп ярата, аларның өстәлләреннән тозлаган кәбестә, көздән үк агач мичкәгә салып әзерләп куйган тозлы алма, берничә төрле гөмбә өзелми. Ярый, хуш, бер күрше утыртмады редисканы быел, ә икенчесе күп итеп чәчте. Җәмилә апа редиска урынына, ашказанына бик файдалы дигәч, үзе исемен дә белмәгән яфрагы эт колагы кебек булып үсә торган үлән орлыклары сипте. Менә берзаман яз кояшы, җир өстендәге ак карны күккә күчереп, ак болытлар итеп таратты. Табигать биләмәләрендә чын-чынлап яз исе таралгач, теге үсентеләр борын да төртеп чыктылар, тамыр җибәреп, баш калкыттылар. Тик ни гаҗәп һәм ни хәл ди әле бу: Җәмилә апаның бакчасында «эт колагы» урынына янә редиска тишелеп чыкты, Сәлимә түти җирендә теге «эт колагы» үсеп ята иде... Әүвәл бик аптыраштылар, бик гаҗәпләнделәр, шаккатуларының чиге-чамасы булмады. Шулай булмый ни: редиска урынына башка үлән үсеп чыксын әле! Ирләр әлеге табышмакны шундук үз файдаларына чишеп тә куйдылар: тел бистәсе хатыннары, сүз белән мавыгып китеп, орлыкларны бутаганнар! Һәм шуңа күрә җавапны да алар тотарга тиеш! Бетте-китте, вәссаләм! Чү, чү! Туктагыз әле, ашыкмагыз әле сез, ир-ат дигән адәмнәр!.. Алайса, нигә югары урамдагы Кадрия апагыз бакчасында, әзерләп куеп та берни чәчелмәгән җирендә, авылга орлыгын быел беренче мәртәбә Галләмнең төпчек кызы Зәринә алып кайткан «эт колагы» борынын төртеп чыккан соң?! Тагын да соңрак, май ахырларында, яңа урамдагы Әлфия апа бакчасында, бөтнек чәчә торып, мәче борчагы басып алган?! Хәер, нигә берәмтекләп санап торырга соң! Байтимердә быелгы язда янбакчалардагы бар үсемлекләр дә буталышып бетте ләбаса! Ни хәл бу? Нәрсә соң бу, шайтан алгыры!

...Халык шулай кан катып, шаккатып һәм аптырашып яткан бер мәлдә сәер мәсьәләнең серен тимерче телсез Габдерәхим эһ тә итмичә, җиңел генә чиште куйды: каргалар гаепле!!! Әйе, әйе, чынлап та, бу адәм ышанмаслык хәлләргә кара каргалар гаепле!..

— Как так каргалар гаепле әле?! — дип, каршы төште шундук Сәмигулла.

— Быть не может! — дип кырт кисте фермер Сибгатуллин.

— Ике күзем чыкса чыксын — гомер ышанасым юк!!! — диде Галләм абзыйның хатыны Җәмилә түти. Бер күзенә моннан ун ел элек үк ак төшкән иде инде аның, ләкин барыбер нинди дә булса да мәсьәләгә катгый каршы чыгып, мөһер сугасы булса, ул гел шулай ди: «Ике күзем чыкса чыксын», янәмәсе...

— Пантазия бу ниндидер! — дип куйды үз гомерендә бернинди җен-пәригә ышанмый торган Галләм агай.

— Нинди пантазия булсын. Күзең чыкканмы әллә?! Чын бит инде, чын! — дип, Әлфия апа Галләм агайның изүеннән үк эләктереп алмакчы иде. Эләктерә дә иде, әгәр телсез Габдерәхим, урамга чыгып басып:

— Яффаймайлар! — дип «аваз» салмаса. «Яффаймайлар» дип, әлбәттә, авызын тутырып яки кешегә аңлашырлык итеп әйтә алмый инде ул. Бары тик шул мәгънәне аңлаткан ымлыклар гына чыгара һәм халык аның авызыннан нинди сүз тәгәрәп төшкәнен тәрҗемә-аңлатмасыз да чамалап ала. Габдерәхим тиктомалдан гына сүгенмәс, ул шулай урысчалатып җиффәрергә мәҗбүр булган икән, димәк, аңа ышанырга кирәк. Һәм бөтен кеше ышана... Салих абзыйдан кала, әлбәттә. Ә Салих абзый исә, үз чиратында, авылда Габдерәхимгә каршы килә ала торган бердәнбер кеше. Хәтта Габдерәхим хак булса да, ул аны җөпләп сүз әйтмәячәк, чөнки алар арасында бу авылда үзенә бер аерым мөнәсәбәт: моннан шактый гомерләр элек телсез Габдерәхимнең башсыз малае Габдулла, халык телендә Сары Абдул, солдатка китәсе язгы матур кичне Салих абзыйның чәчәк кебек кызын, әүвәл клуб уртасына алып чыгып, бар кеше алдында кочаклап суырып үпкән, аннары: «Мин армиягә киткәч, Батай малаена кияүгә чыкмыйсыңмы? Халык алдында ант эч!» — дип, ике кулы белән Саниянең озын толымнарыннан җыеп тоткан килеш ант иттергән. Монысы гына вак-төяк, Абдулы Чечняга китеп баргач, имеш, телсез Габдерәхим авыл буенча хәбәр таратып, сөйләп йөргән ди икән, ди: «Вәт малай булган егет икән минем, тәки Салих кызын үзенә ярәштереп киткән бит, чукынчык!» Әйе, әйе, сөйләп йөргән, дип сөйлиләр. Габдерәхимнең телсез булуын да онытып...

Күптән булган хәлләр инде болар, ләкин авыл өчен кичә генә шикелле. Авыл теленә бер керсәң, шулай инде ул. Югыйсә механик Батай — Бәхтияр малае — Сары Абдулдан соң үзе дә солдатка каралып, Чечня җирендә башын салды. Сары Абдул, армиясеннән хезмәт итеп кайткач, икенче хатынын да аерып, мари авылындагы Үзәкәй кызына өйләнергә өлгергән иде.

— Яффаймайлар! — дип «кабатлады» телсез тимерче һәм авыл халкы аңлаган хәрәкәтләр белән эшнең серен аңлатып бирде: каргалар... кара каргалар... шул кошлар гаепле икән бу эшкә!..

— Как так?! — дип аптырады Сәмигулла. — Каргаларның гаебе юк монда!

— Шыттыра Габдери! — диде Салих.

— Алайса, кем? — диде Галләм абзый һәм такта яручыга, белмәгән башың белән сөйләнеп тормале, буржуй, дигәндәй, каш астыннан сөзеп карап куйды.

— Кит, әкәмәт! Шул телсезгә ышанып торган буласызмы тагын!

Бу сүзләргә ачуы килгән Габдери ни ара Салихның каршысына килеп басты, ни ара якасыннан эләктереп алды һәм, «Ааа-ууу-иии» дигән әллә нинди куркыныч ымлыклар чыгара-чыгара, аны Галләмнәрнең капка баганасына сөяп куйды. Хатыны Сәлимә, арага кереп, телсезне читкә болгап атмаган булса, кул-күкрәкләрендә аю көчләре булган Габдери Салихның бер-ике кабыргасын саный иде югыйсә. Ләкин Сәлимә түти аннан да гайрәтлерәк булып чыкты — телсез юл тузанына барып кадалды. Байтимердә моңарчы бер-берсенә кул күтәргән ир-ат юк, үзара дустанә яшәделәр. Ләкин соңгы берничә елда авыл бөтенләй кире якка үзгәрде дә куйды. Әмма монысына инде кара каргаларның һич кенә дә гаепләре юк, мондый ызгыш-бозылыш вакытында кул күтәрү маһирлыгына ир-ат «кайтканнардан» өйрәнде. «Кайтканнар» дип Байтимердә ата-аналары кайчандыр монда туып үскән, ә балалары авылда яшәргә кайткан буй җиткән егет-җиләнне атыйлар. Аларның беришесе наркоман яки алкаш, һәммәсе дә диярлек нинди дә булса вак-төякме, әллә тагын да зурракмы җинаять өчен утырып та чыккан. Ата-ана, шәһәрдә азып-тузып йөргән багалмаларын, болгавыр шәһәр тормышыннан аерып, кеше-кара күзеннән ераграк тәрбия кылу максатларында үзенең элек туып үскән авылына озатырга тырыша. Моның өчен дистә еллар буе кешесез тора-тора тез чүгә башлаган каралты-куралар сипләнә, яңартыла, кыскасы, яшәрлек хәлгә китерелә.

Байтимердә икенче катлам да бар, алары да — әрәмтамаклар. Алары «кайтканнар»дан шушы авылда туып үсүләре белән генә аерылып тора. Хәтта күбесе Байтимер кызына өйләнеп, колхозда төпләнеп калырга уйлаган кешеләр, аларны бөек төзелеш кенә үзенә суырып алган, төп яшәеш урыннары Чаллы һәм Алабуга тирәсендә. Җитмешенче елларда Барый белән Мөхәммәт, әле буй үстереп килгән чакларда, Байтимернең бер төркем ирләрен җыеп, колхоз аша «КамАЗ» төзелешенә җибәрделәр. Әлбәттә, вакытлыча гына. Бала-чагасы ишле булганы, авылларын, гаиләләрен сагынып, ярты ел буе кайтып-китеп йөргәннән соң, Чаллыга башка бармады. Яшьрәк ирләр исә шунда төпләнеп калдылар, аларга Чаллыдан фатирлар да эләгеп, тәмам шәһәр кешеләренә әйләнеп беттеләр, шунда туган балалары исә Байтимергә җәйге каникуллар вакытында гына кайткалап торалар. Советлар илен Америка яһүдләре «агач мылтык» белән юкка чыгаргач, Рәсәйдә эшсезлек башланды. Эшчеләр өчәр, дүртәр айга түләүсез ялга җибәрелделәр. Менә шул «отпускниклар» басып алды авылны. Чөнки ашарга кирәк, эш булмагач, завод туктальп торгач, боларның кесә төпләре тишелеп бетте. Ә авылда, бигрәк тә туган авылда туенырга була әле. Күбесенең карт ата-аналары да туган авылда яши иде бит. Чөнки алар теге чакларда шәһәр фатирларына сыймадылар, кайсысы килене белән килешә алмады, кайсыберләрен Байтимергә холыксыз кияү балакайлар кире куып кайтарды. Югыйсә аларның күбесе авылдагы өйләрен сатып киттеләр бит. Өй саткан акчалар шәһәр тормышына ияләшә башлаган киленнәрнең лифчик эчләренә сыеп бетте. Андый язмышка дучар булган карт-коры, туган-кардәшләре ярдәме илә көч-хәл белән туган Байтимердә иске, ташландык йортларны сатып ала алдылар. Нәкъ менә шуңа күрә дә аларның бу йортлары җиргә чүккән иде. Иң бәхетле дигәннәре иске йортларны үзләре элек сатып киткән һәм нигезеннән башлап үз хәләл көчләре белән җир тырмашып салган шыгырдап торган каралты-куралы өйләрнең күршесеннән үк туры китерә алдылар. Әмма аларны торгызырга пенсия акчалары гына җитми, ә киленнәрнең ими чүпрәкләре бу вакытта табигать биргән байлыкларын гына кысып-җыеп тора иде инде... Ләкин картлар моңа да бик канәгать булдылар, үз туган җирләренә кайтып егылдылар бит, бахырлар... Шөкер, пенсияләре дә килеп тора. Һәм ул такы-токы акчалар Чаллы якларыннан өчәр айга түләүсез ял алып кайткан сакаллы балаларын туйдырырга да җитми үк түгел иде әле.

Рәсәй илендәге язмышлар диген... Адәм баласына нинди генә газаплар күрсәтмәде ул. Нигә һаман мантый алмый соң бу ил?! Гасырлар буена хәерчелектә яшәп буламыни икәнни ул?

Моның нинди дә булса сәбәбе булырга тиеш ич инде канә? Мөгаен, бу сәбәп милли холыкта яшеренеп ята торгандыр әле?.. Югыйсә болай булмаска тиеш бит.

Авыл теле белән әйтсәк, әрәмтамаклар катламын тәшкил итүчеләр Байтимердә менә шулар.

Алар кайткач, авылда бурлык башланды, яшелчә бакчалары басылды, буразналардан бәрәңгеләр казылып алынды, кетәклектән югалган тавык-чебеш турында әйткән дә юк инде, хәтта казлар саны кимеде, авыл халкы бозауларын арканга бәйләргә курыкты. Менә шуннан соң ызгыш-талаш китте, кайвакыт, каракны кулыннан тоткан чакларда, мөнәсәбәтләр кул сугышлары белән төгәлләнә торган иде. Ләкин ничек кенә булса да, эшләр беркайчан да судларга кадәр барып җитмәде. Ни әйтсәң дә, алар, беренче чиратта, авылдашлар бит әле. Тик менә шуннан соң бер-беренә кул күтәрергә, бер-берсенең борынын канатырга гадәтләнеп калдылар бит тәки. Гомердә булмаганны...

Байтимер чаклы зур хуҗалыклы авыл бөтен Рәсәенә берәү генәдер әле: анда биш меңнән артык кеше яши, заманында бер Байтимернең үзендә генә дә җиде мәхәллә, җиде мәчет булган! Шуңа күрә «кайтканнар» гына зур авылның төп тормыш көен әллә ни үзгәртә алмадылар, чөнки аның борынгыдан килгән гореф-гадәтләре нык тамырланган иде. Ә караклар өчен халык усал этләр тота башлады, хәтта бер ишегалдында икешәрне!.. Шуңа күрә төнге авылда безнең Пиратка бер дә күңелсез түгел хәзер.

...Сүз белән мавыгып, Габдеринең юкка чыкканын да абайламый калганнар иде, менә ул җыелып торган халыкның аяк астына каяндыр ике кара карга үләксәсе алып килеп атты. Каргаларның ачык авызларыннан орлыклар коелды. Бакчадан бакчага йөреп, орлыкларны буаштырып йөрүчеләр тәгаен шулар икән!

— Яффаймайлар! — диде Габдери һәм, бая үзен тузанга төртеп егуларына үпкәләп, тимерче алачыгына таба китеп барды.

...Пират аеруча авылдагы иң усал этне, Сәмигулла шәһәр базарыннан зур акчалар түләп алып кайткан зәһәр Барсны үз итте. Аларның беренче очрашулары урманда булды. Хуҗа алып кайтып бәйләгән көннең икенчесендә үк Барс, тимер чылбырын өзеп, урманга качты, чөнки аның тамырларында ирек, бәйсезлек каны шаулап ага, ул бүре баласы иде. Дөресрәге, әнкә эт белән кушылдырылган бүре малае. Ул төнне алар Пират белән урман-кырларда йөреп кинәнделәр, икесенә бер куян да тотып ашадылар әле. Сәмигулла аны икенче көнне кичен генә табып алып кайтты һәм бу юлы чылбырның ныгын әзерләп куйган иде. Ләкин чылбыр белән генә котылып булмаячагын аңлады хуҗа кеше һәм аны төрле юллар белән үз йортына, хуҗасына ияләндерергә кереште. Ә моның исә бер генә юлы бар, ул да булса, тәмле тел, тәмле ризык. Хәер, бүре баласын моның белән генә дә үзеңә тугрылыклы итү шактый четерекле булып чыкты. Эңгер-меңгер төшүгә, янә тынычсызлана башлады, урманга карап улый-улый өрде, мәсбүх. Үзсүзле, киребеткән Сәмигулланы алай гына җиңеп булмаячагын чамалап бетерми әле ул: хуҗа үзенә йокы урынын ат арбасы өстенә әзерләде. Арбаны эт оясы янына ук китереп куйды. Менә кичне төн алыштырды, Барс торган саен тынычсызлана, вакыт-вакыт урман ягына карап елый, өреп тә куйгалый. Андый чакларда, Сәмигулла, сикереп торып, эте янына килде, башын тез өстенә куеп иркәләде, сыйпады, муен асларын кытыклады, алдан ук әзерләп куйган ит калҗасын каптырды. Хуҗа белән эт өч көн рәттән төнне шулай уздырдылар. Дүртенче көн дигәндә хатыны Рәзифә түзмәде, өйдә кара тавыш чыгарды: «Син миннән бездең! Сиңа мин кирәк түгел! Сиңа эт кирәк! Алай булгачтын, әнкә эт алып кайтырга иде!» — дип ярсыды хатын. Гомерен, инде өйләнеп, бала-чагасы булса да, Рәзифәнең мәхәббәтен яуларга багышлаган Сәмигулла, әлбәттә, сөеклесенә каршы тора алмады. Бүгенгәчә куркып яши Сәмигулла, Рәзифәдән дә курка. Мөхәммәттән дә курка, Рәзифәне ярата, Мөхәммәтне күралмый. Рәзифәне үзеннән тартып алыр дип уйлый. Тикмәгә генә шушы гомергәчә өйләнмичә йөрми торгандыр дип шикләнә. Шул хәерсез шик һаман котыртып тора. Кыргый этне дә, бүре баласын да кулга ияләштереп була, ләкин хатын-кызның мәхәббәтен яулау, ай-һай!.. Моның нинди кыен гамәл икәнлеген Сәмигулладан гына сорыйсы бар! Әлбәттә, хатынын үзе шулчаклы үлеп яратмаса, алай йөрмәс иде, ир-ат горурлыгын йөгәнләп тормас иде. Шашып ярата шул, нишләтәсең... Тырыша торгач, максатына ирешмәде түгел ич инде — әнә Рәзифә хәзер ансыз йоклый да алмый... Димәк... Бирсен Ходай?..

Ләкин Сәмигулла барыбер чүпрәккә әйләнеп бетмәгән әле, «итәк астыннан» вакыт-вакыт башын чыгаргалап алгалый. Бу юлы әлеге гамәле аның өчен бик уңай булды: кичтән уртак ястыкка башын төрткән булса да, барыбер сәгать саен диярлек ишегалдына чыгып, эте янына килде, калҗа каптырып, башын сыйпап кереп китте; ашарга биргән саен, этләрнең башына сугып торасы юк, алар мәче түгел. Теге дөньяда алардан сорарлар, ди: «Хуҗаң ашаттымы», — дип. Мәче: «Юк, ашатмады!» — дип ялганлар, ди. Этләр һәрвакыт: «Әйе, хуҗам яхшы ашат-

ты», — дип торырлар, ди. Шуңа күрә, ашарына биргән саен, мәченең башына сугып куярга кирәк. Ахирәттә әгәр: «Юк, хуҗам ашатмады», — дип алдаса, аңа әйтерләр, ди: «Син ялганлыйсың бит. Әнә башыңда кара тап бар, ашарыңа биргән саен, хуҗаң синең башыңа сугып куйган булган, шуның эзе бит ул!» — диярләр, ди.

Барс та акрынлап хуҗасына ияләнә-күнегә башлады. Тик бүре баласын бүреккә салсаң да... Дүртенче төнне, Барс, дустын сагынып, капка астына Пират килеп башын тыгуга, ул янә чылбырын өзәргә талпынып карады, әгәр Сәмигулла вакытында чыгып күреп алмаган булса — өзәчәк һәм тагын Пират белән бергә урманга качачак иде. Бу юлы хуҗа кеше уяурак булып чыкты, этнең шыңшуын ишетүгә, урамга атылып чыкты һәм капка төбеннән качып бара торган бер ят этне күреп алды. Тәгаен генә чамалап бетерә алмады, бүрегә дә охшатты ул аны... Һәм танып та алды! Бу... теге — Пират дигән бүре кавемле Барый Әкбәров эте бит!.. Әкбәров ничә айлар буе эзли инде аны, Сәмигулла яхшы белә: ишегалдына алып кайтып бәйләр өчен түгел, әлбәттә — атып үтерер өчен!.. Пират Әкбәровның төн йокыларын качырган һәм саташтырып, аны җүләргә салыштыра язып, хастаханәләргә керткән җан иясе бит инде. Авыл күзеннән берниндидә яшерен эш юк Байтимердә... Әйе, этләрнең башына сугып торасы юк — алар барын да яхшы хәтерли. Инде ничәмә-ничә еллар узса да, ялгыз башы урман-кырларда каңгырап йөрсә дә, ул Әкбәровны эзәрлекли, тегесе исә аны атып үтерергә хыяллана. Шулчак Сәмигулланың башына бер уй килде. Әйбәт, яхшы уй! Әкбәровтан үч алырга менә дигән җай чыгып тора, шайтан алгыры!..

Үч алу — күңелдәге давылны тынычландыруның бердәнбер кулай юлы. Мөхәммәтне дә Әкбәров кенә котырта, ул әүвәл аның гаиләсен, аннан соң үзен юкка чыгарырга уйлый. Ничәмә-ничә еллар Сәмигулла күңелендә әнә шундый авыр хис асрый, бик теләсә дә, ул аннан котыла алмаячак — акылына буйсынмый торган бер хәерсез хис ул... Гыйшык акыллы хатынны акыллы итсә, акыллы ирне акылсыз итә, дип, юкка гына әйтмиләр. Сәмигулланың акылын югалтуының тагын да бер сәбәбе бар, ул да булса, организмында барган химик реакция! Әйе, әйе. Нәкъ менә шул химик реакция организмда серотин дигән матдә бүлеп чыгара — ул кешедәге җенси гармоннар өчен җавап бирә. Мари урманында исеме дә билгесез булган сәер агач үсә, аның исе бик тәмле, шул иснең молекулаларында серотин элементларының химик формуласы бар. Кеше организмына килеп эләккәч, ул беркавым вакыттан соң серотин бүлеп чыгара башлый.

Бу исемсез агач күрмәгәнен күрсәтте инде Байтимер халкына. Урманга җиләккә дип барган кыз-кыркын очраклы рәвештә шул агач янына килеп чыкса, алар ни кыланганнарын белми башлыйлар, урманнан кайтышлый Илләттә балык тоткан мари малайларына үзләре килеп бәйләнәләр. Юкка гына Байтимер кешеләре кытайлар кебек үрчеп биш меңгә җитмәгәндер инде!..

Безнең такта яручы Сәмигулла урманга еш йөргәнлектән, аның ашказанындагы химик реакция бер дә тукталып тормый. Ул моны хатыны Рәзифәгә мәхәббәтенең көчле булуы белән аңлата. Ә мәхәббәт белән көнчелек исә бер юрган астында йоклыйлар...

## Тыныч күлдә җеннәр үрчи

Дөнья — куләсә... Монголлар урыс җирләрен яулап алдылар. Көрәш каты булды. Ләкин чиркәүләр үз урыннарында калды, аларга тимәделәр. Ханның әмере шундый булды. Шуннан соң урыслар гасырлар буенча җиңүчеләргә ясак түләп торырга тиеш булдылар.

Дөнья — куләсә...

...Үлгән һәм яраланган кешеләр сансыз: Казансу елгасыннан урманга чаклы булган болынлык, шулай ук урман кырыендагы һәм эчендәге аланнар барысы да татар үлекләре белән тулган иде. Шәһәрнең эче белән тирәсе бигрәк тә куркынычлы булып, аның һәрбер урамнары үлекләр белән тулган, йөрүчеләр үлекләр өстеннән йөриләр иде. Хан йорты артындагы чокырлар, Казансу елгасы буе, болынлык — барысы да татар үлекләре белән тулып, кайсыбер урыннарда өем-өем яталар иде... Иван татарларның хатын-кыз һәм яшь балаларын тере калдырырга боерып, эшкә яраклы ирләрнең барчасын үтерергә боерды...

...Этләргә һәм татарларга керү катгый тыела!..

Дөнья — куләсә...

...Хазарлар башлыгы яһүди Песах урысларны тар-мар итте... Карт Игорьның гыйффәтле хатыны Ольганы кулга төшерде. Шуннан бирле урыс князьләренең каны буталды...

Дөнья — куләсә...

...Петлюра казаклары яһүдиләрне шәп-шәрә калдырып чишендерделәр, кулларыннан бәйләп түшәмгә астылар һәм аяк очларына учаклар яктылар. Бер карт яһүднең сакалын кисеп алып үзенә ашарга мәҗбүр иттеләр, шуннан соң рәхәтләнеп көлә-көлә аны тураклап ташладылар. Кал-

ганнарның кулларын, аякларын кистеләр, иреннәрен кисеп алдылар, күзләрен чокып чыгардылар, көмәнле хатыннарның корсакларын ярдылар. Качып китүчеләрне мылтыклардан, пулеметлардан кырдылар...

Дөнья — күләсә, бер әйләнә, бер баса...

...Мин — Израэль Исаевич Воронов, туган җирем Советлар иле, гражданлыгымның икенчесе — Израильдә. Үзем Казанда эшлим, яшәвем Казан артындагы яһүдиләр бистәсендә.

Мин Израильдәге «Натив» дип аталган разведка хезмәте мониторы. Гадирәк итеп әйткәндә, агент, шпион дисәң дә була. Юк, юк, шпион ук түгелдер. Болай дип атау үземә дә көлке тоела. Мин бары тик мәгълүмат җыючы гына. Әлеге мәгълүматларым бүгенгесе көндә Израиль разведхезмәтенә кирәк булса, киләчәктә ул минем фәнни эшемнең төп темасы.

Мине татарлар кызыксындыра. Аларның тарихи язмышлары яһүдләр язмышы кебек. Шулай ук алар да бөтен дөнья буйлап сибелгәннәр. Шунысы кызык: Рәсәйдә һәм Казан тирәсендә яшәгәннәре милли гореф-гадәтләрен, телләрен акрынлап югалтып баралар, ә чит илләрдә гомер кичерүчеләре туган телләрен яхшы белә, милли йөзләре дә күбрәк сакланган.

«Миңа ышаныгыз, халык картаймый һәм акыллыланмый, халык һәрвакыт бала булып кала», — дигән Гете. Бөек сүзләр. Шуңа күрә миңа бу халыкның үткәне дә, бүгенгесе дә бик кызыклы.

Дустым Барый Әкбәров бу тирәләрнең хуҗасы, бәләкәй генә булса да «власть» кешесе. Ул властьның тәмен белә торган егет. Хәер, хакимлек хисе адәм баласындагы иң көчле хис ул, хәтта мәхәббәт хисеннән дә өстенрәк тора. Барыйны өнәп бетермиләр, ләкин куркалар. Әйе, хаким белән халык арасындагы каршылык адәм баласының табигатенә үк салынган инде. Һәр җан иясе үзен башкалардан өстенрәк дип уйлый һәм тормыш рәхәтлекләре аңа күбрәк булырга тиеш дип исәпли. Кешелек яралганнан бирле иң яхшы җәнлек тиреләре, иң тәмле-том, иң гүзәл хатыннар көчлеләрнеке булган, ягъни тәхеттәгеләрнеке.

Һәр кеше дә беренче булырга һәм иң яхшысын гына үзенеке итәргә тели. Ләкин без шулай булуга карамастан, аерым гына тормыш итә алмыйбыз, безгә башка кешеләр белән бергә яшәү кирәк. Димәк, арадан кемдер берәү лидер булырга тиеш. Мәсәлән, бер урында биш-алты дистә кеше җыела икән, шулар арасыннан, һичшиксез, берәвен башлык, хаким итеп сайлап куярга кирәк, югыйсә мин көчлерәк, мин әйбәтрәк, дип талаша-талаша, алар бер-берсен кырып бетерәчәкләр.

Ләкин һәр кешегә дә хаким булу сәләте бирелмәгән. Бу талант адәм баласына Ходай тарафыннан иңдерелә!..

«Татарларның тарихы гаҗәеп гыйбрәтле». Израэль Исаевич үз хезмәтен әнә шундый җөмләдән башлап китәчәк. Чөнки бу аңа, аның милләтенә дә бик якын. Язмыш ягыннан караганда да, тарихи күзлектән чыгып та. Тарихи җепләр дә бер-берсенә килеп урала түгелме соң?! Хазарларның төп өлеше төркиләрдән торган бит. Югары катлавын яһүдләр тәшкил иткән. Алар Киев Русена барганнар, князь Игорьны тезләндергәннәр, аның хатыны Ольга малаеның атасы да... яһүд бит! Һай, бу тарихи бергәлек һәм аерымлыклар...

Татарларны милләт буларак ислам дине саклап калган. Башка милләтләрне үз диннәре. Безнең хәтта уртак пәйгамбәрләребез дә бар: Гайсә, Муса, Якуб һәм башкалар. Без барыбыз да илаһи көч барлыгын таныйбыз, хәтта фән дә, галимнәр дә — акыллыраклары — ул көчне инкарь итәргә кыймый.

«Җирләрдә һәм күкләрдә булган барча мәхлуклар кайберләре ихтыярый вә кайберләре ихтыярсыз Ходайга сәҗдә кылырлар вә иртәләрдә һәм кичләрдә үзләре сәҗдә кылганда күләгәләре дә сәҗдә кылыр».

«...Бар шундый кешеләр — алтын вә көмеш җыеп асрарлар, Аллаһ юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетүче газап булачагы белән хәбәр бир. Җыйган ул алтын-көмешләре кыямәт көнендә җәһәннәм утында кыздырылып, маңгайларына вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз». Пәйгамбәрләр аша кавемнәргә иңдерелгән сөрән бу! Янау, куркыту түгел — Хакыйкатьнең нәкъ үзе...

Атаклы физик, Нобель бүләге иясе Вигнер әле узган гасырда гына математиканың табигый фәннәр өчен нинди зур әһәмияткә ия булганын бары тик илаһи көч барлыгы белән генә аңлатып була, дип, үзе дә шаккатып язды. Ньютон, Платон, Аристотель, Спиноза, Кант, Гегель һәм башка бик күп галимнәр Галәм Раббысының барлыгын инкарь итә алмаганнар...

Мин, Израэль Исаевич, Барый Әкбәровны зур хакыйкатькә күндердем: тау башына ул диннәр храмы салачак! Ул моны үз фикере, әүвәлдән үк үз башына килгән идея дип ышанып йөри.

Ләкин бу орлыкны мин чәчкәнне сизми дә калды, бахыр. Хәерлегә булсын, мин авторлык хокукын дәгъваламыйм. Ислам җирлегендә вахаббитлар үрчемәсен, мин шуннан куркам. Югыйсә минем Израильдәге туганнарым алардан көн дә үлем һәм меңнәрчә төрле зыян күреп тора...

Дин кануннарын җанны коткару өчен табиб тәкъдим иткән дару кебек чәйнәп нитеп тормыйча тоташ кабул итү зарурдыр...

Тигезлек, Туганлык, Ирек! Менә безнең максат нидән гыйбарәт!..

## Вәлиев Сибгат, аның кызы һәм җимеш сатучы кияү

Капкасын Барый Әкбәров дөбердәткәндә, Сибгат абыең җиденче төшен күрә иде инде. Капка тавышына иң әүвәл хатыны Сәнифә уянды. Һәрхәлдә, Сәнифә үзе шулай дип уйлады. Чынлыкта исә кызлары Сәлимә бу вакытта күзен дә йоммаган иде — үзе йоклаган бүлмәнең тәрәзәсен Нури килеп шакыр дип өметләнеп ята иде ул җиде төн уртасында. Юеш май җиле төнне тагын да суытуга карамастан, Сәнифә эчке күлмәктән генә өйалдына атылып чыкты һәм әче тавышы белән:

— Кем бар анда? — дип сорады. Үзе бер кулы белән өйалды ишегенең тоткасына чатырдап ябышты, теге нәмәрсә, ягъни азәрбайҗан кияү булса, бар ишегалдына кара тавыш чыгарып, ире Сибгатне уяту иде. Хатын җәһәт кенә өйалды почмагында сөялеп торган сәнәккә карап алды, салкын корал урынында тора. Кызганыч, Казаннан алып кайткан усал этләрен кемдер агулап китте.

Тавышының әчелеге аның үзенә дә ошады, тик урам яктагы кешенең колхоз рәисе икәнлеген белгәннән соң, әлеге әче тавышка мизгел эчендә нидер булды — ул чишмә челтерәвенә охшап калды:

— Хәзер, Барый Хаҗиевич, хәзер ачам.

Хатын инстинкт белән өстендә юка эчке күлмәк икәнлеген тоеп, әүвәл тиз генә иңенә халатын салып чыгарга уйлаган иде, ләкин өйгә кире кереп йөрү хуҗа кешене көттерү була дигән фикер белән Сибгатнең бусага төбендә торган кырык бишенче үлчәмле галошларын эләктерде дә лаштор-лоштыр капкага таба китте. Хатынны бастырыкка чаклы: «Барый Хаҗиевич мине эзләп килгәндер, бозауларның ач калганлыгын ишеткәндер дә... Миңа склад ачкычын алып килүедер, бригадир итеп куймакчы була торгандыр мине. Кәримәне төн уртасында эшеннән чыгарып ыргыткандыр да... Ну тәвәккәл кеше инде безнең председатель!» — дигән тәмле уйлар озата барды.

— Сибгаткә әйттем бит мин, капкаңны бикләми тор, дидем! — Авыл хуҗасының тавышы чак кына ачулы. Башка чак булса, Сәнифә апаң үзенең бозау ирен председательдән күбрәк һәм аяусызрак сүктерер иде, ләкин бүген ул гаепнең үзендә икәнлеген танмыйча булдыра алмады, исәбе хуҗа кешегә йортларына бәла килгәнлеген дә сиздерәсе килү бугай.

— Теге җимеш сатучы тәмам үзәккә үтте бит, имансыз! Көн-төн тынгылык бирми, килмешәк!

Барыйның: «Нинди килмешәк ул тагы?» — дип, авыз ачуы булды, кызы Сәлимәнең базарда җимеш сатучы кавказлы белән чуалып китеп, качып шуңа кияүгә чыгарга йөрүен сөйләргә әзерләнгән хатын, Сибгатнең зур галошларына сөртенеп тә китте һәм, Барыйга таба авып, колхоз хуҗасын дәү имиләре белән капка баганасына терәп куйды. Җитмәсә, бер имие пылт итеп эчке күлмәк изүеннән атылып, һава суларга да чыгып өлгерде һәм, егылмыйм дип, аз гына чүгәләгән Барыйның нәкъ борын тирәсенә туры килде. Кайнар иде хатынның тәне, дымлы май җиле белән генә суынып өлгермәгән иде әле.

Сәнифә Барыйның Һади абыйсы белән яшьтәш, ун ел буе бер сыйныфта укыдылар. Һадинең сыйныфташ кызлары, мәктәптә укыганда, үзләреннән шактый яшьрәк Барыйны: «Минем киявем буласыңмы!» — дип шаяртып, теңкәләренә тияләр, алай гына да түгел, юлларында туры килсә, бәләкәй буйлы малайны тотып алып суырып үбәргә дә күп сорап тормыйлар һәм, шул рәвешле аны тәмам оялтып бетерәләр иде. Менә... Әллә ничә еллардан соң «кияү» булып алырга да язганмы соң?.. Барый, теге чактагы шаяртуларны исенә төшереп, учы белән Сәнифәнең кайнар имиенә орынды. Тегесе, шаяргандай булып, Барыйның күкрәгенә ике кулын терәде дә аны читкә этәргәндәй итте. Итсә дә итте, итәсе килмәсә дә итте: өйдә «бозау» булса да ире бар ич!..

— Сибгат кайда?

Барый җитди кыяфәт алып өлгергән иде.

— Соң... бу вакытта? Кайда булсын инде, йоклый.

Сәнифә аның бу соравына иренеп кенә җавап бирде, чөнки Барыйны Сибгат янына түгел, үзе янына, аңа җиде төн уртасында амбар ачкычларын тоттырып, мөдир итәргә килүе дип өметләнгән иде ләбаса. Элеккеге «складчица»ны эштән алып, бүген бозауларны ач калдырганы өчен. Малларга он үлчәп бирүче тол Кәримә кичтән исерек килеш амбарга кереп йоклаган. Юк, аңа Сибгат кирәк булып чыкты бит әле. «Каравыл тавында берәр машинасы батып калгандыр да Сибгаттән тракторын кабыздыртырга исәплиләрдер... Хәер, колхоз маллары кайгысымы соң боларда!..» — дип, тагын да иренебрәк фикер йөртеп алды Сәнифә.

Вәлиев Сибгат Барыйның иң алдынгы, иң булган механизаторларыннан берсе. Барый аның янына юкка гына килмәде. Кешеләр янына төнлә йөри ул хәзер. Чөнки чәчүләр тәмамланганнан соң тау башына күчү хакында хәлиткеч соңгы җыелышларның берсе буласы.

— Сибгат абзый, — диде ул әле һаман уянып җитә алмаган хуҗага: — Сиңа җирне мәчет яныннан ук бирергә булдым... Тау башында дим. Анда урыны да тигезрәк.

— Мәчет яныннан? — Сибгат капылт уянып китте. — Нәрсә, үзбәк кияүгә мәчеткә йөрергә якынрак булыр дисеңме?! Син дә мыскыл итәргә уйладыңмы инде, Барый туган, ә?!

Аның бу сүзләреннән Барый югалып калды, ни дип җавап кайтарырга да белмәде, чөнки ул мәсьәләне белеп бетерми иде әле.

— Ишеткәнсеңдер инде, минем кыз, олы кыз Сәлимә, базардагы җимеш сатучы үзбәк белән чуала башлаган. Капканы да шуңа күрә кичтән бикләп куям хәзер, — дип, әлеге хәлгә Сибгат үзе ачыклык кертте, әйе шул: председатель ишетеп тә бетермәскә мөмкин бит. Ә ишетсә, ярдәм итүе бар, бик бар. Уен түгел, Сибгат абзаң аның карап торган механизаторы да. —Кудырт шул үзбәкне Казаннан, Барый, ә?! Этне дә шул мәлгунь гына агулап китте бит, ә?..

Ул ялварулы күзләрен авыл хуҗасына төбәде.

— Һем... мәчет янындагы урынга ризамы соң син?

— Риза, риза, кудырт кына, чокырлы, ташлы җир булса да риза.

Алар кул сугыштылар.

— Борчылма, Казан — Ташкент поезды йөреп тора бит әле.

Кызганыч ки, бу сөйләшүне җимеш сатучы үзе ишетмәде, әгәр ишетеп калса, чатыр чабып, вокзалга атылган булыр иде, бахыр...

Чынлыкта, Сәлимәнең башын әйләндерүче үзбәк кешесе түгел, азәрбайҗанлы Нури иде. Нури да, башка кардәшләре кебек, озын акча эшләргә Казанга килгән адәм. Бүтәннәр, аңа чаклы килгәннәр, кайсы кая йортка кереп, ялгыз татар хатыннарына өйләнеп, урнашып беткәннәр, андый уй белән шәһәрдә һич тә баш тыгарлык түгел. Нури аптырап калмады, шәһәргә ерак булмаган авылдан үзенә «яр» эзләргә кереште һәм бер дә бер көнне аңа да бәхет кояшы елмайган шикелле булды: ул Байтимер кызы Сәлимә белән танышты. Сәлимәгә өйләнеп алса, — югыйсә Нуриның Сумгаитта хатыны, өч баласы бар, — эшләре тагын да көйләнеп китәчәк. Беренчедән, авыл шәһәр түгел, монда, кияү булган очракта, әлбәттә, тонналап җимеш саклап була, икенчедән, теркәлү кайгысы бетәчәк бит. Шул рәвешле ике-өч ел уңышлы гына сәүдә итә алса, аннары ул, барысын да ташлап, беренче чиратта Сәлимәне, Сумгаиты ягына карап, койрыгын сыртка салачак, кыскасы, моннан кыяклаячак, төзелә башлаган нигезенә ике катлы йорт күтәрәчәк һәм үз хатыны Зөллә белән рәхәтләнеп гомер кичерәчәк иде.

«Сәлимә, Сәлимә», — дип уйлап куйды Барый, Сибгатләр капкасыннан чыккач. Чү! Туктале!.. Аның язмышында Барыйның да катнашы бар түгелме соң?.. Әйе шул, теге чакта шабашник әрмәннәргә аш пешерергә куйдыртты бит ул аны. Көчләп диярлек. Үгетли-үгетли. Ата-анасы белән сөйләште сөйләшүен... Ул чакта бәләкәй генә «Т-25» тракторында эшләп йөргән Сибгатне зур тракторга утыртты, Сәнифәгә амбар ачкычларын вәгъдә итте. Сибгатнең әни карчыгы гүр иясе булган вакытлар. Кечкенә трактор белән генә дүрт баланы аякка бастырырлык акча эшләп булмый, әни карчык китеп баргач, бердәнбер карап торган акча чыганагы — пенсия дә килүдән туктады. Авылдагы күз карасыдай медпункт та ябылган, шәфкать туташы һөнәренә укыган Сәнифә дә эшсез калды. Дөресрәге, Сәнифә эшсез калмады, ә акчасыз калды. Авыл халкы табиб ярдәменә кая барсын — һәммәсе дә Сәнифәнең капкасын шакырга мәҗбүр. Сибгат әүвәл моңа каршы торды. Шуннан соң авылдагы карчыклар кан басымын үлчәтергә дә райүзәккә — кече Филига йөрергә тиешләр иде. Шул рәвешле юлда ике карчык, хастаханәгә барып җитә алмыйча җан тәслим дә кылдылар. Ирләрен сугышта югалткан хезмәт, тыл ветераннары... Картлык көннәрендә алар хөкүмәткә артык кашык булып чыктылар. Шуннан бирле Сәнифәләрнең йорты медпунктка әверелеп китте, күрә торып авылдашларның юк кына чирдән дә кырылганын карап торып булмый бит инде. Ә теге карчыкларның чак кына уйнап алган кан басымнарын көйләү өчен берәр укол гына кирәк булган икән югыйсә!..

Шабашник әрмәннәр — алар колхозда бозаулар фермасы салу белән берочтан Казан читендә кече Филидагы бер иптәшкә коттедж да төзиләр иде — пешекче итеп яшь татар кызын таләп иттеләр. Барый аларның теләкләренә каршы килә алмады, әнә шул рәвешле җиләк кебек япьяшь кыз пешекче булып эшли башлады. Югыйсә шул көздә педагогика институтына укырга керәп, хыялы укытучы булу иде. Дөрес, ярты ел уздымы икән, юкмы, Сәлимә Казанга качты качуын. Ләкин бу адымы түгәрәкләнеп килгән корсагын әти-әнисе һәм авылдашлар теленнән яшерү өчен иде. Билен кысып буып йөри торгач, бер дә бер көнне «әрмән калдыгы» тулай торак туалетында агып та китте... Шәһәрдә эшсез интегеп йөргәннән соң, кыз янә әти-әнисе янына кайтып егылды, ләкин ул каратутлы Нури атлы егет белән танышып өлгергән һәм иртәгә үк аңа кияүгә дә чыгарга әзер иде.

Усал этка агуны Сәлимә ашатты...

## Бәрхетгәрәев Галләм һәм аның кызы Зәринә

Тракторчы Галләм капкасын да төнлә шакырга уйлады Барый. Төнлә килеп керү, беренчедән, халыкны каушатып җибәрсә, төнге сөйләшүләр гадәттә үтемле була, аңа берәү дә каршы килми торган иде. Бу инде сыналган алым.

Ни гаҗәп, төн уртасы булуга карамастан, Галләмнең капкасы бастырыкланмаган иде. Барый ишегалдына керде дә, үрелеп, тәрәзәгә чиртте. Лапас ягыннан эт өргән тавыш ишетелде. Тракторчының бозау чаклы бик усал эте барлыгын белә Барый, шуңа күрә җәһәт кенә шул якка күз ташлады, урам баганасындагы лампочка бар ишегалдын яктыртып тора, лапас ишегенең бикле икәнлеген күргәч, тынычланып, янә тәрәзәгә тырнак очы белән тиеп алды ул. Галләм агай үзе чыкты, төнлә борчучының Барый икәнлеген күргәч, аптыраган булды, әмма аның нигә килгәнлеген сизгер карт белә һәм шуңа күрә дә алдан ук кабыргы йоннарын тырпайтты.

— Минем тракторга ут капмагандыр бит, Барый энем. Ут капса да, минем эшем юк, чөнки кичә яшь малай эшләде, мин билемне кузгаттым, сыктаулап торам әле.

— Беләм, Галләм абый, беләм. Мин башка йомыш белән.

Галләм, өйалды утын яндырып, төнге кунакны баскычка утырырга чакырды, үзе тәмәкесен кабызып җибәрде.

— Җә, ни булды?

— Ни дип инде, үзең дә беләсең бит, Галләм абый, шул күченү турында инде, тау башына, дим.

Галләм тәмәкесен тәмләп суырды да яшел күзләре белән Барыйга карап куйды, аннары көлемсерәп:

— Тау башына дисең инде, алайса?

— Әйе... Авыл белән.

— ...Җил белән, давыл белән, килсә килсен, эшербез ил белән, авыл белән дисең инде, алайса?..

— Алай димим бит әле, Галләм абый.

— Димисең, әмма ләкин шулай дип уйлыйсың син, энем.

Зур гәүдәле, көрәк куллы Галләмдә юмор хисе бардыр дип башына да китерми иде Барый, карт шаяртырга да оста икән. Ләкин аның тавышы кинәт җитди төсмер алды.

— Син беләсеңме, энекәш, утыз җидедә минем әтине нәрсә өчен алып киткәннәрен?

— Белмим, Галләм абый.

— Алайса, сиңа авыл тарихын өйрәнергә кирәк, энем, кешеләрнең үткәнен. Әйтим белмәсәң, утыз җидедә синең бабаң, кызыл коммунист Әкбәр агай, тау башындагы Байтимер авылын тау астына күчереп йөргән. Минем әти күчмәгән, каршы килгән. Шуның өчен аны, син халык дошманы, дип, сөргенгә озатканнар. Шул елны мин туып калганмын. Әти кире әйләнеп кайтмады, мин аны бер тапкыр да күргәнем булмады.

— Минем бабай гаепле булмаган бит анда!

— Белмим, дигән буласың, менә үзең дә беләсең икән бит, энем. Ие, синең бабаң гаепле булгандырмы, юктырмы... Эш узгач, әтине яклап караган, чөнки дус булганнар алар, энем. Әкбәр абыйга, авыр туфрагы җиңел булсын, үзеңне дә ябып куябыз, дигәч кенә районнан кайтып киткән ул. Әтине соңгы юлга озатып калучы да шул булган. Әнигә кайтып сөйләгән... и гомер буе безнең гаиләгә ярдәм дә итеп торган әле. Әтинең сөрелүендә, күрәсең, үзен гаепле санагандыр инде...

— Шулай булгач, нигә карышасың, Галләм абый, мин сиңа иң шәп урыннан җир бирдертер идем. Әйт халыкка, синең бер сүзең җитә.

— Беләм бер сүзем җиткәнен. Тик әйтмим, энем, әйтмәячәкмен. Үзем дә күчмим. Лучше биреп җибәр син мине. Сизәсеңме, тагын утыз җиденче еллар исе килә башлады бит. Мине рәхәтләнеп бөгәрләп тыгачаклар. Себергә үк барып җитә алмам алуын, карт сөякләрем юлда ук таралып бетәр...

Барый дәшмәде, тракторчы белән саубуллашты да капкага таба атлады. Тик соңгы сүзе итеп әйтеп куйды:

— Бурзаеңны бәйдән ычкындыра күрмә, Галләм абый, эт атучылар йөри.

Барый коточкыч авыр һәм күңелсез уйлар белән машина ишеген ачты һәм егылып китә язды: машина эчендә ниндидер шәүлә бар иде. Ләкин «шәүлә» аңа хуштан язарга ирек бирмәде, телгә килде:

— Мин бу, Барый абый, Зәринә.

— Зәринә?! Нишләп утырасың монда, кайдан килеп чыктың син?!

— Тәрәзәдән чыгып шылдым. Сез әти белән өйалдында утырганда.

— Йә, нәрсә кирәк инде сиңа, кызый?

— Мин кызый түгел.

— Миңа димәгәе!..

— Барый абый, зинһар, кызма әле. Мине тыңла син әүвәл. Синең әти янына ник килгәнеңне беләм бит мин. Тик син ул киребеткәнне үгетли алмаячаксың, әти тау башына күчәргә ризалык бирми икән, аңа карап бүтәннәр дә кузгалмаячак.

— Йә, шуннан!

— Шуннан шул, Барый абыкаем, әйдә, тау башына киттек. Безгә йорт урыны сайлыйбыз. Әти минем сүзне тыңлаячак!

— Тыңламаса?

— Тыңлар! Тыңлаячак! Мин вәгъдә бирәм! Сез вәгъдәгездә тордыгыз бит, мине «Культурага» укырга керттегез!

Машина тау башына алып менә торган юлга таба борылды.

Тау башына менеп җитүгә, Зәринә машинадан сикереп төште дә:

— Барый абый, ә клуб, культура йорты кайсы урында булачак? — дип сорады. Кыз төнлә очарга гадәтләнгән күбәләк кебек иде, бер урында гына тора алмый, бөтерелә, әйләнә, тулгана, баскан җирендә биеп тора. Кәефе дә шәп күренә.

— Барый абый, дим!

Барый аңа мәдәният йорты салыначак урынны күрсәтте. Зәринә, җил-җил атлап, шул урындагы бер түмгәккә басты да:

— Тау Башы Байтимеренең беренче сандугачы Зәринә Бәрхетгәрәева! –дип, әүвәл игълан итте һәм шуннан соң үзенең көчле, бормалы-бормалы затлы тавышы белән җыр сузып җибәрде.

Очар кошлар бездән китеп бара,
Әллә җитте инде көзләр?
Аерылганда нигә шулай моңлы
Карый микән синең күзләр?

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш...
Аерылышулар, кавышулар —
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Мәхәббәткә озын гомер телик,
Гаепләмик әле көзне.
Очар кошлар канат сынагандай,
Язмыш үзе сыный безне.

Моңсу да шул, бигрәк ямансу да
Бу җәйләрдән китеп барыш.
Аерылулар, кавышулар —
Шушыдыр ла безнең язмыш...

Язлар безне кабат якынайтыр,
Артта калыр моңсу көзләр.

Синең күзләр, кавышуны көтеп,
Очар кошлар юлын эзләр.

Кызның тавышы Барыйны таң калдырды! Бигрәк тә моңы! Юкка гына мәдәният академиясенә атлыкмаган икән кыз!.. Барый үзенең тәне буйлап рәхәт җылылык узганын тойды. Ул бу мизгелләрдә кечерәеп калды, әллә ничек юкка чыгып бетте дисәң дә була. Менә тавыш, менә моң!!! Шул рәвешле әсәрләнеп басып торганда, Зәринә, йөгереп килеп, аның кочагына ташланды һәм битеннән үбеп алды.

— Рәхмәт сезгә, Барый абый!

— Рәхмәт?

— Әйе, минем моңарчы сезгә рәхмәт тә әйткәнем юк иде бит әле! Тагын җырлыйммы, Барый абый! Барый абый! Бу җырым Сезгә багышлана!

Елмаясың, көләсең син,
Нигә сөям, димисең?
Мәхәббәтең юлга чыккан,
Ник каршына килмисең?

Таң сызылгач, тәрәз ачып,
Күк йөзләренә кара,
Килер бер көн, сизәр әле,
Үпкәләп булмый ярга.

Җанымдагы ут-ялкынны
Сизмисең икән, сизмә!
Көл(ә) алганда көл инде син,
Моңая гына күрмә.

Йөрәккәен ялкын алгач,
Үзе дә белер әле.
Сердәшенә бик яшерен
Сүз итеп сөйләр әле.

Басмалардан чыккан чакта
Күләгәң суга төшә.
Әнә килә, көлә-көлә,
Чын сөю үзе килә!..

Билләхи газыйм дип әйтим, Барый бу минутларда тәмам эреп бетте. Чишмәгә әйләнеп, тау башыннан түбән таба агып төшеп китте... Шушы тау башында басып торган килеш кенә, кулы белән үрелеп, күктән йолдыз алды ул һәм йолдызны каршысында еш-еш сулап басып торган затлы тавыш иясенә тапшырды...

Төнге салкын җил исеп куйды. Барый, үзенә килеп сыенган кызыкайны күтәреп алып, машинага утыртты. Көчле куллары белән аның башын күкрәгенә кысты.

Ул төнне, яше җитмеш ягына авышса да, тракторчы булып эшләүче Бәрхетгәрәев Галләмнең каладан сатып алып кайткан усал эте яман тавыш белән бары бер генә мәртәбә улап куйды. Аннан соң, алга ыргылып, тәү тартылуда ук юан чылбырны шартлатып өзде дә кунакчага менми калган бер яшь чебине ботарлап атты. Әллә лапастан ирекkә чыгасы килгән иде эт җанның, әллә инде бер яше тулган кыз-эт авылга урманнар хуҗасы Пират килгәнне сиздеме соң? Улавы куркуыннан булдымы, әллә урман егетен үзенә кунакка чакыруы микән?..

Хәер, ни генә булса да, бер яшь чеби харап ителгән иде инде...

## Миңлекәев Арслангали һәм аның хатыннары

Урманчы Арслангалинең капкасы бастырыкта, эте исә ишегалдында иде. Барый капка янына якынлашуга, көчек вакытында ук Казанның кош базарыннан шактый бәһагә сатып алып кайтып бәйләнелгән немец овчаркасы калын тавыш белән өрергә кереште. Эт тавышына уянып чыгарлармы, юкмы дип, баш ватып торганда, ишегалдыннан Арслангали хатыны Мәймүнәнең тавышы ишетелде:

— Кем бар анда, Арслангали, син кайттыңмы әллә?

Шакучының Барый икәнлеген белгәч, Мәймүнә, Әкбәровның сыйныфташы, этне оясына кертеп ябып куйды да бастырыкны шуыштырды. Нәкъ шушы мизгелләрдә хуҗа кешенең өйдә булмавын аңлап алган Барый ник килүенә үкенеп куйды, Мәймүнә, авыл башлыгының төн ката

йөрүенә гаҗәпләнеп, тәмам аптырашка төште. Ә мунча өйалдында качып яткан тол хатын Әсма куанычыннан чак кына кычкырып җибәрмәде!.. «Менә бит, тәки эләкте бит! Булды болай булгач, булды гына түгел, кая ул булу гына!» Ул, Әсма, күпме гомер каравыллаганнан соң, мунчага качып, әле капка төпләрендә саклаганнан соң тәки максатына иреште, теләге тормышка ашты лабаса?! Мәймүнә янына... Арслангали хатыны янына, хуҗа үзе юк чакны туры китереп, уңайлы вакытны чамалап, сөяркәсе килде! Сөяркәнең дә ниндие генә әле! Барый Әкбәров үзе! Әлбәттә, рәис кеше төнката эшкә кушарга килмәгәндер инде! Классташлар да бит әле, сөешәләрдер, яратышалардыр... Бетте! Моннан соң, бу хәлләрдән соң Арслангалине Мәймүнәдән башы-аягы белән йолкып алачак ул, Ходай кушып!.. Ә ватык тәрәзәләрнең үче үзе ни тора! Имансыз хатын... тик торганда бит, Әсма өенә килеп, сыерга башак болгата торган таяк белән бар булган тәрәзә пыяласын кырып китте! Имеш, Әсма Арслангалине качырып яткыра! Бик качты ди Арслангалиең! Ишегалдында хатыны дулаганны ишетүгә, чоланның арткы ишегеннән бәрәңге бакчасына чыгып шылмады әле, бары мич кырыена сыенып, тәрәзәдән ялтырап күренмәс өчен посып кына торды. Хатынының Әсма ишеккә өйгән баррикадалар аша барыбер өйгә керә алмаячагын белеп тора бит ул!..

Әсма ире Сәетгәрәйдән тол калганнан соң, урманчы ялгыз хатынны утын һәм башка кирәк ярак белән тәэмин итеп, вак-төягенә булышкалап тора. Әсма Мәймүнә белән яшьтәш, Сәетгәрәй вафатына чаклы да, кыз чакта да бик дус ахирәтләр иделәр. Арслангали исә балта остасы мәрхүм Сәетгәрәй белән дус булды. Урманчы агач белән тәэмин итә, Сәетгәрәйнең балтачылар бригадасы исә атна саен берәр бураны коеп кына тора, аннан соң аны — Казан читендә коттеджлар төзү чәчәк аткан чор — шәп кенә бәягә озаталар. Бер дә бер көнне урманда Сәетгәрәйне агач басты, Әсмасы ике ыштансыз бала белән тол калды. Элеккеге дустының хатынына ничек итеп ярдәм итмисең, ике нарасые белән ничекләр итеп аны язмыш ярында ялгызын калдырасың ди инде! Бик теләп ярдәм итә Арслангали тол хатынга. Җитмәсә, Әсмадан һәрвакыт шәп көмешкә дә өзелми, идән асты тулы яһүдләрдән сатып алган шәраб булыр. Самогон түгел, нәкъ менә көмешкә, күз яшьләре кебек чиста көмешкә. Самогонны мари авылында ясыйлар, ә яһүдләр яшәгән авылда көмешкә белән шәраб коялар. Мари үзе ясаган самогонга, каты булсын, эчкән кешене тизрәк җүләрләндерсен, тилертсен дип, тавык тизәге тондыра, ә яһүдләрнең көмешкәсе исә чишмә суыннан. Заманында Барый яһүд авылына өр-яңа трактор-комбайннар да кайтартып карады, иң уңдырышлы кара туфраклы җирләрне бүлеп бирде — чәчегез, урыгыз, сугыгыз, җилгәрегез, кыскасы, рәхәтен күрегез! Тик яңа тракторлар да, буяулары елык-елык килеп торган комбайннар да озак эшләп, бирәүгә дә рәхәт күрсәтә алмадылар шул, аларны бик тиз ватып сафтан чыгардылар да, яһүднең Арслангали урманында элек үскән, хәзер сагынып сөйләргә генә калган калын имәннәр кебек гренадердай ирләре тагын көмешкә кою белән шөгыльләнә башладылар. Көмешкә һәм шәраб сатып яту күпкә файдалырак иде шул. Яһүд авылы тирәсендәге җирләрне алабута, эт эчәгесе каплап китте.

Әсма көмешкәне берөзлексез яһүд авылыннан алып тора һәм шул аның чите кителгән тормышын алга таба сөйрәп тә бара. Ул гына микән?! Иреннән яшьли тол калган хатынның үзенең дә яз саен чәчәккә бөреләнеп алган чаклары — һәр күзәнәге пылт-пылт итеп торган яшь организмны урман каравылчы китерткән коры-сары утын җылысы белән генә җылытып булмый шул, ул «домна миченә» ир-ат күмере кирәк. Нәкъ менә шул сәбәп белән генә Арслангали белән түшәк тә бүлешкәләп ала иде Әсма апаң... Аларның бу кырын эшен ахирәте Мәймүнә дә сизенде һәм бер дә бер вакыт, икенче көнен өенә кайтмаган каравылчысын эзләп, Әсма ахирәте өенә килде. Шунда икәнлеген белеп килде һәм рәттән тәрәзә пыялаларын да кырып чыкты.

Сәетгәрәе Арслангали эшен эшләгәндә һәлак булды бит, шуңа күрә Арслангали Мәймүнәгә генә түгел, үзенә дә тиеш дип фикер йөртә иде тол хатын. Ләкин кырын эшләре Мәймүнәгә сизелгәч, хәлләр катлаулыга китте һәм аннан котылу чарасын табарга кирәк иде. Иң яхшысы: бозыклык эшендә Мәймүнәнең үзен каптыру һәм ире белән араларын бозу, дөресрәге, кыек эшләреңне ирең җиткерәм, дип өркетеп торып, Арслангалине курыкмыйча бүлешү. Әйе шул, нишләп ахирәтенең ире исән-сау да, ә ул ялгыз башы салкын түшәк җылытып ята? Бер дә гадел хәл түгел бит инде бу?! Кайчак Арслангали атналар буе урманыннан кайта алмый. Шул вакытларда Мәймүнәнең капкасын да читләр какмый торгандыр дисеңме? Бары тик төнге йокыларыңны кызганмыйча, качып, сагалап кына торасы бит инде югыйсә! Чү, тукта! Барый Арслангалине сорады да, өйдә юклыгын белгәч, чыгып китте түгелме соң?! Чукынды! Ник кермәде икән? Әллә аның караңгы мунча тәрәзәсеннән качып карап торганын сизенүче булдымы соң? Алай дисәң, Мәймүнә ишегалдына күптән теге усал этен ычкындырып җибәргән булыр иде. Кара, кара, чынлап та, бәеннән ычкындырды түгелме соң? Барый киткәч, капкасындагы бастырыкны этеп

куйды да... Хәзер моннан ничек чыга инде ул? Караңгы мунча эчендә кыштырдаган тавыш ишетелеп куйды! Нәрсә булыр бу?! Әсманың коты ботына таба тәгәрәде, ул артка чигенәм дип, нәрсәгәдер абынды һәм лыпылдап арты белән сәкегә утырды. Ай! Нәрсә бу! Бака өстенә утырдыммы әллә?! Кара, кара, бака күтен тешләп алды түгелме соң?! Әсма, уктай атылып, ишегалдына чыкты һәм капкага таба йөгерде, этнең бәйдән ычкынган икәнлеген онытып җибәргән иде, артында ырылдаган тавыш ишетелгәч кенә абайлап алды: бозау чаклы эт аңа тешләрен ыржайтып басып тора. Ләкин Әсмада эттән курку хисеннән бигрәк, Мәймүнә күзенә чалынудан шүрләү хисе көчлерәк булды, ул акрын гына бастырыкны кире шудырды да капка келәсенә басты. Урамга чыгып чабам дигәндә генә, овчарка аның артын умырып алды...

## Мирхәйдәр — Тас хәбәрче...

Байтимернең Мирхәйдәр атлы кешесе фермада каравыл тора. Чаңгелдек тавышлы кечкенә этен ияртер дә һәр кичне авыл читендә урнашкан колхоз фермасына китеп барыр ул. Көндезләрен дә йоклап ятмый Мирхәйдәр абзаң, ат җигә, колхозның вак-төяк эшләрендә катнаша.

Мирхәйдәрнең авылда берәүнекенә дә охшамаган кушаматы бар, ул — Тас хәбәрче, ягъни барлык соңгы яңалыкларны җиткереп торуы өчен аны ТАСС хәбәрчесе дип үртиләр, кыскартып әйтсәң, Тас хәбәрче була инде.

Бүген, төн уртасында, каравылын ташлап, авылга кайтты Мирхәйдәр. Максаты изге иде. Чәчү башланыр чак, быел апрель ае җылы килде. Колхоз амбарында көне-төне ашлык чистарту эше бара. Әкбәров күрмәгәндә, машина-машина ашлыкны йә сатып җибәрәләр, йә үз амбарларына алып кайтып бушаталар иде. Мирхәйдәрнең моңа бик тә эче поша, алай гына да түгел, ашказаны тырный ук башлый, ачудан барысын да Әкбәровка җиткерәсе килә. Тотсын гына әле менә! Әкбәровка ярарга тырышуының исә үз сере бар: тау башында яхшырак җир эләктереп калу. Югыйсә аның бәрәңге бакчасы гел таштан гына тора, тәмам җелегенә үтте инде, көзен күршеләре капчык-капчык бәрәңге ташыганда, ул җүләр нәрсә кебек бакчасыннан таш җыеп йөри. Әлбәттә, моның да үз сәбәбе бар. Моннан биш-алты ел элек Мирхәйдәр баш ташлап эчүче, тагын шулай дәвам итсә, тәмам алкашлыкка чыгып бетәсе бер бәндә иде. Шулай бер эчкән вакытында, белая горячка башланып, урамда ыштансыз чабып йөргәннән соң, ниһаять, Мирхәйдәр нәтиҗә ясарга булды. Хатыны күптән ташлап киткән, ялгыз башы гына яшәп ята иде ул бу вакытта. Аннан соң басудагы менә дигән кара туфраклы бәрәңге бакчасын да бер литр аракыга авылдашына сатып җибәрде бит. Айныгач, җир янә кирәк булды. Әмма авылда яхшы җир калмаган иде инде. Ул, аптыраганнан, читтәге ташландык җирне эшкәртергә булды, әлеге урын исә галәмәт ташлы булып чыкты.

Ул төнне Барый авылда мулла булып йөрүче Алихан капкасын шакырга уйлады. Урамда алар Мирхәйдәр белән маңгайга-маңгай диярлек очраштылар.

— Нигә каравылыңны ташлап йөрисең болай?! — диде Әкбәров, каравылчыны танып алуга. Тегесе дөресен әйтергә курыкты, чөнки карак тотылмаган бит әле, шуңа күрә хәйләләргә булды:

— Кичтән хатын сырхап калган ие, тиз генә шуның хәлен белеп килим дигән ием.

Рәис кеше артык бәйләнеп маташмады, бары сүз булсын дигәндәй:

— Эш урыныңны калдырып йөрмә! — дип кисәтәсе генә итте һәм төнге караңгылыкка кереп югалды.

Аның төн уртасында кешеләр белән сөйләшеп йөрүен ишеткән Израэль Исаевич дусларча гына шелтәләп тә алган иде алуын. «Сталин заманы түгел бит, нигә төн уртасында кеше борчып йөрисең?» — диде ул. Барый аңа каршы көлеп кенә куйды, аннары, җавапсыз калырга уңайсызланыптыр инде: «Ул заманнар тагын килмәстер дип кем әйтә ала, Израэль Исаевич?! Әнә бит хәзер стукачларга яңадан яшел юл ачылды». Рәсәй президентының террорчылар хакында сөйләгәндә әйткән сүзләренә ишарә иде бу үзенчә. Сүз чыннан да террорчылар хакында барса да, халык аны үзенчә кабул итте: телисең икән, рәхәтләнеп әләклә! Сиңа рәхмәт кенә әйтәчәкләр. Барый шул сөйләшүне исенә төшерде дә кинәт аптырап калды. Туктале, тукта?.. Израэль Исаевичның үз киңәше түгелме соң бу?.. «Кешеләрне бер йөреп чыгарга кирәк, көндез өлгермәсәң, башка вакыт тап, әмма зур җыелыш алдыннан кылларын тарткалап, үз ягыңа аудара башла!» — дип, үзе киңәш итте ләбаса?! Аңламассың бу яһүдне, дип уйлап куйды ул, Алихан мулла капкасы янына килеп җиткәндә.

Ә Мирхәйдәр замананың кай якка таба барганын күңеле белән сизенгән, күрәсең. Ул төнне Байтимер урамы буйлап таңга чаклы йөрсә дә, бер генә карак очрату бәхетенә дә ирешә алма-

ды. Күңелсез генә фермасына таба атлады. Анда каравылчыны шаккатыргыч яңалык көтеп торган: кечкенә этен, каравыл өенә кертеп, мичкә ябып куйганнар, мескен көчек шуннан чәңгелдәп ята. Мирхәйдәр этне тоткынлыктан азат итте дә сыерлары янына чыгып чапты, һәм анда исә тагын да хәйран калырлык күренешкә тап булды: ишек тышкы яктан аныңча бикләнмәгән, чит кеше йөргәнлеге әллә кайдан кычкырып әйтеп тора; каравылчының эченә курку йөгерде. Абына-сөртенә ферма эченә керсә, ни күрсен — алгы якта аерым ояларда бәйдә торган үгезләрдән җилләр искән! Өчесенең берсе юк! Мирхәйдәрнең аяк буыннары калтырарга кереште, чак-чак сөйрәлеп, сыерларны барларга китте, бәхеткә, алары үз урынында икән. Ул янә урамга чыкты, кергәндә игътибар итмәгән булган икән, ишек янында машина тәгәрмәче эзләре ярылып ята иде...

## Шәңгәрәев Алиханның кендеге селкенә

Урланган өч үгезне Байтимердән еракларак алып китеп өлгерсеннәр әле, без Әкбәров артыннан куып җитик. Ни дисәң дә, мулла йортына бара бит. Байтимер мәчетендә мулла вазифаларын башкарырлык бер генә кеше бар, ул — колхозның элеккеге агрономы, парткомитет секретаре Шәңгәрәев Алихан абзый иде. Алихан муллалыкка махсус укымаган, ләкин ул догаларны яттан белә һәм гарәп язуын рәхәтләнеп таный. Шәңгәрәевнең әбисе Гайфә карчык бик гыйлем кеше булган дип сөйлиләр. Алихан, имеш, яшь чагында дин гыйлемен әнә шул әбисеннән эләктереп калган, ди. Аннан соң, пенсия яше җиткәч, ул кулына китаплар тоткалый башлады һәм шушы көннәрдә генә, район үзәк мулласы янына барып, сабаклар да алып кайтты шикелле.

Әлбәттә, Алиханның әүлия түгел икәнлеген авылның олы кешесе генә түгел, бала-чагасы да бик яхшы белә. Ләкин аның догаларны шартлатып яттан укуын, акыллы вәгазьләрен бик яраталар һәм нәкъ менә шуңа күрә дә инде аның кайбер вак-төяк гаеп-гөнаһларын күрмәмешкә дә салышалар иде бугай. Байтимердә күптән түгел генә яңа мәчет салып чыктылар. Элек каравыл өенә җыелышып, балта элеп куярлык тәмәке төтене эчендә төрле гайбәт сөйләшүдән узмаган авыл ирләренең күбесе хәзер, тәһарәтләнеп, мәчеткә җыйнала. Каравыл өендәге гадәт буенча мәчетне дә гайбәт сөйләү йортына әйләндерергә теләүчеләрне Алихан бик тиз урыннарына утыртты. «Әй Аллаһының ачулы кемсәләре, сөйләшүдән туктагыз! Бәс, сезгә Аллаһының ләгънәте булсын. Сөйләшүдән туктагыз», — дип, фәрештәләрнең әмерләрен укып күрсәтте ул. Әгәр дә без пакь калебле мөэминнәр булсак, безгә фәрештәләр: «Әй Аллаһының намаз ияләре! Сезгә Аллаһының рәхмәте булсын, киләсе намазга кадәр без Аллаһыдан сезнең гөнаһларыгызны истигъфар кылуын сорарбыз», — диеп шатланып калырлар дия иде. Ә без, кеше гайбәтен сөйләшкән булып, мәчеттән фәрештәләрнең ләгънәтен алып кайтабыз, гаиләбезгә афәт һәм кайгы-хәсрәт ирештерәбез.

«Үә үәрадә фил-мәсәҗиди йәкүлүл-хәсәнәт кәмә тәәкүлү әлбәһимәтүл-хәшишә», ягъни китапларда әйтелгәнчә, мәчеттә дөнья сүзләре сөйләшү, хайван печәнне ашаган кебек изгелекне ашыйдыр.

Моннан аңлашыла ки, мәчеттә дөнья хәлләре турында сүз куерту, бер-береңне кимсетү-кыерсыту, бүтәннәргә яла ягу мөселманлыктан түгелдер. Шулай ук «минем гөнаһым юк, мин фәлән доганы укысам, җәннәткә керәм» дигән тәкәббер кемсәләр дә Аллаһ каршында монафикълык кылган булырлар. Җәмәгател-мөслимин, тәннәребездә җаннарыбыз бар чакта истигъфарга ашыгыйк. Аллаһы Раббыбыз — гафу итүче. Тәкъва мөселманга истигъфардан да кыйммәтле нәрсә бар микән? «Иннәд-динә гыйндәл-лаһи исләм» — Аллаһы каршында бердәнбер хак дин ислам дине генәдер. Белгәннәребез белән Аллаһ йортларын буш тотмыйк. Яраткан догаларыбыз белән намазлык өстенә басып, керсез сабыйлар күңеле белән Җәллә җәләлеһкә сәҗдә кылуны көндәлек табындагы ризыкка тиң итик».

Менә шундый рухтагы вәгазьләрне Алихан бик белеп, килештереп сөйли белүе белән халыкны авызына каратып тора ала.

Алиханның әүлия түгел икәнлеген беләләр дигән идек. Әйе, ул элек аракы мичкәсе эчендә йөзгән кеше булып, шуның белән гаиләсенә генә түгел, колхозга да шактый зыян салган бер адәм иде. Хәзер ул көннәрен исенә төшерсә, үзе дә элеккеге халәтен мыскыллап көлә, әмма ләкин аның бу көлүендә ниндидер үкенү хисе бардыр дип һич кенә дә әйтеп булмый шул. Бары мең төрле сәбәп табып акланулар гына... Алиханның әле дә сирәк-мирәк ычкынып китә торган гадәте барлыгы да сер түгел.

Үзенең кылган гамәлләре хакында көлеп, үзен җиңелчә генә юмор дәрәҗәсенә күтәреп читләргә сөйләп йөрү адәм баласыннан зур батырлык сорый. Теләсә кем булдыра алмый мондый

нәрсәне. Алиханның моңа көче җитә. Әкият сөйләгән кебек тәмләп сөйли ул аны. Ә тыңлаучылар көлә. Тәгәри-тәгәри көлә, бахырлар, элек эчеп ташлаганы да көлә, махмырдан булганнары да, чак кына «чиертеп» алганнары да аны тыңлаганда шырык-шырык көләләр. Алиханның үзенә көләргә ярамый, катырак көлеп җибәреп, корсагына ябыштырылган пластыре ычкынып китүдән курка ул.

«Запой» гадәттә вак-төяк сәбәптән генә башланып китә торган иде. Мәсәлән, ышна басуында быел бодай бик уңган. Моны агроном буларак ничекләр итеп юмыйсың ди инде. Юмасаң, гөнаһ булыр. Ә кабинада һәрвакыт бер ярты малае йөри. Алиханның үзенең аерым машинасы юк, аны басулар буйлап эштән бушаган арада сөт ташучы машина йөртә. Менә шул рәвешле күңелле көннәр башланып китә. Аракы аның корсагына кергәннән соң, гадәти булмаган бик сәер реакция башлана, әйтерсең ул сусыз чүлдә бил тиңеннән ком ярып бара, авыз чатнап кибә, ашказаны кендек турысыннан мелт-мелт селкенә башлый: тагын аракы соравы имансызның. Шул рәвешле бер атна үтеп тә китә, ахыр чиктә, Алиханың тәмам агулана, коса-коса эчүгә керешә, урыныннан да торалмыйча башын күтәрми ята. Андый чакта бөтен гәүдәсе сызларга керешә. Хатыны эшкә, балалары мәктәпкә укырга киткәч, сулыш алулары чак кына җиңеләя, хатынының йокыдан торуга, артка чигенә-чигенә, дөньядагы иң актык сүзләр белән әрләүләре дә онытылып тора. Алихан бик җиңел хәрәкәтләр белән урыннан тора, көзгегә карый: кыяфәт кирпеч сорый, йөз шешенгән, күзләр кызару өстенә кысылып та беткән. Димәк, урамга чыгып, кеше күзенә күренеп йөреп булмый. Ни дисәң дә, колхозның агрономы гына түгел, партия оешмасы секретаре да бит әле ул. Димәк, өйдән генә эзләргә кирәк хатынның яшереп куйганын. Ишегалдына чыгып, бер тирән итеп сулыш ала Алихан — баш шөрепләре кыймылдый, селкенә башлый. Суыткычта юк та юк инде ул, кухня шкафында да юк... Чормада! Кыш килүен көтеп яткан киез каталар эчендә! Алихан мәче кебек чорма баскычыннан өскә үрмәли һәм җәһәт кенә киез каталарны эзләп табып, иң беренче туры килгәненең эченә кулын тыгып җибәрә! Бармак очы салкын шешәгә тиеп китә... И, шул чактагы ләззәтне ничекләр итеп аңлатмак кирәк?! Аны тел белән сөйләп тә, каләм белән язып та сурәтләп биреп булмастыр! Ул ләззәтнең иң югары ноктасы! Адәм баласы җир астыннан бер чүлмәк алтын тапса да, бу чаклы сөенә алмастыр, мөгаен!.. Алтыннары ни чуртыма бу вакытта! Аның белән баш төзәтеп булмый лабаса!

Хатын эштән, балалар мәктәптән кайтканчы табылган шешә акрынлап суырылып бетә, Алиханны йокы баса. Хатыны капкадан кайтып керүгә, бер кат ишегалды һавасын тирән итеп сулап, сизгер борыны белән иснәп алганнан соң, иренең каяндыр табып эчкәнен шундук сизенә, шуның дәлиле булып, Алихан гырлап йоклап ята. Тапкан! Кайдан, кайсысын тапты икән, имансыз. Хатын мәче кебек чормага үрмәли һәм киез каталарны актара башлый. Буш, тапкан, имансыз! Ничек тапкан, ничек сизгән?! Бу хатын өчен мәңге чишеп булмаслык шаккатмалы табышмак...

Иртәгесен ире тагын баш авыртып уяна. Кан басымы соңгы чиккә җитеп күтәрелгән, авыз чатнаган, иреннәр бер-берсенә ябышып каткан, йөрәк дөбер-шатыр килеп селкенә, соңгы көченә тибә, ул типкән саен карават та селкенә. Хатыны уянганчы, борынынннан гына бер чәйнек су эчеп бетерә. Күп сыеклык кан басымын соңгы тамгасына чаклы күтәреп куя. Хатын мыр-мыр эшкә җыена, вакыт бик акрын бара, тизрәк чыгып китсен иде бит канә! Менә Алихан өйдә янә ялгыз башы гына кала, хатынын тынычландыру өчен, «башка эчмәс идем» диеп антлар эчеп кала. Хатын, аның сүзенә ышанып, тынычлана да, тагын эшенә китә, балалар мәктәпкә тарала. Өйдә эссе, эсседә йөрәк тагын катырак кага. Ул ишегалдына һавага чыга. Монда да бөркү. Алихан, махмырлы башын кыегайтып, баз өстенә керә, монда карават бар, баздагы кардан салкын бәреп тора. Беркавым шулай ятканнан соң чак кына хәл кереп киткән төсле була, Алиханның башы яңадан эшли башлый. Тик бүген эчәсе килми, ул чынлап торып авырырга керешә. Баз өсте аның кайнарлыгыннан җылына башлый, шуннан соң ул базның капкачын ачып куя. Рәхәт булып китә. Базга аякларын салындырып утырган Алиханның башына шул чакта төрле зур уйлар, планнар килә — бер айныган вакытында базны зурайтып, менә бу тимер караватны шунда төшереп куясы булыр, кар өстенә үк. Аңа карап кына кар өстендә торган чиләкле сөтләргә чуртым да булмас әле!.. Шулай эшләргә кирәк булыр — Алиханың сәгать эчендә кеше булып аягына басачак аннан соң. Мунча ягыннан бер бака малае килеп чыга һәм, күзләрен дүртләндереп, Алиханга карап утыра башлый. Курыкмый да мәлгунь, әллә ул да махмырдан инде?.. «Йә, бака дус, алайса әйтеп кара, кайда яшерелгән шешә бар? Ә-ә-ә, мич артында дисеңме? Юк, анда юк, карадым инде. Келәттәге арыш капчыкларының берәрсе эчендә дисеңме? Юк, аны да тикшереп чыктым. Чормада да юк, теге юлы аннан тапкан идем бит инде... Точно, дөрес уйлыйсың син, бака дус! Каз оясында булырга мөмкин! Каз бәбкә чыгарып утыра бит. Апаң көн саен аның йо-

мыркаларын тикшерә!.. Шунда яшереп куймас дисеңме син аны? Хәзер, хәзер тикшереп киләбез аны. Алихан, абына-сөртенә, лапаска таба атлый. Әнкә каз әле яңа гына йомыркалары өстенә кереп утырган. Ул, Алихан якынлашуга, ысылдый башлый. Тегесе аңа игътибар итми, казның муенынnan каптырып, оясыннан өстерәп чыгара да, кулын йомыркалар салынган салам астына тыга... Молодец икәнсең син, бака дус! Рәхмәт сиңа, мең яшә! Тапты бит! И бу хатынның аңгыралыгын әйтер идем, тапкан яшерер урын, перәме аяк астында гына бит. Җәһәннәмгә үк олактыра алмаган шуны яшергән юлы!.. Менә... аракыны яшерә белмәгәне өчен дә хатын гаепле...

Хатын эштән кайтканчы, шешә тагын бушый, ишегалдында бары гырлаган тавыш кына ишетелеп тора. Каз да никтер бүген оясыннан чыккан, ата каз белән ишегалдында йөри. Хатыны аны оясына куып кертте дә баз өстенә керде. Алихан трактор кебек тавышлар чыгарып гырылдап йоклап ята. Баз капкачы ачык. Хатын, ирен төртеп уята да:

— Баз капкачын нәрсәгә ачтың?! Сөтләремне ачытып бетерәсең бит!

— Бакаларны пленнан коткардым... — дип мыгырдый Алихан, йокы аралаш кына.

— Салкын базда, кар өстендә нинди бака булсын!

Хатынның ачуы чигенә җиткән, ул исерек иренә әйтерлек бүтән сүз таба алмый. Аптыраганнан: «Беләсеңме кем син?! Алкаш син, белдеңме!!!» — дип сүгә. Алиханның иң яратмаган сүзе инде бу, шул сүзне ишеткәч, аның йокысы ачылып китә һәм ул хатынына усал итеп карап: «Ә син? Син үзеңнең кем икәнлегеңне беләсеңме соң, хатын. Ә?» «Мин кем булыйм?! Нәрсә, мин синең кебек эчеп ятаммы әллә?! Йә, мин кем? Мин нишләгән әле, җә?» «Синме, син... хатын, син... мин алкаш булсам, син алкаш хатыны, белдеңме!» Хатын мондый көтелмәгән сүздән әүвәл каушап кала, аннан соң иренең тапкырлыгыннан эчен тотып көлә башлый. «Алихан, дим, Алихан. Айнырга кирәк бит инде, болай ятып булмый бит инде, ә, алтыным...» Хатынның шул сүзе җитә Алиханга, бетте, күреп торырсыз, иртәгә ул эчмәячәк, грамм да. Бугазыннан койсалар да... кире төкерәчәк!!!

Иртәгесен янә шундый ук махмыр. Тагын чәйнек борыны... Җитмәсә, бүген башының гына түгел, эченең дә кәефе юк. Бәдрәф юлыннан кайтып керә алмый. Ах, кашыклап тоз салып... шуны әйбәтләп болгатып... бер стакан, ә?

Юк, бүген эчте юк дип уйлый ул аннан соң. Җитте! Әле менә кәефе дә ярап торган шикелле. Беркавым шулай ятканнан соң, Алихан караватыннан сикереп үк торды. Көзге каршына килде. Күлмәген күтәрде һәм артына ава язды: кендек, кендеге корсак буйлап астан өскә таба йөри иде, хәрәкәт итә иде! Бер түшә, бер менә!.. Һәм шул вакыт аның үтереп эчәсе килә башлый. Ул бер кулы белән кендеген тота, кендек пылт-пылт селкенмәкче була, ләкин ычкына алмый һәм ни гаҗәп, шул мизгелдә аракы эчәсе килү теләге сүнеп тора! Менә сиңа мә, барысына да шул каһәр кендек гаепле икән ләбаса?! Ул һава суырткыч кебек эшләп тора һәм аракы сорый. Алихан кулын кендегеннән алуы була, янә астан өскә, өстән аска хәрәкәтләнергә керешә, тагын эчәсе килү теләге уяна! Ачыш бит бу! Гаҗәп зур ачыш? Үзенең дөньякүләм ачышыннан соң Архимед та болай ук сөенмәгәндер, билләхи! Шатлыгыннан Алиханның хәтта баш авыртуына кадәр бетеп торды, ул һаман бер кулы белән кендегенә басып тора иде әле. Алиханның үз башы гына җитәрлек хәл түгел бу! «Медицинский подход кирәк монда», — дип уйлап куйды агроном. «Медицинский...» Тик кемгә барасы? Медпункт эшләми. Сибгат хатынының өенә барып, аңа корсагыңны ачып күрсәтә алмыйсың, Сибгате бик көнче адәм?.. Кинәт башына сукты Алиханның: дусты, бергә эшләгән дусты, мал табибы Гаптегани дусты бар бит! Мал табибы булсын, ат докторы булсын, ләкин ул да барыбер табиб бит!

Алихан бәрәңге бакчасы буйлап кына Гаптегани өенә таба китте. Табигатьнең «кендек» серен чишәргә кирәк бит инде канә! Бер кулы һаман кендек турысында иде әле, эчәсе килүе дә басылып тора. Бәхетенә күрә, Гаптегани эштән кайткан, абзар-кура тирәсендә йөри. Капкадан килеп керешкә, Алихан аңа:

— Яшьти — алар икесе дә бер яшьтә иде — карале монда, бер кызык нәрсә күрсәтәм! — дип кычкырды. Алар икесе бергә эчә башлаганнар иде, Гаптегани туктаган. «Кара син аны, каһәр, тормозга салган бит бу!» — дип уйлап куйды шул мизгелдә Алихан.

— Кил әле монда, карале! — Алихан, күлмәген күтәреп, кендегеннән кулын алды. — Күрәсеңме, селкенәме?

— Селкенә... Шуннан ни?

— Беләсең килсә, аракы сорап селкенә ул!

— Кит, булмаганны!

— Ышанмасаң, йөз грамм салып биреп кара менә!

Гаптегани йөгереп өенә кереп китте һәм аннан башланган шешә күтәреп чыкты.

— Син түлке күп салма, илле грамм и җитте. Менә карап торырсың.

Алихан кулын кендектән алды да стаканны тотып эчә башлады.

— Күрдеңме, туктадымы?

Гаптегани бу хәлгә шаккатып карап тора иде. Гаҗәпләнүдән ачылып калган авызын кире ябып яңадан ачты да:

— Шаяртмыйсыңмы син, яшьти? Чынлап та шулаймы ул?!

— Соң... үзең күреп торасың бит инде! Ярты сәгатьтән тагын селкенә башлаячак! Менә, яшьти, эчүнең бөтен сәбәбе кайда икән! Кендектә икән, яшьти, кендектә! Син доктор кеше, берәр чарасын уйлап тап. Алайса эчеп үләм бит мин, яшьти!

Гаптегани беркавым башын кашып уйланып торды да аннан соң ботын чабып куйды!

— Хәзер, хәзер, таптым, яшьти, — дип, ул тиз генә өенә йөгереп кереп китте һәм үзенең эшкә асып йөри торган кирәк-яраклары салынган сумкасын күтәреп чыкты. Аннан ябыштыргыч тасма алды.

— Менә шушы пластырь белән ябыштырабыз да куябыз аны хәзер. — Ат докторы кендекне берничә кат ябыштыргыч тасма белән беркетеп куйды: — Яле, селкенәме хәзер?

— Ярты сәгать үттеме соң әле?

— Көтик соң.

Көттеләр, ярты сәгать узды, кырык минут вакыт авышты, әмма кендек беркеткән урыннан кыймылдый да алмады.

— Йә, ничек? Эчәсең киләме хәзер?

— Грамм да килми, яшьти.

— Алайса, пластырьны куптара күрмә инде син, яшьти.

Хатыны, эштән кайткач, Алиханның аек икәнлеген күреп, шаклар катты. Алихан аңа эшнең нидә икәнлеген сөйләп бирде. Ябыштыргычны куптарып карадылар, кендек янә астан өскә таба йөри башлады, хатын тиз генә аны киредән ябыштырып куйды. Хет чукын, эчәсе килми иде инде хәзер. Димәк, бар гаеп кендектә булган икән, баш ташлап эчеп ятуында Алиханның бернинди дә гаебе юк, тамчы да юк менә!.. Хатыны белән икәүләшеп алар әнә шундый фикергә килделәр... Менә шуннан бирле Алихан абыең шешә яныннан әйләнеп уза торган булып китте. Тик һәр мунча саен ябыштыргыч тасманы алыштырып кына торасы. Бу эшне хатыны бик яратып, шуннан үзенә тәм табып башкара иде. Кушамат таралды таралуын. Авылның телен кисеп булмый бит инде. Ямаулы корсак дип үртиләр аны үз артында. Ник? Үртәсеннәр. Аның каравы Алихан үзе хәзер рәхәтләнеп яши башлады, тормышның тәмен табып, мәгънәсен күреп яши. Менә, пенсиягә чыккач, дин юлына да кереп китте әле. Ходай кабул итсен инде...

Иртә-кич хатыны һаман белешеп тора: «Селкенәме, Алихан?..» «Юк, селкенми, карчык, Аллага шөкер...»

### Кара булмаган кара карга баласының соңгы сәгатьләре...

Урман өстеннән каргалар очып узганда, аларның каркылдавы Пиратның эчен пошыра иде. Кара булмаган карганың тавышы бигрәк тә аерылып тора. Көтүләре белән авыл ягыннан очып киләләр дә көтелмәгәндә кинәт кычкырып җибәрә ул, табигать ялгышы! Әйтерсең Байтимердә нииндидер хәвеф булган. Аның Актырнактан туган малае тагын авыл ягына чыгып чапкан иде. Әллә... әллә шуңа берәр хәл булганмы?! Әллә аның муенына да әнисе кебек кызыл тасма салганнармы?! Пират тынычсызлана, борчыла. Аны коткарырга барырга ашкына. Ләкин көпә-көндез авылга йөрми Пират. Малаен да шул гадәткә күпме өйрәтергә тырышып карады — файдасыз, яшь шул әле, аңламый. Кешеләрнең кайвакыт урмандагы бүре туганнарга караганда да явызрак икәнлеген төшенеп бетерми.

Май бәйрәме алды авылда сугым вакыты, чираттагысы сабан туе алдыннан була, гадәттә. Моны эт-бүреләр сизенә һәм андый көннәрдә алар төннәрен авылга сәяхәткә әзерләнә. Бу элегрәк шулай иде, авылның һәр кешесе шәһәрдән усал бурзайлар алып кайтып бәйләп куйгач, суелган малларның адәм балаларының үзләреннән арткан санакларын бәйдәге эт туганнары хәл кылып бара. Фермада берәр бозау-мазар үлсә генә инде. Пират белән Актырнак малае — әнисенекенә охшаган ак тырнаклы шук малай — Агаяк ферма тирәләрен урап килергә дип киткән иде. Кара булмаган карганың, болай ямьсез кычкырып, әллә Пиратка шуның һәлакәте хакында хәбәр салуы булдымы соң?..

Пират үзе картаеп килә инде. Элеккеге сизгерлеге дә, ташып торган гайрәте дә сүнеп бара шикелле. Шулай да кыргый тормыш рәвеше аңа бөтенләй мәлҗерәп төшәргә ирек бирми, ул һаман да көчле, өстәвенә еллар буе тупланган акыл-тәҗрибәсе дә юк түгел. Шулай да бу юлы Агаякны авылга барудан тыеп кала алмады. Инде зур үскән малайның урман-читлектә генә бикләнеп ятасы килми.

Кара булмаган кара карганың иләмсез ямьсез тавышын Барый да ишетте. Аның таң белән урман юлы аша Галләм кызы Зәринәне райүзәктән Казанга йөрүче автобуска илтеп барышы иде. Тау башындагы хәлләрдән соң бу чикерткә кыз аны үзенә бәйләде дә куйды. Ләкин Барый үзе моны вакытлы хәл дип исәпли. Менә ул, Зәринәнең үтенече буенча, аларга ансамбль оештырып җибәрергә ярдәм итә дә... Аннан соң кызның җыр-клипларыннан бер-ике видеокассета чыгарырга ярдәм итсә... Зәринә моны бик тели һәм Барый абыйсына тагын да рәхмәтле булачак. Ни хәл итәсең, ул дөньяга — шоу-бизнеска — Әкбәров кебек иганәче-спонсорлардан башка борыныңны да тыга алмыйсың. Коточкыч конкуренция бара, бигрәк тә талантсызлары котыра. Кем әйтмешли, авызына микрофон төртсәң, балык та җырлап җибәрер иде, билләһи! Чөнки техника-аппаратура хәзер бик көчле, аның ярдәмендә кәҗә тавышын да былбылныкына әйләндереп булыр иде, мөгаен...

Кара булмаган кара карганың шөкәтсез тавышы Барыйны сискәндереп җибәрде. Ул, машинасын туктатып, мылтыгын алды да тәрәзә пыяласын төшерде.

— Бүре-фәлән бармы әллә, Барый абый?

Барый Зәринәгә җавап биреп тормады, ишеген ачты. Әнә карга көтүе алан өстеннән очып бара. Барый мылтыгын өскә күтәрде һәм чакмага басты. Һавага чәчелгән ядрәләрнең берсе кара булмаган кара карганың мәгънәсез башын кыеп төшерде. Адәм баласы үз гомерендә беренче мәртәбә табигатьнең ялгышын төзәтә алды!..

Шулчаклы төз атуы бүген нигәдер Барыйны сөендермәде. Кара булмаган кара карга җиргә кыелып төшкәч, кинәт аны ниндидер сәерлек биләп алды, сул як чигәсендәге кан тамырларының мелт-мелт кыймылдаганына чаклы тойды ул.

Җил тегермәне капылт кирегә әйләнә башлаган кебек, аның баш шөрепләре дә нәкъ кирегә таба эшли башлады бугай: Израэль Исаевичның тау башына салыначак дин йорты хакында әйткән сүзләре исенә төште.

— Диннәрне берләштермәсәк, халыклар арасындагы талаш-сугыш мәңге дәвам итәчәк... — дигән иде яһүд дусты шулай бервакыт. Ә үзе, күптән түгел Барыйның бу эшенә каршы килеп, әллә нинди дәлилләр китерә. Югыйсә теге чакта ул шулай димәгән булса, өч динне берләштерү уе кайдан килер иде Әкбәровның сөт планын арттыру максаты белән чүпләнгән башына? Нигә шулай ике төрле сөйләшә Израэль Исаевич?! Берәр төрле яшерен максаты бармы әллә югыйсә?.. Һәм нигә күптән түгел күренеп киткән ФСБ кешесе Барыйдан Воронов хакында кызыксынасы итте икән? Үз илендә яши ләбаса ул? Хәер, монда андый шаккатмалы сер юктыр да әле, бәлкем. Израэль Исаевич ике илнең гражданины бит, шуңа кызыксынгандыр.

Иң гаҗәбе шул: нигә бу уй аның башына моңарчы килмәде, карга атып төшергәч кенә биләп алды күңелен төрле каршылыклы, сәер хисләр?.. Ахыр чиктә кара булмаган кара карга белән Воронов арасында нинди уртаклык булуы мөмкин соң?

— Барый абый, бүре аттыңмы әллә?

— Аю... Ак аю...

Кыз гаҗәпләнеп аңа карады:

— Ник... безнең урманда ак аю бармыни ул?

— Безнең урманда бала башлы бүре дә бар, Зәринәкәй.

— Бүре?! Бала башлы?

— Юк, шаяртам гына, — диде Барый, машинасына кире утырып. — Син менә миңа шуны әйт әле, Зәринәкәй, син танылган җырчы булып киткәч, миңа сәлам бирерсеңме соң?

Кыз, чытлыкланып, аның беләгенә башын куйды.

— Бирүен бирермен дә, тик сез ул вакытта өйләнгән кеше булырсыз бит инде?

— Кемгә?

— Урман кызына!

— Урман кызына? Урман кызына шүрәле өйләнсен, яме!

— Чынлап та шулаймы, Барый абый?

— Чынлап та шулай...

— Ә Гөлйөзем? Аннары шул дөресме, Барый абый, Мөхәммәт Уразов Гөлчәчәк аркасында гына зур рәссам булган, дип сөйлиләр?

— Сөйләсеннәр. Дөрес сөйлиләр.
— Ә Гөлйөзем? — дип соравын кабатлады кыз.
— Күрәсең, мин атаклы рәссам булып китмәдем бит...
Кече Фили-райүзәккә килеп җиткәннәр иде инде.

— Тиздән концерт бригадасы белән районнарга чыгарга исәп. Безнең концертны сатып алырсыз әле, Барый абый, яме?
— Алырмын. Хәбәр итәрсең.
Саубуллашканда соңгы сүз алышу әнә шул булды.

...Израильнең дәүләт булып оешып яши башлаган беренче көннәрендә үк читтән күпләп яһүдләр тарту була. Үзенә дошман булган гарәп илләре белән чорнап алынган Израиль шул рәвешчә нығырга, дәүләтен аякка бастырырга тели. Ләкин моңа күп кенә илләрдәге иммиграция кануннарының кырыс булуы комачаулык итә һәм нәкъ шул сәбәпле дәүләт махсус разведка оешмаларының эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Кырык сигезенче елда шул максат белән «Алия-Бет» институты оеша, шул исемдәге разведка хезмәте эшли башлый. Элеге оешмалар Израиль өчен бик зур эш башкаралар, читтән күпләп яһүд гаиләләре китерелә. 1948–1949 елларда Ирактан илле мең гаилә, ә 1950–1951 елларда йөз илле мең яһүд күчерелә.

Ләкин «Алия-Бет» ничек кенә уңышлы эшләмәсен, эмигрантларның барсы диярлек Якын Көнчыгыштан гына килә. СССР һәм Көнчыгыш Ауропадан күченүчеләр бик аз була. Өстәвенә 1949 елларда СССР белән Израиль арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла башлый һәм Тель-Авив күбрәк АКШка йөз тота.

Премьер-министр Бен-Гурионның махсус указы нигезендә, «Алия-Бет» таркатылып, аның урынына 1951 елда «Натиф» разведка хезмәте төзелә. Аның максаты, социалистик илләрдә сионизм идеяләрен таратып, Израильгә күпләп яһүдләрне күчерү була.

«Натив» турыдан-туры премьер-министрга буйсына һәм аның эшчәнлеге аерата яшерен була, оешма эшчәнлеге хакындагы мәгълүматлар исә җиде йозак астына бикләнелә.

Израильдәге яһүдләр санын арттыру өчен нинди генә чараларны файдаланмый «Натиф»! Мәсәлән, 1980 елда «Натиф» хезмәткәрләре Лондонда СССРга барырга «теләүчеләрне» оештыралар. Йөздән артык яшь англияле турист рәвешендә Советлар Союзына барып иврит телендә әдәбият, видеокассеталар һәм башка пропаганда материаллары тарата. Бу зур халыкара шау-шу тудыра һәм шуннан соң Б.Бегин «Натиф» җитәкчесе яһүд Леванонны эшеннән азат итәргә мәҗбүр була.

«Натиф» башка социалистик илләрне дә тынычлыкта калдырырга уйламый. Мәсәлән, Румыния, Израильгә яһүдләрне чыгарган өчен, барлыгы алтмыш миллион доллар акча ала, шуның яртысын Чаушеску үз кесәсенә салып куя. Израиль хөкүмәтенә бер яһүд башы өч мең долларга төшә.

Кызганыч, без исә читтән үзләре теләп кайткан татарларыбызны да кайда куярга белмибез!.. Адәм типкесендә йөриләр...

1985 елда Горбачев дәүләт башына килгәч, яһүдләрнең Израильгә чыгуына яшел юл ачыла һәм илне ярты миллионлап яһүд ташлап чыгып китә. Күрәсең, СССР президенты масоннарның якын дусты булган дип фаразларга гына кала.

1991 елда СССР рәсми рәвештә таркалгач, «Натиф»ның бурыч-максатлары да үзгәрә. Хәзер аларның хезмәткәрләре талантлы яһүд яшьләрен генә «чүпләп» тора башлый, шуның өстенә, Рәсәй галимнәре һәм белгечләре белән элемтә урнаштырып, фән өлкәсендәге алдынгы фикерләрне җыя, Рәсәйнең сәяси-икътисади хәлен өйрәнә, анализ ясый, аерым халык-милләтләрен өйрәнә, алар хакындагы мәгълүматны Израиль белгечләренә-аналитикларына тапшырып тора.

Израэль Исаевич соңгыларыннан иде. Фәнни институтта эшләү өстенә Воронов татарлар белән ныклы элемтәдә тора. Тормыш-яшәеш рәвеше бик тыныч кына барган кебек булса да, тыныч күлдә җеннәр үрчи дигәндәй, Израэль Исаевичның күлендә дә «шпион җен» утыра, ләкин аның күле бик тирән булып, «җеннәре» су өстендә күренмиләр иде. Әмма ул беркайчан да үзләренең яһүд авылындагы милләттәшләрен Израильгә күчерүне максат итеп куймады... Мондагы яһүдләрнең хатыннары татар кызлары булып, андый катнаш гаиләдә туган балалар исә интеллектуаль яктан да, талант ягыннан да калган милләтләрдән дә биш-алты башка өстенрәк торганлыктан, Израильдәге тормышны бик яхшы күз алдына китерә һәм берсенең дә палестиналылар, гарәпләр бомбасыннан шартлыйсы килми иде...

**Очты-очты... Авыллар очты, кешеләр очты...**

Иртәгә тау башында урын бүлешәсе дигән төнне халык йокламады, һәркемнең дә иң шәп урынны, иң шәп җирне эләктереп каласы килә иде. Вәлиев Сибгат хатынының колагына кат-кат тукыды: тау башында андый-мондый берәр ызгыш-талаш кебек нәрсә чыга калса, уяу булып тор, янәсе, этне бәйдән ычкындырырсың, дип кисәтте. Фермадагы өч үгезне урлатканнан соң, элеккеге каравылчы Мирхәйдәр кечкенә гәүдәле чәңгелдек этенең муенына таш бәйләп су астына җибәрде дә каладан зур овчарка сатып алып кайтты. Дөрес, Әкбәров аңа үгезләрне гафу итте итүен. Тик бер шарт белән: иреннән тол, Барыйдан көмәнле калган мари хатыны Наташаны ул өенә алып кайтып утыртырга тиеш иде. Башы Себер китәсе килмәгәч, килеште Мирхәйдәр. Наташа белән бик тиз уртак тел дә таптылар. Мирхәйдәр тау башына менеп киткәч, Наташага да уяу булып торырга кушылды. Бу хакта күршеләренә сөйләп йөрмәсәләр дә, ир-атның барысы да өендә шундый әмер калдырды.

Алиханның әүвәл менәргә исәбе юк иде, кичкырын аларга Гаптегани килеп керде.

— Син нәрсә ятасың, яшьти?! Җирсез каласың киләме әллә! — диде ул, бусагадан атлауга. — Кайтканнар белән әрәмтамакларга эләксен дисезме иң яхшы җирләр?

Алиханның җавабы әзер иде:

— Мин мулла кеше бит, мәчет яныннан берәр урын калдырырлар әле.

— Нинди мәчет, дивана, — дип сүгеп алды аны Гаптегани, үз итеп, якын итеп. — Анда мулла гына түгел, поп та булачак бит әле. Поп кына да түгел, еврей мулласы да!

Бу хәтлесен уйлап бетермәгән иде шул Алихан. Ул кырын яткан урыныннан торып утырды да, күзләрен төбәп, Гаптеганигә карап утыра башлады.

— Шулай дисеңме, яшьти?

— Соң! Шулай булмый ни!

— Алайса менәргә кирәк, име!

— Син, яшьти, нәрсә саңгыраеп утырасың соң! Кендегең селкенә башламагандыр бит? — Ул аптырап Алиханның хатынына карады. — Нәрсә, селкенми торгандыр бит?!

Алихан хатыны ашыгып башын чайкады:

— Юк, юк, селкенми, Ходайга шөкер!

— Селкенмәсә, тор әйдә! Карале, мылтыгың барые синең, исәнме ул?

— Исәнен исән, атмый ул түлке.

— Атмаса атмас, барыбер ал син аны.

Сүз мылтык хакында киткәч, Алихан хатыны да кушылмыйча булдыра алмады:

— Сез нәрсә, җир өчен авылдашларыгызны атарга җыенмыйсыздыр бит?

— Җир өчен, мин сиңа әйтим, авылдашларыңны мылтыктан гына түгел... Туры килә калса, бомба белән дә шартлатырсың! Җир бит ул! Җир! Аңлыйсыңмы?!

— Абау, Гаптегани, ни сөйлисең син? Дөнья малы өч көнлек бит ул. Тегендә баргач, ничекләр җавап бирерсең?!

— Бирербез! — дип көлеп куйды ат докторы. — Мулла үзебезнеке бит, әйеме, яшьти!

Алихан аңа җавап биреп тормады, кендек турысындагы ябыштыргычының бер чите кубып маташа иде, ул баш бармагы белән шуны басып куйды да хатынына карап әйтте:

— Бурзайны бәйдән ычкындырсаң да ярый. Әгәр дә мәгәр тау башыннан минем кычкырган тавышны ишетсәң... Ни, яшьти, төнге һавада тавыш каты яңгырый бит ул, име?

Механик Батай малае Сары Абдул дуңгыз танаулы явыз этен үзе белән үк алып менгән иде. «Аудан кайтып килеш», — дип акланган булды ул. Тол хатын Әсманың кулында ике җәпле сәнәк иде. «Урам тулы эт, каршыңа килеп чыксалар!» — дип, ул да аклану җаен тапты. Телсез Габдеринең башсыз малае Габдулланың кесәсендә үзе ясаган пистолет, дары урынына шырпы күкерте генә булса да, ул каты шартлый иде. Ядрә урынына вак кадаклар кисеп тутырды.

Барый Әкбәров ул кичне авылда түгел иде. «Израэль Исаевич өйгә кайтмады», — дип, хатыны килеп әйткәч, ул шәһәргә чыгып чапты. Барый тиз генә Мөхәммәтне эзләп тапты. Тегесе бу вакытта иске татар театры янындагы затлы йорттан өч бүлмәле фатир алып, шунда күченгән иде. Мөхәммәтнең атна-ун көн элек Париждан кайтканлыгын белә, яңа фатирында да булганы бар.

Мөхәммәт Уразовка Луврдагы халыкара күргәзмәдә катнашу бәхете эләккән иде. Сиринә Самуиловна белән икесе бардылар. Һәм хәзер бөек рәссам Уразовның күкнең җиденче катында йөзгән көннәре.

Мөхәммәт өйдә булып чыкты, ике дус кочаклашып күрештеләр. Кунагы хөрмәтенә авылдашы затлы француз коньягы чыгарып утыртты. «Без моны тегендә стаканлап эчтек! — дип мактанып та алды Мөхәммәт. — Без дигәч тә... Почти мин генә инде. Бүтәннәр уймак чаклы рюмкадан гына сөзеп утыра. Ә бездә, татарларда, урыс холкы бит хәзер. Чиләкләп тондырабыз!» Чиләкләп эчкәне күренеп тора иде авылдашының, йөз-кыяфәте шактый таушалган. Гомумән, соңгы вакытларда ул мондый эш белән еш шөгыльләнә башлады. Кайтканына күпме гомер узды, Гөлчәчәге янына барып кайту түгел, хәтта шылтыратып хәлен белә алганы да юк, Париж хисләреннән һәм француз коньягыннан һаман айнып бетә алмый атаклы рәссам. Аның каравы Гөлчәчәк, ул кайтуга, Казанга үзе йөгереп килеп җитте һәм салмыш Мөхәммәтнең Сиринә Самуиловна белән кочаклашып подъездга кереп киткәнен читтән качып күзәтеп торды. Кыз ул вакытта Мөхәммәтнең Сиринә Самуиловна белән бергә тора башлаганын белми иде әле. Әнә хәзер дә ишектә Сиринә Самуиловна иде, кулында хуҗалык сумкасы, күрәсең, «яшь хатын» якын-тирәдәге кибеткә генә чыгып кергән булгандыр. Мөхәммәт Уразов үзенең ничек өйләнгәнен үзе дә сизми калды бугай. Ләкин Барыйның бу хакта төпченеп сораштырып торырга, кызыксынырга вакыты да, андый кәефе дә юк иде. Ул мәсьәләне Сиринә Самуиловнага аңлатты, Мөхәммәт, дусты килгәч, янә ярты тустаган коньяк чөмерергә өлгерде бугай, бөтенләй җебеп төште. «Француз коньягын стаканлап эчәрлек булгач, әйбәттер инде...» — дип уйлап куйды Барый. Сиринә Самуиловна каядыр, кемгәдер шылтыратты һәм: «Вороновың биш минуттан монда булачак!» — диде. Шул арада Сиринә Самуиловна Барыйга Мөхәммәттән дә зарланып алырга өлгерде. «Эчә башлады! — диде хатын, йөзенә канәгатьсезлек чыгарып. — Шулай инде ул, татар аз гына талантлы булса, башын тизрәк аракы мичкәсенә тыгарга ашыга! Югыйсә үзен Франциягә даими эшкә чакырырга торалар, әсәрләрен бик ошаттылар». Барый аңа каршы бер сүз дә әйтмәде. «Эчеп ала да Гөлчәчәгем, дип елый. Нинди кыз булды соң ул шулхәтле?! «Урман кызы» портретына бөтен Париж шаккатты. Зур акчалар тәкъдим иттеләр, сатмады үҗәт татар!» Барый бу юлы да елмаеп кына куйды. Анысы да көчәнеп кенә елмайды. Югыйсә үз хәлләре дә көләрлек түгел, Зәринә белән буталуы Гөлйөземгә барып ишетелеп, тегесе хәзер, ул офыктан күренүгә, капкасын ук бикләп куя. Үзе генә түгел, ничектер дөньясы да чуалып китте әле, җепнең очы югалды. Аны кайдан эзләп табасы булыр?..

Израэль Исаевичны курыныгсызлык комитетына чакырганнар иде. Ул бу хакта җәелеп сөйләп тормады. Шулай да кайтып җитәр алдыннан әйтеп куйды: «Мөгаен, китәргә кирәк булыр...» Эшнең нидә икәнлеген күңеле белән сизенгән Барый кызыксынып сорау бирүне килештермәде. Чынлыкта исә Мәскәүдә Вороновның туганнан туган энесен шпионлыкта тотканнар иде. Җепнең очы нәселләренә дә килеп тоташты.

Воронов язылачак хезмәтенең соңгы җөмләсен көндәлегенә йөртеп куйды: «Татарлар — борынгы милләт. Берничә гасыр ул үзенең «кортлык чорын» кичереп, йокымсырап утырды.

Хәзер әлеге уңдырышлы җирдә бәрәкәтле орлыклар тишелеп чыгып, алардан яшь үсентеләр китте һәм болар инде, тамырланып, ныгып, кояшка таба үрелделәр.

Алар тарихында зур хата-ялгыш гамәлләр дә, бөек эшләр дә бар. Хаталарыннан арына-арына (туган телләрен үстерү, аның кулланылыш даирәсен арттырып, туган телне милли университет аша (анда шәрык факультеты да булдырып) фәндә раслау, бер-берсенә булган хөсетлек, көнчелек, әләктән арыну, һәр милләттәшләренә дә ярдәм кулын сузып яшәү, катнаш никахлардан саклау) алар киләчәккә ныклы адымнар белән барырга мәҗбүр. Бу — котылгысыз. Башка юл юк. Калган юллар упкынга илтәчәк!»

### Тау башында ай сүнгән...

Тулган айның тау башында утырган чагы...

Астан, Байтимердән караганда, чынлап та, нәкъ тау өстендә утырган кебек күренә ул. Йолдызларын ияртеп, төнге җиһанны күзләп йөри-йөри, әйтерсең арып киткән дә монда тукталып чак кына ял итәргә уйлаган, тау башында утырып тора... Шул чакта бик күпләр айны, таудан тәгәрәтеп төшереп, абзарларына бикләп куярга хыялланалар. И! Шуннан соң бар дөньядан алар капка төбенә халык җыелыр иде! Акча түләп айны тотып карарга чират торырлар, бер генә нурын булса да зур бәһаләргә сатып алырга хыялланырлар; адәм сукмагы гомергә өзелмәс иде капка төпләреннән!.. Ә ай урынына, тау башына, бик көчле прожекторлар менгереп куярлар иде! Соң... шулхәтле акчаларга...

Бу хакта бигрәк тә Садыйк Сираевич хыялланырга ярата. Байтимер аша төннәрен мари урманындагы үзенең умарта бакчасына узып йөргәндә килә иде аның башына мондый тәмле уйлар... Менә дигән туристлык бизнесы оештырып җибәрер иде ул аннан соң!

Әлбәттә, монын көлкеле, тормышка ашмас җүләр хыял икәнлеген яхшы белә Садыйк Сираевич. Элек ул эшләгән җүләрләр йортындагы авырулар башына да килмәслек тиле хыял бит инде югыйсә. Юк! Адәм баласын хыялланудан беркем дә тыя алмый! Бик тәмләп хыяллана ул һәм шуннан әйтеп бетергесез ләззәт таба... Садыйк Сираевичның бу дөньяда бар нәрсәсе бар, һәммәсе җитеш, кызы да кияүгә чыгып куйса... Тулган айны да үзенеке итсә әгәр... Менә малай гына... Ни хәл итмәк кирәк!

Тау башында утырган тулган ай аныкы булсамы? Садыйк Сираевич, татлы хыяллардан ләззәтләнеп, күзләрен йома, янәшәсендә утырган китек колаклы этенең башыннан сыйпый, шоферына нииндидер җылы сүз әйтмәкче була, ләкин капылт кына әлеге фикереннән кире кайта. Этенең колагы китек. Урманда бүре токымлы усал эт белән сугышкан. Колагын өздерсә өздергән, әмма бирешмәгән. Хәер, соңыннан дуслашып та алганнар бугай.

Алар умарталыкта вакытта бүре токымлы җан иясе агачлар арасыннан сыртын күрсәтеп-күрсәтеп ала, ләкин якын килергә курка. Аның Казбегын эт телендә үз янына дәшеп китерә, шуннан соң алар беркавым югалып торалар, уйнап туйгач, теге эт җан Казбекны хуҗасына китереп тапшыра. Адәм акыллары бар диярсең, билләһи!..

Тулган айны тау башыннан тәгәрәтеп төшерәсе иде дә, «джип»ка тагып, өйгә алып кайтып китәсе иде! Бар халык шаккатсын, көндәшләре ачуларынан шартласыннар иде. Хәзер халыкны байлык белән кызыктырып булмый. Халыкның күпчелеге шыр хәерче, шуңа күрә аңламый. Фикердәшләре исә үзләре дә бай. Алар аңлый микән, ә? Хәер, ул үзе аңлыймы соң?! Атасыннан калган мал түгел бит. Карт бабасы батрак булган, атасының атасы көтүче, атасы исә гомер буе ат җикте. Нәселдән килә торган байлык булса, бәлки, аңлар иде. Әүвәлрәк, төрле хәйлә-мәйләләр белән мал туплаганда, хөкүмәттән урлаганда, ул бер дә бер көнне боларны югалтырмын да ыштансыз калырмын дип курка, һәрхәлдә, җанын андый куркыныч хис туктаусыз кимерә, көн саен бер баш калкытып ала иде. Хәзер ияләнде инде. Әйтерсең ул җиде бабасыннан калып килгән мал хуҗасы. Гәрчә аларны яңа байлар дип йөртсәләр дә, атасалар да. Тау башыннан аның янына тәгәрәп төшәчәк ай кебек, байлык-муллык аңа көтелмәгәндә ишелеп килде. Ул аны ычкындырмас өчен кул бармакларын гына түгел, ирешкән нигъмәтенә аяк тырнакларына чаклы батырды, ычкындырмаска!.. Бүлешмәскә! Мәдәнияткә, дин юлына, милләт эшенә сарыф итмәскә!

Хәерче баеса, чабатасын түргә элә. Ул рухият эшен кайгыртып йөрүчеләр белән сөйләшеп тә тормый. Аларны бөтенләй кешегә санамый. Татар баеса, хатын алыр, ди. Садыйк Сираевич үзенчәлекле татар булып чыкты, хатынын аермады, болай гына типтерде. Менә хәзер дә умарталыктагы мунчасына арка ышкытырга барышы иде.

Тау башындагы төнге тавышларны ишетеп, Садыйк Сираевич шоферына туктарга боерды. Аның аен урларга менгәннәр мәллә?

Чыннан да, бу вакытта тау башында хәлләр башлана башлаган иде.

Тау Байтимер ягыннан менгәндә генә текә булып, ары таба иксез-чиксез тигезлек китә, тауның аргы ягы юк — аңа менәсе дә шундук капылт төшәсе түгел, җәйрәп яткан болын чакрымнарга сузыла һәм бары Казан читенә җитәрәк кенә ул, чак кына чүгеп, Казансу елгасына барып тоташа. Анда менеп баскач, артка, Байтимер ягына борылып карамасаң, тау икәнлеген дә белмәссең. Ләкин ни генә әйтсәң дә, тау башы тау башы инде, туфрак һәр урында да бертөсле генә түшәлмәгән: кара җирләре бар, комлысы, арырак киткәч исә ташлы һәм чокырлы-чакырлы урыннары күбрәк очрый. Тауның Байтимер ягындагы битен артыш куаклыклары чолгап алган. Челтерәп чишмә тибеп утырган җирләр дә шактый очрый. Кем әйтмешли, һәр калҗа да майлы түгел иде шул.

Үзенең яхшы, иң уңдырышлы җирләреннән урман-чытырман арасына куылганына инде гасырлар узуга да карамастан, халыкның хәтере тарих төпкеленнән үк килә, җир аның өчен бердәнбер яшәү чыганагы, кыскасы, җир җир инде ул...

Җир өчен булган зур гаугаларны, дәһшәтле сугышларны тулган ай да хәтерли... Кая хәтер генә! Җир өчен, аның мае өчен җирдәге адәм балаларын, бар тереклекне Ходайның шул ук бәндәләре йөзәрләп-меңәрләп җир куенына озата барган бер замандамы! Җир өсте бомбалардан шадраланып беткән замандамы?!

Шул дәһшәттән ай кызының бер күзенә ак төште, чиләгендәге суы болганчыкланды, хәзер еш кына чайпалып та куйгалый... Цунамилар шул сәбәпле килеп чыга!

Бер аршын җир өчен туган белән туган ызгышты, илләр белән илләр чәкәләшеп, җир өстен кан елгаларына батырып бетерде...

Җир өченме?! Җир өчен кешеләр генә түгел, авыллар, шәһәрләр юкка чыктылар, җир йөзеннән югалдылар, беттеләр, очтылар!..

Дин йортының дивары өелеп, түбәсе ябылган инде. Гаптегани Алиханны туп-туры шунда таба алып китте.

— Синең урының Алла йорты янында булырга тиеш. Ә мин, синең яшьтиең, күршең булам, — диде ул.

Алар казык кагып әвәрә килеп йөргәндә, яннарына Батай малае башсыз Абдул килеп җикеренергә кереште:

— Нишләп әле сез, кеше котыртып, казык кага башладыгыз?! Менә, пример, мин казык та алып менмәдем, балтам да юк.

— Күңеленә ошаган җиргә сузыл да ят! — дип әче теллеләнде Гаптегани.

— Минме, мин сузылып ятыйммы?! Син мәчет янындагы иң шәп җирне эләктергәнне яткан килеш карап торыйммы?!

— Баскан килеш карап ят!

Сары Абдул, Алиханның мылтыгын күреп, аңа бәйләнергә кереште:

— Ни эшкә син монда мылтык алып мендең әле, мулла абзый, ә?

— Атмый ул.

— Тем более?! — Сары Абдул авызыннан аңкып самогон исе килә иде. — Атмаса, күтәреп йөрмәсиең син аны! Ата торган мылтык ул. Белдеңме!

— Юк, дим бит, атмый, дим! Ник шул агач мылтыкка бәйләндең соң?

— Мин бәйләндемме! Мин бәйләнмәдем! Менә хәзер, шул мылтыгың белән айны атып төшеримме соң? Атып төшерәм бит!

Абдул җирдә яткан мылтыкны җәлт кенә кулына алды да Айга төбәде, һәм аннары күгәреп беткән чакмасына шарт-шорт баскалый башлады. Мылтык чынлап та атмады. Ул, гарьләнеп, мылтыкны читкә томырды. Урыс-француз сугышында катнашкан иске мылтык чык итеп җирдә яткан таш өстенә төште һәм гөрселдәтеп атып та җибәрде. Тулган ай Байтимергә таба тәгәрәп төшеп киткән кебек булды, беркавым колаклар тынып торды, ләкин тынлык озакка сузылмады, кемнеңдер: «Аллай! Үтердең бит!» — дип кычкырган тавышы тау башын янә бер кат сискәндереп җибәрде. Ядрәләрнең берсе Сибгатнең аягына эләккән, «үлдем» дип кычкыручы да шул үзе иде. Бу вакытта, күңеле сизенепме, Сибгатнең хатыны, бозау чаклы этен бәеннән ычкындырып, капканы ачып маташа иде. Мылтык гөрселдәгәнен һәм шуның артыннан ук кычкырышкан тавышлар ишетеп, хатын үзе дә эт артыннан йөгерде! Бозау чаклы этнең калын тавышы башка хатыннарны да аякка бастырды: акчага сатып алынган явыз этләрнең барысы да бәйдән ычкындырылып, капкалар киерелеп ачылды...

Этләр белән этләр, кешеләр белән кешеләр бугазлашып, тулган айның ак йөзенә өч кенә тамчы кып-кызыл кан чәчрәгән бер мәлдә Барый Әкбәров машинасы авыл башына килеп керде.

Садыйк Сираевич халык җыелган урынны, ыгы-зыгы, шау-шуны гомумән яратмый, шуңа күрә ул шоферына кузгалырга боермакчы булып, муенын борган иде, Казбегының багана төбендә аяк күтәреп алырга төшкән җиреннән юкка чыкканлыгын шәйләде дә машинадан төште. Эт җан тирә-юньдә дә күренмәде. Садыйк Сираевич хафага төшмәде, артык борчылмады. Белә бит ул: аның этендә адәм акыллары бардыр; бер сызгыруга, йөгереп килеп җитәчәк иде Казбек.

Әмма Казбек чынлап та эт җан булганлыктан, ерактан ук таныш исне сизеп алып, шул тарафка таба йөгерде. Машинада селкенеп йөри-йөри тәмам туйган, алҗыган, ләкин бу хакта хуҗасына теле белән генә аңлата алмый, шуңа күрә кылган гамәле белән төшендереп бирсен әле. Элеккеге танышы Пират белән бераз уйнаклап алырга да җай чыгып тора менә; бүре токымлы урман эте, Казан кунагы килгәнлеген әллә каян белеп, бая ук үзенең янәшәдә икәнлеген сиздергән иде. Казбек, хуҗасы туктап торган арада, җәһәт кенә шул тарафны урап килергә булды. Күптәнге дуслар иснәшеп күрештеләр. Тик Пират нишләптер борынын капылт читкә алды: Казбектан дары исе килә иде. Хәер, ул каян белсен: Казбек машинаның арткы утыргычында хуҗасының бүре ядрәсе белән корылган ау мылтыгы белән янәшә килде ләбаса. Казбек үзе бу искә күнеккән, ә Пиратның мылтык исен җене сөйми, аны сагаерга мәҗбүр итә. Әмма Пират «төпченеп» тормады, Агаякны ияртеп, эт тавышлары килгән тарафка — тау башына йөгерде. Алар артыннан тагылмыйча Казбекның башка чарасы калмады. Этләр менеп җиткәндә тау башы Бородино кырына охшап калган, кешеләрне талап, тешләп, җәрәхәтләп бетергәннән соң, бәйдән ыч-

кынган усал этләр, үзара әүмәкләшергә керешеп, тулган айның котын алырлык дәрәҗәдә чинаша-өрешәләр иде.

Пират, мондагы канлы бәрелешне күргәч, тулган айга карап уларга кереште. Эттән туган бүре тавышы тау башын сискәндереп куйды.

Киемнәре теткәләнгән һәм кайсыдыр бер усал эт тарафыннан уң кулының ике бармагы чәйнәлгән Сәмигулла бу вакытта, шыбырдап аккан канга да игътибар итмичә, авылга төшеп, үзенең Барсын ычкындырды. Улерактан ук Әкбәровның килгәнен күреп алды һәм, тиз генә артыш куагы артына посып, этен Барыйга таба өстерде...

Садыйк Сираевич, дәшеп-дәшеп тә Казбегы янына килмәгәч, мылтыгын кулына алып, шаушу килгән тарафка — тау башына менеп китте һәм, берара узуга, колагына Казбегының — кыйммәт бәягә Мәскәүнең үзеннән сатып алып кайткан этенең! — ачыргаланып чинаган тавышын ишетте дә, уйлап-нитеп тормыйча, әүвәл һавага атты, аннан соң кая төбәгәнен үзе дә белештермәде.

Казбек — Мәскәү эте — чит кешеләрне сөйми иде. Дөресрәге, аны яшьтән үк шуңа өйрәттеләр, Бу холкы аның хәтта ерак бабаларыннан ук килә иде. Буыннан буынга дәвам итеп, нәселдән нәселгә күчте... Дөньяда аның өчен үз хуҗасы һәм берничә ияләнгән кешесеннән башка калган адәмнәр кан дошманнар. Ул тау башында әрле-бирле чабышкан хатын-кызларга ташланды. Аларны талап, тешләп, киемнәрен аерганнан соң да кайнарлыгы сүрелмәде Мәскәү этенең. Шул уңайдан ул янәшәсендәге Агаякны буып ыргытты. Моны күреп торган Пират, бүре токымлы безгә яхшы таныш урман кыргый җанвары, Мәскәү этенә сикерде.

Этләрнең көче бер караганда тигез иде кебек. Менә беркавымнан хуҗасы янында прәннек кенә ашап яткан Мәскәү этенең хәле бетә башлады. Урман-кырлар баласы, ирек һәм азатлык сөйгән бүре токымлы эт, инде яше хәйран булуга да карамастан, Мәскәү этенә караганда тәҗрибәлерәк тә, елгыррак та иде.

Шул арада алар янына Сәмигулла эте дә килеп басты. Ул, артыш куагы төбендә бер адәмне тәгәрәтә-тәгәрәтә талап, бармакларын һәм кайбер башка әгъзаларын чәйнәп, инде күңеле тәмам булганның соңында, Пират тавышына менгән иде. Казбекка каршы алар хәзер икәү булдылар.

Казбек көньяк-көнбатышка — Мәскәү ягына карап, ачыргаланып чинарга кереште.

Тулган ай, бу мәхшәрне бүтән күрмәс өченме, үзенә таба болыт-пәрдәне тартып китерде.

Тау башында ут сүнде...

Мәчет-чиркәү-синагога шулай ук дөм караңгылыкка чумды. Ләкин беркавымнан анда ниндидер хәрәкәт башланды һәм, озак та узмады, дин йортыннан дүрт күләгә шуып чыкты. Әйе, әйе, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы булса да, күләгәләре шәйләнә иде аларның!.. Күләгәләр артыннан аларның ияләре — өч фәрештә һәм бер тәмуг кисәве пәйда булды. Алар, гәп корып җибәреп, үзара бәхәсләшәләр иде. Араларыннан нурлы вә сөйкемле фәрештә үзен бик горур, ышанычлы тота, һәр сүзе ташка басылган кебек һәм кире каккысыз. Ул:

— Бисмиллаһир-рахманир-рахим, — диде дә, җиде мәртәбә тын алып, моңарчы үзе яхшы инанган җиде төрле хакыйкый сүз-җөмләләр әйтте. Аннан соң балчыктан яратылган адәмгә сәҗдә кылды.

— Аллаһтан иңгән китапка гына табыныгыз.

— Юк, без аталарыбыз юлыннан барачакбыз.

— Сез Аллаһ әйткән дөреслекне яшердегез һәм аны арзан бәягә җибәреп көн итәсез. Сезнең корсакларыгызда ризык түгел, ялкынлы ут тулган. Кыямәт көне килеп җиткәч, сез әйткәннәргә табынучыларга Аллаһ тарафыннан авыр җәза биреләчәк!

Калган ике күләгә, ризасызлык белдереп, баш чайкадылар, күрәсең, каршы килмәкче булдылар.

— Әй сез, китап әһелләре, нигә бәхәсләшәсез? Ибраһим мәсьәләсендә, дим. Тәүрат та, Инҗил дә аннан соң гына иңдерелде бит! Шуңа да башыгыз җитмиме? Сез бит мөселманнарны, юлдан яздырып, алдарга телисез! Ләкин бит сез бу рәвешле аңламыйча бары үзегезне генә юлдан яздырасыз! Ибраһим христиан да, яһүд тә түгел ул. Ул Аллаһны бердәнбер дип танучы мөселман булыр.

Күләгәләрнең берсе кымшанып куйды һәм әйтте:

— Көндезен ышанган булыгыз да кичен аннан баш тартыгыз.

— Аллаһның юлы иң дөрес юл булыр. Тәүратка, Инҗилгә охшаш тәгълимат бүтәннәргә дә бирелә ала. Бу пәйгамбәргә ышаныгыз, монысына инанмагыз, — дип әйтүчеләр, иман белән кө-

ферлек арасындагы юлны сайлаучылар юкмы әллә? Шулар чын кяфер була да инде. Белегез, кяферләргә Аллаһ тарафыннан каты җәза әзерләнгән.

Тегеләр һаман каршы килеп маташтылар.

— Нигә килешмисез?! Яһүдиләр белән христианнар арасындагы барган тарихи сугышлар вакытында Инҗилегезне югалтып, буталып беттегез бит инде. Хәзер аны төрле рәвешләрдә шәрехләп маташасыз лабаса! Шундамы чын хакыйкать?!

Калганнар һаман килешмәде.

— Бүген кыямәт көне. Бу — гаделләрнең үз гаделлекләреннән файда күрә торган көн. Алар өчен гөлбакчалар арасыннан чишмәләр агып торучы җәннәтләр булыр. Аллаһ алардан бик канәгать, алар да Аллаһтан разый һәм аңа рәхмәтле!..

Калган ике төнге күләгә каршы килә алмадылар...

Тәмуг кисәве — Иблис — моңарчы сүзгә катнашмый тора иде. Аңа шулчак: «Адәмгә сәҗдә кыл!» — дип әйтелде. Ул каршы килеп баш тартты. Үзенчә дәлиле дә бар иде: «Мин Адәмнән яхшыракмын. Мине уттан-ялкыннан яраткансың. Аны исә балчыктан». Аңа әйтелде: «Бәс, җәннәттән чык! Инде син, шик-шөбһәсез, ташлар белән атып сөрелгән мәлгуньсең. Һәм, әлбәттә, җәза-кыямәт көненәчә сиңа барысының ләгънәте булыр!»

Шул рәвешле Иблис көферлек җәтмәсенә эләкте, Ходайның бәддогасына тарыды, мәңгелек җәһәннәм — тәмуг кисәвенә әверелде. Иблиснең нәсел-кабиләсе аңа тәлинкә тотучы җеннәр, шайтаннар, кешеләр вә хайваннардан гыйбарәттер. Шайтаннар аеруча куркыныч: алар бәндәләрнең, төп эшләреннән читләшеп, башка мөһимсезрәкләре белән михнәт чигүләрне хуп күрә. Аяныч ки, күпләр моны аңламый, илаһи вә шайтани гамәлләрне аермый. Әмма аларның хәленә керергә дә мөмкин, чөнки шайтан мәлгунь хәер хаһлыкның җитмеш ишеген ача да, гаҗәп, алар аша бәндәне, аңа һич сиздермәстән, яманлык һәм фәсадлык ишеге бусагасына китерә дә бастыра. Чөнки ул Иблиснең һәр әмерен төгәл үтәп баручыдыр. Ә Иблис — тәмуг кисәве. Ул — явыз. Аның чын йөзе түбәндәгеләрдән гыйбарәт булыр: исеме — Иблис, шәһәре — ваемсызлар күңеле, даими хәят урыны — тәмуг, мал-мөлкәте — буш хыяллар, мәҗлесе — базарлар, сәфәрендәге дошманнары — мөселман татарлар, шөгыле — әхлактан яздыру, төс-кыяфәте — төсен үзгәртүче кәлтә елан, яраткан хатыннары — ярым-ялангач киенгәннәр, йорты — бәдрәф вә мунчалар, табигате — аумакайлык, дөньяга килгән көне — Адәмгә сәҗдә кылудан баш тарткан көне, дус-ишләре — икейөзле бәндәләр, дине — көферлек, дәһрилек, вазифасы — Аллаһ хозурында булганнарның баш хуҗасы, хезмәт вакыты — кыяматкә кадәр, сәфәр дуслары — җеннәрдә, шайтаннар — бәндә сурәтендәгеләр, курыкканы — дога, җәтмәсе — хатын-кыз, яраткан шөгыле — ир-атның — ирләр, хатын-кызның хатыннар белән җенси мөнәсәбәтләре.

Дин йортында янә шау-шу купты. Озак та узмады, аның морҗасыннан, утлы төтен булып, ике шайтан бөркелеп чыкты һәм, җиргә төшеп, кагынгандай итенделәр. Шайтаннарның берсе телгә килде:

— Фәрештәләр китте. Фәрештәләр булмаган җирдә без үрчибез!

Икенчесе аның сүзләрен җөпләп тормады, үз уен әйтте:

— Ник шаулашты болар бик каты?!

— Адәмнәр, гадәттә, ике очракта бер-берсенең бугазларына ябыша: хатын-кыз, җир яки акча-байлык бүлгәндә!

— Һәм милли хисләренә кагылсаң!

— Әйе, Иблиснең исемлегендә татар аерым графада тора, мишәр аерым графада, үз күзләрем белән күрдем. Димәк, алар аерым милләт! Шул исемлекне без шыпырт кына антропология институтына илтеп бирдек! Мәскәүгә үк! Директорның өстәлендәге исемлекне алыштырдым да куйдым. Ул моны үзенең исемлеге дип уйлап йөри. Ха-ха! Директор чаклы директор шайтан коткысы белән йөрсен әле! Кемнәрне генә юлдан яздырмыйбыз без, ахири, ә!..

— Укый белмисең бит син!

— Һа, белмәс сиңа! Мин ун ел буе Казандагы татар гимназиясендә укучы кызларны тәмәке тартырга юкка гына өйрәтеп йөрдеммени! Грамотаны да шунда эләктереп калдым!

— Ярый, бүтән йөри алмассың! Татар гимназияләрен ябалар ди анда. Мәскәүдән берәү Казандагы берәүнең колагына шулай дип пышылдаган.

— Ул Мәскәүнең берәве, бик беләсең килсә, мин булырмын! Мәскәү чиновнигына әвереллдем дә... пышылдадым инде колакларына! Чөнки мине настоящий чиновник дип кабул иттеләр!

— Хе, алайса, ул гимназияләре дә шайтан коткысы белән генә ябыла микәнни?!

— Шулай булмый ни! Менә үзеңнең дә башың эшли икән бит!

— Нәрсә көлгән буласың?

— Ник миңа төртәсең?!
— Йә, ярый, безне алда зур эшләр көтә. Безгә ачуланышырга ярамый.
— Адәмгә әверелгәч тә, тукмашырга өлгерерсең әле дисеңме!
— Шулай булмый ни!
— Баш түгәрәк синең!
— Әйе шул. Чү, тукта, адәмнәрчә сөйләшә белергә дә өйрәнергә кирәк сиңа! Адәм кыяфәтенә кергәч, нинди шартларга эләгәсең бит әле! Мафиозникларына тап булсаң...
— Ә мин сихер белән җиңәчәкмен!
— Җиңүен җиңәрсең анысы. Тик сөйләшә дә белергә кирәк! И крыша кирәк!
— Крыша? Анысы ни тагын?
— Крыша там, наверху!
— Син нәрсә, хочешь сказать, что у меня крыша поехала?! Тагын мыскыл итәргә керештеңме! Мин! Сине хәзер!
— Йә, йә, тынычлан! Мин алай димәдем бит әле! Баклан ты, понял?
— Баклан?
— Әйе, мин сиңа хәзер адәмнәр арасында, бигрәк тә яшьләр арасында еш кулланыла торган сүзләрне өйрәтәм. Баклан аңгыра кеше дигән сүз була.
— Баклан — аңгыра. Аңладым, тагын?
— Жопа на два базара — икейөзле адәмгә шулай дип әйтәләр.
— Один базар, два базара и... и-или-ии... одна жопа, да?
— Да, да? Гринь — доллар!
— Аhа, доллар.
— Дичь — ямьсез хатын кыз.
— Ә нормальный кыз?
— Тема... Кыз «тема» була.
— Профессор әфәнде, сез бүген нинди тема өстендә эшлисез? Ха-ха!
— Чымерь — начар адәм.
— Чымерь! Фу! Чымерь!
— Шнурки в стакане.
— Анысы ни тагын?
— Әти-әниләр өйдә дигән сүз.
— Шнурки! Ха-ха!
— Доить самовар.
— Самовар доить? Бәлкем, сыердыр ул, ә?
— Юк, сыер түгел. Әтидән акча сорау дигән мәгънәне аңлата. Тагын менә «лечить» дигән жаргон.
— Дәвалаумы?
— Лечить, ягъни акыл сату. Йә, шулары җитеп торыр сиңа. Боларның һәммәсен Иблис агаң үзе уйлап чыгарды да ярдәмче шайтаннары аша кешеләр арасына кертеп җибәрде.
— Карале, әгәр дә Иблис кушканны башкара алмасак, безгә нинди җәза булыр дип уйлыйсың?
— Ниди җәза? Хе... бернинди дә физик җәза булмаячак. Просто Иблис безне эштән генә куачак һәм гомерлеккә кешеләр арасына җибәрәчәк. Шайтан итеп түгел, ә менә кешегә әйләндереп!
— Ә минем кеше буласым килми! Килми!
— Минем дә килми! Чибәр хатын-кызны бүлә алмыйча, кем беләндер пычакка-пычак киләсем килми! Власть, дан-дәрәҗә өчен сугышып канга батасым килми!
— Тормыш алып барам дип, борыным белән җир сөрәсем килми!
— Йә, булды, чинама! Әйдә лучше кеше булырга өйрәнә торабыз. Иначе безгә шунсыз булмый. Алар арасында яшәргә дә кирәк бит әле.
— Бу нинди шешә? Аның эчендә нәрсә бар?
— Аракы!
— Аракы?!
— Безнеңчә әйтсәк, шайтан суы. Без гомер буе адәмнәрне шуны эчәргә котыртып йөрдек, нәрсә, оныттыңмы әллә: сихер көчебез кимегән очракта адәмнәрнең авызларына аракы гына коя идек. Сихереңдә кирәк түгел, шундук бер-берсе белән талаша, сугыша башлыйлар иде.

— А как же! Хәтерләми ни! Күпме гаиләләрне җимердек! Күпме юньле кешеләрне юлдан яздырдык, шул үзебезнең шифалы су ярдәме белән! Хәзер үзебезгә дә эчәргә туры килә инде.
— Ә эчкәннән соң нишлибез?
— Нишлибез? Нәкъ кешеләрчә эшлибез. Әүвәл җырлап җибәрәбез, аннан соң мактанырга тотынабыз, аннан соң инде сугыша башлыйбыз. Бер-беребезне тукмап туйгач, өйгә кайтабыз да хатыннарга бәйләнәбез!
— Ә ул адәм затларының хатыннары бер дә эчми микәнни?
— Ничек кенә эчәләр әле! Эчәләр дә үзләренең хуҗабикә икәнлекләрен бөтенләй оныталар!
— Ничек оныталар?
— Һай, бигрәк наивный инде син! Ничек онытсыннар инде?! Адәмнәрнең аракы эчәргә яраткан хатын-кызлары... даже... үзләренең... бер нәрсәләренә дә хуҗа була алмыйлар. Аңладыңмы?
— Аңладым, кәнишне! Хәтта үзләренең... менә... колак яфракларына кадәр хуҗа түгелләр уже, әйе бит?
— Соображаешь!
— Әйдә, әүвәл мактанышып алыйк.
— Бик рәхәтләнеп!
— Карале, минем, чынлап та, кеше буласым килми бит! Без аларны, без аларны унҗиденче елдан бирле бозабыз, котыртабыз бит инде! Алар арасында хәзер бездән явызраклары да күренгәли башлады бит!
— Әйе шул. Мин моның белән горурланам гына. Без Иблис агайның приказларын җиренә җиткереп үтәп барабыз.
— Әүвәл, кулаклар дип, иң уңганнарын, тырышларын җәһәннәмгә олактырдык. Аннары миллионлаган адәмнән «халык дошманы» ясаттык. Мин ул Сталин дигәннәренең җанына шундый ныклап кереп урнаштым ки, минем әйткән сүзләрнең һәммәсен карышмыйча үтәп барды.
— Ә мин аңарчы, Ленин дигәннәренең баш миенә кереп урнашып, күпме дөньяны болгаттым!
— Ә мин моннан соң иң дәү түрәнең аңына кереп урнашам да милләтләрне юкка чыгарырга боерам! Чөнки бу татар дигән адәмнәрдән тәмам туйдым. Коткыга бик авыр биреләләр.
— Ә мин аның язган указларын алып чүплеккә ташлыйм да өстәленә Иблис агай язган указларны салып торачакмын! Тик уйлап йөрсен мин чыгарган указ бу дип! Ха-ха!
— Әйдә, әүвәл эшне яшьләрне бозудан башлыйк. Аларны китаптан, әдәбияттан, сәнгатьтән, кыскасы, матурлыктан аерыйк. Телләрен кисик, дөресрәге, туган телләреннән мәхрүм итик! Шуннан соң алар үзләреннән-үзләре бозыла башлаячаклар! Күреп торырсың менә!
— Ә мин авылларны бетерттерәчәкмен! Аларның бар көчләре, әхлаклары авылларда иде элек! Хәзер без моңа таяк тыгачакбыз! Бар дөньясы шайтан коткысы белән яшәвен дәвам итсен!
— Дәвам итсеннәр!
— Карале, ә син чыбыркы шартлата беләсеңме соң?
— Нигә кирәге бар аның? Без көтү көтәргә бармыйбыз бит?!
— Кирәк! Коммунистлар халыкны сарык көтүенә әйләндереп бетергәннәр иде бит инде, хәтерлисеңме?
— Хәтерләмәгән кая ул!
— Һәм стукач көтүенә!
— Ә монысын хәтерләп торасы юк! Бүген шул нәрсә тагын кире кайтты бит! Понимаешь ты?
— Конечно, понимаю!
— Чү, нигә без капылт кына урысча сөйләшә башладык соң әле? Без татарлар арасына барабыз бит!
— Без урысча сөйләшмибез, без сүгенәбез!
— Как так?
— Татарча сөйләшкәндә урыс сүзләрен кыстыру ул сүгенү дип атала! Иблис аганың кешеләр өчен язган Әхлак кодексын оныттыңмыни! Анда шул хакта отдельный статья бар бит!
— Точно, точно, искә төште.
— Син хәзер кай тарафларга юл тотасың?
— Мин — Мәскәүгә! Президент папкасында яткан указ-күрсәтмәләрне, яңа законнарны Иблис агай биргән кәгазьләр белән алыштырып куясым бар!

— Син чамалап. Белә күрмәсеннәр!

— Чуртым да белмәячәкләр, моңа чаклы беркем дә сизмәде бит әле!..

Ике шайтан, кочаклашып, тау башыннан аска — Байтимергә таба тәгәрәделәр...

Моны күреп торган нурлы фәрештә тылсымлы дога сүзләре әйтте. Шул мизгел эчендә нурлар ишәеп, әүвәл биш миллион сөйкемле фәрештә пәйда булды, тора-бара аларның саны җиде миллионга җитте һәм беркавымнан фәрештәләр егерме миллион иделәр инде! Алар нәкъ татарлар кебек үк дөнья буйлап сибелделәр һәм һәр Алла бәндәсенә берәр фәрештә туры килергә тиеш иде.

Иман яңарту башланды. Хәзер бернинди иблис-шайтаннар да куркыныч булмастыр кебек иде инде бу Ходай бәндәләренә...

## Мөхәммәт һәм мәхәббәт

Тау башындагы хәлләрдән соң кала яны һәм шәһәр хастаханәләре яраланган, җәрәхәтләнгән байтимерләр белән шыплап тулды. Барый Әкбәровны Казанның үзенә үк алып киттеләр. Эт тарафыннан чәйнәлгән сул кулының бармакларын, уң колагы һәм башка әгъзаларын кире «терелтергә» кереште табиблар. Барыйның абыйсы Һади, Мөхәммәтне эзләп, Казанга китте. Чөнки энесенә җитди ярдәм, Мәскәүдән яки чит илдән зур белгечләр чакырту өчен Мөхәммәт элемтәләре кирәк иде.

Һади Казанга бер барды, икенче тапкыр чыгып китеп карады, ләкин Мөхәммәтне тапмады.

Атаклы рәссам бу вакытта, өендә бикләнеп, һаман да коньяк чөмереп ята һәм аның дөньялыкта кайгысы юк иде. Дөрес, кичтән ул матур уйлар белән эш бүлмәсендә яза башлаган картинасы өчен бар кирәк-яракларын, буяу-пумалаларын әзерләп, хәстәрләп куя да иртәгесен инде рәссам күңелендә таң атуга сүнгән ай кебек иҗат ялкыны сүрелгән була. Өйдә алар Сиринә Самуиловнаның эте белән икәү генә. Сиринә Самуиловна үзе командировкада, андый чакларда ул яраткан көчеген Мөхәммәткә кертеп китә. Чөнки аны песи янында калдырып китәргә шикләнә иде Сиринә Самуиловна.

Фатир ишеген берәүгә дә ачмады, телефонны исә өзеп үк куйды Мөхәммәт.

Бер дә бер көнне ул, иртән уянып, чәйнек борыныннан гына йотлыгып су эчте дә аптыраганнан эш бүлмәсенә керде һәм шулчак артына авып китә язды: кемдер аның өчен картинасын язып тәмам кылып куйган түгелме соң?! Ул аңа кичтән бер-ике сызык сызып, яхшырак күренсен өчен идәнгә сузып салган иде. Ләкин көймәсе комга терәлде, ул комны «юып» җибәрергә дип, кухняга чыкты һәм тутырып бер стакан җибәргәнен хәтерли. Тик шуннан соң эш бүлмәсенә башка кереп тормады бит инде?! Дөрес, ул әлеге рәсемнән бернәрсә дә аңламады, әмма монда Пикассо кулы уйнагандай иде! Мөхәммәт, гаҗәпләнүдән колакларын тартып, тәнен чеметеп карады — авырта, димәк, ул төш күрми һәм үз аңында... «Бәлки, галлюцинация башлангандыр?!» — дип куркынып уйланды ул, акылы шактый саф булуга да карамастан. Бәлкем, салган баштан кичә үзе нәрсәдер эшләгәндер дә бүген исә оныткандыр... Һаман да шул салган баштан инде?..

Мөхәммәт, аптырап, кухняга керде һәм ачык шешәдән чәшкегә коньяк агызды. Шул рәвешле баш шәрәфләрен майлап, фикерләрен кыймылдатырга, хәтерен кире кайтарырга иде исәбе. Ул янә курка-курка гына эш бүлмәсенә чыкты, бәлкем, теге рәсем бая күзенә генә күренгән булгандыр да хәзер исә ул юкка чыккандыр дигән уй белән атлады ул. Тик ялгышты, картинада бернинди үзгәреш юк, һаман да шул ук әллә нинди аңлаешсыз сызык-күренешләр!..

Ул, ике чигәсен кысып тотып, балконга чыкты. Шушы мизгелләрдә акылдан шашар хәлдә иде егет. Тик, бәхетенә, Сиринә Самуиловна кайтып керде, ул ишекне үз ачкычы белән ачып кергән иде.

Сиринә Самуиловна, картинаны күргәч, йөгереп диярлек килеп, Мөхәммәтне кочаклап алды.

— Ты мой гений! Ты — Пикассо! — диде ул, аның махмырлы йөзеннән үбә-үбә. — Бүген бит, бүген бездә халыкара күргәзмә ачыла бит! Тизрәк моны шунда илтергә кирәк! — дип, ул телефоннан шоферын чакыртып алды.

Ләкин... ләкин Мөхәммәт, һаман да берни аңламыйча, тинтәк башын тотып, диван читендә утыра иде. Әлбәттә, ул күргәзмәгә бармады, картинаны алып, Сиринә Самуиловна үзе китте. Ни генә әйтсәң дә, бүген француз белгечләре килеп караячаклар бит!

Мөхәммәт Уразовның соңгы эшенә зур бәя бирделәр...

Сиринә Самуиловна шул хакта кайтып әйткәндә, Мөхәммәт диван кырыена чүмәшеп йоклый иде. Дөресрәге, ул йокылы-уяулы, күзен ачып аягына да торып баса алмый, йоклап та китә алмый, башы исә комбайн кебек эшли, күз алдында әллә нинди кадрлары еш алмашынып торган төсле кинофильм. Алмагач бакчасында йөриләр икән, Гөлчәчәк белән икәүләшеп. Гөлчәчәк ап-актан киенгән, йөзе шат, бертуктаусыз сөйли, аннан соң капылт кына туктала да алар үбешә башлыйлар. Шулчак кинәт Мөхәммәт алмагачка әйләнеп кала, Гөлчәчәк тә алмагач булып янәшәсендә чәчәк ата. Ул алмагачтан тел белән әйтеп, каләм белән язып бетергесез якты нурлар сибелә, Мөхәммәткә рәхәт, ул ләззәтнең иң югары ноктасында итеп хис итә үзен. Гаҗәп дөнья, искиткеч матур Җиһан! Яшисе килә — сөясе, сөеләсе килә!..

Уразовның соңгы картинасына бер француз тәмам канықты, сатып алырга теләде, мин аны Луврга куячакмын, дип вәгъдәләр бирде. Тик моның өчен Уразовның рөхсәте кирәк иде. Мөхәммәт исә шул ятуыннан бүтән аякка баса алмады, ара-тирә аңын да югалткалап, бер авыз сүз дә әйтмичә, күзләрен түшәмгә төбәп ята бирде. Бу халәтенә икенче көн китте дигәндә, Сиринә Самуиловна табиблар чакыртты. Ләкин бернинди укол да, бернинди дару да егетне аңына китерә алмады. Сиринә Самуиловна үзе дә, якыннары да пошаманга төштеләр. Өченче көн булды дигәндә, ниһаять, аның күзләренә җан кергәндәй булып, ул бары бер генә сүз әйтте: «Гөлчәчәк...» Бу исемне ишеткән Сиринә Самуиловна чак кына артына авып китмәде. Эшне шундук төшенеп алды сизгер күңелле хатын һәм, бер-ике көн икеләнеп, вәсвәсәләнеп йөргәннән соң, катгый карарга килде. Мөхәммәтне югалтасы, Мөхәммәт Уразов атлы бөек талант иясен һич тә югалтасы килми иде сәнгать белгеченең... Әлбәттә, иң беренче чиратта, Сиринә буларак югалтасы килми... Аннан соң... Аннан соң Ходай каршында... Табигать-әнкә каршында көчсез һәм бер чарасыз икәнлеген аңлады Сиринә. Ләкин ул беркайчан да җиңелергә, ике кулын югары күтәрергә өйрәнмәгән иде. Ул моның вакытлы хәл икәнлеген белеп, тирәнтен аңлап эш итте.

Ишек ачылуга, Гөлчәчәкнең килүен сизеп алды Мөхәммәт. Әйтерсең өйгә гап-гади бер хатын-кыз түгел, бүлмәләрне тутырып, якты нур иңде.. Аның тавышы... Аның хәрәкәтләре... Аның бәләкәй кулын маңгайга куюлары!.. Аның... аның, сак кына орынып, кулын тотулары... Йа Хода! Син генә булса да ышан инде бу хәлгә! Юкса синең кодрәтең бит бу! Әйе, әйе, һич кенә дә башкача булуы мөмкин түгел... түгел!.. Мең кат түгел!!!

...Мөхәммәт Уразовны Парижга Лувр музеена эшкә чакырдылар. Сиринә Самуиловна Гөлчәчәккә дә виза эшләтеп алды. Озатырга да барды. Аның Мөхәммәт колагына гына әйтәсе бер сүзе бар, ул сүз түбәндәгедән гыйбарәт иде: «Син беркайчан да мине онытырга тиеш түгел! Син беркайчан да мине ташларга тиеш түгел! Без барыбер бергә булачакбыз! Аңлыйсыңмы?!»

Яраткан көчеген өенә алып кайтырга дип, Мөхәммәтнең фатирына кире кайткач кына этенең койрык очы һәм тәпиләренең буяуга каткан икәнлеген күрде Сиринә Самиуловна. Көчек Мөхәммәтнең эш бүлмәсендә, рәссам абыйсының картина язарга әзерләп куйган полотносы өстеннән узган (Мөхәммәт аны мольберттан алып, стенага сөяп куйган иде, ул шуып идәнгә төшкән), шул җәһәттән буяуга манылган койрык очын да болгап-болгап алган иде. Бу күренешләр Сиринә Самуиловнага нәрсәнедер хәтерләтте сыман. Ләкин ул озак уйлап тормады, астына нечкә пумала белән: «М. Уразов. «Через тернии к звездам», — дип язып куйды да аны күргәзмәгә илтергә әзерләде. Ерактан ук күренеп торсын өчен авторның исемен чекерәеп торган зур хәрефләр белән язды. Аннан соң кыра-кыра бик озаклап көчегенең койрыгын юды...

## Соңгы сүз алдыннан

Байтимернең тракторчы Галләм абзый Казандагы махсус хастаханәне бик озак эзләде. Көн кичкә таба авыша барганда гына тапты ул аны, Барый Әкбәров яткан палатаны да эзләп тапты карт. Тик кыяфәте авыру хәлен белергә килгән кешегә һич кенә дә охшамаган иде. Барый һаман урын өстендә. Сул кулының бармаклары бинтка уралган, билдән түбән өлеше ак җәймә белән капланган. Янында Һади абыйсы һәм Гөлйөзем утыралар.

Галләм карт килеп кергәч, икесе дә гаҗәпләнеп калдылар һәм, аптырашып, бер-берсенә карашып куйдылар.

Галләм карт уңайсызланып кына тамагын кырып алды да, Һадига карап:

— Син, Һади энем, белмисеңдер инде. Без менә алтмыш еллап инде кешеләрдән, авылдашлардан яшереп килдек... Безнең нәсел белән сезнең нәсел... бик якын туганнар бит! Әкбәр бабаң ягыннан... Әтине алып киткәч, мин бабагызга бик нык кисәтеп әйттем: «Безнең туганлыкны бездән соң килгән буын онытырга тиеш!» — дидем. Ул риза булды. Ул әтине... минем әтине... Бер сүз белән генә әйткәндә, ул бик нык үкенә иде. Әтине кире кайтарырга артыннан да йөреп

карады каравын. Тик эш узган иде. «Йөрмә, алайса, үзеңне дә утыртып куярбыз!» — дип куып кайтардылар аны районнан. Үзе сөйләде. Менә шул... без туганнар, кан кардәшләр...

Ул шул сүзләрне әйтте дә, Барый ягына таба күтәрелеп тә карамыйча ничек керде, шулай чыгып та китте. Бу мизгелләрдә Галләм картның кызы Зәринәне искә төшергән Барый Әкбәров эшнең нидә икәнлеген бик яхшы аңласа да, сүз әйтерлек хәлдә түгел иде. Әлеге сүзләрнең серенә төшенгән Гөлйөзем исә, көлемсерәп, башын чайкады. «Барыйның яшь сөяркәсе кан кардәш сеңлесе булып чыга икән, алайса», — дигән уй узды аның башыннан. Тик ул бу хакта әле һаман берни аңламыйча аптырап утырган Һадига сиздермәскә булды. «Ишеттерерләр әле, авыл халкының теле озын...» — дип көрсенеп куйды урман кызы...

## Соңгы сүз

Садыйк Сираевичны хастаханәгә барудан кызы Әлфия туктатты.

— Йөрмә! — диде ул. — Миңа андый кияү кирәк түгел инде хәзер.

— Нишләп, кызым?

— Он не мужик сейчас.

Бу минутларда Барый Әкбәровны катлаулы операция ясау өчен Мәскәүгә алып китәргә әзерлиләр, бәлки, Америка белгечләренең үк ярдәмнәре кирәк булыр әле, моны Мөхәммәт сөйләшеп киткән иде.

Мөхәммәт Уразов, Париждан шылтыратып, яшьлек дустының хәлен белешеп торды. Бу вакытларда Мөхәммәт үзе җиденче кат күктә йөзә, канатлары исә янында яшәгән Гөлчәчәге иде. Шулай беркөнне урман кызы, шаккаттыргыч сүз әйтеп, аның исен-акылын китерде!

— Карале, Мөхәммәт, монда талантның кадерен беләләр икән ич!

Әйе шул, беләләр, хәтта моны Гөлчәчәк тә аңлаган, бахыр. Алай гына да түгел: рәссам буларак, иҗат кешесе буларак Мөхәммәттә үз-үзенә ышаныч хисе уянды! Әлеге хис бу юлы аның үзенеке генә. Ул сәламәт һәм көчле иде. Әйе, әйе, нәкъ шул хис аны тагын бер башка күтәреп куйды, ул аның талант чәчәкләренә шифалы яңгыр кебек тәэсир итә, алар тагын да ачылып, тагын да матураеп киттеләр!.. Әлеге бөек хис — элек аны гел таптап, изеп, сытып киләләр иде — егеттә яшисе, иҗат итәсе килү теләген арттырды!.. Мескен укытучылар, табиблар, әдәбият-сәнгать әһелләре кайчан да булса бу хиснең тәмен сизәрләрме икән соң, ә? Аларның хезмәтләрен (бу төр һөнәр ияләренең хезмәтен югарыда кемнәр бәяләп утыра икән — шуны беләсе иде! Болар бит бәһасез һөнәр ияләре! Синең хезмәтең «өч» тиен, синеке «биш» тиен булыр дип, югарыда нинди адәмнәр исәпләп-санап утыра икән, ә?! Бу башка һөнәр ияләренә дә кагыла, урам себерүчедән алып мәшһүр академикларга чаклы!) чүпкә дә санамыйлар, кадерләре юк!.. Югыйсә болар балалар, яшь буын тәрбияли, шуларны дәвалый! Нәрсә, Рәсәйдә балаларның да кадере беттеме икәнни инде, Ходаем?!

Мөхәммәт әнә шулар хакында бик еш уйлана башлады. Әлбәттә, чит ил кешеләренең яшәеш рәвеше, гореф-гадәтләре аңа ят, сәер иде. Гомумән, ул монда үзен көн саен иртән тозсыз ботка ашаган кебек хис итә, туган җир сагындыра, нишлисең, туган җир барыбер кадерле шул... Шөкер, Гөлчәчәге үзе янында. Хатыны аның туган җиренең бар табигатен — мең яшәр имәннәреннән алып ак күлмәкле каен кызларына чаклы — үзе белән «ияртеп» килгән! Тагын шунысы шаккатмалы — туган җиреннән еракта, Татарстан дигән Ватаныннан шактый читтә, ул үзенең «коеп куйган» татар баласы икәнлеген ныграк аңлый башлады! Һәм ул һәр әсәренә милли сурәт, милли моң һәм шундый тагын әллә нинди төсмерләр бирергә омтыла. Французлар аның бу сыйфатын бик ошаталар, ул аларның бер дә эчләрен пошырмый, киресенчә, кызыксынуларын гына арттыра иде. Ләкин күршең алмагачы ботагында утырып сайрап, үз бакчаңа дан җырлап булмый. Мөхәммәт моны да яхшы аңлый. Тик әлегә ышаныч хисенең һаман арта, үсә баруы аны күбрәк тәэсирләндерә, ул хиснең тәмам ныгып җиткәнен түземсезлек белән көтә. Шуннан соң киләчәк гамәлләре хакында да ныгытып уйларга мөмкин булыр кебек...

...Бәгырьдән суырылып чыккан бер кошчык уктай зәп-зәңгәр болытларга таба атылды. Ул тургай баласына да охшамаган, сыерчык баласы да түгел, үзенә күрә бер аерым кошчык иде. Ул күз күреме биеклегендә күкләр белән хозурланып әйләнде-тулганды да, кинәт югарыга: аккош каурые сыман ак болытларга таба күтәрелә башлады. Күренеп тора: ул иксез-чиксез зәңгәр күк белән хозурланып туя алмый иде...

*Казан, 200*5

# КӘҖӘ ЙӨРИ КЫЕКТАН

Все бабы — дуры,
а мамы умные.

*Афоризм*

## «Мөгезсез үгез...»

«Ферма сыерларын каядыр урман арасындагы җәйләүгә җыеп алып киттеләр. Чит илдән нәселле сыерлар кайтарачаклар икән. Бу эшкә «Химполе» оешмасы үзе алынган. Колхоз да алар карамагында бит. «Квас» кына бирә торган сыерлар кайтартачакбыз, диделәр, ни әйтсәң дә, «химиклар» бит — булыр, булыр, Алла боерса... Бер ай узды, ике ай. Өченче ай китте дигәндә дә, сөт урынына «квас» һәм «пепси-кола» бирә торган нәселле хайваннар күренмәде. Англиядә ящур икән, тоткарлык бары шуның аркасында гына дип шәрехләде әлеге хәлне Галәветдин Минтаһирович. Югарыда ни әйтсәләр, шуңа ышанырга күнектерелгән халык «пепси» бирә торган сыерларны әүвәл бернинди шик-шөбһәсез көтте. Районның баш «химигы» әйткәч, сөт урынына сыер хайваны ничекләр итеп «пепси» бирсен инде дигән сорау белән дә үзенең башын катырып азапланмады — көтүен белде.

Ә Мишка кушаматлы үгезне сыерлар белән ияртеп җибәрмәгәннәр иде. Чөнки хуҗалыктагы сыерларның бердәнбер карап торган Мишкасы иде ул. Халык белән бергә үгез дә көтте.

Ферма бушап калгач, шәхси хуҗалыктагы сыерларның да хәле кыенлашты, чөнки моңарчы алар тагарагына да фермадан кайтып тора иде.

Көттеләр. Көтә торгач, иң беренче булып үгезнең тәкате корыды. Җитмәсә, хуҗалык сыерларының да аның янына тояк эзләре суынды; ни ашатырга аптыраган халык мөгезле эре терлекне сөт кәҗәләренә алыштыра башлады.

Бозаулар янындагы бер абзарда бәйдә торган үгез рәттән өч көн бертуктаусыз мөгрәде мөгрәде дә, ахыр чиктә чылбырын өзде һәм бозаулар абзарын җимереп керде. Бу вакытта фермада акылга бераз җиңелрәк, ләкин элек алдынгы савымчы булган Гайфә түти ялгызы гына иде. Үгезнең мөгрәвен өченче көн инде үзенчә башка нәрсәгә юрап йөргән Гайфә савымчы, тора-торып, ныклы фикергә килде: үгезнең «җиленнәре» тулган, савырга кирәк, юкса шартлап ярылачаклар! Әнә шундый изге нияттән үгез абзарының ишеген ачып җибәргән иде Гайфә савымчы.

Сырт сөякләре шартлап сынган айлык бозауларны икенче көнне үк каядыр юкка чыгардылар. Шул ачудан фермага бер төркем элеккеге савымчы апалар, җыелышып килеп, җинаятьче үгезнең ике мөгезен берьюлы тимер пычкысы белән кисеп аттылар. Ул таза гәүдәле, нәселле сыерга охшап калды. Гайфә савымчы аны бик кызганды, савып, хәлен җиңеләйтү теләге — баш миендәге бер «шаригы» салам арасына төшеп югалган тилемсә хатынның — һаман сүнмәгән иде әле».

Кәрим фельетонның соңгы җөмләсенә нокта куйды да мендәр астына яшерде. Бер ферма сыерларының юкка чыгуы турында аңа элеккеге коллегасы — район газетасы журналисты Садыйк сөйләп киткән иде. Куллары исән-сау булган Кәрим, мендәренә сөялеп утырган килеш, бу вакыйга нигезендә фельетон язып атты. Тик әүвәл кемгә укытырга? Кызына күрсәтергә уңайсызланды. Турыдан-туры район газетасына җибәрсә генә инде! Тик әүвәл... иң беренче хатыны Фәгыйләгә укытмыйча ярамас! Үпкәләве бар. Яраткан кешеңне үпкәләтү — гафу ителмәслек начар гамәлдер...

Бүген өйгә тагын соңлап кайтыр микән инде Фәгыйләсе?.. Тагын төне буе хатынын көтеп ятармы?..

## Минем әни бай хатын...

Кызның үз гомерендә беренче мәртәбә кибет киштәсенә тәртип белән тезелгән исәпсез-хисапсыз, төрледән-төрле уенчыкларны: буе ярты метрлап булган кызыл битле кыш бабайны, алсу йөзле кар кызын, бишектәге тере бәби чаклы курчакларны, гәүдәгә чын юлбарыс баласыннан чак кына кайтыш тагын әллә нинди җансыз җанварны, күз явын алырдай уенчык-муенчыкларны бер селтәнүдә идәнгә себереп төшерәсе килде. Алар матур иде, ялтыравыклы, затлы бизәкле иде, әмма һәммәсе җансыз, ясалма иде. Аларны беренче карашка гына чын дип уйлыйсың,

ясалма икәнлекләрен белгәч, шул алдануыңа хурланасың, бу дөньяның бар алдавыч ялтыравыгыннан үч аласы килә.

Кибеткә нидер алырга кергән кешеләр генә чын, тере. Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә дигәндәй, кибеттә бар да бар. Монда ашамлык-эчемлек тә, чүпрәк-чапрак та, тимер-томыр да сатыла. Бер түбә астына урнашкан бинаның икенче ишегендә саламнан коньяклы коктейль суырып утыру өчен кафе урнашкан, өченче ишек гап-гади ашханәгә алып керә. Арткы, аулаграк ягында менә дигән кунакханәсе бар.

Кызның әнисе шушыларның барысына да хуҗа. Ул әлегә кызын күрми, чүпрәк-чапрак бүлегендә таныш хатыны белән сөйләшеп торалар. Менә аны бер ир-ат кырыйга дәште дә, оятсыз рәвештә биленә кулын салып, колагына нидер пышылдады. Кыз үзе дә сизмәстән аларга якынайды. Әнисе әлеге ир-атны төртеп диярлек җибәрде дә: «Йөрмә монда», — дигәндәй, ачу белән кулын селтәде. Ләкин тегесе дә ниндидер үҗәт иде, һаман чыгып китми.

— Мине танымадың бугай син, Фәгыйлә? Казан кунагын сыйлаганда, мин дә барием бит. Исеме ничек иде әле ул түрәнең?

Фәгыйләнең бит алмалары әүвәл кыш бабайныкы кебек кып-кызыл булды, аннары әлеге төсне янәшә киштәдәге кар кызы йөзендәге алсулык алыштырды. Ул, җәһәт кенә барып, ике шешә аракы алды да теге бәндәнең кулына тоттырды.

— Йөрмә монда бүтән!

— Мин тагын кергәләрмен әле, Фәгыйлә, яме!

Кызга бу адәмнең сүзе дә, үзе дә шыксыз булып күренде.

Әнисе белән сөйләшкән хатынның йөзен күрүгә, кыз куырылып килде. Шул бит инде! Зарифә апа! Айратның әнисе ич! Бигрәк мөлаем апа инде ул! Ләкин шулай булса да, янына барып сүз кушасы, сөйләштерәсе килсә дә, ничектер шүрләтә. Усал хатын булмаса да, кыз аннан уттан курыккандай курка. Үзе якын итә, үзе курка! Бигрәк кызык инде! Малае, Айраты, тагын да кызыграк аның. Алар Айрат белән ун ел буе бер мәктәптә укыдылар, икесе дә Казанга барып укырга керделәр.

* * *

Әнисенең эшенә юкка гына килмәде кыз. Әйтәсе сүзе бар. Әмма ничекләр генә итеп үгетләсә дә, файдасы булмас шикелле иде.

— Әни, синең урыныңа үзем генә барыймчы, ә!

— Юк, юк, балам. Анда әллә кемнәр киләсе, ди. Берәр нәрсә булса, мине шул сәгатьтә үк эштән куачаклар. Үзең беләсең, кызым.

— Әни, дим, әллә үзең дә бармыйсыңмы соң? Кадалып китсеннәр!

— Кәримә, дим, кызым! Бу юлы бик зур түрә киләсе, ди. Сәгыйть Сәетович әтиең турында да сөйләшеп карармын, дигән иде.

...Әнисен ризалату файдасыз иде.

— Бар, кызым, өйгә кайт. Әтиеңнең тамагы ачкандыр. Берәр нәрсә әзерләп ашат.

Әнисен тагын күндереп булмады. Аптыраганнан гына килде, әтисе бит. Йөрмәсен әле әниең шунда, ди. Тагын казаннар килгән икән, ди.

Алар яшәгән бистәгә Казан кунаклары еш килә. Әллә инде хуҗалары Сәгыйть Сәетович шулай бик кунакчылмы соң? Әллә кунакларга Сазлык елгасының суы ошый, әллә елга ярында ук салынган мунча-сауна күңелләренә хуш киләме икән? Әнисе шулай ди бит. Яртышар көн мунчада яталар яталар да аннары ашап туя алмыйлар, ди. Хәер, әнисе әйтмешли, алар зур, укыган кешеләр инде. Казанда вакытта шулай мунчалар кереп йөрергә кайдан вакыт тапсыннар соң?

Анысы да монысы, Сәгыйть Сәетович бик юмарт кеше, көне-төне шуларны сыйларга булышкан өчен әнисе уч тутырып акча алып кайта. Акча капчыгының авызы казаннар кулында икән, ди. Шуларның күңелен күрә алгач, Сәгыйть Сәетовичның да эшләре гөрләп бара, әнисе дә акча эшли. Ә акча Кәримәләргә бик кирәк. Урын өстендә яткан әтисе бар. Моннан өч ел элек, егылып, ике аягын, ике кулын сындырган иде — һаман рәткә килә алмый. Мәскәү хастаханәсенә алып барырга кирәк, ди. Шуңа әнисе тырыша-тырыша акча җыя. Көне буе гел аягүрә кибеттә эшләгәннән соң, кунаклар килгәндә, кичләрен Сәгыйть Сәетовичка аларны сыйларга булыша.

Текә Яр бистәсенең бер очыннан икенчесенә чыгып җиткәнче сәгать ярымлап вакыт кирәк, диләр. Кәримәнең исәпләп караганы юк, чөнки бистәнең югары очыннан түбәненә автобус йө-

реп тора. Әнисе шулай дип сөйли торган иде. Текә Яр, аларның гаиләсе монда күченеп килгәндә, Сазлык елгасы буенда ук урнашкан тугыз йортлы урыс авылы булган. Казан артындагы әлеге авыл нигезендә (урысча исеме — Собачьи Горы) заманында зур төзелеш башлап җибәргәннәр. Төрле яктан һәм кырыкмаса кырык милләттән Текә Ярга торыр җирсез юксыллар, эшсезләр җыелган. Тугыз йортлы салам түбәле Собачьи Горы хәзер шаулап-гөрләп торган Текә Яр бистәсе. Хәер, урысча ул әле дә бөтен язуларда да Собачьи горы дип языла. Татарлар телендә «Текә Яр», урыс телләләр дә, вата-сындыра «Текоярово» дип әйткәләп куя.

Кәримә, үз тукталышларына килеп җитәм дигәндә генә, ике кеше аша үзенә төбәлгән күз карашын тоеп, әллә нишләп китте. Үз яшьләрендәге бер егет бик кызыксынып аны күзәтә иде. Күз карашын оялып читкә алды алуын, тик тагын бер мәртәбә генә булса да, сиздермичә-белдермичә генә аңа караш ташлыйсы килде. Әлеге хис оялчан күңелдән көчлерәк булып чыкты, тәки үзенекен итте: ул янә шул тарафка күз салды. Бер генә мизгелгә карашлары да очрашты әле һәм шундук бит алмаларына эссе ут капты. Пырхылдый-пырхылдый түбән очка көч-хәл белән тәгәрәгән «пазик» әйтерсең очкычка әйләнде дә болытлар өстеннән йөзә башлады, әледәнәле терсәкләре белән бер-берсенең кабыргасын санап барган ачы телле кешеләр гүя шул мизгелләрдә, җәннәт фәрештәләренә әверелеп, былбыл каурые белән аның борын очына кунган өч кенә бөртек тир тамчысын җиләтергә керештеләр, тукталыш саен: «Билеты, за билеты передавайте! Все равно за эти деньги иномарку не купите!» — дип, юл буе теленә салынып барган шофер егет көр тавышы белән сузып торып җырлап җибәрде сыман.

Кыз яңадан «җиргә төшкәндә», аның тукталышын шактый ара узып киткәннәр иде. Күңелендәге «этлек»: «Тагын бер мәртәбә генә карап ал инде шул егеткә!» — дип өстерсә дә, кыз бүтән җөрьәт итмәде. Курыкты. Моңарчы беркайчан да татымаган татлы, әмма ниндидер сәер хиснең тагын кабатлануыннан курыкты. Сәерлеге түгел, артык ләззәтле булуы куркытты бугай.

Чираттагы тукталыштан соң автобус түбән очка таба кузгалды. Гадәти булмаган теге егет тә аның белән китте. Кызның әле генә җанын кайнаткан татлы кичерешләр автобус артыннан ияреп бардылар бардылар да, әллә «хәлләре бетеп», әллә кирәкмәгәнгә санап, үзенә кире әйләнеп кайттылар һәм күз ачып йомган арада күңеленә кереп бикләнделәр. Күңел дигән гаҗәеп дөньяда тагын бер буш урын кимеде...

Әтисе кызының кая барганлыгын белә иде, тел әйләндереп тормады, бары яткан җиреннән чак кына кымшангандай итте, әмма өйдә ята-ята тоныклана барган күзләрендә сораулы караш барыбер чагыла иде.

Бардыңмы, әниең нәрсә дип әйтте, янәсе.

— Имтиханнарыңа әзерлән. Үзем барам, диде.

— Алай икән.

Ата белән кызның әңгәмәсе шуның белән тәмам булды. Болай да тыныч холыклы әтисе, бигрәк тә бу соңгы ике ел эчендә тагын да азрак сүзлегә әйләнде. Күңелендәге соравын сүзсез әйтергә, җавабын да күз карашларыннан табарга өйрәнде бугай инде ул.

— Әти, карының ачмадымы?.. Нәрсә пешереп ашатыйм?

— Су алып кил.

Кәримә суыткычтан шифалы су шешәсе алып ачты. Ул салкын иде. Җылытырга талпынган иде, теге бүлмәдән әтисенең:

— Кызым, салкын килеш әйбәтрәк була, — дигәне ишетелде.

Әти кеше, башын күтәрә төшеп, чынаякны кулына алды.

— Әти җаным, бигрәк салкын. Чак кына җылытыйм инде, ә, — дия-дия, Кәримә учлары белән ике яклап чынаякны кысты. — Хәзер, әти, чак кына.

Әтисе су эчкән арада, кыз күзләрен дә алмыйча яратып аңа карап утырды да, балачактан килгән гадәте буенча, әти кешене көтмәгәндә битеннән үбеп тә алды.

Ул бала әтисен яки әнисен бик ярата, дип әйтергә яраталар. Майга май дигән шикеллерәк килеп чыга инде бу. Ничекләр итеп әти-әнине яратмыйсың ди! Аллаһы боерса, әле менә аякларына да басып китсә, аның әтисе дөньяда бер кеше булачак әле! Хәер, болай да берәү генә инде ул!

Кәримә әтисенең битеннән тагын бер мәртәбә үбеп алды да беркавым никтер тынып торды. Автобустагы хәлне әтисенә сөйлисе килдеме соң? Хәер, нәрсә дип сөйләсен инде. Авыз тутырып сөйләрлек берни булмады ич. Кеше күплектән автобус эче тынчу булгандыр да, бәлкем, бер мизгелгә генә башы әйләнеп киткәндер әле. Теге егетнең монда ни катнашы бар ди!

— Кызым, бүген никтер аяклар кызышкан кебек. Җан кергән шикелле булдымы шунда...

— Әти, озакламый аякка басасың әле син. Менә күреп торырсың. Мәскәүгә май аенда барасы бит әле, име?

— Акча җитсә инде.

— Нишләп җитмәсен! Аңа хәтле айдан артык вакыт бар ич әле!

Әти кеше дәү учлары белән кызының башыннан сыйпады.

Аның бик тереләсе, тизрәк аякка басасы, сөйгән хатыны белән күз алмасыдай кызын соңгы елларда чуалыбрак киткән дөнья мохтаҗлыгыннан коткарасы, тормыш камытын яңадан үзенә аласы килә иде. Нәкъ аяк астыннан гына мондый бәла килеп чыкмасамы? Хатынын үзенең төп эшеннән соң, тилмертеп, кичке сменага калдырып эшләтә торган ир-ат идеме соң ул!

Кайгы агач башыннан йөрми, диләр. Мондый гыйбарәләрне юкка гына, сүз булсын дип кенә әйтмәгәннәрдер, күрәсең. Үткән еллар, кайчак кайгылары белән ишелеп килгән, кайвакыт елмаеп-көлеп каршыңа чыга торган язмыш язусыз-сызусыз зур мәктәп ул. Аннары кайвакыт кайда сөртенәсеңне дә чамалап бетерә алмыйсың. «Кайда егыласымны белсәм — шунда ястык җәеп куяр идем», — дигән ди бит әнә берәү.

Хатынының әнисе — сиксән ике яшьлек карчык — алар кулында тәрбияләнә.

Ут карчык, булган кеше. Җитмеш биш яшенә чаклы кәҗә мамыгыннан үзе шәл бәйләп базарда саттырды. Кызы Фәгыйлә күзлек кия башлаганда, әби, эх дигәнче, күзлексез-нисез энәгә җеп саплый, гарәп язуы белән язылган китаплар укый, Кәримәне чигү чигәргә өйрәтә иде. Әлбәттә, аны берәү дә шәл бәйләргә мәҗбүр итмәде, аңа эш кушмадылар, ләкин карчыкның йөрәге шундый иде, тынычсыз, тасырдык иде.

Картлачын җирләгәннән соң, кияү йортына берданбер мамык кәҗәсен алып килде ул. Торабара хайваны картайды, әбинең картаясы килмәде, кәҗә бәрәнен асрады. Аның фәлсәфәсе болайрак иде. Бу кәҗә токымы аңа бик кадерле. Ул хайванның әбисен алар карты белән икәүләп Морки базарыннан алып кайттылар. Кәҗә бик шәп, затлы мамыклы булып чыкты. Аның мамыгыннан бәйләнгән шәлләр тирә-юньдә дан казанды. Халык аның шәлләренә чиратка язылды. Моңарчы тормышның тишек-тошыгын көч-хәл белән, аннан-моннан гына ямап барган гаилә кәҗә аркасында бөтәеп китте. Фәгыйләнең әтисе, мактанып: «Кемнәрдер ат алып та мантый алмады, берәүләр кәҗәдән дә уңды!» — дип сөйләргә ярата торган булган.

Әнә шул затлы кәҗә аркасында хәлләр булды да инде. Кәрим бер дә бер көнне эштән кайтып кереп капканы ачып җибәрсә, ни күрсен, әби белән кәҗә лапас түбәсендә утыралар.

Кәҗә, күрәсең, лапас түбәсеннән өскә үк менгән дә, кыек буйлап килә-килә, Кәримнең юнып кибәргә сөяп куйган озын-озын киштәлекләре арасына килеп кысылган. Әбинең исә кәҗәсен коткарырга менүе булгандыр, хәзер әнә кире төшәргә куркып түбәдә утыра.

Берәү булса, каенанасының мондый тилелеген күреп: «Чукын шунда, карт тәре!» — дип шатланыр гына иде. Ләкин Кәрим карчыкны үз әнисе урынына күрә. Гомумән, аларның мөнәсәбәтләре ана белән ул арасындагы кебек иде.

Әүвәл кияү кеше, бу хәлне күреп, кычкырып көлеп җибәрде. Чөнки мондый хәлне уйлап та чыгарып булмый иде. Бер генә кинода да күргәне юк, бер генә китапта да очратканы булмады. Әби лапас түбәсендә утыра! Кәҗәсен коткарырга менгән!

Кәрим, ничек кенә тырышмасын, көлүеннән тыела алмады. Көлә-көлә менеп әбине алып төште ул, кәҗә бәтиен дә коткарды. Әбине алып төшкәндә, сөякләре таралып китә күрмәсен дигәндәй, иплэп, җайлап кына тоткан иде. Әби үзе дә, чытырдатып, аның муенына ябышты. Каенанасының арык, әмма көчле куллары муенын шулхәтле иттереп кысканнар ки, әйтерсең куллар түгел, тимерче келәшчәсе диярсең! Кәрим беравык муенын ни уңга, ни сулга бора алмыйча азапланып торды. Каенанасы: «Нишләп торасың инде! Кәҗәмне коткар, кәҗәмне!» — дип шырыйлап кычкырып җибәргәч кенә исенә килде.

Кәҗәне коткару тагын да кыенрак булып чыкты. Ул әби түгел, муенга ябыша белми шул. Кәрим, кәҗәнең киштәлекләр арасына кысылган башын чыгарам дип азаплана торгач, үзе, тигезлеген югалтып, чак кына аска мәтәлмәде, кәҗәнең койрыгына тотынып калды. Койрыктан тарту җитте — кәҗә бәтие ямьсез итеп кычкырды да, лапас түбәсеннән уктай атылып төшеп, дүрт аягына да җиргә басты. Кәҗәсенең шактый биек түбәдән яшен ташыдай мәтәлгәнен күргән каенана әче тавыш белән чинап җибәрде: «Бетердең кәҗәмне, харап иттең! Бетердең, имансыз!» Кемдер килеп, каенананда шундый тавыш бар, дип әйтсә, мәңге ышанасы түгел иде. Үзе ишеткәч, беравык шаклар катып торды әле. Ишегалдына тавык бәрәңгесе урларга төшкән карга-чәүкәләр, котлары алынып, һавага күтәрелде. Келәт буенда тычкан сагалап утырган кара мәче, томырылып, капка астыннан чыгып качты. Кәримнең гәүдәсен яшен суккандай булды, бу-

ыннары йомшарды. Башы әйләнә башлавын да сизгәч, ул тизрәк җиргә төшәргә ашыкты. Әмма тотынып өлгерә алмады, дөбер-дөбер тәгәри-тәгәри аска мәтәлде.

Әби кеше лапас кырыенда гына өелеп торган таш өеме өстендә хәрәкәтсез яткан киявенә әүвәл игътибар да итмәде, бөтен игътибары кәҗә бәтиендә. Кәҗә бәтие Кәрим кебек ишегалдына түгел, яшелчә бакчасы ягына төшкән иде. Лапас түбәсеннән очуы шундук онытылды, ул, як-ягына карана-карана, кәбестә түтәлләренә һөҗүмгә әзерләнде.

Кәримнең авырту-сызлануы бик көчле булса да, эченнән аты-юлы белән үз гомерендә беренче мәртәбә карчыкны сүкте. Көчлерәк сүккән саен, авыртуы да шулчаклы тыйлыгып тора шикелле.

Кәҗә бәтиенә чуртым да булмады, аяк-куллары сынган Кәримне, кәҗә белән әбине коткарып калган кияү-балакайны, хастаханәгә озаттылар.

Аяк-куллар дөрес ялганмады, тагын сындырдылар, тагын нәрсәседер килеп бетмәде...

* * *

Әллә нинди көн булды бу бүген: әүвәл кибеттә нининдидер түрә шоферының әнисе белән сөйләшкәнен ишеткәч, кызның йөрәге тасырдарга керешеп, бер хәерсез хис күңелнең бер читенә таш кебек кереп оялаган иде; хәзер исә шул күңеле, канат яргандай, очынасы итә, гәүдәсе мамык шикелле, очып китәр сыман, аяклары бер урында басып тора алмый. Әллә... әллә инде автобуста күргән егет булдымы соң моның сәбәпчесе?.. Айратның әнисе белән күрешүме? Әтисенең: «Йөреп китәрмен күк тиздән, кызым!» — дип әйтеп, өмет белән тулган зур кара күзләрендәге якты моң, ышанычмы?.. Ни генә булса да, кызның җанын нәрсәдер җилкендерә, тәүлек эчендә кырыкка төрләнә ала торган кыз бала күңеле тынычлыгын тәмам югалткан иде.

Ярабби, яхшыга булсын! Мондый җилкенүләрнең ахыры, гадәттә, хәерлегә түгел. Ләкин нишлисең: күңел дигәнне тыеп торып булмый, андый чакларында ул акылга һич кенә дә буйсынырга теләми икән... теләми икән шул...

Әтисе: «Кызым, бу хәбәрне тизрәк әниеңә дә җиткерергә кирәк. Бүген эшеннән иртәрәк кайта алса, яхшы булыр иде», — ди. «Әти, әни бүген дә вакытында кайта алмаячак. Кала кунаклары килгән, шуларны сыйлыйсы бар», — дип, ничек әйтәсең инде аңа?

Кәримә аптырауга төште. Күңел җилкенүе дә сүрелде кебек. Ләкин җаны барыбер тыныч түгел, ул читлектәге сандугач баласыдай тыпырчына, бәргәләнә иде.

Әүвәл әнисенә телефоннан гына шылтыратмакчы булган иде. Күршеләрендә телефон бар, кайчан керсәң дә, якты йөз күрсәтеп, сөйләшергә рөхсәт бирәләр иде. Әмма әллә хисләр кайнарлыгы зиһененә тәэсир кылып, гакылы тәмам сафланып, хәтер почмагындагы йокымсырый башлаган күзәнәкләре капылт кына уянып киттеләр! Булган иде бит инде бер мәртәбә! Булган иде! Нәкъ шундый хәл кабатланган иде: этисе берзаман, кичтән җиңеләеп китеп, әнисен эштән чакырып кайтырга җибәрде аны. Әүвәл ул, күршеләренә кереп, телефоннан сөйләште. Бу шатлыклы хәбәрне ишетеп, әнисе бик сөенде, бүген иртәрәк кайтырмын, дип вәгъдә бирде. Көттеләр, кичкә чаклы, караңгы булганчы этисе белән икәүләшеп көттеләр аның кояштай балкып ишектән килеп керүен. Әни кеше эш сәгате беткәч тә кайтмады, вакыт шактый узып, караңгы төшкәч тә ишектә «кояш» күренмәде.

...Кәримә, этисенә аны-моны әйтмичә генә, бистә үзәгенә китте, маршрут автобуслары йөреп тора иде әле.

Кибет бикле булгач, кафеның арткы ишегенә китте. Бар тәрәзәләрдә дә утлар яна, эчтә музыка уйный, кемнәрдер шау-гөр килә, тостлар әйтешәләр, тагын әллә нинди тавышлар ишетелә. «Сәет Сәгыйтовичның кала кунаклары!» — дип уйлап куйды кыз. Шул уйдан соң эченә җылы йөгерде, ул кыюланып, батыраеп китте, ашыга-ашыга кафе ишегенә таба атлады. Һәм, тәрәзә буеннан узганда, ирексездән кунакханә эченә күзе төште, җитмәсә, пәрдәнең бер чаты ачылып та киткән иде. Кәримә егылып китә язды, бүлмәдә тәрәзәгә арты белән бер шәрә хатын-кыз басып тора. Почмактагы агач караватта зур бүксәле (аркасына ятуына да карамастан, корсагы түмгәк кебек булып күренә) бер ир-ат ята. Авызында тәмәке, ул бертуктаусыз сөйләнә, ниндидер сүзләр әйтә дә, аннан соң шаркылдап көлеп җибәрә, өстенә япкан одеал кырыеннан буйлы-буйлы трусик балагы чыгып тора. Менә ул шәрә хатынны үзенә тартып китерде дә өстенә одеал каплады. Кәримә телсез, өнсез калды, аяклары атламас булды. Шәрә хатынның сул як калак сөяге астында ике тиен акча зурлыгында миң бар иде. Бу аның... бу шәрә хатын... ике тиен акча зурлыгындагы миңле хатын аның... аның әнисе түгелме соң? Ул, ни кылганын, нәрсә эшләгәнен үзе дә белмичә, янәшәдәге автобус тукталышына йөгерде һәм ишекләрен ябып кузгалып ма-

ташкан автобусның алгы борынына килеп бәрелде. Аны кемдер автобус эченә тартып алды, кемнәрдер шелтәләделәр, ачуландылар. Әмма әлеге мизгелләрдә фани дөнья мәсьәләләрендә аның эше юк иде. Өенә кайтып керүгә, бу халәтен әтисенә сиздерүдән куркып, тизрәк юрган астына чумды. Тынычлана алмыйча бик озак калтыранып, дерелдәп ятты; зиһене чуалган иде, анык кына ни хакында булса да уйлый алмады дисәң, дөреслеккә бигүк туры килеп бетмәстер дә, бәлкем, чөнки баш миен, әлегесен фани дөньяның әшәкелекләре турында нindидер булса фикер йөртеп, акны карадан аерырга күнегеп җитмәгән яшь гакылын һаман берүк төрле хәерсез, юньсез һәм ямьсез уйлар, агач кәүсәсен чокыган әрсез тукран кебек, өзлексез талый иделәр: «Әниең шул рәвешле акча эшли! Ә акча сезгә бик кирәк! Чөнки әтиеңне аякка бастырасы бар!» Бу уйлар коточкыч уйлар иде. Ул, алардан качарга теләп, башын юрганына да урап карады, мендәр астына да тыгып бакты, ләкин алар котылгысыз иде, үҗәт, усал һәм аяусыз уйлар иде!.. Әтисе янына килеп нәрсәдер әйтү хакында хыялланасы да юк, кыз, түземсезләнеп, әнисенең кайтып керүен көтеп ятты. Көтүен көтте, ләкин ишектән «кояш» керүен көтмәде. Бүген бусаганы тонык «ай», ярым китек моңсу «ай» атлап керер төсле кебек тоелды...

Кыз, юрганының читен чак кына ачып, тәрәзәгә карады. Инде төн җитеп килә. Ә офыкта баеп бара торган тонык ай шәүләсе тирбәлә. Нәкъ үч иткәндәй бит, шайтан!..

Йоклап китү турында уйлыйсы да юк. Гәүдәсеннән хәерсез калтырау һаман китми дә китми. Шул рәвешле күпме яткандыр, берзаман кайтып керде әнисе. Кәримә башка вакытта аны аягөсте каршы ала, алар юк-бар хакында гәпләшеп бик озак әтиләренең караватт кырыенда утыралар, аннары, бергәләшеп урыннар җәеп, йокларга яталар да һәм тәмле-тәмле, матур-матур төшләр күрәләр иде. Бүген ул алай итмәде, башымны юрган астыннан чыгармыйм, дип уйлады. Уйлавын уйлады, ләкин барыбер юрган читен аз гына ачып, өй эчен күзәтте, әнисенең чишенгәнен карап ятты һәм шулчак кычкырып җибәрә язды: теге ике тиен акча зурлыгындагы миң, тәрәзә аша арты белән борылып торган шәрә хатынның калак сөяге астындагы хәерсез миң... Һе, менә сиңа мә! — ул миң әнисенең уң ягында икән бит! Кәримә тәгаен хәтерли, — бу очракта ялгышу, хаталану һич мөмкин хәл түгел иде, — Сәет Сәгыйтович кунакханәсендәге шәрә хатынның миңе сул як җилкәсендә иде ләбаса!

Кызның гәүдәсен янә калтырау алды. Әлбәттә, бу юлы сәбәбе бөтенләй башка иде! Хәерлегә булсын!..

Әнисе, әтисе яткан бүлмәгә кереп чыкты да (әти кеше йоклап киткән булгандыр, күрәсең) эчке күлмәген киеп, кызы янына килеп ятты.

— Кәримә, Кәримә, йоклыйсыңмы, кызым?

Җавап булмагач, ул үзенә аркасы белән борылып яткан кызын кочаклады... һәм, кызының бизгәк тоткан кебек калтырануын тоеп, мышык-мышык еларга керешге. Ана белән бала арасындагы биокүзәнәкләр аша күңелсез әңгәмә башланды.

— Гафу ит, кызым! Мин күп итеп акча эшләп кайттым!

— Акча? Сиңа кем акча бирсен?! Синең миңең уң як җилкәңдә бит?

— Менә тиздән әтиеңне больницага салырбыз.

— Әти үзе дә йөреп китәчәк әле ул!

— Түләүле операциягә дә акча җитәрлек хәзер.

— ...

— Аннан соң бу эшемнән китәм. Әтиең аякка баскач, дим... Ул акчаны күп итеп таба иде бит.

— ...

Тәрәзәдән күренгән теге ярым китек ай көчәнә-көчәнә өй эченә, идәнгә, стенада эленеп торган сәгатькә үзенең тонык нурларын сипкән булган тагын... Ник азапланып маташа инде? Тулган чагы түгел бит барыбер...

* * *

Кәримәнең әнисен суд залыннан ук алып киттеләр.

Әүвәл җиде елдан да ким булмас, дигәннәр иде. Анысы да «аванс» белән әле. Авыру ире, гаиләсе барлыгын исәпкә алып, соңыннан, ни хикмәттер, суд дүрт ел дигән карар чыгарды.

Күрсәтмәделәр, очраштырмадылар, сөйләштермәделәр.

Дигәннәр иде, сөйләгәннәр иде, юраганнар иде...

Авыру әтисе янында ялгыз башы калган студент кызны сыгылып төшәр, бу кайгыны күтәрә алмас, дигәннәр иде. Киресенчә булды: әүвәл көне-төне бертуктаусыз елады-елады да... Анна-

ры, әтисе янында әбисен калдырып, укырга китеп барды. Әнисен уйлый-уйлый акылга җиңеләеп калыр бу кыз бала, дип сөйләгәннәр иде. Күз яшьләре кибеп беткән идеме, әллә бәгыре каттымы — бүтән яшь түкмәде. Бериш адәм баласы кайгы-хәсрәт һәм кыенлыкны күпме күбрәк татыса — шулчаклы ныгый, үҗәтләнә генә икән. Кәримә шундыйлардан иде, күрәсең.

Әнисез калгач, укуын ташлар бу кыз бала, дип юраганнар иде.

Әйе, элек укуга алай бигүк битараф булмаса да, барыбер күңелен биреп бетерә алмый кебек, кирәк булганга гына укый шикеллерәк иде. Киресенчә булды, кышкы каникуллардан соң... Хәер, әнисен, газиз әнкәсен төрмәгә алып киткәннән соң, аның фәннәргә дә мөнәсәбәте үзгәреп, ул һәр нәрсәдән мәгънә эзли башлады.

Ләкин тагын өстәмә бер акыл теше чыгу түгел иде бу. Нәрсә белән булса да кызыксынмаса, күңелендәге бу хәшәрәт дөньядагы бушлыкны шулай буш килеш калдырса, һич тә яшерен-батырын түгел, кызның үксеп-үксеп елыйсы, тулай торак идәнендә, — алай гына да түгел! — Бауман урамы ташына ятып тәгәри-тәгәри елыйсы килер кебек иде шул... Акыллы иде кыз, төпле иде кыз. Шул аяз акылы аны төрле җүләрлекләрдән саклап килә әле, шөкер...

Ул укыган гуманитар факультетта фәлсәфә, социология, психология фәнен тирәнтен өйрәнәләр. Башлангыч курслардан ук. Ни гаҗәп, хәзер ул аны аңлый башлады сыман. Әлбәттә, күп нәрсәне кабул итеп бетерә алмаса да. Элегрәк кыз баланың күңеле башка дөнья яссылыгында яши, гакылы исә аерым юлда сыман иде. Гаҗәп һәм кызык: адәм баласын кеше итеп торткан әлеге ике төшенчә, шул төшенчәләр аңлаткан мәгънә вакыт-вакыт кушыла башладылар, үзара якынайдылар. Күп гомерен чәчәкле болында үткәргән кайгысыз күбәләккә охшаш күңел, әледәнәле йолдызларга очынып алгалаган иләс күңел, берзаман җиргә кунды, фигыль-гамәлләре гакыл белән охшаша, килешә башладылар. Мондый үзгәреш сиздермичә генә килде. Һәм кызны үзгәртте. Ничек үзгәртте, юл-сукмагын кай якка борды — анысы әһәмиятле түгел, ләкин үзгәреш булуы хак иде.

Артык акыллы булуның беркайчан да хатын-кызны бәхетле иткәне юктыр. Хатын-кыз турында ир-ат ничә гасырлар буе фәлсәфә корган, бик акыллы булып, әлеге җенестән үзен өстен куеп, аның гамәлләрен бала-чага холкына тиңләгән. Хатын-кыз өчен иң якын дус ир-егетләрнең дуэльләрдә бер-берсен үтерешкәнен нишләптер фәлсәфи күзлектән карарга онытып җибәргән ул.

Кәримә киң, ялтыравык маңгайлы, аксыл йөзле яшь профессорны тыңлый. «Ир-атның гакылы һәм рух дөньясы утыз яшькә якынлашканда гына камилләшә, хатын-кыз мондый югарылыкка унсигездә үк ирешә. Шуңа күрә дә хатын-кыз гомере буе бала-чага булып кала, зур бала-чага... Өйләнә-тирәсендәгесен генә күрә ул, вак-төяк белән шөгыльләнүне бик мөһим дип уйлый. Нәкъ менә гакыл нәтиҗәсендә кеше, хайван кебек, бүгенге белән генә яши алмый, үткәнне анализлый, киләчәкне фаразлый, шуның аркасында ул сак эш итә, кайгыра-кайгырта, борчыла, гакылының сыеграк булуы сәбәпле, хатын-кыз ир-аттан аерылып тора. Үзенең рухи күрә-карау булуы белән аерыла ул: аның интуитив (турыдан-туры кабул итүче) акылы якындагын бик ачык күрә, ләкин күз күреме чикләнгән, читтәгене күрү сәләтенә ия түгел».

Ул әйткән фикерләрне дәфтәренә төшереп куя да кыштыр-кыштыр лекция язган группадаш кызларына күз салгалап ала. Гуманитар бүлектә егет-малайлар бармак белән генә санарлык. «Димәк, әле болар малайлар гына... утызга җитмәгәннәр, димәк, өлгереп тә җитмәгәннәр», — дип уйлый кыз.

Профессор һаман сөйли, борынгы фәлсәфәчеләрдән мисаллар да китерә, үз сүзләре белән дә сөйли, инде күптән яттан белгән фикер-цитаталарны бернинди аңлатмасыз гына аудитория өстенә сибә.

«...Хатын-кызның гәүдәсеннән үк аның гаять зур хезмәт өчен яратылмаганы күренеп тора. Физик яктан да, рухи нисбәттә дә. Ул үзенә язылган гомерне чынбарлык белән түгел, ә газапмәшәкатьләр эчендә уздыра: бала табу газаплары, балалар турында кайгырту, иренә буйсыну... Бу зат югары кичерешләр, көчле шатлыклар өчен яратылмаган. Ир-атка караганда аның гомере талгын-тынычрак, мәгънәсезрәк, әһәмиятсезрәк уза һәм ул аннан гына бәхетле дә, бәхетсез дә була алмый».

Моннан йөз илле ел элек әйтелгән фикерләр Кәримәне вакыт-вакыт сискәндереп җибәрә.

«Адәм балалары кавемен дәвам иттерү, сүндерми саклау вазифасы табигать тарафыннан яшь, сәламәт һәм чибәр ир-егетләргә тапшырыла. Бу — табигатьнең какшамас ихтыяры һәм ул хатын-кызның кайнар хисләрендә чагылыш таба. Бу бик борынгы канун, канунnarның аннан да элгәрересе юк. Кем дә кем үз хокуклары һәм мәнфәгатьләрен шушы канун белән кисештерә — ул кеше ни генә дисә дә, ни генә кылса да — аның хокук һәм мәнфәгатьләре беренче җитди кар-

шылык туу белән аяк астына салып тапталачак. Чөнки хатын-кызда бик эчкәре яктан, яшерен, кычкырып әйтелми торган, хәтта азагына кадәр төшенеп тә бетелмәгән, тик тумышыннан ук бар булган бер гакыл болай дип тукып тора». Яшь профессор, сүзеннән бүленеп, тәрәзәгә карап алды. Әллә Бауман урамы буйлап дөбер-шатыр чапкан троллейбусның узып китүен көтәме, әллә хәзер әйтәчәк фикеренең гаять әһәмиятле булуына шул рәвешчә искәртүеме соң? Бәлки, вакыт алай күп тә узмагандыр, ләкин студент халкына бу бик озак тоелды, урындык-өстәлләр шыгырдый башлагач, профессор сүзен дәвам иттерде: «Безне индивидуум буларак кайгыртып, безнең аша тереклекнең бер төре (species) саналырга хокуклы булдык дип ышанучыларны алдарга хакыбыз бар безнең. Безгә иң якын торган — бездән туган буынга нисбәтле рәвештә тапшырыла һәм без чын күңелдән ул игелекне булдырырга тырышабыз». Әмма хатын-кызның әлеге югары принципны һич тә abstracto түгел, ә in concreto гына аңлый һәм аны җае чыкканда үз гамәлләре аша чагылдырудан да кулай юл күрми; ә менә аларның вөҗданы күпчелек очракта без уйлаганга караганда тыныч кала, чөнки алар индивидуум каршындагы бурычларына хилафлык китергән хәлдә, үзләре югарырак кимәлдә саналган нәрсәгә — тереклек төренә тугры калу хисен йөрәкләренең иң аулак почмакларына качырып саклыйлар.

Хатын-кыз, фәкать адәм балалары кавемен арттыру өчен генә кулланылуы һәм вазифасы шуның белән төгәлләнү сәбәпле, индивидуумда яшәүдән бигрәк, кавем эчендә яши һәм аның өчен кавем тормышы индивидуаль тормыштан якынрак. Бу хәл аларның бар булмышларын, эш-гамәлләрен билгеле бер җилбәзәклек өрфиясе белән каплый һәм үзләрен ир-ат юлыннан үзгә юлга — бик еш һәм тиз генә җимерелә торган никахлар юлына алып китә».

Лекция тәмам булганнан соң, маңгай чәче пеләшләнә башлаган кырык яшьләрдәге профессор сорау-җавап кебегрәк семинар оештыра.

Кызлар профессорга быел июль аенда кырык өч яшь туласын да беләләр, фамилиясенең Иштәков, исеме Руслан, атасының исеме Дәүләт икәнлеге дә яхшы мәгълүм аларга. Тик яшьләр профессор хакында төп ике нәрсәне ачыклый алмыйча чып-чын газап утында яналар иде: өйләнгәнме ул, юкмы, яки хатын аерганмы, аерса, ничәнче хатыны белән тора һәм милләте белән кем? Татарныкына охшамаган фамилия, аннан соң үзен Дәүләтович дип түгел, Руслан Даулатович дип әйтергә кушты. Кыяфәте белән грузинга да охшаган, ләкин каратутлы түгел, киресенчә, немецлар кебек аксыл. Грузин булса, болай лекция укып йөрмәс, базарда әфлисун сатуны кулайрак күрер иде, ә немец милләтенә фамилиясе туры килми. Кыяфәтендә яһүд чалымнары да бар — моңа янә фамилиясенең Иштәков булуы каршы килә.

Профессорда хатын-кызны уштан яздыра торган ниндидер «мәхәббәт магниты» бар, фәлсәфә фәненә гашыйк булганы һәм хатын-кыз өммәте хакында юк-барны сөйләгәне өчен йөрми кызлар аның лекцияләренә, әнә шул сөйкемле сөяге, мәхәббәтле кыяфәте үзенә тарта. Әлбәттә, серле булуы. Хатын-кыз өчен ир-аттагы иң мөһим, әһәмиятле, әйтергә кирәк, иң бөек сер — өйләнгәнме-юкмы икәнлеген белү. Руслан Даулатович әле аларга лекцияләрне күптән түгел генә укый башлады, аңа кадәр фәлсәфәне Козловский фамилияле карт профессор укыта иде — ул Израильгә китеп барды.

Өйләнгәнме бу, юкмы? Һай, беләсе килә бит, ә!

Бүгенге лекциясендә хатын-кызны эттән алып эткә салды. Аңа да ачулары килә һәм яшь профессорның бу гамәле теге «бөек сер»не тагын да катлауландыра иде: «Хатын-кызны шулай юкка чыгарасыз, димәк, сез өйләнмәгән кеше?!»

Группада Аниль исемле бик чая Казан кызы бар. Мулла кушкан исеме — Әнил, ди. Ул зур кара күзләре белән тутырып бер караса, факультеттагы ир-ат студентлар гына түгел, сакаллы профессор абыйлар да атлаган җирләреннән сөртенеп-сөртенеп китәләр. Чибәр, курчак кебек матур кыз... Анасы кайдадыр зур урында, әтисе дә галим, диләр. Кәримәнең кайгысын да беренче булып Әнил ишеткән иде, ул аны кочаклап алды да:

— Пессимизмга бирелмә, Кәримә. Бар кайгыларыңны онытырлык шөгыль табармын әле мин сиңа, менә күрерсең! — дип юатты.

Ләкин Кәримәнең хәле юатулардан узган инде. Ул һәрвакыт әнисе турында уйлый, аны төрле халәтләрдә күз алдына китереп, җаны сызлый, күңеле сыкрый. Әнә ул читлек эчендә, япа-ялгызы, хәтта читлекнең ишеге дә юк. Бер почмакта бөрешеп утыра. Менә ул караңгы, таш идәнле камерада ята. Янында күселәр йөгерешеп йөри. Кәримә тизрәк күзләрен ачып җибәрә, ямьсез уйлардан котылырга теләп, дерелдәгән кулларының юеш уч төпләре белән битен ышкый, чигәләрен уа. Ләкин бу гына ярдәм итәрлекме соң, ахырда кыз барыбер үксеп-үксеп сыгылып төшә...

Руслан Даулатовичның лекцияләре генә Кәримәне фани дөнья уйларыннан аерып тора шикелле. Шулар аша кыз бу болгавыр тормышны аңларга, танырга һәм, шуңарга таянып, үзе кереп адашкан «караңгы мәгарә»дән чыгу юлын эзләргә азаплана. Нинди генә бикле ишек булса да, барыбер кайдадыр, кемдәдер аның йозагын ача торган ачкыч, тылсымлы ачкыч булырга тиештер бит инде югыйсә! Шул ачкычны бик тә, бик тә кулга төшерәсе һәм... әнисен якты дөньяга чыгарасы килә иде кыз баланың.

Әлеге авыр уйларны Әнилнең яңгыравыклы тавышы бүлә:

— Руслан Даулатович, Вы наверняка знаете, поговорку, которая гласит, что петух, может быть, хорошо кукарекает, но яйца все-таки сносит курица.

Руслан Даулатович студентларының кыю-кыю сорауларын, фикерләрен ярата, ләкин үзеннән дә акыллы булганны өнәп бетермәве дә күз карашыннан ук сизелеп тора. Ул моны сиздермәскә тырыша, тик барыбер күз карашында чагылып-чагылып алган усал чаткы-мизгелләргә хуҗа булып бетерә алмый, яшь профессор моны үзе дә белә, шуңа күрә андый вакытларда аңа акыл шәрифләрен икеләтә эшкә җигәргә, шома маңгаен тагын да катырак җыерырга туры килә.

— Мин сезгә Шопенгауэрның тормышка карата булган фикерләрен китерәм! — ди ул.

Ырынбур егете Заһид андый чакларда, белдеклегә салынып, гел сүз кыстырырга ярата. Заһид килеш-кыяфәт белән кызларның ушын алырлык егет түгел. Ләкин ул белә: үзенең очкынланып торган зәңгәр күзләре кызларга ошамый түгел. Әмма ул күзләр сәер рәвештә төрле якка хәрәкәтләнгәндә (күз чокырына бик яхшылап майлап тыгып куйган зәңгәр шарлар кебек), аның йөзе таш сын кебек, ник бер җыерчык пәйда булсын, ник бер керфеге селкенсен. Заһид әгәр елан булса — бу җир йөзендә бер генә бака да калмас, һәммәсе Заһид авызында булырлар иде. Елан күзләренә капма-каршы буларак, алар гел хәрәкәтләнеп торса да, ул күзләрнең сихри тарту көче бар. Заһид күп сөйләшә һәм үзенең бу гамәлен кызлар бик ярата дип уйлап нык ялгыша. Хатын-кыз күп сөйләшергә яраткан ир-ат белән бик теләп гәпләшсә дә, тыныч һәм аз сүзле ир-егетләр аңа күбрәк ошый. Үзе хатын-кыз булмагач, Заһид атлы студент бу кадәресен үк, әлбәттә, төшенеп бетерми торгандыр инде.

— Руслан Даулатович, Шопенгауэр, Ницше, дисез. Ницше тәгълиматы белән коралланып немецлар дөньяны һәлакәткә китерә яздылар бит инде! — ди Заһид.

Руслан Даулатович, әлеге сүзләргә исе китмәгәндәй генә:

— «Алтын балык» әкиятен укып та әллә нинди фантазияләргә бирелеп булыр иде, — дип әйтеп куя да озын тырнакларын матурлап утырган Әнилгә таба борыла. Бар группа белә: профессор Әнилгә битараф түгел. Ул бу хакта турыдан-туры да сиздерми, аны имтихан бирергә бакчасына да чакырганы юк; әмма студент халкы усал эт кебек сизенә — Руслан Даулатович Әнил нинди генә кирле-мырлы яки дорфа сүз-фикер әйтсә дә, аның шома маңгаенда ике сызык пәйда булып, гадәттә, ул бу җайсыз холыклы кызга кире кагып булмаслык дәлилләр китерергә тырыша, хәтта азапланадыр да шикелле иде. Заһидның соравыннан соң профессорның маңгаенда бер генә сызык уелып алган иде.

Күренеп тора: бүгенге лекция һәм немец фәлсәфәчеләренең хатын-кыз хакындагы кискен фикерләре кызга бер дә ошап бетмәгән иде — тырнак матурларга керешүе дә шуның өчен генә булгандыр әле. Ләкин кызның игътибары барыбер аудиториядә барган бәхәсләрдә иде.

— Мужчина единственный самец, который бьет свою самку, — диде ул урысчалатып һәм аннан соң өстәп куйды: — Шорес Куртелин сүзләре.

— Шорес түгел, Шорж... Шорж Куртелин, — дип, бик итагатьле генә төзәтте аны профессор.

— Икенче хатыны аны күсе агуы биреп үтергән.

Монысы, әлбәттә, Заһид инде. Җитди сөйләшү вакытында юк-бар сүз кыстырмаса, ул Заһид буламы соң?!

Руслан Даулатовичның маңгаенда берьюлы өч сызык пәйда булды! Моңа кадәрле бу хәлнең булганы да, күренгәне дә юк иде әле! Бетте Заһид, профессор сытачак аны, бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмаса — язгы имтихан вакытында! Руслан Даулатович белән Әнил арасына кысылмаска иде дә бит канә! Телен тыя алмады. Үз башына булыр, мөгаен. Әмма шул тиктормас теле Заһидны күп очракта зур фаҗигаләрдән коткарып та кала тагын...

— Ир-ат нәкъ бала-чага кебек инде ул: кулыннан тотып йөргәнне ярата, әмма шул ук вакытта үзен зур кеше итеп исәпләргә куша.

Руслан Даулатовичның маңгае шомарды: аудитория җиңел сулап куйды, димәк, Заһид бу юлга исән-сау кала икән әле. Әлеге, кемнәрдер әйткән тапкыр сүз коткарып калачак аны, тапкыр сүзләр ошаса, Әнил дәшмичә калмаячак иде. Ә Руслан Даулатович исә күбрәк Әнил сөйлә-

вен тели, шуңа күрә дә Заһид сүзләреннән соң сырт йоннарын кабарткан иде өйләнмәгән ни яшь, ни әллә ни карт түгел профессор абыең.

— Я согласна жить в мире, которым правят мужчины, до тех пор, пока могу быть в этом мире женщиной, дигән Мэрилин Монро. — Әлбәттә, мондый гыйбарәләрне урысча китерә Әнил.

Кыз шулай диде дә, бурлаттай кызарып, куллары белән ике чигәсенә ябышты. Ни булганын аңлар ара булмады — тәнәфескә чакырып кыңгырау чылтырарга кереште.

Кәримә Әнилнең иңбашына кулын салып, үзенә таба тартты.

— Ни булды, Аниль! Авырыйсыңмы әллә? Кит, бөтенләй йөзең үк качты бит?!

— Авырмыйм, — диде аңа каршы Әнил, өзек-өзек тавыш белән. — Бу минем әнинең яраткан сүзләре, — диде ул.

Кызлар урыннарыннан тордылар. Артларыннан чыгып килүче Заһид, кызларны аерып, икесенең арасына керде дә:

— Бальзакны тыңлагыз сез, кызлар, Бальзакны. Ул менә нәрсә дигән: «Если мужчина остроумен, хорош собою и общителен, женщины интересуется не тем, откуда они вышли, а тем, куда он хочет прийти!» Ха-ха!

Әнил сиздермичә генә терсәге белән лыгырдавык группадашының касыгына төртте. Егет мондый һөҗүмне көтмәгән иде, һәм авыртуын да каты авырта иде бугай, ул сыгылып калды һәм ыңгырашып:

— У-у-у! Үтерәсең бит! Кинжал белән чәнечтеңме әллә син, җен! Ай, эчем, эчем! — дип зарланырга кереште.

Әнил ачулы иде, сүзләре теш арасыннан гына кысылып чыкты:

— Бәдрәфкә йөгер. Тизрәк! Чират көтә!

*** * ***

Уку бинасының ишеген ачып урамга чыгуга, Әнил Кәримәгә эч серен ачып ташларга тиеш кебек иде. Һәрхәлдә, Кәримә, группадашының холкын аз-маз белгән Кәримә, үзе шулай дип уйлады. Тик алар сөйләшеп китә алмадылар — Кәримә янына бер үсмер йөгереп килде дә каршысына ук килеп басты.

— Кәримәме? Каюмовамы?

Иске-москы киемле, озын пычрак чәчле таныш түгел үсмернең бу соравы кызны тетрәндереп җибәрде. Беравык ул югалып калды.

— Булса! Шуннан ни? — дип, аның өчен Әнил җавап бирде.

Кызның усал тавышы үсмернең чак кына ачуын да китерде бугай, ләкин аның телләшеп торырга һич тә исәбе юк иде, шулай да үпкәсен сиздергән тонда:

— Син әйтмәсәң дә, беләм Кәримә Каюмова икәнен. Әнисе фотосын күрсәтте. Мә! — дип, ул Кәримәнең учына кәгазь кисәге салды да, вокзал ягына таба китеп, күздән дә югалды.

*«Иртәгә, 12се көнне, сәгать өченче яртыда Казан вокзалында булабыз. Әниең».*

Язуны аның белән бергә үк Әнил дә укыган иде, ул аптырап иптәш кызына карады. Хәзер сыталачак, үксеп елап җибәрәчәк иде. Әнил, шуны сизепме, аны култыклап алды да тиз-тиз ишек төбеннән ераккарак алып китте, аннан соң, бу авыр халәтне йомшартырга теләп:

— Димәк, Себергә, этап белән, — дип куйды.

Кызлар, Кремль урамына менеп, университет каршындагы утыргычка утырдылар. Кәримә юл буе тавышсыз-тынсыз, шыпырт кына елый, күз яшьләренең бер өлеше бите буйлап тәгәри, батыр кыз калганын эченә йота һәм алар аның күзәнәкләренә сеңә дә тамырлар буйлап аккан яшь канга килеп кушылалардыр төсле.

Әнил бәләкәй сумкасыннан кесә телефонын алды да ниндидер номер җыярга кереште. Кәримәнең баягы тыныч күз яшьләре мышкылдауга күчә башлаган иде инде, Әнил йә юатса, йә болай гына әнисе хакында берәр сүз әйткән булса, бая ук, Бауман урамында ук акырып елап җибәрергә әзер иде.

— Мышкылдап утырма әле, яме! — дип, Әнил аңа җиңелчә генә төртеп алды.

Кара!.. Юатасы урынга! Иптәш кызының муеныннан кочаклап, яшьле күзләреннән үбә-үбә юатасы урынга! Бигрәк тупас бу Әнил! Таш йөрәк! Акыллы кешеләр әйткән цитаталарны ятлап кына кеше булып булмый шул әле! Аның өчен күкрәк читлегендә йөрәк дигән нәрсәнең дә тибүе кирәк!..

— Руслан Даулатович! Сезме! — дигән сүзләр Кәримәне әлеге уйларыннан аерып, айнытып җибәрде. — Руслан Даулатович! Бүген кич буш буласызмы? Күрешәсе иде!

Кәримәнең яшь тулы күзләре гаҗәпләнүеннән маңгаена менә яздылар. «Руслан Даулатович белән кич күрешәсе бар???»

Әнил телефонын сумкасына чумдырды да, Кәримәгә карап, күз кысып куйды. Ә тегесе, карга баласы кебек авызын ачып, тик аптырап утыра иде. Әүвәл Әнил үзе сүз башлады:

— Борчылма, Кәримә. Руслан Даулатовичның дусты шишка! Большая, большая шишка! Әниеңне спасут!

— Как спасут?! — дип, урысчалатып сораганын Кәримә үзе дә сизми калды.

— Дело техники. Впрочем, нам результат важен, а им — процесс. Тут и процесс важен, и результат важен, подружка!..

«Әнил, Әнилә, Аниль... Мәңге аңлап булмаслык, чишеп, төшенеп бетеп булмаслык сер син, дустым!»

«Дөрес уйламыйсың, Кәримә. Бернинди сер түгел мин. Хәер, серен сердер. Ләкин бер дә катлаулы түгел, гади, бик гади. Әнә теге газондагы яшел чирәм өстендә аунап яткан пычрак таш кебек гади. Үзе пычрак... үзе таш».

Күңелләр сөйләшә белә. Бер кешенең күңеле икенче кешенең «телен» аңларга сәләтле. Әгәр алар бер-берсенә якын ике кеше булсалар. Бигрәк тә аларны сытып, изеп торган берүк төрле кара кайгы булса...

Бер-берсен үлеп яраткан парлар күз карашлары белән дә аңлаша ала, диләр... Юк, аңлаша алмыйлар. Ялган бу. Аңлашу түгел, алар хәтта борыннары белән сулый да алмыйлар... томау төшкән була, хисләр томавы. Күз карашлары да хисләр пәрдәсе белән капланган була. Аларга әнә теге пычрак таш та хәтта бер зур алма кисәге булып күренәчәк. Дөресрәге, шулай шәйләнер иде.

«Йа Ходам! Нигә шулчаклы катлаулы итеп яраттың соң син җиһанны, бәндәләреңне?!»

«Мин?! Бәндәләремне? Җиһанны? Юк, бәндәләремнең адәм булганнары, сез алай ялгышмагыз! Мин яраткан дөнья бик гади иде. Һәм ул Табигать-әнкәгез кануннары белән генә яшәргә тиешле иде».

«Алайса, нигә көчлерәк бөҗәгең көчсезен җәберли яисә, тамагы ач икән, тотып ашый ук? Нигә бүреләрең куяннарны ботарлый?»

«Яшәү — көрәш ул! Ә көрәш — кешелекнең бердәнбер энергия чыганагы. Ул булмаса, хәтта кояш та сүнәр, ай да калыкмас иде. Ләкин ул көрәш гадел көрәш иде. Кагыйдәләре хак иде аның. Сез көрәш кагыйдәләрен үзегез боздыгыз. Әүвәл бер бәндә бозып җибәргән иде, аннан күреп икенчесе, өченчесе... хәзер исәбе-хисабы юк инде».

«Иң дөрес һәм тугры дин ислам дине булыр. Без, мөселман бәндәләре, шулай дип инандык. Христиан, будда һәм башкалары нигә хаҗәт иде соң?»

«Куркыныч, каты яшеннән соң һавалар сафланып кала. Бәндәләр үпкәләрен тутырып, рәхәтләнеп сулый башлыйлар».

«Яшәү — көрәш, дидем. Көрәшне сез уен дип тә атыйсыз. Һәр уенның да көрәшнеке кебек үк үз кагыйдәләре була. Дин, мин, син — башка мәсьәлә. Сез менә үзегез уйнаган уенның кагыйдәләрен генә бозмагыз!»

Ходай Тәгалә, үзеннән ерак булганга күрә, адәм баласы язмышын һәрдаим алдаларга тырыша. Ләкин Ходайның фәрештәләре һәрвакыт адәми зат янында икәнлеген исеннән чыгара...

...Чал университет каршындагы мәйдан Казанның иң биек урыныдыр, мөгаен. Күккә иң якын нокта да шушында микән әллә?.. Югыйсә күкләр белән болай турыдан-туры сөйләшеп булыр идеме икән?..

Һай, пинжәген җилкәсенә салган таш сынны кешеләр теге чакта, узган гасыр уртасында, моны үзләре дә аңламыйча, бик хаклы рәвештә куйганнар! Ул элек һәйкәл булса... хәзер кара багана хезмәтен үти. Хаталанмагыз, адәмнәр! Менә бу бәндәгез кебек уенның кагыйдәсен, табигатьнең кануннарын боза күрмәгез, зинһар! В.И.Ульяновка һәйкәл түгел ул, Сабак-һәйкәл!

Ул һәрвакыт һәр адәмнең хата җибәрергә сәләтле икәнен күрсәтеп, исегезгә төшереп торсын. Бу үзгәртеп кору дигәннәре үзенең билгеле бер ноктасына җиткәч, мавзолейдан ук чыгарып ташламасалар ярый ла?! Аның мәетен хәзер этләр дә ашамас инде...

...Фәлсәфә лекцияләреннән соң баш миләрен сәер фикер-микерләр тәмам шулпаландырып бетерә, билләһи!.. Әллә нинди бөек ачышлар ачылып ташлана шул чакларда! Йа Хода! Үзең ярлыка инде син бу кыз балаларыңны! Ә менә аларның бүген кич кылыначак гөнаһ-гамәлләрен кайчан да булса ярлыкый алырсыңмы соң?..

Хатын-кыз ике төрлегә бүленә: кайберләре тормыштан тәм табарга сәләтле, икенче бер төрлесенең бар белгәне гел зарлану, сукрану.

Уйлар ачык форточкадан өйгә бәреп кергән шарлы яшен кебек. Урамга кире чыгып китмәсә, яндырачак, шартлатачак. Тизрәк ишегеңне, йә булмаса, тәрәзәңне ачып куй әле син! Кайдан килсә — шунда китсен! Алайса шартлавың бар, бахыр...

Әнә, университет колонналары яныннан узып баручы көяз ханымга игътибар ит!

— Әнә минем әни! — дип, терсәк очы белән төртеп алды Әнил.

— Ничек синең әни? Алайса, нигә дәшмисең?! Әйдә куып тотабыз.

— Хәзер куып тотабыз, — диде Әнил тыныч кына. Әмма үзе урыныннан да кузгалмады, киресенчә, эскәмиядән күтәрелә башлаган Кәримәне җиңеннән тартып кире утыртты. Ул кесә телефонын сумкасыннан яңадан чыгарган иде, усал көлемсерәп, номер җыярга кереште. Көяз ханым кул сумкасыннан телефон алып колагына куйды.

— Алло! Мам! Привет! Ты когда домой придешь?

Көяз ханым:

— Исәнме, кызым! Син нигә бу вакытта өйдә түгел әле? Сотовыйдан бит син?

— Әйе, өйдә түгел әле мин, мам! А ты когда придешь?

— Кызым, миленькая, я сегодня немного задержусь после работы, ладно, скажешь папе.

— Ты сейчас на работе?

— Да. А что?

— Ничего, мам. Так просто! Пока, мам!

— Пока, пока, дорогая!

— Хахаль янына бара, — диде Әнил тыныч кына.

— Ничек?! Син нәрсә, Әнил?! Юләр сүзләр сөйләмә инде!

— Юләр сүзләр сөйләмим мин, подружка! Киләсе атнага әтинең защита. Докторский. Ученый совет Мәскәүдә. Әти язган темага бары тик Мәскәүдә генә яклап була. Әни айлар буе Мәскәү юлын таптады инде. Блат имеет. Хәзер ул Мәскәү бабае янына бара. Гостиницага. И бүген төнлә генә кайтачак. В лучшем случае поздно вечером. Она умная, красивая. Смотри, какая походка красивая, правда, да?!

Кәримә, Әнил үзеннән көләдер дип уйлап, авызын турсайта башлаган иде, ләкин тегесе шундук аның баш миен сафландырып җибәрде:

— Ышанмасаң, әйдә артыннан барабыз. Мин хәтта кайсы номерда булачакларын да беләм. Зато мой бедный папа удачно защитит свой докторский, возможно потом его поставят проректором. Если нет, мамочка поможет. Она у меня красивая! Ой, юк, подружка, безнең алар артыннан тикшереп йөрергә вакыт юк, безне Руслан Даулатович көтә. Киттек!

Кыз сикереп торды да Кәримәгә кулын сузды. Әнилнең куллары дерелди, күзләре дымлы иде. Кәримәнең аяк буыннары йомшарды, ул атлый алмас булды. Өстәвенә Әнилгә дә ачуы басылмаган иде әле.

— Син! Син! Ничек?! Ничек! Үз әниең турында шундый пычрак сүзләр сөйли аласың!!! — дип кычкырды ул, кулын кире тартып алып. Бу мизгелләрдә Әнилнең йөз-кыяфәте кара янган, сүзләре ачы, үтергеч иде.

— Ә синең әниең ничек шулай эшли алган соң?!

— Әтине... әтине терелтергә акча кирәк булганга бит ул! Аптыраганнан, гаҗиз булганнан! Син! Син! Минем әниемә тел тидермә! Ул әтиемне бик ярата минем.

Әнил аңа карап мыскыллы көлде дә:

— Успокойся, девочка! Минем әнием дә әтиемне бик ярата! Әти докторскиен якласын дип тырышып йөрүе генә бит. Әтигә докторскийны яклаттырмасалар, ул — бетәчәк!

Кәримә бераз тынычланган иде инде.

— Ничек бетәчәк? — дип сорады ул аннары.

— Эчеп... Минем әти голова! Он очень талантливый физик! Ләкин аңа үсәргә ирек бирмиләр! Хәтта әнинең кандидатскиен да әти язып бирде. Яклавын әни үзе яклады. Әти яза, әни яклый. Икесенә дә Ходай ике төрле талант биргән.

Әгәр бу докторскиен якламаса, әти эчүгә сабышачак! Әни аны ярата. Зур кеше булуын тели. Йә, ярый, разболтались тут! Киттек! Вакыт юк! Руслан Даулатович көтә торгандыр.

«Мин Ходайдан һәм үз-үземнән генә куркам», — дип куйды кыз үзалдына.

Китсеннәр. Кызлар ашыга. Ә безнең вакыт бар. Без Әнилнең әнисе — колонналар янынннан узган чибәр ханым артыннан иярәсе иттек. Әнилнең ачулы чагы — телсез сөяк ни сөйләмәс?.. Үзебез тикшереп карыйк...

Әдилә Кремль урамыннан «Сәфәр» кунакханәсенә чаклы машина тотты. Кунак аны түземсезләнеп көтеп тора иде инде. Ишектән килеп керүгә, киемен салырга булышып, шкафка элде. Мәскәүдә чакта үзен бик иркен тота торган Козлов (Әдилә ханым профессорны фамилиясе белән атый) Казан җирендә үзен ничектер уңайсызрак сизә һәм, үзенең бу халәтен чибәр ханымга күрсәтмәс өчен, бертуктаусыз сөйли, киеренкелекне шул рәвешле йомшартмакчы була иде, күрәсең.

— Тәрәзәдән Казанга сокланып тордым әле. Гаҗәп күренешләр, гаҗәп! Казан искиткеч үзгәргән. Яшь чакта минем Казанны төсле открыткалардан күргәнем бар иде.

— Абрам Ильич, сезнең Казанга беренче тапкыр гына килүегезме? — дип гаҗәпләнгән булды Әдилә ханым, гәрчә Козловның Казанда яшәп алганын белсә дә. Сугыш вакытында этисе, ниндидер юлын табып, гаиләсе белән Казанга хәрби заводка күчүгә ирешә, аннары фәнни институтта эшли.

— Кырыгынчы-илленче елларда Сталин заманы Казаны иде ул. Минем аны искә төшерәсем килми, — дип җавап бирде Абрам Ильич ханымның соравына.

Абрам Ильичны Әдилә кунакханәгә үзе урнаштырган иде, аның килүенә рестораннан ризыклар керттерде. Бүген өстәл төрле тәм-томнар белән тулган. Абрам Ильич аның җилкәсеннән кочып алды.

— Казанның кызлары матур була.

Әдилә карт яһүднең иңбашы аша өстәл өстендәге тәгамгә күз салды һәм эсселе-суыклы булып китте — француз шәрабы юк иде, күрәсең, онытылгандыр. Бу очракта ул кунагы өчен түгел, күбрәк үзе өчен борчылды: димәк, коньяк эчәргә туры киләчәк. Коньяк каты, ул хәзер баш мие күзәнәкләрен чәчеп-таратып ташлый, икенче көнне көне буе шуларны җыеп, тәртипкә салу белән шөгыльләнәсе була. Бөтенләй эчмәсәң? Һе, бөтенләй эчмәсәң... ничекләр итеп бу карт профессорның гел сөяктән генә торган аркасына массаж ясыйсың?! Шулчак Әдиләнең башына кылт итеп бер шәп фикер килде һәм ул әлеге фикернең нәкъ менә аңа иң кирәкле вакытта ярдәмгә килүенә сөенеп бетә алмады.

Абрам Ильич диссертациянең шәп язылуы турында фикер әйтте һәм тиздән совет утырышын җыячакбыз, диде. Әдилә өчен бу бик зур яңалык булып, ул шатланырга, куанырга тиеш иде, һәм моны Абрам Ильичка да ачыктан-ачык сиздерергә бурычлы иде бу мизгелдә. Ләкин теге хәерсез уй һаман гакылын кимерә: «Ничекләр итеп коньяк эчәрмен?» Ул уйларының теленә чыкканын үзе дә сизми калды.

— Шәраб алып керергә әйтергә онытканмын. Мин ресторанга шылтыратып алыймчы, Абрам Ильич, — диде ул, итагатьле генә яклаачак диссертация өчен рәхмәт әйткәннән соң. Ләкин бу вакытта Абрам Ильич, ике чәркәгә коньяк коеп, берсен Әдиләгә сузып маташа иде.

— Өлгерербез, Әдилә Мәннәфовна, өлгерербез. Иң яхшы закуска синең иреннәрдәге француз помадасы. Француз помадасы белән бергә кушылгач, бу француз коньягы затлы шәрабка әйләнәчәк.

«Гафу ит, Фәнилем», — дип пышылдады ул, шул мизгелдә нигәдер ирен күз алдына китереп. Белә иде хатын, алдан күрә: коньяк аны җебетеп ташлаячак!.. Эчкән хатын-кыз өчен иң беренче кабымлык — аның гакылы, беренче чәркәдән соң ул аның яртысын «югалтса», икенчеөченчесеннән соң кабымлык урынына әнә өстәлдә өелеп торган йөзем җимешләре, конфетлар гына калачак. Хәзер хатын-кыз идәнне кулына чүпрәк тотып юмый... Тузан суырткыч... мәгәр чүпрәк тотып юса... бәлкем, идән чүпрәген күз алдына китерер иде, үзен шуның белән чагыштырып караса, күңеленең бер читендә булса гына да горурлык дигән хис уяныр иде дә...

Эттән тугандыр бу хатын-кыз өммәте... Югыйсә шул мизгелдә үк котылу юлын таба алмас иде. Карт яһүд, кесәсеннән кульяулык алып, бик пөхтәләп ханымның иреннәрендәге помадасын сөртеп торган арада (помада кабымлыкка булыр дигән иде үзе!), шалт, Мөхәммәтҗан, аның түм-түгәрәк башкайларына янә бер шәп фикер килеп кунмасынмы!

— О-о-о! Абрам Ильич, гафу итегез, мин онытып та торам икән ич. Мин сезгә сюрприз әзерләдем бит әле!

Абрам Ильич чәркәсендәге эчемлекне чәй эчкән кебек шупырдатып чөмереп куйды да Әдиләгә текәлде.

— Сауна... Менә дигән сауна әзерләп куйдым бит мин сезгә. Шундый хөрмәтле кеше Казан чаклы Казанга килеп массаж алмыйча китмәстер инде, шәт!

Ул тиз генә телефонга үрелде һәм кайсыдыр мунчага шылтыратты, икенче шылтыратуы таксига иде.

Абрам Ильич су ярата торган кеше булып чыкты. Казанда торганда аларның бакчалары да Казансу ярында ук булган икән, хәзер Яңа Савин районы җирендә, йөзмә күпер читендә үк. Анда Казансу аша яңа күпер салыначак.

Номер иркен иде. Чиста, пөхтә. Әдилә ханым бу номерга иптәш хатыннары белән еш йөри һәм, Казанның бар гайбәте шунда чәйнәлә-чәйнәлә дә, тәмам мунчалага әйләнгәннең соңында, юылып, чистарынып, шулардан арынып чыга иде алар. Гайбәт чүлмәкләре тула башлагач, әлеге дус дүрт хатын янә җебенергә җыеналар. Люкс номерда бар нәрсә дә кеше өчен эшләнгән иде. Саунадагы такталарына кадәр сап-сары юкә... Такталардан тезелгән ләүкә, күн диван, душ кабиналары.

Әдилә ханым, ишекне эчтән бикләп алгач, массаж ясаучы кызга анадан тума чишенергә боерды. Унҗиде яшьлек чибәр чуаш кызы аның үзенә караганда да кыюрак булып чыкты: иң беренче чишенеп ташлап, массаж өстәле кырыена хуш исле төрле крем-майларын тезеп куйды да, душка кереп чыгып, иңенә сөлге салды һәм Абрам Ильичның чишенгәнен көтеп тора башлады. Әдилә плащын салып элде дә телевизорлы бүлмәдәге күн кәнәфигә чумды.

Вакыт бик озак узадыр кебек тоелды аңа. Ниләр генә уйлап бетермәде шул арада Әдилә Мәннәфовна. Тиздән доктор булачак ире турында да, буйга җиткән студент кызы Аниль хакында да. Шунысы гаҗәп, үзенең кунакханәдәге баягы кыланышларын исенә төшереп, хәзер үзүзеннән көлә иде ул. Ник фикере кинәт үзгәрде соң әле? Югыйсә ул саунага да кермәде — фикерләре җебемәде; коньяк та эчмәде — баш шәрифләре чуалмады. Әллә... әллә... яшь кызның күкрәкләре арасына борынын төртеп күн диванда утырган ир сыныгы гаеплеме моңа?!

Адәм баласы организмының нигезен табигый күзәнәкләр тәшкил итә. Алар гакыл биләмәсендә. Шул биләмәдән беркая да читкә чыга алмыйлар. Гакыл — сакчы. Ышанычлы, сау-сәламәт сакчы. Бер чәркә эчемлек гакылны җебетеп, хәлсезләндерәчәк, уяулыгын югалттырачак. Иренә бер хыянәт итеп караган хатын-кыз яшь, сусыл уҗым тәмен татыган мәнсез сыер хайваны кебек. Улагына алтын башак салсаң да, аның «койрык очы» һәрвакыт уҗымга тартачак. Рухи көчне кыргый инстинкт таптап, сытып китә ала.

Әдилә ханым әһ дигәнче чишенеп атты да, рәттән ике чәркә коньяк эчеп, шоколад капкалады һәм, каты эчемлек кендек турысына төшеп җитеп, кымырҗый, кыздыра башлагач, массаж бүлмәсенә чыкты, һәм аның карт яһүденә сөлек булып ябышкан кызны шәрә иңбашларыннан каптырып куптарып алды да саунага куып кертеп җибәрде...

— Ты слишком красива!.. — диде Абрам Ильич, баш бармаклары белән ханымның күкрәк башына орынып.

— ...чтобы быть нормальным человеком, — дип дәвам итте әлеге фикерне баш мие парланган Әдилә Мәннәфовна.

### Аклану

Мин түрә ханым белән карт яһүд турындагы бүлекне яздым да, автор буларак, үз-үземә ачуым килеп, каләмемне читкә тотып аттым. Ни хакым бар соң минем бар хатын-кызны да бер чыбыкка тезеп чыгарга?! Ниндидер фәлсәфәчеләрнең фикерләренә таянам, имеш, әллә кайчан күзгә чалынып, хәтердә калган тапкыр сүзләрне файдаланып, геройларымның гамәлен пичәтләп барам, имеш!

Минем кияүдә дүрт сеңлем бар. Шушыннан соң аларның күзләренә ничек күренермен?! Нигә мин, иҗат итә башлаган романымнан бүленеп, әлеге бәян-кыйссага тотындым соң әле?

Әнә шундый уйлар битәрләргә кереште мине. Һәм кульязмамны язу бүлмәсендәге шкафның бер караңгы почмагына тотып аттым.

Бу вакыйгадан соң берәр атна вакыт уздымы икән, урамда элеккеге сабакташым — Ырынбур егете Заһидны очраттым. Ул миңа фаҗигале яңалык җиткерде. Безнең бүлек кызы Әнилне кичә кич ниндидер машинага утыртып алып киткәннәр дә... Әйе, әйе, суынып беткән шәрә гәүдәсен Салмачы бистәсе янындагы урманнан табып алганнар...

Мин бик каты тетрәндем. Башыма күсәк белән суккан кебек булды. Берничә көн гел шул хакта гына уйлап йөрдем. Аңыма килгәндә, минем өчен янә яңалык ачылган иде: әлеге кыйсса-

да бер героемның прототибы да нәкъ шул Әнил үзе иде бит инде һәм... Һәм төп образ аның туганнан туганы Камилә. Шул кызларның язмышларын сурәтләгәнмен бит мин!..

Бу әсәр хатын-кызның һәммәсен дә бер чыбыкка тезү максатыннан язылмый. Үзем дә хатын-кыз дөньяга тудырган җан иясе. Күп кызларның гөнаһсыз яшьләренең сәбәпчесе бит... үзем дә... Шуларның, берәрсенең, каргышлы күз яшьләре тоткандыр да әле мине?.. Юкса яшем утыздан узып китте, һаман өйләнә алмыйча йөрим.

Бер караганда, Австралия феминисткаларының лозунг-чакыруы миңа тач туры килеп тора инде: «Әгәр ир-атны тотсагыз, күтенә тибегез!..»

### Фагыйләтен-тайбәтен...

Руслан Даулатович янына барудан бик курка иде Кәримә. Лекция-семинарларда гына күрергә ияләшкән укытучыңа ничекләр итеп үз тормышыңны ачып салмак кирәк? Уңайсыз бит, ояты ни тора?! Ләкин бармыйча чарасы да юк... Әнисе хакына бит... Бу көннәрдә ул газиз әнкәсе өчен ут-суларга керергә әзер. Әйе, ул аны әүвәл каргады, сүкте, күралмас дәрәҗәгә җиткән иде. Ул бит... ул бит акча эшлим дип... Сәгыйт Сәетович капкорсакларының күңелен күргән ләбаса... этисенә хыянәт иткән. Кәримәнең урын өстендәге этисен коткарам, аякка бастырам дип... шул ук эти кешегә хыянәт иткән!

Ул көнне, дөресрәге, ул хәерсез кичне... Аракы чөмерә-чөмерә дуңгыз хәленә килгән өч хайвани зат... өчесе берьюлы мыскыл итәргә уйлагач, Фәгыйлә, хурлыгына түзә алмыйча, хәер, бәлкем, үз-үзен белештермичәдер: кухня пычагы белән бер кунакның корсагын тишеп агызган булган. Теге бәндә үлүен үлмәгән үзе — эчәкләрен кире җыеп алып өлгергәннәр. Алай гына булса, бәлкем, эшне зурга ук та җибәрмичә йомарлар иде. Ләкин үткен пычак түрә-бәндәнең «җан җирен» дә яртылаш кыеп төшерергә өлгергән икән шул.

Фәгыйләне утыртып куйдылар...

Менә хәзер шушы вакыйганы укытучы кешегә сөйләп бирергә туры килер микәнни, Ходаем!..

Ләкин янында атлаган Әнил аңа уй дөньясында алай озаклап хисләнергә ирек бирми.

— Акча кирәк булачак, күп акча! — дип куя Әнил, Кәримәгә күтәрелеп карап. — А может, кирәк тә булмас әле.

Кәримә аның әлеге сүзләреннән берни төшенми, шулай да шәрехләвен сорамый, Әнил барысын да үзе аңлатып бирәчәк.

— Синдә нинди эчке киемнәр?

Нинди мәгънәсез сорау бирә инде бу тагын?!

— Нәрсә булсын — трусик та лифчик инде!

— Нинди төстә дип сорыйм?

— Зәңгәр... нигә?!

— Кара булса, эффектлырак... и кара колготки...

— Син нәрсә, Руслан Даулатович белән постельгә ятарга кирәк булмаячактыр ич?! — дип сорады күзләре зур булып ачылган Кәримә. — Мине... кем беләндер постельгә салырга уйламыйсыңдыр ич! Тогда пошла ты к черту, яме!

Кәримә атлавыннан капылт туктап калды. Аның аяк буыннары дерелдәргә керешеп, хәлсезләнгән аягында көч-хәл белән генә басып тора, менә-менә егылып китәр төсле иде.

— Әниең хакына дамы?!

— Причем монда минем әни?

— Аны коткару өчен, — дип шәрехләде Әнил, гап-гади генә итеп, ләкин бик аңлашырлык җөмләләр белән.

— Аниль! Син... син чынлап тамы?

Әнил, капылт туктап, группадашының йөзенә күтәрелеп карады да, Кәримәнең мәет төсе кергән кыяфәтен күреп, кычкырып көлеп җибәрде, үз итеп, яратып аның җилкәсеннән кочып алды. Әллә шаярта, әллә чынлап сөйли иде Әнил, ул тагын Кәримәгә ят булган табышмакка күчте:

— Неужели син... кыз кеше әле?! Бер дә ир-ат белән йоклап караганың юкмыни соң? — дип сорады ул, бу юлы җитдиләнеп.

Кәримә, беренче сыйныф баласы укытучысының соравына уйламыйча-нитмичә җавап биргән кебек:

— Юк... Нигә? — дип куйды.

— Девственницалар кыйммәт тора!

— Аниль! — дип кычкырып җибәргүен Кәримә үзе дә сизми калды.

Бауман урамы буйлап ваемсыз агылган халык төркеменнән кемнәрдер аларга таба борылып карады. Шулчак каршыларына әзмәвердәй ике егет калыкты.

— Девчонки, хотите заработать? Пошлите с нами! — дип бәйләнде берсе, бакыр сыман оятсыз карашын әле Кәримәгә, әле Әнилгә күчереп. Кәримә курка калды, аяк буыннары капылт йомшарып, тез астының хәле киткәндәй булды. Әнилнең генә исе китмәде, ул каршысында басып торган әзмәвернең берсен юлыннан төртеп җибәрде дә:

— Пошел вон! — дип, юлын дәвам итте, икенче кулы белән Кәримәнең кулыннан эләктерде. Мондый кыюлыктан егет кисәкләре үзләре дә каушап калганнар иде бугай, бәйләнеп артларыннан иярмәделәр.

— Руслан Даулатовичка ошаячаксың син. Ул сиңа ярдәм итәчәк!

«Гөнаһсыз кыз бала булганым өченме?» дип сорарга Кәримәнең батырлыгы җитмәде.

Руслан Даулатович кызларны институт ишеге янында урамда көтеп тора иде. Кәримә шундук игътибар итте: профессор киемнәрен алыштырып өлгергән, костюм-галстукларын салып, хәзер ул соңгы модалы киемнәрдән иде. Бу киемнәрдән ул хәйран яшәреп тә киткән, хәтта тавышында да көндезге таләпчән кырыслык калмаган төсле: әйтерсең кызлар белән бергә укып йөрүче өлкән курс студенты гына...

Ни гаҗәп: килеп җитешкә, Әнил Руслан Даулатовичны култыклап алды, әйтерсең кинога барырга чакырган егете!

Алар, Кәримәне чак кына артта калдырып, алданрак атладылар: Кәримәнең йомышын әйтү өчен Әнил махсус шулай иткән иде. Ул иптәш кызының кызу-кызу сөйләвеннән берни дә аңламады диярлек, дөресрәге, аның ни әйтүе әһәмиятле дә түгел кебек иде. Руслан Даулатовичка хәлне сөйли торгандыр — инде катлаулы төенне чишү өчен аның тиктормас теле тагын нәрсәләрдер әйләндереп чыгара икән — берни кылып булмый: ул аңа үзе риза булып иярде, гәрчә Әнилнең баягы юклы-барлы куркыныч сүзләре кара мәче кебек аның эчен тырнап тора, гәүдәсендәге калтырау бер кимегәндәй була, беравыктан тагын отыры көчәеп, тез буыннарын йомшарта, аякларын калтырата, бәлки, шул сәбәпле артта кала, аларга ияреп бара алмый торгандыр да әле... Руслан Даулатовичның сүзләрен ачыгырак ишетәсе килә иде аның: «ярар» диярме икән яисә итагатьле итеп кенә кире кагармы? Андый хәл була калган очракта, Кәримә үзе, Руслан Даулатовичның икенче ягыннан эләктереп алып: «Мин риза, Руслан Даулатович!» — дип, сүзгә кушылырга әзер торырга уйлады. Ничек итеп кенә булса да аны ризалатырга, ничекләр итеп кенә булса да «юк, булмый» дигән сүзне әйттермәскә иде бит канә!!! Чү, туктап тор әле... «Мин риза» дип сүзгә кушылырга әзерме соң ул?! Нәрсәгә риза икәнлеген үзе дә белмәгән килеш... Әйе, нәрсәгә риза?..

Кәримә шул уйларын тагын бер кат күңеленнән кичерде дә башын түбән иде: нигә үз-үзен бимазалый — нәрсә икәне мәгълүм бит инде, көн кебек ачык...

Урам почмагында Руслан Даулатовичның машинасы тора иде. Алар шунда утырдылар. Арткы утыргычка кереп чумган мәет кыяфәтендәге Кәримәгә Әнил:«Все нормально!» — дип пышылдарга өлгерде. Шуңа күрә ул бу минутларда үзе түгел, әледән-әле тәне эсселе-суыклы булып китә, йөрәге лепер-лепер тибә, ул йөрәгенең тавышын ишетә, типкәнен ишетә, ләкин ни әйткәнен ишетми — йөрәк сөйләшә белми, белсә, ни дип әйтер иде икән? Ачуланырмы, әллә хупларmы бу гамәлләрен?! Кая хупласын инде, хупласа, бу чаклы каты типмәс, күкрәк читлеген ватардай булып сикермәс иде. Каршы ул... Бәлкем, сөенеченнән шулай җилпенә торгандыр, ә? Әнисен уйлап борчылган чакларында йөрәге гел авыртып кысылып-кысылып куя торган иде бит... Бәлкем, хәзер тынычланыр, бар да әйбәт булгач, әнисе котылып ирекkә чыккач, борчылырга бүтән сәбәп тә калмаячак бит югыйсә? Йөрәге дә тынычланып калачак. Бәлкем, шуларны уйлап, алдан ук җилпенә торгандыр ул, бахыр?..

«Күп дигәндә тагын бер айдан!..» Әйе, әйе, нәкъ шул вакыт эчендә Кәримәнең әнисе ирекkә чыгачак! Һәрхәлдә, аңа шулай дип вәгъдә иттеләр...

Руслан Даулатовичның берүзенә өч бүлмәле фатир. Аның берсе китап киштәләре белән тулган, стенасында китап шкафы булмаган ярты метр да урын калмаган. Анысы профессорның эш бүлмәсе дә икән. Калган бүлмәләрнең берсе кунаклар кабул итү өчен, бәләкәйрәге — йокы бүлмәсе.

Әнил, кесә телефоны шылтырауга, каядыр китеп барды. Тик өйгә кире кайтам дип әйтмәде. Алар Руслан Даулатович белән фатирда икесе генә калдылар, буйдак профессор һәм яшь студент кыз. Руслан Даулатович телефоннан хәбәр көтте. Ул хәбәр Кәримәнең әнисенә бәйле иде, шуңа күрә Әнилгә ияреп кайтып китү хакында ничектер уйламады студент кыз, әйтерсең профессорына имтихан бирергә килгән; әллә ялган, әллә чын: чибәр студент кызлар зачет яки имтихан куйдырырга бакча-дачаларга йөри икән дип тә ишетеп белә иде. Юк, алай булмас! Менә укытучысы аңа бик җиңел генә сорауга җавап бирергә кушар да, ул тиз генә киенеп, рәхмәтләр укый-укый, үзенең шыксыз тулай торагына кайтып егылыр. Буйдак профессор болын чаклы фатирында япа-ялгыз башы торып калыр. Чөнки аның вакыты юк, профессорның үз фәнендә яңа ачышлар ясыйсы бар...

### «Ахырзаман башы»

Яшь профессор студент кызның эчке калтыравын сизде булса кирәк, әллә Кәримәнең тышкы кыяфәте чынлап та куркак куянны хәтерләтә иде инде, җиңелчә генә өстәл әзерләде, кофе кайнатты, кызга исә, буш утырмасын өчен, «теләсәң, китаплар белән таныша аласың» дип, ымлап, үзе бик озак кына кухня ягында югалып торды.

Тыш-кыяфәте белән генә түгел, хәтта бар халәте белән бу мизгелләрдә чынлап та бүре авызына керергә әзерләнгән куркак куянны хәтерләткән кыз, Руслан Даулатович аны бала-чагага саный һәм шуңа күрә юата, тынычландырырга тели дип уйлап, чак кына турсайды, үпкәләгән сыман да булды; үзенең куркак куян түгел икәнлеген расларга теләгәндәй, «Булышыйм!» дип, әүвәл кухня якка да кергән иде, профессор итагатьле генә кире какты — «Юк, юк, мин үзем. Син әнә китаплар караштыргалый тор!»

Руслан Даулатович, үзе кабатларга яратканча, шактый катлаулы язмышлы кеше иде. Аның әбисенең әнисе — карт әбисе — узган гасыр башында Урта Азиягә мөгаллимәлеккә чыгып киткән яшь татар кызы — шунда бер үзбәккә кияүгә чыгып, төпләнеп калган Казан арты татары. Бер-бер артлы дөньяга килгән унике кызның язмышы һич кенә дә бер-берсенә охшамаган — кайсы, шундагы үзбәк-казакъларга кияүгә чыгып, чит милләтләрнең дәвамчылары булып, сеңеп-эреп беткәннәр. Руслан Даулатовичның әбисе исә үзбәк егетенә тап була. Шуннан соң аның нәселендә янә Кырым татары бар, соңгы буыннары тагын Гайнә татарлары белән кушылып киткән.

Руслан акыллы, чибәр егет булып үсте. Заманында Ленинградтагы югары уку йортларының берсендә фәнни коммунизм факультетын тәмамлаган егетне зур түрә булыр дип фаразладылар. Ләкин ул, барысын да шаккатырып, фән юлыннан китте һәм үзе мондый һөнәр сайлауга бер дә үкенми иде. Гадәттә, төгәл фәннәрдә генә зур ачышлар ясап, дөньяга танылырга мөмкин. Әмма безнең Руслан Даулатович нәкъ менә гуманитар фән өлкәсендә дөньяви ачыш ясарга хыялланган бер исәр галим иде. Фәнни коммунизм факультетын тәмамлап, инде бу түрә булып китәр дигән өметләрне өзеп, укырга, янә белем эстәргә дип, икенче уку йортының биология факультетына барып кергәч алды ул «Исәр» дигән исемне. Үзенә тагылып йөргән әлеге исәрлек егеткә бик ошый, чөнки белә, күреп тора бит: исәр булмаган адәм беркайчан да дөньяви ачыш ясый алмаячак!

Хәтта аның сөйгән кызы да бар иде. Хәтта ул сөйгән кызының зур урыннарда теш казып утырган түрә ата-аналары ярдәме белән тормыш дигән бу фани дөньяның иң бөек ноктасына менеп, шуннан гына бер кайгы-хәсрәтсез дөньяның арт ягына тибеп яши ала, хәтта аңа дөньяви ачыш ясарга да комачаулык итмәячәкләр иде. Ләкин... ләкин. Тормышның шул «ләкин»нәре булмаса әгәр... Өйләнешеп ике-өч ай узмагандыр, аның сөекле хатыны бер дә бер көнне кайтып керде дә: «Руслан, мине факультетның деканы итеп сайларга (куярга иде, дөресрәге) исәплиләр», — диде. Бу вакытта алар икесе дә Петербургның бер югары уку йортында укытучы, фәннәр кандидатлары иделәр. Әлбәттә, хатынны зур урынга түрә итеп куюларына сөенергә генә кирәк булгандыр. Руслан әүвәл куанды да кебек. Ләкин яши торгач, бу сөенечләр яшь ир-атның күңелендә көенечләр белән алмашына барды. Хатынның эштәге түрәлек «холкы» өйгә дә ияреп кайта башлагач, ир кинәт кенә тәртәгә типте — Азия мохите белән сеңгән патриархатлык галәмәте көнкүреш тормышының гап-гади мәсьәләләре белән дә килешергә теләмәде бугай — түрә хатын белән юллар, бер чатка җиткәч, икегә аерылып, төрле якка китеп бардылар.

Яшь, чибәр ир тора-бара докторлык дәрәҗәсе алды, профессор булды, тормышында төрле-төрле хатын-кызлар да очрамады түгел. Ләкин ул яши-яши һаман бер нәрсәгә гаҗәпләнә бара: җәмгыять эт җамаягы кебек әйләнгән, асты өскә килгән, кайчандыр үз җаена гына тәгәрәгән тә-

гәрмәчне кемдер таудан этеп төшереп җибәргән һәм ул, бер түмгәккә туры килеп, хәзер туры юлын үзгәрткән дә упкынга таба барып маташа кебек иде.

Кәримә исемле иде Руслан Даулатовичның беренче хатыны... Беренче хатыны гына түгел, күңелен, бәгырь телемнәрен уеп алган мәхәббәте дә! Яшь егетнең җанында туган иң тәүге, иң садә хисләр шул кыз белән бәйләнгән иде. Ул аны акылы белән түгел, күңеленең иң-иң нечкә хисләрен кушып яратты. Алар тагын кушылдылар, әмма бәби табуга кадәр барып җитә алмадылар — Кәримә, докторлыгын яклап, шул араларда аны проректор итеп куясылар иде — бәби алып кайту арткырак планга күчеп торды. Тагын икесе ике якка киттеләр. Әмма бер шәһәрдә яшәделәр, төрле уку йортларында эшләделәр. Сирәк-мирәк кенә булса да күрешәләр дә иде. Туган көннәр, бәйрәмнәр гел бергә узды. Икесе дә нәкъ печән өстендәге эт кебек иделәр: ерагаеп та китмәделәр, кушыла да алмадылар. Һәм мондый хәл озакка да сузыла алмас, кайчан да булса барыбер бер чиге чыгар, дип уйладылар күңелләреннән генә.

Андый чик булды, бер дә көтмәгәндә һәм бик сәер, гайре табигый рәвештә. Бердән бер көнне Русланга докторлык диссертациясен яклау турында читтән тәкъдим ясалды, ул әле аны-моны уйлап җиткергәнче, тәкъдим артыннан бик тиз генә яклау да булып узды. Дөрес, аның бу вакытта үз темасына монографиясе дә, саллы гына фәнни мәкаләләре дә бар иде. Фәнни җитәкчесе Аркадий Ильич — үтә итагатьле яһүд карты — Русланның мондый тизлегенә үзе дә аптырап калды. Чөнки шәкерте, бер караганда, алай тиз генә якларга ашыкмый, һаман эзләнә, винегрет кебек буталып беткән бүгенге фәлсәфә фәнен үзенчә тәртипкә салырга азаплана кебек тоелган иде.

Бу эштә Кәримәнең каты кулы уйнаганын Руслан Даулатович үзе генә сизде. Һәм, шуны белүгә, шәһәрне үк ташлап, ерак әбисенең туган якларына китеп барды...

Дөрестән дә, сәер гамәл кебек иде бу бер караганда. Бер яктан караганда да шулай, икенче яктан караганда да...

Ир-атның үз горурлыгы була. Ул горурлык аны ир итә, чүпрәк булудан гына түгел, хәтта чүпрәк-чапраклар арасында да буталып калырга ирек бирми... Дөнья яшь галимнең әнә шул горурлыгына тиде булса кирәк... Дөнья шайтаннар, фәрештәләр белән тулган гаҗәеп серле һәм шул ук вакытта бик буталчык, яктылы-яктысыз мәгарә сыман...

Руслан Даулатович җәмгыятьтә шау-шу куптарырга тиешле хезмәтенең исемен әүвәл «Ахырзаман ахыры» дип куймакчы иде. Ләкин уйлый торгач, әлеге исемне үзе үк килештермәде — гап-гади мәкалә исемен хәтерләтә шикелле. Шәп фикер үзеннән-үзе килде: «Яңа Манифест»... Әйе, чынлап та, дошманга үз күсәге белән орсаң, үтемлерәк булачак бит! Руслан Даулатович дошман дип, эченнән генә көлеп, Маркс белән Энгельсны атый. Аларның тулаем хезмәтләрендә аның эше юк. Иң куркынычы — алар, җәмгыятьтәге ике җенес арасында шактый буталчыклар китереп чыгарып, җәмгыятьне астан кимерә торган «корт»лар уйлап тапканнар. Шул демагоглар аркасында эксперимент буларак җитмеш кенә ел яшәп алган Советлар илендә адәмнәр өстенә коточкыч бәла-казалар, бәхетсезлекләр килгән!..

Ир-ат белән хатын-кыз тигезлеге хакында иң беренче сафсата сатучылар да шулар бит! Маркс белән Энгельсның «Манифест Коммунистической партии» әсәрендә һәм Энгельсның «Происхождение семьи, частной собственности и государства» хезмәтләрендә үк гаилә мөнәсәбәтләрен бутау башлана. Имеш, балалар гаиләдә түгел, ә җәмгыятьтә тәрбияләнергә тиеш. Имеш, хатын-кызның төп көче гаиләдә түгел, ә иҗтимагый хезмәт, эш урынында файдаланылырга тиешле!.. Аларча, гаилә хатын-кыз өчен төп хезмәтләре белән чагыштырганда вак-төяк шөгыль генә булып калырга тиешле...

Табигать хатын-кызны хатын-кыз итеп, ир-атны нәкъ менә ир-ат итеп яраткан да инде. Әлеге ике җенесне берүк төрле яссылыкка кую, ирләр генә башкарырга тиешле хезмәтне үтәүне, ул да тигез хокуклы ич, дип, хатын- кыздан да таләп итү — ахмаклыкның һәм, алай гына түгел, хатын-кыз бәхетсезлегенең иң биек ноктасы! Нәкъ шул ахмаклыкның гади генә, ләкин тормышчан мисалы итеп кулларындагы ломнар белән трамвай юлларын ремонтлаган апаларны, химия заводларында сәламәтлеген какшаткан хатын- кызларыбызны китерергә булмыймыни!

Хатын-кыз ул Илаһи зат!!! Хатын-кыз, беренче чиратта, бәби табу сөенечен кичереп, гаилә учагының иң якты уты булырга тиеш! Иҗтимагый хезмәттә катнашу яки катнашмау (нинди микъдарда катнашу) беренче чиратта хатын-кызның үз ихтыярыннан гына торырга тиеш! Ул яши торган җәмгыять исә аннан шуннан артыгын таләп итәргә тиеш түгел! Ир-ат белән рәттән дүрт сәгать эшләгәне сигез сәгатькә исәпләнергә тиеш! Ә теге демагог яһүдләрнең тәгълиматы нигезендә корылган ялган, алдавыч фикерләр исә әүвәл җәмгыятьнең табигый үсешенә зыян

салды, шуның белән беррәттән хатын-кызны бәхетсез итте! Алардан ир-ат ясады, ир-атны чүпрәк итте!!!

Хатын-кыз сөяр һәм сөелеп яшәр өчен яратылган зат! Ул, беренче чиратта, ир-атның илһамчысы, рухландыручысы булырга тиешле зат!

Ана теләге баланы диңгез төбеннән чыгарыр, ди! Шәхестә, индивидта бары тик ана мәхәббәте генә кешелек күзәнәкләрен тәрбияли ала, ул аны үзенең баласына булган мәхәббәтенең илаһи көче тәэсирендә тормышка ашыра!

Җәннәт аналарның аяк баскан урынында!!!

Ир-ат әгәр дә бөек җиңүләргә ирешә икән яки зур гамәлләр кылырга сәләтле икән, беренче чиратта, ул моның өчен хатын-кызга, бары тик хатын- кызга гына бурычлы!!!

Әнә шул аксиоманың, тормыш, яшәеш аксиомасының, кайчандыр «муены сындырылды», барлык бәлаләрнең башы тик шуннан гына!!!

Ул демагогларның ялган тәгълиматы Руслан Даулатовичны бәхетсез итте — сөйгән хатыныннан аерды...

Аның тамырларында гына да бит әллә ничә төрле милләтнең каны ага! Кем аркасында! Хатын-кыз аркасында!!! «Ирек» хатын-кызга теләсә кемгә кияүгә чыгарга мөмкинлек бирде! Һәм шуның белән ул кавемне дә бәхетсез итте!

Цивилизация куркыныч алдында! Аны коткарып калу өчен хатын-кызны үз урынына, ир-атны үз урынына утыртырга кирәк!..

«Хатын-кызга яңадан пәрәнҗә ябындырып, аны үз ихтыярыннан башка яратмаган кешесенә кияүгә бирү синең черегән цивилизацияңне коткарып калырмы соң?!»

«Хәзер берничә буын яшьләр гарип буын буларак тәрбияләнеп килә. Гаиләдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт — бала тәрбиясендә, аның шәхес булып формалашуында төп этәргеч!»

Гаиләләрдә хөкем сөрергә тиешле гади генә табигый баланс бозылды. Патриархат та түгел, тулысынча матриархат та юк.

«Мат-Пат» дип аталган яңа төр винегрет. Ә ул нәкъ менә балаларның ашказаннарын боза да инде, черт побери!»

Я научила женщин говорит...
Но, боже, как их замолчать заставить?

Бу юлларны хатын-кыз шагыйрә язган.

Руслан Даулатовичның әлеге мәсьәләгә булган карашы шактый четерекле, катлаулы иде. Чөнки Марксны тәнкыйтьләп кенә хакыйкатьне ачып-аңлатып биреп булмаячагы сукыр күзгә дә күренә. Каннар бозылу галәмәте — төрле милләтләрнең буталуы — аның хезмәтендә, дөресрәге, бөек ачышларында шулай ук әһәмиятле фактор буларак өйрәнелергә тиеш ләбаса, дип фикер йөртте инкыйлабчы галим. Җәмгыять, беренче нәүбәттә, ныклы гаиләдән торырга тиеш, тагын да төгәлрәк әйтсәк, милли гаиләдә тәрбияләнеп үсәргә тиеш яшь буын.

Әлеге ачышларны ясау өчен теория белән гамәлне кушу мәҗбүри микән дигән мәсьәлә-сорау исә үзеннән-үзе хәл ителде — фәнни институттан югары уку йортына күчкәч, имтихан бирә алмый интегеп йөргән чибәр студент кызлар яшь профессорның тәмам башын әйләндереп бетерә яздылар.

Тол профессорның өендә телефон шылтырады.

— Бәхетле йолдыз астында тугансың икән... — Руслан Даулатович китап киштәсе янында тынсыз калып, аннан түземсезләнеп нинди дә булса хәбәр көткән кызга карап торды да: — Әниең Казанда гына калачак. Һәм... ким дигәндә бер айдан ул иректә булачак!

Бу мизгелдә кызның гәүдәсе генә түгел, бөтен барлыгы — гакыл-хисләре, җаны һәм бар рухы — пружина кебек киерелгән иде. Хис-пружина кинәт бушады һәм ул, үз-үзен белештермичә, каршысында басып торган, үзе өчен әлеге минутларда дөньядагы иң изге кеше булган ир-атка таба атылды да аны кочып алды.

Әлеге «шатлык йолдызы» һич көтелмәгәндә атылды ки, Руслан Даулатович, аягында басып кала алмыйча, артындагы диванга ауды. Кыз аны шашына-шашына битеннән, маңгаеннан үбә, аның җир җиләге сыман сусыл һәм өстәвенә кап-кайнар иреннәре, тол ирнең кытыгын китереп, гакылын томалап куйды да, калган гамәлләре бары тик хисләр иркендә калдырылып, тәмам каушатты, уянырга өлгергән күзәнәкләре ары-бире чабулый башлады, аннары, тәмам буталышып бетеп, юлларыннан ук яздылар һәм аны да үз артларыннан иярергә чакырдылар. Менә

аның кулы ирексездән кызның тыгыз күкрәкләренә орынып китте, шуннан соң инде яшь ир тәмам хисләр иркендә генә калырга әзерләнде. Ләкин ниндидер көч, иңбашларыннан тотып диярлек, кызны диваннан тартып торгызды, ул әле нәрсә булганын да һәм алда ни булачагын да аңларлык хәлдә түгел, тәне әле яңа гына салкын суга чумып чыккан кебек калтырана, йөзе генә түгел, җиләк кебек кызарышып, тулып торган иреннәре дә ап- ак булды, әмма ул, үзендә көч табып:

— Рәхмәт сезгә, Руслан Даулатович! — дип әйтә алды шикелле.

Чыннан да, рәхмәт Руслан Даулатовичка, рәхмәтнең дә иң зурысы! Ул бер сүз дә әйтмәде, бары матур итеп елмайды һәм, кызны юатып:

— Борчылма, Кәримә, бар да яхшы булыр! — дип, юатыр сүзләр дә тапты әле. Әлбәттә, аның бөтен эчен җиңелчә генә калтырау алып, йөрәге, нәрсә булса да көткән шикелле, дөп-дөп тибәргә керешкән һәм тамырларындагы канны да гадәттәгедән көчлерәк, тизрәк куа, шул сәбәпле кан басымы күтәрелеп, аны сугышчан халәткә китереп җиткерә язган иде инде.

Бераз суына төшкәч, ул: «Шөкер!» — дип куанып куйды. Бу кыз аның диванында аунаган башка студент кызлар кебек түгел, аларга охшамаган! Мәсьәлә исеменең беренче хатынныкы кебек Кәримә булуында гына түгелдер инде, әлбәттә.

Руслан Даулатович яшь, чибәр һәм, кагыйдә буларак, шактый надан кызларның, имтихан бирә алмауларыннан файдаланып, аларны үз ястыгына салучылардан түгел, тол ирнең андый максаты юк. Ул чытлык кызлар һәрвакыт аңа үзләре җәтмә коралар, очраклы, көтелмәгән әллә нинди очрашулар оештыралар. Дүртенче дистәне җыюына карамастан, Руслан Даулатович яшьләр булган кичәләргә йөрергә ярата, турыдан-туры катнашмаса да, шул мохитнең һавасын ярата тол ир, шул рәвешле ул үзенең яшьлеген эзли, яшьлегендә өзелеп яраткан Кәримәсен янадан эзли. Бу заманда кырык яшь ир-атның чәчәк аткан еллары булса да, кем әйтмешли, «Яшем җитте кырыкка, эшем китте шырыкка» дигән әйтем куркыта аны. Нәкъ менә шул «шырык» аркасында аның күңеленә мең төрле шик-шөбһә кереп оялый да рухын басып, сытып тора. Фәнни эш белән шөгыльләнсә дә, Руслан Даулатович фәнни институтлардан урын эзләп йөрмәде, укытасы, яшьләр арасында буласы килде аның. Китап, лекцияләргә ябышып ятарга яратмаган чибәр кызлар аны, тол профессорны, Казанның мең төрле почмагының көтелмәгән борылышында очраклы рәвештә генә очратып, ялгыз ир-атның кытыгын китерәләр, бу эшнең ахыры Руслан Даулатовичның өч бүлмәле фатирында шәм яктысында тәмам кылына иде гадәттә. Студентларның наданлыгын яки фәнне төшенеп, аңлап бетермәүләрен файдаланамы ул?! Әүвәл Руслан Даулатович үзен зур җинаятьче итеп хис итә иде. Тора-бара бу авыр хис үзгәрде. Ярый, хуш, надан студент кызга, бер мәртәбә аның фатирында очрашып, яхшырак аңлашканнан соң, ул аның зачеткасына шәп билге дә «утыртты» ди һәм шуның белән моңа нокта да куелырга тиеш бит инде. Юк... теге кыз өч көннәнме, берәр атнаданмы, ниндидер дөньяда булмаган ахмак сәбәп тапкан булып, юлына тагын килеп чыга яки батыраеп фатир ишеген шакый. Югыйсә аның фәненнән имтихан да бирәсе юк бит инде канә!..

Бу кыз балаларның әтиләре алып биргән чит ил машиналарында җил куып йөргәннәрен белсә дә, мескен, хәерче стипендияләргә мохтаҗ түгел икәнлекләрен белсә дә (аларга шәп билге кую өчен аталарының телефон трубкасын күтәреп куюлары да җитә югыйсә), баштарак аларның бу җилбәзәк гамәлләрен башына сыйдыра алмыйча азапланып, интегеп йөрде. Ниһаять, үзенә кунакка килгән бер тау ягы кызы бик ачык итеп аңлатып бирде аңа мәсьәләнең серен. Бу чибәр кызны үз лекцияләрендә сирәк күрә иде ул. Шулай да фатирына турыдан-туры килеп кергәч таныды — өченче курстан.

Зур түрә дәрәҗәсенә ирешкән авыл малаеның мантыйгы бик гади: үзе нәкъ менә үз акылы белән шундый зур дәрәҗәгә ирешә алгач, аннан туган балалар тагын да акыллырак, талантлырак булырга тиешләр. Аларны тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән азат итәргә кирәк, ул ашау-эчү турында, матур кием-салым хакында яки затлы чит ил машинасы турында уйлап һәм, ахыр чиктә, Казан тулай торакларының берәрсендә таракан санап яшәргә тиеш түгел, атасыннан күчкән сәләтен, гакылын ул малай яки кыз бала фәнгә багышларга тиеш, максаты яхшы билгеләргә генә укып, кесәсенә диплом салу булырга тиеш. Югары уку йортында укыган чакта билгеләре бик шәптән булмый икән, аның өчен дә борчылып торасы түгел: бала әлегесен ачылып җитмәгән! Килер бер көн, аның ефәккә төрелгән баласы зур кеше булып өлгереп җитәр, иң юк дигәндә, ахыр чиктә, атасы эшенең дәвамчысы булыр. Монысы малайларга кагыла. Кызларга килгәндә исә... Монда да үз мантыйгы бар. Берәр зур җитәкченең асыл малаена тап булып, алдагы тормышын муллыкта, рәхәттә уздырыр, шөкер!.. Чөнки аның тормышыннан бик канә-

гать булган үз хатыны көне-төне колагына шул хакта тукып тора лабаса! Колагына гына түгел, бу нәрсә аның инде һәр күзәнәгенә кереп сеңгән!

Әлеге кызлар үзләренең алар өчен әти-әниләре махсус уйлап тапкан алтын бөҗра эчендә икәнлекләрен беләләр. Тик, алтын булса да, барыбер аның бөҗра икәнлеген аңлыйлар. Кайсы яшь күңелнең «ябылуда» яшисе килсен! Аларның күңелләре бу гамәлләргә, кырыс мантыйкларга карата үзләренең ризасызлыгын белдерә һәм менә шул эчке ризасызлык белән сугарылган каннары аларны «читкә» каерып тора, әти-әнисенең теләкләренә каршы килеп, төрле җүнсез гамәлләргә чакыра. Ничек телибез — шулай яшибез, ди, ул кызлар. Ничек телибез — шулай кыланабыз дип, фикер йөртә бу чибәр кызлар һәм чәчәкле болындагы бәйсез күбәләкләр сымак теләгән тарафларына очып киткәлиләр дә... Аларның бик гади генә бер теләкләре бар, ул да булса үз язмышларына үзләренең хуҗа буласылары килү.

Аларның берсе дә, малае да, кызы да, әти-әниләре теләгән югары баскычларга күтәрелә алмый. Чөнки тормыш — көрәш ул. Ә боларда көрәш иммунитеты бала чакта ук ата-аналары тарафыннан үтерелгән, юкка чыгарылган була. Тормыш әзергә бәзер генә яшәргә өйрәнгән балаларына карата нишләптер бигрәк аяусыз шул...

Бер мәртәбә имтихан биргәннән соң, студент кызларның аның янына үз теләкләре белән бернинди сәбәпсез икенче, өченче тапкыр килүләре — Руслан Даулатович өчен бердәнбер һәм ныклы аклану. Аннан соң... аннары ул тикшеренүче-галим, хатын-кыз холкын никадәр якыннанрак өйрәнә икән, димәк, аның фәнни ачышлары шулчаклы тормышчан һәм кире каккысыз булачак! Фән өчен галим кеше, шагыйрьләр читтән илһам эзләгән кебек, әхлак кануннарына сыешмаган гамәлләр кыла икән, бу, һичшиксез, табигый күренеш итеп кабул ителеп, аны гаепләргә урын калдырырга тиеш түгелдер ләбаса!

Кәримә атлы бүгенге студент кыз исә билге куйдырырга килмәгән. Бу самими карашлы кыздан чынлап торып курка Руслан Даулатович. Дөресрәге, әлеге кызның үзен юлдан яздырудан, башы-аягы белән хиссият дөньясына алып кереп китеп, башын, акылын югалтудан курка иде. Кырлап-сырлап торасы да юк: Руслан Даулатович үзенең бу кызга карата битараф түгел икәнлеген сизә башлады бугай. Ходай сакласын, ул бүтән гашыйк булып, салкын акылын җебетергә теләми, йөрәгендә беренче Кәримәдән соң калган җәрәхәттән һаман кан саркый, ул аны төшләрендә күреп уяна, кайбер төннәрен таңга чаклы беренче хатынының «куенында» уздырып чыга, төне буе ләззәт, мәхәббәт тәмен татыганнан соң, уянып киткәч, хак чынбарлык аның башына күсәк белән китереп органдай була. Тол ирнең яшисе килми башлый, ул төшкә чаклы төшенкелектә йөри. Шул рәвешле акылдан язуың да бар. Менә тагын... бу кыз да, дөресрәге, бу кызга да күңеле битараф түгел шикелле, нилектәндер ымсына, кытыклана. Күңелең бер «бәйдән» ычкынса, аны бернинди фәлсәфә кануннары белән дә урынына утыртып булмаячагын аңламыймыни ул?!

Борынгы грек фәлсәфәчеләре үк моңа игътибар иткәннәр. Бу нисбәттән Платон Софоклның сүзләрен мисал итеп китерә. Өлкән яшьтәге Софоклдан сораганнар икән: «Мәхәббәт ләззәтенә мөнәсәбәтең ничек? Хатын-кыз сине һаман кызыксындырамы әле?» — дип. Тегесе җавап биргән: «Мин бу нәрсәләрдән үзенең кырыс әфәндесеннән йөгерә-йөгерә качкан кол кебек шатлана-шатлана арындым, качтым инде».

Руслан Даулатовичның Кәримә иреннәре тигән ике бите бик рәхәт булып һәм бик озак янды...

Буласы нәрсә булмый калды. Көтелеп тә булмый калган нәрсәләрне җил үзе белән эзен дә калдырмыйча очыртып алып китә. Тормыш безнең уй-фикерләрдән үрелгән. Шуңа күрә кайбер авырлыкларны адәм баласы кичереп, үткәреп җибәрергә тиеш. Чөнки Ходай шулай тели. Ә ахыры хәерле булыр кебек...

...Кәримә көтте, үзе белән якын арада булачак зур үзгәрешкә алдан ук әзерләнде. Әлбәттә, аңлы рәвештә һәм махсус түгел, бу әзерлек кызның акылыннан гайре рәвештә барды шикелле. Әйтерсең ул бик текә ярның читенә үк килеп җиткән дә... юк, кыз инде шул текә ярда аякларын ук салындырып утыра, чак кына кузгалса яисә талпынып алса — аста кайнаган диңгез дулкыннары арасында булачак. Ул диңгез аны төпкә алып китмәячәк, үзенең акулаларына ризык итеп тә бирмәячәк, ул диңгез аны йомшак дулкыннары өстендә уйнатачак, иркәләячәк, бишектә тибрәткән кебек тибрәтә-тибрәтә, соңыннан гәрәбәдәй комлы ярына чыгарып бастырып куячак — яшә, рәхәтлән, тормышның тәмен таты, син хәзер инде үзең бая гына аягыңны салындырган текә яр өстендә түгел, син кичәге кебек болыннан чәчәкләр җыеп йөри аласың. Хуш исләр белән хозурлана аласың. Син хәзер гөнаһсыз кыз бала түгел. Ләкин шуны бел, син инде самими кыз-

чык кебек ул матур чәчәкле, хуш исле болында бер кайгысыз очып уйнаган күбәләкләр артыннан дөньяңны онытып куып йөри алмаячаксың, дөресрәге, синдә бүтән андый теләк уянмаячак, беркайчан да... Син хәзер хатын-кыз, син хәзер ул күбәләкнең очынып уйнавына соклана-соклана күзәтә генә аласың...

Нигә?! Аерма шунда гынамы икәнни соң?.. Юк, аерма анда гына түгел. Син кайчан да булса үзең ошаткан кешегә кияүгә чыгарсың. Зөфаф кичендә, бәлкем, хатын-кызга хас мәкерлегеңне файдаланып, үз кешеңне алдый да алырсың. Ләкин син гомерең буе яшерен сереңнән котыла алмаячаксың, ул сине кабереңә чаклы озата барачак. Ул сине фани дөньяда да адым саен эзәрлекләп, ирең белән ястык бүлешкән мизгелләреңдә бигрәк тә битәрләп, җаныңны өшетеп торачак!.. Син үзең тудырган газиз балаларыңның күзенә дә тутырып карый алмаячаксың! Син инде буй җиткән кызыңа тәүфыйклы бул, балам, дип әйтәсең, кисәтәсе килгән чакларында теге мәкерле серең күсәк сыман башыңа тондырачак, син аңгыраеп калып, кызыңа бирәсе киңәшләрең дә табигый һәм самими булмаячак, кызың, бәгырь кисәгең, ул киңәш-теләкләреңне колагы, аңы белән кабул итсә дә, ул аның җанына үтеп кереп, кызыңны бәлаләрдән коткарып калу көченә ия булмаячак инде...

Син кулыңда искиткеч матур һәм бик хуш исле чәчәк тотып торырсың, ләкин син инде чәчәкнең хуш исе белән матурлыгын бергә, икесен дә берьюлы тоя алу ләззәтеннән мәхрүм ителгән хатын-кыз буларак, йә матурлыкны гына күрә алырсың, йә борыныңа хуш исе генә килер...

Бу сүзләрне кемдер Кәримә атлы гыйффәтле кызның колагына пышылдый иде. Кем шулай кисәтә аны, хәтта... ул кемдер аны өркетә, куркыта шикелле. Тулай торагына кайтып пружиналы тимер караватына аугач та, әлеге «кемдер» пышылдавыннан туктамады.

«МИНЕМ ӘНИЕМ ИРЕККӘ ЧЫГАЧАК! МИҢА ИҢ БЕРЕНЧЕ НӘҮБӘТТӘ ШУНЫСЫ КАДЕРЛЕ».

Кызны йокы алмады. Алар сабакташ кызлары белән, күптән түгел генә җыелышып, кача-поса бер фахишәнең көндәлеген укыганнар иде. Кәримә яшергән җиреннән тиз генә шуны тартып чыгарды һәм аның үзенә кирәкле битен эзләп тапты.

*«Шундый карар кабул иткән мизгелдән кала, мин ул төннең һәр минутын аермачык хәтерлим. Кызык — үземне бер тамчы да гаепле итеп сизмим. Элек мин үз тәнен сатып көн итүче хатын-кызларга тормыш бүтән юл калдырмагандыр дип уйлый идем, — хәзер моның алай түгел икәнлеген күрәм. Мин бит, «юк» дип, кире кага ала идем, «әйе» дип ризалашырга да була иде.*

*Һәммәсе дә мин алдан фаразлаганча булды: гарәп белән аның кунакханәдәге номерына кердек, шампан эчтек, мизгел эчендә бик каты исердем, анадан тума чишенеп, урынга барып яттым һәм тыныч кына аның кәефе булганын көттем (үземә дә рәхәт булганлыгын күрсәтеп кыланып та тормадым). Душка кердем, гарәптән акчасын алдым да, такси тотып, өйгә кайттым. Таңга чаклы бернәрсә белмичә йоклаганмын.*

*Мин урамнан барам. Кешеләрнең йөзләренә текәлеп карыйм һәм белергә тырышам: бу кешеләр барысы да язмышларын үзләре сайлады микән? Әллә минем кебек язмыш тарафыннан ирексез рәвештә сайландылар микән?*

*Мин үз-үземне тамчы да кызганмыйм. Корбан итеп тә хис итмим, чөнки гыйффәтле булып калган хәлдә, буш кошелегымны кыстырып, рестораннан ук чыгып китә ала идем бит. Мин ул гарәп каршында әллә кем булып та кылана ала идем. Ала идем... Ләкин күпчелек кебек үз-үземне тулысынча язмыш кулына тапшыруны кулайрак күрдем».*

*«Без күпме теләсәк, шулчаклы хыяллана алабыз, ләкин реаль тормыш бик кырыс. Моның белән син нәрсә әйтмәкче буласың? Сине кайчан да булса гаепләячәкләр дипме? Ләкин бу хакта беркем дә белмәячәк бит һәм бу шөгыль вакытлыча гына бит...»*

Кәримә үзенә таныш булмаган фахишә кыз белән килеште дип тә, килешмәде дип тә әйтеп булмый. Һич әйтеп булмый. Ул бары тик аның көндәлеген укыды, укыган саен укыйсы килде. Чит кешенең эч серләрен белергә омтылу теләге идеме бу, әллә үзе дә мондый гамәл кылырга мәҗбүр булган очракта, тырыша-тырыша котылу өчен салам эзләү идеме?..

Кәримә йотлыга-йотлыга укыды.

*«Мин шуны аңладым: ир кеше хатын-кызга түли — бәхетле булыр өчен түли...*

*Табигый хисләрен канәгатьләндерү өчен генә шулчаклы акчаны чыгарып салмас бит инде ул. Бәхетле буласы килә аның. Җир йөзендәге башка кешеләр кебек үк минем дә бәхетле буласым килә, ләкин моңа беркем дә ирешә генә алмый. Әгәр дә төптән уйлап карасаң, нәрсә югалтам соң әле мин?*

*Намус. Горурлык. Үз-үземә хөрмәт. Әгәр дә төптәнрәк уйлап карасаң, боларның берсенең дә миндә булганы юк. Мин бу дөньяга туарга атлыкмадым, мин үземнең мәхәббәтемне очратмадым, мин һәрвакыт ялгыш гамәлләр кылдым һәм минем тормышым да үз тарафымнан ук җимерелгән...»*

Кәримә әлеге мескен кызны ирексездән үзе белән чагыштырып куйды. Аның да моңарчы чын мәхәббәтен тапканы юк бит әле, аны да, әнисен коткарып калу хакына, бүгенме, иртәгәме... нәкъ шул язмыш көтәргә мөмкин бит? Ул бүтән бу хакта уйларга теләмәде, тизрәк китапка капланды.

*«Яратышуга килгәндә, әлеге нисбәттә берни дә үзгәрмәде. Чишенеп ятасы, ыңгырашкан булып кыланасы (әлеге ыңгырашулар кайчак артык акча алып килә), соңыннан душка керәсе — су астында торган чакта тәнең генә түгел, җаныңның бер өлеше дә чистара кебек. Әллә үзең шулай булуын теләгәнгә генә микән? Клиент белән берниндн үбешү юк. Иптәш кызым әйтә, үбешүне киләчәккә, үзеңнең чын мәхәббәтеңне очратканчы сакларга кирәк, ди. Әйе, әйе, кайчан булса да ул үбү киләчәк, һәм синең бар дөньяңны аллы-гөлле төсләргә күмеп, сине мәңгегә бәхетле итәчәк!.. Шул Үбү Синдә гүзәл хатын-кыз уятачак!!!»*

Чү, туктале, ул Руслан Даулатовичны битеннән үпте бит?! Юк ла, үз- үзеңне газаплама инде, шатлыктан гына, рәхмәт әйтәсе килгәннән генә ләбаса ул...

*«Минем янга килгән барлык ир-ат та — озын буйлымы ул, кыскамы, тынычмы, яки тел бистәсеме — һәммәсе дә үзләренең куркуларын җиңеп киләләр. Тәҗрибәлерәкләре бу куркуны басар өчен кычкырып сөйләшкән була, кайберләре үзенең әлеге халәтеннән качу өчен хәмер эчә. Курку хисе кичермәгән ир-атны минем әле моңарчы күргәнем юк. Әлбәттә, алар хатыннарына ишетелүдән яки кеше теленә керүдән куркалар.*

*Ләкин нигә? Алар түгел, киресенчә, мин куркырга тиеш бит әле монда! Һәр кичне үземә таныш булмаган кешеләр белән кунакханәгә мин керәм бит. Мин керәм, көчсез хатын-кыз башым белән, үзем белән хәтта коралым да юк?! Гомумән, бу ир-атлар кызык кавем. Минем белән кунганнары гына түгел, минем юлымда очраган һәммәсе дә... Әйе, алар куркытырга мөмкиннәр, кычкырырга, суккалап та алырга күп сорамаслар, әмма барысы да хатын-кыздан куркуларыннан акылларыннан язарга мөмкиннәр. Бу курку үзләре башларын итәкләре астына тыккан хатыннарыннан гына да түгел. Мәсәлән, туган әнисеннән курку...*

*...Өстәвенә әгәр артык салган баштан булдыра алмасалар, алар оялалар да. Югыйсә «уята алмаганым» өчен мин оялырга тиеш бит, алар түгел...»*

Кәримә китапны читкә тотып атты. Ниндидер бер фахишәнең эч серләре аңа нәрсәгә кирәк булды соң әле? Кадалып китсен шунда! Җитмәсә, Кәримә укырга да оялган җөмләләрне ул ачыктан-ачык яза да бит әле! Әнил булса, «какой ужас!» дип, бу көндәлекне күптән чүплеккә тондырган булыр иде инде...

Кыз үзе шулай дип уйлады, ләкин бик яхшы белә ләбаса — әлеге уйларында хилафлык та юк түгел, үз-үзен чак кына алдый да бит ул... Чөнки яхшы белә, күптән укыды инде, соң чиктә әлеге фахишә кыз чын мәхәббәтен таба һәм аны тапканчы ук шул хакта, ягъни чын хисләр хакында уйлана башлый. Көндәлекнең ул өлеше Кәримәгә аеруча ошый.

*«Мин бүген шөгыльләнгән һөнәрме, кәсепме ул, ни булса да — аның бик борынгы булуына төкердем мин. Шунысы хак: мин бу кәсебемне күралмыйм!!! Ул минем җанымны ашый, бәгыремне кимерә, ул миңа акчаның бар нәрсәдән дә өстен икәнлеген аңлатмакчы була!*

*Минем тирәмдә бәхетлеләр юк. Ул ир-атлар яхшы белә: бушка да ирешеп була торган нәрсәгә алар учлап акча түлиләр, шул нәрсә аларны кимсетә, ачуларын китерә. Иркәләү, сөюләр хакына бушка да бирелергә әзер булганымны белә торып, сатылырга, акча таләп итәргә мәҗбүр ителгәнем өчен минем җаным кыйнала. Берәр атнага гына түзәм дә... Аннан нишлим? Нокта куяммы? Әйе, куям. Һәм мин боларның барысын да киләчәк тормышымда онытырга, ниндн оныту гына, бәлки, тормышымнан ук сызып ташларга тырышачакмын! Минем күңелем дә бит мәхәббәткә сусаган! Минем дә яратасым, сөеләсем килә!*

*Тормыш артык кыска... Ул кыска тормышны бары тик чын мәхәббәт мизгелләре генә озынайта алачак... Мин шуны аңлый башладым. Ниһаять... Бар адәмнәр өчен дә уртак булган «ахырзаман» белән беррәттән һәр кешенең үзенең генә дә «ахырзаманы» була торган булса, кыз бала өчен ул мин кылган гамәлләрдер... Аның да беренчесе үктер, Ходаем.*

*Үзең ярлыкый күр, Ходаем! Муеннан гөнаһларга батабыз да... аннары, авыз күтәреп, гафу итүеңне үтенәбез, тәүбәгә килмәкче булабыз, сине искә төшерәбез...»*

* * *

...Ул төнне Руслан Даулатовичның фатирында таңга чаклы ут сүнмәде. Кан тамырларын шартлатырдай булып гәүдәсендә тупланган көч-гайрәт аңа йоклап китәргә ирек бирмәде. Ул язу өстәле янына килеп утырды.

...Борын-борыннан ук күршеләр булып гомер итсәләр дә, холык-кыяфәтләре белән бер-берсеннән җир белән күк кебек аерылып торган милләтләр тарихның кайсыдыр мизгелләрендә, үзара буталышып, каннарын бозганнар... Басып алынган халыкның каймак кебек кызлары коллыкка алынган. Әлеге чуалыш-кушылулар нәтиҗәсендә җир йөзенә йөзләгән-меңләгән «безобразияләр» туа торган. Гибрид грейпфрутлар ничек тәмсез булса, боларның каннары кушылу нәтиҗәсендә дөньяга килгән «җимеш»ләр дә шундый ук чиле-пешле була торгандыр. Йа Хода! Әгәр синең изге китапларың булмаган булса, адәм балаларың җирдән атлап түгел, күптән агач башыннан йөрерләр һәм бер-берсенә нарат күркәсе атып уйнап, тәннәреннән бет чүпләп утырырлар иде... Син — тудыручы, Син — коткаручы!.. Шулай булгач, Синең тәгълиматың күкләрдән иңмәгәндер, дип, кем авыз күтәреп әйтә ала?!

Тарих белән «тарих» кына бит, дип шаярмагыз, ул хакта җиңел генә фикер йөртмәгез! Халыкның тарихы аның кичәге язмышы гына түгел, ул аның туачак таңы, офыктан күтәреләчәк кояшы. Син кичә нинди идең, бүген дә шулай син, иртәгә дә, алдагы көннәрдә дә шулай булачаксың! Кабыгың гына алмашынырга мөмкин, тик асылың үзгәрмәячәк. Белеп тор моны!..

Руслан Даулатович студентларына да шул ук фикерләрне тукый тора. Дөресен әйтергә кирәк, әгәр ул аларны үзе, ягъни булачак монографик хезмәте өчен генә теркәп барган очракта, күңеле һич канәгатьлек тапмас иде. Уйлаганнарын студентлары белән уртаклашасы... юк, дөресрәге, ул аларга шәкертләреннән, чит кешеләрдән тагын бер кат раслатып, күңел тынычлыгы табарга омтыла шикелле.

— Милләтләрнең каннары буталып беткән. Кан күзәнәкләре бертөрле генә түгел. Кайда кайсы милләт күзәнәкләре өстенлек итә — индивид үзен шул милләт «бишегендә» уңайрак хис кыла.

Яңа исәп-хисаптан башланган бүгенге дөньяның берничә йөз елы милләт каннары кушылу-буталудан гына тора. Аңарчы ул чагыштырмача тотрыклы булган. Һәр милләтнең үзенә генә хас холкы, фигыль-гамәле аеруча көчле чагылган.

Ул шулай диюгә, арадан берәр кыюрак студенты, сикереп торып:

— Руслан Даулатович, мин сезнең белән һич килешә алмыйм! Каннар буталу революциядән соң гына башланган ич! — дип, каршы да төшмәкче була.

Шулчак профессор абзагыз, дөньясын онытып, тарихка кереп китә. Әлбәттә, үзенә каршы килгән студентны гаепләми ул. Хәтта аның сүзләрен куәтли дә. Мисал итеп урыс елъязмачыларының сүзләрен китерә.

955 елның җәендә князь Игорьның хатыны Ольга греклар янына Патша шәһәренә килә. Ул заманда патша булып Левның улгы Бөек Константин хакимлек итә. Ольга менә шуның катына бара. Патша гүзәл Ольганы күреп соклана һәм «безгә бергәләшеп патшалык итәргә язгандыр» ди. Ольга, үзен саклап калу өчен, шундук хәйләгә керешә, дөресрәге, чын максатын әйтә. «Мин мәҗүси бит, христиан кеше мәҗүси хатынны хатынлыкка ала алмый, мине чукындырасың килсә, тик үзең генә чукындыр, югыйсә мин чукынудан баш тартачакмын» ди. Һәм патша аны патриарх белән бергәләп чукындыра. Патриарх хатынга христиан диненең тәгълиматларын өйрәтә. Чукынганнан соң Ольгага Елена дигән яңа исем бирәләр.

Үз диненә күчкәннән соң, Константин патша Ольгага хатыны булырга тәкъдим ясый. Ләкин Ольга, аңа шундук каршы төшеп:«Ничек итеп син мине үзеңә хатынлыкка алмакчы буласың?! Син бит мине үзең чукындырдың һәм кызым дип атадың! Ә христиан кануннары буенча ата кеше үз кызына өйләнә алмый».

«Хәйләләдең син мине, Ольга» дип, патша аның фикере белән килешергә мәҗбүр була. Шуннан соң ул аңа күп мал-мөлкәт, алтын-көмеш биреп кайтарып җибәрә. Ольганың халкы да христиан диненә күчә. Ләкин аның улы Святослав, христиан диненә күчүдән баш тартып, мәҗүси булып калса да, алар бик тату һәм матур гомер кичерәләр.

— Сезгә билгеле мәгълүматлар нигездә әнә шулар, — дип, никтер авыр итеп көрсенеп куйды Руслан Даулатович.

— Борынгы елъязмада язылганча бит инде!

— Аларда чын хаклык бар дип уйлыйсызмы? Алдый алар...

— Ничек инде?..

— Монастырьларда утырган елъязмачылар хуҗаларына нәрсә кирәк, нинди данлы тарих кирәк — шуны язганнар да. Мәсәлән, Святослав кенәз Игорь малае түгел! Ул Ольгага өйләнгәндә шәлперәйгән карт була инде. Тоткынлыкка төшкән Ольганың гыйффәтен хазар башлыгы ала, малай, ягъни урыс кенәзе Святослав шуның баласы! Менә каннар буталуның ачык мисалы сезгә!

Елъязмаларда ялган күп, дидем. Дөрестән дә шулай бу. Мәсәлән, шул ук Святославның малае Владимир үзе кенәз булып алгач, Выдубицкий монастыре монахы Сильвестрны дәштерә дә, беренче урыс елъязмасын юкка чыгарып, яңаны язарга куша. Чөнки анда Русьны берләштерүдә Владимирның роле кечерәйтеп күрсәтелгән була. Шуннан бирле тарихчыларның башы әйләнеп беткән инде. Княгиня Ольганың кайчан Константинопольгә килгәне дә, урыс илен төгәл чукындыру датасын да тәгаен белгән кеше юк. Дөреслекне бары тик патша Константинның сәркәтибе язмаларыннан гына эзләргә кирәк. Порфирогинетның бу хакта аерым хезмәтендә тәфсилләп язылა. «De ceremoniis Auiae» дип атала әлеге хезмәт һәм сәркәтип Ольганы скандинав исем белән Елга дип атый. Константинопольгә, Сильвестр язганча, 955 елда түгел, ә 957 елның 9 сентябрендә килә Ольга. Мондый мисалларны күпләп китереп булыр иде. Шунда тукталып торыйк әлегә. Ләкин мин бу урында тагын бер әһәмиятле фактны искә алып китәргә уйлыйм, ул да булса кенәз Владимир, атасы кебек үк, законлы никахтан тумаган, ул «ключница» Малуша малае.

Рухи яктан шактый тотрыксыз бөек урыс кенәзе Владимир исә, барлык ир туганнарын үтереп бетереп, Киев тәхетенә утыруга, абыйсының көмәнле хатыны грек кызы Юлияне көчли, аның белән генә дә чикләнеп калмый бу бозык җан. Шуннан соң византияле принцесса Аннага өйләнү бәрабәренә бөтен Русьны чукындырып ташлый. Әбисе Ольганың максаты әнә шул рәвешчә тормышка аша. Ольга әби исә, үз чиратында, җеп очын яшерү өчен, Владимирның әнисе Малушаны Киевтан куып ук җибәрә.

Әйткәнемчә, Святослав — хазар патшасы яһүди Песах малае.

Каннар буталу белән бергә, әлбәттә, гореф-гадәтләр, яшәеш рәвеше дә үзгәрә. Мәсәлән, Ибне Фазлан шул дәвердә яшәгән урыслар хакында менә ничек язып калдырган. Шунысына игътибар итегез: халыклар гадәтләре белән бер-берсеннән ул вакытта нык кына аерылып торганнар. «Көннәрдән бер көнне мин Итил ярында сәүдә эшләре белән бирегә килеп чыккан русларны күрдем. Мондый камил гәүдәле адәмнәрне минем әле күргәнем юк иде. Алар кыяфәтләре белән пальма агачларын хәтерләтә: чәчләре сары, йөзләре алсу, тәннәре ап-ак. Аларда җилән, кафтан киеп йөрү гадәте юк, ир-атлары «киса» дип аталган тукыма кисәге белән ярты тәннәрен генә каплап йөри, бер куллары тышта кала.

Руслар тәһарәт алмый, җенси якынлыктан соң пакьләнми, ашар алдыннан кулларын юмый.

...Һәркемнең өй эчендә озын урындык бар, анда хуҗа үзе һәм сатып җибәрү өчен алып килгән гүзәл кызлар-җарияләр дә тезелешеп утыра. Кайчакта русларның берәрсе җария белән якынлык кылырга тотына, ә иптәше шуны карап тора. Кайвакыт әлеге оят эшне бер төркем кеше дә күзәтә...

...Алар көн дә дөньядагы иң пычрак су белән юыналар. Бу менә ничек эшләнә: иртән хезмәтче кызларның берәрсе хуҗасына зур кисмәк белән су китерә. Теге анда кулын юа, битен, чәч үскән бөтен урыннарын юарга тотына, тарак белән чәчләрен тарап, аларны кисмәккә ташлый бара. Аннан шул кисмәккә борынын сеңгерә, төкерә, кыскасы, су пычрансын өчен барысын да эшли. Хуҗасы юынып бетергәч, хезмәтче кыз кисмәкне урындыкта көтеп утырган икенче берәү алдына китереп куя. Бусы да хуҗа кеше кебек бөтен эшен башкара — шул ук суда юына, чәчләрен тарый, какыра-төкерә. Кисмәк шул рәвешле өйдәге бар кеше юынып беткәнче берсеннән берсенә йөри. Һәркайсы аңа төкерә-какыра, битләрен, чәчләрен юа».

Аудитория һәр сүздән дерт итеп сискәнеп киткәндәй була. Студентлар, аптырашып, берберсенә карашалар. Ләкин ни хәл итмәк кирәк, Фазлан үзе күргәннәрен ташка язып калдырган шул.

«...Миңа шулай ук берәр башлык үлгәннән соң, аны ничек күмүләре хакында да еш ишетергә туры килде. Бу очракта йоланың иң гадие — мәетне яндыру икән. Шуңа карамастан минем бу йоланы үз күзләрем белән күрәсем килә иде. Шулай беркөнне нindидер башлыкның үлеме турында хәбәр таралды.

Үлгәннән соң алар мәетне ун көнгә кабергә төшереп куеп, өстен ябып тоттылар, шул вакыт эчендә мәрхүмгә яңа киемнәр тегелде.

Берәр фәкыйрь кеше үлеп китсә, алар кечкенә генә көймә әмәлләп, мәетне шунда куялар да көймәсе-ние белән яндыралар.

Бай, мал-мөлкәтле кеше үлгәндә, аның бөтен байлыгын өч тигез өлешкә бүләләр: бер өлеше гаиләсенә кала, икенче өлеше җирләү, йолалар үткәрү һәм киемнәр тегүгә тотыла, ә өченчесе исерткеч эчемлек әзерләүгә китә. Алар бу эчемлекне мәрхүмнең җариясе, үз-үзен үтерергә риза булып, хуҗасы белән бергә корабта яндырылган көнгә чаклы эчәләр. Набыз дип аталган бу эчемлекне алар артык күп эчәләр, көнен-төнен шушы эш белән шөгыльләнеп, кайберләре хәтта савыт тоткан килеш үлеп тә китә.

Мәет озату әзерлеге барган ун көн эчендә алар хатын-кызлар белән якынлык кылалар һәм сазда уйныйлар. Корбан булырга ризалык биреп, тиздән яндырылырга тиешле җария кыз исә шушы ун көн дәвамында набыз эчү һәм күңел ачу белән шөгыльләнә, ул матур итеп киенә, чәчләрен, күлмәкләрен бик матур итеп бизи һәм теләгән кешесе белән якынлык кыла.

Әгәр дә берәр башлык үлеп китсә, аның гаиләсе мәрхүмнең җарияләреннән, хезмәтче егетләрдән: «Кем аның белән теге дөньяга китәргә тели?» — дип сорый. Гадәттә, арадан берәрсе ризалыгын бирә. Шушы сүзен әйткән кешегә сүзен кире алу тыела. Ул кире уйлаган очракта да бу аңа рөхсәт ителми. Бу эшкә, нигездә, җария кызлар ризалык бирә.

Шулай итеп, арадан бер башлык үлеп китте дә җария кызлардан: «Кем аның белән теге дөньяга китәргә тели?» — дип сорадылар. Кызларның берсе «мин» дип җавап бирде. Шушы сүз әйтелгәч, аны ике кыз карамагына тапшырдылар: алар җарияне сакларга, ул кая барса да, гел аның белән булырга тиешләр иде. Әлеге кызлар хәтта җариянең аягына хәтле юалар иде.

Мәрхүмнең туган-тумачасы аны озату хәстәрен күрде — яңа кием-салым тектереп, кирәкле бөтен эшләрне башкарды. Ә корбан ителергә тиешле җария бу вакыт кәеф-сафа кылып, күңел ачып йөрде, шат йөз белән булачак тантаналы йола турында хыялланды.

Менә башлыкның үзен, аның белән бергә корбан ителәчәк кызны да яндыру көне килеп җитте. Бу көнне мин мәрхүмнең Итил ярында торган корабы янына төштем. Менә корабны судан сөйрәп чыгардылар, алдан әзерләп куелган дүрт махсус җайланма өстенә урнаштырдылар. Аның як-якларына күтәрмә-баскычлар куелды. Шулай ук корабка сак та билгеләнде, алар, арлы-бирле йөренгәндә, ниндидер сүзләр әйтәләр, нәрсәдер укыйлар иде. Бу эшләр башкарылганда, мәрхүм вакытлы каберендә ята бирде, аны әле чыгармаганнар иде.

Корабның урта бер төшендә колгалардан тирмә сыман бер куыш урын ясалды, өстенә төрле төстәге тукымалар ябылды. Аннан озын урындык алып киленде дә корабка куелды. Шуннан соң аларда «үлем фәрештәсе» дип аталып йөртелгән бер карчык килде. Аның җитәкчелегендә корабтагы урындык өстенә калын киезләр түшәлде, алар рум парчасы белән капланды, шундый ук парча тышлы мендәрләр куелды. Аларда мәрхүмне соңгы юлга озату эшләренә әлеге карчык җитәкчелек итә, ул мәеткә киемнәр тектерә, аны киендерә, корбан буласы җарияне дә ул үзе үтерә икән. Мин бу карчыкның алыптай таза һәм караңгы йөзле булуына игътибар иттем.

Аннан соң чират мәрхүмнең үзенә килеп җитте. Иң элек аның вакытлы кабере өстендәге туфрак катламы алынды, аннан түшәме сүтелде һәм өстенә җәймә капланган мәет көн яктысына чыгарылды. Мин аның суык кабердә ятып карасу-зәңгәр төскә керүенә игътибар иттем. Мәетне кабергә салганчы ук, руслар анда исерткеч эчемлек, ниндидер җимеш һәм лютнага охшаган уен коралы төшереп куйганнар иде. Бу әйберләр барысы да кабердән чыгарылды...

...Бу йоланың бик күп халык җыелган җирдә үткәрелүен әйтергә кирәк... Корбан ителәсе җария, бизәнеп-ясанып, мәрхүмнең туганнары урнашкан куышлар борынча йөрде, анда һәрберсе белән якынлык кылды, куыш хуҗасы аңа, кешегә ишетелерлек каты тавыш белән:

— Анда баргач, хуҗаңа тапшырырсың: бу эшне ул сине яратып һәм хөрмәт итеп башкарды, диярсең, — дип әйтә иде.

Җария кыз шулай, куыштан куышка йөреп, мәрхүмнең барлык туганнары белән якынлык кылып чыкты».

Фазланның язганнары уйдырма-әкият түгел, ул үз күзләре белән күргән манзараларны тасвирлаган. Милләтләрнең, халыкларның холкы бүген генә формалашмаган, аның башлангычы — гасырлар төпкелендә.

Тагын шул ук Фазлан язганнарга мөрәҗәгать итик.

«Башкортлар сакалларын кырып йөриләр һәм бет ашыйлар. Берсенең курткасын салып, аның җөйләрендәге бетләрне теше белән сыткалавын үз күзләрем белән күрдем. Безнең арада бер хезмәтче башкорт бар иде. Бервакыт ул киеменнән бет тотып алды да, аны тырнагында изгәч, теле белән ялап куйды.

Аларның һәрберсе таяктан ирләрнең җенес әгъзаларын юнып ясый, аны бау белән муенына асып куя. Берәр сәфәргә җыенганда яисә дошман белән очрашканда, шушы таякны үбә, аңа сәҗдә кыла.«Йә Тәңрем, ярдәмеңнән ташлама!» — ди.

Бу хәл миңа кызык тоелды һәм мин тылмачтан:

— Берәрсеннән бел әле, алар ни өчен болай эшлиләр, аңа нинди мәгънә салалар? — дип сорадым. — Ни өчен Тәңреләре итеп ирләрнең җенес әгъзасын сайлаганнар?

Башкорт безгә:

— Ни өчен дисезме? Чөнки мин якты дөньяга шушы нәрсә аркасында килгәнмен, башка тудыручыны белмим, — дип җавап бирде».

Болгарлар турында да яза Ибне Фазлан: «Аларда ир-атлар белән хатын-кызлар, елгага төшеп, ят җирләрен каплап тормыйча, шәп-шәрә килеш бергәләшеп коеналар, әмма бу халыкта бернинди зина-фәлән кылу юк. Берәрсе шуны эшләсә, кем булуына да карамастан җәзасын ала: моның өчен башта җиргә дүрт сука тимере кагып куела, зиначының ике кулы белән ике аягы аларга ныгытып бәйләнә, аннан соң гаепле кеше муеннан бот төбенә чаклы балта белән икегә чабыла. Гаепле хатын-кыз да шундый ук җәзага тартыла. Шуннан соң зиначыларның һәр саны агачка бәйләп куела... Аларда карак-угрылар да зиначылар кебек җәзалана»[1].

«Әгәр дә болгарлар укымышлылыгы белән аерылып торган берәр кешене очратсалар: «Бу кеше башкаларга караганда Тәңрегә хезмәт итәргә лаеклырак!» — диләр дә, муенына элмәк салып, аны агач ботагына асып куялар».

Йа Хода! Мин моны белгәч шаклар каттым! Бүгенге болгар-татарларның холкында да бар бит шул нәрсә: кем акыллырак, талантлырак, укымышлырак, ул кешене хәзер батырырга, юк итәргә торалар. Бу нәрсә татарларның иң кабахәт милли үзенчәлеге!!! Нәкъ менә шуның аркасында кол хәлендә яшисең дә инде син, милләтем!..

Гасырлар узып, тора-бара бу халыклар үзара тагын да якынлашып, ахыр чиктә кушылып-катнашып беткәннәр. Әмма тарих уеп салган гореф-гадәтләрне вакыт җилләре дә, үзара буталышу-кушылу да юкка чыгара алмый, әлбәттә. Алар кан-күзәнәкләрдә яши. Алар бүген дә милләт әхлагының төп нигезен тәшкил итә.

## Түләү

Кәриманең әнисе озакламый иреккә чыгарга тиеш. Бу мәсьәлә хәл ителгән, очы тәмам чишелер өчен бераз вакыт кына кирәк иде.

Бер караганда, кызның җилкәсеннән тау төшкәндәй булды, шулай да тынычланырга иртәрәк — моның өчен түлисе бар иде бит әле...

Йа Хода! Бу дөньяны коткаруны тагын хатын-кыз кулына калдырырсың микәнни?!

Ни булса да, тормыш алга китте кебек. Әнисе иреккә чыга, әтисенең «Мөгезсез үгез» дигән мәкаләсе, район газетасында дөнья күреп, бик зур шау-шу куптарды. Әтисенә туктаусыз шылтыраталар, өйгә килүчеләр дә бар. Чөнки мондый кыю мәкалә барысының ушын алган, күпләрнең күзен ачкан, тагын да күбрәкләрнең отыры ачуын китергән иде. Район матбугатында җирле җитәкчелекне тәнкыйтьләп кара әле син! Бу кыюлык кына түгел, бу зур батырлык һәм тәвәккәллек тә иде. Дөрес, газета редакторын икенче көнне үк эштән алдылар алуын. Ләкин болай да пенсия яшендәге Мохтаров абыйның моңа әллә ни исе китмәде. Ул элегрәк елларда байтак вакыт районның партия комитетында эшләгән җаваплы хезмәткәр, пенсия яше җиткәч, газетага күчкән иде. «Безнең заманнарда, фермадагы бер бозау үлсә дә, колхоз председателенең теңкәсенә тияләр иде, ә хәзер колхозларның малларын фермалары-ние белән сатып җибәрсәләр дә, бернәрсә юк!..» — дип, кереш сүз язган иде Мохтаров «Мөгезсез сыер» фельетонына.

Барыннан да бигрәк, әтисенең йөзенә нур кунды, күңеленә яшәү дәрте кереп оялады.

Алда тагын бер чишелмәгән төен тора иде әле. Шул турыда уйласа, Кәриманең күз аллары караңгыланып, аягында басып тора алмый башлый, тиктомалдан хәле китә һәм борып-борып эче авыртырга керешә иде. Әйе, чишелмәгән төен... Әнилгә нәрсә, ул көлә генә, Кәриманең халәтен аңлап көлә. Әмма көлүе бик серле, нидер әйтеп бетермәгән төсле иптәш кызы. Ләкин әйтелмәгән сүзне кеше авызыннан тимер келәшчә белән генә тартып алып булмый. Кәримә ике ут эчендә. Соңгы араларда Руслан Даулатовичның күзенә дә күренергә ояла, качып йөри. Әлбәттә, бу яхшы гамәл түгел. Рәхмәт әйтергә кирәк, алдына тезләнеп, әнисен коткарганы өчен, мең-мең рәхмәт укырга, бәлки, «Сезнең бу яхшылыгыгызны гомер онытмам!» дияргә дә кирәктер, тагын әллә ничаклы матур сүзләр өстәп әйтергә кирәк һәм тагын, тагын...

Әнил төрттерә: «Руслан Даулатовичны отблагодари инде син», — ди. Моны үзе дә яхшы белә Кәримә. Тик ничекләр итеп үз-үзен җиңәсе соң?! Ничекләр итеп... бәллүр пыяла кебек чәлпәрәмә килергә торган күңелкәен, күкрәк читлеге эчендә бәргәләнгән йөрәккәен күндереп, андый адымга җөрьәт итәсе?

Әниеңне коточкыч бәладән йолып калу бәһасез нәрсә! Андый бәхетне дөньядагы бернинди кыйммәтләр белән дә бәяләп булмый торгандыр әле, бәлки?.. Ни булса — шул булыр...

Дөнья кыз алдына коточкыч авыр мәсьәлә китереп куйды. Монысы хак...

Кәримә аптырагач, фахишә кызның көндәлеген тагын кулына алып карады. Үзе ясаячак адымнарга, кылыначак гамәлләренә аклану эзләргә, күңеленә ышаныч иңдерергә иде исәбе... Берни булмагандай ятасың да... аннары душка кереп, тәнеңне генә түгел, җаныңны чистартасың. Әйтерсең дөньяда бернинди үзгәреш тә булмаган. Әнә кояш та нәкъ вакытында һәм элеккеге урыныннан чыкты, кичен ай да үз вакытында калыкты...

Мондый икеле-микеле халәткә, ниһаять, бер дә бер көнне чик куелды. Тагын Әнил ярдәмгә килде, ул аны кичке якта Руслан Даулатовичның фатирына алып китте. Алдан сөйләшмәгәннәр иде, ничектер бик кинәт кенә килеп чыкты кебек. Әмма юлда барганда Кәримә дулкынланудан чак кына һушыннан язмый калды, тик, ни галәмәт, профессорның ишеген ачып керүгә, кызга каяндыр һәм ниндидер кыюлык иңгән сыман булды, кыяфәтенә нур кунып, йөзләре ачылып китте.

Руслан Даулатович, кызларны бик ачык йөз белән каршы алып, өчесенә дә кофе кайнатып алып чыкты. Аны-моны сөйләшкәләп утырдылар да, беркавымнан тол профессор, җитди тонга күчеп, кызларга үзенең эше, диссертация хакында сөйләп алды. Әнил сумкасыннан компьютерда җыелган шактый калын кульязма алып, профессор алдына куйды.

— Сезнең киңәшләрне искә алып, өр-яңадан карап чыктым, Руслан Даулатович.

— Яхшы, яхшы, булдыргансың! Иртәгә фикеремне җиткерермен.

Кәримә, берни аңламыйча, тик аптырап карап утыра иде. Ләкин профессор, аңа да сүз кушып, мәсьәләнең нидә икәнлеген тәфсилләп төшендерергә кереште. Баксаң, бер караганда, мәсьәлә бик гади икән ләбаса. Ул Кәримәгә курс эше тәкъдим итә. Ләкин темасы гайре сәер: «Яңа Манифест». Тезис-фикерләре дә сәер генә, ләкин кызык. Әнил исә бу эш белән бер елга якынлап кызыксына икән, шактый өлешен язып та бетергән инде. Кыскасы, Руслан Даулатовичның студентлары шул хезмәтләре белән зур фәнни конференциядә чыгыш ясарга тиешләр. Әле тиз генә түгел, вакыт бар. Руслан Даулатович бу эшкә аларның группадашлары Заһидны да тартырга уйлый икән, ләкин егеткә капылт кына үзе башлап әйтәсе килми, Заһидны кызлар әзерләргә һәм, үз чиратында, аны да ризалатырга тиешләр иде. Бу темалар әлегә сер, курс эшләре әзерләнеп беткәч тә, аның хакында кешеләргә белдерергә ярамый. Вакыты җиткәч кенә, фәнни конференция вакытында, барысының да маңгайларына бәреп, өчесе дә рәттән чыгыш ясыйлар, ноктаны профессор үзе куярга тиеш иде.

Кызлар саубуллашып чыгып киттеләр, тол профессор Әнилнең кульязмасын укый калды. Ләкин Кәримәнең күңеле барыбер нинди дә булса чишелеш көтә иде. Ул ишек янында басып торган Руслан Даулатовичны кочаклап битеннән үбеп алды да: «Рәхмәт сезгә әнием өчен! Мин моны беркайчан да онытмам, Руслан Даулатович!» — дип әйтергә үзендә кыюлык таба алды.

Ишек ябылгач, Әнил үзалдына гына сөйләнгән кебек әйтеп куйды:

— Әни белән барыбер ачыктан-ачык сөйләшәчәкмен әле мин!

— Ни турында сөйләшәсең?

Әнил аңа турсаеп карады да:

— Беләсең ич инде! — дип төрттереп куйды.

— Әйе, әйе, беләм шул...

— Әүвәл менә курс эшемне яхшылап язып бетерәм дә... фәнни конференциягә әнине дә чакырам... Аннан соң ачыктан-ачык сөйләшергә җиңелрәк булачак.

Кәримәгә өн кергән иде инде, ул Әнилнең кулыннан кысып тотты да:

— Бу Руслан Даулатович... таякны артык бөкми микән? Хатын-кызны чүпкә санамыймы? Син ничек уйлыйсың?

Әнил ачу белән кулын тартып алды да ниндидер ят тавыш белән:

— Әгәр... әгәр чүпкә санасамы?! Ул очракта ул сине, дустым, кылган яхшылыклары өчен, анадан тума чишендереп, постеленә төртеп еккан булыр иде! Алай итмәде бит! Итмәячәк тә! Мин аның фатирында йоклап та калганым бар... кристальный чиста кеше! Төне буе үзенең хатыны турында, аны ничек яратканлыгы хакында сөйләп чыкты ул миңа... Вот мәхәббәт булган!

Кәримә үзе дә сизмичә сорау биреп куйды:

— Булган?

— Әгәр мәхәббәт ике яклы булмаса, ул барыбер сүнүгә дучар...

Әнил хаклы дип уйлап куйды Кәримә... Рәхмәт Әнилгә! Әгәр ул, ул булмасамы?..

Йә, ярый, ул да дустына бурычлы булып калмас әле, Алла боерса...

Коммунистларның иң котырган чагы. Маркска, Энгельска һәм Ленинга, аларның дистә еллар буе бик күп халыкларны шашындырган, юлдан яздырган тәгълиматларына кизәнергә курыкмыйсыңмы, дип сораячак әле бер дә бер көнне Руслан Даулатович Кәримәдән. Шул чакта Кәримәнең күз алдына әнисе, Сәгыйть Сәетович кунакханәсендә яткан буй-буй трусик кигән капкорсак күз алдына килер дә ул: «Юк! Курыкмыйм!» — диячәк.

* * *

Руслан Даулатовичның хатын-кызны «чүпкә» санамавы чынлап та хак иде. Ул моны бер лекциясендә студентларына да исбатлап күрсәтте. Кайсыдыр, утырган җиреннән генә:

— Казан хатын-кыз кулында булмаса, Иван Грозный шәһәрне ала алмаган булыр иде. Казанны хатын-кыз саткан, Сөембикә саткан урысларга! — дигән сүзләр ычкындырган иде.

Профессор әүвәл әлеге студент егетне эттән алып эткә салырга, наданлыкта гаепләргә уйлаган иде, ахыр чиктә Сөембикә хакындагы чын тарихны сөйләп бирүне кулайрак күрде бугай.

— Минем өчен Сөембикә гомергә якты шәхес образы булып яши. Ул гүзәл, батыр, кыю хатын, көчле хатын. Башка Казан бәкләре чүпрәк-чапрак яки акча өчен урыска ата-анасын да сатып җибәргән шул дәһшәтле чорда Сөембикә алардан ун башка өстенрәк тора! Язмыш аны, Сафагәрәйдән аерып, тол калдыра.

Үзен, ирексезләп, Мәскәүгә алып китәр алдыннан, Сөембикә ире Сафагәрәй кабере белән хушлашканда сөйләгән сүзләренә игътибар итегез сез! Чәчләрең үрә торырлык! Бу елъязмаларда теркәлеп калган[1]. «Сөембикә кабер янына җиткәч, башындагы алтын башлыгын алып ташлады. Моңлы тавыш илә еглап: «Әй минем сөекле падишаһым Сафагәрәй! Күрәсеңме бөтен хатыннарыңнан артык яраткан хатыныңны! Хәзерендә мин сөекле углың илә урыс йортына тоткын булып китәмен. Синең илә озак ханлык итмәдем... күп яши алмадым. Син ник миннән вакытсыз аерылдың? Ни өчен мине тол, сөекле углыңны үксез калдырып, кара җир астына киттең? Син кайда торасың? Мин дә синең яныңа барыймчы, икәүләп бергә торыйкчы! Ни өчен син мине монда калдырып киттең? Күрмисеңме, синең бикәң үзебезнең мәңгелек дошманыбыз булган Мәскәү падишаһы кулына биреләдер. Мин ялгызым гына аңа каршы тора алмадым, үземә ярдәм итүче кеше таба алмаенча, ирексез аңа биреләмен. Әгәр дә тел һәм динебез бер булган падишаһ кулына тоткын ителгән булсам иде, мин һич кайгырмаган булыр, шатланып кына барыр идем. Сөекле падишаһым! Минем ачы еглауларымны ишетсәнә! Үзеңнең караңгы ләхетеңне ачып, мине үзең яныңа алсана! Синең ләхетең миңа һәм сиңа хан урындыгы, якты сарай булсыннар, әй сөйкемле падишаһым! Кайсы чакта мин, рәнҗеп, сиңа «үлүчеләр илә тумаучыларга куаныч булыр» дия идем түгелме? Шул мин әйткәнчә булмадымы? Син шуларны белмәдең, менә безгә хәзерендә тере көенчә кайгы һәм рәнҗү килде. Сөйкемле падишаһым, үзеңнең яшь һәм матур бикәңне кабул итсәнә! Мине харап итмәсәнә! Минем матурлыгым илә дошманнар файдаланмасыннар иде. Мин синнән аерылмыйм, көлке һәм мыскыл ителер өчен, телләре һәм диннәре башка булган ят җиргә китмим. Сөекле падишаһым! Кем анда килеп минем еглавымны басылдырыр, кем минем ачы яшьләремне туктатыр, кем минем җанымның кайгыларын таратыр, кем минем яныма килер? Миңа һичкем юк... Мин кайгымны кемгә сөйлим: углыма сөйлимме, ул сөттән аерылмаган, атама сөйлимме, ул моннан бик ерак, казанлыларга сөйлимме, алар бит, үз ирекләре илә ант итеп, мине урысларга бирделәр. Әй сөекле падишаһым Сафагәрәй! Ник син миңа җавап бирмисең, ни өчен үзеңнең сөекле бикәңнең ачы яшьләрен ишетмисең? Менә монда, ишек төбендә, мәрхәмәтсез гаскәрләр торалар, алар мине, ерткычлар кыр кәҗәсен алып киткән кебек, синең яныңнан алып китмәкче булалар. Бер чагында синең хатының булган, бөтен Казан падишаһлыгының бикәсе саналган кеше хәзерендә кызганыч тоткын, ярлы һәм арык кол булып калды. Борынгыдагы куанычлар, андагы кәеф-сафалар өчен хәзерендә еглаулар, ачы күз яшьләре килде. Электәге ханлык шатлыклары урынына мине рәнҗүләр, кайгылар, бәлаләр чорнады. Мин хәзерендә еглый да алмыйм, күземнән яшьләрем дә чыкмый. Бетми торган ачы яшьләр илә минем күзләр сукырайды. Күп кычкырудан тавышларым кысылды!» — диде.

Аудитория тулы яшьләр әлеге хәлне тынсыз калып тыңладылар. Кызларның күзләрендә яшь, егетләр исә авыз ачып сүз әйтерлек дәрәҗәдә түгелләр иде. Авыр тынлыкны Руслан Даулатович үзе бозды:

— Күрәсезме, Сөембикә ничек итеп иренә сыгына, үзенең хатын-кыз язмышы ире кулында булган чакларны сагынып, ачы күз яшьләре белән искә ала! Сүз дә юк, гүзәл хатын, сокланырлык хатын, кыю, батыр ханбикә! Ләкин шуңа да карамастан Сафагәрәй атлы иренең канаты астына сыенып яшәүне артыграк күргән сөйкемле, чын хатын-кыз!

Заһид, кызык булсын өчен:

— Ә хәзерге кызлар чит милләт кешесенә кияүгә чыгарга атлыгып торалар, алучы гына булсын! — дип, сүз кыстырып караса да, авызын ерып көләргә атлыгып торучы булмады. Чөнки бу бер дә көлке түгел иде...

Руслан Даулатович фикерен:

— Моны борынгы тарих дип кенә карамагыз. Тарих гасырлар буена кабатланып тора ул... — дигән сүзләр белән төгәлләде.

### Тагын... Шул үгез…

Әнисенең ireккә чыгуы әтисенә бик-бик тә шифалы дәва булды — аякларына җан керә башлады, бармаклары кыймылдарга кереште. Йа Ходаем! Иң үтемле дәва яки җылы сүз, яки яхшы тәэссорат икән ләбаса!..

Ләкин бу бәхетле көннәрнең гомере кыска булып чыкты. Абруйлы кешеләргә нахак бәла яккан, дип, Химик Кәримәне судка бирде һәм бик зур суммада акча таләп итте. Химик белән судлашып торуның файдасы юклыгы һәркемгә дә көн кебек ачык иде, ул җиңеп чыгачак һәм акчасын да каерып алачак иде. Бөтен бәла дә шунда — аларның андый акчалары юк иде. Гаилә янә хафага төште. Әнисе тагын Сәгыйть Сәетович кебегрәк берәр шома кешенең кооперативына эшкә урнашырга йөри башлады.

Кәримә бу юлы озак уйлап тормады — туп-туры Сәгыйть Сәетович янына үзе китте.

Сәгыйть Сәетович кызны бик теләп кабул итте, нигәдер аның әнисенә дә ачу итми һәм кем кызы булуыннан да курыкмый иде, күрәсең. Әллә үзен гаепле сизә инде, чучка танау, дип уйлап куйды кыз. Әнә бит, шампан шәрабына чаклы алып килергә кушты, өстәл өстен төрле нигъмәтләр белән тутырдылар.

Тик шампан шәрабына бөкесе аша гына шприц белән аракы кушылганын, шуңа йокы даруы да өстәлгәнен каян белсен инде ул гөнаһсыз кыз бала?!

Сәгыйть Сәетович, аның гозерен ишетүгә, алдан ук әйтеп куйды, акча белән үзем ярдәм итәрмен, әниеңнең дә бездән алачак акчалары шактый әле, бүген үк исәпләтермен, диде бит, рәхмәт төшкере. Күрәсең, ул теге вакыттагы хәл өчен бик нык үкенә һәм гаебен әнә шул рәвешле юмакчы, гөнаһларыннан котылмакчы була иде, ахрысы, бахыр...

Бу урыс президенты Борис Ельцинның исерек баштан Мәскәү күпереннән сикергән бер матур, җылы кич иде...

*2004*

## КЫШЛАГАН ҮГЕЗ

Күз керүгә, аларның күп вакыты капка төбендә уза. Бер кат мал-туар карагач, авылда әллә ни эш юк. Көне салкын булса да, берәр сәгать вакытларын барыбер шунда уздыралар алар. Хәер, бу гадәт эшсезлектән түгел. Авыл кешесен эшсез дию дөреслеккә бик үк туры килеп бетми дә торгандыр. Үзен йөртә алган пенсионерына хәтле күп итеп аяклы мал асрый бит аның. Күз җитеп, җирләр туңдыруга, аны чалып, базарга алып чыга һәм шул рәвешле ел буе җан асрарлык запас туплый.

Капка төбендәге «җыелыш»та әнә шул малларның һәрберсе телгә алына, кемнеке нәрсә һәм ничек ашый, суйганнан соң, үгезнең арт боты күпме киләчәк — һәммәсе дә, үз җае белән, рәтечираты белән, тәмләп кенә әйтелеп кителә. Анысыннан да бигрәк, суйганнан соң, кем ни рәвешле һәм кайсы базарга илтеп сата — барысы энә күзеннән үткәрелә.

— Быел малай үгезне үзем кайтып суярмын, диде.

Һәрвакыт каладагы малаен кыстырып сөйләүче Хәлил абзый башлап җибәрде. Малай — аның горурлыгы, мактанычы.

Ир-ат, Хәлил абзыйның каладагы малае турында сүз чыкса, тынып кала, дәшмичә тыңлап кына тора. Аның, минем малай, дип, авыз суы корытуына аз гына эчләре пошып, чак кына кытыклары да килә бугай. Имеш, анда гына малай, аның малае гына зур түрә, янәмәсе!.. Әнә Чәүкә Шамиленең олы малае, район сабан туенда батыр калып, өр-яңа «Жигули»га утырып кайтты.

Шамил абзаң да, берәр ай чамасы кәпрәеп йөргәннән соң, бүреген янә батырып киде, сүз саен «Жигули»ны кыстырмый башлады, һәрнәрсәнең чамасы бар...

Хәер, Хәлил абзыйга да, аның түрә малаена да берәүнең дә үче юк, ачулары да бик каты килми. Болай гына инде ул. Мактансын, горурлансын Хәлил абзый. Рәхмәт аның малаена, авыл башындагы җимерек күперне төзәттерде бит әле! Хәлил абзый үзе дә әйбәт кеше. Менә дигән мал врачы. Пенсиягә генә чыкты. Тирә-юньнең сарык тәкәләрен печүче дә ул иде. Тәкә дигән кушаматы да шуннан калды. Ә, гомумән, әйбәт кеше Хәлил абзый.

Капка төбендәгеләр сугымнар турында бик тәмләп сөйләшсәләр дә, бүтән елларда мал сатудан кергән акчаның нинди максатларда файдаланылачагы турында җентекләп сөйләшмиләр, бу хакта хәтта авыз да ачмыйлар, барысы да ләм-мим иде. Ә быел, быел авыл халкы мәчет салу эшенә керешмәкче. Быел сүзләр күп һәм аларның төрлесе булачак әле.

Хәлил абзыйның үгезе ике кыш чыккан. Узган кыш февраль башында яше тулды, хәзер бер яшь тә ун айлык үгез ул. Мунча бурасы хәтле. Атнага бер мәртәбә муенындагы тимер чылбырын өзмәсә, күңеле булмый, ди. Тамакка да шәп, җиткер генә икән. Хәлил абзый үгезен бик хасиятли. Ул — аның мактанычы, горурлыгы, куанычы. Менә, малае кайтуга, бу атнада ук, муенына кызыл җеп салырга уйлап торалар әле. Быел ноябрь үтә дә салкын килде. Ураза кергәнче, үгезнең эшен тәмам кылу бик мәслихәт булачак, ди.

Хәлил абзый белән карчыгына ел әйләнәсе ашап торырга келәт хәтле үгезнең бер боты да җитеп ашкан. Калганын малаеның машинасына төяп җибәрергә исәп тота. «Базардан урыс суйган ит алганчы, мөселманныкы бит, натуральный». Шулай ди Хәлил абзый. Һәм бу аның җанын рәхәт кытыклап, күңелен җылытып тора. Үгез карау газаплары да, шул хәерсез хайван җәй көне очлы мөгезе белән төртеп сындырган кабыргалар авыртуы да онытылып тора.

Бүтәннәр мәчеткә дә өлеш чыгарырга уйлый. Хәлил абзый, Аллага да, муллага да ышанмаучы дөньяви кеше буларак, андый исәпне күңеленә дә кертеп карамады. Малае да хупламас кебек иде аның бу эшен.

— Йөз процент минем геннар малайда! — дип мактанып алу да килешеп кенә тора иде Хәлил абзыйга.

Мал врачы буларак, әлбәттә, ген кебек сүзләр аңа күптән яхшы билгеле. Андый сүзләрне соңгы арада теленә аеруча еш кертә башлады. Карчыгы — элеккеге укытучы — мәхәббәт гәзите алдыра, «Таһир-Зөһрә» дигән. Элегрәк Хәлил абзый аны: «Мәхәббәт гәҗите укыр көнгә калдыңмыни, кортка!» — дип үчекләп тә йөргән иде. Карчыгы өйдә юкта өстәл өстендә яткан гәзитне караштыра, укыштыра башлагач, үзе дә кызыксынып китте. Бер мәкаләдәге: «Баланың холкын туксан процент ата-анадан килгән геннар формалаштыра», — дигән фикер аеруча ошаган иде аңа. Шул рәвешле, мал врачы буларак, инде күптән белеп, хәзер теленнән төшеп калган «ген», «нәселдәнлек» сүзләре янә әйләнеп кайттылар. Бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй, мәхәббәте дә юк нәрсә түгелдер инде аның. Кичләрен карчыгы белән яшь чакларын исләренә төшереп утыралар бит әле. Хәлил абзый дингә ышанып ук бетми. Шулай да дин сабакларын укый. Әллә... Әллә инде картаймыш көнендә, кайчан булса да бу фани дөньядан китәселәре күңеленә кереп, акыл шәрифләре дин хакындагы фикерен үзгәртмәкче микән?

Бу җиһанда иртәгә тормышы өчен ныклы терәге булмаган адәмнәр генә, дин юлына басып, Аллаһы Тәгаләгә табына торганнардыр. Ә аның терәге бар бит. Каладагы малай — аның куанычы, ышанычы.

Хәлил абзыйның тормыш фәлсәфәсе элек әнә шундый иде. Соңгы елларда халыкның дингә уң як белән борылуы, күпләп мәчетләр салына башлау, өлкәненең-яшенең намаз иясе булып китүе аның күңелендә дә эзсез калмагандыр, әлбәттә.

Хәер, халык элек тә диннән йөз чөермәгән иде. Ничекләр генә итеп таптасалар, хурласалар да, ул динен ташламады. Дингә каршы котыртучы мокыт бәндәләр, үзләрен «пульно умный»га санасалар да, шуны төшенмәделәр: һәр кеше үзенең кайчан да булса дөньялыктан китеп барасын белә, акылы белән оҗмах-тәмугларга бигүк ышанып бетмәсә дә, аннан кире кайтып: «Ышанмагыз, оҗмах та, тәмуг та юк икән ул!» — диюче булмагач, «Ә бәлки?» дигән гомерлек курку-икеләнү адәмнәрне һәрвакыт борчып торачак. Мәгълүм ич, кеше, олыгая барган саен, Ходайга ешрак мөрәҗәгать итә башлый.

...Әгәр дә кешенең хәлен аның тормыш дәрәҗәсе белән чагыштырып бәялисең килә икән, син аңардан шатлыгы турында түгел, кайгы-борчуы хакында сора. Соңгысы зур әһәмияткә ия булмаса, ул кеше — бәхетле кеше. Бәндәнең вак-төяккә дә игътибар итүчән булуы аның тормыш бөтенлеге хакында сөйли, чөнки бәхетсезлек барында ул аларга игътибар итә алмый.

Бүгенгесе көндә Хәлил абзый җыен вак-төяккә дә игътибар итеп яши торган кеше иде. Мәчет салуны исәпкә алмаганда, капка төбенә җыелышып сүз куерта торган мәсьәләләре дә гел юк-бардан гына тора бугай.

Мәчет салу турындагы сүз моннан берничә атна элек, колхоз чөгендерен җыеп саткач та башланган иде. Капка төбендәге әңгәмәнең бер өлеше сугым турында булса, калганы мәчет салу эше иде. Агачтан салыргамы, таштанмы? Кеше яллап эшләтергәме, әллә үзләре, авыл ирләре җыелышып керешергәме? Мулла кем булыр, кем азан әйтер, җомга намазларын кем укыр? Аксак Галимулла малае Габдулланың тавышы да матур, укуын да укый белә, гарәп хәрефләрен дә таный, диләр. Тик ул эчә. Егылып ятмаса да, туры килгәндә, мичкәсенә төшә торган малай.

Хәлил абзыйны, мәчет хакында сүз чыккач, беренче нәүбәттә, әнә шул нәрсә борчый, һәм ул мәчет мәсьәләсендә гел кирегә сукалый, бу эштә катнашырга атлыгып тормый. Ходайны танымаучы адәм буларак, әлеге гамәле аның холкына тач туры да килеп тора иде.

— Лучши картлар йортына ярдәм итәм мин, — ди.

Һәм ярдәм итә. Хәлил абзый, колхозда ветераннар советы рәисе буларак, картлар йортының тишек түбәсен алыштыру эшен кайгыртып, үз куллары белән җимерек мичен сүтеп, яңасын чыгарды. Әле быел да, бәрәңге ала башлауга, ике капчыгын басу бакчасыннан ук шунда илтеп тапшырды.

Дөнья көн саен болганып, тулганып тора. Каладагы малай да авылда мәчет салырга ярдәм итәм дип атлыгып йөрүчеләрдән түгел. Бүген болай, иртәгә тегеләй ич хәзер дөньясы. Коммунистлар яңадан килеп утырса дип, ул партбилетын да ертып ташламады. Кем белә?..

Хәер, барыбер бу атнада, үгез суярга кайткач, Хәлил абзый малаена мәчет турында сүз катырга уйлап тора әле. Чыгарган ташы, меңгә якын кызыл кирпече дә әрәм ята. Халык купса, мәчетнең нигезенә, бәлкем, шуларны бирергә булыр дип уйлап куя ул кайчакта. Малаеның ни әйтәсен алдан ук белә белүен. «Юк белән башыңны катырып йөрмә, артык булса, картлар йортына илт!» — диярме икән тагын? Мөгаен, бу хакта авыз ачмавың хәерлерәк булыр.

Юлдаш әби әйтүен әйтә ул, узган юлы барганда да әнә нәрсә диде әле, ирләр хатыннарны ярата, хатын-кыз — балаларны, балалар — песиләрне, ә песиләр беркемне яратмыйлар, диде-ме?

Юлдаш әби гомер йомгагын картлар йортында сүтеп ята. Чыгышы белән Байтимердән, унҗиде чакрым ераклыктагы Юлдаш авылыннан. Гомере шәһәрдә узган. Фәннәр кандидаты. Ире белән бер малай тәрбияләп үстергән. Ире вафат булып, үзе дә газ плитәсен кабызып чәй куярга да ярарлыгы калмагач, килене, карт кешенең балалар тәрбиясенә йогынтысы начар, дип, аны Байтимердәге картлар йортына урнаштырган.

Хәер, әби, дигәч тә... Газ кабыза алмый, дигәч тә... Кызлар кебек әле ул. Сөйләшү, фикерләве генә түгел, хәтта гәүдә-сыны да бетәшмәгән, кем әйтмешли, тот та бүген үк берәр яшьрәк бабайга кияүгә биреп җибәр. Хәлил абзый белеште: килене белән килешә алмаганнар алар, ә малаеның килен кулындагы дилбегәсе бик тә нык каештан ишелгән, ди, имеш.

Хәлил абзый һәр баруында әнә шул Юлдаш карчыгы белән гәпләшеп утыра, тегесе, килгән саен, гомереңнең бәхетле минутларын озынайтасың килсә, карчыгыңның сәламәтлеген кайгырт, ялгыш үлеп китә күрмәсен, дип акыл сата. Әлбәттә, Хәлил абзыйның карчыгы, кайчак ыңгыр-шыңгыр йөргәләсә дә, алай үлеп китәрлек түгел әле, тфү, Аллам сакласын!

Хәер, соңлап булса да төшенде Хәлил абзый: Юлдаш карчыгы үз малаена бик тә үпкәле, шуңа күрә ул Хәлилнең: «Малай, түрә малай!» — дип авыз суын корытуын бигүк өнәп бетерми бугай.

Нишлисең, балалар һәрвакыт акыл ягыннан аталарыннан өстенрәк инде, чөнки үз акыллары янына аталарыныкы да өстәлгән була бит.

Хәлил абзый каладагы малаен ярата гына түгел, ә кайчак аңардан шүрли дә булса кирәк. Шулай булмый ни! Нindидер Байтимердән чыккан Хәлил малае Казан хәтле Казанда зур түрә булып эшләсен әле! Авылга бер мәртәбә вертолет белән дә кайтып төшкәне бар аның! Шуннан соң авыл халкы атна буе һушына килә алмыйча миңгерәп йөрде!

Юлдаш әби сөйләр ул. Тик малай малай инде. Үгезне дә шуның өчен генә симертте Хәлил абзаң. Урыс суйган итне ашап ятмасыннар, дип. Мал врачы буларак, белә ич ул: Казан шәһәрендә юньле ит юк, белмичә алсаң, океан артыннан китерелгән «бракованные» ук булмаса да, барыбер Чернобыль үләнен ашап үскән сыерлар була инде ул. Ире шулай дигәч, хатыны Зөләйха:

— Ни сөйләп утырган буласың?! Аның кем булып эшләгәнен белмисеңмени?! Аларның ашаган ипиләренә тиклем ашлама белән үстерелмәгән. Үзең әйтмешли, натуральный! — дип каршы төшә.

Нишләрсең, карчыгы аның сүзләренә каршы киресен әйтергә ярата инде, шуннан тәм таба бугай кортка. Ә абзый аның белән килешми, үзе дә киресен сукалап ләззәтләнә. Дөресен генә әйткәндә, Хәлил абзый башта ук малаеның авыл хуҗалыгы институтына керүен, авылда яшәвен, тора-бара үз колхозларында рәис булып эшләвен теләгән иде. Зөләйха шул вакытта кырт кисте:

— Синең кебек тирес корты буласы юк!

Соңгы елларда гына, малай инде күптән юрист һөнәрен үзләштереп, зур урыннарга үрмәләп, дәрәҗәле түрә булгач кына, бу хәл белән килеште Хәлил абзый. Белмәссең, аңламассың! Теге чакта, малай мәктәп тәмамлап, һөнәр сайлаганда, хатыны да хаталанмый, ул да хаклы иде кебек ич! Һәм хәзер дә... Чөнки Зөләйханың килен хезмәте күргәне юк. Ә Хәлил абзыйның, бер рәхәтләнеп, авыз тутырып: «Киленкәем!» — дип, килене белән сөйләшә алганы, оныкларын үз туган телендә тәмле сүзләр әйтә-әйтә сөя алганы юк. Сынок, имеш, миленький, имеш! Марҗаның да нинди диген әле: Нонна Иосифовна! Яһүди кода-кодагыйлары белән аралашканнары да юк, алар, кызлары кияүгә чыгуга, Израильгә күченеп киттеләр.

Шулай инде менә... Ул да хаклы, хатыны да хаталанмый...

Хат ташучы тартмага гәзитләр салып киткән. Район гәзите бар, бу калын журналны Зөләйха алдыра, мәхәббәт гәзитенең дә чираттагы саны килгән. Монысын да Зөләйха алдыра. Карчыгының, шушы яшенә җиткәч, мәхәббәт җене кузгалганмы? «Таһир-Зөһрә», имеш. Әллә... әллә инде Юлдаш әбинең кем икәнлеген белгәнме? Хәер, юктыр, каян белсен, күрешкәннәре юк бит.

«Таһир-Зөһрә», имеш. Хәер, бер яшьлектә, бер картлыкта, диме әле? Хәлил абзый Зөләйхасын болай гына, шаяртып кына, — хәтта яратып та түгелме икән әле, — үрти, ирештерә иде.

— Мә, гәҗитләрең килгән, — дип, ул аларны өстәлгә таратып салды. — Берәрсендә үгезне ничек итеп симертү турында киңәш-табыш булмасмы икән. Булса, миңа да әйтерсең әле.

Тагын үрти Хәлил абзый Зөләйхасын. Зур гәүдәсе белән өй тутырып, идәнне шагыр-шыгыр китереп йөргән Зөләйхасы — гомере буе балаларга әдәбият фәне укыткан хатыны — үртәлми, иренә ачуы килсә, юри мишәрчә акцент белән авызын томалап куя. Бу юлы да:

— Цукындың инде шул үгезең белән! Паетка[1] цыгар халь юк. Күрдеңме соң әле, тагын киртәсен җимергән бит, норсыз хайван! — диде дә өстәлдәге гәзит-журналларны җыеп, көзге алдына алып куйды.

Хәлил лапаска чыгып китте. Чынлап та, теге хәерсез мал муенындагы сибен тагын өзгән һәм лапастагы салкын ояның ике тактасын шартлатып сындырган. Хуҗасы килеп кергәндә, әле һаман дөбер-шатыр килә иде.

Хәлил абзый, кулына көрәк эләктереп, кызу-кызу үгез янына керде. Ә үзенең нинди ширлек эшләгәнен тойган хайван, сыртына көрәк сабы төшәсен алдан ук чамалап, арты белән почмакка чигенде. Хәлил абзый белә: үгезнең тынычлануы түгел әле бу, муенындагы авыр тимер бауның юклыгын сизү аның кытыгын китергән, ул әле тиз генә җимерү эшеннән тукталачак түгел, мондый гамәле исә кулына көрәк тоткан хуҗа абзыйны хәйләләү өчен генә иде. Мөгезе белән төртеп алырга да күп сорап тормас.

Һи, ашыкма әле син, үгез дус. Гомере буе мал-туар арасында кайнашкан Хәлил абзаңны алай ансат кына хәйләләрмен димә! Иң әүвәл муеныңа сибеңне кидерсен әле ул. Әһә, карышасыңмы, бәйләтәсең килмиме! Алайса, хәзер болай итәбез. Абзаң шуннан эләктерсә, тыпырчына да, мөгезләрең белән айкана да алмассың — шым булырсың, хайванкаем. Берьюлы ике кабырганы сындырдың инде син теге чакта.

Хәлил абзый, үгезнең борынындагы боҗрасыннан тотып, гәүдәсе белән аны улак янынарак этте. Борыны авыртуга түзә алмаган үгез карусыз буйсынды, муенын бәйләгәндә дә тыпырчынмады. Кызганыч тавыш белән мөгрәп кенә куйды. Нәрсә ди, күрше сыерының тавышын ишеткәч кенә ычкындым, аның янына кунакка гына кереп чыкмакчы идем, диме? Ә-ә-ә, иртәгә син көтүгә чыгасыңмы, дип сорамакчы идем, ди бугай. Вәйт хәйләкәр. Көтү кергәнгә бишбылтыр инде. Иртәгә син бүтән җиргә кунакка китәсең, Алла боерса. Хур сыерлары янына. Беләсең килсә, бер көтү хур сыерлары чәчәкле болында, сине көтеп, утлап йөри, ди анда. Берүзенә бер көтү булыр, яме. Иртәгә кадәр генә түз инде, җаныкаем.

Хәлил абзый, шулай сөйләнә-сөйләнә, үгезенә башак болгатып, аның муен асларын кашыйкашый иркәләде дә, тизәкләрен алгач, лапастан ишегалдына чыкты, «Һе, — дип көлемсерәде

ул, — оҗмахта хур кызлары бар, дип сөйләгән булалар бит әле. Үгезгә дә хур сыерлары буламы икән соң анда, ә? Юлдаш әбидән сорап карыйсы булыр әле. Ул Коръәнне су урынына эчә».

Үзенә әби түгел инде ул аның. Хәлил белән бер кормада алар. Картлар йортында яшәгәнгә күрә генә «Юлдаш әби» дип йөртәләр аны. Юкса... юкса теге чакта... Юлдаш авылы урманында чикләвек җыйганда очраткан кыз бит ул. Казанда студент булып институтта укып йөргән вакытта, Хәлил атлы гаярь егет аны — шомырт күзле, озын толымлы Таңгөлне — кинотеатрга да чакырган иде. Бары бер мәртәбә барды Таңгөл, икенчесендә кырт кисте: Хәлил, син авылга кайтып яшисе кеше, ә мин холкым белән дә, һөнәрем белән дә (ул университетның тарих бүлегендә укый иде) шәһәр кешесе булачакмын. Вакытыңны бушка уздырып йөрмә. Үз тиңеңне тап!

Әйе шул, башкалар өчен генә Юлдаш әби ул. Чынлыкта Таңгөл исемле. Таңгөл әби. Хәлил өчен — Таңгөл. Язмыш диген... Язмыш кешене ярты гомеренә чаклы үз артыннан тартып, сөйрәп бара, аннан соң, туктап калмыйча атласын өчен, эткәләп-төрткәләп кенә тора, ди. Хәер, без бәхетсезлегебезне генә язмышка сылтыйбыз, уңышларны, бәхетле чакларны исәпкә кертмибез. Бәлки, эш монда язмышта гына да түгелдер... Алай дисәң, адәм баласының язмышы аның эшләпәсе астында гына, диләр бит. Кара, кара, ул, Хәлил абзый, нәкъ Таңгөл кебек фикер йөртә түгелме соң? Юлдаш әби теленнән төшкән фәлсәфи сүзләр белән фикерли ич!..

Язмыш дип инде, бәлкем, алай дип әйтерлеге дә юктыр. Бик гади һәм гадәти кебек кенә булды ич. Киного чакырырга икенче, өченче көнне дә барды Хәлил. Бер килүендә Таңгөл, группадаш Казан егетенә ияреп, ресторанга китеп барды. Хәлил күз алдында. Казан малае бер бәйләм розалар күтәреп килгән иде. Хәлилнең хәтта ромашка да бүләк иткәне булмады: «Кино карарга яратмыйм мин!» — диде кыз һәм, бүлмәдәш кызы белән икесен генә калдырып, култыклашып чыгып та киттеләр.

Бүлмәдәш кыз Зөләйха егетнең тирләгән учында бөгәрләнеп беткән кино билетларын үзенә сорап алды ул чакта, аннары тиз генә үтүген кыздырып, билетларны өстәлгә салды да, өсләреннән марля белән каплый-каплый, үтүкләп тигезләде һәм яңагына куйды:

— Кайнар, битне пешерә, киносы да шәп булырга охшаган, — дип, гади генә һәм бик тыныч тавыш белән әйтте дә салды.

Киного ул көнне Зөләйха белән икәү киттеләр. Хәзер дә алар, олыгайган көннәрендә, кино карарга яраталар. Үз өйләрендә, икесе янәшә кәнәфигә утырып, телевизор экраныннан. Ияләнелгән, күнегелгән инде. Бергә яши-яши... гомер буе...

Теге чакта? Әйе, ул вакытлар, бигрәк тә беренче очрашу, тора-бара, еллар уза-уза, һаман саен ачыграк булып искә төшә, барлык нечкәлекләре белән күз алдына килә дә баса.

Кинодан соң («Кара каен» дип аталган бик әйбәт фильм иде) бик озак Казан урамнары буенча сөйләшеп йөрделәр. Кино тәэсиреннән егетнең теле аңкавына ябышкан, күп сөйләшми, тыңлый гына. Зөләйха, Чувашстанның Батыр районыннан Казан университетына укырга килгән мишәр кызы сүли дә сүли. Әүвәл аңа кызның теле ничектер ят, сәер булып тоелган иде. Шунысы коткарды: аларның үз якларында да «ж», «ч», «һ» хәрефләрен нәкъ мишәрчә каты итеп әйтәләр һәм белмәгән кеше аны мишәр егете дия иде. Хәер, белмәгән кеше дип, ерак бабалары кыпчак белән туганнардан бит. Аны мишәр диючеләр, үзләре дә белмичә, асылда, дөресен әйтәләр булып чыга инде.

Күңеле һаман Казан егетенә ияреп киткән күрше Юлдаш авылы кызы Таңгөлдә булса да, Зөләйханың эчкерсезлеге, гадилеге егеткә бик ошый, кыскасы, аның белән күңелсез түгел иде.

Сәгать унберләр тирәсендә генә Зөләйханы тулай торагына озатып куйды ул. Кыз тулай торак ишеген ачкач, кермичә булдыра алмады: вахтада утыручы хатын, ярдәм эзләп, каравыл кычкыра иде. Баксаң, ике солдат, аны читкә кысрыклап, тулай торакка керергә маташалар икән. Вахтер хатын, таныш егетне күрүгә:

— Әнә, БКД начальнигы үзе кайтты! Күрмәгәнегезне күрсәтә ул хәзер сезгә! — дип шәрран ярды.

— О-о! Боевая комсомольская дружина меня бережет! — дип, солдатларның берсе ыржая ук башлады.

Салмыш иде алар. Буе ике метрлы, таза бәдәнле көрәшче Хәлил аларның якаларыннан гына эләктереп алды да ишектән чыгарып атты. «Хәзер мин сине урамга чыгарырга куркам инде!» — дип еламсырады Зөләйха. Вахтер хатын да: «Узыгыз, уз!» — дип кертеп җибәрергә әзерлеген әйтеп куйды. Бу фикер Хәлилнең үзенә дә ошады. Таңгөл дә кайткандыр. Хәлилне Зөләйха белән бергә күреп шартласын әле: кино карарга яратмый, имеш...

Ләкин бүлмә бикле, Таңгөл кайтмаган иде.

Иртәгесен кояш икенче яктан чыкты...

Ә Таңгөл өчен ул бөтенләй сөенеп торды кебек. Чөнки Хәлилгә үзе дә битараф түгел, теленә шайтан төкерсен: авылга кайту-кайтмау турында ул болай гына әйтте. Дөресрәге, кызның иләс-миләс чагы иде, Хәлилнең күзләрендә мәхәббәт уты күреп, аны алай тиз сүнәр дип уйламый, һәм, көнләштереп, әлеге ут-ялкынның тагын да көчлерәк дөрләвен генә көтә иде. Таңгөлне пыскып торган мәхәббәт уты гына канәгатьләндерми, аны, чибәр, гүзәл кызны шашып яратырга тиешләр.

Кыз-хатынны егет-ирләрнең холкы да, йөз-кыяфәте дә түгел, тасма теле һуштан яздыра. Ул вакытта янып торган шомырт кара күзле, сөлектәй сылу, тулган айдай гүзәл авыл кызы, бераз кирерәк тә, чак кына кыланчыграк та яшь кыз, аның шулай икәнлеген каян төшенсен инде?..

Хәлил, беренче күрүгә, Юлдаш әбинең Таңгөл икәнлеген белмәде. Тегесе таныса да, сиздермәскә тырышты бугай.

Картлар йортының дәү корсаклы миче ишелгән. Үз түбәсе астына ундүрт караучысыз җанны сыйдырган йортны, элеккеге клубны, көзгә кергәнче җылытырга кирәк иде. Хәлил, колхозның ветераннар советы рәисе, мич чыгаручы оста эзләп йөреп тә таба алмагач, үзе тотынды. Кулы белә, бала чактан өйрәнгән эше иде.

Картлар йортында, аның җитәкчесенең сүзләре белән әйтсәк, тугыз әби һәм биш бабай тәрбияләнә. Күбесенең балалары исән-сау, бик сирәге генә япа-ялгыз.

Миччегә кирпеч биреп, балчык изеп тору эшенә барысы да дәррәү алынды. Мичнең хатын-кызлар ягындагысы ишелгән иде, шуңа күрә төп киңәшчеләре дә алар һәм шулар ук аны өйрәтеп тә тордылар.

Мичнең яртысы өелеп беткән иде инде, Хәлилнең кулыннан калагы ычкынып китеп, идәнгә барып төште. Әбиләрнең берсе, җәһәт кенә иелеп, калакны алды да миччегә сузды һәм... Хәлил абзый чак егылып төшмичә калды: Таңгөл бит бу! Юлдаш авылыннан. Агач башында эләгеп калган кыз, Казанда бары бер генә мәртәбә булса да бергә киногa барган Таңгөл! Ул егет чакта шашып сөйгән Таңгөл ләбаса бу! Әллә охшаган гынамы? Туган тиешлесе булса?

Ул калакны Юлдаш әби кулыннан алды да ниндидер ят тавыш белән әйтеп куйды:

— Рәхмәт, Таңгөл!

Юлдаш әби дерт итеп китте. Аның сүрелә барган күз карашы гөлт итеп кабынды, аксыл йөзенең урталары кызарып чыкты, маңгаендагы җыерчыклары язылды, канәфер төсендәге юка иреннәренә кан йөгерде. Хәлилнең исә сап-салкын кирпеч кулын пешергәндәй булды.

— Мин сине күрүгә таныган идем, Хәлил.

— Мин танымадым, Юлдаш әби...

Ул көнне алар ике-өч сүз генә алышсалар да, Хәлил абзый, калган булышчыларын азат итеп, мичне икәүләп кенә диярлек чыгарып бетерделәр, Таңгөл Хәлилгә кирпеч биреп торды. Шунысына шаккатты Хәлил: нинди кирпеч кирәген, — бөтенеме, яртылашымы, — булышчысына әйтеп тә торасы юк, ул үзе белеп сайлый, хатын-кыз башы белән каян белә, ничек чамалый диген, һәр кирпече нәкъ туры килеп тора.

Мичләрне тиз чыгара торган иде Хәлил. Бу юлы нигәдер озаккарак сузылды. Әллә һәр кирпече күңел җылысына төреп салынды инде? Балчык, кирпеч һәм күңел җылысы... «Фәйләсуф булып барасың түгелме, Хәлил туган», — дип көлемсерәде мичче үзалдына.

Чикләвек урманында булган хәлне хәтерлисеңме дип бик сорыйсы килсә дә, теле әйләнмәде. Оныткандыр да, аннан бирле күпме сулар акты...

Чикләвек җыя-җыя урман эченә үк кереп киткән Хәлил кечерәк бер аланлыкка килеп чыкты. Ул кай тарафка китәргә белмичә таптанып торганда, аланлыкның икенче ягында: «Коткарыгыз!» — дигән ялварулы тавыш ишетте. Кыз бала тавышы. Егет, абына-сөртенә, тавыш килгән якка китте. Күңелендә курку да юк түгел иде — ерткыч мазар йөрсә! Тик шөбһәсе урынсыз булып чыкты, бер кыз агач башына менгән дә төшә алмыйча куркып утыра, дөресрәге, юан, кәкре нарат ботагы күлмәк итәгеннән эләктереп алган.

Хәлил төбе чикләвек белән яшьнәгән бәләкәй ак капчыгын үлән өстенә куйды да җитез генә агач башына үрмәләде, ботакка эләккән күлмәк итәген ычкындырды һәм, сикереп төшеп, кулларын югарыга таба сузды:

— Төш, төш, курыкма! Тотам мин сине!

Кыз, акрынлап, төшә башлады. Менгәндә ничек менгәндер, наратның аскы өлешендә ботаклары да юк, шоп-шома. Шул урынга җиткәч, ул күзләрен чытырдатып йомды да егетнең кочагына сикерде. Аның гәүдәсе шулчаклы җиңел иде, күбәләккә әйләнеп, очып китәр кебек. Әле генә куркып агач башында елап утыра иде. Хәлилнең көчле кулларына килеп эләккәч, куркыныч узганга сөенеп, көлеп үк җибәрде.

— Ник мендәң агач башына?
— Үзебезнең авылның өй түбәләрен карарга дип.
— Кайсы авылдан соң син?
— Юлдаштан.
— Күрдеңме соң өй түбәләрен?
— Менеп җитеп булмады ич. Син нәрсә, прокурор кебек миннән сорау алып торасың әле! Ә?
— Мин прокурор түгел. Ә син менә — карга баласы. Агач башына каргалар гына куна, белдеңме!
— Син үзең карга баласы, ә мин — Таңгөл!
— Таңгөл. Юлдаш кызы Таңгөл.
— Син үзең?
— Байтимердән мин. Чикләвеккә килдем.
— Безнең урман чикләвеген җыярга килгәнсең икән.
— Әгәр мин чикләвеккә килмәгән булсам, син агач башында елап утырган булыр идең әле.
— Харап икән! Нинди герой! Коткаручы табылган булыр иде әле, белдеңме!
— Белмәдем шул.
Шул рәвешле бер-берсенә урынлы-урынсыз сүзләр әйтешә-әйтешә беркавым чикләвек тә җыйдылар.
Ул елны чикләвек бик эре, бик ишле иде Юлдаш урманында. Ләкин ул, кызганычка каршы, кыш көне сакларга яраклы булмады, эчләре кортлы яисә куыш иде.
...Хәлил абзый, үгезне бәйләп, өйгә кергәндә, Зөләйхасы, аны дәшәргә дип, үзе лапаска чыгарга җыенып тора иде. Төшке аш алдыннан алар икесе, кара-каршы утырып, өрек җимеше капкалыйлар һәм Зөләйха җәй көне үзе җыеп әзерләгән кырык төрле файдалы үлән төнәтмәсе эчеп куярга гадәтләнгәннәр иде. Дөрес, аш алдыннан ярты сәгать кала көндә эчелә торган үлән суы да, җимеше дә хатыны өчен түгел, нәкъ менә Хәлил абзый өчен генә әзерләнә иде. Чөнки аның ашказаны авырта. Әгәр аның белән бергә өстәл янына үзең утырмасаң, Хәлилнең җимешкә дә, үлән төнәтмәсенә дә орынып карамаячагын белә ул. Көйсез баланы юмалап ашаткан кебек, әүвәл үзе үрнәк күрсәтә. Йөрәккә хәл кертә, дигәч, соңгы араларда ул ирен өрек җимешен сәгатьләп ашарга мәҗбүр итә башлады. Хәлил абзый тыңламыйча булдыра алмый, аның өчен дип тырыша бит Зөләйхасы.
Шул арада гәпләшергә дә өлгерәләр үзләре.
— Гәҗиттән укыдым әле, — дип башлый сүзен Зөләйха түти. — Илле яшьлек берәү үзенең яшьтәшенә өйләнгән. Гомер буе күрше булып торганнар үзләре. Берсе өйләнмәгән, икенчесе кияүгә чыкмаган булган. Бар инде хәлләр дөньяда! Шаклар катарлык! Шуннан, болар өйләнешкәч, беләсеңме, игезәк балалары туган! Малай белән кыз, ди. Хатыны кырык җиде яшьтә. Ничек батырлыгы җиткән. Ничек кавышканнар диген әле! Ул яшькә җиткәч тә мәхәббәт туар икән, ә?..
Хәлил абзый дәшми, ашыкмыйча гына авызындагы җимешен мүкелдәтә. Дәшмәсә дә, уйлый: «Мәхәббәттерме инде, юктырмы. Әмма нәрсәдер бар, карчык, бар...»
Моңарчы, болай дип уйлау түгел, — бигрәк тә шушы яшенә җиткәч, — хис мәсьәләсенә кагылышлы хәлләр ике ятып бер мәртәбә төшенә дә кереп карамагандыр. Яшь чакта хәлләр булды инде анысы. Таңгөл өчен утка-суга керергә, теге Казан егетен телеграмм баганасына элеп куярга әзер иде. Ярый Зөләйха булды әле. Әнә хәзер аның каршысында гәзит хәлләрен сөйләп утыра ул кортка. «Нәрсә ди, иллегә җиткәч тә мәхәббәт буламы икәнни, диме? Причем монда мәхәббәт! Ир-атка әгәр кыен икән, ул өйләнә, рәхәт булса, шуның өстенә тагын берәр хатын-кыз эзләп чаба башлый, диме? Тегеңә дә кыен була башлагандыр. Шуңа өйләнгән».
Хәлил абзый шул рәвешле үзалдына сөйләнә-сөйләнә янә бер кат лапасны урап килде. Үгезе тынычланган, тагарагындагы башагын чупырдата. Үгезләрнең язмышы очар кошлар язмышы түгел. Очар кошлар кебек аларның җаны гына оча, кире әйләнеп кайтмый, Ходай катында алар.
Адәм баласы үзе үк үз башын төрле әкият-фаразлар белән дыңгычлый да һәм аннары гомер буе шул ялганына үзе ышанып яши бирә.
...Теге кирпечләрне мәчеткә биреп әрәм иткәнче, лапас стеналарын өяргә тотасы булыр. Алайса, үгез, тиктормас җан, ташкүмер калдыклары — шлактан коелган стенаны, мөгезләре белән төртә-кашый тишеп чыгара язган...
Хәлил абзый шундый киләчәк уйлар белән капка төбенә чыкты. Авыл тыныч, төшке аш вакыты булгангамы, урамда кеше-кара күренми. Беркавым капка баганасына сөялеп басып тор-

ганнан соң, ат караучы Галимҗан узып китте — ферма складына онга барышы. «Атын дагалатмаган икән әле бу хәчтерүш малай», — дип уйлап, Хәлил абзый аны күз карашы белән озатып калды. Фермадан ат абзарына кайтышлый ул берәр капчык онын ярты литр аракыга алыштырачак, әлбәттә, һәм фураж оны калдырган кешесен, башы авырткан саен, йөз грамм сорап кереп, ай буе изалаячак аннары.

Хәлил абзый капылт уйлады да янә лапаска таба юнәлде. Үгезгә башак биргәндә, онын азрак салды бугай. Шуңа өстәп аңа он суы да эчерергә булды. Үпкәләп китмәсен хайван. Үгез он суы эчеп торганда, борынындагы боҗрасын да салдырырга ниятләгән иде, ләкин бура кадәрле бу хайванның башын, аякларын ничек кенә нык ытып бәйләсәң дә, чалыр алдыннан егулары җиңел булмас, дип, кире уйлады, чөнки шул боҗрадан тоткан очракта гына гаярь үгез кәҗә бәтиенә әйләнә дә кала иде. Боҗрасыннан каптырмасаң, аякларын да бәйләтмәячәк әле ул: хайван пычакны әллә кайдан сизә, диләр бит.

Малай иртәгә иртүк таң белән кайтып җитәргә тиеш иде. Бу юлы, ит алып китәсе булгач, вертолет белән кайтмастыр инде, шәт.

...Ходай Тәгалә кешегә тәхет биргәндә, шуның бәрабәренә аның акылын да алып кала, диләр. Күрәсең, вакытын да ала бугай...

Иртәгесен Хәлил абзыйлар капка төбенә куе яшел төстәге япон «джибы» килеп туктады һәм аннан шофер белән тагын ике гулливер егет төштеләр. Хәлил абзыйның малае — машина хуҗасы — үзе күренмәде. Бәлкем, артта, икенче машинада кайта торгандыр, берәрсенә эше төшеп, тоткарланыбрак калгандыр? Хәлил абзый күн курткалы урыс егетләренең күзләренә өметләнеп карап, сорауларына җавап эзләде. «Нәрсә, багана кебек торасыз, әйтегез инде, әйт, хәзер кайтып җитә, диегез». Малаеның үгез суярга кайтачагын бөтен авыл белә бит инде! Егетләрнең берсе машина артындагы әрҗәдән катыргы тартма алды да әле һаман Байтимер юлын күзәтеп торган хуҗа абзыйга таба атлады.

— Мясо здесь, мясо дикого кабана?

Хәлил абзый аңа борылып та карамады, соңгы өмете итеп, моңарчы инде күргәне булган шофер егеткә текәлде.

— Үзе кайда?

— О, Халил абы, ему некогда, сегодня, в субботу, у них день охоты. На кабана поехали.

— А быка, быка кто будет резать, дип сорыйм мин сездән? — дип, ул яртылаш урысчага күчте.

— Мы, Халил абы. Не бойтесь, мы его сразу кых!

Хәлил абзыйның хәле китте, гәүдәсе калтырана башлады, тез асларына әйтерсең утын агачы белән китереп сукканнар иде.

Малай кайта дип сугымчы Галимуллага да әйтмәде. Югыйсә кичә кичтән Галимулла үзе килде, башы авырта иде. Хәлил абзый аны, салкын су да бирмичә, куып чыгарды. Җитмәсә, артыннан: «Минем малай кайта!» — дип калды.

Бу кәттә урыс малайлары белән ничек итеп суймак кирәк инде ул кыш чыккан үгезне!

Хәлил абзый аптырап басып торды да, егетләргә үз артыннан барырга кушып, лапаска юнәлде. Сугым өчен кирәк булган бар нәрсәсе дә кичтән үк хәстәрләнеп куелган иде, таяклары да, баулары да. Утын пычкысыннан үзе ясаган пычагы да әллә кайчан кайралган, лапас шкафында гына тора.

Ул әүвәл, үгез янына үзе кереп, борынындагы боҗрасын алды. Якын килеп карагыз хәзер! Бу атнада кайтмаса, киләсендә кайтыр малае. Икәүләп тә бик шәп суярлар әле.

Ә бу әзмәверләрнең үгезгә көче җитсә, ә?

Ул егетләргә үгезне күрсәтте дә, үзе җылы су белән чиста тастымал алып чыгарга дип, өйгә кереп китте. Каны сиптермәсенгә каплап кую өчен искерәк мунча себеркесе дә кирәк булыр әле.

Малай кайтмаганга ишегалдында дулап йөргән иренең күзенә артык чалынмас өчен, Зөләйха түти өйгә кереп, әллә кайчан җылы суын да, тастымал-сөлгесен дә хәстәрләп куйган, шәһәр егетләренең өс-башын алыштырырга бишмәт-бушлатлар, киез итекләр әзерләү белән мәшгуль иде.

Хәлил абзый ачулы иде, хатынына сүз катмады. Авылга вертолет белән кайтканда, малай — атасының горурлыгы, берәр төрле ярамаган гамәл кылса — Зөләйха түти гаепле, малай аңа охшамаган булып чыга иде. Гомергә шулай. Иренең гадәтен яхшы белгән хатыны ана күтәрелеп карарга да курыкты. Ул бары: «Һай, малай актыгы, ичмаса, дуңгыз атарга киткәнлеген әйтеп җибәрмәсен ие, бүтән берәр сәбәп тапсын ие», — дип кенә уйлап куйды.

Хуҗа, бер кулына сулы чиләген, икенчесенә бушлатлар тотып, өйалды баскычыннан төшеп барганда, ар якта, бәрәңге бакчасында, шарт та шорт аткан тавышлар ишетеп, каушавыннан, баскычта таеп китте һәм чиләге-ние белән бусага төбенә барып төште.

Ахырда беленде: урыс малайлары үгезне абзарыннан сөйрәп алып чыгып, лапас баганасына бәйләргә теләгәннәр. Үзенең үләсен сизеп, әүвәл юаш кебек күренгән үгез, чит кешеләрне өнәмичә, кинәт дулый башлаган һәм ачык лапас ишегеннән бәрәңге бакчасына чыгып киткән, шул җәһәттән яшьләрнең берсен төртеп егып, кабыргаларын сындырган, үлем исереклеге белән котыра-сикерә башлагач, урысларның берсе пистолетын чыгарган.

Иртән яуган ап-ак йомшак кар өстендә үлем белән тартышып, дерелдәп яткан мескен хайванның эч-башы тишкәләнеп беткән, алардан берөзлексез алсу кан саркый. Телен чыгарган, күзләре зур булып ачылып тора. «Һай, хуҗа абый, дога-бисмилласыз кемнәр кулына тапшырдың син мине! — ди кебек иде зур күзләрендәге сүнеп бетергә өлгермәгән рәнҗүле карашы. — Хур сыерлары янына да кертмиләр ич инде хәзер мине!..»

Хәлил абзый дәшмәде, тешләрен чыкырдатып читкә карап бер төкерде дә хатынын Галимулланы чакырырга йөгертте.

Үгезнең итен Казанга җибәреп, бер ресторанга тапшырттылар да, акчасын, тиененә кадәр санап, мәчет салу эшендә башлап йөрүче Төлке Хәкименә илттеләр. Хәким икенче көнне бөтен килеш акчаны кире кайтарды.

— Мондый акчаны, урыс атып үтергән хайван ите акчасын, изге эшкә, мәчет салуга тоту хәрәм булыр. Халык риза түгел, ачуланма, Хәлил кордаш, — диде ул, моңа үзен дә гаепле санады кебек.

...Иртәгесен иртүк Байтимергә китте Хәлил абзый. Йомыш-фәлән белән түгел, болай гына. Үзе чыгарган мичкә туңган аркасын терәп, байтак утырды ул. Иртәнге намазын укып тәмамлаганнан соң, аның янына Таңгөл-Юлдаш әби дә килеп утырды. Хәлил абзый, беренче мәртәбә күргәндәй, аңа озаклап, текәлеп карап торды да:

— Таңгөл, әйт әле, син чикләвек җыйган чакларны хәтерлисеңме? — дип сүз катты.

— Нигә хәтерләмәскә?! Син миңа агач башыннан төшәргә булыштың.

— Тагынниләр хәтерлисең?

— Синең белән киногa барганны.

— Нинди кино караганыбыз исеңдәме соң?

— Индийский иде бугай.

— Байтимер клубында да кино була икән бүген. Монда килешли белдерүен күрдем. Әйдә, бүген кино карарга барабыз, ә?

Юлдаш әби утырган урынында кыбырсынып куйды. Дәшмәде.

Мичкә терәлеп үк утырса да, Хәлил абзыйның аркасы һаман җылынып җитә алмый иде әле.

— Таңгөл, дим!

— Синнән тирес исе килә...

Хәлил абзый җавап кайтармады, янәшәдә генә таралып яткан черек усак утыннарын мич авызына томырды да туңган аркасын җылыга терәде...

## АЙНЫҢ ТУГАН-ТУМАЧАСЫ ЮК

Теге китте. Сөт машинасына утырып. Райүзәккә, судка дип. Ул калды. Кузгалып китәм дигәндә генә машинадан сикереп төште дә капка төбендә үскән кәкре агач артына ышыкланды. «Районга нишләп бу хәерче киемнән барырга тиеш әле мин! — дип сукранды ул үзалдына. — Өстендәгесе матур бит, үзе барсын! Аерылышу кәгазен дә үзе алып кайтсын!..»

Сорады бит иртә белән: «Яңа күлмәк-ыштан әзерләп бир», — диде. Җавапка: «Аерыласы хатыннан кием сорамыйлар! Яшь хатының табып бирер, җәме!» — дип кенә кычкырды.

Ул, аягын көчкә сөйрәп, түбән очтан югарыга — өенә таба атлады. Шулчак кылт итеп башына мондый фикер килде: яз көне аерылышу килешәме соң ул? Ахыры хәерле булырмы? Шуны Хәбибә карчыктан кереп сораса? Әнә генә бит аның йорты! Ул өшкереп имләгән хатын бәбигә уза, кысыр сыер бозау алып кайта, дип, юкка гына сөйләмиләрдер?

«Кермим әле! Муртымамы соң?! Яз көне аерылыштың ни дә, кыш көне ни... барыбер күңелле нәрсә түгел инде», — дип кире уйлады да иренеп кенә өенә таба атлады. Уйлары аякларына чолгана, шуларга менә-менә сөртенеп егылыр төсле. Авыл урамында эт тә юк. Бик иртә әле. Хуҗалык сөтен сәгать биштә үк җыеп озаталар. Урамда — уйлар гына. Уйлар басуга җим эзләп

очкан каргаларга ияргән, алар ерганаклар булып агалар, алар капка төбендәге шәрә агач ботакларына эленгән, беришесе сөт машинасына төялеп китте. Кичәге, бүгенге көн турындагы уйлар... Ә иртәгә?.. Аерылышкач ничек булыр икән соң, ә?..

Бала-чагалары юк югын да... Армиядән соң дүрт ел өйләнмәскә кушканнар иде аңа. Хезмәтен тутыргач, каты итеп, кисәтеп әйттеләр: дүрт елсыз өйләнмә, балаларың гарип туачак! «Туачак! Тумаячак!» — дип сөйләнә, сөйләнә ул капка келәсенә басты.

Фәгыйлә — армиягә озатып калган күрше кызы — йә өйләнәсең, йә мин башкага чыгам, дигәч кенә, солдаттан кайтуына өч ел дигәндә генә кушылганнар иде алар. Беренче балаларын Аллаһы Тәгалә ничек бирсә, шул рәвешле үз катына алып та куйды.

Икенчесенә үзләре җөрьәт итмәделәр. Көтәргә булганнар иде. Хәер, армиядән кайтканына дүрт ел да ике ай була икән бит инде. Күрәсең, аларга бәби язмагандыр. Инде менә аерылышуга да барып җиттеләр...

Чү, нидән чыкты соң әле алар арасындагы бу ызгыш? Юк, юк, үзеннән гаеп эзләргә, яисә акланырга түгел иде аның исәбе. Болай гына... Уйлар өермәсе алып кереп китте аны бу тарафларга. Чынлап та, нидән килеп чыкты соң әле бу хәлләр?

Бая, хатынының бертуган апасы яшәгән йорт яныннан узганда, аякларын көзән җыера язды, әйтерсең баганалары тимер торбадан утыртылган бизәкле капкадан бозау кадәрле, саллы колаклы астыртын эт чыгар да аңа ташланыр күк иде. Тизрәк, тизрәк! Җәһәтрәк инде!

Монда хатынының апасы яшәп ята. Гаиләсе белән. Гаилә дигәнең: хатын да ир, тракторда эшләүче исерек малайлары гына.

Тимер баганалы капканың келәсе «чык» итте дә аннан чуар яулыклы бер баш күренде. «Кая чабасың бу хәтле? Сөртенеп егыласың бит инде! Ташка егылып тез капкачыңны ярсаң! Бүлнискә эләксәң!..»

Хатынының апасы Фатыйма бу. Өйрәтә. Яшәргә өйрәтә. Ни ашарга, ничек йокларга... Кияүгә чыкканына байтак булса да, сеңлесе бала тапмый. Баланы каян аласын гына өйрәтеп җиткерә алмый Фатыйма. Ирек куйсаң, урталарына кереп ятарга да күп сорамас иде канә...

«Фатыйматын-таибатын — минем әни бай хатын» дип мыгырданды Хәмит, капкада хатынының апасы күренгәч.

— Кая болай чабасың, дим бит! Ни булды? — дип төпченде Фатыйма.

Хәмитнең аның белән сөйләшеп торырга ни теләге, ни кәефе юк иде. Әмма сорау шундый итеп бирелде ки, һич кенә дә җавапсыз калу мөмкин хәл түгел иде. Кияүнең гәүдәсе бишек сиртмәсе кебек җыерылды, тамак төбенә вак бәрәңге сыман төер тыгылды. Барыннан да бигрәк аның үз-үзенә, җавапсыз торуына ачуы килде һәм, ниһаять, әлеге хис тамактагы төерне этеп төшерде дә, акылы белән киңәшеп тә тормастан, хәерсез теле:

— Фәгыйләне районга илтеп куйдым. Бәби апкайтырга! — дигән яңалык әйләндереп чыгарды.

Капылт кузгалудан Фатыйма чайкалып китте, җәһәт кенә капка баганасына ябышты.

— Нинди бәби булсын ди!

Үз ялганы үзенә дә ошап китте Хәмитнең. Хатыны белән ачуланышканнан бирле ягылмаган тимер мич шикелле суык җанына җылы йөгерде.

— Корсагы да беленми ие бит әле аның?! Шул арадамы? Бигрәк тиз бит?!

— Тиз шул! Космос гасырында яшәгәнеңне белмисеңмени?

Күрәсең, Фатыйма һушына килеп өлгергән иде инде.

— Кай җирендә йөрткән ул аны! Алдыйсыңдыр ла! Миңа әйткән булыр ие!

— Төнлә участкауайны алып кайтканыем инде мин. Икәү булырга тиеш, ди. Игезәк! Берсе — кыз...

Хәмит телен тешләде. Арттыра бит! Артыгын шыттырып җибәрсә, мәңге ышанмаячак теге! Бу рәвешле хатынның апасыннан үч алуы рәхәт, җан рәхәте иде. «Мокыт! — дип уйлады ул, авызын колакларына тиклем җәйде. — Атлаган саен акыл саткан була. Яшәргә өйрәтә. Үзе шуңа да ышанды тагын! Мокыт... Бәби дә алып кайтмаган килеш, Фәгыйлә синең аркада гына китә! Соң, бала тапкач кына китсә? Малаем яки кызым ятим үссә?..»

Чү!.. Кызулык белән... Ачуланышу кайнарлыгы белән уйлап та, уйланып та караганы булмаган икән ич — хатынсыз ничекләр итеп яшәр икән соң ул? Моңарчы алай талашып тормады ич алар. Яшь, матур хатынның итәк җиле кагылып узганда да, каны шундук кайнарлана, аңа буйсынырга теләмәгән чуар күңеле һәм дуамал башы «нигә яшим?» дигән мәңгелек сорауга гади генә җавабын табып, урынына кире утыра торган иде.

Һаман да шул Фатыйма: «Бәби апкайтмыйсыз!» — дип тинтерәтә торгач, алар икесе бер авыздан: «Балалар өчен яшәргә өлгерербез! Әүвәл үзебез өчен яшәп калыйк», — диярләр иде.

Фатыйманың бертуктаусыз өйрәтүеннән, тормышларына кысылуыннан гарык булган Хәмит кияү көннәрдән бер көнне: «Синең дә балаң берәү генә. Нигә тагын апкайтмыйсыз!» — дип үртәгән иде, аңа мәчегә ташланган эт кебек ябышты. Бераз сүрелә төшкәч, аклангандаймы, әллә үз-үзен юатырга теләпме: «Көтү көткәндә яр буенда утырып салкын тигезде бит бажаң!..» — дип, башка балалары юклыгын әллә ире өстенә, әллә язмышка аударып калдырган иде. Шулчак беренче мәртәбә кызганып куйган иде Хәмит хатынының бертуган апасын. Адәм баласының күңелендәге кызгануны шундук этлек хисе алыштырды: «Нәрсә, чыбыркысы шартламый башладымы әллә?»

Бу ямьсез сөйләшү Хәмитләрнең ишегалдында бара иде. Әлеге сүзләрдән соң Фатыйма түтиебез бер агарды, бер күгәрде дә, нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде — сүзе чыкмады, аннан аңлаешсыз ымлыклар гына коелды. Гаярь хатынның моңа тагын да ачуы килде һәм ул, Хәмитләрнең салпы колаклы ялкау эте арт аягын койма култыксасына күтәреп кире төшергәнче, җәһәт кенә өенә кайтып, аннан иренең иске чыбыркысын өстерәп килде. «Нәрсә! Шартламыймы?! Хәзер шартлатып күрсәтәм мин сиңа!» — дип, ишегалды буйлап Хәмитне куып йөри башлады. Ире белән апасының дорфа сөйләшүеннән кәефе киткән Фәгыйлә, моны күреп, эчен тота-тота көләргә кереште. Апасы белән ире ишегалды буйлап куышуларын дәвам иттеләр. Ишегалды хәйран зур булса да, качып котылыр урын юк иде. Фатыйма шарт та шорт чыбыркы шартлата. Коты табан астына тәгәрәгән кияү балакай качарга урын эзли, үзе: «Кара, ничек шәп шартлата икән!» — дип уйлый. «Шартламыймы! Шартламыймы! Менә сиңа, менә сиңа, мә!» Бер-ике мәртәбә чыбыркы очы кияүнең колак яныннан да сызгырып узды инде. Ул чарасызлыктан лапаска чумды. Печәнлеккә качып котылу иде исәбе.

Тегесе Хәмит артыннан үрмәләде. Бәхеткә, печәнлектә чыбыркы шартлатып булмый иде. Шулай да Фатыйманың ачуы һаман да яман иде әле. Ул абынып печән өстенә ауган Хәмиткә ташланды. Буып үтерергә... борынын тешләп өзәргә диптер инде. «Борынсыз калсам, бетте баш!» дигән уй Хәмитнең миен көйдереп узды. Һәм ул өстенә ауган Фатыйманы, тыпырчынмаслык итеп, үзенә таба тартты. Хатынның кайнар сулышы битенә бәрелде, дәү имиләре күкрәген басты. «Йә, бу хәтле булса да булыр икән! — дип уйлады ул, хатынының апасын кочаклаган килеш. — Нәкъ Фәгыйлә! Кайнар сулышына тиклем! Имиләре генә бушрак. Ишегалды буйлап чаба-чаба тирләгән үзе. Фәгыйлә исе килә! Йа Раббым, булса да булыр икән!..» —дип, уйлап ятты ул аста килеш...

Эшнең болай килеп чыгуына Фатыйма үзе дә аптырап, хәтта каушап калды. Бу рәвешле кияү өстендә ятуына и оялды, и уңайсызланды хатын. Әмма хатын-кызның эчтәге зәһәрлеге көчлерәк булып чыктымы, йә инде әлеге хәленнән котылуның бердәнбер юлы, чарасы диптерме: «Каяле, каяле! Синең чыбыркың шартлыймы икән! Тикшереп карыйм әле!» — дип, тез башы белән җиңелчә генә бот арасына төртеп алуга, үзен салам көлтәсе астында калгандай хис иткән Хәмит, җәһәт кенә кочагын бушатып, «чүмәлә» астыннан шуышып чыгып, аска сикерде.

Печәнлектә кичергән иләс-миләс хисләр икенче көнне үк юкка чыкты. Икенче көнне үк Фатыйма тагын килеп, аларны янә яшәргә өйрәтә башлады.

Инде берничә ел бергә яшәп, Хәмит белән Фәгыйлә бер-берсенең гадәт-холыкларына тәмам ияләшеп бетә яздылар, әмма кияү балакай хатыны апасының «диктатурасын» күңеле белән дә, акылы белән дә кабул итеп, килешә алмады.

Беркөн шулай Хәмит такта ярдырып кайтты да ишегалдына бушатты. Мунчаны бәрәңге бакчасына табарак дәвам иттереп, шунда ян корылма төзү иде исәбе. Бәлкем, келәт булыр. Ишегалдындагы тактага Фатыйма да игътибар итте.

— Келәтегез бик тузгание, яңасын саласыңмы әллә? — диде ул, эссе каккан тавыш белән.

«Барысын да каян белеп тора бу, зәхмәт!» — дип сукранды Хәмит.

— Нинди келәт! Нәрсәгә кирәге бар аның! Бассейн төзим, — диде ул киреләнеп.

— Бассейн?! Авыл җирендәме? Мунчаң була торыпмы?

— Мунча үз урынына, бассейн үзенә!

Шулай иттереп, бер дә уйламаганда-көтмәгәндә, келәт урынына бассейн пәйда булды.

Тора-бара боларның аралары тәмам бозылышу чигенә җитте. Кияү хатынының апасын өнәмәс булды. Моны Фатыйма, күрәсең, үзе дә сизенеп йөрде микән, беркөнне ул аларны кунакка дәште. Итләре бетте. Ат алып суярга булдылар. «Килегез!» дип, бажа үзе чакырып китте. Фатыйманың бусагасыннан атлап керергә бер дә күңеле тартмаса да, бажасы килеп әйткәч, карышырга яхшысынмады.

Ат дигәннәре айгыр өммәтеннән иде. Аны чалырга күрше-тирәнең бар ир-аты җыйналды. Гадәт буенча, Фатыйма сугымчы ир-атларга киңәш-табыш итәргә үзе алынмакчы иде, арадан берәү ярым чын, ярым шаяртып:

— Монда йөрмә инде син, Фатыйма килен. Җә балаң гарип туар, — дигәч тә исе китмәгән иде. Ә төп сугымчы Гарәфи карт:

— Йөрмә дигәч йөрмә инде, килен. Борчылма, әгъзасын синә кисеп бирербез, — дигәч кенә, оялып, өйгә кереп китте.

Ир-ат тыныч кына, медер-медер сөйләшә-сөйләшә үз эшен эшләде. Нәрсәгә тотынса, кулыннан шул шөгыль килә торган күрше Гарәфи — алтмыш яшьләрдәге, колгадай озын буйлы, чандыр кеше — сүзнең тәмен белеп, сөйләр урынын белеп сөйли.

— Берзаман шулай күрше мари авылында Үзәкәйгә тәкә суйдым. Урманда агач тарттыра идек. Трактор ватылды да бер көн ял бирделәр. Иптәшләр өйләренә кайтып китте. Мин кайтмадым. Гәүһәр апагыз белән дә талашып чыгып киткән ием. Сагынсын әле, мин әйтәм, кайтмыйм. Икенче көнне тагын билдән кар җырып кире киләсе бар, мин әйтәм. Үзәкәйнең ире, Иванның дим, чыбыркысы шартламый ди бит. «Тройной» эчеп янган да... Химия бит инде. Нефтедән эшләнгән.

Шулай кичтән Иван белән самагун чөмердек-чөмердек тә чирмешем өстәл астына ук тәгәрәде. Тере кешеләрдән Үзәкәй белән икәү генә. Мин дә үз урыныма барып яттым инде.

Хикәянең нәкъ шушы төшенә җиткәч кенә, Фатыйманың бертуган энесе — колхозның бердәнбер «КамАЗ»ында шофер булып эшләп, салган баштан күптән түгел идарә каршындагы баганаларны рәттән кырган өчен эштән чыгарылган Хатыйп, салкын тигән юеш тавышы белән:

— Үзәкәй янына чумдым, диген инде, ичмасам, — дип, Гарәфи абзыйны «төзәтәсе» итте.

— Син нәрсә, энекәш! Кеше хатынына кул саламмы соң! — диде тегесе ачу белән.

— Үзәкәйнең шәп чаклары барые бит, дип кенә әйтүем.

Хатыйпның ялгыш сүзләре өчен үкенүе булдымы бу, аклануымы, әмма ул барыбер үчекләвен дәвам иттерде.

— Кеше хатынының йөзенә туры караганым да юк минем, энекәш! Үзәкәй яныма үзе килеп ятты беләсең килсә!..

Гарәфи сөйләвеннән капылт кына туктап калды. Сүзнең иң кызык җирендә генә өзде дә куйды, хәйләкәр. Хатыйпның борынына яңадан су җыелган иде, ул тыңкыш тавышы белән:

— Әйттем бит, әйттем бит! — дип кабатлады.

— Әйттең пычагым! Беләсең килсә, арканы куйдым да яттым, һаман китми әкәең. Шуннан юри киерелгән булдым да артны туңкайттым, караватта урын калмагач, Үзәкәй лап итеп идәнгә егылды да төште.

Иртәсен үлеп баш авырта гына бит. Үзәкәең самагунын җәһәннәм тишегенә үк яшереп куйган. Бирми. Иван эзләп тә карады. Үч ала, янәсе. Әүвәл тәкәне суеп бир, аннан соң бирермен, может, ди. Нишлим инде? Тәкәсен чалдым. Кулына табак тотып, Үзәкәй басып тора. Канын шушы табакка агыз әле, ди. Минем ишеткән барие инде — алар свежий канны куырып ашый икән. Ярар, мин әйтәм, китер табагыңны. Үзәкәй кереп киткәч, аяк тотып торырга да ярамаган Иван үзе миңа күз кыса, үзе тәкәнең җомыркасын йолкый. «Моны да табакка салырсың әле, бүтәкә дип әйтерсең», — ди. «Кит, мин әйтәм, ул җирен бездә килмешәк этләргә генә ташлыйлар» дим. «Җук, жук! Турап сал инде табакка! — ди. — Хатын-кыз шуны ашаса, дәрте кузгала, ди. Андый хатын үлгән кешене дә терелтә алырлык гайрәтле була», — ди. «Синең хатын болай да кимен куймый бит инде», — дип әйтеп булмый ич инде чирмешкә. Ялына гына бит. «Утын әрдәнәсендә яшереп куйган бер чирек самагуным бар, шуны алып чыгарыем», — ди. Дустың гозерен аяк астына салып булмый бит инде. Шулай эшләдек тә.

Хатыйпның борынына бу юлы су бик тиз җыелды, авызын ачып, сүз әйтә алмады. Беренче булып Хәмитнең баҗасы телгә килде:

— Алайса, айгырныкының да көче бардыр бит инде? Кемгә ашатыйк икән?..

Ул сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, кулына җылы су салынган комган күтәреп, Фатыйма күренде. Икенче кулында зур сары табак иде. Күрәсең, аларның сөйләшүен дә ишеткән...

Ул комганны кар өстенә утыртып, кул сөртергә дигән тастымалын айгыр түшкәсен асарга әзерләгән киштәнең ботагына элде дә, җаен туры китереп, Хәмит янына килде. Фатыйманың йөзе гадәттәгечә түгел иде, тавышы да йомшак, үзен беренче көнне кияү куенына керергә әзерләнгән яшь бичә кебек тота, оялчан, кыюсыз. Бит очлары — салкыннан түгел, җылы өйдән генә чыгып килеше бит — алсуланган, күзләре утлы күмер кебек яна.

«Хатын-кызның холкы юк дип әйтмәс идем, бар аларның холкы, тик ул көн саен үзгәреп кенә тора», — дигән бер шагыйрь. Фатыйманың да моңарчы ала-колалы чуар холкы бүген үзгәргән, йомшарган, үзе тыйнак кына бер мөлаем хатынга әверелгән дә куйган!.. «Хәерлегә булсын!» — дип шомланып уйлады Хәмит. Хәер, вәсвәсәсе юкка булган, Фатыйманың кияү балакайга үтенече бар икән.

— Хәмит, дим, энем-җаным, кеше күрмәгәндә шыпырт кына ат җомыркасын менә шушы табакка салырсың әле, пожалысты!

Тегесе, аптырап, күзләрен шарландырды:

— Ә-ә?..

Фатыйманың тавышы сүнеп бетә язды.

— Беләсең бит инде, баҗаеңа, баҗаеңа... — диде ул, ярым пышылдауга күчеп. — Пешереп ашатмакчы булганыем... Чыбыркысы бит...

Хәмитнең аптырау-гаҗәпләнүдән оешып каткан йөзе яктырып китте.

— Була ул! Айн момент!

Кичен Фатыйма сугымчыларны, авылдагы якын-ерак туган-тумачасын, күршеләрен кунакка чакырды. Сыйландылар, бик күңелле утырдылар. Төнгә чаклы дәвам итте бәйрәм. «Ат чалу шәп нәрсә икән!» — дип уйлады Хәмит кияү. Өйләренә төн уртасында гына кайтып яттылар. Авыл күгендәге ялгыз ай аларны капка төбенә кадәр озата барды. «Айның туган-тумачасы да юк. Безнең кебек кунакка да йөри алмый, бахыр...» Башына әллә ниткән фәлсәфи уйлар килә. Хатын белән тору зур тормыш мәктәбе ул, ир-ат шул мәктәптә гап-гади бер укучы гына. Әйтелеп бетмәгән бу, фикер китек әлегә. Өстәргә кирәк моңа: «Ул мәктәптә хатын-кыз да укый. Ир — арткы партада, хатын иң алда утыра».

Хәмит, колак төбендә безелдәгән черкине кугандай итеп селтәнде дә: «Нәрсә, фәйләсуфланган булам соң әле! Вакытымыни!» — дип, үз-үзен җиңелчә генә шелтәләп алганнан соң, шартлатып, өйалды ишеген бикләп куйды.

Хатыны инде юрган астына ук чумарга өлгергән. Кич буе кешесез торгач, өй эче суына төшкән: күлмәкне салуга чытайтып җибәрде. Ул, киемнәрен аннан-моннан гына урындык өстенә өеп, тизрәк юрган астына... хатынының җылы кочагына ашыкты.

Тәрәзәдән өй эченә үтеп кергән ялгыз ай күпме генә тырышып күзәтсә дә, караваттагы икенче кешене һич кенә дә эзләп таба алмады, кат-кат җентекләп исәпләсә-санаса да, очына чыгарлык түгел, юрган астында бер генә кеше ятадыр сыман иде. Хисап дигән фәнне каян белсен инде ул мескен ай! Санаган була тагын...

Иртәгесен кибет артында баҗасы белән күрешкәч, тегесе, барлык шартын туры китереп, ат ите кысылган саргылт тешләрендә сынык шырпы белән казына-чокына:

— Ну, ничек суң? — дип куйды.

Үзе чабатадай авызын тагын да җәя төшкән, куе сары кашлары арасына яшерелгән бәләкәй күзләре нинди дер сер белгәндәй тәмам кысылып беткән. Ут чыбыгында тезелешеп утырган чыпчыкларның һәммәсен берьюлы баҗасының авызына җыеп тутырасы килде Хәмитнең — чупләнсеннәр иде рәхәтләнеп. Сүзен әйткәндә дә шырпысын теш арасыннан алып тора алмый, ичмаса.

— Нәрсә, ничек суң?

Сары каш астындагы күзләр урынында ике нечкә сызык кына калды, алар тагын да озынайдылар һәм колакка тиклем сузылып, нәкъ шул урыныннан бу баш бүреге-ние белән кырт киселеп төшәр күк тоелды. Киселер, пычагым! Баҗа кеше әнә рәхәтләнеп ыржая. Ә нигә дип ыржая соң әле? Ул һаман аңламый, яңа капкага кайтып кергән сарык бәрәнедәй тик аптырап карап тора. Баҗасының карт алаша ите кебек кызыл йөзендә баягы серле-сәер тантана ничек тиз кабынган булса, шулай ук сүрелде дә; шырпы сыныгын чиртеп җибәреп, башын чайкап куйды.

— У-у-у! Фатыйма апагыз... ат күкәен генә түгел... хәленнән килсә... Бертуган сеңлемнең кияве дип тормасые!..

Баҗалар тиз аңлаштылар, чөнки Хәмит тә аңа кичәге серне чишеп ташлады. Әлбәттә, бу хәлгә баҗаларның бик тә ачулары килде. Гарьләнделәр, хурландылар. Икесе дә чыгырларыннан чыктылар. Әмма күтәрелеп бәрелмәделәр, икесе ике якка — өйләренә ашыктылар.

Кайткач та, баҗасының лапаста маллар карап йөргән Фатыйматтәйне шунда ук салам чүмәләсе өстенә төртеп екканын Хәмит баҗа күрмәде, әлбәттә. Моңа кикриге өшесә дә, әле бик гаярь булган кызыл читекле әтәч кенә шаһит булды. Әмма бу хакта ул кунакчада бөрешеп утырган тавыкларына да сөйләмәде. Әтәч кенә булса да, сер тота белә икән тагын үзе...

Хәмит баҗа нишләде дисезме? Иң башта урам капкасын иңсәсе белән генә төртеп ачты, аннары тибеп япты да ишегалдына аяк басуга: «Фәгыйлә! Ананңы!..» — дип кычкырмакчы, аны үз янына чакырып чәчеп-туздырып ташламакчы иде, дыңк иттереп капка ябылган тавыш ис-һушына китерде бугай, бер мәлгә туктап калды: үзе еш-еш сулый, буылган кеше кебек әледән-әле изүләрен тарткалый. Беравыктан суына төште. Шулай итми нишләсен, ул хәтта хатынына нәрсә дип әйтергә кирәклеген дә, башлап ни дип авыз ачасын да белми, белү генә түгел, башына да китерә алмый. Чарасызлыктан интегүе әллә каян күренеп тора. Шулай шул, апаң миңа айгыр җомыркасы кыздырып ашаткан, дип әйтеп булмый бит инде!..

Дуамалланып кайтып килүче ирен Фәгыйлә тәрәзәдән үк күреп, болдырга чыкты. Әнә шулай каршысына чыгып басуы белән Хәмитне «аяктан екты» да инде. Әүвәл тез аслары хәлсезләнеп, аннары теле көрмәкләнде — сүзен әйтә алмас булды. Яшь хатынның иннек-кершән белән каешланмаган, табигый төсен җуярга өлгермәгән ак, чиста йөзе, аптыраулы гөнаһсыз коңгырт күзләре Хәмитне каушатты.

— Хәми-и-ит! Ни булды-ы? — диде яшь хатын, чак кына сузып.

Тавышының мөлаемлылыгы, күңелгә ятышлылыгы ирне икенче мәртәбә җиргә чүктерде. Ләкин җанындагы үпкә-ачу алай гына басылырлык түгел иде, һай, түгел иде шул.

— Фатыймаң бүтән монда аяк басмаячак!

Хәмитнең кызган күкрәгеннән әнә шул җөмлә генә сытылып чыкты.

Кем әйтмешли, хатын-кыз ир-аттан акыллырак, чөнки алар азрак белә, ә күбрәк аңлый. Фәгыйлә дә иренә каршы капылт кына сугылып бәрелмәде, сәбәбен дә сорашмады — апасы белән ире арасында игълан ителмәгән сугыш барганын күреп тора, ләкин аңа һич кенә дә игътибар итми, бу аяк астында буталып йөргән вак-төяк ызгышлар дип кенә уйлый иде. Шулай да ул бу юлы:

— Нигә? Тагын нәрсә булды инде? — дип сорап куйды.

Мондый сорау һич кенә дә кирәкми иде Хәмиткә. Нәрсә дип җавап бирсен соң ул аңа? «Ярар» дип мыгырданды ул авыз эченнән генә һәм лапас алдына «кикрикүк!» дип аваз салган ак әтәчкә хатынының көтү куа торган юан таягын алып тондырды.

* * *

Ә бүген алар аерылышалар. Фәгыйлә район үзәгенә гариза илтә китте. Судка икесе барырга тиешләр иде дә бит... Ул качып калды, кузгалам дигәндә машинадан сикереп төште. Хатын-кыз алай сикереп йөри алмый бит. Хәмит төшеп калгач, яшь хатынның ачуы отыры кузгалган иде. Юл шактый сикәлтәле, сөт бидоннары төягән машина әрҗәсендә дөбер-шатыр сикерә торгач, тынычланды тагын үзе.

Дөресен генә әйткәндә, хатын белән аерылышу җиңел эш түгел икән. Хәмитнең җаны уйный башлады. Шуны басар өчен диптер инде, ул кибеттән аракы алып кайтырга уйлады.

Аракы — арыш мае,
Эч әле, карышмале.
Бушат калын кесәне,
Җанга дәва булале,
Әй, аракы, аракы...

Ул, каяндыр ишеткән әлеге такмакны көйләп, урамга чыкты. Баш комбайн кебек эшли, җан уйнаклый, күңел әсәренә. «Усад аракысы усал хатыннан яхшырак!» — дип сөйләнде ул үзалдына. Уйлап тапкан шәпкә әлеге тапкыр җөмләсе бик акыллы, үткен булып тоелса да, кибет янына якынлашкан саен, ул бу сүзләрнең үзенә һәм хатынына бик үк туры килеп бетмәгәнлеген чамалады. Усал түгел бит аның хатыны. Тик нигә аерылышырга җыенганнарын аңлатып кына бирә алмый ул. Беркөнне, — ат суйганнан соң атна да узмагандыр.

— Фатыйма килеп киткән, Хәмит шуңа дулады. «Сезнең нәсел белән араны өзәм!» — дип җикеренде ул хатынына. «Өзәм!» — «Өз!» И шуннан бетте-китте, вәссәлам!..

Кибет алдында җигүле ат тора. Ат хәтта бәйләнмәгән дә, тезгене чишелгән, ул, башын төрле якка йөртә-йөртә, кар өстеннән азык эзләгәндәй итә, борыны үз нәҗесенә төртелгәч, чирканып, кинәт башын күтәрә, арткарак чигенә. Аннары кибет алдындагы рәшәткә башына таба сузыла. Кимереп алырга исәбе. Ул шатыр-шотыр агач кимерергә керешкәч, кайдадыр чәң-чәң эт өргәне ишетелде. Хәмит шуннан соң гына чанадагы салам арасыннан этнең башын күреп алды. Колхоз электригы Ярулла абзый кибеткә тукталган икән. Бар тирә-юнь белә: Ярулла абзый дөм исерек хәлдә чанасында йокласа да, нинди генә буранда яки ерак юлда калмасыннар — бу кызгылт ат

белән Бурзай кушаматлы нечкә сыйраклы чәңгелдек эт хуҗа кешене капка төбенә хәтле алып кайтып җиткерәчәкләр.

Кибет эченнән тавыш-гауга ишетелә. Нindidер шәп тауар кайтып, шуның өчен ызгышалар кебек. Баксаң, анда кибетче Солтан кызы, Ярулла абзый белән хатыны Мөштифәдән гайре эт тә юк. Мөштифә уң кулындагы бер чәки аракыны баш өстенә күтәргән, икенчесе белән үзенә ташланырга әзер торган Яруллага кизәнә.

— Тагын бер генә адым атлап кара менә! Атлап кына кара, бәрәм дә ватам! Ике дә уйлап тормыйм менә!

Ярулла абзый бик ярсулы, шулай да үзен тыеп тора, күрәсең, хатынының холкын күптән өйрәнеп бетергән: чәкине ваттырасы, әрәм иттерәсе, зәмзәм суыннан колак кагасы килми. Солтан кызы, кайсысын якларга да белмичә, аптырап, үлчәү артына поскан да шуннан тыныч кына күзәтә.

— Ватып кына кара менә! Бакча җимеше түгел ул сиңа, акча җимеше!

— Бер генә адым атлап кара менә! Ике дә уйламыйм, белдеңме!

Солтан кызы, яңа гына кияүгә чыгып, ир куенында берәр атна чамасы гына төн уздырган бала, кайсысын якларга да белми. Дөресрәге, бу мизгелләрдә болар урынына ире белән үзен куеп карап, шуннан нәтиҗә чыгарырга азаплана бугай. Ләкин бернинди дә нәтиҗә чыкмый. Чөнки тормыш тәҗрибәсе бик сай әле, чыпчык тезеннән генә. «Вата бит хәзер Мөштифә апа! Батырлыгы җитмәячәк! Кара Ярулла абзыйның кыяфәтен, котырган үгез кебек!» Кызның уенда әнә шундый ике фикер тарткалаша-ярыша.

— Ватып кына кара менә! Мин сине бүген үк аерып җибәрәм!

Һай, Ярулла абзый! Шушы сүзеңне әйтмәгән булсаңчы, хатын-кызның холкын белмәгән кеше кебек! «Аһ, син шулаймы! Аерасыңмы! Сиңа аракы кадерлерәкме?!» Чәки ишек төбендә торган ябык кильки мичкәсе кырына очты һәм чык иткән тавыш кына ишетелде. Мөштифә, үз кыюлыгыннан үзе дә коелып төшеп, аптырап-югалып калды һәм котырган аю кебек алпан-тилпән өстенә килә башлаган иреннән качып, ишеккә йөгерде. Аның артыннан — Ярулла абзый...

Кибет эче тынып калды, урамда ярсып-ярсып эт өргәне генә ишетелде. Солтан кызы да, Хәмит тә җиңел сулап куйдылар. Икесе дә белә: чәки өчен генә аерылыша торган гаилә түгел инде болар. Өйгә кайтуга, Ярулла абзыйны әзмәвердәй ике малае караватка бәйләп салачак, ә иртәгесен Мөштифә Ярулласына — махмырдан интегеп яткан иренә, сөтле аш пешереп, аны кашыклап үзе ашатачак. Авылда белмәгән кеше юк: электрик Ярулланың сөтле аштан соң эче йомшарып, махмыры да юып алгандай юкка чыга. Ә кичен алар атка утырып, парлашып, күрше авылга һинд киносы карарга барачаклар. Моның шулай буласын авыл халкы белеп тора. Чөнки беренче мәртәбә генә түгел. Өстәвенә Ярулла абзыйның олы кызы килеп, кибет идәнен дә юып-себереп китәчәк әле. Төштән соң. Моны кибетче Солтан кызы да белә. Шуңа күрә хәзергесе вакытта почмакта таралып яткан шешә ватыкларына тамчы да исе китми аның. Кибет эченә таралып өлгергән аракы исе генә күңелне болгатып, күзләрне әчеттерә.

Хәмит тә, Солтан кызы да, тегеләр чыгып киткәч, бу хакта бер сүз дә алышмадылар. Кибет түренә нәрсәдер алып кайтып өйгәннәр. Хәмит, аракы дип авыз ачасы урынга, ияге белән шунда таба ымлады.

— Әллә мебель апкайттыңмы?

Әлеге сүзләрдән Солтан кызы җанланып китте.

— Ие шул, Хәмит абый, сафа ул. Двухспальный караоват. Агачтан, мендәрләре дә бик йомшак.

Хәмит әүвәл караватның бар җирен җентекләп тикшереп чыкты, аннан соң кибетчегә күтәрелеп карады. Аның ни әйткәнен дә көтмәстән, Солтан кызы кызу-кызу тезеп китте:

— Без үзебез дә районнан яңа гына кайттык әле. Сиңа хәбәр салырга өлгермәгәнием. Фәгыйлә апа белән районда күрешкәниек. Бүлнискә кереп барадырие. Күренергә килдем, ди. Хәмит абыеңа әйттер, карават безгә бик кирәк, дигән ие. Менә хәзер берәрсен сиңа йөгертергә дип торадырыем.

— Ие шул, ие, — дип мыгырданды Хәмит. — Алам мин моны. Ошады бу. Карават кирәк безгә. Бик кирәк...

## МИЧ БАШЫНДА КҮРГӘН ТӨШ

Гыйлаҗи карт юрган астыннан башын чыгарды да, өйдә кеше-кара юклыгын белергә теләгәндәй, әүвәл беркавым тынын кысып, кымшанмыйча гына ятты. Аннары стенага ук елышкан карчыгының аркасына сак кына терсәге белән төртте. Карчык йоклый иде, ахрысы, тавыш бирмәде.

— Син дим, әй! — Карчыгы, ризасызлык белдергәндәй, кыймылдап куйды. — Юл төше күрмәдеңме бүген?

Йокысыннан айнып җитә алмаган карчык төшенеп җитмәде.

— Әү?

— Юл төше күрмәдеңме, дим?

— Нәрсә дидең?

Картның кәефе кырылды, бүтән бер сүз дә әйтмичә, карчыгына аркасы белән борылды да мич янәшәсендәге яшел сандыкка карап ята башлады.

— Нәрсә дидең, Гыйлаҗи?

— Тозлаган кәбестә, дидем.

Карчык монысын да ишетмәде. Әмма башка кайтарып сорамады.

Картның күңеле тыныч түгел иде. Таң алдыннан күргән шомлы төштән соң күңеленә шиккурку кереп кунаклады. Кичтән каладагы оныкларының берәрсе кайтмасмы дип, юл төше күрү өмете белән белгәннәрен дә укып ятканнар иде. Тик таң алдыннан хәерсез төш күрде Гыйлаҗи карт.

Имеш, карчыгы белән икәүләшеп, ямь-яшел урман аланында йөриләр икән. Аландагы җиләкнең күплеге! Учлап сипкән диярсең. Кып-кызыл булып утыралар. Икесенең дә кулында бик зур кәрҗиннәр, имеш. Кәрҗиннәре тулган икән инде. Җыйган җиләкләрен ашап баралар, имеш. Менә берзаманны алан читендәге корыган усак башына козгын килеп утырды да адәм теле белем сөйләшергә кереште.

— Кәрҗиннәрегез тулган бит инде, җитәр сезгә, китегез моннан, — ди козгын. Козгынның кисәтүе күңелләренә курку салса да, җиләкле аланны калдырып китәселәре килми, имеш.

— Юк, — ди алар икесе беравыздан козгынга. — Без ашап туймадык әле. Ник куасың безне?!

Козгын:

— Китегез, кит моннан, — дип, канатларын салмак кына җилпи-җилпи күздән югала.

Әнә шундый шомлы төш керде Гыйлаҗи картка. Имеш, төштә дә имеш-мимеш башланган, имеш...

Туксан өч яшьләрен тутырып килә торган карт белән карчыкның төп урыннары түр яктагы мич артында. Үзләре алар аны «мич арты» дип тормыйча, «мич башы» дип кенә атыйлар. Мич арты хәйран гына иркен булып, анда йомшак матраслы агач караватт кереп кунаклаган. Шуның янына ук Гыйлаҗи карт белән карчыкның яшел сандыгы да сыйган. Мич башында җиз комган кукраеп утыра.

Картларны мич артына малайлары да, киленнәре дә куып кертмәде. Элегрәк алар ишле иде. Кызлары Зөләйха да калага китеп урнашмаган, оныклары Ринат белән Тәслимә дә бәләкәй иде әле. Шул чакта ук картлар үз караватларын мич артына кертеп куйдылар.

Беркавымнан соң Нәфисә карчык та торып утырды.

— Бая нәрсә дидең әле? — дип сорады ул картыннан. Кырын ятканлыктан Гыйлаҗи картның әйбәт ишетә торган уң колагы мендәр белән томаланган иде. Ул, миңа әйтүеңме дигәндәй, башын чак кына күтәрә төшеп, карчыгына карады.

— Бая нидер әйттең, ахры, ишетмәдем.

— Юл төше күрмәдеңме дигән идем.

— Ә-ә. Җук шул. Төш кермәде бүген.

— Алай икән.

— Син күрмәгәнсеңдер бит?

Таң атканда күргән төшен сөйләп бирергә теле бик кычытса да, карт:

— Җук, — дип кенә җавап бирде. Карчыгының күңеленә дә шик-шөбһә саласы килмәде.

Икесе дә менә-менә туксан өчне тутырабыз дип торсалар да, әлегә алар, киленнәре әйтмешли, җен кебек таза-саулар иде. Тамакларына әйбәт ашыйлар, аякларында әйбәт йөриләр, авырусыктауның ни икәнен дә белмиләр. Тик хәзер карчыкның күзләре начаррак күрә башлады, аның каравы колаклары бик яхшы ишетә. Ә картның, киресенчә, күзләре әйбәт күрә, колаклары гына катырак. Күзлек тә кимичә энәгә җеп саплый, көн саен стенадагы календарь битен ертып укып бара. Ә оныгы гәзитне дә күзлексез таный алмый.

Өй ишеге ачылып ябылды. Кухня якта нәрсәдер дөбердәп идәнгә төште. Картларның аяк очында бөгәрләнеп яткан йонлач мәче, ялт кына башын күтәреп карады да, караваттан сикереп төшеп, кухня якка чыгып китте.

Киленнәре Галимә фермадан кайтты. Кем беләндер сөйләшәләр, аңа ияреп өйгә тагын бер хатын-кыз керде, ахрысы.

Карт, «синең колакларың үткенрәк, кем ул анда» дигәндәй, карчыгына карады. Карчык беркавым тыңлап торды да:

— Күрше Нәсимә шикелле, — диде. Үзе кухня яктан килгән тавышларга колак салды.

— Сезнең картлар тормаган әле, ахры? — дип сорый күрше хатыны.

— Иртә бит әле, эшкә барасылары юк, — ди аңа каршы киленнәре.

— Карале, Галимә, аларның кайсысы олырак соң? Гыйлаҗи бабаймы?

— Икесе дә бер елгылар.

— Туксанны узгандыр инде, име?

— Акрын, үзләре ишетмәсеннәр. Безнең әбинең колагы бик сизгер. Быел язда икесенә дә туксан өч тула инде.

— Вәт син, ә! Ходай кайбер кешегә гомерне бирә шул, җәлләми. Мич башында ятсалар яталар, яши бирәләр. Без менә пенсия яшенә дә җитә алмабыз әле, хәзер дә ыңгыр-шыңгыр гына йөрибез.

— И, алдагысын кем белгән инде аның. Әлегесен сау булсаң, шунысына канәгать.

— Әйтмә инде, әйтмә, — дип, киленнең сүзләрен җөпли күрше хатыны.

Инде торып киенергә ниятләгән карчык, бу сөйләшүне ишеткәч, башын янә ястыкка төртте. Әмма нәрсә ишеткәнен картына сөйләмәде.

Карчыгы кире ятса да, Гыйлаҗи карт кузгалырга булды. Таң алдыннан күргән төш сөреме әле һаман да зиһенен томалап тора. «Озакламый Газраил дигәннәре дә килеп җитәр микәнни инде?!» — дип пышылдады карт үзалдына. Аны шулчак күптәнге хәерсез уйлары бимазалый башлады. «Әүвәл кемне алып китәрсең икән син, ә? Кайсыбызның чираты икән? Минекеме, Нәфисәнекеме? Икебезгә берьюлы килмәссең бит инде?! Җук. Алай булмый. Башта беребезне. Минеме, Нәфисәнеме?..» Оекбашларын киеп утырган карт, карчыгын мәңгегә күзләре йомылган сурәттә күз алдына китереп, әллә нишләп китте. «Җук. Башта мине алып китәрсең...» — дип авыр сулады. Икенче оекбашын кигәндә аягында бүртеп торган зәңгәр кан тамырларын күреп, бу юлы үз-үзен кызганып куйды. «Мин белмим. Башта кемне икәнен үзең карарсың шунда...»

Карт, бу күңелсез уйлардан тизрәк котылырга теләпме, җәһәт кенә аягына торып басты. Аннары карчыгына таба борылды.

— Өйлә җитә инде, ятма!

Картлар торуга киленнәре табын әзерләп куйган иде. Нәфисә карчык мич башыннан һинд чәе дә ала чыкты. Аларның икесенә генә аерым чәйнекләре бар, киленнәре әзерләгән грузин чәен өнәмичә, үз чәйнекләренә һиндныкын салып пешерәләр. Ә һинд чәен каладан кызлары ташый һәм әрәм-шәрәм итмичә үзләре өчен генә тотарга куша.

Карт беравык карчыгының чәй әзерләгәнен күзәтеп утырды да боерулы тавыш белән:

— Бу чәйнектән киленгә дә яса! — диде. Карчык килен ягына күз төшереп алды да:

— Ясыйм, ник ясамыйм ди, әйдә, килен, утыр, — диде.

— Юк, мин әле эштән кайткач кына эчтем, — дип чакыруны кире какты килен.

Картлар тирләп-пешеп бик озак чәй эчтеләр. Гыйлаҗи карт, чәй янында төшен сөйләргә дип, тагы бер мәртәбә талпынган иде, тик бу юлы да тыелып калды.

Гадәттә, иртәнге чәйне эчкәндә, карт үзе башкарырга тиешле көндәлек эшләрен уеннан барлап куйган була иде. Хәзер менә туксан ягына чыкканнан бирле бу гадәте бетте. Нинди генә эшкә килеп тотынмасын, килене яки улы Гомәр шундук каршы төшәләр: «Әти, кирәкми, азапланма, ял ит, без үзебез», — диләр. Элек ул кыш көне булса, иртә-кич мал-туар астын җыештырып чыгара, мичкә яга иде. Җәй икән, көтү куа, ишегалдын себерә, ян бакчадагы яшелчәләргә су сибә иде. Көндезләрен лапастагы остаханәсендә маташа. Өстәвенә фермага килененә бозаулар карашырга йөрде. Хәзер аны эш эшләүдән тыялар. Каладагы кызы кайтып күрсә, буранның тагын да көчлерәге чыга. Карт чарасыз, аларга каршы бер сүз дә әйтә алмый. «Әти, ял ит! Үз вакытында эшләмәгән түгел, эшләгәнсең. Хәзер ял ит. Авыр эш эшләп өзлегеп китә күрмә!..» Һәрвакыт менә шундый сүзләр. Әйттеләрме — бетте. Авызыңны да ача алмыйсың.

Эшсезлектән тинтерәп аптырагач, мәктәп чакыруы буенча укучылар белән очрашуга да йөреп карады ул. Революция еллары турында, гражданнар сугышы хакында сөйләттеләр. Өченче

баруында колхозлашу чоры турында сөйләвен үтенгәннәр иде. Ләкин ул өстәл артына килеп утыруга, четеркән кебек бик тере кыз сикереп торды да:

— Бабай, озак итеп яшәү өчен нишләргә кирәк? — дип сорау бирде.

Гыйлаҗи карт аптырап калды. Укытучы кыз аңа ярдәм итәргә теләп:

— Озак яшәүнең сере нәрсәдә дип сорыйлар, Гыйлаҗи бабай. Мәсәлән, озак яшәү өчен нәрсә эшләргә, нәрсәдән башларга кирәк, — дип төшендереп бирергә тырышты.

Карт бер кулы белән өстәл өстен сыпырып куйды, аннары теләмичә генә:

— Белмим инде, нишләргә кирәк икән соң? — диде. Укучылар, дәррәү кубып, кыен хәлдә калган картка ярдәм кулы суздылар.

— Чаңгыда йөрергә кирәктер име, бабай?

— Җәй көне күп итеп су коенырга, футбол уйнарга, йөгерергә кирәктер?!

Карт тамагын кырды:

— Мич башында ятарга кирәк!

Бу сәер сүзләрдән соң барысы да шып туктады. Күрделәр: картның кәефе кырылган иде. Ул акрын гына урыныннан купты да ишеккә таба атлады. Чыгып китәр алдыннан борылып:

— Адәм баласына гомерне Аллаһы Тәгалә бирә. Дөньяда кемнең күпме яшисе аның кулында. Ходай Тәгалә кодрәтеннән бер карыш та узып булмый, — диде.

Шушы хәлдән соң, педсовет җыеп, әлеге очрашуны оештырган укытучы кызның тетмәсен теттеләр. Совет мәктәбен мәчеткә әйләндергәнсең, диделәр. Балаларның аңына дин агуы салуда гаепләделәр, һәм, билгеле инде, Гыйлаҗи картны да мәктәпкә очрашуга чакырырга теләүчеләр бүтән булмады. Картның тормышы янә элеккеге күңелсез эзенә төште. Моңа иң сөенгән кеше Нәфисә карчык булды, йөрмәссең, өйдә генә утырырсың, ичмасам, миңа иптәш булырсың дип уйлады ул.

...Менә бүген дә карт, иртәнге чәйне эчкәннән соң, стена календаренең битен ертып алып укыды да яңадан мич артына — үз урынына кереп китте. Бераздан янына карчыгы да керде. Нәфисә карчык, табынны җыештырып, савыт-саба юыйм дигән иде, килене шундук:

— Үзем, үзем, әнкәй, ял ит, борчылма! — дип каршы төште.

Картлар бер-берсенә бер авыз сүз дә катмыйча түшәккә кырын яттылар. Бу рәвешле яту да туйдырды аларны беркавымнан. Иң әүвәл карт торып китте. Эче пошканнан гына телевизорны кабызды. Үзе аңа күз дә салмыйча тәрәзә янына килеп баскан булды. Бераздан карчыгы да мич артыннан чыкты. Ул берара идән уртасында аптырап торды да:

— Чәй куйыйммы, тамагың кипмәдеме? — дип картына дәште.

— Эчтек кенә бит әле, — диде карт, коры гына. Бүген кергән төше турында уйланып тора иде. «Юрап азапланасы да юк! Ул хәерсез козгынның кая куганлыгы мәгълүм!..» — дип пышылдады карт үзалдына һәм, бик тә күңелсезләнеп, янә мич артына кереп китте. Карчыгы аңа иярде.

— Кул эше тотар иең, ичмасам, — диде аңа карты.

— Җук бит, бер эш җук, — дип куйды карчык офтанып.

Элек оекбашлар, бияләйләр бәйли иде ул. Хәзер исә килене аннан бернәрсә дә эшләттерми. Чөнки каладагы кызлары кайткан саен, әти-әнисенең ни белән булса да мәшгуль икәнен күреп, тавыш чыгара, карт белән карчыкны нигә үзегезгә хезмәт иттерәсез, ди. Һәм әти-әнисен кат-кат кисәтә, мең дә беренче кат колакларына тукый:

— Ял итегез. Берүк аркылыны буйга да алып салмагыз.

Менә хәзер карт белән карчык мич башында гына гомер кичерә. Сәгать унны суккач, Гыйлаҗи карт, мич артыннан чыгып, радионы җибәрде. Әмма озак эшләтмәде, сүндерде дә тагын тәрәзә каршына килеп басты. «Теге төшне Нәфисәгә дә сөйләргә кирәк, ахры, — дип уйлады ул. — Озакламый килеп җитәчәген ул да белеп торсын. Кинәт килсә, бик авыр булыр. Болай әзерләнеп торасың!»

Карт шундый уйлар белән мич артына атлады. Түшәктә кырын ята торгач, карчыгы изрәп йокыга киткән икән. Карт, аның шул рәвешле йоклап ятуын күреп, каушап төште. «Әүвәл сиңа киләләрме әллә, карчык?» — дип, иреннәрен кыймылдатты. Йөзенә текәлебрәк карагач, тигез итеп тын алуын күреп, бераз тынычлангандай булды.

Карт бермәл уйланып торды да, аннары нидер исенә төшкәндәй, җил-җил атлап кухняга чыгып китте. Киленнәре өйләгә ашарга әзерләп йөри иде.

— Килен, — диде карт, ишек бусагасында басып торган килеш. Бәрәңге әрчегән килене аңа таба башын борды да:

— Әү, эткәй? — диде. Карт тамагын кырды һәм: «Килен, бүген мин дә фермага бозауларыңны карашырга барам», — димәкче иде, әмма тел очына башка сүзләр килеп:

— Эшеңдә бик авыр түгелме соң?— дип сорады.

— Юк, эткәй, иялэнгэн эш бит инде. Нишләп алай дисең?

«Туйдым мич башында ятудан, сиңа барып булышасым килә», — диярге теләгән иде, авызыннан икенче сүзләр чыкты:

— Болай гына соравым.

— Хәзер азыкны да китереп бирәләр бит. Ташып азапланасы юк. Һәрберсенә тигезләп бүлеп саласың да, асларын тазартасың да шуның белән эше бетә.

— Ә-ә-ә, алай икән.

Карт киенеп ишегалдына чыкты. Әүвәл капкадан башын тыгып урамга күз салмакчы иде. Бу уеннан тыелып калды. Моннан бер ай чамасы элек урам аша гына яшәгән Хәмитләрнең каладагы малайлары исерек килеш машинага тапталып үлде. Мәетне авылга алып кайткач, соңгы юлга озатырга дип, Гыйлаҗи карт белән Нәфисә карчык та керделәр. Тик өй бусагасыннан ук керергә өлгермәделәр, капканы ачуга, өйалдында хуҗа хатынының кычкыра-кычкыра елавын ишетеп, икесе дә шып туктап калды. Хуҗа хатын сөйләнә-сөйләнә елый иде.

— Әй Раббым! Нинди гөнаһларым өчен тартып алдың миннән газиз балакаемны! Нишләп рәхмәтең бар кешегә дә тигез түгел суң синең, Ходаем! Әле яши генә башлаган ие бит! Җан кирәк булса, әнә күршедә генә карт белән карчык яшиләр бит, инде йөзгә җитәләр, минем балага тигәнче, Газраилеңне шунда җибәрсәң ни булган суң! Ай-й-ай!

Моны ишетеп, йөзләреннән кан качкан карт белән карчык аптырап бер-берсенә караштылар да аннары капканы шапылдатып ябып чыгып киттеләр, һәм шуннан соң ике атна рәттән мич башыннан төшмәделәр.

Гыйлаҗи карт, бүген шуны исенә төшереп, капкага якын барырга, урамда күренергә җөрьәт итмәде. Шашкан күрше хатынының күзенә чалынасы килми иде.

Туп-туры лапаска таба китте ул, остаханәсен ачып керде. Остаханә эчендә тәртип иде. Һәр нәрсә үз урынында. Тик улы Гомәр генә пычкысын тоткан, ахры, карт куйган җирдә түгел, башка урында эленеп тора. «Һы, ташлап калдырмаган, элеп куйган, маладчина», — дип сөенде карт.

Почмакта күптәннән ясый башлаган китап шкафы тора. Эше беткән дә диярлек инде. Бер ишеген утыртасы да, икенчесен ясап куясы гына. Аннары яхшылап чистартып, лак белән каплап чык та өйнең түренә керт тә утырт! Картның үз эше үзенә дә ошап китте. Моны ясап бетерсә, студент оныгы сөенәчәк инде. «Китаплар теләсә кайда ауный, бабакай, шкаф сыман нәрсә ясап бирче!» — дип, байтактан әйтеп йөри. Керешкән иде дә, Зөләйхасы кайтып, Гомәрне пыр туздырып сүкте. «Ник этине җәфалыйсың?! Теләсәң, мин сиңа кибеттән шкафны унны алып чыгып бирәм», — дип ярсыды кызы. Шуннан бирле Гомәр остаханәгә этисен якын китермәде, берара ишегенә йозак ук элеп тотты.

«Аңламыйлар шул! — дип, чын күңелдән үпкәләде карт. — Акча әрәм итеп кибеттән урындык ташыйлар, әллә нинди катыргы шкафлар алып кайталар. Мин тотынсам, менә дигәнен ясап бирәм бит, шыгырдап торган өр-яңа такталардан!..»

Хәзер менә аның элек ясаган шкафлары, урындыклары, өстәлләре лапаска яисә келәткә күчеп беттеләр. Өйдә карт үз куллары белән ясаган агач караватт кына мич артында калды. Аның да матрасын килене кибетнеке белән алыштырып куйды.

Гыйлаҗи карт, ишек яңагына сөялеп, беркавым почмактагы шкафына карап торды да, кырт кына кузгалып, такталар өеменә таба китте. Кызы Зөләйха үзе кайтып керсә дә, бу шкафны ясап бетерәчәк иде ул бүген. Аның монда эшләп ятканын килене генә күрмәсен. Зөләйха кебек ачулана да белмәс ул, Гомәр кебек коры гына итеп: «Әти, җитте, ташла балтаңны!» — дип тә әйтә алмас, бары: «Әй, эткәй, нишләвең инде бу?» — дия-дия чын күңелдән үпкәләячәк. Килененен бер дә үпкәләтәсе килми картның.

Нишләргә соң дигәндәй, карт әүвәл лапас уртасында басып уйланып торды, аннары остаханә ишегендәге асылмалы йозакны тартып алды да кызу-кызу өйгә таба китте һәм, өйалды ишеген акрын гына ябып, йозак элеп куйды. Аннан соң, бу эшеннән бик канәгать булып, кет-кет көлә-көлә лапаска атлады. Остаханәгә кереп шкафның әзер ишеген утыртты. Икенче ишекне ясарга җыенып йөргәндә, килене белән бергә бозаулар караучы тау башы Суфия капкадан башын тыгып кычкырды.

Галимә килененең фермага барыр вакыты җиткән иде. Карт балтасын бүкәнгә кадап куйды да абына-сөртенә капкага йөгерде:

— Чү! Кычкырма! Хәзер!

— Галимә кайда суң, Гыйлаҗи бабай?

Карт, хатынның авызын капларга җыенгандай, бер кулын югары күтәрде.

— Чү, тавышланма, Суфия килен. Галимә билен каймыктырды. Эшкә бара алмый. Ята. Аның урынына үзем барам, әйдә, киттек.

Бу сүзләрдән соң хатын аны мыскыллап көләр дип уйлаган иде. Шундый мәсхәрәгә алдан ук каршы торырга әзерләнгәндәй, картның йөзе кызарып чыкты, борын тишекләре киңәйде. Ул сынын тагын да турайтыбрак басты...

Рәхмәт төшкере! Сүз әйтү түгел, йөзендә мыскыллы елмаю әсәре дә күренмәде. Хатын, Галимәнең хәлен сораштыра-сораштыра, урамга чыкты һәм Гыйлаҗи картка күтәрелеп карады да:

— Җен кебек әле үзең, Гыйлаҗи бабай! Күз тимәсен! — диде.

Бу сүзләрдән тагын да канатланыбрак киткән карт кет-кет көлә-көлә, аның артыннан иярде. Галимә белән Нәфисә карчыкның ишек дөбердәткәнен ул да, Суфия да ишетмәделәр. Нәкъ шул чакта авыл кырыендагы зират ягыннан козгын тавышы килгән сыман булды. Карт коелып төште, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. «Мич башыннан төшәсем калмаган икән лә!» дигән үкенечле уй шул мизгел эчендә миен бораулап узды. Ул, егылып китүдән курыккандай, ирексездән хатынның беләгенә тотынды һәм аннан: «Козгын тавышын син дә ишеттеңме?» — дип сорарга теләде. Картның бу хәрәкәтен үзенчә аңлаган хатын аны култыклап ук алды һәм яңгыравыклы тавышы белән:

— Әйдә суң, Гыйлаҗи бабай, урам буйлап бер подручкам барыйк әле! — дип, ихлас күңелдән рәхәтләнеп көлә башлады. Бу көлү козгын тавышын күмеп, каплап китте. Шул көлү картның шомланган йөрәгенә сары май булып ятты, буыннарына җегәр өстәгәндәй итте. Карт, гайрәтләнеп китеп, култыклашып барырга гына риза булмыйча, кулын хатынның биленә үк салырга ымсынган иде. Тирә-ягына күз ташлагач, бу уеннан тыелып калды. Рәт-рәт булып тезелгән йортларның тәрәзәләре, бик тә кызыксынып, бик тә бирелеп, урамны күзәтәләр иде. Тәрәзәләрдән уңайсызланды карт.

Аннары ул, хатынны чак кына узып, алгарак чыкты һәм әүвәл ялт кына зират ягына күз ташлап алды, шуннан соң, көлә-көлә, Суфияга бүген иртә белән күргән төшен сөйләргә кереште.

## АК БОЛЫТ КҮЛӘГӘСЕ

Хурлыгы!!! Җир тишегенә керерсең!.. Ире ниндидер бер кәнтәй белән типтерә икән!.. Бүген ишетте. Килеп әйттеләр. Гарьлегенә ничекләр итеп түзмәк кирәк.

Теленә шайтан төкерсен: бу хакта ахирәт хатыны җиткерде. Әле тагын, Фидаилең, уч төбендәге юеш сабын кисәге кебек, синнән шуып китеп бара, иртәме-соңмы ялгыз калачаксың, аның дилбегәсе, — кая дилбегә үк булсын! — дилбегәнең дә бер очы гына кулында әләгеп тора бит инде, ди!..

Һай, ахирәткәем! Бу хәбәрне ишеткәч, Тәслимә тол каласын уйлап елар дигән идеңме әллә! Кая ул елау! Әүвәл бик каты гарьләнде ул. «Мокыт! Бозау! Ни җитмәгән! Югыйсә бозауның да бозавы бит үзе!» — дип бәргәләнде.

Баксаң, Фидаил гади бозау гына түгел, аның ире уҗым бозавы да икән әле!

— Син үзең ут уйната торган хатын, үзең нәкъ карга баласы! — дип әрли-әрли иренең «уҗым»га йөрүен ахирәте Фәридә чиште. Хатын иң соңыннан белә диюләре хак икән...

Фәридә әллә сөенеп әйтә инде, әллә, — хәер, кем белсен, — кызганып, чын күңелдән җәлләп йөрүе инде — Тәслимә бу хәтлесен үк аңышып бетерә алмады. Ул чакта халәте ни булса да чамаларлык, аңларлык түгел иде. Аннан соң күңел дигәне дә икеле-сикеле әле. Бәлки, бу юк һәм буш сүз генәдер?! Дошман сүзедер?! Һәй, шулай гына булсачы! Шулай булмасамы! Әгәр дә мәгәр алай түгел икән, ул Фидаилне, ул Фидаилнеме?! Берәр җиреннән эләктереп, трамвай артына тагып җибәрәчәк!.. Тәслимәме, Тәслимә!..

Казан каласы зур кала. Трамвайлар алар яшәгән ун катлы йорт каршысыннан гына уза...

...Хыянәт шундый була микәнни ул? Бигрәк тә гарьлеге үтерә. Тәслимә өчен, — теләсә, көзге караңгы төннең күгенә учлап йолдыз сибә алырдай, күз карашы белән иртәнге томаннарны эретерлек чая һәм чибәр хатын өчен, — әйтеп һәм сөйләп бетерә алмаслык хурлык-гарьлек ләбаса бу!

Аннан соң... аннары ирләре хыянәт иткән хатыннар ни кыла да, алар нишли икән?

Берәүләр авыз ачып сүз дә әйтә алмыйлардыр: мышык-мышык елыйлар да елыйлардыр. Икенчеләре «бозык» ирнең битен тырнап бетерәләр, өйдә, балалары янында, кара тавыш чыгаралардыр. Кайсыберләре, бәлкем, гариза тотып, суд юлын таптыйлардыр...

Дөнья хәтта салават күпере кебек кенә дә түгел, дөнья күзендә мең төрле төс чагыла. Кемнең күңеле аны кай якка таба әйди — ул шулай эшли. Адәм баласының күңелендәге хисләр яр читләрен кимерә-кимерә бәргәләнеп аккан язгы ташу кебек. Акыл дигәнең исә шул ташу өстендә чайкалган йомычка кисәгенә генә әйләнеп кала андый чакта.

Әмма татар кызларына хас булмаган зәңгәр күзле, алтын бодай башагы кебек сары чәчле, тик тора белмәс тынгысыз җанлы Тәслимәбезнең холык-фигыле әле әйткән төрләрнең берсенә дә туры килми, ул кысаларга гына сыешып җитә алмый иде. Ул Тәслимә иде, үзенчә һәм башка иде. Алма кебек ун яшьлек малаеның әтисез калачагы хакында да уйламады. Фидаил белән ни газаплар кичерә-кичерә алган өч бүлмәле фатир да күзенә күренмәде. Күңелгә бары тик үч алырга кирәк дигән теләк кереп урнашты. Шуннан соң гына җаны тынычланып, күңеле урынына утырачак, бары шуннан соң гына уч төбендәге песнәктәй тыпырчынган җанкаена тынычлык иңәр төсле.

Алар Фидаил белән унбер ел бергә гомер кичерәләр. Яшь чактагы мәхәббәт дигән уртак һәм шактый ук кайнар хис-тойгылары, гадәти тормыш шаукымына кушылып китеп, бер-береңә күнегү, ияләнү шикеллерәк төшенчәләр кысасында калдылар шикелле. Бу — син, монысы — мин, менә уртак җимешебез — балабыз, болар безнең гаилә була инде. Яшибез шулай тыныч кына. Фатир да бар, эшкә дә йөрибез, үзенә күрә акчасын да алып торабыз. Бу — тормыш итү, бергә-бергә гомер кичү...

Чү! Тукта! Торып тор! Әле менә хәерсез бер теләк — үч алу теләге — күңеленең кай төшендәдер давыл кебек кузгалган әлеге хис хатынның башын чуалтып ташлады. Чү! Сабыр ит әле! Кешеләр арасында яши бит алар! Икесе генә карурманда түгел ич! Тәслимә үзе дә... Әйе, әйе, бергә эшләгән хезмәттәше Шамилне ул үзе дә якын итә бит. Кайчак, онытылып китеп, егетнең маңгай бөдрәләренә бармак очлары белән генә орынып аласы килеп куйган мизгелләре булмыймыни! Әлбәттә, ул үзен бик тиз кулга ала, ояла, кызара һәм үз-үзен әрли, талый башлый.

Ә бүген исә күзенә ак-кара күренми. Бүген күңелендә дәһшәтле давыл!..

* * *

Тузгытылган җанын тынычландыру өчен кимсетелгән хатын үч алуның берничә төрле юлын сайлады.

Шул ук ахирәте, шул ук Фәридә, ул ым кагуга, икенче көнне үк көндәшенең адресын китереп тоттырды. Адресны белүгә, Тәслимә уктай шундук атылыр төсле иде. Тагын Фәридә ярдәмгә килде.

— Кара бу кыяфәтеңне! Соңгы бер атнада җен хатынына охшап калдың! Әүвәл, парикмахерскийга барып, чәчеңне рәтләт! — дип, алтын киңәшен бирде.

Тәслимә шулай итте дә. Чәчләрен соңгы фасон белән кистерде, шуннан туп-туры көндәшенә юл алмакчы иде. Ләкин алай итмәде, әллә киселгән чәчләр муенына, тәненә кереп кунды, әллә инде батыр, кыю хатын эчтән шул рәвешле калтырана һәм күңелендәге хәерсез уй тынычлык бирми: аның тәне кычытырга кереште. Ул ашыгып кына өенә кире кайтты да, юыну бүлмәсенә кереп, анадан тума чишенеп ташлады. Көзге сукыр түгел, аның күзе очлы: хатын кайнар су агыза башлауга кием астыннан араланган матурлык көзге йөзендә чагылды, карашын иркәләде, аннары көзге-күз түзмәде, оялып, шәрә тәннән карашын алды — тирләп чыкты, пар белән капланды.

Хатын шкафтан кунакка йөри торган яңа киемнәрен алып киде, болай да килешле чәчләрен төзәтте һәм, затлы хушбуй сөртә-сөртә, көзге каршында әйләнгәләде дә өен бикләп чыгып китте.

Кая бара, нигә бара? Башында нинди уй-фикерләр хатынның?.. Хәер, бу вакытта җаны бераз тынычланган шикелле дә булган иде. Көзгегә дә зур рәхмәт: ул аңа: «Син бик гүзәл!» — диде бит...

Хатын әүвәл ире белән күзгә-күз карашып сөйләшергә дә уйлаган иде. Тик бу мескенләнү, горурлыгыңны өстерәлчек ир аяк астына салып таптау була бит! Юк!

Бүген ял көне, бүген ире өйдә. Кичә, шимбә көнне, соңга калып кайтты. Эштә тоткарладылар, дип, акланып та маташты бугай. Ул кайтканда Тәслимә малаен кочаклап йокларга яткан иде. Хәер, нинди йокы булсын инде! Әлеге хәбәрне ишеткәннән бирле...

Җомгада да соңга калып кайткан иде Фидаил. Ул төнне Тәслимә аны:

— Ник шунда гына кунып калмадың! — дип каршылады. Шул вакытта Фидаил үзенең кыек эшләрен хатыны сизенгәнне белде. Акланырга дип авызын ачмакчы иде, Тәслимә тавыш чыгармагач, телен тешләп, койрыгын кысты.

Тәслимә исә үзенең сабырлыгына шаккатты! Ул моңарчы һәркөнне диярлек төрле сәбәп тапкан булып яки бернинди сәбәпсез дә кайнап торган җаныннан пар чыгарып ала торган тынгысыз хатын, шулчаклы тыныч булса да булыр икән! Әллә гарьлек, хурлык һәм рәнҗеш-үпкәләре, песи баласы кебек бөгәрләнеп, бер төенчек яки йомгакка әверелгән дә тышка ыргылырга җай гына көтеп ятамы соң?!

Үзенә кирәкле фатирны тиз эзләп тапты ул. Казансу елгасы буенда, бик затлы итеп эшләнгән агач мәчеттән ерак түгел икән.

Ишек кыңгыравына үрелде дә аннары җәһәт кенә кулын кире алды. Ник килде ул монда?! Нәрсә калган? Шул рәвешле мескенләнеп йөрергәме? Фәридә: «Фидаилне кулдан ычкындырасың бит! Ирсез хатыннар буа буарлык хәзер! Һәммәсенә дә ир кирәк! Авызыңны ачып каласың бит, ахирәткәем!» — дип, учагына ялкын өстәп җибәргән иде. Фәридә ни әйтмәс! Җитмәсә, шул җирбитнең йөзенә сиптерерсең дип, кесәсенә бәләкәй газ баллоны да салган иде.

Хатын ишек кыңгыравына кабат басарга җөрьәт итмәде. «Мескенләнеп йөрергәме!» — дип уйлады ул һәм лифтка таба кире чигенде. Ул лифт каршына килеп җитүгә, аның ишеге ачылып китеп, ике кеше чыкты. Лифт эчендәге ут караңгы коридорны беразга гына яктыртып алса да, хатын аларның йөзләрен шәйләми калды, киемнәренә караганда яшүсмерләр бугай! Хатын почмакка посты.

Яшүсмерләр әле генә каршысында Тәслимә басып торган ишеккә таба атладылар. Үзләре ике генә авыз сүз дә алыштылар:

— Мин кулларын бәйләгәндә, син авызына чүпрәк тыгарсың!

Хатын, сулышын кысып, почмакка сеңде. Менә тегеләр ишек кыңгыравына бастылар. «Кем бар?» дигән тавыш артыннан ук ишек ачылды.

— ЖКУдан без. Счетчик тикшерәбез.

Хуҗа хатын ышанып, тимер ишеген дә ачты. Яшүсмерләр аны җәһәт кенә фатирына кире төртеп керттеләр дә артларыннан шапылдатып ишекләрен яптылар.

Тәслимә бер мәлгә югалып калды. Хуҗа хатынның чырылдап кычкырган тавышы гына аны кисәк айнытып җибәрде. Ул кесәсендәге нәни газ баллонын чытырдатып кулына кысты да фатирга таба атлады. Үзе дер-дер калтырый, үзе сак кына ишеккә якынлаша. Эчке яктан бикләргә онытканнар бугай, йозак тавышы ишетелмәде.

Башка вакыт булса, Тәслимә урамга ничек очып чыкканын да сизми калган булыр иде. Бүгенге халәте ничектер сәер аның — гәүдәсе калтыранса да, үзе тыныч, сугышчан холыклы һәм куркусыз иде.

Ул сак кына ишеккә төртте. Рәхмәт төшкере, анысы тавыш чыгарып шыгырдамады, җай гына ачылды. Ике яшүсмер малай — берсе хуҗабикәнең кулларын артка каерган, икенчесе аның авызына чүпрәк мүкләп маташа — чит кеше кергәнен шундук сизделәр һәм берсе ишеккә таба атылды. Бу минутта Тәслимә газ баллонын ике куллап кысып тотып, әзер тора иде.

Газга тончыккан малайларны Тәслимә ишек төбендәге аяк киемнәренә таба этеп җибәрде. Тегеләр, сөртенешеп, буш капчыклар сыман коридор идәненә аудылар. Аннары ул тиз генә хуҗабикәнең бәйләнеп җитмәгән кулларын чиште, авызындагы чүпрәген алды, шул мизгелдә үзе: «Һи, ямьсез нәрсә икән бит бу! Кай төшенә кызыккан моның Фидаил?!» — дип уйлап алды. Хатынның авызы да кечкенә түгел икән, шактый чүпрәкне сыйдырган. Ләкин озак маташырга вакыт юк, яшүсмерләр айнып, һушларына килеп аякка басарга мөмкиннәр иде.

— Телефоның бармы? Милиция чакырт! — дип боерды Тәслимә хуҗа хатынга. Тик тегенең керфеге дә селкенмәде, ул бер кат тынычланган иде инде, күрәсең.

— Юк, юк! Милиция кирәк түгел! Күрше подъезд малайлары бу! Наркоманнар, милициягә биреп җибәрсәң, ата-аналары күземне ачырмаячаклар!

Тәслимә башка сүз катмады, лып итеп кухнядагы урындыкка барып утырды. «Әллә ни чибәр булмаса да, сөйкемле генә нәрсә икән тагын үзе».

— Куркак малайлар алар үзләре. Милициядән котлары оча, ломкалары башланыр дип тә куркалар.

Көндәшенең ирен өстендә, уң яктарак, килешле генә миңе бар икән. «Гәүдәсе дә төз генә икән. Ә минем белән чагыштырганда...»

— Икенче подъездагы минем кебек ялгыз хатын, шушы ике шакал өенә басып кергәч, милициягә хәбәр иткән булган икән. Икенче көнне иртән эшкә барганда, берсенең атасы өстенә

бульдогын җибәргән. Янәмәсе, ул сабыйларга ник милиция чакырттың! Ай-һай әшәке хәзер халык!

«Минем белән чагыштырып та булмый ич моны хәтта! Кискән тырнагыма да тормый бит бу! Әйе, миннән яшьрәк инде яшьрәген...»

— Сезгә бик зур рәхмәт инде. Коридордан ишетеп кердегезме соң? Күршедә генә милиция тора, капитан. Аның да ишеге ачылып ябылды. Ләкин ул андый эшләргә кысылырга яратмый. Теге юлы үзе шулай диде. Имеш, ул службада түгел, имеш, кысылырга не имеет право. Алкаш! Аракы сорап кермәсме әле!

«Яшь булса да, минем белән чагыштырып булмый моны. Чебеш бит бу! Йоны йолкынган чебеш! Әллә... Әллә моның да битенә сиптереп, тибә-тибә кыйнаргамы».

— Узыгыз әле, кухняга узыгыз. Хәзер чәй куеп җибәрәм. Теге шакаллар бүтән керми инде алар, яхшы сабак булды, рәхмәт инде сезгә!

Тәслимә карусыз гына кухняга узды. Көндәш чәй әзерләргә керeштe. «Вкусы юк икән моның пычагым да! Стенасы — бертөсле, өстәлдәге клеенкасы — икенче. Гарнитурының төсе дә стена обоена туры килми!»

— Үзем ул малайларны кызганам да мин. Япь-яшь килеш бит... Киләчәкләре юк инде ул мескеннәрнең!

«Тәрәзәдәге пәрдәсе дә килешсез, һәй, чукынып китсен лә тәрәзәләре. Нәрсә, мин монда чәй эчәргә килдемме соң! Чәчләреннән йолка-йолка кыйнап чыгып китсәң инде моны? Болай да теге малайлар котын алды бичараның...»

— Әйбәт коньягым бар иде. Авыз итәбезме?

«Фидаилдән калганмы?» — дип, чак кына сорамый калды Тәслимә. Телен тешләп өлгерде. Әгәр дә мәгәр коньяк башланган булса... башланган булсамы? Шешәсе белән башына берне тондырам да чыгып китәм!»

Бәхеткә каршы, шешә ачылмаган иде.

Гомердә булмаганча, Тәслимә рәттән ике-өч рюмка эчеп куйды да авызы, тамаклары януга түзә алмыйча, кабалана-кабалана өстәлдәге конфетка үрелде.

— Рәхмәт инде сезгә! Курыкмадыгыз! Яклаучысыз икәнлегемне белә ул шакаллар. Бер ай элек алар кергәндә, өйдә иптәш мужигым туры килеп, тәпәләп чыгарган иде инде аларны. Якшәмбе көнне аның килмәсен беләләр.

Тәслимә өнсез калды. Бер ай элек диме! «Һай, син! Себерке! Әле мин бер атна элек кенә ишеттем бит! Бер ай ук бармыни инде!»

Хатын, кабалана-кабалана, кесәсеннән баягы баллонын чыгарды да күзләрен мөлдерәтеп үзенә карап утырган көндәшенә таба төбәде һәм төймәгә басты.

...Якшәмбе көн урамы. Чуп-чуар халык. Ыгы-зыгы. Аның кешеләрдә, кешеләрнең анда эше юк. Ул... ул — бу дөньядагы иң бәхетсез һәм кирәксез, ташланган, мыскыл ителгән, җаны мәсхәрәләнгән мескинә хатын.

Күктә — ак болытлар. Яңгырсыз, кысыр болытлар. Җирдә кайсы култыклашкан, кайсы җитәкләшкән яшь кызлар, егетләр.

Күктә ни булса — җирдә шул булыр. Яшьләрнең кыяфәтләре сүрән.

Аларның Фидаил белән беркайчан да кала урамында җитәкләшеп йөргәннәре булмады. Киного барганда, кайтканда култыклашканнардыр инде, анысы...

Алар икесе дә бер авылдан, классташлар иделәр. Мәктәп тәмамлаганнан соң, икесе дә университетның математика факультетына укырга керделәр.

Аннан соң ул Фидаилнең, яшь лейтенантның, армиядән хезмәт итеп кайтканын көтте. Каникулда өйләнештеләр. Замана җилләре уңай якка исә башлагач, Фидаил компьютерлар белән эш итүче шәхси фирма ачып җибәрде. Тәслимә, университетны тәмамлауга, мәктәпкә урнашкан иде, һаман да математика укыта.

Туйларында аларга ак бәхетләр теләделәр. Нинди була икән соң ул ак бәхет? Күктәге ак болытлар кебекме? Бәлки, яңа яуган ак кар сымандыр? Үзе ап-ак, үзе сап-салкын!.. Өшетә, туңдыра...

Тәслимә тротуар буйлап атлады, йөгерде. Атламый да, йөгерми дә, ә бәлкем, йөзә торгандыр ул! Ә алда иксез-чиксез зур, чәчәкле болын! Көне! Кояшлы да, матур да. Болын аллы-гөлле чәчәкләр белән тулган! Чәчәкләрне үбеп-үбеп очкан күбәләкләрнең нindие генә юк! Күбәләкләр Тәслимә атлы озын толымлы, күк йөзе кебек чиста, зур күзле кызчыкның кулларына куна, кыз аларны иреннәренә үк китереп, серле сүз пышылдыйм дигәндә генә, алар капылт кына очып китәләр.

Чү! Тәслимәнең алдыннан гына түмгәкләргә абына-сөртенә тагын кемдер йөгерә түгелме соң? Ул да күбәләкләр белән куышлы уйный. Кем булсын инде! Фаил бит! Аның газиз баласы! Тәслимә күбәләкләр артыннан түгел, ә улы янына йөгерә икән бит. Ә болын... болын бик зур. Карале, шундый зур болын читәннәр белән уратылып алынган. Читәннең аргы ягында тагын бер шәүлә күренә. Фидаил түгелме соң? Шул бит, үзе! Тик ул читән аша бу якка чыга алмыйча азаплана икән. Шулчак нидер булды: күктә берән-сәрән генә йөзгән ак болытлар кояшны каплады, чәчәкле болынга күләгә сузылып ятты: шуның артыннан ук болытлар арасында иләмсез зур канатлы кош пәйда булды. Әлеге кош кычкырган тавышына караганда гап-гади, әмма бик дәү козгын икән. Ул җилкәндәй канатлары белән һаваны шапылдатып алды да читән буенда Тәслимә белән Фаилгә кул изәп торган Фидаилне күтәреп тә алып китте. Алар югарыга, бик-биеккә күтәрелә башладылар. Менә козгын кинәт кенә яшь хатын-кыз кыяфәтенә керде. Әлеге яшь хатын белән Фидаил, бергәләшеп, кояшка таба оча башладылар. «Кояшка бик артык якынаймагыз! Яндыра, көйдерә бит!» — дип кычкырды Тәслимә. Кычкыруын кычкырды, әмма тавышы чыкмады. Аның тавышын урлап киткәннәр иде...

Болын да, андагы чәчәкләр, күбәләкләр куып йөргән улы да кинәт юкка чыктылар. Янәшәсенә килеп туктаган машинаның сызгырган тавышыннан өркеп, хатын яшь боландай читкә сикерде. Машина тәрәзәсеннән кыркылган такыр башлы шома йөз күренде.

— Девушка, а, девушка! Работаешь? Давай садись! Для тебя и 50 баксов не пожалею! Садись, коровушка моя! Деньги вперед получишь, а!

Тәслимә авызын ачарга да өлгермәде, «джип»ның арткы ишеге ачылып, кемнеңдер көчле куллары аны машина эченә суырып та алды. Арткы утыргычта кыска чәчле, шома битле яшүсмер утыра иде.

Хатынның гәүдәсе буйлап бер көтү кырмыска чабышып узды, куркуыннан тезләре калтырады, бер-берсенә тешләре бәрелде. Һәм ни гаҗәп: мизгел эчендә үз-үзен кулга ала алды да, бәргәләнмәде, чәбәләнмәде, сиздермичә генә кесәсенә тыгылды да матур авызларын җәеп елмайгандай итте. Бите, тамаклары, алай гына да түгел, бар гәүдәсе уттай яна, кызыша башласа да, тавышын суытып, мөмкин кадәр битараф булырга тырышты:

— А куда едем? — дигән булды ул чытыкланып.

Руль артында утырган муенсыз кара-кучкыл йөзле ир артка таба борылды һәм авызын ачып нидер әйтергә җыенган гына иде, хатын аның йөзенә газ җибәрде, шул мизгелдә диярлек үк янәшә утырганын да өлешсез калдырмады.

Җитез мәче кебек машинадан чыгып, кая таба чапканын да белештермичә йөгерде дә йөгерде хатын. Сулуы кабып һәм эченә кату чыгып тукталып калганда ул — озын Әмирхан урамының аргы ягына килеп җитә язган иде инде. Машина базары да кул сузымы җирдә генә — үзенең кайда икәнлеген хатын шуның буенча чамалады, чөнки иренә ияреп бу базарга еш килгәли, Фидаил машиналарына кирәк-ярак эзләгәндә, машина саклап кала, йә үзе дә, малаен җитәкләп, базар эченә үк керә торганнар иде.

Хезмәттәше Шамилнең дә бу тирәдә генә яшәве исенә төште хатынның. Узган ел эштәгеләр белән җыелышып барганнар иде, туган көнен сәбәп итеп бугай. Тәслимәнең чуалган баш мие ак-караны абайламады, туп-туры таныш йортка таба атлады. Башка чакта булса, мондый хәлләрдән соң ул, әлбәттә, тиз-тиз өенә йөгереп кайтыр һәм үзенең нинди бәлагә дучар була язганын ашыга-кабалана, хәтта елый-елый да иренә сөйләр, җаны алай гына тынычланмаса, малаен кочагына алып, шуннан күңеленә юаныч табар, кайгы катыш мәшәкатьләрен онытыр иде. Бүген алай итәсе килмәде, әлбәттә, баласы, бердәнбере, Фаиле, бик тә, бик тә кадерле аңа. Ул аны сагына да башлады инде. Ләкин анда, аның гади генә өй-гаилә дип аталган оясында икенче берәү дә бар бит әле!..

Күктә ак болытлар йөзә. Каурый сыман ап-ак болытлар. Алар кояшны каплаганда, җиргә күләгәләре төшә. Ул күләгәләр җирдән шуышып, өстерәлеп баралар.

Тәслимә юл буенда очраган эскәмиягә барып чүмәште. Йа Алла! Ни булды соң әле? Вак-төяк тормыш мәшәкатьләреннән үзенә күрә тәмен табып көйле генә яшәп ятканда бит! Ни булды соң?

Уйлар учагы сүрелә башлап, башындагы мең төрле керделе-чыктылы гакыл-фикерләре салмакланып, салкынаеп киткәндәй булды. Баш мие тырыша, тырмаша, азаплана: тирә-юньне чолгап алган караңгылыктан яктылыкка чыгар юл эзли. Тик юл юк, барыр юлы баткаклык, үтеп чыгар капкасы бикләнгән, бастырыкланган... тагынмы... тагын... хәер, бөтенләй юк бугай ул капка! Әнә күк йөзендә ак болытлар гына бар. Алар берсен-берсе бик җай гына, иплэп кенә этә-этә төньякка таба, Казансу елгасы ягына йөзәләр. Әнә ак болытлар... тагын кара болыт була. Та-

гын ниндиләре, кайсы төстәгеләре?.. Көнозын баш өстендә ак болытлар гына күреп ияләнгән күңел күзе болытларның кара булуына гаҗәпләнгәндәй дә итә. Ак кына, бары ап-ак кына бит алар!

Тәслимә утырган эскәмия астыннан ак болыт күләгәсе шуыша.

Эскәмия сихерле булдымы, әллә инде... Хәер, ни генә булса да, ниндидер бик аз вакыт эчендә генә хатынның күңеле һушына килде. Күзләре бик ачытса да, үксеп-үксеп елыйсы килсә дә, үзен-үзе юатырлык көч-гайрәт таба алмыйча, чарасызлыктан интексә дә, уй-фикерләре сабырлана төште. Нигә теге сөйрәлчек хатын белән, көндәш белән ачыктан-ачык, күзгә-күз карап сөйләшмәде соң әле ул! «Син! Син! Нигә минем иремне аздырасың! Син!.. Тфү!» Шуның белән авыз чайкап сөйләшеп торыргамы! Яңагына берне чалтыратырга иде дә!..

Хатынның аяклары яңадан Казансу буена таба, көндәше яшәгән йорт ягына атлады. Хәтта теге шакмак муенлы адәмнәр утырган чит ил машинасы очрар дип тә куркып тормады. Аңа барыбер кебек иде. Ничек кенә булса да, аның бүгенге ниятен очлыйсы, ахырына чыгарасы килә иде.

Баягы таныш йорт подъезды каршысында таныш машина күргәч, хатын имәнеп китте. Фидаил машинасы бит! Кәнтәй янында! Тегесе телефоннан шылтыраткандыр, үләм-бетәм, йә талыйлар, йә йөзгә газ сиптерәләр, дип зарлангандыр да аның өстерәлчек ире, шул кәнтәйне юату өчен чыгып чапкандыр!

Ул ирексездән башын күтәреп югарыга карады. Бишенчеме, дүртенчеме катның балконында ир-ат шәүләсе карангалап тора. Аның янында хатын-кыз. Кызып-кызып ни хакындадыр гәпләшәләр. Гөрләшәләрме, талашалармы — Алла белсен!

Тәслимә, сөртенә-сөртенә, олы юлга таба йөгерде. «Чүпрәк мин! Җебегән! Үч алырга, миңа да күптән үч алырга кирәк иде бит инде!» — дип битәрләде ул үз-үзен. Һәм, чыннан да, хатын шуннан башка бүтән юл күрмәде дә бугай инде.

Бәхеткә каршы булдымы икән, кызганычка каршы микән инде, Шамил өйдә туры килде. Өйдә, һәм үзе генә. Ул көтмәгәндә-уйламаганда хезмәттәше килеп кергәч, бик гаҗәпләнде, аптырады.

— Берәр нәрсә булмагандыр ич? — дип сорады ишекне ачуга.

Тәслимә үзен кулга алып өлгергән иде инде, Хак Тәгалә хатын-кызга биргән бар талантын эшкә җигеп, күңелендәгесен тышка чыгармаска, сиздермәскә тырышты. Әйе, бик теләсә, һәрбер хатын-кыз да коеп куйган актер була ала, хатын-кызның башында төпле фикер кинәт тумый, ул аны берәмтекләп җыя-җыя да аннан соң гына иреккә чыгарып җибәрә. Үзен табигать тарафыннан да, җәмгыять тарафыннан да кимсетелгән, кыерсытылган җенси зат дип уйлау хатын-кызның ми күзәнәкләрен бертуктаусыз хәрәкәттә тота һәм ул һәрвакыт уяу, һәрвакыт дошманына ташланырга әзер тора. Туктаусыз хәрәкәттәге ми күзәнәкләре сай суда әрле-бирле килгән вак балыкларны хәтерләтәләр.

Безнең Тәслимәнең «вак балык»лары бер юнәлештәрәк, тәртип беләнрәк йөзделәр.

— Узып барышлый гына, юл уңаеннан гына. Ничә еллар бер бүлмәдә утырып эшлибез, мин әйтәм.

— Әйдә, әйдә, уз, Тәслимә. Тартынма.

Ишек бусагасында Тәслимәне күреп каушаган Шамил, үзенең әлеге халәтенә ачуы килеп, янә каушады, кыскасы, ни кылырга белмәде. Тәслимәсе күптән узган инде, бер туфлиен дә салырга өлгергән, ә ул һаман: «Уз, уз, тартынма», — дип кабатлап торуын белә.

Тартынып торырлык булса, монда кадәр киләме соң инде ул, тиле баш!

Шамил Тәслимәнең килеп керүенә сөенә дә. Ир хатыны булган өчен генә хис ташкынын тыеп тора. Эштә вакытта тик торганнан, алай начар-бозык уйлар белән түгел, әлбәттә, ут уйната торган зәңгәр күзле чая Тәслимәнең бит очыннан үбеп аласы килгән чаклары була торган иде лә югыйсә...

Өйдә Шамилнең маңгай чәчләре тагын да бөдрәрәк булып күренә икән. Өйдә ул эштәге җитди, һәр сүзен җиде кат үлчәп сөйләшә торган Шамил түгел. Бүлек җитәкчесе дә түгел, гади, бик гади, фәкать Шамил генә. Әгәр Шамилне белмәгән кеше булса, озын буена, ярау гәүдәсенә һәм төксе чыраена карап кына да аны усал, тәкәббер кеше дип уйлар иде. Ә өйдә, хәтта тышкы кыяфәте дә андый тәэсир уятмый икән: буе да кайтышланып киткәндәй, хәтта ирен читенә елмаю да эленгән әле.

Нинди генә үткен акыллы һәм чая булмасын, Тәслимә монда кадәр килеп, ят ир бусагасын атлый белде. Әмма шуннан соң нишләргә кирәклеге башына килмәде, аптырашта калды. Рәх-

мәт төшкере, аны әлеге тилемсә халәтеннән бары хатын-кыз актерлыгы гына коткарып тора, аннан соң кире чыгып йөгерергә, күңелдәге баягы ачуы да ирек бирми бугай инде.

Шамил хатынны бер бүлмәле бик тә килешле, пөхтә итеп җыештырылган фатирының түренә кертеп утыртты да, ашыга-кабалана чәй куеп, кунак сые хәзерләргә кереште. Хәер, аның сые күптән әзер икән инде: ул почмактагы тәгәрмәчле бәләкәй арба-өстәлне Тәслимә янына гына этеп алып килде дә өстендәге ашъяулыгын читкә алып куйды. Әгәр дә шампан белән коры шәраб һәм коньяк шешәләрен дә сый-нигъмәт дип атасаң, матур тәлинкәләргә өелгән йөзем, банан, әфлисун кебек җимешләре әлеге төргә керә дә керә инде.

— Мин сине көтеп утыра идем әле.

Бу шартларда бер-берсенә ияләнә, күнегә башласалар да, барыбер үзара тартыну, читсенү һәм әлеге дә баягы һаман шул кыюсызлык өйдә һаман хөкем сөрә иде. Шамил бокалларга шампан бүлде. Ул аның бөкесен дә аттырып тормады, тавышсыз гына ачты. Икесе дә күреп, сизеп тора, телләрен бары тик шәраб кына чишә алачак иде.

Көндәше өендә эчкән коньяк Тәслимәнең авызын киптергән иде, ул шампанны йотлыга-йотлыга эчте. Хәтта каршысындагы Шамилгә дә игътибар итмәде. Исенә килгәндә, соң: шампан бокалы бушаган иде инде. Әллә уңайсызланудан, әллә эчемлек тәэсиреннән бит алмаларына ут кабуын тойды хатын, колак яфракларына хәтле кызарган иде бугай. Тора-бара — ниндидер бик тиз арада гына — әлеге уңайсызлану хисләрен күбекле шампан гайрәте кысрыклап чыгарды, хатын үзен иркенрәк тота башлады. Тәслимәнең үзгәреш-халәтен тоеп, күреп утырган Шамил дә кыюлана төште. Җитмәсә, күңелен хәерсез хис биләп алды, каршысында балкып утырган хатынны кочагына суырып аласы килде. Килде генә, ләкин мәңге алай эшли алмаячак, һәм ир үзеннән дә батыррак, кыюрак була алмаячак иде. Юкка гына шушы көнгә чаклы өйләнми йөрми ич инде ул. Ходай Тәгалә аңа баганадай буй-сын, төс-кыяфәт һәм акыл биргән. Тик менә кыюлык дигән сыйфатка чират җиткәч, никтер саранланган иде. Өйләнәсе килгән егет кәҗә сатып өйләнә дигәндәй, әлбәттә, әгәр аны өйләнү дип атап булса, ул бер мәртәбә өйләнгән, дөресрәге, өйләнеп караган иде инде. Язылышмадылар да, кәләш белән никах укытырга дип, авылга, Шамилнең әнисе янына кайттылар. Яхшы хәтерли: җомга көнне кич кенә кайтып җитте алар. Сәлимә, булачак килен, кияүдән аерылып кайткан, бик чая һәм үткен мишәр кызы иде. Дөресрәге, Шамилне өйләнү дәрәҗәсенә ул үзе китереп җиткерде.

Иртәгә никах дигән көнне икесенә аерым-аерым урыннар җәеп йокларга яттылар. Ишек катында әнкәсе караваты, ике як почмакта өйнең түрендә үк ике карават. Ул караватлар арасында кулдан ясалган озын өстәл. Ут сүнеп ун-унбиш минут уздымы икән, Сәлимә, өстәл астыннан гына шуышып килеп, Шамилнең юрган астына кереп ятты. «Нишлисең, әнкәй өйдә бит», — дип пышылдады Шамил уңайсызланып. «Сезнең өйдә үзем генә йокларга куркам мин...» — дип, егетнең муенына кайнар сулышын өрде хатын.

Шамил иртәгесен әнисенең йөзе генә түгел, үз-үзен тотышына кадәр үзгәргәнен сизде.

Җомга көн кичтән үк сөйләшеп-белешеп куйган мулла бабай кинәт кенә сырхаулап киткән, имеш. Ул шимбәдә Шамил белән Сәлимәгә никах укылмый калды. Хәер, аның алай ашык-пошык укылмавы яхшыга булды: алар барыбер кушылмадылар. Шуннан соң Шамил бүтән өйләнеп карамады. Атна саен авылга кайтып йөрде, кайбер киленнәрдән дә болайрак итеп ялгыз әнисен бакты.

Шәраб, тәнгә таралып өлгереп, кан йөрешен кызулатты, соңгы көннәрдә кичергән стресслардан талчыккан, алҗыган гәүдәсенә яңадан көч-куәт кайтты. Ул Шамилнең бик тә үлчәп-чамалап кына әйткән сүзләреннән тырыша-тырыша үз-үзенә кызык эзләде. Шамилнең кыюсызлыгына караганда, тормыш тәҗрибәсе салынган үлчәве басарак төште. Аулак өйдә сәламәт яшь хатын белән шулай ук гаярь ир арасында хөкем иткән тартыну, уңайсызлану дилбегәсен бушатырга азапланып, мәзәк арты мәзәк сөйләргә кереште. Әле уен-көлкеле, төрткеле мәзәкләрдән соң үзенең дә, хезмәттәш хатынның да тотнаклы акыллары, менә кабына, менә дөрләп китә дип кузгалырга торган хис-тойгылары кымшана башлады, кыймылдарга, селкенергә кереште.

— Патша армиясендә хезмәт иткән солдат дембелгә кайтып килә, — дип, чираттагы мәзәген башлады Шамил. — Киткәндә моның кулына «Сораган бер теләгенә дә каршы килмәскә!» дигән мөһер белән кәгазь-документ тапшыралар. Китә бу шулай кайтып. Кич җиткәч, бу юл уңаендагы бер авылга төн кунарга туктала. Авыл башындагы бер йортның капкасын шакый. Хуҗа хатын — шактый карт кына тешсез әби — солдатны ашата-эчертә. Тамагы туйган служевый әбидән: «Әби тагын кемнәрең бар соң?» — дип сорый. «Кирәксә, чакырам. Внучка Майя еще», — дип җавап бирә әби. Солдат: «Әби карт инде, кирәк түгел, внучка Майя дигәне артык яшь, бала гынадыр», — дип уйлый-уйлый печәнлеккә менеп китә. Иртәгесен йокысын туйдырып

ишегалдына төшсә, ни күрә: бик сылу, җиләк кебек өлгереп пешкән бер кыз, шәрә ботларын елтыратып, болдыр идәнен юып маташа. Соклануыннан өнсез калган солдат моның янына килә дә:

— Ты кто такая? — дип сорый.

— Я — внучка Майя. А ты кто? — ди кыз.

Үз-үзенә бик тә ачуы килгән солдат:

— А я мудак из сеновала! — дип җавап бирә.

Шамил әлеге мәзәген сөйләгәндә, Тәслимәдән күзен алмады, янәсе хатынга тәэсире ничек. Сөйләп бетергәч, үзе рәхәтләнеп, кычкыра-кычкыра көлә башлаганын да сизми калды. Шулчаклы бирелеп, чын күңелдән көлде ки, ул кулындагы бокалдагы шәрабы чайкалып күлмәгенә түгелгәнен дә сизмәде. Тәслимә исә мәзәктән бигрәк Шамилнең үзеннән көлде бугай, моңарчы хезмәттәшенең болай дөньясын онытканын аның күргәне юк иде.

Шамил көлүеннән капылт кына туктады да, диванга хатын янына күченеп утырды. Бокалларга янә шампан койды.

— Яле, Тәслимә, шул бәхетсез солдат өчен күтәрикче.

Сүз булсын өчен генә, Тәслимә:

— Нишләп бәхетсез булсын? Өенә кайтып бара ич ул! — дип каршы килде.

— Бәхетсез генә түгел, мудак ул, мудак! — диде Шамил, хатынга якынрак елышып. Әмма шуннан соң нишләргә дигәндәй, аптырап, аңа күтәрелеп карады. Хатынның күзләре, күзләре генә түгел, зәңгәр күзләренең кайнар карашы аны үзенә тарта, сихри көч белән магниттай суыра иде. Моны хатын да, ир дә аңлап бетерә алмадылар, шул мизгел эчендә Тәслимә Шамилнең кочагында иде инде. «Үч алам! Барыбер үч алам!» — дип уйлады хатын. Күлмәк төймәләре итәгенә тиклем ычкындырылып, лифчик каптырмасының черт иткән тавышы аны сискәндереп җибәрде. Ир шулчаклы дәртләнгән, кызган иде, аны һичничек тә тынычландырып, башы белән бозлы суга тыксаң да, суытып булмый иде инде. Тәслимә исә, киресенчә, ничек тиз кайнарланса, шулай тиз аңына да килде. «Һай, Аллам! Җиңел түгел икән ләбаса. Үч алуы алай гади түгел икән лә». Ул читкә тартылды, ике кулын ирнең күкрәгенә терәде. Юк, юк, Фидаилдән башка кешене кабул итә алмый икән бит ул! Ләкин соң, бик соң иде инде. Хәтта «үч алу» теләге дә юата, тынычландыра алмады аны! Ни хәл соң бу! Шамил аны көчләми ләбаса! Үзе килде бит, үзе ишеген шакыды. Максаты да бер иде. Хәзер, чынлап та, соң микәнни инде? Бу Фидаил ничекләр итеп ят, чит хатын-кызны кочаклап ята алды икән соң? Ничек, ничекләр итеп?! Ул үзе иренә күнеккән, ияләнгән, тәненә читләрнең бармак очы белән дә орынуын теләми икән ләбаса!

Әллә хатынның теләгәне кабул булды инде, ишек кыңгыравы чылтырады. Очраклы гына түгел, максатчан чылтырый. Хатын ике күкрәк арасына борынын төртеп өлгергән ирне җәһәт кенә читкә этәрде.

— Ишектә кеше бар! Шамил, дим!

Кыңгырау өзлексез чылтырады. Әүвәл ачмаска уйлаган Шамил түзмәде, сак кына басып, кем икәнлеген белер өчен ишек катына таба китте.

— Шамил, ач инде, ач, — диде Тәслимә, ашык-пошык төймәләрен каптыра-каптыра. Тегесе һаман аңына килеп өлгермәгән иде булса кирәк, аптырап әле чәчләрен төзәтергә керешкән Тәслимәгә, әле бертуктаусыз чылтыраган ишек кыңгыравына карап, баскан урынында каткан да калган.

Әүвәл тышкы яктан йозак борылган тавыш ишетелде, аннары ишек үзе ачылып китте. Кыңгырауга басучының ачкычы да бар иде, күрәсең. Ачылып та китте, өермә кебек дуылдап бер кыз-хатын килеп тә керде һәм, Тәслимәне күрүгә, юлында басып торган Шамилне кырыйга төртеп җибәрде дә өй эченә узды. Бикле ишек, өстәлдәге шәраблар, ялгыз ир белән ялгыз хатын икәүдән-икәү генә... Аңлашыла инде. Ишектән керүче Шамил кебек озын буйлы, акшарланган йөзле кыз-хатын хуҗага таба борылды. Һәм:

— Син! Син! Ялганчы, аферист! Импотенциядән дәваланам, дип, бер ел буе мине алдап, өйләнмичә йөрисең! Хәзер аңлашылды инде нинди импотент икәнлегең! — дип чәрелдәргә кереште.

Тәслимә, үзенә игътибар итмәүләреннән файдаланып, ашык-пошык кына җыенды да ябылып җитмәгән ишеккә атылды. Артыннан теге кыз-хатынның «автоматтан атканы» беренче катка җиткәнче аермачык булып ишетелеп торды.

Урамга чыккач, Тәслимә җиңел сулап куйды. Хәзер үч аласы килү теләге дә сүнгән, сүрелгән, тизрәк өенә кайтып егыласы килә иде. Автобус-мазарга утырып, һич кенә дә кешеләр күзенә чалынырга теләмәде. Казансу буйлап җәяү генә, әүвәл «Нәшрият» тукталышына чыгасы ит-

те, аннан циркка кадәрге юлда бераз суынгач, тынычланып җиткәч, трамвайга утырыр. Урамда эңгер-меңгер төшә башласа да, караңгы түгел әле. Караңгысына караганда ул барыннан да бигрәк теге хатынның артыннан чыгуыннан һәм куып җитеп чәченә ябышуыннан шүрләде булса кирәк. Шамилгә төкереген чәчеп бетергәч, аннары, әлбәттә, ул Тәслимәгә күчәчәк иде. Яхшы чакта үкчәңне күтәрергә кирәк. Хәер, яхшы ук булмады шул. Шамилнең ярәшелгән, вәгъдәләшкән кызы булганын белмәде лабаса ул. Ә бәлкем, Фидаилнең сөйрәлчеге дә белмәгәндер аның хатынлы икәнен. Фидаил гаиләсе барлыгын яшергәндер аннан?! Мондый уйлардан котылу мөмкин түгел иде. Алардан арыныйм дип, таллыклар янәшәсеннән сузылган комлы юлдан йөгермәкче дә булып караган иде. Булмый, аяклар бата.

Алдарак, Казансуның комлы яры буенда ук, чүп-чар яндыралармы, учак ягалармы — уты тирә-юньне яктыртып, балкытып тора. Хатын шул тирәгә җитүгә, куаклар арасыннан каршысына телеграмм баганасыдай ике адәм килеп чыкты.

— Дамочка, пойдемте к нам. Вместе веселее будет. Шашлыком угостим, песеньки будем петь.

Куян кебек дерелдәргә керешкән хатынны икесе ике кулыннан эләктереп алдылар да учакка таба өстерәделәр. Кычкырмакчы булып авызын ачкан иде, әзмәвернең берсе касыгына төртте:

— Будешь кричать — на Казанке утопим!

Хатын чәбәләнде, бәргәләнде, тик файдасыз иде.

— Тихо! Сказали утопим, значит, утопим!

Аны, җилтерәтеп, учак янына алып килделәр. Учак тирәсен яшүсмер егет-кызлар әйләндереп алган. Әнә бер кыз үзе кебек үк яшүсмер малайның чалбарын тартып төшергән дә, комга тезләнеп, аның бот арасына шприц тыгып маташа. Икенчесе «ыштансыз»ны юата:

— Не бойся! Твои предки, надеюсь, с тебя штаны сдерать не будут?

Тәслимәне төрткәләп учак янына алып килделәр.

— Скучно тебе, видимо. Час, очень весело будет!

Күз ачып йомган арада, шприцлы кыз Тәслимә янына килеп басты.

— Приготовились, — диде ул, чырык-чырык көлә-көлә.

Сул беләгенең тамырын нидер ачыттырып куйды. Шуннан соң... шуннан соң җиңелчә генә башы әйләнәсе килеп торды да беркавымнан рәхәт булып китте. Кечке Казансу өсте күбекләнәкүбекләнә кайный, төнге күккә учлап диярлек сипкән исәп-хисапсыз йолдызлар ниндидер бик җиңел, кызу көйгә биешә, сикерешәләр. Яңа туган ай кырын яткан да, ялкауланып, иренеп кенә челем тартадыр сыман. Әйләнә-тирәсенә тәмәке утлары-йолдызлары чәчри. Ай Тәслимәгә күз кысты. Хатын җавап итеп үзе дә аңа күз кысты һәм: «Мине үзеңә ал әле! Зөһрә бит мин, күрәсезме, мин Зөһрә кыз!» — дип кычкырырга кереште.

Кемдер аның авызын томалады. Кемдер:

— Менты! — дип сөрән салды.

Яшүсмерләр, тараканнар кебек, төрлесе-төрле якка качыша башлады. Яр буенда учак һәм айга кулларын сузып торган Тәслимә генә калдылар. Шулчак учак янына өч кеше йөгереп килде һәм берсе хатынның кулларыннан эләктереп артка каерды.

— Син ник качмадың, красавица?

Милиционерларның бу сүзләреннән соң хатын көлеп җибәрде.

— Нигә качыйм ди мин. Моя милиция меня бережет!

Тегеләр үзара нидер пышылдашып алдылар да, аны култыклап, машинага таба алып киттеләр.

Машинада эссе, тынчу. Кара, рәхмәт яугыры, кемдер аңа эссе икәнлеген белгән кебек күлмәкләрен салдырырга кереште. Аны иркәлиләр, күкрәкләреннән, тәннәреннән үбәләр.

Хатынны арткы утыргычка сузып салдылар да шәрә милиционер аның өстенә атланды. Ул әле мышкылдый, әле тончыккандай гыр-гыр килә иде. Чү! Нишлисең син, кабахәт! Хатын чәбәләнә башлады. Кемдер аның башына басты.

Милиция машинасында, аулак урында туктый-туктый, аны таңга кадәр бушка утыртып йөрделәр. Аннары, таң беленә башлауга, үзе яшәгән йортның ишегалдында машинадан этеп диярлек төшереп калдырдылар.

Аның күңеле болгана, башы әйләнә иде. Аяклары да тотмый, басып торган җирендә як-якка чайкалып тора. Менә аның подъезды, әнә өченче катта аларның балконы. Балконда... балконда Фидаил басып тора. Әүвәл ул хатынын танымады. Танып алгач, атылып урамга чыкты һәм йөгереп килешенә хатынын күтәреп алды. Үзе тилергән кебек берөзлексез кызу-кызу сөйләнә:

— Тәслимә, бәгырькәем, зинһар, гафу ит мине, кичерә күр, Тәслимәм.

Фидаилнең көчле кулларын тоеп, бишектә тирбәлгәндәй барды ул. Шундый рәхәт. Хатын чытырдатып күзләрен йомды. Ул оча, ул канатлы икән бит! Ул — Җир баласы — мизгел эчендә күк кызына әверелде. Ул оча, ул күктә йөзә! Янәшәсендә генә Фидаил дә оча икән. Бераз алдарак, нәни канатларын тырышып җилпи-җилпи Фаил дә оча.

Алар өчесе бергәләшеп очалар. Алар болытлардан да өстәрәк... очалар да очалар... Кояшка таба очалар... Һай, Кояш аларның канатларын көйдермәсә ярый инде...

## КИЧҮ

Үзара шаярышып, бер-берсе белән уйнаган төсле генә күренгән кара сыртлы дулкыннар килеп җитәрәк сыртларын тагын да кабартып, дәррәү ярга ташланалар. Комлы яр, һәр яңа дулкын өере килеп бәрелгән саен, сыкранып-сыкранып кына артка чигенәдер, дулкыннар аны авызларын чапылдата-чапылдата, кабаланмыйча, тәмен белеп кенә ашыйлар, кимерәләрдер төсле тоела. Су чәчрәгәнгәме, әллә чарасызлыктанмы, ярның маңгае юешләнеп, тирләп чыккан кебек.

Яр буенда баш сөякләре таралышып ята. Адәм башлары, бу рәвешле аунап ятуларына хурлангандай, ярга бәрелгән дулкынга ияреп, эчкә тәгәриләр. Чираттагы дулкын аларны кире кагып чыгара.

Мөхәммәт атлы малай яшәгән әлеге диңгездәй зур суның аргы ягында да баш сөякләре бик күп. Аларны җыеп зиратка илтеп күмә торалар. Ләкин алар һаман пәйда була тора, башларны җыеп бетерә торган түгел...

Өстенә кыска соры кожан кигән, тәбәнәк буйлы, җыерчыклы, ләкин чиста, күркәм йөзле карттан кала яр буендагыларның берсе дә аунап яткан баш сөякләренә игътибар итми кебек. Карт, баш сөякләренең әле берсенә, әле икенчесенә озаклап карап тора-тора да, авыр көрсенеп, карашын югары күтәрә, аннары су кырыена ук килеп, буш кулын өстенә куйган килеш, Зур Су өстен күзли.

Картның аркасында соры киндер капчык. Нәрсә тутыргандыр — капчык хәйран авыр күренә, карт аны авырлык белән генә бер иңбашыннан икенчесенә күчерә. Җиргә генә куйса инде канә!

Мөхәммәт атлы малай, шул турыда әйтергә теләгәндәй, аңа таба тартыла. Ләкин кулыннан этисе кысып тоткан, җибәрми.

Капчыклының яр буендагы көймәче карт янына килеп аңа нидер әйтәсе дә килә шикелле. Менә ул көймәчегә таба борылды, хәтта аңа таба бер-ике адым атлап та куйды, тик бармады, арырак яткан баш сөякләрен карарга кереште.

Мөхәммәтләр монда килгәндә, әлеге карт теге көймәче белән ни хакындадыр кызу-кызу сөйләшә иде. Кешеләр килгәч, сүзләре бүленде, ахрысы, туктап калдылар.

Көймәче аңа:

— Кит әле, кит. Комачаулама! — диде. Ачуланып әйтмәде, болай гына, үз итеп кенә куалады.

Көймәче карт көймәнең моторын кабызып азаплана. Мөхәммәт атлы малай яшәгән кырык йортлы авылның барча сыерына да берьюлы башак болгатып бирерлек агач тагарак хәтле бу көймәнең кузгалып киткәнен тагын өч кеше түземсезләнеп көтә. Икесе — ак якалы, галстуклы, күн тужуркалы кырык-кырык биш яшьләрдәге пөләш маңгайлы абыйлар. Өченчесе — Мөхәммәтләр белән бергә килгәне — кәләпүшле, түгәрәк ак сакаллы карт. Мулла бабай.

Көймәче карт мотор бавын бар көченә тарта. Мотор төчкергәндәй итенә дә тагын тына. Күн тужуркалы абыйлар көймә хуҗасын ашыктыралар, берсе, өлкәнрәк күренгән түгәрәк корсаклысы, әледән-әле сәгатенә карый, янә көймәчене ашыктыра.

Бу абыең шушы җирләрнең, бу Зур Суның хуҗасы, ди, этисе Мөхәммәткә һәм үзе аңа сүз кушарга, аның белән сөйләшергә бик теләсә дә, кыюлыгы җитми, уңайсызлана, читтәрәк торырга тырыша. Аның район башлыгына әйтәсе сүзе бар. Колхозга кайткач, яңа тракторга председатель тагын үз туганының киявен утыртмакчы. Югыйсә чират Мөхәммәтнең этисенекендә иде.

Хуҗаның кәефе юклыгы йөзенә чыккан. Аскы ирене кысылган. Ул кулындагы сәгатенә ешеш карый. Тиздән аның районына Мәскәү кешеләре, Казан җитәкчеләре килеп төшәчәк. Әүвәл алар Зур Суның бу ягына килергә тиешләр иде, хуҗага кунакларны бирге ярда көтәргә кушылган иде. Районның барлык җитәкчеләре дә таң тишегеннән үк бу ярга җыелды. Ныклап, зурдан кубып кунакларны көттеләр.

Ярты сәгать элек кенә яңа хәбәр ирештерделәр: җитәкчеләр әүвәл теге ярга, райүзәккә киләселәр икән.

Моннан теге якка күпер аша әйләнеп чыгу өчен өч сәгатьлек юл үтәргә кирәк. Җитәкчеләр исә сәгать унбердә, ягъни нәкъ бер сәгатьтән райүзәктә булачаклар. Самолетка күпер кирәкми, ул туры юлдан оча. Моторлы көймәдә исә Зур Суны кырык минутта кичеп чыгып була. Хуҗа кеше үзенең ярдәмчесе белән иң ышанычлы көймәне сайлаган иде. Каһәр суккан мотор һаман кабынмый!..

Теге карт, капчыгын җиргә куеп, авызын чиште дә, иелеп яр буеннан бер адәм башы сөяген алды һәм капчыгына салып куйды. Ул баядан бирле шул баш сөягенә текәлеп карап тора иде. Хуҗадан кала бу хәлгә игътибар итүче дә булмады. Тирә-юнь кешеләренең яр буеннан адәм башлары җыеп йөрүләре хәзер табигый хәл иде. Моннан бер ел элек байтак авыллар зиратлары белән бергә Зур Су астында калды. Яр буенда калган каберлекләргә Зур Су тынгылык бирми.

Кешеләр бәләкәй генә елгадан Зур Су ясаганда аны бу кадәр үк зураер, киңәер дип башларына да китермәгәннәр иде.

Мөхәммәт атлы малай өчен дә гадәти күренеш иде инде бу. Чөнки аларның мәктәбендә адәм башы сөякләрен җыеп яңа урынга күмү буенча ярыш оештырылды.

Мәскәүлеләр килер алдыннан Хуҗа яр буенда бер генә баш сөяге дә калдырмаска дигән әмер биргән иде. Бу эшне оештыру янәшәсендә басып торган ярдәмчесенә кушылган иде. Хуҗа, тотып ашардай булып, ярдәмчесенә карады. Тегесе куырылып килде, кечерәеп калды, аның борын очына тикле тирләп чыкты.

Хуҗаның нерв җепләре өзелердәй булып киерелгән иде, ярдәмчесен әрләп яки баядан бирле көймә койрыгында маташкан картны сүгеп берәр сүз әйтсә, ул җеп өзеләчәк һәм аннары ни кылачагын, моның ахыры ни белән бетәчәген ул күз алдына ачык китерә иде. Шуңа күрә бар ачуын эченә җыйды.

Көймәче тагын мотор бавын тартты. Мотор төчкерде-пошкырды да янә сүнде. Хуҗаның түземлеге төкәнде. Көймәчене дорфа гына бер читкә этәрде дә бауны үз кулына алды. Бер аягын көймәгә терәде, икенчесен арткарак шудырды һәм бар көче белән тартып җибәрде. Мотор төчкереп алды да тырылдап эшләргә кереште. Хуҗа кулыннан ычкынып киткән бау бөтерелеп читкә очты һәм капчыклы картның муенына килеп уралды.

Көймәгә беренче Хуҗа сикереп менде, аның артыннан ярдәмчесе үрмәләде, аннан соң Мөхәммәтләр утырышты.

Мотор кабынуга, муенындагы бауны кулына тоткан килеш, ашыга-ашыга, капчыклы карт та килеп җитте һәм капчыгын көймәгә куймакчы булды. Көймәче аны читкә этәрде:

— Кит, дидем бит инде. Әйләнеп узам, бүген дә бармыйм. Күрәсең ич, көймәдә бала бар, — диде. Ул бу юлы да җикеренеп, ачуланып түгел, бик якын кешесенә яхшы киңәш биргәндәй әйтте. Карт капчыгын көймәгә салып өлгергән иде инде, көймәченең сүзенә колак салмады. Аларның сөйләшүен тыңлап торган Мөхәммәт атлы малай, күзләрен кыса төшеп, борынын тартып куйды.

Көймә кузгалып китте, йөзләргә эреле-ваклы тамчылар чәчрәде, дымлы җил, киемнәрне салдыргандай итеп, тәннәрне кытыклады.

Яр да, баш сөякләре дә артта калды.

— Турыдан, түлке турыдан гына! — дип әмер бирде күн тужуркалы Хуҗа.

Көймәче, сүзен әйтер алдыннан, әүвәл күккә күз ташлады, аннары аның карашы көймәдән читкә чабышкан дулкыннар өстеннән сикереп узды. Зур Суга ияләнмәгән, күнекмәгән кешегә аның холкын белү кыен иде. Кайчандыр көймәче, Зур Суның киңлегеннән куркып, үзе дә көймәнең шактый зурын ясаган иде. Аның әле һаман Зур Суның табигатенә төшенеп җитә алганы юк. Ул янә күккә карады. Болытлар бик тиз хәрәкәт итә, күктә Зур Судагы дулкыннар чагыла. Зур Су өстеннән торып Күкнең дә «телен» аңлый алмады көймәче карт. Күкне аңлау өчен аяк астында җир булуы кирәк иде аңа.

— Турыдан ярамас. Чоңгылны әйләнеп үтәргә кирәк. Җил көчәя, шуңа әйтүем.

Хуҗа нидер әйтергә җыенган иде — дәшмәде, килеште, ахрысы. Алайса үзең кара дигән кебек урынына җайлабрак урнашты, аякларын сузып җибәрде.

Иксез-чиксез Зур Су, яшькелт сыртлы җитез дулкыннар аны сәламлиләрдер кебек. Әнә теге чыелдавык су өсте кошлары бу Суның, бу биләмәләрнең хуҗасы хөрмәтенә очалардыр сыман. Әлеге Зур Су монда аның көче белән барлыкка килде. Шушы диңгезне өстәгеләрнең әмере белән аның кулы һәм йокысыз төннәре ясады.

Бүген аның зур эшен күрергә Мәскәүнең үзеннән үк киләчәкләр. Аны тагын да югарырак күтәрелү көтә. Шул изге эш хакына үзенең туган нигезен дә Зур Су астында калдырды ул. Адәм баласы кайда яшәсә — нигезе шунда дип уйлый иде Хуҗа.

Аның ата-бабалары гомерләре буена Зур Су күрмәгән. Алар күрмәгәнне балалары күрсен. Суның алыптай көче миллиардларча сукыр лапмалар уты белән чагыштыргысыз яктылык бирәчәк, хезмәт куячак.

Хуҗа бөек уйларыннан капылт кына аерылырга мәҗбүр булды. Бер көйгә генә тырылдап эшләгән көймә моторы йөткереп алды да шым булды. Барысы да койрыкта утырган көймәче картка таба борылдылар. Көймәче, берәүгә дә игътибар итмичә, акрын гына күтәреп моторның капкачын ачты, башын чайкый-чайкый беркавым карап торды да кире япты. Аннары, кабызгычына бау урап, кисәк тартып җибәрде — өмет күренмәде. Тагын тартты: тагын юк. Каушап калган көймәче карт Хуҗага гаепле караш төбәде:

— Бетте бу. Кабынмый. Күптән эшләткәнем юк ие. Мин шул ишкәкләр белән генә ие...

Хуҗа урыныннан кузгалып өлгергәнче, Мөхәммәтнең әтисе, үзе ярдәм сорап барачак җитәкчегә яхшатланыпмы, җәһәт кенә мотор янына килде дә бауны уң кулына урады. Көймә чайкалып китте, мотор сәер тавыш чыгарып пырхылдады, Мөхәммәтнең әтисе кулындагы бауны кире чорнады, янә аны үзенә таба йолкыды, әмма мотор кабынмады. Мөхәммәтнең әтисе исә моторга күкрәге белән капланды да башы белән суга чумды.

Бу көтелмәгән хәл көймәдәгеләрне өнсез итте, бик нык каушатты. Мөхәммәт, шырыйлап кычкырып, әтисен коткарырга дип, көймә кырыена менеп атлангач кына аңнарына килделәр. Хуҗа кеше малайны кырыйдан каерып алды, аның ярдәмчесе белән көймәче карт Мөхәммәтнең әтисенә көймәгә менергә булыштылар.

Көймәче карт, ишкәкләрне алып, ике якка беркетте. Бары капчыклы карт кына, капчыгын тез өстенә утыртып, берни булмагандай, ирен читләре белән елмаеп утыра бирде.

— Синең нигезең монда иеме әллә? — дип сорады ул, беркавымнан Мөхәммәтнең әтисеннән.

— Нинди нигез?

— Авылың, дим, шушы урында ие мәллә? — диде капчыклы карт, суга таба ымлап.

Мөхәммәтнең әтисе су астында калган элекке авылының кайда икәнлеген тәгаен генә белми иде, күрәсең, иңбашларын гына сикертеп куйды.

— Алай... — дип сузды капчыклы карт. — Нигез чакыра микән әллә дигән ием.

Мулла бабай көймә төбенә тезләнеп күзләрен күккә төбәде, авыз эченнән медер-медер дога укырга кереште.

— Нишлисең, Алла ялчысы! Безне кемнәргә санныйсың син! Тукта! — дип җикеренде Хуҗа, аннары, борылып, ачу белән суга төкерде.

— Мулла бабай бит ул! Мулла бабай! — диде Мөхәммәтнең әтисе, исем кушучы бабайның бу кыланышын акларга теләгәндәй.

— Мулла?! Нинди мулла ул? Нинди мулла ди ул безнең заманда? — Хуҗа бу сүзләрен баягы шикелле кычкырынып та, җикеренеп тә әйтмәде. — Мулла булса, намазлыгында гына утырсын. Ниемә дип йөри ул?

— Минем малайга исем кушарга бара ул. Мин алып кайтып барам аны, — диде Мөхәммәтнең әтисе, төп гаепнең үзендә икәнлеген Хуҗага аңлатмакчы булып.

— Син коммунистмы?

— Кандидат, — диде Мөхәммәтнең әтисе, кыюсыз гына.

— Һе... Кандидат. Бер кесәңдә Коръән, икенчесендә партбилет йөртергә уйлаган идеңме? Кайтуга кандидатлыктан чыгарга гариза язган бул! Алайса, сине партиягә алган кеше үз партбилетыннан колак кагачак! Аңладыңмы?

«Аңладым. Анысы синең эш, теләсә ни кыл. Барыбер үз теләгем белән кермәгән ием. Түлке миңа яңа трактор гына бирдерттер, — дип уйлады Мөхәммәтнең әтисе. Аннары: — Ай-һай! Яңа тракторны бирмәс бу адәм!» — дип офтанды.

Хуҗа аңа кырын күз белән генә карап куйды. Мөхәммәтнең әтисе бу караштан куырылып килде. Әтисен җылытыйм дип, нечкә беләкләре белән аның муеныннан кочаклаган Мөхәммәт суга чыланган тәндә җиңелчә генә дерелдәү тойды.

Үз карашының тәэсирен Хуҗа да яхшы күрде.

— Йә ярый, туңасың, җылын бераз, әнә кулыңа ишкәкләрне ал, — диде ул һәм күн тужуркасын салып Мөхәммәтнең әтисенә сузды: — Мә, ки моны.

Хуҗаның «ярый» дип ни турында әйткәнлеген Мөхәммәтнең әтисе төшенеп җитмәде, кайтарып сорарга исә уңайсыз иде. Ул эчтән генә үзен мулла артыннан чыгарып җибәргән хатынын орышты. Исем кушарга кирәк, имеш. Исеме бар бит инде аның, акка кара белән язылган!..

Ишкәк белән генә ишеп тә җитәкчеләр килгәнче аргы якка чыгып җитеп була иде әле. Шуңа күрә Хуҗа тыныч. Мулла бабайга да бүтән бәйләнми, — ишкәк көенә барган көймәнең акрынаюына гына бераз эче поша бугай, — ара-тирә Мөхәммәтнең әтисенә күз төшереп ала. Һәр караш саен, көймә кызулангандай итә кебек.

Мулла бабай медер-медер капчыклы карт белән сөйләшә, дөресрәге, үзе генә сөйли. Капчыклы аны тыныч кына тыңлап утыра.

— Инешләр елгага, елгалар диңгезгә әверелә. Җир өстен су баса, коры җир тарая. Дөнья имансыз бәндәләр белән тулды. Алланы санга алучы, аннан куркучы кеше калмады.

— Әһе, — ди капчыклы карт, аның сүзләре белән килешкәнлеген аңлатып.

«Ә мин Алладан куркаммы соң?» — дип уйлый Мөхәммәт атлы малай.

— Адәмнәрнең табыныр нәрсәләре калмады, шуңа күрә халык бозылды хәзер. Ата-бабасының каберен җуйган кеше ничек итеп иртәгәге көне турында уйлый алсын инде. Нигезләрне, каберлекләрне су юып алып китте.

— Әһе, әһе! — диде капчыклы карт бу юлы.

Мулла бабайның сүзләре көймәдәгеләрнең һәммәсенә дә ишетелгән икән. Хуҗа аңа таба караган килеш урынында кымшанып куйды һәм:

— Их, бабай, бабакай! — дип мыскыллы көлемсерәде. Аның аскы ирене бер якка тартышып куйды. «Бетте! Эләгәчәк хәзер бу картка!» — дип куркынып уйланды Хуҗаның гадәтләрен яхшы үзләштергән ярдәмче. Әйе, аскы ирененең чалшаюы юньлегә түгел икәнен белә иде ул. Ләкин Хуҗа беренче мәртәбә үзенең гадәтенә каршы барды: җикеренмәде, кычкырмады, өстәл сукмады. Күрәсең, мулла бабайның томаналыгы аның күңеленә чынлап тигән иде, ул үзе инанган нәрсәгә шушы картның да ышануын, аның катып калган фикерләрен җебетергә тели иде. Шуңа күрә менә-менә чыгырдан чыгам дигәндә генә, холкының дилбегәсен тарта төшеп, сүзен тыныч кына дәвам итте:

— Инде җитмеш ел яңа тормышта, яңа заманда яшибез ләбаса! Нүжәли синең башыңа һаман барып җитә алмый. Алла дисең, иман дисең... Нигә без әллә нинди юк Аллага ышанып, булмаган нәрсәгә табынып яшәргә тиеш ди. Дураклар што ли! Җиргә кеше үзе Хуҗа. Алла — без ул, кеше үзе Алла, беләсең килсә!

— Тфү! Кит, кяфер! Авызыңнан җил алсын...

Мулла бабайның тавышы бик зәгыйфь чыкты, аның гәүдәсе бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калды. Әзмәвер яшь ир каршында ул тагын да бәләкәйрәк күренә иде. Йөзәрләгән кешелек зур залларда утлы чыгышлар ясап, аларның дәррәү кул чапканнарына күнегеп беткән Хуҗа иренеп кенә елмайды да дәвам итте:

— Син бераз аңлап калмассың микән дип кенә сөйләвем, бабакай, ачуланма. Менә мин, мәсәлән, үземә-үзем Алла. Шулай булмаса, казлар гына коена торган елгадан шушындый диңгез эшли алыр идекмени? Теге чаклардагы чыра яктысы, сукыр лампа яктысы синең күзеңне бетергән, күрмисең син, менә шул! Иман дисең, минем иманның нәрсә икәнен әйтимме соң (Хуҗа, ике кулын да җәеп җибәреп, Зур Суга күрсәтте)? Менә шушы минем иман! Монда минем хезмәтем, йокысыз төннәрем! Шушы Зур Су кешеләр өчен, менә синең өчен кирәк! Ә син Алла, Алла дип сөйләнәсең... Аллаң алай бик тә кодрәтле икән, монда инеш түгел, Зур Су ясаган булыр иде. Бу эшне безгә калдырмас иде.

Мулла бабайның күзләре зур булып ачылган иде. Ул көймә төбенә тезләнде дә ашыга-ашыга дога укырга кереште.

— Кяфер! Имансыз икәнсең!

Хуҗа тагын көлеп җибәрде, көймәдәгеләргә күз ташлады. Әмма бу юлы нигәдер аңа кушылып көлүче булмады. Карт белән сүз көрәштерү Хуҗаның үзенә дә ошамый иде. Ул үзенең ваклануын тойды. Бер аягы гүрдә торган карт белән мәктәп баласы кебек бәхәскә керү аның өчен килешә торган гамәл түгел. Хуҗа моны яхшы сизде. Гаепле икәнлеген тойган чакларда гел нинди дә булса аклану эзләргә гадәтләнгән бу кеше, кәефе шактый ук кырылса да, гадәтенә тугры булып калды: «Бу очракта мин дәшми калырга тиеш түгел идем бит. Коммунист буларак та, җитәкче буларак та... Әйе, дәшми калырга тиеш түгел идем мин. Минем үз иманым, минем үз хакыйкатем бар ләбаса. Үземнеке генә түгел, миллионнарныкы...»

Җил исеп куйды. Көймәгә бәрелеп югары сикергән су тамчылары аның хакыйкате булган Зур Суның берничә тамчысы Хуҗаның битенә кунды. Шәлперәйгән карт белән сүз көрәштереп

утыруына әле һаман эче пошса да, салкын тамчылар аның кызган йөзенә рәхәтлек бирде, кәефен күтәреп җибәрде.

Бу вакытта Мөхәммәт атлы малайның да үз уйлары иде. Өлкәннәрдән күргән-ишеткән һәрнәрсәне үз иләгеннән чыгарып, шулардан үзе өчен дә сөземтә табарга яраткан бу хыялый малай үзенең иманы бармы-юкмы икәнлеге турында баш ватты. Ул моның ни икәнен бигүк аңламаса да, күңеле белән тоя, сизә, аны аңларга азаплана иде. Нәрсә икән соң аның иманы? Тапты... тапты! Ул велосипед турында хыяллана, шул хакта бик еш уйлый. Ә этисе һаман алып бирми дә бирми. Тагынмы? Энесе тизрәк үсеп җитсен дә, бергәләшеп менә бу Зур Суга балыкка йөрерләр иде.

Мөхәммәт атлы малайның күзләре елтырап китте, ирексездән авызы ерылды. Ә менә «Хуҗа» дигән абыйның иманы, ай-һай, зур икән! Диңгез хәтле! Шушы Зур Су — минем иманым, диде бит...

Ә этисенең иманы нәрсә? Ул Су астындагы нигезләрендә бабайлардан калган бер чүлмәк алтын булырга тиеш, ди. Элек казый алмаган иде. Хәзер менә алтынны Зур Су үзе казып чыгаргандыр инде. Тик ничек төшеп аласың? Әтисенең иманы шул чүлмәк эчендә микәнни?!

«Юк! — диде аннары Мөхәммәт атлы малай, үзалдына катгый итеп. — Иман болай булмыйдыр ул! Мулла бабай аны бик зур итеп, серле итеп әйтте. Алайса, мин иманның нәрсә икәнен белмим икән».

Мөхәммәт атлы малай күңелсезләнеп Зур Су өстендә куышкан дулкыннарны күзәтергә керешге. «Хуҗа абыйның иманы барыбер зур икән шул», — дип уйлады ул.

Дулкыннар һаман чабыша. Мөхәммәт атлы малайның шуларга кушылып куышлы уйныйсы килә башлады. Дулкыннар аның өчен тере, җанлы кебек иде.

Баш өстеннән генә аргы якка таба самолет очып узды. Хуҗаның дерт итеп сискәнүеннән тагарак-көймә дә чайкалып киткәндәй булды. Ул күзләрен зур ачып ярдәмчесенә карады. Тегесе исә, «белмим шул» дигәндәй, иңбашларын сикертте. Аның карашы да самолетка төбәлгән иде.

— Турыга чыгабыз! Турыга! Турыга! — дип боерды Хуҗа. — Өлгермибез! Турыга!

Көймә борылды. Капчыклы карт тез өстендәге капчыгын күкрәгенә кысты. Аның йөрәге дөп-дөп тибә, капчык кочаклаган куллары калтырый иде. Димәк... димәк, юллары аның нигезе турысыннан узачак. Аның хыялы, сиксән ике яшьлек картның теләгәне, кереп оялаган уе, ниһаять, кабул булыр микәнни? Иншалла!

Су өстендәге дулкыннар ишәйде, көймәгә берөзлексез шап та шоп сугып торган кара сыртлы дулкыннар зурайганнан-зурайды. Бая, болар баш сөякләре аунап яткан ярдан кузгалып киткән чакта ук, Зур Су өстенә якынлашып килүче давыл турында хәбәр бар иде инде. Аны Зур Су үзе хәбәр итте. Ләкин гомерләре буе Зур Су күрмәгән, аның телен аңламаган, белмәгән картлар да, Зур Суны ясаткан Хуҗа да якынлашып килгән давыл хәбәрен аңламадылар.

Ишкәкләр һаман Мөхәммәтнең этисе кулында иде әле. Ул ара-тирә үзе янында утырган малаена күз салгалап алды. Аның беләкләре көч белән тулды, ул ашыга-ашыга иште.

— Турыга чыгарга ярамый. Анда алда чоңгыл бар. Давыл килә бугай, — диде көймәче. Бу сүзләрне әйткәндә ул ни өчендер, малай белән киңәшкәндәй, Мөхәммәткә карады.

— Турыга! — диде Хуҗа, тешләрен кысып.

Көймәдәгеләр, син әйтеп кара әле, сине тыңламас микән дигән кебек, ярдәмчегә төбәлделәр.

— Турыга кирәктер. Бәлкем, давылга кадәр чыгып җитәрбез әле. Турыга! — дип кабатлады Хуҗа.

Давыл гына түгел, тагын әллә ни кузгалса да курыкмый иде ул. Бу аның үзе ясаган суы, бу суны дөньяга ул китерде. Үз суы аны йотмаячак...

«Шөкер! Турыга...» — дип уйлады капчыклы. Аның күңеле йомшарды. Ул, калтыранган куллары белән кабалана-кабалана, капчык бавын чишеп җибәрде һәм аннан адәм башы сөяге алып Хуҗага сузды.

— Мә.

Хуҗа, чирканып, артка тайпылды:

— Кит! Миңа ниемә ул! Нәрсә ул?!

— Атаң башы...

Картның үзенчә яхшылык кылуы иде бу. Көймәдәгеләр, куркуларын да онытып, карт белән Хуҗага төбәлделәр.

— Исәр, шашкан карт!!!

— Юк, энем. Үз акылымда мин. Чынлап та, синең атаңның башы бу. Кормашныкы бит син, Галиулла малае, ялгышмасам, — диде карт һәм суга таба күрсәтте. — Сезнең авыл менә бу ту-

рыда иде. Әтиең урман каравылчысы иде. Башына атып үтерделәр. Гәүдәсен урманда без таптык аның. Менә маңгаендагы чокырларны күрәсеңме? Җәдрә тишекләре.

Көймәдәгеләрнең колаклары үрә торды. Хуҗаның йөзе каралып чыкты. Ул берара әйтәсе сүзен дә әйтә алмыйча утырды, аннары капылт кына урыныннан торып, карт кулындагы баш сөяген үзенә алды. Хуҗа бер мизгелгә югалып калды, гадәттә, боз төймәгә охшаган соргылт күзләре аз гына вакытка бөтенләй үзгәргән шикелле булып, гөнаһсыз сабый малайныкына охшап калды. Аның бу халәтен капчыклы карттан кала берәү дә күреп өлгермәде, чөнки аларның карашлары Хуҗа кулындагы баш сөягендә иде.

Яшен уты кабынып сүнәрлек вакыт арасы узды микән, аның күзләрендәге малайлык сүнеп юкка чыкты, һәм алардан тагын бакыр салкынлыгы сирпелә башлады. Капчыклы карт әлеге яктырып алган күз карашыннан элекке танышы Галиулланы танып калган иде...

Сүз-кыяфәте белән йөзләрчә кешене сәгатьләр буе тын да алдырмый тотып торырга сәләтле Хуҗа берничә мизгелгә үз халәтенә хуҗа була алмады...

Ул баш сөяген ачу белән дулкыннар арасына томырды...

— Тфү! Черт! Шашкан карт!

Көчәя барган дулкыннар бу сүзләрне үз кочагына суырып алдылар да аннары кире өскә чөеп җибәрделәр, кайтаваз тонык кына булып ишетелде:

— Шашкан... ш-ш-ш-ш-аш-ш-ш-ка-а-а-а-н...

— Шашкан! — дип кабатлады Зур Су хасил итәм дип маңгай чәчләре пеләшләнгән Хуҗа.

Көймәгә зур-зур дулкыннар килеп орды. Көймә бала бишегедәй чайкалырга, тирбәнергә керәште.

Мөхәммәтнең этисе арыды, талчыкты, әмма ишкәкләрне кулыннан ычкындырмады. Ләкин монда көч кенә түгел, осталык, Зур Суда зур осталык та кирәк иде. Көймәче ишкәкләрне үзенә алды, гомер иткән чал картның Зур Суда берьеллык кына булса да тәҗрибәсе бар иде. Мөхәммәтнең этисе малаен кочагына алды һәм, котыласыларына ышаныр-ышанмас, аргы ярга төбәлде. Яр буе күренми, алгы ярда пәри туе, ярны тузан болыты баскан иде...

Мулла бабай, көймә төбенә тезләнеп, Алладан ярдәм сорый. Ике кулын да күккә сузганлыктан көймә чайкалганда ул егылып китә, башы белән көймә кырыена бәрелә. Мөхәммәтнең этисе икенче кулы белән аның чабуыннан тотып, егылудан сакларга тырыша.

— Баягы сүзләрең Ходайга барып иреште! Синең аркада гына бу! — ди кинәт Мулла бабай. — Ярлыка, диген! Нәзер әйт!

Ул моны Хуҗага карап әйтмәсә дә, кемгә ишарәләгәне барысына да аңлашыла иде.

— Алга! Турыга! — ди Хуҗа ярсып.

«Ходайдан гафу сора!» — дип уйлый Мөхәммәтнең этисе эчтән генә.

«Карышма инде, мәлгунь!» — дип уйлый көймәче карт.

— Нигез кычкыра! — ди капчыгын кысып тоткан карт.

— Алга! Турыга!

— Иманың юк синең! — ди Мулла бабай. — Гафу сора!

— Синең ул гафуың белән генә котылып булыр дип беләсеңме әллә, алланың кашка тәкәсе! — дип җикеренде Хуҗа һәм ишкәкчене читкә этәреп, аның урынына үзе утырды. — Көч кирәк монда, баш кирәк бу афәттән котылу өчен!

Ул каерып-каерып ишә башлады. Көймә бераз тынычлангандай булды.

— Нигез кычкыра! Нигез чакыра! — диде капчыклы карт.— Аның элекке авылы нәкъ чоңгыл турысында иде.

Давыл озаклап кузгалды. Әйтерсең күптән түгел генә хасил булган Зур Суга давыл да җайлашып, ияләшеп җитә алмый иде әле. Зур Суның да давылны кабул итәргә тәҗрибәсе аз, ул аңа бик озаклап, акрынлап әзерләнә иде.

Ишелеп-ишелеп килгән дулкыннар көймәне йомычка урынына чөеп йөртә башлады. Көймәче карт Хуҗа кулындагы ишкәкләрне тартып диярлек алды, үзенең бу кыланышын аклагандай:

— Дулкынга борыны белән тотарга кирәк, борыны белән! — дип кычкырды.

Котылуга әллә ни ышаныч күренми иде. Көймә чоңгылга килеп керде һәм, шырпы тартмасы кебек, бер урында әйләнергә кереште. Ишкәкләргә Мөхәммәтнең этисе утырды. Әмма йомычка урынына бөтерелгән тагарак-көймә ишкәкләрне генә санларлык түгел иде инде.

— Ходайның ярлыкавын сора! — диде Мулла бабай.

— Тыңла сүзне! — дип кычкырды көймәче карт.

Бу вакытта аның бәләкәй гәүдәсе зураеп киткәндәй булды, әзмәвер кебек Хуҗа, киресенчә, кечерәеп, бөрешеп калды.

Капчыклы карт, көймә кырыена тотынып, аягына торып басты да, айкала-айкала, койрык турысына китте, һәм шактый авыр капчыгының бавын җәһәт кенә муенына элде дә суга егылып төште. Көймәче авызын ачкан килеш катып калды.

— Нигез кычкыра! — диде көймәне йомычка урынына йөрткән дулкыннар.

Бу хәлне үз күзләре белән күреп торсалар да, көймәдәгеләр берни кыла алмадылар.

— Коткарыйк! — дип кычкырды, ниһаять, һушына килгән Хуҗа.

Ул үзе йөзә белми иде.

Зур Суда йөзәргә өйрәнмәгән иде ул...

— Файдасыз! — дип кычкырды көймәче. Дулкыннар шавы арасыннан бу тавыш тагын да дәһшәтле, куркыныч булып ишетелде. — Коткарырга кирәкми аны! Ул үзе котылды инде! Соң инде, соң! Капчыгында таш иде аның! Мин беләм...

Көймәгә таба тагын да зуррак дулкыннар килергә тотынды. Көймәгә су керә башлады. Ике куллап көймә кырыена ябышкан Хуҗа чытырдатып күзләрен йомды. «Йа Хода!» — дип авыр көрсенде ул. Һәм шулчак күзәнәкләре аша нидер, суырылып чыгып, күккә ашкандай тоелды. Аның гәүдәсе дер-дер калтырарга кереште, ул туңа башлады — гүя тәнендәге җылысы аны ташлап чыккан иде. Бу сәер халәттән аерылып, дөньялыкка кайтасы килде, күзен ачмакчы булды... Юк... Үлем шулай көтмәгәндә, гади генә килергә тиеш түгел, түгел иде. Тик әнә ул якынлаша бугай... Әнә... куллары, аяклары... башы шыр сөяктән генә икән. Хуҗа үзен инде үлгән итеп тойды. Ләкин үлгән кеше уйлый алмый... Ә ул бит әле уйлый, димәк, ул исән. «Ю-ю-юк!!! Үләсе килми... килми-и-и-и!!! Коткарыгыз мине! Кем?.. Кем?! Кем коткара ала мине!!! Коткара күр, зинһар!!! Син!!! Син генә!!! Бирмә! Бирмә бу Суга мине! Бары син генә коткара аласың! Көчле, диләр, кодрәтле, диләр бит сине!!! Йа Хода! Ярдәм сорыйм синнән! Үләсем килми бит минем! Алла, Аллам... бисмилләһи-ррахмани...» Ул Аллага ничек мөрәҗәгать итәсен белми иде. Шуңа күрә бертуктаусыз: «Аллам, Аллам!» — дип кабатлады. Бу изге сүз аны коткарачак, бары шушы сүз генә аны үлем авызыннан йолып калыр сыман иде. Тик... тик... кабул булсын өчен, кычкырып әйтергә кирәктер аны:

— Йа Хода! Ярлыка син минем гөнаһлы җанымны!!!

Ул, ниһаять, күзләрен ачты, күзләрен зур итеп ачып күккә төбәлде. Аларның баш өстендә генә мотор гөрелтесе ишетелде. Ул янә, ашыга-ашыга:

— Аллам, Аллам! — дип кабатлады.

Мөхәммәтнең этисе ишкәкләр белән дулкыннарга каршы көрәште. Дулкын таулары тагаракны көймәне чоңгылдан этеп чыгардылар да аннары кинәт кенә юашланып калдылар. Мөхәммәтнең этисе каерып-каерып иште, көймә күндәмләнде, ишкәкләрне тыңлый башлады. Ләкин әле бу котылу түгел иде...

Шулай да көймәдәгеләр җиңел сулыш алдылар, чөнки ярдагы тузан болыты басылып, яр буйлары ачык шәйләнә иде инде. Җирне күргәч, бүтәннәр кебек шатланасы урынга, Хуҗаның гадәттәге кызыллыгы кайта башлаган йөзе янә кара коелды. Алда — яр буе, алда Зур Су өстендә купкан давылдан котылу иде. Маңгай чәче пеләшләнгән башын кара кайгыга шул салды. Бетте! Моннан соң бар да бетте! Инде кеше булдым, гомер буе барган максатка менә-менә ирешәм дип кенә торганда! Аны җиргә аяк басуга (ярдәмчесенең ярдәме белән) урыныннан алып ташлаячаклар! Аллага табына, Ходайга ышана торган коммунист җитәкче!.. Их син, Зур Су, йотмадың да ичмаса! Хурлыгы булмас иде!..

Зур Су көймәне һаман тирбәтә бирде... Күңелләр болгана, башлар әйләнә... Хуҗа тагын күзләрен йомды. Әлеге хурлыклы хәбәр әллә кайчан кайтып җитеп партбилетыннан, яраткан эшеннән, яшәеш рәвешеннән колак кактырырга әзерләнеп торалардыр шикелле тоелды — ул, куркып, күзләрен ачты.

Зур Суның дулкыннары шап та шоп көймәгә кага. Аның хәлен аңламый, мыскыл итә кебек Зур Су! «Тукта! Ашыкмагыз! Тотыгыз капчыгыгызны, яме!!!» — дип тешләрен кысты Хуҗа. Аннары кинәт айнып киткәндәй: «Карале, мине шул сүз өчен урынымнан алып ташлаячаклармы? Минеме?.. Туктале... Мин Аллага ышанмый идем ич! Алайса, ник бая ышандым икән соң? Хәер, ышандыммы соң? Ие... Әллә...»

Хуҗа кистереп уйларга да җөрьәт итмәде. Чөнки алар әле һаман су өстендә иде... Ул бары кемгәдер янагандай, эченнән: «Тотыгыз капчыгыгызны!» — дип кенә куйды.

Мөхәммәтнең этисе һаман дулкыннар белән көрәшә. Ярга якынлашкан саен, дулкыннар вагая бара, ләкин алар барыбер ишле һәм көчле әле.

Мулла бабай һаман Ходайдан коткаруын үтенә.

— Син, син! Син, белә торып, кеше кадәр кешенең суга сикерүенә юл куйдыңмы?!! — дип җикеренде Хуҗа көймәче картка.

Хуҗаның тавышы бик көр чыкты. Чөнки бу вакыйга, капчыклы картның су астына китүе, акланырдай бердәнбер ышанычы иде. Бу вакыйга калганнарын күмеп, каплап китәрлек зур хәл иде...

Көймәченең әллә ни исе китмәде. Әлеге сүзләрне ишетмәгән дә кебек иде ул. Дулкыннар тавышы белән әллә чынлап та ишетмәде инде? Әллә юри ишетмәгәнгә салышамы? Хуҗа тагын телгә килде:

— Аның үлемендә син гаепле!

Ишеткән икән көймәче карт, әнә акрын гына башын Хуҗага таба борды.

— Аны Зур Су үтерде, — диде ул, кипкән иреннәрен ялап, һәм: — Ул авыл зиратында үзенә урын сайлаган булган, шунда китеп барды, — дип өстәде. Әйтерсең кеше кадәр кеше үлеме турында түгел, һава хәлләре хакында сөйләшә иде.

— Син! Белә торып!

Мөхәммәт атлы малайга көймәче кызганыч булып китте. Чарасыз, мескен бер картка охшап калган иде ул бу минутта.

— Теге баш сөяге чынлап та синең атаңның башы иде ул, энем, — диде карт, тыныч кына. Әйтерсең ниндидер бер уенчык хакында сүз бара.

— Син җаваплылыктан котылмакчы буласыңмы, карт шайтан!

— Җиргә алып чыгып күмәргә иде атаң башын, улым. Мин үземнекеләрнең сөякләрен яр буйлап күпме эзлим инде, һаман таба алганым юк. Ә син кулыңа тоттырганны кире суга ташладың. Әй энем, энем.

— Ә синең башың барыбер төрмәдә чериячәк!

— Мин инде әллә кайчан, әле су астында калганчы, зиратыбызда карчыгым янында урын алып куйган идем. Су басты бит, каһәр, шуңа күрә үлә алмыйча йөрим. Бу Зур Су китмәсме икән моннан, ә!..

Көймәче карт шаяртмый иде, аның кысылган күзләреннән ике генә бөртек яшь тамчысы саркып чыкты да битендәге җыерчыклар арасына кереп күмелде.

Мөхәммәтнең әтисе, көймәне тизрәк бу Зур Су кочагыннан коткарырга теләгәндәй, көчәнеп-көчәнеп иште. Тагарак-көймә, кара сыртлы дулкыннар өстендә бала бишегедәй тирбәлә-тирбәлә, Зур Җиргә таба йөзде.

Мулла бабай, көймә төбендә утырганлыктан, Җирне күрмәгән икән — күргәч, янәшәсендәге Мөхәммәтнең башыннан сыйпады һәм калтыранган тавышы белән:

— Бәхетең бар икән, балакай. Аллаһы Тәгалә син гөнаһсыз сабый хакына коткарды безне, — диде.

Хуҗа боларның берсенә дә игътибар итмәде. Ул, гасабиланып, иреннәрен чәйни, саркып чыккан канны ачу белән әледән-әле суга төкерә иде. Ярдәмчесе дә дәшми ичмаса, авызына су капкандай тик утыра. Мөгаен, эчтән генә тантана итә торгандыр. Хәзер Хуҗаның дилбегәсе аның кулында бит...

Көймә борыны яр кырыена килеп бәрелде.

Мөхәммәтнең әтисе әүвәл улын, аннары аяк буыннары сыекланган Мулла бабайны җиргә төшерде. Көймәдә көймәче карт ялгызы гына утырып калды.

Җиргә аяк басуга, алдан сүз куешкандай, борылып, барысы да Зур Су өстендә биешкән дулкыннарга күз ташладылар. Баягы куркулар, бугаздан ала язган һәлакәт Зур Су уртасында калды, аларның һәммәсен дә Зур Су үзенә йотты.

Хуҗа Мөхәммәт атлы малайның башына кулын куйды да, барысына да ишетелерлек итеп:

— Ну, энекәш, синең хакка хәтта абзыйларың да Аллага мөрәҗәгать иткән булып шаяртты, ә! — диде һәм көчәнеп көлергә кереште. Аңа кушылучы булмады.

Мөхәммәтнең әтисе көймәче картка:

— Давыл тына хәзер. Чоңгылны әйләнеп уз! — дип кычкырды.

Көймәче кулын гына селтәде:

— Минем авыл да чоңгыл турысында бит! — дип, әллә шаяртып, әллә чынлап җавап кайтарды.

Хуҗа, эре адымнар белән җиргә нык басып, үзен көтеп торган машинага таба китте. Күктә самолет тавышы ишетелде. Мотор гөрелтесен дә басып яр кырыена кара кыртлы дулкыннар шап-шоп бәрелә иде.

Мөхәммәтнең әтисе, малаен җитәкләп, Мулла бабайны култыклаган килеш берара җир киткәч, Зур Суга таба әйләнеп карады.

Ярдан ераклашкан көймә артыннан, зәңгәр утларын балкытып, сары билле моторлы көймә томырыла иде.

Дулкыннар һаман тынычлана алмый әле, алар һаман дәррәү ярга ташланалар, һәр яңа дулкын өере килеп орынган саен, комлы яр сыкранып-сызланып кына артка чигенәдер, дулкыннар аны авызларын чапылдата-чапылдата, кабаланмыйча, түмен белеп кенә ашыйлар, кимерәләрдер шикелле...

# ЭЧТӘЛЕК

**Роман-дилогия**

Терсәк сугышы. Беренче китап
Эттән туган. Икенче китап

**Повесть**

Кәҗә йөри кыектан

**Хикәяләр**

Кышлаган үгез
Айның туган-тумачасы юк
Мич башында күргән төш
Ак болыт күләгәсе
Кичү

Литературно-художественное издание

(Зиннур Хуснияр)
Хуснутдинов Зиннур Зиятдинович

**Сукин сын**

Роман-дилогия, повесть, рассказы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Д.Л.Нәүрузова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова,*
*Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.05.2005.
Форматы 84X108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Mysl» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 20,79. Нәшер-хисап табагы 21,63 + форз. 0,36. Тиражы 3000. Заказ А-361.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

ААҖ Идел-Пресс нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.